## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

# БЕЗНЕҢ КӨННӘР

## I
## КУРКЫНЫЧ КИЛӘ

Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез түбәндә кемгәдер ачу белән үкеренә. Аның куәтле дулкыннары тау-тау булып биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагы бер-ике тапкыр ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр. Ләкин сезгә куркыныч юк. Дулкын ничаклы каты булса да, ул сезнең биек тау итәгендәге урыныгызга килеп җитә алмаячак. Сезгә тыныч булырга, тәрәзәләрегезне ачып, диңгез тавышын тыңларга да аннан соң рәхәт-рәхәт тагы йокыгызга чумарга мөмкин.

Олы Русия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары да илнең караңгы почмакларында яшәгән халыкларның кайбер караңгы катлауларына баштарак менә шулай булып тоелды.

Кайдадыр хөкүмәт белән эшчеләр сугышалар... Кайдадыр, урамнарда баррикадалар ясала, киң мәйданнар адәм үлекләре белән тулалар... Кан дәрья булып ага... Ләкин болар кайдадыр еракта... Монда тик аның куәтле шаулавы гына килә, шуңардан йөрәккә бераз шом төшә. Тик шул гына. Әмма дулкын үзе килеп җитә алмаячак. Халыкка тыныч булырга, тарих буенча килгән иске тормышын элеккечә алып бара бирергә мөмкин. Һәм шулай мондагы тормыш үзенең борынгы эзеннән акрын гына ага тора.

Тик менә көннән-көн каралана барган имеш-мимеш сүзләр генә, ничектер, җанны азрак борчыйлар, хыялга куркыныч сурәтләр китереп, йөрәккә шом салалар.

Башта ул дулкын бер дә искитәрлек нәрсә түгел кебек иде. Ниндидер студентлар, укып-укып, эшкә аша алмаганнар да инде шуның ачуыннан фитнә чыгарып йөриләр. Бу болай бик гади хәл төсле иде... Ләкин шомлы сүзләр моның белән генә бетмәделәр, күңелсез хәбәрләр, барган саен таралып, халык хыялындагы куркынычларны зурайта, кабарта бардылар: имеш, менә шулай кояш батышыннан күтәрелгән кара болыт тиз арада бөтен күк йөзен каплап алачак та, коточыргыч күкрәүләр, утлы яшеннәр уены башланачак; имеш, дөньяның асты өскә киләчәк.

Элек, азгын студентлар, диләр иде. Бара торгач, тагын бөтенләй яңа бер төркем кешеләр пәйда булдылар. Ничек атыйлар шунда үзләрен?.. Социалистмы, кемме, диләр. Боларның бер кулларында – озын таяк башына беркетелгән кызыл байрак,! Менә бер заман патша торган башкалада

эшчеләр кузгала, дөньяга эш икенче кулларында – җәһәннәм машинасы кебек яман куркыныч кораллар ташлау дигән яңа бер сүз туа, заводлар, фабрикалар ябыла, тимер юллар туктый. Кешеләр барам дигән җиренә бара алмый, кайтам дигән иленә кайта алмый, әллә нинди чит-ят станцияләрдә ярты юлда калалар.

Ул арада дулкын авылларга да барып җитә башлый: кичә үзенең күрше бояры алдына егылып баш орган крәстиәннәр бүген шул алпавытның җирен талыйлар, урманын кисәләр, бай, матур имениеләрен яндыралар. Кичә тыныч йокыда яткан шәһәр өстендә бүген бомба, мылтык, пулемет тавышлары гөрлиләр. Бер көн губернаторга, иртәгесен министрга, полицмейстерга ташланган бомбаларның шартлаулары тын урамнарны туктаусыз яңгырата торалар. Талаулар гади бернәрсәгә әйләнә. Бүген почтадан йөз меңне басып алалар, иртәгә банктан ярым миллион алтынны кораллы отрядлар кереп алып чыгып китәләр. Хөкүмәтнең башы әйләнә; ул, төрле яктан кысрыкланган ерткыч бүре кебек, үзенең гаскәре, полициясе, жандармериясе белән бертуктаусыз дулкыннарның өстенә ташлана. Зинданнар яңа тоткыннар белән тулалар, крәстиән яланнары, завод-фабрика урамнары үлекләр белән каплана, кан дәрья булып таша; караңгы төннәрдә, биек таш кирпеч койма белән чолганган тар, ябык мәйданнарда, шомлы төскә уралып, күккә таба сузылган үлем баганалары белән кызыл якалы, иблис йөзле палачлар үзләренең корбаннарын көтәләр. Көрәш кыза, тирәнәя, көрәш язгы ташкындай ашкынып зурая, җәелә бара.

## II
## КЯФЕР ҮЗАРА СУГЫША

Ул көннәр вакыйгаларның яшен тизлеге белән кайнашып аккан чаклары иде. Кинәт дулкын якынайгандай булды. Яшен күз алдында ялтырана башлады. Кайдадыр еракта кебек күренгән, монда килеп җитмәстәй тоелган кара, куркыныч көрәш чаткылары баш очында уйнаган кебек сизелеп китте. Үз түбәсендә кара болытның куерганын, яшен ялкыннары уйнавын күргәч, татарның авыр йокылы караңгы катламы да сискәнде.

Чү! Бу ни хәл тагын? Йа Ходай, әллә безгә дә килеп җитәләрме?

Җитәләр! Җитәләр! Дулкын бу шәһәрне, бу урамнарны да баса. Үзе әллә кайда еракта шаулап, монда тик куркыныч сурәте генә хыялда торган революция аждаһасы боларга таба ташлана, боларны да йотарга якынлаша.

Калада нindидер ят-чит адәмнәр күргәннәр. Һәркөн шәһәрнең төрле урамнарында, базар башларында, чат буйларында күк кара белән язылган кәгазьләр табалар. Урысча, кяферчә түгел, үзебезчә, мөселманча язылган кәгазьләр табалар!

Аларда:

– Күп йокладык!

– Инде уянырга вакыт! – дип язылган, ди.

– Нинди йокы?!

– Нинди уяну?!

Боларны уйлап очына чыгарга өлгермиләр, калада яңа бер сүз туа: «Эшчеләр берегә», диләр. Урыс юк, яһүд юк, немец юк, татар юк – бары бергә, бары бер, бары бер юлда, имеш, диләр. Имеш, каланың барлык эшчеләре берләшәчәкләр икән дә, ди, җыелышып, кызыл байрак күтәреп губернатор каршысына барачаклар, нидер сораячаклар икән, ди, әгәр инде сораганнары бирелмәсә, эш ташлаячаклар имеш, ди.

– Бу нәрсә, тилелекме? Болар акылдан шашканнармы?.. Имеш, эш ташламакчылар! Барсыннар! Ташламагае, кадалып китсеннәр, муеннары асларына килсен! Дөньяда эшчедән күп нәрсә бар? Берсе ташлар – унысы килер. Байга барыбер түгелме? Тегеләр бала-чагалары белән ачтан дөмегерләр!

Шулай дип уйладылар. Ләкин вакыйгалар яшен тизлеге белән акты. Мөселман агай-эне, шулай юанып, үзенең уен тынычландырырга өлгерә алмый, шәһәрдә заводларның, фабрикаларның берәм-берәм тукталуы телгә керә. Водопровод та тукталачак икән дип, өй хатыннарының котларын очыра. Болар батманнарын, мичкә, чапчакларын, комганнарын ашыгып-ашыгып су белән тутырырга тотыналар. Электр станциясеннән дә куркыныч хәбәр килә. Икмәк пешерүчеләр дә эш ташлый икән, имеш, дигән сүз таралгач, тыныч өйләрне уттан, судан, күмәчтән берьюлы мәхрүм калу куркынычы каплый. Инде каушау көнләп түгел, сәгатьләп арта. Хәзер ышанмау да кыен. «Алар» моңарча патшадан, полициядән, жандармнан качып эшлиләр, идән астында яшиләр иде, якты дөньяда тик шул күк кара белән язылган кәгазьләре генә күренә иде. Менә өченче көн инде «үзләре» дә калкып килеп чыктылар.

Агай-эне бераз аптырап кала:

– Бу ни гаҗәп?! Бик яман сөйлиләр иде ич! Араларында болай коточарлык бер әйбер дә күренми бит! Бары да безнең кебек кешеләр! Тик бик күбәүләр, бик усаллар! Атлы казакның камчысына, солдатның мылтыгына, жандарның кылычына карамыйча, киң урамнарны иңеннән буена тутырып, ярларыннан чыккан язгы ташкын кебек дулкынланып, агылып йөриләр. Алларында кызыл байрак бара... Бара торгач, бер чатта, бер мәйданда тукталалар да араларыннан берсен югары күтәрәләр. Ул җә бер баганага, җә ике эшченең кулбашына сикереп менә дә, кулындагы байракны селкә-селкә, бөтен мәйданны яңгыратып нидер сөйли башлый, җыелган

халык аңа «ур-ра!.. ур-ра!..» кычкыра, дөнья күтәреп,ниләрдер әйтеп, кемнедер куркытырга теләгән кебек шауларга тотыналар. Талаш-кычкырыш китә; жандарлар, кемнедер тотып алмак булып, халык эченә ташланалар. Аны бирмиләр, бәрелеш, тарткалаш кузгала, мылтык тавышы күтәрелә. Атлы казачийлар шаулы, тавышлы халыкны камчылап таратырга омтылалар. Кылычлар, сөңгеләр уйный башлый. Ниләр булганын кем белсен, яралыларның исәбе-саны юк, диләр, кырыклап үлгән имеш, диләр. Якындагы ак өйләрнең кабыргалары мылтык ядрәләре белән шадраланган, җиргә түшәлгән ташлар кызыл кан белән юылган имеш, дип сөйлиләр. Менә шул кич адәм ышанмаслык хәбәр тарала:

– Шәһәрне алалар имеш, диләр.

– Кем ала?

– Кемнән ала?

– Ни өчен ала?

Күңелләрне тынычсызлаган бу сораулар җавапсыз кала. Һәммә кеше куркыныч яшен алдында була торган минутка ошаш бер хәлгә төшә. Караңгы катлау мөселман агай-эне:

– Ходаем, тагы нинди афәтләрең бар икән? Үзең сакла, илаһым! – дип, тәңрегә ялваралар.

Бу куркынычлар эчендә күңелне юатырлык бер генә нәрсә бар – ул да булса, фитнәчеләр эчендә, шул кызыл байрак тирәсендә мөселман агай-эненең күренмәве иде. Бу авыр көннәрнең куркыныч эшләре турында сөйләшкән саен:

– Кяфер үзара сугыша! – дип, кечкенә бер тыныч якны табып куялар.

Ләкин бу: «кяфер үзара сугыша» дигән юаныч үз тамырында тора алмый селкенә башлады. Һәркайда бер куркыныч хәбәр йөри. Әйтәләр: «тегеләр» күбрәк халык торган йортларга керәләр икән дә, ди, ялангач кылычларын кизәнеп-кизәнеп: «Безгә кушыласыңмы, юкмы? Кушылмасаң, хәзер башыңны чабып өзәм!» – дип, өстеңә кычкыралар имеш, ди, әгәр инде аз гына карышсаң, шунда ук үзеңне бетерәләр имеш, дип сөйлиләр.

Бу шомлы сүзләр, башка һәркемнән бигрәк, икешәр-өчәр йөз шәкерт тулып яткан кадим мәдрәсәләрне хафага сала. Һәрбер хәзрәтнең, һәрбер хәлфәнең йөрәгенә яңа кайгы, яңа курку төшә: «Мәдрәсәгә кереп, «тегеләр» көчли башласа, ни кылырбыз?!»

Саграк кешеләр саклану чарасын күрәләр. Якынрак авылдан килгән башкорт старшина улы пишкадәм[1] карт шәкерт: «Атай чирли икән! Мине

---

[1] *Пишкадәм* – мәдрәсәнең уку программасын тәмамлаганнан соң, муллалык урыны көтеп, мәдрәсәдә яшәүче шәкерт.

чакыртып язган!» – дип, авылына сыза.

Берничә казачий шәкерт: «Керсәләр, каршы торырга ярар», – дип, агасыннан үзенең күгәргән сөңгесен китертә.

Бер өлкән казый мишәр: «Саклангнанны Ходай саклар!» – дип, үзенең шикәр вата торган зур озын калын тимерен сандыгыннан чыгарып, өстәл өстенә, билгеле җиргә алып куя.

Хәлфәләр дә тик ята алмыйлар. Мәдрәсәнең җимерек агач капкасын ныгыттыралар. Ишекләргә яңа тупсалар, элдергечләр, бикләр куялар, караңгы төшүгә ишекне, капканы бикләтәләр. Мәдрәсәнең иске аксак кизүе төн йокламый каравыллап чыга.

Һәркем шулай кулыннан килгәнчә сакланган ул куркыныч көннәрдә шәһәрнең иң могътәбәр хәзрәте Вафа ахун һәр җомга саен мәчет мөнбәрендә бу фитнәләр турында үгет-нәсыйхәт, вәгазь сөйли:

– Җәмәгать, агяһ булыгыз[1]! Җир йөзе фитнә белән, фитнәчеләр белән, бәгъе вә гыйсьян әһелләре[2] белән тулды. Ислам вә Коръән исеменнән Аллаһе Тәгаләнең әмере буенча сезгә тәблигъ итәмен[3] ки, шул фитнә вә гыйсьян әһелләре арасында бер мөселманның күренүе – бөтен дөнья мөселманына йөз каралыгы булачак. Исламны сатмагыз, мөселманга йөз каралыгы булмагыз, бәгъе вә гыйсьян әһелләре, фитнә әһелләре эченә катнашмагыз, – дип, патшаның үзенең, хатынының, нәсел-нәсәбенең исәнлегенә, тәхетнең ныклыгына, аларга каршы дошман көчләрнең җимерелүенә күз яше белән дога кыйлдыра.

Алгы сафлар хәзрәт белән бергә җылыйлар, мәчеттән кипмәгән күз яше, ләкин тыныч күңел белән чыгалар. Инде афәт күтәрелде, инде куркыныч ерагайды дигәндәй бер хәлдә өйләренә кайталар.

Ләкин бу тынычлык күпкә бармый.

Шул җомга көн кич, теге кызыл байрак күтәреп йөргән фитнәчеләрнең башлыклары арасында элек яһүд байда приказчик булып торган Габдрахманны күргәннәр. Алар янында тагын яшь җилкәнчектән берничә кызыл авыз бар имеш, ди. Тик танымый калганнар. Шуның артыннан ук икенче сүз китә: әгәр чын булса, ул Габдрахман дигән кызыл авызны ике мөселман егет тар тыкрыкка чакырып керткәннәр имеш тә, ди:

– Нигә син мөселманнарга йөз каралыгы ясыйсың? – дип, канга батырганчы кыйнаганнар, ди.

Кыйнаучы егетләр үзләре, базарга төшеп, чатта җыелган агай-энегә

---

[1] *Агяһ булыгыз* – белеп торыгыз.
[2] *Бәгъе вә гыйсьян әһелләре* – бунт чыгаручы һәм баш күтәрүче кешеләр.
[3] *Тәблигъ итәмен* – белдерәм, хәбәр итәм.

мактанып сөйләгәннәр, ди.

– Бирдек малайга кирәген, дип әйтәләр, ди. Малаең изрәп төште: үтермәгез, абзыкайларым, моннан соң якын бармам, башы-ахыры шул булыр, дип җылый-җылый тәүбәгә килде, дип әйтәләр, ди.

Күп көлкеләргә уралып йөргән бу җуанычлы хәбәр татар урамнарын әйләнеп чыгарга өлгерә алмый, тагы яңа вакыйгалар! Инде бусы яһүдтә торучы приказчик белән түгел, саф үз агай-эне хәле белән бәйләнә:

– Имеш, шәһәрнең зур сәүдәгәре Кадыйр байның унике приказчигы баш күтәргәннәр, ди. Боларны кызылланганнар дип аптырап, кызганып, ачуланып сөйлиләр. Шуларга тоташып, мәдрәсәдә дулкын кайнап китә. Әйтәләр: Мәдрәсәи исламия шәкертләре арасында остазларына каршы көрәш башланган икән, диләр:

– Имеш, ике йөз шәкерт, кул куеп, Гали мөдәррискә[1] гариза биргәннәр, ди. Нindидер ислахлар[2] сорыйлар, ди. Кайбер китапларны ташлыйлар, берничә карт хәлфәне куып чыгаралар, безгә урысныкы булсын, схоластика бетсен дип әйтәләр имеш, ди. Бер атна вакыт куйганнар, әгәр шул вакыт эчендә сораганнары үтәлмәсә, тәрәзә ватып, таш стена җимереп, җыр җырлап чыгып китмәкчеләр, ди.

Башта шулай Кадыйр бай приказчиклары белән Мәдрәсәи исламия шәкертләре тирәсендә кайнаган бу сүзләр тиз арада бик тиз җәелеп тә киттеләр, үстеләр, кабардылар.

– Юк! Фитнәнең башы гына бу! Кадыйрныкылар, Галинекеләр ялгыз түгел! Начар чир тиз йогучан. Хәзер инде приказчиклар «Үзара ярдәм» исемендә яшерен җәмгыять ясаганнар, ди. Шуңа акча җыялар, ди. Хәзер Кадыйр байны ташлап чыккан унике янына Ибрай байныкы, Салахи хаҗи, Зәңгәр Вәли, Чатан Садри, Гариф солдат, Ашыт Нигъмәтләрнең приказчиклары да кушылган, ди. Алар хәзер барлыгы берләшәчәкләр икән дә, ди, байларына язып бирәчәкләр, ди:

– Безгә эш вакыты сигез сәгать булсын!.. Хезмәт хакы арттырылсын!.. Приказчиклар белән адәм кебек мөгамәлә кылынсын! – дип әйтәчәкләр; әгәр дә инде сораганнарын байлар бирмәсә, урыннарын ташлап чыгачаклар имеш, ди.

Шәкерт чуалышы да шуңа килеп өстәлде.

– Галинекеләр ялгыз бармый икән. Алар хәзер үз якларына тагы дүрт мәдрәсәне тартканнар, ди. Берләшеп, «Ислахчы шәкерт» исеме белән яшерен җәмгыять төзиләр, шунда үз яклы шәкертләрне кертәләр, аннан барлыгы бер

---

[1] *Мөдәррискә* – мәдрәсәдә өлкән укытучыга.
[2] *Ислахлар* – реформалар.

булып, эшкә тотыналар, ди:

– Мәдрәсәләргә яңа тәртип кертелсен. Мантыйк[1], схоластика ташлансын! Европа фәннәре – тарихлар, җәгъракфияләр, һәндәсәләр[2], химияләр укылсын! Урыс теле мөкәммәл[3] булсын! Фөнуне җәдидә[4], рәдде нәсара[5], тәфсир[6], хәдис[7], әдәбият дәресләре програмда булсын! – дип, гариза бирәчәкләр. Әгәр инде мөдәррисләре бу теләкләрне кабул кылмаса, дүрт-биш мәдрәсәнең шәкерте барлыгы бергә уку ташлаячаклар, ди.

– Кяфер үзара сугыша! – дип, бер читтә үзенең борынгы гадәте, тормышы эчендә элеккечә яшәп баруны өмит иткән иске катлам мөселман агай-эне дә дулкынның үз эчләренә килеп керүеннән ачу катнаш аптыраулы хәлгә чума, бу үсеп барган куркыныч ташкынны ничек басу турында тынычсызланып уйларга тотына. Һәр бай, әлбәттә, элеккечә, үзенең куәтенә ышана. Беренче килеп кагылганда, ул Кадыйрлар да, Садри, Ибрай байлар да бу тилеләрнең чуалышыннан мәсхәрә белән көлә генә:

– Чыксыннар!.. Чыгып кая баралар?!. Тамагы ачыккач, яңадан килеп, бик ялыныр да, мин аны типкәләп җибәрермен!.. Менә җыен маңка малайлар! Адәм көлкесе бит: имеш, сигез сәгать эш вакыты! Имеш, бер ярым хак арттырылсын!.. Тот капчыгыңны! Унбиш сәгать эшләп тә әллә кая китә алган юк әле!..

Бай башта шулай каршылый, аның үз фикерләре үзенә бик нык дөрес тоелалар. Приказчиклар өчен дә ышанырлык булалар. Ләкин магазинга барып, алар белән бәрелешә башлагач, ул, ниндидер бер яңа нәрсә сизенеп, эченнән бик аз гына шикләнә башлый. Моңарчы башын иеп торган Фәхри хәзер ничектер бүтәнрәк күренә. Башкалары да элекке кебек түгелләр. Аз гына каты сүз әйтергә, катырак йомыш кушарга ярамый, мин синең колың түгел дигәндәй, кире йөз күрсәтә башлыйлар. Хуҗа боларны тоя, аяк тибеп акырасы килә, ләкин үзен көчләп тыя; эченнән бераз шүрли, ләкин сер бирми, шунда ук бу йомшаклыгына үзен шелтәләп, тагын кызына:

– Юк!.. Бирермен мин ул этләргә! Тамаклары туйгандыр: эт, симерсә, иясен талый... Болар да шулай... – дип, үзалдына әрнеп, әгәр тагы башбаштаклык күренсә, өсләренә аяк тибеп акырырга, карышсалар, хәзер куып чыгарырга күңелен беркетеп куя. Тагы шунда ук шөбһәгә төшә: –

---

[1] *Мантыйк* – формаль логика.
[2] *Һәндәсә* – геометрия.
[3] *Мөкәммәл* – тулы, камил.
[4] *Фөнуне җәдидә* – яңа фәннәр.
[5] *Рәдде нәсара* – христиан динен кире кагу.
[6] *Тәфсир* – Коръәннең аңлатмалы тәрҗемәсе.
[7] *Хәдис* – пәйгамбәр сүзләре.

Кууын куарсың да... адәм хурлыгы бит! Приказчиклары баш тарткан дип, илдә гайбәткә калырсың.

Бай шундый кара-каршы утлар эчендә янган кебек, хәзрәтләр, мөдәррисләр дә тынычлыкларын югалттылар. Муллалар үзләренең тарих белән килгән остазлык хакларына таяналар. Алар шәкерт алдында үзләренең авторитетына да ышаналар. Юк-бар кайнашларны ишеткәч, ул үзен юатырга тырыша:

– Юк! Дөнья буталыр, әмма минем шәкертләрем миңа мотыйг[1] калыр, – ди.

Ләкин мәдрәсәгә барып кергәч, аның эченә дә моңарчы булмаган шик төшә. Хәзер менә ничектер шәкертләр элекке кебек түгелләр. Өс-башны әйтмисең. Йөреш-торышта булган үзгәрешләргә дә күз йомасың. Чәч үстерүләренә дә элекке кебек сугыш башламыйсың. Менә бит ул әле үзен ун ел укыткан остазына каршы тел әйтүне – бер егетлек, шәплек саный. Синең фикерең алай икән, әмма мин болай уйлыйм, дип, карулашыр дәрәҗәдә оятсызлыкка барып җитә... Инде бертөрлесе дәресләргә дә суынды. Башта яшерәләр, ачык әйтергә тартыналар иде, ә хәзер:

– Андый схоластика белән ми черетер чак түгел! – дип җибәрәләр бит!

Казый һаман зарлана:

– Әллә кайларга китеп югалалар. Вак-төяк әкият-сафсата китаплар укыйлар, – ди. – Бары да менә шул юк-бар китаплардан чыккан ахмаклык! Тукта, болай ярамый, аларны йөгәнләргә кирәк. Маңкалары кипмәгән, остазлары белән карулашырга телиләр икән! Танысыннар минем кем икәнемне! Танытырмын, – дип гайрәт чәчә.

Бу көннәр, башка һәркемнән бигрәк, аналарга авыр хәсрәтләр, каты кайгылар алып килделәр. Бала сөючән Камиләнең улы байда хезмәт итә. Кайда булса да байлар белән хезмәтчеләр арасында талаш-тартыш чыкканлыгы турында сүз ишетелсә, ананың барлык тынычлыгы югала, йөрәген курку ала: шулаймы икән, аның кадерле улы Фәхри дә шундый фитнәчеләр эчендәме икән? Ул да шулай байларына, хуҗаларына каршы тел әйтеп, талашып йөриме икән?

– Илаһым, хуҗа, үзең сакла. Үзең сакла. Тәүфыйгыннан-бәхетеннән аерма!

Камилә карчык озын төннәрен шулай газапта, догада үткәрә. Менә хәбәр килә, аның улы кушылмаган. Элеккечә тыңлаучан, буйсынучан булып хезмәтендә йөри икән. Ана йөрәге шатлыгыннан бәйрәм итә. Ләкин бу шатлык озакка бармый. Тагы имешләр, хәбәрләр, тагы дулкыннар, тагы

---

[1] *Мотыйг* – буйсынучы.

йокысыз төннәр, өмит-газап эчендә үткәрелә торган авыр минутлар!

Кәримәнең ялгыз улы Җиһангир каядыр ерак мәдрәсәдә укый. Аны яраталар, мактап сөйлиләр, менә укуын бетерер дә, кайтып, мулла булыр, чалма-чапаннан ил түрендә кадер-хөрмәт күрер дип өмитләнәләр. Ләкин ана күңеле тынычсызлана. Шулаймы икән, юк-барга катнашмадымы икән, юк-барга алданып, хәлфәсенә, остазына каршы талаш чыгарып йөрмиме икән?! Бер өмит, шатлык, икенче сәгать тынычсыз хәбәр, дулкын – тагы ана өчен кайгылы, хәсрәтле йокысыз төннәр!

Аталарның йөрәкләре дә тыныч түгел. Ләкин алар кайгы белән күз яше түкмиләр. Намаз артларында, караңгы төннәрдә җылап, Аллага ялвармыйлар. Садакалар, нәзерләр белән кайнашмыйлар. Аларның ир табигате көрәшкә каршы сугыш белән җавап бирергә ашкына. Фитнә бармы, баласы байга, хәзрәткә, остазга каршылык иткәнме? Ата күңеле аны гафу итмәс, җылап-сыктап та тормас. Чакырып алыр да акылга, тәүфыйкка утыртканчы, авызын кара кан белән юганчы ярыр, әрнеп, ачу, зәһәр белән ярыр. Болай да тәүфыйгына кайтмаса, эт урынына куып чыгарыр.

– Мин кем? Ата хакы кая? Мәдрәсәгә биргәннәр икән – укысын! Байга биргәннәр икән – хезмәт итсен. Яхшы укысын, яхшы хезмәт итсен. Фатиха алыр. Адәм булыр. Ата-анасын тәрбияләр; үлгәч, алар артыннан хәер-догачы булыр!

Ләкин ул заманнар нурлы киләчәкнең якты күренешләре ачылган көннәр иде.

Көрәш кайный. Көрәш утының ялкыннары эчендә иске тормыш чүпләре янып җимерелә баралар. Алда, ерак күренеш эчендә, туачак тормышның нурлары азатлык яктысы белән ялтырап уйныйлар. Күңелләрне, йөрәкләрне үзләренә чакырып тарталар.

Көч җитәрме? Ул якты киләчәкнең азат, бәхетле ярларына алып барып чыгарырлык канатлар бармы?

Болай сорама. Бу сорауның җаваплары – алдагы тарих битләренең эченә яшеренгәннәр. Бу сорауларның җавапларын көтмәстән, көтәргә теләмәстән, бөек тарихи-сыйнфый сугышларның тирән көчләре якты киләчәк өчен көрәш мәйданына ташланалар, шул көрәш, шул сугыш аркылы алда ялтыраган азат көннәргә омтылудан үзләрен тыя алмыйлар.

## III
## КАРТ ЖАНДАРМ

Җилле, давыллы көннәрнең берсе иде.

Карт жандарм полковник Герасимов сәгать икегә үзенең кара атын иярләргә кушты. Билендәге маузерын үзе карап, үзе корды. Каты бәрелешкә

әзерләнгән сугышчы яки арыслан көтүенә каршы барырга әзерләнгән сунарчы кебек, йөрәге суккан хәлдә, утыз кешелек атлы жандарм отрядына ашыгыч хәзерләнергә боерык бирде.

Иртәнге якты, матур кояш каядыр качкан. Күк йөзен карасу-соры катлаулы болытлар каплап баралар. Таулар, яланнар, урманнар ашасыннан шәһәр өстенә таба каты давыллы, җилле яңгырлар ишерелеп киләләр. Авыр, юеш көзге көн кичегеп бара. Куе-кара болытлар эченнән гөрләтеп эре тамчылы, салкын яңгыр коя башлый. Агачлар, түбәләр, урамнар, тротуарлар яңгырдан чыланып ялтырыйлар, канаулардан шарлап сулар агарга тотына. Таш түшәлмәгән урамнар адәм йөри алмаслык булып пычракка әйләнәләр.

Ләкин салкын яңгырлар да, аяк астының пычрагы да, җилле-яңгырлы болытлар да революция белән ашкынган халыкларны өйләренә бикли алмадылар.

Карт жандарм үзенең һәрбер чыгышка әзер итеп алып иярткән отряды белән ат өстендә килеп җиткәндә, шәһәр уртасы – цирк мәйданы үзалдына шаулап, дулкынланып торган халык диңгезенә әйләнгән иде инде. Әйтерсең, дөньяда башка җирдә тереклек беткән; әйтерсең, зур шәһәр үзенең көнлек кайгысын, эшен ташлаган да, тарихның олы мәсьәләләрен чишәр өчен, язгы ташкындай агылып, шул мәйданга килеп тыгылган. Шулай тыгызланып кайнашалар. Хәзер клублар, театрлар, цирклар тарлык итә. Заводтан, фабрикадан, уку йортларыннан ярлы кварталлардан агылып җыелган халык диңгезе боларның заллары эченә сыймыйлар. Менә өченче көн инде губернатордан рөхсәте тартып алынган, һәркайсы зур бер демонстрациягә багланып туган митинглар шул цирк мәйданына күчтеләр. Бүгенге җыелыш шундый зур митингларның берсе иде.

Жандарм Герасимов отрядны читкә кырыйлап сипте дә, үзе халыкны җыра-җыра уртага – ясалма трибунага таба атламакчы булды. Ләкин шул арада ук сул як урамнарда, дөнья яңгыратып җырлап, эшчеләр килеп чыктылар. Алар артында әллә ничаклы вак һөнәрче халыклар, укучылар, яшьләр, малайлар ияргәннәр иде. Жандарм кире шуларга таба ташланды. Кичә хәбәр бар иде: эшчеләр тимер дружиналар төзегән имеш, демонстрациягә, җыелышларга коралланып чыгалар имеш, диделәр. Карт жандармның бүген отрядны утыз кешегә җиткерүе – шул сәбәптән иде. Ләкин җырлап килгән массаның алдына чыгарга ирек бирмәделәр. Уң яктан кемнәрдер, кая таба барырга диптер, этәрә башлыйлар, дулкын үзенең ташкыны белән Герасимовны да элеп алып китә дә зур коймага китереп тери.

Мәйданда халык арта бара. Эшчеләргә, ярлы кварталларга тагылып, төркем-төркем мәдрәсә яшьләре, шәкертләр, татар приказчиклары да агылалар. Мескен бүрекне басып, казакиның биш төймәсен дә каптырып,

читек-кәвешне яңгыр суында лачт-лочт пычратып, байтак мөселман агай-эне дә җыелып китте. Болар нәрсәдәндер бераз читсенәләр, үзләрен үги кебек тоталар. Шулар эчендә соңгы ике көннең батыры кызыл приказчик Габдрахман да күренде. Аның күз төбе күгәреп тора. Яңагына ак яулык бәйләгән. Татар приказчикларыннан бер төркем халык аны әйләндереп алдылар. Кадыйр бай приказчикларының җитәкчесе, яхшы киемле, купшы Фәхри аңа килеп кул бирде дә көлеп сорады:

– Ишеткәч, ышанмаган идем... Чынлап шулаймыни? – дип, иптәшенең яңагына күрсәтте.

Габдрахман сул күзен кылыйлатып көлде:

– Әйтмә, малай! Яңакны эштән чыгардылар бит эт авызлар!.. Җитмәсә тагы, яшь кәләш алырга йөргән чакка туры килде ләбаса бәхетсезлек! – диде. Тагы хихылдап көлеп өстәде: – Ишеткәнсеңдер, өйләнәм бит, Нәфисәне алам, яучы ризалык белән кайтты, – дип, үзенең өйләнәчәк кызы Нәфисә турында сөйли башлады.

Фәхри аның кыйналганын ишетсә дә, ышанмыйчарак карый иде. Габдрахман үзе дә моны сизенде булса кирәк, Кулындагы кечкенә китабын кесәсенә тыкты да, яңагындагы яулыкны чишеп, канлы яраны күрсәтте. Фәхри йөзен чытты:

– Бәйлә, иптәш, җил тияр! – диде.

Габдрахманның уң як колак асты чиләнеп, кызыл канланып тора. Сул як чикәсе, күз төпләре кара янган. Ул ипләп бәйләде дә, ярым көлкегә салып, үзенең трагедияле вакыйгасын сөйләргә кереште:

– Мин, – ди, – ул көнге зур демонстрация чагында, губернатор турына җиткәнче, һаман кызыл байрак янында бардым, ди, шунда йөргәндә үк, ди, берничә дошман күзнең ялтыр-йолтыр итеп миңа ачулы карашын сизенгән идем. Ахры, мине сагалап йөргәннәрдер, атлы казаклар камчы белән демонстрацияне таратырга тотынгач, йөгереп качып, бер тар тыкрыкка борылсам, үземнең таныш ике егет Сәйфулла белән Хәйбулла килеп чыктылар да: «Син нигә алай мөселманга йөз каралыгы ясыйсың?» – дип сүгеп, хурлап, канга батырганчы үземне кыйнап качтылар. Мин, як-ягыма каранып, караул кычкырырга тотынсам, бу вакыт малай...

Габдрахман сүзен бетерә алмады, үзалдына дулкынланып шаулап торган халык диңгезе өстеннән:

– Иптәшләр, гражданнар, зур көрәшнең хәзерге көннәре... – дип башланган калын, көчле, батыр тавыш яңгырап, тирә-як урамнарга, йортларга чәчелде.

Мәйдан берьюлы тынды. Читтәрәк торган кешеләр бер-берен таптап уртага таба ташландылар, тирә-яктагы койма башларына, капка өсләренә,

агач ботакларына малай-шалай, яшүсмерләр менеп асылдылар.

Беренче оратор Абрам Моисеевич Соломонов иде. Аның чәчрәп яңгыраган нечкә тавышы бик тиз халыкны үзенә тартып алды. Ул мәгълүм кеше иде. Урта буйлы, кечкенә, түгәрәк кара сакаллы, үткен, ялтыр кара күзле, ябык йөзле бу адвокат электән хөкем залларында прокурорга каршы каты, усал талашлары белән билгеле булса, соңгы дүрт-биш айда ул сәяси көрәш фронтларында да үзен танытып өлгергән иде. «Р» хәрефен йота-йота, ачык, кискен яңгыратып, ул хөкүмәт белән халык арасында була торган мөнәсәбәтләрне үзенчә, кадетча, буярга тырышты. Бөек Франция революциясенең конвент көннәренә [1*] тукталды. Аннан 48 нче елга сикереп, Париж баррикадаларына [2*] килде. Хәзер Русия революциясе эчендә үзара бугазга-бугаз килеп талашкан партияләр эчендә, демократия нигезендә конституция яки конституция нигезендә демократия дип, парламентаризм дип сайрады.

Жандарм Герасимов өчен болар иске, билгеле нәрсәләр иде. Алда кораллы сугыш фронтлары, баррикадалар торган чакта, адвокатның конституция кебек сүзләренә аның карт колагы да өйрәнеп килә иде инде. Ләкин Соломонов артыннан трибунага Коляның [3*] күтәрелүе башта аның йөрәгенә ачулы дулкын бирде:

– Менә бит, әллә кайчан асылырга тиешле кешеләрне без трибуналарга мендереп йөртәбез! – дип, үзеннән югары торганнарның соңгы берничә атна эчендәге тактикаларын әрнеп шелтәләде. Шулай да урыныннан кузгалмады. Бәрән күргәч авыз сулары килә башлаган ач бүре кебек, иреннәрен ялый-ялый, баскан җирендә катып тора бирде.

Фәхри белән Габдрахман, трибунага Коля менүгә, халыкны җырып, кысылып, аңа таба омтылдылар. Алар зур тузган чәчле, соры күзле, кызыл күлмәк өстеннән чуклы зөннар[1] бәйләгән бу ораторны күптән беләләр иде. Якын арада асылу хәбәре таралган студент Егордан сабак укып йөргәндә, аның туган агасы булган Коляны еш очраттылар. Ул шундый юк сәбәпне бар итеп танышты да, боларга беренче сәяси аңны биреп, боларны кызыл якка борып җибәрде. Эшчеләр дә беләләр икән. Ораторның тузган чәче трибуна өстендә җил белән тузгыла башлауга, татарлардан текстильче Галимов каты кул чабып җибәрде. Аңа башкалар да кушылдылар. Татар эшчеләре партиянең бу шәһәрдә иң эшлекле ораторларыннан саналган бу иптәшне үзләренең Кавказлы Гәрәй Солтаннары, Зариф Булатовлары белән бер уңайдан якын итеп, үз итеп яраталар. Революция сугышында аңардан җитәкчелек алдылар. Ике тапкыр, эләккән чагында, жандармнар белән талаш,

---

[1] *Зөннар* – билбау.

бәрелеш кузгатып, аны коткардылар. Шулай үзләренеке булып беткән Коля авыз ачуга, Галимов артыннан башка татар эшчеләре дә, алга тартылып, аны тыңларга йотылдылар! Ләкин бүген аның тамагы карлыккан иде. Тавышы элеккечә корычтай яңгырап чыга алмады, ишетелгән сүзләре дә авыр килде, ул башта ук алдынгы[1] ораторга каршы кискен тәнкыйть ачты, аннан киңәйтеп җибәрде:

– Иптәшләр, – диде, – иң якын сугыш, әлбәттә, самодержавиегә каршы сугыш. Ләкин, иптәшләр, бу дошманны җиңү өчен тик беренче адымны атлау, тик беренче баскычны үтү генә булачак. Монда сезгә конституция турында, парламентаризм турында сайрадылар. Дөрес, болар кирәк әйберләр, Ләкин түбән сыйныф халыкларга: «Инде конституция булды! [4*] Дөнья төгәлләнде!» – дип уйларга мөмкин түгел. Без, әлбәттә, беләбез, иң якын дошман – патша хөкүмәте. Ләкин бу патша, бу хөкүмәт безгә дус булмаган кебек, капиталист та, алпавыт та, буржуа да безгә дус түгел. Әгәр дә беренче дошман җиңелеп, власть буржуазия кулына керә калса, шул ук буржуа хөкүмәте дә пулемет белән, туп, мылтык, сөңге, кылыч белән пролетариатка каршы сугыш ачачак. Бүген «хөррият! хөррият!» дип кычкырган кешеләр арасында сез либераль буржуа вәкилләрен дә күрәсез. Ләкин алданмагыз, әгәр власть үзләренә күчсә, менә шул либераллар кан, үлем эчендә эшче революциясен басачаклар... Менә бу чуалчык сыйнфый көрәшләрне бер минут та күз алдыннан җибәрергә ярамый, иптәшләр...

Ораторны кул чабып, яклап тыңладылар. Берничә тапкыр зур алкышлар белән бөтен тирә-якны, мәйданны яңгыраттылар. Герасимов монда шул моментны әрнеп йөрәгенә алды: ораторның сүзе ничаклы кискен чыкса, ул иске хөкүмәткә каршы ни дәрәҗәдә каты, яман, үткен сүз әйтә белсә, халыкның алкышы шул дәрәҗәдә көчле була. Әмма арада иң дөрес, иң файдалы сүзләрне җүнләп тыңламый да башлыйлар. Ул, үз эченнән зәһәрләнеп, уен беркетте: теләсә ни булсын, әмма полиция кылычы белән казак камчысы «халык» дип аталган бу сарык көтүе өчен үзенең тәрбиячелек ролен бетермәгән әле.

Төрле партияләрнең ораторлары бер-бер артлы трибунага менә тордылар. Хөкүмәтне, иске идарәне сүгеп төшә тордылар. Халыкның әле бер катлавы, әле икенчесе ораторларның әле берсенә, әле икенчесенә алкышлап кул чаптылар. Ләкин жандарм һәммәсенә ачу йотты: «Вакыт әрәм! Һәммәсен пулемет авызына куярга кирәк иде», – дип уйлады. Әмма департаментның манифест чыкканнан бирле [5*] мондый котырган көтүләргә, шул көтүне агулаучыларга, кыздыручыларга, котыртучыларга каршы ничектер сак

[1] *Алдынгы* – «алдагы, алда сөйләгән» мәгънәсендә.

кылануы – аның кулларын бәйләделәр. Һәр ораторның һәрбер сүзе революциягә каршы көрәш фронтында утыз ел хезмәт иткән карт жандармның йөрәгенә барып кадалды. Аның ревматизмлы аягы сызлый башлады. Йөзе каралып кипте, күзенә ачу чыгып катты: «Бетәбез!.. Болай барсак, бетәбез! Үзебез дә бетәбез! Русияне дә бетерәбез!» – дип көеп уйланды.

Шул иске, бикләнгән ачулы уйлар белән зәһәрләнеп торганда, митингны алып баручы рәиснең:

– Зариф Булатов, – дип кычкырып җибәрүе Герасимовны кинәт уятты. Ул, авыр уйларын берьюлы ташлап, карчыга күзләре белән трибунага кадалды. Анда зур буйлы, киң җилкәле, ябык, чандыр, кара-туткыл йөзле, кырган сакаллы, куе, кабарып үскән  кыска кара мыеклы һәм бераз гына кысыла төшкән кара күзле бер ир кызу, кискен атлап килеп баса да кызу ялкын белән сөйләргә тотына. Аның башында кепка. Өстендә кара пальто. Тавышы – күкрәк тавышы. Ләкин бераз чатнаган. Сөйли-сөйли дә, үзенең яңгыравын югалтып, гырылдап куя. Сүз, мәгънә уңае белән бөтен гәүдәсе, куллары туктаусыз селкенәләр. Гүя ул әйтергә теләгән фикерен бөтен хәрәкәте белән шунда, мәйданга тулган халык алдында гәүдәләндереп, җанландырып бирмәк була. Шулай ялкынланып:

– Иптәшләр, монархиянең җимерелү сәгатьләре якынлашу белән... – дип башланган берничә сүзләре киң мәйдан өстеннән яңгырау белән халык эчендә нindидер хәрәкәт, нindидер дулкын кузгалды. Русчаны аз аңлаган, шуңа күрә үткән ораторлардан күп тәм тапмаган мәдрәсә яшьләре, татар приказчиклары, кысылып-кысылып, трибунага таба тартылдылар. Һәрвакыт бергә кайнаган татар эшчеләре дә аны тиз танып, елмаеп алдылар.

Герасимов башта: «Бу кем? Таныш йөз ич!» – дип аптырады. Рөхсәтсез җыелышларга катнашкан өчен, эшчеләр, студентлар белән бергә, бервакыт Зариф та эләгеп, жандармериягә китерелгән, шул чакта полковник жандарм аны, арада бер татар азгыны да бар икән дип, төсмерләп калган иде. Ул вакыт егет сүзгә ипле, ләкин бик астыртын, хәйләкәр күренде. Шулай да Герасимов ул чакта аны артык зарарлы тапмады: «Мин татарларны яратам, утыз ел татар эчендә эш алып барам. Татарлар ак патшага каршы баш күтәрә торган халык түгел. Бу да яшь адәм. Моны тик жидлар[1] аздырган. Төзәлер!» – дип, җиңел карап, чыгара алган иде. Бүген менә кыю, кискен адым белән трибунага ташланып, кызып-кызып иске хөкүмәтне сүгәргә тотынган ораторда ул бик кыенлык белән әнә шул үзе коткарып җибәргән Булатны таный алды. Шулын – шул. Ләкин бөтенләй башка. Аз вакыт эчендә ул ун еллык үскән, ун еллык

[1] *Жидлар* – еврейләр.

пешеп өлгергән, ун еллык чыныккан, ләкин ябыгып, кара күз төпләренә җыерчыклар да чыга башлаган. Тавышы да ул чактагы нечкә, саф, яңгырак түгел. Әмма һаман да бу шул Булатов иде. Жандарм үзенең ул вакыттагы хатасын аңлады. Ул чакта чыгару ялгыш булган, инде ычкына алмас дип, теш кысып куйды да трибунага таба атлады. Ләкин барып җитә алмады, мәйданның агач коймага якын караңгы почмагыннан итче Фәсхетдин трибунада сөйли торган Булатка каты, яман, кычкырып җибәрде:

– Син кайчан чукындың?! Мөселманча сөйләргә телең юкмы әллә? – дип, бөтен халыкны сискәндерде.

Башка вак жандармнар бу тавышка таба борылдылар. Ләкин нәрсә әйткәнен аңламаганга, ни эшләргә белми, полковник Герасимовка карап тик тордылар. Баш жандарм баскан җирендә туктады. Бер Булатка, бер Фәсхетдингә таба күз ташлады.

Коляның янында гына Фәхри бар иде:

– Ник кычкыра? Нәрсә әйтә ул бүрекле татар? – диде.

Эшне аңлау белән, Булатның трибунасына килеп кысылып, пышылдап русча дәште:

– Әйдә, татарчага күч. Яр әйдә татарча! Алар безне аңламый калдылар ич! – дип кызынды.

Ләкин Булат, митингның күбе татарча аңламаганга, һаман русча алып китә бирде. Аңарчы үзләрен җыелышның үгирәк баласы кебек, бераз читсенеп торган татарлар төрле яктан кычкыра башладылар:

– Падишаның манифесты бар ич, әйдә мөселманча сөйлә, мөселманча! – дип, шау-шу күтәрделәр.

Булат өчен барыбер иде. Ләкин ул кинәт татар теленә күчәргә аптырабрак калды. Зур сәяси мәгънәләрне әйтергә татарчадан терминнар таба алмас, сүз җиткерә белмәс дип уйланды. Шулай да киреләнмәде, митингның татарлар күбрәк кайнашып торган ягына таба зур гәүдәсе белән борылды да татарча:

– Иптәшләр, мөселман агай-энеләр, патша манифест биргән. Теләп түгел, көчләнеп биргән. Ләкин моңа алданырга ярамый. Иске самодержавие бер кулы белән манифест чыгарса, икенче кулы белән революциягә каршы туп, мылтык хәзерли. Сүздә манифест, әмма гамәлдә, эштә – полиция, жандарм, сөргеннәр, зинданнар, палачлар белән революцияне буарга сугыш ача, пролетариат сугышып алган азатлыкларны кан-үлем эчендә батырыр өчен, иске хөкүмәт каты көрәш алып бара... Сез манифест дип өмитләнәсез, әмма алдыгызда, сездән бер минут күзләрен алмый, карчыгадай карап торган полковник жандарм Герасимов басып тора. Иптәшләр, манифест бирелде, хөрриятләр вәгъдә кылынды, ләкин моның белән көрәш бетмәде, тик

башланды, тик тирәнәйде, киңәйде генә... Бу көрәш самодержавиене җимергәнче...

Ораторның ни әйткәнен аңламау Герасимов өчен гомерендә беренче тапкыр килеп баскан бер ачу китергеч, хурландыргач нәрсә кебек булып китте. Ләкин патшаның 17 нче октябрь манифесты уңае белән җыелган мөселман җәмәгатен бик кинәт өркетәсе килмәгәнгә, башта икеләнеп: «Әйдә, әзрәк лыгырдасын, көтүнең күңеле булыр!» – дип, сабырланырга тырышкан иде. Әллә нинди сыйфатта, – әлбәттә, яманлап булыр инде, – оратор аның үзенең исемен дә телгә алгач, ул чыдамын югалтты, кискен бер кузгалу белән трибунага атлады да, кынындагы кылычын югары күтәреп, русча кычкырды:

– Губернатор җәнаблары, – диде, – бу җыелышны халыкка патшаның манифестын аңлатып бирү өчен генә рөхсәт иткән иде. Сез монда рөхсәтнең чигеннән чыгасыз! Чуалышка, фитнәгә чакырасыз, патша хәзрәтләренең манифестларын бозып күрсәтәсез... Монда тылмач та юк. Мин шарт куям: рөхсәтнең чигеннән чыгылмасын, һәммә ораторлар дәүләт вәкилләре аңлаган телдә генә сөйләсеннәр... Юкса... юкса... мин мәҗлесне ябарга, бу чиктән чыгучыларны дәүләтнең тынычлыгын саклау кануны буенча җавапка тартырга мәҗбүр булырмын! – диде.

Җыелышта төрле яктан, аптырап, курку һәм ачу катнаш шау-шу кузгалды.

Рәсми рөхсәтне үз исеменә алган адвокат, куркынып, агарынды, Булатка карап, үтенгән сүз белән сорады:

– Зариф Гыйрфаныч, нигә эшне бозасыз? Барыбер аңлыйлар ич! – дип ялынып әйтте.

Коля моны ишетеп калды да, бетәр-бетмәс, ике эшченең җилкәсенә күтәрелде, сары чәчен туздырып, ялкынлы аваз белән шау-шуны бүлде:

– Иптәшләр, бу ни эш бу? Манифест шулаймы? Нигә татарларның телләрен кисәләр? Бу җыелыш халыкка манифестны аңлатыр өчен рөхсәт ителгән булса, русча белмәгән татарларга үз телендә сөйләмәгәч, ничек аңлатасың! Бу – бер. Икенче, тагы шул гаҗәп: манифест-манифест, диләр, сүзгә, җыелышка, берләшергә иркенлек, диләр. Ә монда жандарм Герасимов безнең тирәгә ялангач кылычлы жандарларын тезгән, үзе уртага баскан да һәрбер сүздә ораторның телен кисә. Бу – манифестмы? Иркенлек шулмы? Мин әйтәм: жандарлар җыелыштан бөтенләй чыгарылсыннар, дим...

Шул шау-шу эчендә кайнаган халыкны этәреп, җырып, әле күптән түгел Бакудан кайтып эшли башлаган татар эшчесе Кавказлы Гәрәй Солтан җыелышның үзәгенә, президиум янына ук килеп җитә алды. Аның йөзен-ачу баскан, күзен каплаган; ул, хәзер сугышка ташланырга торган кебек, кызып, кайнап трибунага таба ыргытылды. Бер түбән жандарм, куркынып, аңа карап

чигенде: «Бу нәрсә ерткыч бит! Бомба ташламасын тагын!» – дип, янындагы револьверына тотынды.

Гәрәй бомбасыз, ләкин эчкә яшеренгән мылтыклы иде, ул ораторга бөтенләй якын тыгызланып бәрелде, эчтән кысылган шелтә тавышы белән кызып акрын әйтте:

– Ни торасың? Яр әйдә! Башладың, татарча яр да сал! – диде.

Ләкин кайнашкан митинг эчендә Булатов аны җүнләп ишетмәде. Һәммә кешедән катырак кычкырырга тырышып, гөжләгән, дулкынланган җәмәгать өстенә русча яңгыратты:

– Иптәшләр, – диде, – бу манифест сугышып алынды. Моның чыгуы өчен пролетариатның канлы, рәхимсез көрәшләре кирәк булды. Хәзер без бу көрәшләрнең иң кискен җиренә килеп җиттек. Дошман бер чигенде, бераз җиңелде, ләкин ул бөтенләй җимерелеп бетмәде. Аны бөтенләй җимереп бетерү өчен, аны юк итәр өчен, анардан котылыр өчен, пролетариатка, крәстиәннәргә үзләре теләгәнчә яңа тормыш кору өчен бер генә юл, бер генә чара бар. Иптәшләр, дошманны бөтенләй җимерү – тик аңа каршы кораллы сугыш аркасында гына мөмкин булачак... Дошман кулында – гаскәр; дошман кулында – зиндан, суд, палач... Дошман кулында – полиция, жандарм; дошман кулында – туп, пулемет, мылтык! Мондый дошманны җимерү өчен революция алдында бер генә чара бар, ул да – кораллы сугыш! Иптәшләр, дошманга каршы зур кораллы сугыш булачак – без менә шуңа хәзерләнергә тиешлебез!..

Булат кызып сөйләп барганда, кайдандыр, ниндидер күп тавыш белән җырлаган кебек, бер шау-шу ишетелә башлады. Карасалар, бөтен киң урамнарны, тротуарларны каплап, ниндидер бер агыш – кеше агышы килә. Алларында югары күтәрелгән сары алтын, зур, матур тәре. Аның янында зур гәүдәле, сары ука киемле, көмеш тәре асылган киң күкрәкле, көрәк кебек киң чал сакаллы өч поп янәшә бара. Алардан байтак артта, арада ике сажинлык өзек калдырып, биш-алты ак чалма селкенә. Иске камчат бүрекле, искечә төймәләнгән яхшы бишмәтле, яшел савырлы читекле карт татар байлары кузгалалар. Бу бөтен агыш өстеннән ниндидер авыр чиркәү моңы белән русча поп тавышы, монах тавышы килә: «Боже, царя храни...» [6*] җырлап, шуның тавышы белән бөтен якны каплап баралар. Бу тавышлы җыр бөтен циркны, мәйданны, җыелган җәмәгатьне каплап алды. Карт жандарм Герасимов мондый кара демонстрациянең бүген менә шул сәгатьтә булачагын яхшы белә иде, ул үзе моны хәзерләшкән иде. Ләкин бу дәрәҗәдә зур булыр дип, мөселманнардан аерым рәсми бүлек ясалыр дип өмитләнә алмаган иде. Күрүгә – кайнап катты. «Вакыт җитте, кызыл дошманның канатын сындырырга сәгать сукты!» – дип, үз эченнән кискен карарга килде.

Моңарчы аны департаментның яңа, җебегән, икеләнүчән тактикасы тотып тора иде. Хәзер аны онытып җибәрде: «Юк, – диде үз эченнән. – Русия бетми, чын сәламәт катлау әле дә исән», – диде.

Булатов, бу агылып килгән урам җәмәгатенә карамыйча, цирк мәйданы өстеннән алдагы, кораллы сугышка чакырып, һаман яңгырый иде.

Герасимов кискен ачу белән кайнап китте дә үзенең отрядына кычкырды, шуның белән митинг өстенә каты боерык белән акырды:

– Җыелыш үзенең рөхсәтле чигеннән чыкты! Монда манифестны аңлатмыйлар, аяк астына салып таптыйлар, халыкны патшага каршы коралланырга чакыралар! Мин, дәүләтне саклау вәкиле, мондый сүзләргә юл куя алмыйм, митингны таратам! – дип җикеренеп җибәрде. Шунда ук үзенең жандармнарына, халыкны таратырга, трибунадагыларны тотып алырга кычкырып-кычкырып боерыклар бирә башлады.

Жандармнар, полицейскийлар, гөж килеп, уртага ташланалар. Абрам Соломонов тиз генә сыза. Бөтен цирк мәйданын ут чыккандагы кебек бер тапташ, кычкырыш, йөгереш каплый. Шул шау-шу эчендә эләктереп алырга дип, Булатов Зарифка ике жандарм ыргытыла, ул арага Галимов белән Кавказлы Гәрәй Солтан килеп тыгылып, шау-шу эчендә жандармнарны этәреп җибәрәләр. Коля яңадан трибунага сикереп менә дә халыкны таралмаска өнди башлый; өч жандарм аңа ташланалар; сөйләргә теләп кычкырына – аны тартып төшерәләр. Тагы бер студент, бер эшче, бер-бер артлы трибунага менеп, кычкырып карыйлар – аларны полицейскийлар бәреп төшерәләр.

Бу арада инде кара демонстрация циркның капкалары, коймалары тирәсен үзенең тәреләре, патша сурәтләре, чалмалары, өч төстәге флаглары, поплары, муллалары, өс-башын алмаштырган полицейскийлары, охранка агентлары белән бөтенләй чолгап алган иде инде. Митингтан чыккан революция массасы белән ике арада бәрелешләр, тапташлар башланды. Жандармнар, ат белән чаптырып килеп, халык өстенә ташланалар; эшчеләр, шундагы коймаларны, капкаларны җимереп, агачларын сындырып алалар, коралланалар, урамның, тротуарның ташларын каерып, бәрелешкә әзерләнәләр. Ләкин сугышка җитми, почмакта, көтелмәгән бер вакыт, кайдандыр кызыл байрак күтәрелеп җибәрелә; аның җилбердәвен күреп, киң масса шунда таба дулкынланып каерыла. Ул арада атлы казачий эскадроны белән бер рота җәяүле солдат бөтен тирә-якны әйләндереп алалар. Кызыл байрак кузгала, аның артыннан эшче халык, яшьләр, шәкертләр, приказчиклар, һөнәрчеләр, үзләренең юлын буган полиция белән талашып, солдат штыгы, казак камчысы астында шаулашып, кычкырышып, шул кузгалган байрак ягына таба агылалар. Башкалар, ерткычтан качкан кебек,

кая туры килсә шунда йөгерәләр, әмма байрак астында кузгалган зур төркем, гаскәрнең, жандармнарның һөҗүменә, тыюына карамастан, бөтен шәһәр күтәреләчәкме дигән куркыныч бер көч белән дулкынланып:

Вихри враждебные воют над нами...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

В бой роковой мы вступили с врагами... [7 *]–

дигән җырлар тавышы астында урамнар яңгыратып, сәяси тоткыннар тулган зинданга таба китәләр.

Булат цирк эчендәге бәрелештә эләгә язып калган иде, шау-шу эчендә ычкынып китә алды. Җырлы яңа демонстрация дулкыны астында аңа Галимов белән Гәрәй дә очрады. Ләкин Коляны белә алмадылар, ул эләктеме, әллә котылдымы – бүген билгесез калды.

## IV
## БУЛАТ

Моңарчы ярым ачык, ярым качып яшәгән Зариф Булатов бүгенге бәрелештән соң бөтенләй идән астына төште. Шәһәр читендә, татарлар арасында, Балчык урам дип йөртелгән бер тыкрык бар. Булат әлегәчә шунда, почмак кибеттән ике йорт аша, әнисе, сеңелесе белән кечкенә бер өйдә тора иде. Цирк мәйданында гаскәр, полиция белән бәрелешеп таралгач, ул яңадан анасына кайта алмады, кайбер яшерен әйберләрне качырып саклый торган Гәүһәр туташны күреп, аның аркылы аңлашты да төнге сәгать икеләрдә кызыл приказчик Фәхринең квартирына кунарга барды.

Шәһәрнең зурларыннан Кадыйр байның унике приказчигы эш ташлап чыгып киттеләр. Фәхри шуларның җитәкчеләреннән иде. Башта болар калада бик зур шау-шу күтәрделәр, мөселман агай-эне арасында әллә ничаклы сүз, талаш булды. Ләкин Фәхри өчен хәзер бу сүзләрнең, бу талашларның үткенлеге дә, мәгънәсе дә бик кечерәеп бара, хәзер төплерәк, кирәклерәк бер эшкә катнаша белмәвенә эче поша башлаган иде. Куе вуаль эченә яшеренеп, караңгы кичтә Гәүһәрнең конспиратив рәвештә үз итеп килеп керүе – аның дәртен канатландырып җибәрде. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач, ул башта бик аз гына шүрләде.

«Аны кундырырсың, артыннан ук жандар да килсә...» – дип, чак кына куркынды. Ләкин беренче адымның бу куркуын ул үзендә тиз җиңде. Каушау күзенә дә чыгып өлгерә алмады, ул:

– Ярый. Ярый. Бик ярый. Бик мөмкин. Баш өсте, туташ. Беләсең, мин партияле кеше түгел. Шулай да бик ярый. Бик мөмкин, – дип, кат-кат ризалык сүзләрен тезде.

Ул үзе кызыл да иде, купшы да иде. Кеше алдында һичнәрсә белән дә

йөзгә кызыллык китерергә, үзен ким күрсәтергә теләми иде. Гәүһәрне капка төбенә чаклы озатып, кулын кысты, аның караңгы төндә, чат башында югалганын карап калды да тиз-тиз бүлмәсенә керде. Уен түгел бит. Беренче тапкыр ул конспирация эшен үз өстенә йөкли. Монда куркыныч та бар, әлбәттә. Беленсә, рәхмәт әйтмәсләр, йә сөрерләр, йә ябып куярлар. Ләкин хәзер андыйлардан курка торган чак түгел ич. Бөтен дөнья асты-өскә килеп кайнаганда, һаман-һаман шул Кадыйр байны сүгеп, унике приказчикны сөйләп йөрү генә җитми шул. Беренче. Әле бу – беренче. Беренче тапкыр менә аңа зур яшерен эш бирәләр. Бу хәзер – революциянең конспиратив квартирларыннан берсе була. Гәүһәр ни ди бит, усал, агу телле нәрсә үзе:

– Марҗа кызларыңны ташла. Телеңне тешләп тот. Бер кешегә генә әйтсәң дә, бөтен конспирацияне харап итәрсең; беләмсең, син провокаторлык иткән кебек буласың, – диде.

Ләкин бу сүзләр нигә кирәк? Фәхри баламы? Ул революция дулкынында кайнамыймы?

Сәгать уникедә килер дигәннәр иде. Унике үтте. Бер үтте. Тик менә икене сукканда гына тәрәзә чирттеләр. Калтырабрак чыкса, әллә нинди бер кеше: башында – тирән зур татар бүреге, өстендә – кама якалы билле тун, кулында – ниндидер бер төргәк. Бу – Булат иде. Сөйләшми-нитми керделәр, кунак акрын тавыш белән:

– Квартир хуҗаларың кем? Бик бәйләнчек адәмнәр түгелме? – дип сорады.

Фәхри монда күптән тормый икән:

– Белеп булмый. Ләкин бик чукыналар. Бөтен өйләре тәре белән тулы, һәр бүлмәдә ике патша сурәте! – диде.

Булат арыган, болай да ябык йөзе суырылып эчкә кергән, күзләре бераз тонып, хәлсезләнеп карыйлар иде. Тизрәк ятарга кирәк дип итеген сала башлауга, тәрәзәгә күзе төште. Анда ниндидер бер шәүлә капкадан бу баскычка таба атлагандай тоелды. «Жандарммы, филермы?» – дип шикләнеп, тиз тәрәзәгә ташланса, анда тыш яктан ишеккә таба кылычлы, мылтыклы ике кеше менеп килә. Артларыннан тагы берничә карачкыл күренә. Ул бик тиз итеген киде:

– Арт ишек кайда сезнең? – дип сорады да, бүреген, тунын эләктереп, кухня аркылы шул якка атлады; аннан тар, караңгы, җимерек баскыч белән төшеп, йорт аша урамга, аннан кала аркылы заводка, Галимовка сызды.

Монда Фәхри шашып калды: харап булдым, провокатор дип, Булатны бирде дип, мине үтерәчәкләр дип аптырап катты. Анда, тышта, ишекне җимерердәй булып кагалар да кагалар. Өстенә киде дә каршы чыкты. Ишекне ачмыйча:

– Сезгә кем кирәк? – диде.

Аннан моның исем-фамилиясен әйттеләр. Ләкин Булатны телгә алмыйлар. Аны эзләп, аны эләктерер өчен килгәннәрме? Атап сорамаулары – бер тозак кынамы? Әллә чыннан кызыл приказчик Фәхринең үзен эзлиләрме? Ул аера да алмады.

Пристав, бер жандарм, ике пүнәтәй – шулай дүртәүләп керделәр, аннан-моннан, өстән-өстән генә тентеделәр дә, егеткә анасыннан килгән ике татарча хат белән татар социал-демократлары басмасыннан берничә китапны алып чыгып киттеләр. Гаҗәбе шул булды: Фәхри үзе тыштан белдермәсә дә, эчтән бик каушаган, эләктем, күрәсең, дип шүрләгән иде. Ләкин аның үзен алмадылар.

Ул таңгача йокламады, көн яктыру белән шәһәргә чыкты. Аның башында үзенчә авыр мәсьәлә иде: бу чуалчык трагедияне кай ягыннан чишә башларга? Булат эләктеме, юкмы? Башкалар нихәлдә? Гәүһәр бит кичә өзеп әйтте: «Бер кешегә белдерсәң, үзеңне провокатор дип карарлар», – диде.

Бу көтелмәгән зур газаптан ничек котылырга?

Туры Гәрәй Солтанга китте. «Һәммәсе шунда кайныйлар, берсе туры килер, Нина белән Коля да шуннан чыкмыйлар. Анда булмасалар, Гәүһәргә барырмын», – шулай уйланып, Солтанов тора торган йортка барып керсә, күк фуражка күзенә чалынды. Караса, пристав икән; аның янында тагы ике жандарм, тагы ике пүнәтәй. Нәкъ Гәрәйнең баскычыннан менеп баралар. Бу ни хәл, болар әллә бүген бөтен дөньяны басканнармы? Шулай вәсвәсәләнеп, кире чигеним, мине күрмәсеннәр дигәндә генә, пристав бу якка әйләнде, арыган, тонган күзе Фәхринең нәкъ маңлаена кадалды. «Кирәк бугай, бу да кирәк бугай, бу кеше Солтан Кавказскийга йөри бугай», – дип үзалдына уйланды. Ләкин аның ике тәүлек йоклаганы юк иде, менә шул бер төн эчендә генә дүрт җирдә тентү ясап, унбер кешене ябып, инде менә уникенче кешегә бишенче квартирга килә иде. Аның күзе томаланган, башы кабак булып каткан иде. Фәхрине күрде, бу да кирәк бугай, дип уйлады да шул минутта ук онытты.

Фәхри, шунардан файдаланып, тиз генә кире чигенде дә юк булды.

Пристав үзенең кешеләре белән эчкә, квартирга, аннан Кавказлы Гәрәй Солтанның кечкенә, ярлы, ярым караңгы бүлмәсенә керде. Керсә, тагы аптырап катты. Солтанов юк. Анда нindидер бер бик чибәр яшь кыз ашыгып-ашыгып нидер язып утыра, йөзе агарынган. Нечкә иреннәре зәһәрләнеп кипкән, көйгән, күзендә әллә нинди ачулы әрнү ялтырый. Пристав керүгә, язып утырган кәгазен тиз-тиз алып йомарлады да өстәлгә ташлады, аннан, кире алып, ридикюле эченә тыкты. Өстендә кара йон юбка, кызыл ефәк кофта. Аягында биек үкчәле кечкенә сары ботинка. Күзләре

зәңгәр күк кебек карыйлар. Коңгырт чәче матурлап кыскартылган.

Пристав арып ватылган булса да, монда көтелмәгән яңа кешене күрү аны уятып җибәрде:

– Сез кем? Хатынымы, кардәшеме? – диде. Шуңа кушып ук өстәде: – Без тентү белән килдек. Кая, сез, нинди кәгазьне анда йомарлап ридикюльгә тыктыгыз? – дип ачу белән сорады.

Кыз – марҗамы, татармы, аерыр хәл юк, русча бик оста сайрый – ридикюлен кочаклап, бер якка сыена:

– Юк, – ди, – ул минем үз язуым. Сез мине түгел, бүлмә хуҗасын тентергә килгәнсез бит. Монда һичбер сәяси сүз язылмаган, ул бары ике иптәшнең үзара аңлашуы гына! – дип, бирергә теләми.

Приставның аруы онытылды. Ул кызның карулашуыннан тирән шөбһәгә төште: «Кем белә, әллә нинди серләр ача торган бер язу булыр», – дип, бүлмәне тентүдән бигрәк, бөтен фикерен шул туташ кулында йомарланган кәгазьгә туплады. Яхшы сүз белән бирмәгәч, янындагы жандармга кушты:

– Ридикюлен тартып ал! Ач! Кәгазьне чыгар! – диде.

Жандарм көч белән каера башлагач, кыз:

– Хәзер үзем бирәм! – дип, кире чигенә, тиз-тиз ридикюльне ача, кулына кечкенә кәгазьне ала да, приставка сузган булып, авызына кабып җибәрә.

Бу инде кәгазьнең кыйммәтен тагы күтәрде. Көчләп кенә түгел, үтереп булса да, хәзер шуны бөтен көенчә алырга кирәк булып табылды. Пристав үзе кызны каты кулы белән кочаклап ала, гәүдәсен бот арасына кыса да бер кулы белән аның авызын каера. Кыз бирелмәскә тырыша. Ләкин приставның ике көн юмаган пычрак, тәмәкеле бармагы кергәч, чыдый алмый, кәгазьне төкереп ыргыта. Үзе укшып, кызарып, урындыкка ава. Ләкин һушыннан язмый. Аз гына хәл ала да, шунда бер кадакка эленгән жакеты белән эшләпәсен алып, чыгарга киенә башлый.

Пристав аны җибәрми. Шунда өстәл читенә утырта да җавап ала. «Гәүһәр Илбаева!» – дигәч, аптырап кала:

– Ничек Илбаева? Сезнең атагыз земствода эшлиме? Сез Мөхәррәм Сөләйманович кызымы? Минә көтмәгән идем. Көтмәгән идем. Сез нишләп бу кызыл авыз бүлмәсенә килеп чыктыгыз?

Гәүһәр бу соңгы сорауга җавап бирми, көрәшеп ватылган йөз белән акрын гына елмайды да:

– Бик ватылдым, сез мине кайтарсагыз иде, господин пристав! – диде. Шуннан вакыйганы, сәяси моментларга бер дә кагылмаска тырышып, сөйләп бирде: – Булат белән болай танышлык бар. Минә Солтановта без аның белән

очрашкалый идек. Кичә цирктагы җыелыш алдыннан ул мине монда чакырган иде, кердем, ул үзе килмәгән. Монда Нина дигән бер кыз аңа хат калдырган икән. Мин менә шулар турында язган идем, сәяси һичнәрсә юк, сез укымый миңа кайтарсагыз иде, – дип үтенде.

Ләкин бу пристав өчен мөмкин түгел иде. Ул ипләбрәк утырды да кыздан талап алынган һәр ике кәгазьне үзенчә бик җентекләп укыды. Бу ике язуның берсе Нинадан Булатка икән. Ул бик кыска:

«Мине бүген һич көтмә. Эш шулай чыкты. Берничә көнгә Чиләбегә китәм», – дигән.

Икенче хат озын. Үзе бик нервланып, кызып, нечкә, матур каләм белән русча язылган:

«Зариф, сиңа актык хатым булыр. Минем алдымда көтелмәгәнрәк нәрсәләр ачылды. Син мине Гәүһәрем дип, акыллым дип иркәлисең. Нинага да шулай икәнсең! Ул нигә сиңа төннәрдә килеп йөри? Нигә сиңа «син» дип яза? Шулаймыни, син, мине алдап, үзең чит марҗалар артыннан өстерәләсеңмени? Шул томшык борынга бик исең киткән булса, мин сине бөтенләй аңа калдырам...»

Укып чыккач, пристав көлде. Нина хатын протоколга теркәде дә Гәүһәрнекен үзенә кайтарып бирде.

Кыз, арып, йөрәге белән изелеп, кайгысыннан, хурлыгыннан кайтып китте. Пристав та, бүлмәне тентегәч, протоколга кул куйдырып, пүнәтәйләрне чыгарды да, Гәрәйнең бүлмәсендә табылган әйберләрне өч төргәк ясап, инде башым мендәргә тияр вакыт җитте бугай, дип, участкага кайтты. Ләкин аңа ял итү насыйп түгел иде.

Петербург департамент начальнигыннан Герасимовка ашыгыч № 021450 шифрлы телеграм алынды. Анда губернада булган революцион оешмаларның ликвидациясенә хәзерлек күрергә боерык бирелгән. Шул телеграм алынганнан бирле жандарм полковник Герасимов үзенең кабинетын оператив штабка әйләндерде. Авыруына карамастан, бөтен контрхәрәкәтнең, контратакаларның һәммәсенең иң кечкенә тармакларынача үзе турыдан-туры җитәкчелек итәргә тотынды.

Аның эчке агентурасы да, тышкы күзәтчелеге дә яхшы куелган иде. Партиянең дә, эшче хәрәкәтенең дә бөтен барышы, нәрсәгә хәзерләнешләре үз вакытында кирәгенчә беленеп торыла. Аеруча, татар арасы турында материал алу баштарак кыен иде. Хәзер ул да юлга салынды. Булатның аяк атлавына чаклы килеп хәбәр итәләр. Мәдрәсә яшьләре арасындагы панисламист, пантюркист, социалистик хәрәкәтләр дә вакытында билгеле булмый калмый. Приказчиклар да яшерен түгелләр. Тик менә кичәдән бирле яңа бер чуалчык нәрсә чыкты. Әле һаман шуның очына барып җитә

алмыйлар. Кичә циркта булган митингны таратып кайткач, аноним хат алынды. Анда бер мәсьәлә кузгата: «Сигез эшче-боевик мондагы большевиклар комитеты җитәкчелеге астында яшерен корал склады, бомба-динамит фабрикасы тоталар. Араларында берсе татар – моның исеме-фамилиясе Гәрәй Солтанов, кушаматы – Кавказлы. Бу – зур, көчле, яшерен оешма. Болар, большевик оешманың әйтүе буенча, тиздән булачак коралды күтәрелешкә, коралды сугышка әзерләнүчеләр. Боларда маузерлар, бомбалар, динамитлар, пироксилиннар, нитроглицериннар, бикфорд җепләре бар. Бу җеп күптән түгел Париждан алынды. Аны Үзәк Комитет, бер кызга урап, Русиягә җибәрде. Бу – җәһәннәм кебек яман бер көчле шартлагыч тудыра. Мин азын гына әйтәм. Әгәр ун мең сум бирсәгез, менә шул яшерен фабриканы сезгә ачам», – ди. Үзенә ничек акча тапшыру, үзе белән ничек аңлашу юлларын яза. Бу хатны алу Герасимовны дары мичкәсе өстенә утырган кебек хәлгә куйды. Ул, эт булып аруына карамастан, төнен йокламады. Тентүгә баручыларга үзе инструкция бирде; кайткач, һәрберен кертеп, үзе сорашты. Бу яшерен фабрика мәсьәләсе, Петербург департаментының, ликвидациягә хәзерләнегез, дигән телеграмыннан мең тапкыр зуррак бер мәсьәлә булып, карт полковник жандармның алдына килеп басты. Кем белә, бәлки бу бөтенләй ялгандыр. Ләкин дөрес булуы да мөмкин. Чөнки башка шәһәрләрдә мондый хәлләр бик еш булып тора. Әгәр дөрес булса, син ликвидациягә барам дигәндә, алар үзләре сиңа ликвидация ясаулары бик мөмкин. Бу эш була калса, Герасимов утыз еллык вояк[1] полковник түгел, бала чүпрәге юа торган алама хатыннан да түбән булып калачак. Шулай уйланып, ул үзенең бөтен көчен менә шул ике моментка – ликвидация хәзерлеге белән яшерен корал складын, яшерен корал-бомба фабрикасын эзләтеп таптыру чарасына бирде.

Гәрәй бүлмәсен тентеп, ике тиен тормаган җыен чүп-чар материал белән кайткан приставның информациясен эченнән сүгенеп тыңлады. «Болван! Исерек баш, моңардан ни чыксын?!» – дип, мөһер сукты. Башка бер сүз әйтмәде.

– Кич шәһәр театрында мөселманнарның Думага сайлау алды хәзерлеге турында җыелышлары була! Сез шунда власть вәкиле булып, тәртип сакларга барырсыз! Кирәген алдан карагыз, аек барыгыз! Зур талашлы, җәнҗаллы булачак. Авызыгызны ачып калмагыз тагы! – диде дә чыгарды.

Пристав башкасын аңламады, бары: «Кич сәгать сигезгәчә бушмын, ашыйм, эчәм, йоклыйм, җиде ярымда торып, басурманнарны кыйнарга барам. Бу җиңел эш!» – дип уйлап, хатыны янына кайтты.

---

[1] *Вояк (вояка)* – сугышчы, сугыш чукмары.

## V
## ШӘҺӘР ТЕАТРЫНДА

Ул үзенең ачык, яшерен агентларын ияртеп килеп кергәндә, бөтен театр бинасы, галереясенә чаклы, татар җәмәгате белән шыгрым тулып беткән иде инде. Ул театрның тышкы ишеген атлаганда, сул яктан аңа кемдер килеп бәрелде. Караса, таныш йөз. Бик таныш һәм бик якын арада күргән кеше. Ул, үзе тотарга эзләгән кеше түгелме дип, кадалып карый башлаганда, теге адәм юк булды.

Бу кеше – Фәхри иде. Ул, каушап, үз эченнән вәсвәсәләнеп калды:

«Бу нинди бәхетсезлек. Бер тәүлек эчендә шул эт өченче тапкыр очрый. Бу мине күзәтәме? Әллә язмышның берәр бәласе миңа таба якынлап киләме?» – Шулай вәсвәсәләнде дә, приставтан тизрәк югалыр өчен, халык белән тулып, кайнап торган театр эченә ташланды. Ул кичәге вакыйгадан соң, үзе эзләп табып, Галимов квартирында Булатны күргән, аңардан Гәүһәргә берничә йомыш алган иде. Бүген бу җыелыш арасында туташны күрергә дип исәпләп килгән иде. Иң элек партерга керде. Анда һәммә урыннар тыгызланып тутырылган иде. Башка вакытларда мондый җыелышларга күбрәк приказчиклар, яшь сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, шәкертләр йөрүчән була торган иде. Кайбер яңа фикерле муллаларның җомга намазыннан соң мәчет мөнбәрләреннән: «Җәмәгать, дин-шәригать эшләре дә каралачак, бармый калмагыз!» – дип өндәүләре аркасында, бүгенге җыелышка талчокчы, динче татарлардан башлап, итчеләргә, калын корсак байларга, хаҗиларга чаклы һәммәсе агылганнар иде.

Фәхри, боларны җырып, таптап, үзенә күрергә тиешле туташны эзләде. Шунда алдагы урыннарның берсендә Давыт Урманов белән Габдрахман күренәләр. Госман да күзгә чалынды. Ләкин аңа кирәк кыз юк. Ярусларга, галеркага күз ташлады. Анда тыгызланып утырганнар, ләкин Фәхринең эзләгәне юк. Ул, бәлки, килмәгәндер дип өмит өзгәндә, күзләре кызыл шәкерт Җиһангирга очрады. Тыгызлап барып, аның белән бер урындыкны уртаклашты да акрын гына сорады:

– Күрмәдеңме? Теге Гәүһәрләр килмәгәнме? – диде.

Җиһангир җавап бирмәде: «Тукта әле, тыңларга бир!» – дип кисте. Бу вакыт сәхнә урынына, өстәлләргә урнашкан президиумның уң ягында, трибунада, озынча буйлы, бөтенләй Европача киенгән, түгәрәк сакаллы оратор Әхмәт Нурый әфәнде, бераз гына Истанбулча катнаштырып, бик шома тел, яңгырак тавыш белән сөйләп тора иде. Ниндидер бер уңышлы оста сүз әйтте булса кирәк, Фәхри ишетә алмады, партер халкы ораторга бик каты кул чапты. Шул шау-шу арасында Фәхринең күзе сул яктагы бер ложага төште. Анда иске форма кием, сипкел йөз гимназист Тангатаров белән үзенчә

аристократ кыяфәтле, бик чибәр, тулы йөзле реалист Акчулпанов күренделәр. Тагы чак кына сузылып караса, алар янындагы эшләпәле ике туташның Ширинская Разия белән Илбаева Гәүһәр икәнен танып калды. Фәхри акрын гына торды да шул ложага бару өчен, фойега чыкмак булып, партер ишегенә таба атлады.

Оратор Әхмәт Нурый әфәнде халыкның алкышларыннан соң күтәренке тавыш белән сүз көчәйтеп җибәрде:

– Мөхтәрәм Садыйк хәзрәтнең, – диде, – фикере тугрыдыр, әфәнделәрем!.. Хәзрәтнең дидекенчә, безем дини ихтыяҗларыбыз бик күп. Думада алар каралачак. Аларның безем шәригатебезгә муафыйк рәвештә хәл ителмәге өчен барачак мәбгусләребезнең[1] динебездән хәбәрдар булмаклары лазем. Моңа каршы һичбер шәй[2] диячәгемез юктыр. Фәкать, әфәнделәр, шуны да хәтердән чыгармаялым ки, мәмләкәтебез рус лисаны[3] илә бәрабәр заманның әхвәл вә кидеш атына вакыйф[4], мәмләкәтебезнең низам[5] вә каванинына[6] ашнә булмак лөзүме[7] дә һәммәгезгә мәгълүмдер, әфәнделәрем... Әгәр мөхтәрәм имамнарыбыз, могътәбәр хәзрәтләребез арасында бөйлә икътидарлы[8] затлар булса, мәгальмәмнүният интихабә[9] хазермез, фәкать, әфәнделәр, дин вә милләтебез юлында хезмәтләре сәбкать итмеш[10] могътәдил[11] фикерле зыялыларыбызны сайлаячак улсак, фикри гаҗизанәмә күрә[12], даһа[13] исабәт итмеш[14] улачакмыз... Чөнки безнең мөкаддәс динемез...

Бу оратор Әхмәт Нурый әфәнденең сүзе ярты сәгатькә якын барды. Аңа театрның кайбер өлешләреннән бик озак, бик каты кул чаптылар. Алкыш күтәрделәр. Ләкин бу алкышлар арзанга төшмәде. Партерның җиденче рәт урындыкларыннан берсендә тирече Гайнетдин утыра. Бу – хәзерге социалист кызыл яшьләрне генә түгел, барлык җәдитләрне дә иң пычрак сүзләр белән сүгеп, гаепләп йөрүдә татар базарының каһарманы саналган кеше. Оратор Әхмәт Нурый әфәнденең сүзләренә каршы башланган кул чабулар, алкышлар

---

[1] *Мәбгусьребезнең* – депутатларыбызның.
[2] *Шәй* – нәрсә.
[3] *Лисаны* – теле.
[4] *Кидеш атына вакыйф* – алга китүеннән, прогресыннан хәбәрдар.
[5] *Низам* – тәртип.
[6] *Каванин* – законнар, кануннар.
[7] *Ашнә булмак лөзүме* – таныш булу кирәклеге.
[8] *Бөйлә икътидарлы* – мондый булдыклы.
[9] *Мәгальмәмнүният интихабә* – шатланып сайларга.
[10] *Сәбкать итмеш* – беренче, алдынгы урында булган.
[11] *Могтәдил* – урта.
[12] *Фикри гаҗизанәмә күрә* – кыска фикеремә күрә.
[13] *Даһа* – аеруча, тагын да.
[14] *Исабәт итмеш* – дөрес эшләгән.

тирече Гайнетдин абзыйның йөрәгенә барып кагылдылар. Ул кинәт сикереп торды. Кеше аңламаган бер тавыш белән нидер кычкырып җибәрде. Башындагы чите камалы тирән бүреге, майланып беткән казакие туктаусыз җилләнгән килеш, кызыл калын кулларын бутый-бутый, акырырга тотынды. Алкыш эчендә аның ни дигәне дә ачык ишетелми. Ул тагы яман аяк тибеп, кул сугып кычкырына:

– Бу ни эш?! Бу нинди эш, ә? Сез урысмыни? Сез кайчан чукындыгыз? Нигә кул чабасыз? Бу урыска ошау була ич! Сез кайчан чукындыгыз?!

Тирече Гайнетдин абзыйның ялгыз тавышы бөтен театр җәмәгатенең кул чабуыннан өскә чыкты. Халык, ирексез тукталып, шул якка борылдылар. Гайнетдиннең башка чакта да чиртсәң кан чыгардай кызыл булган йөзе бу акырынудан тагын яман бүртенеп каралды, күзләрен кан басты. Алкыш туктагач, тагы:

– Сез нигә кул чабасыз? Сез урысмыни? – диде дә президиумга ачык сүзләр ата башлады: – «Сайлау, сайлау», диләр! Монда җыен кыска койрыклар эшне үз кулларына алганнар, әмма зур хәзрәтләр артта кысылып утыралар. Бу шәйтан кыска койрыклар үзләре сайланмакчы да, анда Петербур марҗаларына динне сатып кайтмакчы... Голәма барсын! Хәзрәтләр барсын! Безгә дин кирәк! – дип дулап, озак кычкырынды.

Рәис аны тыярга тырышты:

– Сөйләргә сүзегез булса, нәүбәт алыгыз, агай! – диде.

Итче тагы җенләнеп сикереп торды:

– Мин нәүбәт-мәүбәтләрегезне белмим. Петербурга голәма барсын. Бетмәс монда кыска койрыклар! – дип, кулларын төрле якка бутый-бутый кычкырынды.

Рәис тагы туктатты:

– Белмәсәгез, тик торыгыз! Булмаса, мин сезне полиция белән чыгартачакмын! – диде.

Гайнетдин агайның каны бераз басыла төшкән иде инде. Үзалдына нидер мыгырданды да:

– Чыгартыр, эт, чыгартыр. Аның иманы юк. Урыс полиция белән бер кашыктан ашый ул эт! – дип, кире утырды.

Гайнетдиннән соң нәүбәт шәһәр муллаларыннан Габдулла әфәндегә иде. Хәзрәтнең чал кергән түгәрәк сакалы, кара юл сызылган озын яшел чапаны, Бохарача зурлап ишеп чалынган чалмасы – мөселман агай-эне күңелендә җылы уяттылар. Сүзгә шома, тавышы да ягымлы икән.

Ул кайта-кайта:

– Думага голәма барсын, динебезне белгән кешеләр барсын, – дип

сөйләде. Аның өстенә: – Хөкүмәттән муллаларга мәгаш[1] сорарга кирәк, һәрбер имамга үзенең мәхәлләсендәге фисык-фәсадны[2], эчүне, зинаны тыяр өчен гаеплеләрне яткырып суктыру хокукы бирелсен! – дип, сүзеннән тукталды.

Тагы берничә оратор, шул сүзләрне кабатлап, озак сөйли алмаулары өчен гафу үтенеп төшкәч, муллаларга каршы ачы теле белән танылган Дашкин сүз алды, туры кисеп башлады:

– Муллалар бер тиенгә дә ярамый... Анда хәез-нифас[3] турында фәтва сорамаслар, анда үлек күмәргә, җеназа укырга да кирәк түгел. Муллалар алар урядник алдында, полиция алдында дер-дер калтырап торалар. Анда алар ни эшләргә? Ни эшкә ярар? Безгә алар кирәкми, без, хөкүмәт белән сугышып, халык кирәген алырга җибәрәбез... Хәез-нифас турында фәтва сорарга җибәрмибез! – дип бетерде.

Дашкин артыннан Садыйк хәзрәт, аякка басып, аять[4]-хәдисләр[5] китерә-китерә, озын сүз сөйләде. Халык ялыкты, берсе кереп, берсе чыгып йөри башлады.

Президиумнан җыелышның секретаре: “Давыт Урманов!” – дип кычкырды.

Давыт бүген төн буенча, өеннән килгән хатларга каршы язып, Нәфисәгә җавап кайтарып, иптәше Хәбип Мансуровны озату мәшәкатьләре белән җәфаланып, җүнләп йоклый алмый чыккан иде. Арып, ватылып кузгалды, өстендәге пальтосының төймәсен чишә биреп, озын йонлы чиркәс бүреген бераз артка этәреп, аякка басты. Президиумга бармыйча, партерның бер як читеннән сүзгә кереште. Ләкин аны:

– Монда чык, монда чык! – дип, сәхнәгә өстерәделәр.

Фәхри Давытны белә иде. Ни әйтер дип, ишек төбендә катып тукталды, ул беткәч, ложага бармак булды. Давыт сәхнәгә менде:

– Гасырлар буенча голәма, голәма дип тордык. Һәр эшне мулладан көттек. Аларга тапшырдык. Нәтиҗәдә халкыбыз менә шул кызганыч хәлгә төште. Ничә йөз еллык тәҗрибә безне уятырга тиеш, халкыбыз үзенә кем дошман, кем дус икәнен аерырга бик вакыт иде... – дип, башта голәма сайлауга җавап бирде дә, аннан соң «Мөселман иттифакы» партиясенә [8*] тукталды. – Монда һәммә бүреләр җә сарык, җә куй тиресенә төренеп

---

[1] *Мәгаш* – хезмәт хакы.
[2] *Фисык-фәсад* – начар, бозык - азгын эшләр.
[3] *Хәез-нифас* – күрем, аналык каны.
[4] *Аять* – Коръән сүрәләрендә (бүлекләрендә) аерым җөмләләр, бәетләр.
[5] *Хәдисләр* – олуг сүзләр (Мөхәммәд пәйгамбәрнең сөләгәннәре һәм эшләгән эшләре турында).

чыгалар. Бер як: дин, ди, шәригать, ди, шул пәрдә белән капланып, Думага үтмәкче; икенче як: милләт, ди, тәрәккый[1], игътидал[2], иттихад[3], ди, шундый тозаклар белән халыкны ауламакчы, үз артына ияртмәкче дә, Петербурга барып, үзенең кадет дусларына кушылмакчы... анда кәеф-сафа сөрмәкче... Безгә хәзер аңларга вакыт инде: безнең кысылган халкыбызның ихтыяҗларын алу юлында кемнәр ныграк көрәшсә, без народниклар...

Урманов сүзенең ахырына таба бер як аяк тибеп сызгырырга, икенче як кул чабарга тотынды. Оратор аягүрә баскан килеш шау-шуның беткәнен көтә, инде тынып та киләләр иде. Ләкин һаман да аңарга сөйләргә юл бирмәделәр: алгы рәтләрнең берсеннән буе бөкре, яңаклары эчкә баткан, йөзе кипкән, бөтен торышы белән иске мәдрәсә җимеше икәне күренеп торган бер адәм калыкты да, әллә кайдан кысылып, көчләнеп чыккан тавыш белән:

– Мин... җәмәгать!.. – дип кычкырып җибәрде.

Бөтен театр ораторның сүзен бүлгән бу адәмгә борылды. Бик күпләр танып, гаҗәпләнеп, мыек астыннан көлделәр.

Бу – Вафа хәзрәтнең мәдрәсәсендә алдынгы пишкадәм булып бетергән, атаклы эфьюнчы Кәбир хәлфә иде. Ул сигез яшьтән кырыккача җәен-кышын мәдрәсәдә ятты. Зирәклеге начар, әмма тырышлыгы зур иде. Бозыклыкка бармады, ләкин Бохарадан кайткан бер танышы аркылы эфьюнга гадәтләнде. Ул элек көлкерәк иде. Ләкин җәдит-кадим талашы көчәйгәч, дәрәҗәсе күтәрелде. Яңаларга каршы иске схоластиканы яклауда ул беренче сафка күчте. Инде революциягә кергәч, аңа каршы иң явыз дошман булып китте. Ул мәдрәсәне бикләтә. Яңа китап, гәзитне тапса, утка яга. Шәһәрдә җыелышларның берсенә генә булсын аяк атлаган шәкертне мәдрәсәдән куу белән куркыта. Ләкин үзе мөселман җыелышының берсеннән дә калмый, үзе бер фикер әйтү өчен түгел, башкаларның фикерләренә каршы төшәр өчен, башкаларның сүзләрен элеп алып, селкеп салыр өчен ашкынып бара: җыелышта әллә ничаклы вак, мәгънәсез сүзләр сөйлиләр. Юк белән халыкның башын әйләндерәләр – эфьюнчы Кәбир хәлфә барачак та, боларга каршы талаш-моназарә[4] куптарачак, боларны юкка чыгарып ташлаячак, кызу оста сүз белән мәҗлестәге һәммә сүзләрне, фикерләрне рәд кыйлып[5], юкка чыгарачак. Җәдитен, Думасын, көрәшен, кул чабуларын, барын-барын җимерәчәк!

Мондый сугышка ул нык хәзерләнә. Җыелышларга килер алдыннан

---

[1] *Тәрәккый* – үсеш, алга китү.
[2] *Игътидал* – гаделлек.
[3] *Иттихад* – берләшү.
[4] *Моназарә* – бәхәс, сүз көрәштерү.
[5] *Рәд кыйлу* – кире кагу.

мәдрәсәдә, дәресханәгә бикләнеп, сөйләячәк сүзләрен төзә, каршы әйтәчәк игътиразларын[1] берәм-берәм күңеленнән үткәрә, болар һәммәсе бик шәп чыгалар, әлбәттә, бөтен җәмәгатьнең исе дә китәчәк. Ләкин мондый театр, клуб, цирк залларының артык зурлыгымы, өйрәнмәгән булуымы, җыелган халыкның күплегеме, тикшерелгән мәсьәләләрнең бөтенләй яңалыгымы, нәрсәдер аның әфьюн белән изелгән нервларын баса, нәрсәдер аның йөрәген кыса, тавышын кыса, аның көчен ала. Ул һәрбер мәҗлестә берничә тапкыр дәртләнеп аякка баса: «Мине нәүбәткә языгыз!» – дип кычкырырга уйлый. Кайбер чакта каршы җавап бирергә уңайлы урыннар чыкканда, сөйләп торган ораторның сүзе барганда, нидер әйтергә теләп сикереп тора. Ләкин шундый гөнаһ-шомлык: нәрсәдер аның йөрәген кысып ала, бугазын буа башлый, аның теле-тамагы кибә, әзерләнгән сүзе онытыла, бугазыннан тавыш чыкмый; ул газап, каһәр эчендә, күзләре томаланып, кире урындыгына чүгәргә мәҗбүр була. Аһ, әгәр дә Алласы ярдәм биреп, ул бер генә, тик бер генә тапкыр шунда авызын ача алса, ничек тә берничә сүз чыгара алса иде – аннан соң мәйдан аныкы булачак, аның сүзе, фикере, мәдрәсә моназарәләрендәге кебек, агып китәчәк. Зур аш мәҗлесендә, өлкән байлар алдында, заманының иң зур хәзрәтләрен, иң зур мөдәррисләрен мантыйк, кәлям[2] мәсьәләләрендә аптыратып, мөсәлләм иткән[3] кебек, бу зур шау-шулы җыелышны да аяк астына салачак. Ләкин шул бәхетсез тамакны нәрсәдер буа, йөрәкне нидер кысып ала, инде сүз әйтәм дип аякка басканда, тагы күз алды караңгылана, бугаз буыла, тавыш чыкмый – ул тагы бәхетсез булып кала.

Урмановның голамә турында ачы сүзләр кулланып китүе аны бу тапкыр яңадан аягына калкыткан иде инде. Нәүбәтсез булса да, бәхетенә каршы, кинәт сикереп торып, күп җәмгыятьләрдән бирле беренче тапкыр: «Мин... җәмәгать!..» – дип кычкырып җибәрә алган иде.

Бик мөмкин, аның хәзерләп килгән моназарәсе, бәлки, агып китеп, бар халыкны хәйран иткән дә булыр иде. Ләкин икенче бәхетсезлек килеп басты: теге тирече Гайнетдин тагы ыргып торды да, майлы җиңнәрен селкә-селкә, театрны яңгыратып җибәрде:

– Әйтегез! Җә, Алла хакы өчен әйтегез... Бу кыска койрык кем бу?.. Үзе китапча сөйли, әмма тел төбе кяфергә бара. Әйтегез, бу ни хәл? Имеш, җир кирәк, ирек кирәк! Имеш, боларны алып бирер өчен сулларны сайларга кирәк! Имеш, мөселманнан кеше булмаса, сул фикерле урыслар белән

---

[1] *Игътираз* – каршы фикер.
[2] *Кәлям* – сүз; бу урында «Коръән» сүзе.
[3] *Мөсәлләм итү* – сүз көрәштереп җиңү; әйткән фикере белән ризаландыру.

берләшергә кирәк1 Әйтегез, моны кем сөйли? Бу ни дигән сүз? Безгә җир дә кирәкми, бернәрсә дә кирәкми! Безгә дин кирәк, шәригать кирәк! Урысны сайлап дин табыламы, урыс липутат[1] синең өчен тырыша диме? Тот капчыгыңны, бик тырышыр!

Тагы кычкырыш-талаш күтәрелә, кыңгырау туктаусыз шалтырый, рәис бик зур көчлек белән, кычкыра-кычкыра тамагы карлыгып беткәч кенә мәҗлесне тәртипкә кертеп, икенче тапкыр куркыта:

– Агай, сезгә соң мәртәбә әйтәм: сүзегез булса, нәүбәт алыгыз, тәртипне бозмагыз, әгәр яңадан бер генә мәртәбә нәүбәтсез сүз башласагыз, мин сезне мәҗлестән чыгартачакмын...

Гайнетдин алай тиз каушардай күренмәде, яман усал кызган тавыш белән театрны яңгыратты:

– Чыгармагаең!!! Тапкан бер сүз: имеш, мәҗлестән чыгартам. Бик исем китми, чыгарта бир! Минем сүзем шул: монда җыен кыска койрык дин сатарга җыелганнар, безгә җир кирәкми, дин кирәк! Кадалыгыз, муеныгыз астыгызга килсен, кяферләр! – дип акырынды да үзе үк йөгерә-йөгерә чыгып китте.

Әфьюнчы Кәбир хәлфә шул баягы: «Мин... җәмәгать!..» – дигән сүзе белән калды, аның яңадан кузгалып сүз башларга куәте җитмәде.

Тирече Гайнетдиннән соң итче Фәсхетдин аякка басып:

– Бу хәерсез кызыл авызлар кайдан килеп чыктылар соң, явызлар? Ул нинди сүз? Хәзрәтләр бар чагында урысны сайларга димлиләр бит. Иман кая? Оят кая? Нинди акылдан шашкан кызыл авызлар болар?.. – дип лыгырдана башласа да, тавышын җүнләп ишеттерә алмады, гайрәт, кыюлык ягыннан бу инде тирече Гайнетдиннең баласы гына иде. Рәис, каты берничә сүз ташлап, моны урынына утыртты.

Тәртип буенча барганда сүз Госман учитель Азаматовка бирелергә тиеш иде. Рәис үз эченнән уйланды да бу таркалып, сугышып барган җәмәгатьнең фикерен борып җибәрүне дә кирәк тапты: дүрт-биш кешене аша күчереп, сүзне теге бераз Истанбулчарак сөйләүче Әхмәт Нурый әфәндегә бирде. Бу үзенчә бик тәрбияле рәвеш белән, ләкин бераз әрнегән, бераз гаҗәпсенгән, шулай да юлга төшерүгә өмитләнгән тавыш белән, үзенчә бик татарча сөйләргә тырышып, сүз башлады:

– Әфәнделәрем, – диде, – мин яшьләремезнең бер хәленә һәм тәгаҗҗеб[2] һәм тәәссеф итәм[3]. Европада, Америкада капитал бар. Капитализм нигезенә

---

[1] *Липутат* – депутат.
[2] *Тәгаҗҗеб итү* – гаҗәпләнү.
[3] *Тәәссеф итү* – үкенү, ачыну.

корылган андагы тормыш халыкны икегә аерып, бер якта зур миллиардер Ротшильдләр [9*] вөҗүдә килгән[1] булса, икенче якта эшчеләр сыйныфы мәйданга чыккан... Шулай ук бер якта алпавытлар, мәмләкәтнең бөтен җир-суын кулларына алып, крәстиәннәргә, авыл халкына һичнәрсә калдырмаганнар... Анда җир мәсьәләсе, эшче мәсьәләсе туган икән – һич тә гаҗәпләнергә ярамый, аларда ул табигый! Әмма бездә ни бар? Безнең мөселманда кая капиталистлар да кая зур алпавытлар? Шулай булгач, бездә халкыбыз дин, милләт намына[2] берләшергә тиешле. Сыйныф аермасы баш күтәрергә бездә урын юк иде. Ләкин дөньяда тәкълид[3], мода бәласе һәрнәрсәдән көчле имеш ки, безем яшьләремез дә шул мода, тәкълид афәтенә йотыларак...

Оратор сүзен бетерә алмады, кайдандыр арттан Кавказлы Гәрәй Солтан яман сызгырып җибәрде; аны, Гәүһәрләр ложасына барырга кузгалып та, партер ишеге төбендә катып калган Фәхри яклап алды – кушылып сызгырырга тотынды.

Алдан, уртадан, Әхмәт Нурый әфәнделәр исемен атап:

– Яшәсен! Яшәсен! Нигә сүзне бүлдерәсез! – дип, кул чаба башладылар.

Тагы талаш, ызгыш, «сөйләсен», «сөйләмәсен»нәр театрны күтәрделәр. Рәис карлыккан тавыш, көчле кыңгыравы белән бик озак акырынганнан соң гына мәҗлесне яңадан тәртипкә кайтара алды. Әхмәт Нурый әфәнде, тагы сүз алып, озак сайрады.

## VI
## ГӘРӘЙ СОЛТАН КАФКАЗЛЫ

Фәхри моны тыңламады. Партер ишеге төбенә аягүрә басып тыгылган халыкны җырып, этәреп, кысыла-кысыла фойега чыкты да Гәүһәрләр утырган ложага таба борылды. Ләкин кереп китә алмады. Ачыйм дип ишек тоткасына кулын салганда, арттан берәүнең акрын, әмма кискен тавышы аны туктатты. Әйләнеп караса: ярым грузинча, ярым Казан татарынча киенгән, карасу кипкән йөзле бер кеше каты басып моңа таба килә. Фәхри аны чак таныды: Гәрәй Солтан икән. Күргәч, шатлана биреп, аңа каршы барды. Булатны моның бүлмәсенә качырып китерү вакыйгасының уңышсыз бетүе аркасында бераз борчылган Фәхри, инде менә шул хәзерге каты талашлар эчендә бөтенләй үз итеп, Гәрәйнең ышанып сүз башлавы белән канатланып, куанып китте. Баскан җире ныгыгандай булды.

---

[1] *Вөҗүдә (вөҗүдкә) килгән* – барлыкка килгән.
[2] *Намына* – хакы өчен.
[3] *Тәкълид* – иярү, башкалар эшләгәнне эшләү.

Фәхри монда, шәһәрнең кызыллары арасында, Булатка кызыгып йөри иде. Менә соңгы көннәрдә каяндыр бу Кавказлы Гәрәй Солтан кайтып төште. Ул үзе бераз серлерәк тоела. Башта аның турында төрле сүз булды. Максималист [10*] икән, элек меньшевик [11*] та булган икән, дип чәйнәделәр. Аны Давыт Урмановлар, Хәбип Мансуровлар үзләренә тартып карадылар бугай. Аннан соң, җүнсез нәрсә, меньшевик икән ул, дип сүгә башладылар. Булатлар иптәше элекке учитель Госман Азаматов белән Акчулпановлар да начар караган кебек күренәләр. Алар Гәрәйне бер максималист дип, бер партия дисциплинасын җимерүче боевик дип читкә этәрделәр.

Ләкин бу төрле гайбәтләрнең һәммәсе бик тиз арада юкка чыктылар. Ул үзе Казан ягыныкы икән. Бабасы иске заманның николайский солдаты булып, егерме биш ел хезмәт иткән дә, авыл белән дөньясы өзелгәч, шәһәрдә каравылчы булып торып калган. Анасы Казан байларының элекке комач, кытат[1] фабрикаларында эшләп гомер иткән. Гәрәй шул фабрикаларда туып үсә дә аталары белән Казанга күчә. Алафузов, Крестовников заводларында[12*] сигез яшьтән эшләп, кыйналып-сугылып үсә дә егет булып килгән елларда, үзеннән зур татар эшчеләренә кушылып, Бакуга китә. Анда Тагиев фабрикаларында эшләгән чакта партиягә алына. Ике тапкыр кечерәк экспроприациягә катнаша. Инде менә эләктем дигәндә, бер караңгы төндә, Кавказдан Русиягә кача. Булат исеменә бирелгән явка буенча Казан организациясенә килеп төшә. Килеп тә төшә, татар эшчеләренең беренче зур ачык митингларында ук меньшевикларга, эсерларга [13*] каршы сугыш ача; эт итеп сүгеп ташлый да аларга каршы татар эчендә туктаусыз фронт рәвешендә утлы кампания алып китә. Аңа кадәрле иттифакчыларны сүгү гадәте кызыл яшьләр эчендә көчле иде. Гәрәй, менә шул «Иттифак» белән янәшә меньшевикка, эсерга каршы ут ачып, фронт алып бара. «Иттифак» – чалмалы, кәләпүшле кадет булса, бу меньшевиклар, эсерлар да шул «иттифак-кадет-буржуа»ның сул кабыргасы гына. Аерма бары сүздә генә, тамырлары-төпләре барының да бергә кайта», – дип кискен куеп җибәрә. Кызыл яшьләрнең бер төркеме Гәрәй Солтанның теленә, кискенлегенә иярә башлыйлар. Эшчеләр ничектер берьюлы аны үз кешеләре итеп эчләренә тарталар. Ничектер ул мондагы татар эшчеләре арасында үз булды да китте. Әйтерсең, оешманың ишеген ачып керә дә, беркемнән сорамый-нитми, аның түренә үзе генә менеп утыра. Шунда үзенчә хуҗалык-җитәкчелек итә башлый. Шуның белән бергә нindидер кискенлек гадәткә керә. Шуның сәбәпле иптәшләр арасында да көн саен аңлашылмаулар чыга. Реалист Акчулпанов белән Госман Азаматов партиянең түгәрәкләрендә яхшы эшләп

---

[1] *Кытат* – парча, кытай ефәге.

киләләр, болар файдалы кешеләр саналалар иде. Әмма Гәрәй аңа карамады. Беренче тапкыр татар эшчеләрен, яшьләрне кораллы күтәрелешкә әзерләү, кораллану чараларын табу турында сүз ачканда, Госман белән Акчулпановның мыек астыннан көлеп, мыскыл беләнрәк караганын шәйләп алды да иптәш дип тормады: «Сез меньшевик, сезне куарга кирәк, сез мунчала булып партия оешмасының аягына бәйләнмәгез», – дип, өсләренә җикеренде. Госман байтактан эшли. Парткомда да аны беләләр. Ышанычлы кебек саныйлар. Ул Гәрәйнең бу сүзләрен күтәреп кала алмый: «Син дезорганизатор!.. Син дисциплина бозучы!» – дип каты җавап бирә. Эш бик зурга китәргә тора, һәр ике як, бер-берен гаепләп, партия комитетына мәсьәлә куярга әзерләр иде. Арага Булат килеп кысылды да коткарып алды. Гәрәй дә, Госман да аның сүзен тыңладылар – талашны кыздырмадылар. Ләкин эчләреннән икесе ике план, ике перспектив, ике төрле көрәш турында уйлый торган кешеләр булып калыпландылар. Госман үзарада укымышлыларның алдынгысы булып танылa. Ул түгәрәкләрдә, митингларда, иттифакчылар белән теория буенча зур талаш алып бара. Кирәксә, мәкалә яза ала. Ул үзен күбрәк шул якка тарта. Әмма Кавказлы Гәрәй Солтан аның кебек сүзгә оста түгел. Озын итеп, сәгать буенча доклад ясарга аның хәленнән килми. Ул революция фронтының үзәге дип икенче төрле эш алып бара: ул революцияне сугыш дип, канлы, каты, рәхимсез сугыш дип аңлый. Башка һәрбер сугышта булган кебек, бу канлы, каты, рәхимсез революция сугышларында патшага, буржуага, алпавытка, боларның гаскәрләренә, жандармнарына каршы нык коралланырга кирәк дип ышана. Шул ышануы буенча эшче яшьләрне коралга өйрәтү, отрядларга туплау, бу отрядларда чыныккан боевик большевиклар ясап чыгаруны революция эшләренең иң алдынгысы дип белә. Менә бу эшләрнең һәммәсе өчен акча кирәк, партиянең, оешмаларның кулында акча булырга кирәк; моның өчен әгъзалардан, ихтыярый ярдәмнәрдән җыелган нәрсә генә җитми; моның өчен йөз меңнәр, миллионнар кирәк; боларны табар өчен хөкүмәтнең почталарын, банкларын, поездларын басып, алтынны талап алудан башка юл юк; шуңа күрә, укымышлыларча әйткәндә, экспроприация ясарга[1] кирәк дип яна. Шул фикерләрне партия эчендә якларга, шул эшне туктаусыз алып барырга үзенең бөтен көчен түгә. Болар белән янәшә, монда кайтып төшүгә, тагы икенче әйбергә ташланды. Менә кайчан инде Булатлар гәзит чыгарырга рөхсәт сорап биргәннәр. Әле бер, әле икенче сылтау табалар да кире кайтаралар. Башкалар татарча үз гәзитләрен өлгерттеләр, әмма иң элек рөхсәт соралган татар гәзите – боларныкы булган хәлдә, һаман бирергә исәпләре күренми; Гәрәй, моңа

[1] *Экспроприация ясарга* – көч белән тартып алырга.

әрнеп, татарча яшерен типография белән саташа башлый. Ул тиз арада татар типографияләренең полиграфистларыннан ике егет белән танышты. Болар һәркөн кич, кесәләренә тутырып, шрифт урлап чыгуны гадәткә әйләндерделәр. Унҗиде генә яшьлек татар полиграфисты Айдар, беркөнне янып, күзендә уйнаган шатлык уты белән ялкынланып килде дә канатланып кычкырды:

– Гәрәй абый! Ни әйтерсең?! Ике көннән бастонны[1] урлап чыгарам... Куярга урын әзерлә! – диде.

Банк, почта-поезд басу белән янәшә барган кораллану хәзерлеге өстенә, Гәрәй Солтан алдында менә бу яшерен типография өченче фронт булып планга керде. Ул, бу эшләр эчендә янып, Акчулпановны, Госманны бөтенләй онытып җибәрә торган булды. Бу зур эшләрне аңламаганга, мыскыл белән караганга, ул, искә төшкәндә, аларны дошман меньшевик дип карап, төкереп җибәрә торган булды. Ләкин Булатны үзенә тартырга, тегелердән аерырга, аларга җибәрмәскә тырышты. Бакудан аның явкасы белән килгәнгә генә түгел, болай сүзгә кискенлеге, дошманга каршы усал, үткен теллелеге, көн-төн завод-фабрика тирәсендә, эшчеләр эчендә кайнавы өчен дә Булатны ярата иде. Октябрь эш ташлауларында тоткан тактикасы аның күңеленә бик ошап калды. Ләкин шулай да үз эченнән әрнеп куя иде. Булатның, яшерен отрядка, боевикларга кереп, экспроприациягә бара алмавын Гәрәй тиз сизенде, шулай ук, гаскәргә каршы кораллanып, сугышка чыкканда да бу Булатлар бик зур батырлык күрсәтә алмаслар бугай дип, күңеленнән борчылды, шуның белән үз эчендә кайбер вакыт: «Бу да мәми авыз шул! Бу да йомшак муен шул! Их, кайдан аласың Ризван Вахитов кебек корыч егетләрне!» – дип өзәләнеп куя иде. Шулай да татарлар арасында иң якын күргәннәрнең, иң нык ышанганнарның берсе, иптәш итеп караганы – Булат булды. Ул кайбер чакта бөтен комитет турында да шиккә килә, экспроприация эшләрен аңлап бетермиләр бугай, дип тиргәп куя иде. Аңа Булат бик озаклап партиянең бу мәсьәләдә нинди юл тотканын сөйләде, партия моңа каршы түгел, ләкин башбаштаклык ярамый, бу эшләр тик партия Үзәк Комитетының планы буенча гына, аның рөхсәте белән генә мөмкин, дип аңлатырга тырышты. Дисциплина турында күп тапкыр кабатлады. Гәрәй аңа карап көлде: «Зинһар курыкма! Беләм. Беләм. Мин – партиянең солдаты. Мин дисциплинаны җимерергә теләмим. Мин бөтен партиягә менә шул фикеремне аңлатырга телим», – дигән мәгънәдә өзеп, кисеп әйтте. Шулай да үзенең планнарын хатага саный алмады. Монда, шәһәрдә, партия җитәкчелеген алып барган берничә иптәшкә киңәшә-киңәшә, үзенең шул югарыгы өч тармак буенча

[1] *Бастон* – бостонка; китап баса торган кечкенә машина.

хәзерлеген аз гына туктатмады, бөтен җаны-тәне белән шулар эченә кереп китте. Көнендә дә, төнендә дә шулар белән саташты. Татар эшчеләреннән Исрафилләрне, Вахитов Ризваннарны, әле яңа катнашып та, бик тиз үсеп барган Галимовларны үз артыннан шул ялкын эченә ияртте, шул казанда кайнатты. Ул баштарак, бәлки, ике оешма уртак фронт тотмасмы, партия моңа юл куя ич дип, бу турыларда Давыт Урманов белән дә ике тапкыр утырышып карады: «Сүз боткасы белән гомер үткәрергә ярамый. Николайның туп, мылтыкларына каршы кәгазь пулеметтан сүз атып кына революция җиңә алмаячак», – дип, каты бәйләнде, ләкин күңеле тиз суынды, ике оешманың уртак фронты фикерен ташлап, тагы үзенең рус-татар иптәшләре эченнән боевиклар эченә чумды. Шул дулкынга таба Булатны да тарту исәбе белән янып, өч тармак буенча хәзерлек көрәшендә яна бирде.

Фәхри, читләп-читләп, бу хәлләр, бу көрәшләр турында кайбер нәрсәләр ишеткән иде. Моңарчы бик үткен интерес[1] белән бу ярым грузинча, ярым Казан татарынча киенеп йөргән киң җилкәле, каты басымлы, чандыр йөзле эшче егетнең эшләрен күзәтеп килә, аңа якынлашырга тели, әмма бер яктан бераз курка да иде. Ләкин бүген бу шәһәр театры җыелышында аны очрату хәтеренә дә килмәгән иде. Әхмәт Нурый әфәнденең трибунадан сөйләгәнен тыңларга теләмичә фойега чыгып, аннан Гәүһәрләр ложасына керим дигәндә артыннан кычкырган кеше – шул Кавказлы Гәрәй Солтан икәнен күргәч, бу куркуы тагын килде. Ләкин егет бу куркуны тиз җиңде. Бераз каушаулы кызу шатлык белән аңа таба атладымы, миенә бер минутка ахмак уй менде: «Бу ни хәл? Әллә мине банк басарга чакырамы? Чакырса, барыргамы, юкмы?» – дип калтыранды. Ләкин үзенә җавап табылып өлгермәде, Гәрәй аны бер почмаккарак тартты да санап, кисеп әйтте:

– Син Гәүһәргә барасыңмы? Җаен тап та аңардагы әйберләрне ал. Булат та җүләр кеше. Андый элементларга ышанырга ярыймыни! Барын да ал: дүрт адрес, өч паспорт, бер браунинг булыр. Бүген үк ал. Ишеттеңме?! – диде. Үзе, тиз-тиз кире борылып, тегендә, тагы әллә нәрсәдән шаулаша башлаган партерга кереп, югалды.

## VII
## КӨНЧЕЛЕК

Фәхринең өстеннән тау төште. Шул арада аның маңлаена салкын тир чыккан иде. Ярый әле андый куркыныч эшкә чакырмады. Чакырса, ни эшләрсең? Бармасаң, эт итәр, барсаң – үлем! Харап бит! Ярый, җиңел котылдым. Әле әйткәне дә күңелле йомыш. Гәүһәр белән дә, курсистка

---

[1] *Интерес* – кызыксыну.

Ширинская Разия белән дә арада бер нечкә җеп урала башлый. Ул үзе генә ни тора!

Ул шат күңел, җиңел адым белән ложага барып кергәндә, әле һаман Әхмәт Нурый әфәнденең ярты татарча, бераз Истанбулча сайравы туктамаган иде. Ахры, кызларның бу бетмәс-төгәнмәс сүздән, талаштан эчләре поша башлагандыр: Фәхри барып керүгә, аны елмаеп каршы алдылар, ашыгып-ашыгып, иң яңа, иң соңгы сәяси гайбәтләр турында сорашырга тотындылар. Чәчләрен кыскартып кискән, озын буйлы, кара-туткыл чибәр йөзле курсистка Ширинская туташ, зур күзләре белән елмая-елмая көлеп, русча әйтте:

– Расмы, Фәхри? Кадыйр байның яшь хатыны Һаҗәр бикә теге матур шәкерт Җиһангир белән качып киткән имеш. Чынмы шул, юктыр ла! – диде. Аның артыннан ук, күзләрен тагы нурландыра төшеп, хәйләләп, мәкерләп өстәде: – Габдрахман өйләнә икән, ишеттеңме? Теге Нәфисәне ала имеш, тик бичараның яңагын ярганнар, шул гына туйга комачаулый бугай... Безнең Давыт ни эшләр, Нәфисә аның беренче мәхәббәте ич! – диде, вә һиһелдәп, йомшаклап көлде, җавап көтеп, егеткә туры карады.

Ләкин Фәхри бу сүзләрне, бу гайбәтләрне киңәйтеп тора алмады; ул кыска-кыска җаваплар кайтарды да сүзгә аз катнашып, ничектер эчке әрнү, зәһәрле караш белән ачуланып утырган урта буйлы, нечкә зифа гәүдәле, гаҗәп дәрәҗәдә нечкә, зәһәр, ләкин матур алсу иренле кызга – эшләпәгә тоташтырып, куе кара вуаль белән битен каплаган Гәүһәр туташның янына ук килде. Гаҗәп нечкә, тирән сер әйткән кеше кебек, акрын, яшерен тавыш белән:

– Гәүһәр иптәш! Мин Булаттан килдем, сезгә бик зур йомыш, мөмкин булса, бер генә минутка чыгыйк! – дип үтенде.

Кыз, кинәт селкенеп, Фәхригә борылды, күзеннән ут уйнатып, зәһәр белән җавап бирде:

– Булмас! Миңа Булат сүзе белән килеп йөрмәгез! Аның турында ишетәсем дә килми, әнә томшык марҗасы Нинага барыгыз! – диде дә, бөтенләй кискен борылып, партер халкы өстеннән сәхнәдәге ораторга капланып катты.

Фәхри, ни әйтергә белми, аптырап калды. Ширинская Разия туташ, боларның ике арадагы серләренә катнашмыйм дип арткарак чигенеп утырса да, һәммә сүзләрен ишеткән иде. Егетнең ни эшләргә белми аптырап торганын күргәч, катнашмый булмады: урыныннан кузгалып, уен-көлке төсен бөтенләй ташлады, шелтә тавышы белән сөйләнә-сөйләнә, дусты Гәүһәрнең култыгыннан тотып, үзенә таба әйләндерде, шундый ук шелтә белән русча әйтте:

– Акыллым, син нәрсә кызасың? Ул ни сүзең? – дип, күзенә батырып

карады.

Кичә тентү вакытында нинди трагедия булып үткәне Ширинскаяның колагына чалынган иде. Ләкин ул, Гәүһәрнең бик яшерүчән астыртын табигатен аңлаганга, ул вакыйганы белмәгәнгә салынган, ул турыда үзе сүз ачмаган иде. Эш болай кискенләшкәч, һәрвакыт олырак, сабыррак булып килгән туташ чыдамады, сергә катнашты:

– Гәүһәр иркәм, ачуланма! Мин барын да беләм. Син юкка бәйләнәсең: ул Нина дигәнең Коля белән тора ич! Булатның партия иптәше генә ул. Җүләрләнмә! – диде.

Бу сүзләр соңында Гәүһәр кинәт Фәхригә борылды, ачудан шатлыкка әйләнеп, алсулана башлаган йөзеннән вуален ачып җибәрде, Ширинскаяның кулыннан тотты, тиз, кискен тавыш белән:

– Әйт, син боларны кайдан беләсең? Тентүдә минем эләгүне кем әйтте? Нинаның Коля белән торганын кайдан беләсең? – дип, күзләренә текәлеп, җавап көтеп катты.

Курсистка кыска чәчләрен башы белән артка селкеп җибәрде дә йомшак елмаеп әйтте:

– Җаным! Ник белмәскә: Нина минем дустым. Мин аның белән гимназия бетердем. Аның белән Петербургта курсларда бергә укыдым. Анда бергә түгәрәкләрдә эшләдек. Бергә куылдык, бергә монда туган илгә җибәрелдек! Аның белән безнең арада яшерен нәрсә юк. Ул миңа үзе сөйләде, син юкка җәнҗал куптарма! Булатка бәйләнүең урынсыз! – диде.

Ул үзе дә кайчандыр күңелендә Булатка каршы бер дулкын асрый иде. Ләкин егет дуслык күрсәтмәде, Гәүһәр ничектер аны тиз арада үзенең тозакларына урап алды; Ширинская үзенең икенче кандидаты булган Урмановка борылды, сәяси эшләрендә дә Булатлардан аерылып, Таңгатарлар, Давытлар белән багланып китте. Күңелендә Булатка каршы аз гына җылы, яшерен тойгы белән бергә бетмәс-төгәнмәс үпкә дә, шелтә дә бар, урыны чыккан саен ул аны тыш яктан чәнчеп алырга ярата иде. Гәүһәр кинәт бәйләнә башлагач, үзен тыя алмады, Булатны яклап, аннан да бигрәк, ямьсез, ләкин гаҗәп яхшы күңелле, гаҗәп сөйкемле Нинаны да аклап сүз әйтми калырга көче җитмәде. Гәүһәрнең өстеннән кара болыт таралды. Ул әле Фәхригә, әле Ширинскаяга якынлашып:

– Менә нәрсә икән! Мин белмәдем ич! – дип, шатланып елмайды да, дус кызына: – Син үпкәләмә, мин бер генә сүз әйтәм Фәхри иптәшкә! – дип, урыныннан сикереп торды, ридикюлен алып, ашыгып-ашыгып фойега чыкты.

Фәхри аңа иярде. Икәүләп фойе буенча йөри башладылар. Кызның йөзеннән, күзеннән, бөтен торышыннан астыртын зәһәр әсәре таралды; ул

җанланып, алсуланып, бөтенләй изгеләнеп, Фәхригә дус, сердәш булып китте, русча тезәргә тотынды:

– Дуслыкка каршы дуслык булыр, Фәхри иптәш, сез инде Булатка барын да үзегез сөйләгез. Сез бит көтелмәгәндә минем җүләрлекләремә шаһит булып алдыгыз; ярар инде, яшермәссез, барын да, барын да сөйләп бирегез. Тик әйтегез: минем күңелем тыныч түгел, бүген сәгать уникегәчә ул мине ничек кенә булса да күрсен, күрмәсә, тагы үпкәләрмен, мин аңарга бер кыз, бер туташ кына түгел, мин бит аңа эш, көрәш иптәше, революция иптәше, әмма бу гына түгел – мин аңа кыз иптәше дә... Аңладыгызмы?

Фәхри бу чуалчык, катлаулы вакыйга эчендә үзен бераз югалтты. Ул алай укымышлы, мәдәни кызлар белән күп катнашмаган иде, кай яктан китереп сүз кыстырырга аптырады, килешсез чыгар кебек тоелды; шулай да туташ үзе сәяси якны китереп тыккач, егет батырланды:

– Гәүһәр туташ, минем килү бит башка нәрсә өчен: мине сезгә Булат җибәрде. Гәрәй Солтан менә монда күреп, сездәге кайбер әйберләрне алырга кушты, – дип әйтә алды.

Кыз, бу соңгы сүзгә каршы тагы кискенләшеп, зәһәрләнде, тагы күзенә, йөзенә ут чәчрәде:

– Шул булыр, шул Гәрәй Солтан булыр! Мин кем, әллә провокатормы? Нигә миңа ышанмыйлар, Ходаем, дошман киселде ләбаса шул Гәрәй!.. – дип, әрнеп-әрнеп, ридикюлен ачты, тиз генә аның кечкенә озынча көзгесенә каранып, чәчен, эшләпәсен төзәтте дә нечкә күк кардаш-каләм[1] белән блокнотын тартып чыгарды. – Юк, бу хурлык! Бу ышанмау! – дип, зәһәрләнә-зәһәрләнә, аягүрә Булатка русча хат язарга тотынды:

«Зарифкаем! Тентү трагедиясен Фәхри сөйләр. Ул хәзер минем якын дустым булды. Нина турындагы шикләрем дә бетте. Әмма бернәрсә мине газаплый: син нигә миңа ышанмыйсың? Нигә бу Гәрәй Солтан мине дошман күрә? Әллә булмаса, мин һаман сезгә йомышка-юлга йөри торган чибәр туташ кынамы? Болай каравыгыз – мине тәхкыйрь итә[2]. Син Гәрәйгә әйт: мин әйберләрнең берсен дә бирмим. Бүген бирмим. Үземдә саклыйм. Вакыты килсә, үзем илтеп тапшырырмын... Башкалар тагы бер хәл. Булат, син мине аңларга тиешсең! Фәхригә дә әйттем, бүген төнге сәгать уникегәчә мин сине күрергә телим. Юктан котың очмасын. Син бит кырык тапкыр жандармны алдап качкан кеше. Эләкмәбез, кайда күрешергә икәнен үзең билгелә. Көтәм. Үпкәләп, сагынып көтәм, Зарифчыгым!..»

Кыз шулай бетерде, ахырына аен, көнен дә, кулын да куймады. Аны

---

[1] *Кардаш-каләм* – дөресе: карандаш-каләм булса кирәк.

[2] *Тәхкыйрь итә* – хурлый

Булат шулай өйрәткән иде. Кәгазьне урталай бөкләде дә Фәхригә сузды, шунда блокнотта ике марка күренде, ул тиз генә алды да, кәгазьне, телеграм кебек итеп, маркалар белән бикләп ябыштырды.

– Сезнең күзегез төшмәсен, ябыштырдым да, – дип елмаеп, Фәхригә хатны тоттырды.

Егет, як-ягына карана биреп, театрдан чыгып сызды.

Кыз, йөрәген каплаган авыр чуалчык хәлләрнең болай күңелле бетүенә шатлана-шатлана, яңадан ложага керде, аның күңеле тынычланды, күтәрелде; бүген төнге уникегәчә Булатны күреп, аның белән бу ышанмаулары турында сөйләшә алса, тагы да канатланачагын уйлады. Шулай дәртле хәлдә кереп, инде ораторның һәммәсен, начарын-яхшысын бик нык тыңларга дип уен беркетеп, Ширинская янына сүзсез килеп утырды.

## VIII
## ГАБДУЛЛА АБЗЫЙ

Мәҗлеснең барышына караганда, Думаларга сайлау эшләрендә дини муллалар белән кадет фикерле зыялыларның уртак фронт тотачаклары сизелә; бу ике төркем берләшерләр, өлешне уртак бүлешерләр, хәзрәтләрдән берничәне, адвокат, кадет, иттифакчы мирзалардан бер-ничәне үткәрергә булырлар – эш шуңа таба ага. Гәүһәр моны аңлап алды: «Кая соң безнекеләр, Булатка килергә ярамый, тоталар, Гәрәй Солтанның батырлыгы – миңа дошманлыктан үтми, кая соң Акчулпаннар, Азаматлар, нигә сугышмыйлар?» – дип уйланды, ләкин шуның очына чыгарга өлгермәде, бу талашлы җыелышта арып беткән рәис карлыккан тавыш белән:

– Госман Азаматов! – дип кычкырды.

Бүтән чакларда яратмый читкә какса да, Гәрәй Солтан мондый талашларда Госманның көченә, кирәгенә, дөреслегенә ышанып карый иде. Ачык киң йөзе, зур сары мыегы, башка яшьләргә һич тә ошамаган рәвештә, бөтенләй буржуа либералларча яхшы киенеп, галстук, манжетлар белән ялтырап, сәхнәгә күтәрелгән таза гәүдәле бу иптәшне күргәч, түзмәде, эченнән: «Менә кайда аларның кирәге», – дип уйланып, рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Үзе, ачыграк ишетер өчен, партерның стена буйларына аягүрә баскан халыкны тыгызлый-тыгызлый, алга таба кысылды...

Бөтен театрда Госманның сүзен тыңларга аерым бер хәрәкәт дулкыны үтте. Ул – арада иң эшлеклеләрнең берсе санала. Аның турында, атасыннан калган йортны сатып, берничә мең акчаны партия һәм революция файдасына тоткан имеш, дигән сүз йөри. Ул кызыллыгы өчен үзенең учительлек урыныннан куылды. Шулар белән бергә, ул, Булаттан кала, сәяси ягы белән иң хәзерлекле татар яшьләренең берсе булып бара, русча, татарча яхшы

ораторлык итә. Ул сүз башлар-башламас, бер як кул чабарга теләде, аңа каршы каяндыр:

– Ишеттек инде, бетмәс кызыл авызлар!.. – дип кычкырып, сызгырып җибәрделәр.

Госман Азаматов боларга карамады, сабыр тавыш белән санап сөйләргә тотынды:

– Авыл ач. Аңа җир кирәк. Эшче ач. Аңа хезмәт хакы арту кирәк. Бөтен хезмәт халкы авыр түләүләр белән күмелгән – боларны җиңеләйтергә кирәк. Бөтен ярлылар, барлык милләтләр кысылганнар – боларга азатлык кирәк. Бу кирәкләрне булдыру өчен пролетариат сугышка чыкты, крәстиән алпавытка каршы күтәрелде. Бөтен мәмләкәтне революция дулкыны басты. Бу дулкын үсә, көчәя! Бу каты дулкын эчендә үзенең әҗәле якынайганын күргән самодержавие халыкны алдарга теләде, бер кулы белән – революцияне буарга корал, жандарм, полиция, зиндан, палач хәзерләсә, икенче кулы белән – кәгазь манифест, ялган азатлык игълан кылды. Хәзер менә шул халык дулкынын басар өчен Дума җыймакчылар. Төрле сыйныфларның «кирәкләрен» булдыру өчен дип парламент коралар... Ләкин бу Дума ни бирер? Бернәрсә дә бирә алмас, бюрократия кулында уенчык булыр, пролетариатның революция юлындагы зур көрәшләрен басарга терәк булыр, халыкны алдарга тозак, пәрдә булыр. Шуңа күрә без әйтәбез: эш Думада түгел, Дума берни бирмәс. Бирергә теләсә, аны куарлар, бу бары революциягә каршы кискә[1] булып ятыр, мондый Дума пролетариатка да, крәстиәнгә дә, азатлык теләгән милләтләргә дә һичнәрсә бирә алмас, моның кирәге юк, монда сайлау дип йөрергә ярамый, Думага бойкот итәргә кирәк, революциянең юлы, көрәше башка методлар буенча...

Оратор сүзен бетерә алмады, тагы аяк тибеп, урындык сугып сызгырырга керештеләр, долой, туктасын, сөйләмәсен, дип акырырга тотындылар. Боларга каршы: «Ярый, егет, бүген кирәк җирне кашый белдең!» – дип, үзалдына куанып, Госманны бөтенләй яратып, Гәрәй:

– Сүз бирегез! Әллә сез жандар булдыгызмы? Ул көнне демонстрациядә жандарлар Булатның телен кистеләр... Сез монда Азаматка сүз бирмисез! Бу ни эш! Әйдә сөйләсен!.. – дип шундый каты акырып җибәрде, бөтен театр, партер, ложалар – һәммәсе гөр килделәр, барлык халык: «Бу кем?» – диешеп, тавыш килгән якка, ярым грузинча киенгән Гәрәй Солтанга карап:

– Бу кем тагы? Мөселманча сөйли ләбаса! – дигәләп, аптырап каттылар.

Тегендә полиция агенты кузгалды. Алга таба атлый башлады, ләкин

---

[1] *Кискә* – кузгатып булмый торган авыр әйбер.

шул арада партерның уң як ишеге төбендә бик зур шау-шу күтәрелде. Ниндидер бер исерек:

– Юк! Керәм дигәч керәм! Керәм дигәч керәм! – дип гырылдый.

Аңа каршы русча берничә тапкыр:

– Тот! Җибәрмә! Нинди исерек баш ул! – диешеп кычкырышалар.

Халык җыела, шау-шу күтәрелә. Шулар эченнән башына ертык фуражка, өстенә пычрак иске сәләмә пинжәк, аягына ташландык чабата кигән бер исерек татар килеп чыга да, туп белән аттырган кебек, тиз-тиз уртадагы, урындыклар арасындагы тар юл буенча сәхнәгә таба йөгерә. Рәис ни эшләргә белми катып кала, халык шаша, мәҗлеснең тәртибе югала, театр гөж килә; исерек татар сәхнәгә килеп җитә дә, бер кулы белән барьер тактасына суга-суга, кычкырырга тотына:

– Рәхмәт, энем! Рәхмәт! Кем ул әле генә сөйләде? Рәхмәт аңа... Җә әйтегез, мин кем? Җә әйтегез, мин кем?..

Бу көтелмәгән хәлдән рәис бөтенләй агарынды, аптыранды. Янындагыларга, секретарьга карап:

– Кая соң полиция? Бу адәм хурлыгы ич! – дип кычкырды.

Исерек, аңа аз гына да карамый, үзенекен яра бирде:

– Җә әйтегез, мин кем? Ясакка актык атымны саттырдылар. Ачлык елда өч балам белән авыру хатыным ачлыктан шешенә башлагач, күз яшенә чыдамадым... җир-иманамны саттым... Җир булмагач, авылда ничек торасың? Калага килдем... Өч ел ачлы-туклы тордым... Менә бер атна инде заводтан кудылар... Эш юк, диләр. Инде кая баш сугарга?.. Ә монда мин тыңладым, безнең фәкыйрь халыкка каршы әйтүчеләр дә булды...

Шул арада ишектән полиция кереп, исереккә атылды, ләкин ул тиз бирелмәде, аңа карышып, кулына фуражкасын алды да тагы исерегрәк тавыш белән кычкырына бирде:

– Менә урыс фуражкасы... Сез моны күңел каралганга кигән дисезме?.. Бер дә түгел... Мин...

Полиция аңа:

– Тукта! – дип, аяк тибеп кычкырды да өстери башлады.

Исерек, чыга-чыга, гырылдады:

– Менә өч ел инде мәчет йөзе күргәнем юк. Ничек күрәсең: башта фуражка, өстә урыс калдыгы, ике тиен садакага юк... Мөселманнар гаеткә китә, мин үземнең өч балам белән авыру хатынымны кочаклыйм да, бишәүләп җылашабыз... Ә монда фәкыйрьгә каршы сызгырдылар...

Халык, бер-берсен таптап, юлны буган иде инде, полиция бик күп җәфалар соңында гына дулкынны икегә аерып, исерекне типкәләп чыгара алды. Инде үзара гүләшеп, сүз китте. Бу – кем бу? Моны кем котырткан?

Күпләр ышанмыйлар, үзе кермәгән – кызыллар юри берәрсен шулай киендереп керткән булырлар, диләр. Моны тик Давыт кына таныды. Ул аларның йортында торучы бер фәкыйрь татар икән. Урыныннан куылгач, шулай актык әйберен сатып эчүгә салышкан, Абдул (Габдулла) исемле кеше икән.

Бу ызгыштан соң мәҗлеснең яме китте, халык туеп бетте, үзара сөйләшә, ораторларны тыңламый, күбе чыгып сызу ягын карый башлады; рәис бөтенләй ялынган тавыш белән ялварды:

– Җәмәгать, ун гына минут сабыр итегез, менә берничә генә хатибка[1] сүз бирәм дә, карарлар кабул итәргә керешәбез, сабыр, җәмәгать! – диде.

Җәмәгать теләр-теләмәс кире утырды, кайберләре тыңламый сыза бирделәр. Шул арада секретарь:

– Хәбип Мансуров әфәнде, сүз нәүбәте сезгә! – диде.

Бу – ишетелгән фамилия түгел иде, кем булыр дип гаҗәпләнә төштеләр. Өстенә яңа костюм, аягына сары штиблет, башына котелок кигән, ак якалы, манжетлы, урта буйлы, кара-шадра йөзле бер егет сәхнәгә таба үрмәләде, купшы гына итеп сүз башлады:

– Әфәнделәр, Думадан һәркем, һәрбер халык үзенә файда көтә, бер җиңеллек бирер дип ышана... Байлар сәүдә малына түләүләр азаюын, эшчеләр хезмәт хакы артуын көтә. Авыл халкы җир өмит итә, поляк, яһүд, татар кебек чит милләтләр үзләренең дини-милли ихтыяҗлары үтәлүен, киңлек, тигезлек булуын көтәләр... Ләкин, әфәнделәр, бу хәзерге рәвеш белән сайланып барган тар хокуклы Дума бу теләкләрне бирә алырмы? Алмас, булмас, берен дә бирә алмас! Алда сөйләгән бер иптәш сезне Думага бойкот итәргә чакырды... Мин үзем шул бойкот турында сезгә...

Ораторның сүзе халыкның: «Кирәкми, сөйләмәсен, сөйләмәсен, бетмәс монда хәерсез кызыл авызлар», – дигән каты шау-шу эчендә югалды.

Бу егет күптән түгел үзе укыган школаның директорына каршы һөҗүмдә гаепләнгән иде. Аны полиция эзли иде, бөтенләй чит кеше киемендә булганга, башта танымадылар, ләкин провокатор, яшерен агент, карт учитель Әхмәт ничектер аяк атлавыннан, тавышыннан аны таныды да минуты белән жандарм колагына салды. Полиция, жандарм кешеләренең кызу-кызу кузгалуы рәисне шөбһәгә төшерде, бу эш эченнән нindидер бер бәла чыгарын йөрәге белән сизенде, театрдагы җәмәгатьнең таяк тыгылган кырмыска оясы кебек кайнавы эчендә ораторга берничә тапкыр:

– Мәсьүлият[2] минем өстемдә, сезгә сүз бирмим, туктагыз! – дип

---

[1] *Хатибка* – ораторга.

[2] *Мәсьүлият* – җаваплылык.

акырды.

Ләкин Мансуров тыңламады, халык тагын яман акырына башлады, шулар эченнән полиция дә ашыгып-ашыгып сәхнәгә ташланды, рәис, каты шалтыратып:

– Җәмәгать, мин мәҗлесне яптым! – дип кисте.

Бер минутка аптырап, катып калдылар; полиция сәхнәне басты. Күпләр монда Хәбип Мансур эләгер, кызык бер эш чыгар дип торганнар иде, ләкин өмитләр бушка чыкты: мәктәп директорына һөҗүм эшендә гаепләнеп, полиция тарафыннан эзләнгән Мансуров шул арада каядыр юк булды; жандармерия аның шул директорга һөҗүм итүче икәнен белде, таныды, ашыгыч, буталчык чабып, эзләүгә ташланды, егет чыгып сызды.

Тиз, ашыгыч кереп, бу киемнәрен ташлап, үзенекен киде дә караңгы төндә яңадан урамга ыргытылды.

## IX
## СӘРҮҖИ

Руслар арасында Беглец дип, татарларда бер җирдә Качкын, икенчеләрдә Сәрүҗи дип аталып йөргән Хәбип Мансуров, үзенең иске киемнәрендә туңа төшеп, караңгы төндә шәһәр бакчасының кеше аз йөри торган кечкенә капкасыннан чыкты да, капкыннан качкан җәнлек кебек, як-ягына ялт-йолт каранып, төньякка таба китте. Аның башында салам эшләпә, өстендә култык астындагы тишекләреннән көзге яңгырлы, ачы суык җил уйнап торган иске юка пальто, аягында кыска кунычлы итек кисәге, уң кулында ниндидер бер төргәк, сул кулында тимер таяк иде. Ул, бераз баргач, Николаевский урамга төште дә аякларын тагы кызулата башлады: аңа төнге сәгать өчкә поездга өлгерергә кирәк. Хәзер ике булып килә. Димәк, бер генә сәгать вакыт бар. Шул арада Урмановка да кереп чыгасы... Ашыкмаса, соңга калырга мөмкин. Үчеккән кебек яңгыры да арта бара, җиле дә төймәләре җүнләп каптырылмый торган пальто ашасыннан күкрәккә туры суга... Өшетә, туңдыра.

Николаевский белән ике чат үткәч, Пушкинскийга керде дә уңга – тар, караңгы тыкрыкка борылды: монда фонарьлар юк. Үтә караңгы. Аяк асты тубыктан бата, кайбер җирләрдә кыска кунычлы итек бөтенләй чумып-чумып китә. Шулай да ул бу җирләрне тыкрык белән үтәргә мәҗбүр күрде. Менә шул берничә урам тирәсендәге полицейскийлар аны таныйлар, якты урам белән барсаң, эләктерүләре бик мөмкин... Ул шулай уйланып өлгерә алмады, аяклары үзлегеннән кире чигенделәр... Чү!.. Тукта!.. Алда бер карачкыл тора... Полицейский бугай!.. Фу, хәерсез! Багана икән!.. Чү!.. Тагы кем?.. Каһәр булсын, тагы багана!..

Ул, курыкканга куш күренә дип, үзеннән үзе көлде дә, суык яңгырга күшеккән ябык тәнен актык бер җебенәчә юешләнгән нәзек пальтосы эченә бөрештерә төшеп, йөгерә-атлый, Екатеринский урамга чыкты.

«Ни булса шул булыр, барлык полицейский танып өлгермәгәндер әле...»

Ул Урмановның квартирында булганы юк иде. Ялгыш кителмәсен дип, өйрәткән буенча, уйлый башлады: «Успенский белән шәһәрнең читенә, яланга чыкканчы барасы... Анда почмактан икенче капка белән зур каенлы йортка керәсе... Йорт уртасында киң тәбәнәк өй. Шуның җир астындагы катлавына шакылдатасы...»

Аңа шулай өйрәттеләр. Менә инде Успенский урам, әнә шәһәрнең чите дә ерак калмый. Ул, кичегә күрмим дип, тагы кызулана төште. Шул кала читендә, соңгы, салкын көзнең караңгы төнендә, пычрак урамнардан ялгыз уйлана-уйлана, каенлы йортка таба кызуланып атлады.

Хәбип Мансуров – утыз еллар буенча учитель булып, хәзер пенсиягә яши торган Гомәр картның бердәнбер улы. Ул быел школаны бетереп, учитель булып чыгарга тиеш иде. Дулкын кузгалды. Мәскәүдә, Петербургта хәрәкәтләр башланды, министрга, губернаторларга ташланган бомба тавышлары аның йөрәген кузгаттылар. Школада кайбер укытучылар белән назирларга[1] каршы укучылар арасында дошманлык бар иде. Әмма кара фикерле, каты тәртипле директор Ивановны усал ерткыч кебек карыйлар иде. Беркөнне прокламация таптылар. Анда школаның барлык бозык, начар яклары язылган. Директор Ивановны полицейский белән үбештереп рәсем керткәннәр. Тикшерү, тентү китте, – таба алмадылар, шулай да эшнең төбен бунтарь, баш бирмәс табигатьле Хәбиптән күрделәр, кызыл фикердә аны гаепләделәр. Икенче көнне тагы прокламация, тагы рәсем: бусында инде директорны мәгариф министрының лакее ясап, җитмәсә, укучылар өстеннән әләкләүче итеп төшергәннәр. Берничә укытучы белән назирга да әләккән. Моны тиз җыеп алдылар. Сүз тагы куерды, бу гаеп тагы инде администрация тарафыннан Мансурга йөкләтелде. Аны куачак булдылар. Ләкин ул үзе күренмәде, ул көнне кайтмады. Кич директор Ивановка чиркәүдән кайтканда һөҗүм була. Тиз полициягә хәбәр итәләр; бүтән түгел, тик шул гына дип, Хәбипкә сылтыйлар. Моны ачык белә алмыйлар. Ләкин егет үзе күренми, өйләдән соң чыгып китә дә кайтмый; эзләтеп-эзләтеп тә тапмыйлар, шул китүдән эзе суына. Жандарм аны ачык, яшерен юллар белән эзләргә тотына. Егет шул көнне исемен, фамилиясен, паспортын, өс-башын алмаштыра да дулкын эченә кереп китә. Менә ничә айлар инде ул кайда туры килсә шунда

[1] *Назир* – тәрбияче, тәртип караучы.

куна, ни тапса шуны ашый, вакыты белән ачыгырга да туры килә. Башта ул руслар арасында эшләргә уйлап караган иде. Аны тиздән ташлап, авылга, крәстиәннәр арасына китте. Аннан, авылны да ташлап, монда килде. Менә икенче ай инде ул монда эшли. Иң элек ул татар эшчеләре арасына завод-фабрика тирәләренә керергә уйлаган иде. Русның үзеннән дә эшләүче юк түгел, мөселман эшчеләре ничектер аны канәгатьләндермәделәр; җитмәсә тагы, монда Булатлар, Госманнар, түгәрәкләр төзеп, тамыр җәеп, эшне кулга алып бетергәннәр иде инде. Ул кечкенә ике түгәрәге белән бергә татар шәкертләре, приказчиклары арасына керде. Яшеренү яхшы бара, полиция дә танымый. Тик берничә тапкыр Әхмәт учительнең каршына килеп чыгып, харап була язды. Ул – кара кеше. Аның турында яшерен әләкче дигән, җасус[1], провокатор дигән сүзләр йөри. Җитмәсә тагы, Хәбипнең атасы белән яшьрәк чакта бер урын өчен талашы булган. Шуннан бирле Мансуровлар нәселенең бөтенесенә ачу саклый. Хәбип берничә тапкыр аның ачулы тозагыннан котылса да, әле менә бүген театрда, татарлар җыелышында, тагы килеп каба язды. Ул, берничә иптәшнең ярдәме аркасында, бу театрдагы шау-шулы җәнҗал арасыннан чыгып кача белде, ләкин полиция, жандарм аның төсен танып калды, хәзер аны бик нык эзлиләр, әлбәттә. Ул үзен эз яздыруда оста саный, алдап кача белә, бу турыда шәкертләр арасында анекдотлар да сөйлиләр, менә шулар аркасында теге гарәб әдәбиятында мәшһүр «Мәкамәте Хәрири»нең [14*] каһарманына охшатып, шуның ләкабе[2] буенча, Хәбипкә шәкертләр Сәрүҗи дип кушамат та бирделәр, ләкин ул ничаклы яшеренмәсен, эзгә төшүләре ачык иде. Баязид карый[3] дигән бер үткен кызыл шәкерт бар. Ул һәрвакыт менә бу Мансуров белән прокламацияләр баса. Якын арада менә бу Баязид карыйда да тентү булган. Үзен зинданга алганнармы, юкмы – белә алмады. Чөнки ул шәкерт тә квартирына кайтмый йөри икән. Җитмәсә әле Сәрүҗинең кичә кунып чыккан приказчик иптәше Шаһиәхмәттә бүген тентү ясалган. Менә болар бары да полициянең нык көрәшкәнлеген күрсәтәләр, эз яздыру мөшкил булачагын аңлаталар. Тагы шул бар: Яманташ буендагы крәстиәннәр арасында чуалыш кузгалган икән дигән сүз дә чыкты. Комитеттан кеше сорап хәбәр бар. Руслардан өченче көн ике адәм китте, татардан берәү дә юк. Сәрүҗинең бу караңгы көзге төндә ашыгып поездга төшүе – менә шунда китү өчен иде.

Ул, өйрәтү буенча, шәһәрнең читенә, киң яланга чыгып, почмактан икенче йортның ауган капкасы аркылы кергән вакытта, болытлы күкнең бер

---

[1] *Җасус* – шымчы, шпион.
[2] *Ләкаб* – кушамат.
[3] *Карый* – Коръәнне күңелдән ятлаган кеше.

ягы бераз ачылды, аннан, нуры белән уйнап, якты ай карады. Тәүлек буенча яуган яңгырдан соң, киң, тигез йорт эче суда йөзә, бу тулы су төбендә нурлы ай ялтырап агып бара. Исәпли-исәпли йортка кергәндә күлнең капка як читендә ап-ак ике каз күренде. Башларын канат асларына тыкканнар да тыныч кына йоклыйлар. Казларны үткәч – тәбәнәк иске кызыл өй. Әйтүләре буенча, Давыт Урмановның «җәһәннәм базы» менә шул өйнең җир асты катлавы булырга тиеш. Хәбип Мансуров як-ягына караныпбрак килде дә тәбәнәк кызыл өйнең казларга караган башыннан ватык, җимерек баскыч белән бер сажин чаклы түбәнгә төште. Анда җиргә түшәлгән таш та, бусага да су эчендәләр. Начар, иске агач ишектә тимер элгеч асылып тора. Егет, иплэп кенә төшкәч, алдан әйтешкән буенча, дүрт тапкыр шакылдатты. Ишекне тиз ачмадылар. Сәрүҗи өши башлады. Табигате дә шуңа ачу иткәндәй кылана. Йорт уртасында су эчендә утырган ялгыз карт каен әле һаман коелып бетәргә өлгермәгән актык сирәк яфраклары белән кызганыч рәвештә шаулый башлый. Ялан ягыннан искән ачы җил өй түбәсендәге тимерләрне шакылдатып каера, ачу белән, зәһәр белән каты бәйләнеп тарта, җиңә алмагач, ууу... ууу... дип тавышланып, сызгыра-сызгыра, ватык, җимерек өйләр арасында кемгәдер ачу белән үкеренеп, дуланып йөри-йөри дә тәбәнәк өйнең тимер түбәсенә тагы килеп тотына. Тагы әрнеп, сызгырып каера башлый, тагы көче җитми. Тагы ачу катнаш каһәр белән ууу... ууу... килеп ыжылдый да, шәһәр өстеннән болытларны куып, киң яланнар, урманнар ягына таба дуланып китә...

Өстән акырган бу җил, түбәнгә, баскычның ышыгы төбенә дә төшеп, егетнең култык асты тишекләреннән кереп, күкрәгеннән чыгып уйнап үтә. Пычрак урамнар буенча суык баткакларны җырып килгән тишек итектән аяк астындагы су керә башлый. Егет әле бер аягын, әле икенче аягын күтәреп куя: итек эчләре лыгырдап торалар. Әйтерсең, бу каһәр көзге салкын су аякларның табаннарыннан, бармак башларыннан керә дә акрын-акрын үрмәләп югары таба – тубыкка, тезгә, ботка менә, аннан кан тамырлары буенча, өшетеп, күшектереп, бөтен тәнгә юеш суык булып тарала; бөтен тән, кул, аяк, арка, күкрәк – һәммәсе дерелдәп калтырый башлый.

– Нигә ачмыйлар тагын? Әллә дөмектеләрме? – диде дә, төнге кунак үзенең юеш, пычрак итеге белән берничә тапкыр ишеккә типте, бар көче белән шакылдатырга тотынды.

Тегендә, эчтә, кайдадыр җан иясе барлыгы беленде: кемдер акрын, бик акрын атлап ишеккә килде дә, үләргә торган кеше сыман, хәлсез, зәгыйфь тавыш белән, мине нигә бу чаклы газаплыйсыз дигәндәй, ыңгырашты:

– Кем бар? Көнозын кеше өзелми... Инде тагын төнлә дә кеше... Сезгә кем кирәк? – диде.

Мансуров тыныч җавап бирергә тырышты:

– Миңа Урманов кирәк иде... Ул монда торамы? – дип сорады.

Эчтән җавап булмады. Баягы хәлсез аяклар бик акрын өстерәлеп кире эчкә таба ераклашканы ишетелде.

Кунак аптырый калды: «Чү! Ачмады ич! Ул әллә моннан күчкәнме? Әллә «күчергәннәрме»?»

Шул минутта эчке бүлмәдән икенче аяк тавышы ишетелде. Бусы инде егетләрчә нык, җиңел атлап килде. Иптәшчә таныш тавыш белән:

– Хәбип, синдер бит?.. – дип, ишекне ачты. Аннан, кулына янып торган шәм тотып, озынча буйлы, ябык аксыл йөзле, бераз эчкә баткан уйчан карасу күзле, киң маңлаена төшеп торган зур тузган чәчле, кара күлмәк өстеннән билгә каеш бәйләгән хуҗа егет килеп чыкты. Ул төнге кунак иптәшнең яңгырлы, суык җилдә күгәргән иреннәренә, күшегүдән вак сары йон калыккан карарак шадра йөзенә карады да тиз үк:

– Син гаҗәп өшегәнсең, әйдә тизрәк кер! – диде. Гафу үтенгән сыман өстәде: – Синең килереңне Тангатар әйткән иде... йокламый көттем... Ләгънәт төшкән лампаның мае бетте, караңгыда утыра-утыра, киенгән килеш йоклап киткәнмен... Сине озак көттерделәрме?..

Хәбип бусаганы атлый-атлый җавап бирде:

– Байтак булды. Нинди җүнсез нәрсә ул? Авырыймы, дим?

– Карчыкны әйтәмсең? Үләргә ята ул! Әмма минем өчен бик яхшы: күзе җүнләп күрми. Бераз чукрак та бугай... Монда яшерен бомба фабригы корсаң да мөмкин...

Егетләр эчкә таба атладылар. Урманов бик аз яктырткан нечкә шәме белән алдан китте. Керү белән Сәрүҗинең борынына әллә ниткән әчеле-төчеле ис бәрелде. Квартир тәбәнәк. Һавасы юеш, авыр. Ишектән бер адымда өлкән, иске кызыл мич. Аның алдында яртылай ауган күмер чиләге. Шунда ук бер колагы сынган кап-кара, пычрак җил самовар. Сул якта буялмаган агач өстәл, аның өстендә – калган аш, юылмаган савыт-саба, бәрәңге кабыгы, касмагы кырылмаган ватык чүлмәк; уң якта, юыныр өчен, мунчала белән асылган бер балчык савыт. Бу беренче бүлмә – карчыкныкы. Көндез ул шунда кайнаша, кич мич башына менеп йоклый. Бу бүлмәдән үтеп, тагы бер ишек ачкач, түргә – Урманов торган бүлмәгә керделәр. Анда да байлык зур түгел. Почмакта – каралып, чебен пычратып, таракан кимереп беткән зур, иске кара тәре. Бу кайчандыр чобар[1] бизәкле, алтын сары төсле булса да, заман аны шулай картайткан. Бүлмәнең стеналарына ябыштырылган зәңгәр буй кәгазьләр, искереп, тузанга, төтенгә буялып, каралып-ертылып

---

[1] *Чобар* – чуар.

беткәннәр, күп җирдән астындагы кандалалы, тараканлы, мүкле бүрәнә ярыклары күренеп торалар. Иң түрдә – дерелдәп җимерелергә торган иске агач карават, аннан почмакка таба – агач, җимерек өстәл; аның янында – артсыз ике урындык, шунда ук бер ташландык шкаф кисәге; аның эче-өсте гәзитләр, русча, татарча китаплар белән тулы.

Хәбип бик арган иде. Бүлмәгә керү белән шул иске караватка ауды:

– Их, туйганчы бер йокласаң иде!.. Булмый шул, миңа ашыгырга кирәк! – дип, кире торды. – Кая, тамак җебетергә бирәр нәрсәң юкмы ичмасам? – диде.

Урманов шәмен куйды да шунда савыт-саба тирәсендә кайнаша башлады.

– Менә самоварда кайнар су бар, менә икмәк белән бәрәңге, тоз, – дип, Хәбипкә ашарга әзерләде.

Егет, икмәкне, бәрәңгеләрне тозлап, инде суына башлаган чәйне йота-йота, тамак эшенә кереште.

Давыт, теге бүлмәгә чыгып, мич артыннан бер төргәк китерде. Иптәшенең алып килгән төргәген ачып, браунингны карады, дәртләнеп, шатланып карады. Ул арада Сәрүҗи ашарлык әйберләрне бетергән иде, үзен басып җиңеп барган аруга бирелмәс өчен, кинәт сикереп торды.

– Ну, шәп төште бу! Кая, син тегеләрне әзерләдеңме? – диде.

Давыт теге яктан алып килгән кәгазьләрен актара башлады.

– Менә, – диде, – «Крәстиәннәргә ни кирәк?» илле данә бар. «Дума ни бирер?» җүнләп чыкмады, «Эшчеләр авазы»ның карасы сыек төшкән. Танылмый... Аны алмасаң да ярый...

Мансуровның маңлай тамырлары кабарды, чигәсе кызды, сүгенәсе, бар дөньяны сүгеп, иптәше Давытны да эт итеп ташлыйсы килде. Шулай да үзен тыйды, иплән зарланды:

– Менә бит ничек безнең эшләр? Ичмаса, шул прокламацияне басарлык та көч юк бит бездә... Ә Булатлар инде гәзит чыгарырга әзерләнеп беткәннәр. Беләсеңме, шушы араларда аларга партияләреннән мең сум биргәннәр, ди. Бары да гәзиткә, ди. Кичә мин үземнең авылдаш Шакир солдатны күрдем. Булат әйтте, ди, бары тик жандарм аяктан ега, менә ике кеше исеменә ике тапкыр гәзиткә рөхсәт сорадык, ничәшәр ай йөртеп, бирмәделәр, дип әйтә, ди. Хәзер инде тагы сораганнар, бөтен эш шуңа терәлгән, тик шул кул-аякны бәйли, дип әйтеп сөйләде, ди. Менә бит халык ничек?..

Давыт дәшмәде, сүз икенчегә күчте. Хәбип тагы әрнебрәк сүкте:

– Комитетка ничә тапкыр мәсьәлә куелды. Шәкертләр үзләре кузгата, үзләре барырга ялкынланып тора, без тик аларга бераз булышлык итик, юл күрсәтик тә качарга ат бирик, дидем; шуны эшләргә куллары бармады...

Үзләре белән талашып чыктым... – дип озак тиргәде.

Мәдрәсә яшьләре арасында «Фидаиләр»[1] исемендә бер яшерен группа тудырмакчылар. Бу үзе, Кавказның «Дифагый»лары[2] кебек, революциягә каршы кара көчләр белән сугышмакчы, иң элек мөфтине атып үтермәкче, аның артыннан хөкүмәт терәге Ишми ишанны [15*], теге җәдит дошманы Кышкарчы Вәли мулланы [16*] бетермәкчеләр. Боларга башка тагы шулай искелекне, кадимне, хөкүмәтне яклаучы булып танылган зур, атаклы берничә ишан, берничә ахун боларның планына кергән. Бу эшне башкару өчен бераз корал кирәк, акча кирәк. Давыт белән Хәбип рус иптәшләре аркылы менә шул хакта үзләренең партия комитетына мәсьәлә куйдылар, ләкин анда һаман сузалар, була дип тә, булмый дип тә өзмиләр икән. Кичә генә Җиһангир белән Баязид килгән иде, алар өзеп әйттеләр: «Әгәр аннан ярдәм булмаса, без үз башыбызга керешәбез, мылтык булмаса, пычак табылыр, без тукталачак түгел», – диделәр.

Урманов, иптәшен озатыр өчен кузгала башлап, кызып китте:

– Сөйләмә инде, ишаннар, муллалар, мәчет мөнбәрләреннән революциягә каршы вәгазь сөйлиләр, тәре артыннан, патшаны яклап, урамга демонстрациягә чыгалар, кызыллар арасында бер мөселманның күренүе – бөтен дөнья мөселманына йөз каралыгы дип ләгънәт тараталар... Инде килеп, мәдрәсә яшьләре менә шул контрреволюциянең татар арасындагы кара баганаларын аударырга, кара терәкләрне җимерергә ялкынланып чыгалар икән, безнең аларга бернәрсә ярдәм эшли алмавыбыз оят бит!..

Хәбип, кинәт тукталып, шөбһә белән Давытка карады:

– Ә син үзең ул фидаи шәкертләрнең бу планнарыннан эш чыгарына ышанасыңмы?

Урманов икеләнде:

– Өзеп әйтү читен, шулай да булышлык, җитәкчелек итәргә кирәк!..

Сөйләшә-сөйләшә яңадан йортка чыктылар.

## X
## ХАТ

Тышта җил басылган. Күк йөзе ачык, тулы ай нурлы йөзе белән җир өстеннән елмаеп үтеп бара.

Егетләрнең аяк тавышларын ишеттеләр булса кирәк, күл буендагы казлар уяндылар да үзара гайгылдаша башладылар: «Таң да атмаган, йөрергә иртә әле!» – диешеп, йорт уртасындагы карт каен төбенә күченеп утырдылар.

---

[1] *Фидаи* – берәр максатка ирешү өчен үз-үзен корбан итәргә әзер кеше.
[2] *Дифагый* – обороначы.

Егетләр капкага җиткәндә, шәһәр ягыннан бер карачкыл күренде. Үзе адәмгә ошый, болай таба атлый да бугай. Һәр икесе берьюлы: «Полиция түгелме?» – дип уйладылар. Карачкыл якынлаша, аны көткән сыман туктадылар. Давыт Урманов китәчәк иптәшенә актык сүзен әйтте:

– Ничек карыйсың, теге яшь бай Гариф сүзендә торырмы, юкмы? Бөгелмәдәге йортымны сатсам, сезгә дүрт йөз сум бирәм, диде. Аннан тагын Хәбибрахман әйтә: атай үлем хәлендә, аннан миңа җитмеш мең тия, ди. Сезгә биш йөз бирәчәкмен, ди... Әгәр бу икенең берсе генә барып чыкса да, безгә гәзит башларга мөмкинлек була бит!..

Ул сүзен бетерә алмады, теге карачкыл ава-түнә килеп җитте. Ипләбрәк карасалар, бу ташландык иске фуражка кигән бер исерек татар булып чыкты; тагы якынрак килгәч, моның бүген кич театрда, мөселманнар җыелышына кереп, җәнҗал куптарган Абдул икәне мәгълүм булды.

Ул әле дә бик каты исерек иде. Аяклары чак атлый, гәүдәсе әле бер якка, әле бер якка саллана. Үзе боларны җүнләп күрмәде бугай: күтәрелеп карамады – пычранып беткән фуражкасын кулы белән як-якка селкә-селкә, ярым татарча, ярым русча начар сүзләр белән сүгенеп мыгырданып, ауган капка аша үтте. Ялгыз каенның уң ягындагы түбән ишекләрнең берсендә югалды. Урманов берничә тапкыр: «Габдулла абзый!» – дип кычкырырга уйлады да тагын тыелды. Хәбип: «Бу кем?» – дип соравына, ул сөйләп бирде. Бу ачлык елда авылдан күчкән бер ярлы татар. Исеме Габдулла. Ул агач заводында кара эшче булып тамак туйдыра булган. Менә соңгы көннәрдә урыннан чыгарганнар. Хәзер эшсез, урынсыз; үзе шул арада эчәргә дә сабышкан. Аның хатыны Хәдичә җиңги кичә генә, Давытка кереп, авылдагы кардәшләренә хат яздырды, шунда күз яше белән җылап утырды:

– Үзем авырыйм, – ди, – кечкенә өч балабыз бар... бер кабым икмәк калмады, инде менәтерәк фатирдан да куалар, үзе эчеп кайта да сугыша, нәрсәләребезне эчәргә сатып бетерде, инде ачка үләбез, күрәсең, Ходаем...

Хәбип: «Авылдан килгәч, моны тартып карарга кирәк!» – дип уйлады.

Шул ук яктан тагы ике карачкыл күренде. Болар нык, таза, каты басып, ашыгып киләләр. Ерактан күзгә кылычлы, мылтыклы булып күренәләр. Шулаймы, түгелме – аерыр хәл юк.

Хәбип, боларны күрүгә, кулын бирде дә тиз-тиз атлап вокзал ягына сызды. Ул почмактан югалу белән Давыт Урманов та ашыгып өенә керде. Хәбип Мансуровтан калган револьверны шул төргән көенчә карчыкның мич артына яшерде; теге пешми чыккан прокламацияне дә шунда тыкты; үзе ятарга әзерләнде.

Шул арада, ахры аяк тавышына уянгандыр, авыру карчык кузгалып чыкты:

– Зиһенем таркау минем, балам, картлыгым җиткән, көндез үк сиңа бер хатын керткән иде, – дип, егеткә алсу төстә озын конверт китереп бирде.

Давыт кечкенә, нәзек шәмнең актык яктысы астында, тиз-тиз конвертны ертып, хатны укырга тотынды:

«Давыт абый!

Вакытыгыз булса, бер генә минутка килеп китәр идегез... кич сәгать унда. Беләсез, теге зур баскычлы Чокыр урамын... Габдрахманнан тагын яучы бар. Актык сүзне ишетәсебез килә, дип әйтәләр, ди. Әткәй әле һаман миңа бернәрсә дә белдерми, мәһәренә килешсәләр, бирергә исәбе бар бугай. Яучы киткәч, миңа Фәхри җиңги аркылы әйттермәкчеләр, ди. Ходаем, хайван саталармыни? Тагы ниләр генә күрәсем бар икән! Вакыт тапсагыз, килми калмагыз, шул турыда бер-ике сүзем бар.

*Нәфисә*».

Кызның соңгы вакыттагы башка хатлары кебек, бусы да Урмановта шелтә катнаш кызгану тойгысы уятты.

«Матур... акыллы... тәрбияле, үзенә күрә укымышы да бар. Әлбәттә, бәхетле булырга, үзе генә түгел, бер иргә, берничә балага да бәхет бирергә тиешле иде. Ләкин ул бичара үзенең язмышы алдында көзге җилгә каршы ялгызы утырган гөл чәчәге кебек калтырап тора, менә-менә сынып төшәчәк тә егылып тапталачак».

Ашыгыч эшләр бар. Ләкин Давыт, барыбер бернәрсә дә эшли алмаячагын, иртәгә Нәфисәгә барырга кирәген уйлап, караватка сузылды. Авыр, чуалчык төшләр белән саташа-саташа йокыга китте.

## XI
## БАЯЗИД КАРЫЙ

– Мин авылга кайтып атайны үтерергә карар бирдем!

Баязид сүзне шулай кисеп әйтте. Урманов әле караваттан торып җитмәгән, юынмаган, киенмәгән иде, – тегеннән, карчыкны сукрандырып, ишек кактылар. Анда кипкән кискен йөз белән, ниндидер кискен уй белән иптәше Баязидны күргәч, Давыт бераз гаҗәпсенеп карады. Алар бергә туып, бергә уйнап үстеләр, байтак еллар аерылып яшәгәннән соң, менә бу ел тагы юлыгыштылар. Баязид үзен партиясез революционер, ди. Кирәк чагында Булатларның, Госманнарның да йомышларын үти. Кавказлы Гәрәй Солтанны да бер күрү белән яратты: «Менә мин үзем шулай каты корыч буласым килә, әмма көч җитми», – дип сөйләнде. Ләкин Давыт белән аны балалык дуслыгы һәм кардәшлек җепләре баглый һәм шул якынлык аның сәяси фикерен дә Давытлар белән бергә бәйли иде. Йокысыз үткәргән төн эчендә аның башында ачык фикер, ачык план туды; киңәш өчен түгел, үзенең йөрәк

ярасына табылган дәваны аңлатыр өчен әйтергә кирәк тапты. Иртә торгач, ашамый-эчми Давытка шуның өчен килде. Аны аяк тавышы белән уятты да, һичбер сәбәбен сөйләмәстән, ярып салды:

– Мин авылга кайтып атайны үтерергә карар бирдем! – диде.

Давытның Нәфисәгә хат язасы яки, барып, күреп кайтасы бар иде. Һәммәсе хәтереннән чыкты. Ләкин бик артык гаҗәпләнмәде. Ул Баязид карыйдан шундый бер эш көтә кебек иде. Кискен сүзен ишеткәч, әйбер үзенең тиешле урынын табып утырган кебек булды. Ул үзеннән бер сүз әйтергә өлгермәде, Баязид әрнүле тавыш белән өстәде:

– Мин мирасны уйламыйм. Атай кулында газапланган сеңелләремне коткару өчен генә дә түгел! – диде. Иптәше ялгыш аңлый күрмәсен дип тагын арттырды: – Менә шулай йөрәгемә кара таш булып катып кереп утырган ул. Сулыш ала алмыйм, тыным кысылган кебек була минем... Аңлап бетә алмассың: менә ничек! Йөрәк итенә керен кадалган кадак дип әйтимме, ул да түгел, якты кояшны каплап торган черек багана димме, ул да түгел, әллә яшь чәчәкләр өстенә агулы корым таратып яткан зәһәр сөремле морҗа дип әйтимме, ул да түгел... Белмим инде, менә шулай йөрәгемә кара таш булып кереп утырган... Шуны алып ыргытмасам, сулышым кысыла, тын ала алмыйм кебек...

Давыт, юынып-киенеп, чәйгә утырды. Баязид үзенә кирәкле әйберне бер сүз белән әйтеп бирә алмавына газаплана башлый. Менә бер сүз кирәк. Тел очында гына тора. Ләкин табып әйтеп булмый...

– Менә бүген мин тәмәке тарта башладым, – диде дә кесәсеннән папирос чыгарып яндырды, үзе, Давытның сораганын көтмичә үк, тәмәке төтененә урала-урала, авыр язмышын, бу фикергә китереп җиткергән газаплы үткәнен сөйләргә кереште.

## XII
## ЯШЬ ГОМЕР

Ул яшьтән үк үзен мәңге котыла алмаслык читлеккә ябылган кош кебек сизә. Уенчак. Үткен. Матур. Зирәк. Ләкин аны нидер кыса. Йөрәгендә ашкыну бар. Канатлар каядыр очарга телиләр; ләкин бераз гына селкендеме, аны тимер читлекнең челтәрләре кыса башлый, тыеп, богаулый башлый. Тугыз яшьлек бала. Аны Каргалының биш йөз шәкертле, кара, кадим, фанатик мәдрәсәсенә [17*] салалар. Ул – мәхдүм. Ул – ишан баласы. Атасы хөрмәтенә аңа дәресханәдә хәлфә янында урын бирәләр. Якты, шат дөньяда пакь, яшь, матур, нәфис баланың сабый йөрәгенә, беренче авыр яра булып, аның турында, Хәлим хәлфә исеме белән бәйләп, пычрак гайбәт туа. Баязид хурлыгыннан утка ташланырлык минутлар кичерә. Ләкин һичбер нәрсә белән

мәдрәсәнең ул пычрак, хаксыз гайбәтен үз өстеннән юып ташлый алмый. Бераз үскәч, моның өстенә тагын намаз хәсрәте кушыла. Ул намаз укырга яратмый, сәҗдәгә бөгеләсе килми; аны бинамаз дип мыскыл итәләр. Ул бирелми, көчли башласалар, тәһарәтсез укый. Моны сизәләр. Хәзрәткә әйтәләр. Өлкән бер ишанның баласы булганга, ул ике тапкыр гафу кыйлына. Ләкин атасы Җиһан ишан мәдрәсәгә, даменлага, казыйга хат язып әйтә: «Кызганмагыз! Бер рәкәгать[1] намаз калдырса, аркасын ярганчы суктырыгыз. Бинамаз[2] булып өйрәнмәсен! Ризалыгым юк. Гафу итмәгез. Аны үз мәдрәсәмдә тотмавымның сәбәбе дә шул: монда анасына таянып, иркәләнүчән, намазын, догасын калдыручан була. Сез анда мөсаһәлә кыйлдырмагыз[3]!» – ди.

Мәдрәсәнең башлыгы Вафа хәзрәт баланың атасы Җиһан ишан белән Бохарада бергә, бер хөҗрәдә укыган кеше. Ул Баязидны чакырып ала да үгетли, иркәли. Яшь сабый, әсәрләнеп, хәзрәтнең сүзен тыңлаучан булырга тели, көчләнеп, намазны калдырмаска тырыша башлый. Ләкин тыштан ябыштырылган бу хәл озакка бармый. Җае чыга да, ул тагы алдашып куя. Сизәләр. Бер-ике тапкыр күз йомалар. Тагы кабатлана. Инде атасының сүзен хәтерлиләр. Баязидны әчелеккә[4] яткыралар, бөтен шәкертне җыялар да, аркасын, бөтен йомшак җирләрен ачтырып, мәдрәсәнең иң әшәке малаеннан унбиш чыбык суктыралар. Ул бу хурлыктан кая керергә белми. Көндезләрен һичкем белән сөйләшми – ялгызы агарынып йөри. Төннәрне йокысыз үткәрә. Авыр хурлыгын уйлап, мендәренә каплана да таңгача җылап чыга. Таяк эзләре төзәләләр. Хурлык онытыла. Тагын бер җай килә, тагын намаз калдыра.

Тагы эләгә – тагы әчелек. Тагы камчы, тагы чыбык. Ул тагы, мендәргә капланып, хурлыгыннан озын төннәрне йокысыз үткәрә.

Уразалар килә. Көн буе ач торганнан соң, карын ярылганчы ашыйсың да егерме рәкәгать тәравих[5] белән, хәтем[6] белән дүртәр-бишәр сәгать газапланасың. Баязид өчен болар да зур җәфа булып төшәләр. Ул мәчеткә бара, ләкин эттәхият[7] вакытында утырган килеш йоклап кала...

Ул үзе гаҗәп зирәк булды. Моның белән атагы чыкты. Шәкерт

---

[1] *Рәкәгать* – намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны эченә алган өлеше.

[2] *Бинамаз* – намазсыз, намаз укымаучы.

[3] *Мөсаһәлә кыйлдырмагыз* – йомшаклык күрсәтмәгез.

[4] *Әчелек* – мәдрәсәләрдә кергәндә читек-кәвешләрне салып калдыра торган ишек төбендәге бүлмә.

[5] *Тәравих* – уразада кич белән укыла торган намаз.

[6] *Хәтем* – Коръән уку.

[7] *Эттәхият* – намазда тезләнеп укый торган дога.

арасында аны: илһами дип, авызына Хозыр-Ильяс [18*] түкергән дип, укымый белә дип йөртәләр. Һәм ул чынлап та башкалар кебек меңгер-меңгер дәрес ятлап баш ватмый, хәлфә алдыннан чыгуга китабын киштәгә атып бәрә дә, мәдрәсәнең астын-өскә китереп, җенләнеп уйнап йари.

Ул үзенең тавышы белән дә күтәрелеп китте. Үзе җыр яратучан. Атна кич килдеме, Кадер , Мәүлед бәйрәме [19*] булдымы, шәкерт мәҗлесләре башландымы – Баязид анда беренче каһарман. Аңа көйләргә булсын, ул җырларга ярата, матур мәкам[1] белән коръән укырга да ярата. Унөч яшеннән үк аңа җомгалардан соң мәчеттә коръән укырга куша башладылар. Аерым дәрт белән укыган чакларында картлар, җыелып, күз яше белән аны килеп кочаклыйлар иде. Шул якларның атаклы сукыр карыйсы үзе бер тапкыр ишетү белән, Баязидның тавышына, коръән мәкаменә хәйран кала. Янына чакырып, башыннан сыйпый да әйтә:

– Балам, үзеңне сакла, синдә Дауд пәйгамбәр [20*] тавышы бар. Әрәм булма, мин атаңа хат яздырыйм. Син коръән ятла, миннән соң варисым булырсың! – ди.

Болай да матур көйләрне сөйгән Баязидка бу киңәш бик ошый. Ул атасыннан рөхсәт килгәнен дә көтми, карт сукыр карыйга тезләнеп, фатиха ала, аның атаклы шәкерте Сафый карыйга утырып, Коръән ятлый башлый.

Зирәк, үткен яшь ми, яшь хәтер йота гына. Бер ел тулар-тулмас бер арада Коръәнне ятлап кына түгел, тәкърарлап та чыга. Икенче елның рамазанында хәзрәт аңа Коръән хәтем кыйлырга[2] куша. Шулай ул Баязид карый булып китә.

Ләкин бу хәлләр аны тыя алмыйлар. Ул, башында Коръән булуына карамый, күп җәмәгатьне артына оетып, зур мәчетләрдә, изге рамазан айларында коръән хәтем кыйлуларын да исәпләми, телгә алырга авыр булган гөнаһларда йөри: аны рамазан шәрифнең сигезенче көнендә, иртәгә коръән багышларга торган бер вакытта, көпә-көндез шәһәр читендә бер марҗа белән күрәләр. Хәбәр тиз тарала. Гайбәт сәгате белән шәһәрне каплый. Атасына хәбәр итәләр. Җиһан ишан ачуыннан үзен кая куярга белми, килеп җитә. Улы белән күрешми, исәнләшми, Баязид карыйны мәдрәсә уртасына идәнгә яткызып сала да, бетен шәкертләр, хәлфәләр алдында, таяк белән эштән чыгарганчы, канга батырганчы яра, суктыра.

[1] *Мәкам* – көй.
[2] *Хәтем кыйлырга* – укырга.

## XIII
## ШӘКЕРТ ХЫЯЛЫ

Таяк туктагач, Баязид идәннән күтәрелә дә, җыламый-нитми, һичкем белән сөйләшми, каядыр чыга да китә. Төн караңгы. Шәһәрнең вак, тар, кечкенә урамнары күп. Шул китүдән аның эзе суына: кая югалды? – һичкем белми.

Элек тәравихларда коръән хәтем итә башлагач, карый дип аны авыз ачарга – ифтарга[1] чакыралар, садакалар бирә торганнар иде. Шул чакта җыелган акча хәзер Баязидка эшкә ярады. Ул Казан, Уфа, Оренбург тирәләрендә әйләнә-әйләнә дә, ни өчен икәнен үзе дә юньләп белмичә, Себер ягына китә. Йөреп-йөреп акчасыз кала. Кулда һөнәр юк. Күп газаплар эчендә елны үткәрә дә, рамазан якынлаша башлагач, тагы шул карыйлык белән эш итәргә исәп кора. Яңадан Эчке Русия ягына – Чиләбегә килә. Шуның өязендә атаклы бер мәдрәсәгә шәкерт була. Җомгаларына бара, Мисыр, Шаһмирза, Бәдри карый мәкамнарына салып, матур моң, көчле күкрәк тавышы белән көйләп намаз артында, мәчеттә коръән укый. Карт-коры сокланып тыңлыйлар.

– Гомеребездә мондый мәкамне, мондый авазны ишеткәнебез юк иде! – диешеп, хәйранга калалар. Ул тагы карыйлык исемен кайтара. Мәҗлесләргә чакыралар.

Электән монда хәтем чыга килгән конкурент карыйларның хәсрәтләренә, ачуларына каршы, бу ел тәравихта хәтем итүне Баязид карыйга тапшыралар.

Кыш шунда үтә. Аңарда садакадан җыелган бераз акча да бар. Ләкин ул бу тормыштан шул чаклы туя, бизә ки, яз әсәре сизелеп, шәкертләр киткәли башлау белән моннан да сыза. Акча тагы да бетә. Тагын ачлы-туклы көннәр башлана. Ул ничә төрле кәсепкә тотынып карый: приказчик булып кибеткә керә. Аннан бае белән талашып, сүгешеп чыга. Ерак Себердә, Байкал буйларында, юл салучыларга атчы малай булып ялланып эшли Эчке Русия белән Себер арасында елкы сәүдәсе йөртүчеләргә ялланып, кызге суык яңгырларда, караңгы төннәрдә мал саклап, корулы мылтыгын төзәп, ат өстендә якты таңнар көтеп үткәрә... Атлары талана, хезмәт акчасын басып калалар. Аны ташлагач, тимер юлга керә. Менә япон сугышы башлана. Анда күңелле булып китәргә тели. Ләкин яшь дипме, ни диптер – алмыйлар. Ул арада Русия диңгезендә куәтле дулкын күтәрелә. Шул дулкын эчендә татар көймәсе кузгала, җанлана башлый. Искене, кара, кысык, бозык иске тормышны җимерү өчен, яңа, якты, азат көннәргә барыр өчен көрәш

---

[1] *Ифтар* – уразада авыз ачу мәҗлесе.

башлана. Егетнең йөрәге ашкына. Шул көрәшкә ташланасы, көрәш үзәгенә керәсе, тар, кысык богаулы ул каһәр иске тормышны җимерүдә җаны, каны белән катнашасы килә. Шул дәрт белән яна. Ләкин ничек көрәшергә, кайдан, ничек, кем белән башлап китәргә юл тапмый, шуңа хәзерлек күрми. Ул арада шәкерт хәрәкәте кузгала. Әллә нинди зур, яңа программалары, яңа тәртипләре белән Мәдрәсәи исламия исеме дөньяга күтәрелә. Баязид, башкача җай тапмагач, бәлки бер баскыч хезмәтен үтәр дип, шунда килеп керә. Ләкин аз вакытта моның төбен аңлап ала – монда да шул динче, садакачы хәзерләү икәнен, бу да шул теге искеләрнең бераз буялганы, бераз төзәтелгәне генә икәнен ачык күрә. Ләкин инде тагын кая таба сугылырга, үзен ничек, кай армиягә, кем аркылы бирергә юл тапмый. Бүген сеңлесеннән хат ала, ул җылап язган: атасы Җиһан ишан исән икән, элекке кебек каты икән. Бөтен гаилә җәһәннәм утында икән. Шуны алгач, митингларда кайнап арыды да, юл уңаенда, бер манарадан мәзиннең азан әйткәнен ишетте. Тукта, болар һаман да шулаймы икән дип, госелсез, тәһарәтсез көе мәчеткә җомгага керде. Анда мөнбәр, мөнбәрдә яшел чапанлы, ак чалмалы, зур яшел таяклы карт хәзрәт вәгазь сөйли. Тавышында, күзендә яшь тулы:

– Җәмәгать, – ди, – агяһ булыгыз! Заманалар бозылды, урамнар фптнә белән тулды, кем дә кем шул фитнә әһленең эчендә булса, кем дә кем аларга ярдәм кыйлса, ул дөньялыкта бөтен дөнья мөселманына йөз каралыгы булачак, ахирәттә мәңге тәмуг газабына дучар булачак. Җәмәгать, мондый фитнә әһелләре өстенә Алланың каһәре төшсен, шуның өчен кулыбызның сырты белән дога кыйлыйк! Амин! Амин! – ди.

Бөтен мәчетне кул сырты белән дога кыйлдыра, амин кычкырта.

Баязид күптән мәчеткә аяк басканы юк иде. Ул, шаярыбрак: «Дин дигән, Алла дигән кешене яткырып суктырасым килә, шулай җирәнәм», – дип сөйли иде. Мәчеттә мулланың бу догасын ишеткәч, башы әйләнде, дөнья кире киткән, тарих артка кайткан кебек булды, ни эшләргә белмәде; халыкка ияреп, намазга тотынган иде, икенче рәкәгатьнең фарызында[1] сәҗдәгә яткан җиреннән сикереп торды да, намаз беткәнне көтмичә, сафларны җырып чыгып китте. Шул көнне, төнне җүнләп беркем белән дә сөйләшми, ялгыз үткәрә – гомер буенча йөрәгенә җыелган каһәр, ләгънәт, протест тойгылары бары бергә укмашып килеп чыгалар. Үзләренә конкрет бер формада конкрет бер калыпка салыналар. Ул йокысыз үткәргән төннең иртәсендә тора да Давыт Урмановка килә. Аның әйткәне: «Мин авылга кайтып атайны үтерергә карар бирдем!» – дип, туп-туры сөйләве менә шул газапларының актык калыплануы иде. Ул сәбәбен әйтергә кирәк булыр дип уйламады, әйтмәсәң

---

[1] *Рәкәгатьнең фарызында* – үтәлми калмаска тиешле, мәҗбүр өлешендә.

дә, үзеннән-үзе билгеле ич дип карады; ләкин, Давыт бераз аңлап җитмәгән төсле күренгәч, алдан хәзерлексез-нисез, үзеннән-үзенә, бөтен язмышын сөйләде дә ташлады.

Урмановның бу эшкә тик шәхси бер протест дип каравы мөмкин иде. Баязид моңардан куркынып куйды. Аңлатырга кирәксенде:

– Син беләсең: бер мин түгел, башкалар да ашкыналар. Оренбург, Троицк, Казан, Уфа, Әстерханда да шундый дәрт бар. Тик кайдан, ничек башлап китәргә белмиләр. Менә безнең «Фидаиләр» юлга салынса, һәммәсен өйрәтер, – диде; тагын өстәде: – Гомерем буенча газап чиктем... Гомерем буенча җаным, йөрәгем белән кысылдым... Менә хәзер генә сулыш алырга әйтәм бугай. Үземне шулай сизенәм... Сау бул. Мин киттем.

## XIV
## БЕРЕНЧЕ АДЫМ

Икәү бергә чыктылар.

Почмакта аерылганда Давыт Урманов дустының кулын кысып, күзенә карады, кисеп әйтте:

– Чәнчелсеннәр. Мулла-мунтагай дип, ишан дип моңарчы да халыкның башын әйләндерделәр. Алар мәчеттә безгә каршы кул сырты белән дога кылсалар, шулай итеп, безгә каршы армия җыйсалар, безнең кулда башка чаралар табылыр. Әйдә, хәерле сәгатьтә. Кулымнан ни килсә, барын да эшләрмен... «Фидаиләр»не дә оештыр, атаң картны да дөмектер...

Аңардан аерылгач, Баязид ялгыз ике тапкыр бакчаны әйләнде дә, Мәдрәсәи исламиягә барып, Җиһангирне эзләп тапты. Болар иске тормышка каршы сугыш дәрте белән бергә яналар. Һәр икесе иң каты, иң кискен чаралар белән көрәшкә чыгу ягында баралар. Ләкин хәзергәчә үзләренең партия якларын ачык билгели алмадылар. Алар үзләрен кай урында, без партиясез революционерлар дип, икенче бер вакыт, без милли социалист, яки партиясез социалист дип ычкындыралар. Булат боларны үз юлына тартуга чамалап карады. «Партиясез революционер дигән сүз – әле пешеп җитмәгән социалист дигән сүз була, сезгә пешәргә вакыт», – дип шаярып та карады. Ләкин болар икесе дә рус матбугатын аңламыйлар, ул чорда татарча чыккан кечкенә кызыл китаплардан үзләренә җитәрлек азык таба алмыйлар. Әле Булатның, әле Давытларның сәяси түгәрәкләренә йөри башлап карасалар да, һәр ике якны жандарм килеп басып таратты, яшерен түгәрәкләр шулай тиз генә боларның миләрен формалап өлгермәде; үзләренчә революция өчен, искегә каршы, кысынкылыкка, бәхетсезлекләргә каршы сугышу дәрте белән янып йөри бирделәр, ләкин төп күңелләре Давытларга кайта иде. Мәдрәсәләр эчендә хәзрәтләргә каршы сугыш аларның беренче конкрет эше булса,

демонстрацияләргә, митингларга чабу да зур дәрес иде. Әмма «Фидаиләр» оешмасын тудыру фикере аларның йөрәгенә ут кабызды. Давыттан чыккач, Җиһангирне очрату белән Баязид үзенең кискен планын сөйләде. Ике яшь революционер, бүлмәгә бикләнеп, бертуктаусыз җиде сәгать шул хыял уты эчендә яндылар. Мең төрле план, бетмәс-төгәнмәс зур-зур хәрәкәт, бөек көрәшләр эчендә ялкынландылар. Менә бервакыт күрше залда сәгать суга башлады. Җиһангир, кинәт уянган кебек, санарга кереште, тугыз, ун дигәнне калтыратып санады, тагы бер суккач:

– Харап булдым. Унбер икән! Мин ун сәгатьтә бакча почмагында булырга тиеш идем, киттем, – диде дә, ут чыккан кебек, атылып чыгып югалды.

Баязид, кая барасың, дип аңардан сорарга кирәксенмәде, чөнки ул бу яшь, үткен, матур егетнең кызлар, хатыннар белән бетмәс-төгәнмәс романнар эчендә кайнавын белә иде. Соңгы көннәрдә Кадыйр байның яшь бикәсе Һаҗәр белән баглап чыгарылган гайбәтне дә ишеткән иде. Ләкин моңа күп тукталмады, тагы үзенең көрәш хыялларына кереп югалды, үз бүлмәсенә ничек кайтып җиткәнен сизми дә калды. Арыган, талган иде. Ачыккан иде. Ашарга да бер әйбер юк. Алар мәдрәсә ташлап чыккан бер иптәш белән ике тәңкәгә бу бүлмәгә керделәр. Бүлмәдәше кичләрдә русча укырга йөри, учительлеккә хәзерләнә. Ахры, шуннан кайтмаган булыр. Китаплары да юк.

Баязид акрынлап чишенде дә, кечкенә зәгыйфь лампаны сүндереп, җимерек агач караватка ипләп кенә ятты. Йокы килмәде, башында зур планнары туктаусыз кайнаштылар...

Чү!.. Тукта, анда кем бар? Тышкы ишектән берьюлы берничә аяк бу квартирга керде бугай. Әнә тавышка хуҗа хатын торып каршы барды. Ни диләр? «Баязид Сафаров» диләр түгелме? Болар кемнәр булыр? Үзләре русча сөйләшәләр. Менә залны аша үтәләр, моның бүлмә ишеген кагалар. Җавапны көтмичә үк ишекне ачып керергә маташалар. Баязид карый эчтән бераз каушаулы тавыш белән:

– Мин чишенгәнмен, һич булмаса, чалбар кигәнче сабыр итегез, – дип кычкырды.

Ләкин аңар карамадылар.

– Без кунакка килмәдек... Тиз ач, булмаса, ватабыз! – дип, каты боерык ташладылар.

Егет, караваттан торып, киенү белән азапланды, тиз генә барып ача алмады, үзе бераз каушап, ни эшләргә белми аптырап та калды. Тышкы «кунаклар» түзмәделәр; ахрысы, монда берәр әйберне яшереп маташалар дигән шиккә төштеләр бугай: берсе җүнләп кысылып җитми торган ишек ярыгыннан кылыч кынысын тыкты да ишекнең элгечләрен каера башлады.

Баязид тагы каушады, чалбарының тискәре ягын киеп, аны салып азапланды; берсенең дә очына чыга алмыйча, өстенә озын бишмәтне генә киде дә ишекнең элгечен ычкындырып җибәрде. Аннан кылычлы, мылтыклы пристав, околоточный, ике городовой басып килеп керделәр. Болар артына тагы ике пүнәтәй – күршенең бер татар тегүче белән бер кибетче рус ияртkәннәр. Баязид тентү ясауларыннан, зинданга алып китүләреннән курыкмады, ләкин ул үз гомерендә моңарчы болай рус түрә белән, жандарм белән йөзгә-йөз килгәне юк иде. Гадәтләнмәгән нәрсә булганга, нык каушап җибәрде, җәзадан куркып түгел, революционерлыкның намусын сатмасам ярар иде, тиешле жавапларны тиешле рәвештә бирә белә алырмынмы икән, берәр ягын бозып җибәрмәсәм ярар иде дип куркынды, йөзе агарынды, кул-аягы калтырый башлады.

Пристав керә-керүгә кулындагы фонарь белән бүлмәне яктыртып карады да, бер карават, өстәл, ике урындыктан башка һичнәрсәсе булмаган ярлы бүлмәнең кай җиренә әйберләреңне яшерәсең икән син дигән кебек, шөбһә белән Баязидның йөзенә кадалды.

– Баязид Сафаров син буласыңмы? Без тентүгә килдек, кая, әйберләреңне күрсәт. Мылтыклар кайда, прокламация кайда? Шунда басасыз ич! – дип, юри кабатлап китте. Үзе сорармы икән дип, ордерны чыгармады.

Баязит ул турыда ишеткән иде, ләкин бүген каушау белән исеннән киткән. «Ордерың кайда?» – дип приставтан сорау теленә килмәде.

Пристав үзе өстәл янына, зәгыйфь артсыз урындыкка утырды да егеттән сорау алды. Аннан кәгазьләрне, китапларны актарырга тотынды. Барлыгы биш төргәк әйбер җыелды. Болар эчендә әле кичә генә басылган прокламациянең таратылмый калган унике нөсхәсе чыкты, мич башыннан җилем басма белән күк кара табылды. Пристав протокол язганда боларга аеруча тукталды:

– Син кечкенә. Ияреп, үзеңне әрәм итмә. Безгә башкалар кирәк, дөресен әйт: боларны сиңа кем бирде, кем килеп эшләде? – дип, Баязидның күзенә текәлеп карады.

Баязид гаҗәп бер ачыклык белән, шатлык белән һәммәсен үзенә, тик үз өстенә күтәрде:

– Миңа кем китерсен? Мин үзем революционер! Басманы үзем ясыйм, үзем прокламация язам, үзем басам, үзем таратам! – дип, кискен, ашыгыч, бераз каушаулы җавап кайтарды. Аның өчен куркыныч як – беренче сүзне ачык, дөрес әйтә алу иде. Инде берне әйтте, каушап ялгышу куркынычы калмады, башка сорауларын, тәҗрибәле кеше кебек, бер дә калтыранмыйча, каушамыйча әйтәчәгенә ышанып, тынычланды. Пүнәтәйләр артыннан протоколга тынычлык белән кул куйды.

Лəкин пристав өчен революциягə хезмəт дəрте белəн яна торган бер төркем яшьлəрнең бу психологиясе, мондый кискен, ачык баруы күптəн таныш бер хəл иде. Ул эченнəн көлде: «Зыян юк, бераз утырткач, башкачарак сайратырбыз əле сине!» – дип уйлады.

Баязидны участкада кундырдылар да, икенче көнне охранкада əллə ничаклы буталчык, катлаулы, ялганлы сораулар белəн җиде сəгать газаплаганнан соң, шəһəр зинданының сəясилəр камерасының дүртенче бүлмəсенə ялгызын илтеп яптылар.

## XV
## БЕРЕНЧЕ ҖАВАП

Исерек татар Абдулның хатыны Хəдичə җиңги, бу Баязидлар тора торган йортка килеп, вак-төяк эшлəр эшлəштерə, шимбə саен идəннəр юа иде. Баязидка тентү килеп басканда монда булган, зал ягыннан, хуҗа карчык белəн бергə аптырап, бу таныш мөселман шəкертне харап итəлəр бугай, дип кызганып карап торган икəн. Тентү бетү белəн, Баязидны алып киткəч, йөгереп өенə кайтты; сөйлəргə карты өйдə юк иде, эченə җыеп кала алмады, йөгереп кире йортка чыкты, түбəн катка карап,

Урмановта ут барын күрде дə, авыру əбине җылата-җылата, аның җəһəннəм базына төште.

Давыт, вакытның соң булуына карамастан, каядыр китəргə киенеп маташа иде. Мондый соң кичтə акылыннан шашкандай төс белəн өс-башын пычратып килеп кергəн Хəдичə җиңгине күргəч, егет гаҗəпсенеп карады; яулыгы, чəче тузылганга карап, ире белəн сугышкандыр бичара, дип уйлады.

– Җиңги, ни бар? Бик соң ич инде! – дип сорады. – Мин хəзер чыгарга торам! – дип өстəде. Ул кичəге хаты буенча Нəфисəгə барырга дип җыенган иде, җиңгинең килеп тыгылуына ачуы кабарды, лəкин үзенə белдермəде.

Җиңги мондый каршылауны сизəрлек түгел иде, керə-керүгə кычкырып җибəрде:

– Син утырасың монда... иптəшеңне баструкка алып киттелəр. Харап булды мескенкəем, нинди əйбəт егет иде! – диде.

Урманов бернəрсə дə аңламады, жандармерия тагын берəрсен килеп баскандыр дип, ашыгыч сорады:

– Иплəп əйт, җиңги, кем харап булды?

Хəдичə җиңги шундый ук куркынган төс, тузылган яулык, чəч белəн, каушаган тавыш белəн, үзен тыя алмын сөйлəп китте:

– Харап əйбəт егет иде шул, иремə бер күлмəк бирде. Кечкенə кыз балама барган саен акчалар тоттыра иде... Ни булыр икəн? Хəзер андыйларны асалар, ди, имеш! Баязидны да асмасpréвармы икəн?.. Ходаем, ник соң аларга

катнашырга инде! Безнең мөселман адәмгә... нигә катнашырга инде... Менә бит синең Йәгүр дигән иптәшеңне асканнар, ди. Син аның белән бер бүлмәдә тордың ич, ничек сине асмадылар? Алла үзе генә сакласын, нигә инде безнең мөселман агай-энегә шундый юк-барга катнашып, үзен әрәм итәргә инде...

Урманов бер стакан су бирде; ире, балалары турында сүз кузгата башлагач, хатын байтак тынычланды, авыру, кара-саргылт йөзенә сибелеп, ниндидер аяныч төс керткән тузган чәчләрен җыеп, яулыгын ипләп бәйләде дә уңайлабрак сөйләргә тотынды:

– ...Ишек артыннан тыңлап торып җаным өзелде... Үзен-үзе бу чаклы харап итәр икән кеше. Полиция аңардан ипләп сорый: бу нәрсә? Моны кемнән алдың? ди. Моны кем китерде? ди. Баязид, көлгән, мәсхәрәләгән кебек, жандарның күзенә карый да: кайдан алыйм, үземнеке, ди. Мин ишек артыннан котларым очып торам. Җә, мин әйтәм, үземнеке, үзем эшләдем дигәнче, мин әйтәм, таптым дисә, фәлән-фәсмәтән кеше бирде дисә, ни булган булыр иде, мин әйтәм. Үз башын үзе генә харап итте бит, мин акылдан яза яздым... Бик күп зәңгәр язулы кәгазьләр чыкты. Жандар аның күзенә карап сорый: бу нәрсә? Моны кайдан алдың? ди. Теге әйтми, үземнеке, ди дә тора бит. Менә бервакыт караваты астыннан әллә нинди ак калайга коелган киң җилем такта тартып алалар. Бу ни? ди. Бумы, ди, бу, ди... Мин аныңча әйтә алмыйм инде, шунда әйбер басарга үзем ясадым, дип әйтте дә салды лабаса! Мич артыннан тагы бер тартма өстерәп алдылар. Анда вак кургашын кебек нәрсәләр. Ул инде таш басма кебек китап басарга имеш, ди. Жандарның күзе дүрт булды, кыза, ачулана башлады. Баязид аның йөзенә дә карамый, үзе каушаган кебек: нигә сорыйсыз, нәрсә икәнен беләсез ич, ди. Нәрсәдер шунда басарга әзерләнә идем, ди... Харап инде, бар әйберен бәйләделәр, язып алдылар. Әллә ничә түк булгандыр, үзен солдат белән, ристан[1] итеп баструкка[2] алып киттеләр... Ходаем, аңа ни булыр?.. Асмасланмы икән?.. Аңа ни калды инде юк-барга катнашырга?.. Нигә алай дөрестен әйтергә?.. Урыс кешесе беләме, тотсын ялганласын! Теле калырмы? Үзен-үзе харап итте шул бичарам, шундый әйбәт егет иде, кызым аңа Баязид абый дип үлеп тора иде... Асмасланмы икән бичараны?!.

Давыт Урманов үзенең кичегүенә борчылды, сүзнең актыгын көтә алмый атлый башлады.

– Юктан курыкма. Асмаслар. Тиз чыгарырлар. Менә мин иртәгә иртә үк аның хәлен белергә төрмәгә барырмын... Ни булганын сиңа әйтермен... – дип, тынычландырырлык сүзләр әйтте дә тиз-тиз чыгып китте.

---

[1] *Ристан* (арестант) – тоткын.
[2] *Баструк* (острог) – төрмә, хәбәсханә.

## XVI
## НӘФИСӘ

Төн караңгы. Шулай да күп тапталган таныш урамнардан бару артык кыен булмады. Менә Чокыр урамы. Менә биек баскыч. Әнә баскыч төбендә бер карачкыл күренә. Хатын-кыз шәүләсенә ошый. «Ул» булса кирәк.

Егет баскычка якынайды; чынлап та анда, каршы як өйнең тәрәзәсеннән озаеп чыккан яктылык эчендә, урта буйлы, ак күлмәкле, кызыл яулыклы бер хатын тора. Килеп җитәр-җитмәс, Давыт сак, акрын тавыш белән:

– Нәфисә, синме? – диде.

Шәүлә баскан җиреннән кузгала төште, бераз оялчан, бераз тартынкы тавыш белән җавап кайтарды:

– Ходаем! Бу җиде төн уртасында Нәфисә монда ничек килсен1 Ул түгел, мин – Зөһрә апаң ич, танымый да башлагансың!.. Ирләр дисәң ирләр шул!..

Зөһрә атлы бу хатын – Нәфисәнең яшь, үги анасы. Урмановның танышы, кыз белән ике арада илчелек итүче. Башка вакыттагы кебек, әле дә туп-туры чиште:

– Мин, – диде, – Фәрхи җиңгиләргә әйбер илтергә чыктым... Картым Алмалы базарына китте, иртәгәсез кайтмас... Балалар йоклаган... Нәфисә ялгыз, бар, сине бик көтә... Теге Габдрахман дигәннәреннән тагы яучы килде бит... – диде. Сүзен әйтеп бетерер-бетермәс почмакка борылып, караңгы төн эчендә югалды.

Урманов кайчандыр, әле Нәфисә белән беренче мәхәббәт романнары корып йөргән чакларда, бу урамнарда торган, ерак Төркстаннардан шул урамның бер итекче аркылы дусты Нәфисәгә хатлар җибәргән иде. Адашмады, караңгы тыкрыклардан, күбе шул талчукчы вак сәүдәгәрләр яшәгән кечкенә, иске агач өйләр буйлап атлый бирде. Вакыт соң. Урамнар, тыкрыклар тын. Һичбер фонарь юк. Үтереп-суеп китсәләр, аһ дип эндәшерлек адәм табылмас. Шулай каберлек тынлыгы чолгап алган. Менә чатта ике катлы агач өй. Аның өске катында бер тәрәзәдә ут яна. Аның пәрдәсе төшерелгән. Эчтә һичнәрсә күренми. Ләкин егет таныды. Бу – «аның» бүлмәсе. Яман күзләрдән саклана-саклана, күп тапкырлар кавышкан, яшьлек белән янган иреннәрнең юлыгышкан бүлмәләре. Төнге кунак капканы сак кына ача да, бер караңгы, таныш баскыч белән югары катка таба аяк очлары белән генә баса-баса менеп, ишеккә бик сак кына чиертә. Карт өйдә юк. Балалар йоклый. Үги ана Зөһрә апа, гәрчә үги булса да, бәлки үги булганлык өчен, каядыр китә. Кем белсен, бәлки беркая да китмәгән, кире кайтып, шунда бер җиргә яшеренгән булыр. Әмма боларның берсе дә туктата

алмыйлар, тик саклана гына белергә кирәк. Егет шул уйлар эчендә бусага төбендә катып кала. Ахрысы, ышанып көткәндер, бер-ике чиертүгә эчтән йомшак басып кемнеңдер ишеккә таба якынаюы ишетелде. Тавышсыз-тынсыз ишек ачылды, аннан, кулына яшел лампа тотып, куштан итәкле, яшь, чибәр кыз килеп чыкты.

Давыт бүген, үзе ашкынудан бигрәк, рәсми бурыч үтәр өчен, кызның алдында торган чуалчык эш турында бергәләп киңәшеп, бер юл табар өчен дип, бәлки актыгы булыр дип килгән иде. Тын, караңгы төннең ялгызлыгы эчендә алдына килеп баскан Нәфисә аның йөрәгендәге элекке тойгыларын дулкынландырып җибәрде. Кыз бүген аңа тагы да матуррак, тагы да хәсрәтле уйлар эчендә шат, уенчак булырга әзерләнгән кебек күренде.

Кызның куштан итәкле, килешле тегелгән зәңгәр күлмәге аның нечкәрәк, уртача зифа буен ничектер аеруча чибәр күрсәтеп тора. Коңгыр чәч өстендә маңлай турына киелгән кечкенә, ак энҗеле калфак, язның матур чәчәге кебек, соклангыч күренә. Бөтен торышы килешле, ягымлы, һәммәсе карар күзне рәхәтләп, иркәләп чакыралар, ләкин түгәрәк ак, алсу йөзе белән аз канлы иреннәр, кайчандыр туктаусыз сөенеп уйнаган карасу күзләр бүген аптырану эчендә тукталганнар, әйтерсең, язмыш өчен нидер көтәләр, әйтерсең, авыр уйга китеп, шулай ук бәхетсез булырмынмы икәнни мин, дигәндәй карыйлар. Шунда шик килә, бу кем? Җанлы, тулы канлы бер яшьме, караңгы кичтә, ай яктысында ясаган бер рәсем генәме дип уйлата. Ләкин бу – бер секунд булды. Килерме, юкмы дип шик-шөбһә астында көткән дус егетен күзгә-күз очрату белән кызның сүзе ачылды, иреннәренә, яңакларына алсу кан уйнап китте. Аның бөтен торышы: «Ах, мин сине бик көттем!» – ди иде. Ләкин теленнән башка сүз чыкты:

– Ходаем, танымый торам! Сез әллә нинди озын бүрек кигәнсез ич! – дип, Урмановка үзенең эчке ялкыннан кызган аз канлы, ябык кулын сузды. Ул оялчан, тартынучан, үз эчендәге утларны яшерүчән кыз иде, ләкин бүген көче җитмәде, кулын тартмыйча, үзе Давытның күкрәгенә таба сыенды, иреннәре сагынулы ялкын эчендә янып, бер-беренең кочагында югалдылар.

Залда балалар йоклый иде.

Аяк очы белән генә басып Нәфисәнең үз бүлмәсенә үттеләр.

Урта хәлле татар гаиләсендә үскән, атага каршы талаша-талаша бераз яңарган, матурлык сөюче яшь, чибәр татар кызының матур, пөхтә җыелган кечкенә җыйнак бүлмәсе.

Урамга күз атмасын, үткән-барган егетләр белән күз кысышмасын дип, кечкенә тәрәзәгә калын пәрдә корылган бу бүлмәгә керү белән, егетнең җаны рәхәтләнеп китте. Байлык юк. Ләкин һәммә нәрсәсендә беркадәренчә матур зәвекъ сизелеп тора. Бүлмәнең түрендә бөтенләй актан челтәрләп

җыештырылган чибәр карават. Кечкенә-кечкенә ак мендәрләр, челтәрле чигүле япмалар. Аның аяк очы башында өсте ак җәймә белән ябылган пальто, берничә платье[1], шәл эленеп тора. Тәрәзәгә якын куелган кечкенә матур өстәл өстендә бер көзге, берничә савыт ислемай, байтак татар әдәбияты, иң матур тышлылары өскә салынган алтын язулы берничә китап, берничә рәсем, каләм, кара, тагы шундый, Европа хатынының язу өстәле, көтепханәсе, туалет өстәле кебек берничәгә аерыла торган әйберләр монда, бәлки дустының киләчәген белеп, шулай тырышлык белән бергә тезелгәннәр, үзләренчә һәммәсе килешеп карыйлар, матурлык сөюче зәвекъ иясе бер кулның пөхтәлегән сөйлиләр.

Бүлмәгә кереп, лампаны өстәлгә кую белән, Нәфисә егетнең күзенә текәлеп карады:

– Расмы? Сезнең бер иптәшне асканнар имеш, расмы? – дип сорады.

Бу сүз Егор турында иде. Давыт аңа:

– Әле ачык билгеле түгел, – дип, бер генә сүз белән җавап кайтарды да, биленнән кочаклап, кызны янына утыртты, үзе кебек үк батырып карап әйтте: – Нәфисә, иркәм, вакыт бик соң бит. Мин бер генә минутка кердем. Көндез кеше күрүе дә бар. Минем бер минут вакытым да табылмый, балалар да уяна башлар, ну, синең хәл ничек? – дип, кулын тотты.

Кызда оялчанлык белән кыюлык сугыша башладылар. Шулай да ул үзен көчләмәде, егетнең кочагына сыена төшеп, кибә, калтырый башлаган тавыш белән җавап кайтарды:

– Баягы хатымда да язган идем инде... Габдрахманнан тагы яучы бар ич! Актык сүзне ишетәбез, диләр икән. Әткәй миңа бер сүз дә ачмый. Мин читләп кенә белдем, мәһәренә килешсәләр, бирергә исәбе бар бугай... Менә бит, Ходаем, ничек, әйтерсең, төнлә урлап мал саталармыни?..

Кызның тамагына нидер килеп тыгылган, күзе яшьләнергә башлаган кебек хәл булды. Ул бер генә минут туктады да тагын сөйләп китте:

– Әйтегез, зинһар: ул кем соң? Бу араларда аның бу урамнан йөргәнен бик еш күрәм. Үткән саен минем тәрәзәгә йотылып-йотылып карый... Аңа ни булган: нигә ул яңагына яулык бәйли? Безнең аста бер итекче хатыны бар. Шул әйтә: аның яңагына тилчә булган, ди, черегән, ди. Гомергә төзәлми икән, ди, шуңа күрә, ди, яулык бәйләп йөри, ди...

Давыт көлде:

– Менә гаҗәп: ни эшләп чересен? Шалкан кебек таза егет ул. Нигә кызылларга катнашасың, нигә мөселманга йөз каралыгы ясыйсың дип, аны ике татар егете төнлә тар тыкрыкта кыйнаганнар, яңагында шуның ярасы

---

[1] *Платье* – хатын-кыз күлмәге.

бетмәгән әле... Ул бернәрсә дә түгел, – дип, кызның башында кайнаган шикләрен бетерергә тырышты.

Ләкин Нәфисәнең исәбе Габдрахман турында сүз куертып, Давытның үзеннән актык нәрсәне әйттерү иде, шуңа күрә ул һаман шикле якны каерды:

– Менә, – ди, – бер дә чынын белер хәл юк, берсе әйтә: ул бик яхшы приказчик, айга йөз сум ала, үзе ялгыз, тик бердәнбер анасы бар, ул да башка кайнаналар кебек гыйфрит булмас, ди. Кайбер кешеләр: эшкә ярамагач, урыныннан куганнар, хәзер ач-ялангач йөри, диләр... Аптырадым инде, бу арада шуны уйлый-уйлый башым катты... Сез, ичмаса, чынын әйтегез миңа! – дип, Урмановның күзенә сорау белән карады.

Урманов үзе дә ут эчендә, ул җүләр түгел. Нәфисәнең хат артыннан хат язып нигә чакыртканын да, Габдрахман турында нигә сүз куертканын да сизә. Ләкин кызның көткән актык өмитен бирә алмый. Аңа бит кып-кыска итеп, бер генә сүз әйтергә кирәк: «Нәфисә җаным, ташла ул Габдрахманнарны! Без яратышабыз, атаңның ризалыгы да кирәге юк. Әйдә киттек бу җәһәннәмнән. Ни күрсәк бергә күрербез!» – дисә, бер секундта кызга канатлар үсәчәк, кыз шул сүзне ишеткән вакытта әллә ничаклы күтәреләчәк, дөньясын, усал атасын, үги анасын онытачак та, йөзендәге барлык кайгы төсләре югалачак, яшь, матур, уенчак күзләрендәге яшь ялкын белән егетнең йөрәгенә ут яндырачак һәм шул минут, бөтен нәрсәсен ташлап, әнә шул өстендәге күлмәге белән оекчан моннан чыгып качарга атылачак, сөйгән егете белән бергә булса, дөньяның иң каты газапларына да уенчак йөз белән каршы барачак.

Хәл менә шулай иде. Ул үзе шундый бер дәрәҗәгә үсеп китә алырлык кебек иде. Ләкин Давыт аңа кирәк сүзне әйтмәде, тагы шул Габдрахманга кайтты:

– Әйе! Мин аны бик яхшы беләм. Ул таза-сау егет. Элек яһүдтә иде. Хәзер инде Кадыйр байга кергән. Айга кырык сум ала. Бае аңа тыныч эшләсәң, өйләнсәң, тагы ун сум арттырырмын, дигән... Менә минем белүем шулай! – диде.

Кызның тәненә суык су сибелгәндәй булды; ачык сүз булмау аны кара бәхетсезлекнең караңгы ярыннан ыргытып җибәрүгә якын китереп куйды. Бераз рәнҗү катнаш сөю тавышы белән тагы шул катлаулы сүзнең өске ягында йөзде:

– Ичмаса, атаң кеше булса иде! Аның белән аңлашып карап булса иде! Ул бит мондый турыдан бер сүзне күтәрми. Мин башласам да: ташла юкны, кыз кеше андый сүзгә катнашмый, син тик тор, мин үзем беләм, дияр дә куяр. Әнә бит озын колак хәбәре йөри: имеш, мәһәренә килешсә, бирергә исәбе бар бугай. Аның бар курыкканы шул. Ул мине сиңа ябышып чыгар дип коты оча.

Кызым качып киткәнче эшне бетерим дип, кем сораса шуңа сатарга тора. Тик мәһәрне генә мул бирсеннәр. Ул үзе әйтеп утырды: сөеп алган, сөеп барган кеше гомергә бәхетсез була ул, әнә Гомәр карт үзенең бердәнбер кызын, җаны теләгән җылан ите ашаган, үзе яраткач, миңа нәрсә, дип, Чатан Гәрәйнең улы Шәрәпи солдатка биргән иде, эт көнендә гомерләре үтә хәзер, ди. Менә ул һаман шундый юк-бар белән сүзне баса да куя, мин аңа бер сүз әйтергә база алмыйм...

Кыз атасы турында озак зарланды. Ләкин тел боларны сөйләсә, күңеле Давыт тирәсендә иде. Ул каяндыр, ничектер ишетеп калды яки үзе сизенде: ни дә булса, аның башында бер каты уй бар. Менә бит Давыт – революция юлына кергән яшьләрнең берсе. Мондый яшьләр өйләнеп, гаилә корып, бала-чага асрап, тормыш коруга якын бармыйлар. Болар аны чәүкә оясына ошаталар. Бу чәүкә оялары аларның кул-аягын бәйлиләр, мещанлык сазлыгына батыралар, аларны революция өчен яшәү юлыннан аералар имеш. Кыз үзен менә шундый каты уй астыннан коткара алмый; бу турыда беркем белән дә сөйләргә, аңлашырга җай юк, атасы усал, иске карт. Тик мәһәр белән туйны-никахны гына белә, үги анасы Зөһрә үзе егетләр белән уйнаш итә. Бу серләрне чыгармасын дип, Нәфисәгә булышлык кыла, аның сөюенә, кавышуына ярдәм күрсәтә. Ләкин ул өйләнү белән революция эшләренең бәрелешләре турында бернәрсә аңламый. Ул гына түгел, Нәфисә үзе дә аңламый – ничек ул алай? Давыт өйләнсен, Нәфисәне үзенә алсын. Әмма нигә Нәфисә аның муенына бәйләнгән таш булсын! Моны аңламады, мин наданмындыр, башым җитми торгандыр, бу хәлләр минем башыма төшкән бәхетсезлек икән. Илаһым, мин нигә сөйдем?! Нигә генә сөйдем? Сөймә икән, җаның тыныч булыр иде! Хәер, алай торуның ни тәме булыр?.. Кыз, үз эченнән шулар белән көенгән хәлендә, тыштан сүзне башка әйберләр тирәсендә әйләндерде. Давыт аңа гаҗәпсенгән тавыш белән, ярым шелтә белән кайтарды:

– Мин, – диде, – сине аңламыйм! Менә синең укый торган китапларың! Син бит, башкалар кебек, бөтенләй чапан астында бикләнеп ятмыйсың. Укыйсың, әдәбият сөясең. Атаңның үзе теләгәнчә сатарга хаклы түгел икәнен беләсең... Нигә бу турыларда ап-ачык итеп аның белән сөйләшмисең?! Хәзер бөтен Русиядә патшага каршы сугыш бара, яшьләр шуңа ташландылар, син монда шул аксак атаң белән сөйләшә алмыйсың...

Кыз бер хурланды, шулай да яшермәде:

– Алмыйм шул! Ни эшлим! Менә ялгыз чагымда каным кайный, башымда фикер тула, телемнән сүзләр чәчриләр. Әмма әткәй белән кара-каршы килсәм, зиһенемне томан каплый, барлык әзерләнгән сүзләрем югала... Ул бер тапкыр минем өстемә аяк тибеп кычкырса, тамырларымда кан

суына – менә бит ул ничек минем өстемдә албасты булып тора... Аннан бит, сөйләп тә ни файда: ул сиңа күп сайрарга бирми, каршы бер сүз ишетсә, аның күзен кан баса, маңлай тамырлары кабарып чыга, ул бер тапкыр: «Тыгылма минем эшемә», – дип аяк тибеп акыра, аннан да туктамасаң, ни туры килсә шуның белән тәнеңне кара яндырганчы кыйнап ташлый... Инде моның белән дә акылга утырмасаң, эт урынына өеннән куып чыгарачак...

Кыз залга чыгып керде дә тагын кайгысына йөзеп китте.

– Безнең аста, – ди, – бер итекче тора. Әдәм карамаслык кабахәт бер исерек баш нәрсә шунда. Көн буе өйдә утырып ялыгасың, кибәсең. Шәһәргә чыгармыйлар. Бакчага йөртмиләр. Мин, бик аптырагач, шул тегүченең хатыны белән дуслаштым. Уенчак, шаян бер хатын ул. Шуларга еш-еш кереп йөри башладым... Беркөн шуларда утырганда, балалар: «Апа!.. Апа! тизрәк чык! Әти кайтып килә!» – дип акырыштылар. Атылып чыксам, ни күрим, каршымда әткәй тора. Йөзе ачудан кара көйгән, күзләрен кан баскан. Үзен чак танырсың, шундый рәхимсез төскә кергән. Мине күрүгә әллә нинди усал тавыш белән: «Сиңа ни бар анда? Ә? Сиңа ни бар анда? Ашарың әзер, эчәрең әзер. Өстең-башың бөтен. Сиңа тагы ни җитми? Анда ни калган, әйт? Син анда егет күзләргә йөрисең, сез анда җыелып егетләр сөйләшәсез булыр, явыз, бәдбәхетләр!» – дип, өстемә җикеренде дә, чәч толымнарымнан өстерәп югары мендереп, каеш белән ярырга тотынды. Балалар акырып җылый башладылар. Әнкәй килеп тыймакчы булган иде, каеш белән аның йөзен ярып җибәрде... Мин тавыш чыгармадым, ни булса шул булыр, тик битемә сугып яралый гына күрмәсен дип, йөзем-башым белән аска таба бөгәрләндем дә яттым... Шундый ярды, шундый кыйнады инде, тәнемдә кара янмаган урын калмады, менә эзләре әле дә бетмәгән әле, – дип, Нәфисә беләген, муенын күрсәтте.

Бу газаплар егетне ике ут арасына куйдылар, бер дулкын аны Нәфисәгә тартты: «Әйдә, җаным, бу җәһәннәмдә ятма! Киттек, ни күрсәк бергә күрербез!» – дип, кызга кул бирергә чакырды, шуңа өстерәп китерде, икенче көч аның уен авыр көрәш мәйданнарына очырдылар.

Кыз тукталмады:

– Ул, – ди, – үзенчә мине бик ярата да... Элек алай кыйнамый иде, эшләре бик начарланды, шул талчуктагы ике кечкенә кибетнең берсен япты, яшь әни Зөһрәнең уйнаш итүләре турындагы гайбәтләр дә аның канын бик боздылар. Ул шулардан бик яман холыксызга әйләнде. Үзе тагын гаҗәп кебек: кичтән мине шулай кыйнап ташласа, икенче көнне харап инде менә иркәләргә тотына... Элек сорап та алмаган әйберләремне табып алып кайта, сүзе йомшаклана, ни әйтсәм шуңа күнә, балаларны, әнкәйне кыйный башласа, мин арага керәм икән, кыйнаудан туктала, атналар буе шулай,

майлаган кебек, ал да гөл, син дә мин булып йөри... Шунда тагы бернәрсә чыга да, тагы эт итеп кыйнап ташлый... Миңа тагы бер хәл, җитү кыз очар да китәр, менә балалар белән әнкәйгә бик харап... аларны бик кызганам...

Залда сәгатьнең калын карлыккан тавыш белән уникене сукканы ишетелде. Балалардан берсе йокы арасында:

– Әнкәй, су!.. Әнкәй, су!.. – дип кычкырды. Нәфисә ярым чын, ярым уен белән Давытка бармак селекте:

– Чү! Балалар уяналар!

Ләкин тавыш кабатланмады. Нәфисә үзалдына:

– Саташадыр хәерсез малай... Бу арада әллә ни эшләп йокысының җүне юк! – диде дә: – Дөньялар менә шулай, Давыт абый! – дип, егетнең тез өстенә үзе килеп утырды.

Урманов иреген югалта башлады. Тәннәр уралалар. Кызның өстеннән, чәчләреннән аңкыган хуш исләр егетнең башын әйләндерәчәк бер көч белән дулкынланып килеп кагылалар. Инде Нәфисә үзе дә баягы агарынган иренле, ак йөзле, оялчан кыз түгел. Сөйгән егетенең янында аның тәне кыза, каны кайный, йөзе, иреннәре алсу-кызылланып яналар, саф, матур, ачык якты күзләре томанланып исерәләр. Егет ялкын эчендә янган көчле beläкләре белән кызны күтәреп ала да, бер секунд башын-акылын югалтып, катып кала – менә-менә томан каплаячак, мәңге төзәлми торган бер хәл киләчәк, боларны караңгылык йотып алачак!..

Шул актык секундта тегеннән тагы бала тавышы килде, кечкенә малай:

– Апа... су! – дип саташа башлады.

Читтән килгән бу кечкенә ярдәм егетнең башын айнытып җибәрде. Ул, дивана кебек, уң кулын маңлаена сукты, бөтенләй ят, шашкан тавыш белән:

– Тукта! Мин ни эшлим?! Харап ич! – дип, исереклектән кинәт уянды.

Нәфисә һушка килде, күзен ачып карады, хәлсез кул белән чәчен төзәтте дә мендәргә кире капланды. Өмитсезлек тулы тавыш белән кисеп әйтте:

– Давыт абый, син кайт инде, әнидән дә яхшы түгел, синең иртәгә эшең дә күптер! – диде.

Тормады, озата чыкмады, Давыт, чыгам дип, аның маңлаеннан, кулыннан үбәргә әйткәндә, егетнең муеныннан кочаклады да ялкынлы ирененнән озак, каты суырып үпте, аннан кире мендәренә капланды. Бераздан кергән Зөһрә апага да күтәрелмәде, күз яшьләре туктамадылар. Утны тиз сүндерде, ләкин йоклый алмады. Озын, караңгы төнне күз яше белән, үзенең киләчәк язмышы турында газаплы уйлар белән үткәрде.

## XVII
## СЕЗ МОНЫ КАЙЧАН ЯЗГАН ИДЕГЕЗ?

Давыт Урманов, үзенең җәһәннәм базына кайткач, бүлмәнең бер башыннан икенче башына йөреп, озак уйланды, аннан, утырып, кечкенә хат язды.

«Нәфисәкәем! Мине гафу ит! Синең белән гомерлек дус булып калуны өмит итәм. Сиңа күп бәхет телим. Синең якты көннәреңне күрәсем килә! Хәзергә башка сүз яза алмыйм...»

Башка сүз таба алмады, иртә торгач, бу хатны конвертлады да кесәсенә тыкты.

Баязид карыйның Давыт Урмановтан бүтән кардәше юк. Башкаларны кертмәсләр. Хәлен, чамасын белергә кирәк. Бәлки ашыгыч бер кирәге бардыр... Шулай уйланып, шәһәр зинданына, Баязидның хәлен белергә юнәлде.

Ләкин тоткынны күрү алай бик тиз генә мөмкин булмады. Беренче барганда:

Хәзер соң, иртәгә килерсең, – диделәр.

– Бездә тоткыннар белән күрешү өчен атнада ике көн билгеләнгән. Шуны көтегез, – дип, кире кайтардылар.

Бу билгеләнгән көннәрдә тагы аңа ишек ачылмады:

– Аерым рөхсәт кирәк, – дип, чыгардылар. Давыт, аптырап, адвокатка – сәясиләрне буш яклый торган Абрам Моисеевич Соломонов атлы кадетка барды, – ул бик ачык кабул итте, вакыйганы сөйләде, ахырда:

– Әгәр бөтен эш ул Хәдичә дигән хатын сөйләгәнчә булса, йә крепость, йә Себер булыр, – дип сөземтә ясады.

Шулай эшнең кай ягыннан башларга белмәгән чакта, гаҗәбрәк бер вакыйга булды: зинданда кемнәр аркылыдыр Кавказлы Гәрәй Солтанның яшерен элемтәсе бар икән. Шуның буенча Җиһангиргә Баязидтан хат килде. Ул анда начар яза:

«Бер атна эчендә күкрәктән ике тапкыр кан килде. Йокысызлыкка дучар булдым. Төн буе йокламый саташып чыгам», – ди.

Давыт тагын Соломоновка йөгерде:

– Эше каралганчы залог белән чыгарып торып булмасмы? Сәламәтлеге бик начар, һәлак булыр бит болай барса, – дип киңәште.

Ләкин адвокат юаныч бирә алмады:

– Әгәр хатынның сүзе дөрес булса, Баязид үзен куркыныч җинаятьче ясап күрсәткән була, андыйларны залог белән чыгармыйлар! – диде.

Ләкин бу эшнең эчендә ниндидер бер катлау табылды: Баязид карыйны, эшләре каралганчы, алты йөз сум залог бәрабәренә чыгарачак

булдылар.

Инде эш акчага терәлде.

Баязид карый теге вакытта хур ителеп, кыйналып, суктырылып, мәдрәсәдән качканнан бирле атасы белән бөтенләй өзелгән, еллар буенча сәлам хат та алышмаган иде. Шулай да бердәнбер улының авырулыгы, тоткынлыгы бәлки күңелен бераз йомшартыр дип уйлап, Баязидның атасы Җиһан ишанга телеграм бирде: «Авыруы куркыныч, башка җирдән акча табарга өмит юк, балагызны коткарыгыз», – диде. Беренче, икенче телеграмнар бөтенләй җавапсыз калды. Ун сүзгә җавабы түләнгән өченче телеграмга каршы тоткынның атасы ишан хәзрәттән дүрт сүз алынды:

«Минем андый улым юк!..»

Ишаннан өмит өзелгәч, Урманов либералларга сугылырга уйлап карады. Монда Салихов Шакир атлы яшь бай бар. Ул үзе һәрвакыт: «Мин кызылларга каршы түгел, мин астыртын социалистмын, әгәр социализм килеп чыкса, мин барлык малымны ярлыларга үз кулым белән бүлеп бирәчәкмен», – дип сөйләнеп йөри. Башка җүн булмагач, шуңа сүз салдылар. Ләкин ул кул гына селкә. Аның белән сатулашмак булалар.

– Юкны кызганасың, син бит ул алты йөзне бер кичтә шантанда[1] да бетерәсең! – диләр.

Бу да файда итми, яшь бай куркынып тәрәзәгә карый:

– Сезнең гөнаһ шомлыгыгыз миңа тия башлар! – дигәнне аңлатып, сүзне полициягә, жандармга, охранкага борып җибәрә.

Шулай өмитсезлеккә төшкән чакта, көтелмәгән бернәрсә килеп чыга.

Шәһәрнең атаклыларыннан Кадыйр байның Йосыфҗан исемле улы бар. Бүтән байбәтчәләргә ошамаган рәвештә гыйлемгә ихласлы күренгән бу зирәк, тырыш егет кадим мәдрәсәдә Давытларның сыйныфташы иде. Алар бергә талашып, дуслашып, моназарә эчендә кайнап, байтак еллар бергә бардылар. Ләкин соң вакытта аралары бозылган, катнашу, очрашу беткән, бер-беренә дошман киселгәннәр иде.

Салиховтан буш кул белән кайтып, аптырый төшеп утырган бер заманда менә шул дус-дошман егет, байбәтчә Йосыфҗан, көтелмәгәндә Урмановның җәһәннәм базына килеп керә дә туп-туры әйтә:

– Баязид кан эчендә ята дип ишеттем. Залог белән чыгарырга акча тапмагансыз икән. Алты йөзне мин бирим! – ди.

Урманов башта егетнен яхшы исәп белән килүенә ышанмады, шулай да аны кулыннан килгәнчә, якты чырай күрсәтеп, авыру кардәшен тоткыннан

---

[1]*Шантан* – азартлы уеннар уйнап, исерткеч эчемлекләр кулланып күңел ачу урыны.

чыгарып тору өчен алты йөзне Йосыфҗаннан алырга күнде.

Менә шул шатлыклы хәбәр белән иртәнге сәгать унбердә шәһәр зинданына килсә, аның алдында капка ачылды. Шул арада мылтыклы ике каравыл уртасында, ябыккан, кап-кара сакал-мыек баскан Баязидны зинданның зур, таш, кызыл корпусыннан, киң йорт мәйданы аркылы, конторага таба алып киткәннәрен күреп калды. Давыт зиндан гадәтен белми иде, капкадагы каравылга ашыгып әйтте:

– Әнә минем кардәш... бер генә сүзем бар... – дип, керергә омтылды, аны кире суктылар. Ул шунда ук кесәсеннән кәгазь-каләм чыгарды да тоткынга русча хат язды. Шул алты йөз табылганын, бәлки хөкемгәчә чыгарып тору мөмкинлеген аңлатты. Ләкин бу хат зиндан башлыгына, аннан прокурорга китте, шунда йөреп, «эш»кә беркетелеп калды, тоткынга барып ирешмәде. Баязид капка төбендә ачык ишектән кычкырган Давытның тавышын да ишетмәде, үзен дә күрмәде, аны, зинданның конторасы аркылы алып барып, эчке бер кабинетка керттеләр.

Үз бүлмәсендә тентү вакытында бер тапкыр сораганнар иде, участкада тагын бер ярты сәгать протокол язып азапладылар. Аннан жандармериягә кереп, тикшерүче офицер жандарм Филиппов бер уңайдан дүрт сәгать җәфалады, дөньяда сорамаган нәрсәсен калдырмады, кырык төрле төскә керде, бер дус булды, бер дошман киселде, Себер белән, каторга белән, асу-кисү куркынычлары белән шаярды. Баязид тентү вакытында, теге Хәдичә җиңги күреп торгандагы кебек, берничә әйбер турында өзеп, ап-ачык әйтте дә салды, башка әйберләр турында җавап алучы жандарм офицер Филипповның соры күзләренә карады да катты.

– Белмим, белмим, күрмәдем, ишетмәдем, хәбәрем юк! – диюдән башка сүз ычкындырмады.

Ләкин жандармерия каршында бу кызу канлы ачык егет тирән шөбһәле, бик бай бәйләнешле кебек булып күренде. Зинданның тар, кечкенә, юеш, таш бүлмәсендә, тимер йозак эчендә бикләнеп, бераз җәфалансын – аннан соң башкачарак сөйләр, дип уйладылар. Аны ике атнага якын җавапка чакырмый тордылар. Бүген төндә тагы бик күп яңа тоткыннар, яңа материаллар алынды. Шулар эчендә егетне аяктан егачак берничә әйбер бар иде. Жандарм полковник Герасимов кайбер вакытта Зубатов методын [21*] гамәлгә куючан, бигрәк тә, беренче тапкыр эләккән яшь тоткыннарны яхшы сүз, үгет белән туры җавапка тартырга яратучан иде. Йокысыз үткәргән ике төннең гадәттән тыш арытуына карамады, Баязидны үзенә сорап алды.

Яшь тоткын зинданнарда әйттерер өчен кыйнаулар, җәфалаулар була икән дип күп ишеткән, үкчәсен кисеп, тоз сибүләр, чәчен, аяк-кул тырнакларын суыртулар кебек газаплар хакында күп нәрсә белгән иде. Ул,

үзенчә, моңа хәзерләнде, нинди генә каты газапласалар да, кирәгеннән артыгын әйтмәскә, сер бирмәскә, революцияне сатмаска дип үз эченнән атлар бирде. Бүген конторага дип чакыргач, шул куркынычлар аның алдына килделәр, ике каравыл астында контораны үтеп, җавап кабинетына кергәндә, тезләре калтырады, үзенең антын тагы яңартты, тагы ни генә эшләсәләр дә, ничек кенә җәфаласалар да, кул-аягымны суырсалар да, кирәгеннән артыкны әйтмәскә! Әйтмәскә! Әйтмәскә! Әйтмәскә! Әйтмәскә!!! дип кат-кат үзенә үзе тукыды. Үзенә ышанып бетмәгәнгә, нервалары какшап, харап итүдән курыкты, курыккан саен тагын үзенә-үзе йөрәгеннән, миеннән ныклык, катылык сорады. Шул өмит белән газап һәм курку эчендә зур якты кабинетка барып керсә, анда һичкем юк. Тик ак стенада һәрбер кергән кеше өстенә күзен чекрәйтеп карап торган Николай патша бар. Аның бер ягында хатыны, икенче ягында кызлары басып торалар. Егет, як-ягына каранып, башка һичнәрсә тапмады; тик уртада зур яхшы өстәл, аңа кара постау җәелгән. Графин белән су куелган, аның янында бер стакан, көл савыты. Башка берни юк. Тоткын, аптыранып, әле бу өстәлгә, әле Николай патшага каранып торганда, икенче яктан ишек ачылды да, җиңел атлап, карт жандарм полковник Герасимов килеп керде. Баязид аңа текәлде. Ләкин бу кешедә бер дә алай куркыныч, ерткыч төсе юк. Киресенчә, ак чәче, ак сакалы, ачык көләч йөзе белән, өлкән агаң яки туган атаң кебек ягымлы тавышы белән бу жандарм безнең тоткынга бик ипле карт булып күренде.

Герасимов, керүгә, каравылны чыгарды да бөтенләй якын кардәш тавыш белән русча:

– Менә монда утырыгыз!.. Мин сезне биш-ун минутка гына чакырдым, бер-ике сүзем бар. Аннан бит, сез зур ишан хәзрәт баласы икән. Атагыз хөрмәтенә менә анда, иректә калган танышларыгыз сезнең өчен залог салмакчылар. Күкрәгегездән кан килгән бит, безнең зиндан докторы Ефим Серафимович эчәргә ярата, җүнләп карамый; мин әйттем, сезгә анда башка специалистны китереп каратсыннар, дидем... Тәмәке тартасызмы, рәхим итегез! – диде дә көмеш портсигарны, шырпыны тоткынга таба этәрде; үзе шуннан папирос яндырып капты да, нәкъ күзгә-күз карашып, Баязид каршысына, өстәлнең түр ягына, Николай патша сурәте астындагы тирән креслога чумды.

Баязид бөтенләй үзен югалта язды, каушап, калтырап, дерелдәгән кул белән портсигарга сузылды, аны бер ачты, дерелдәп, тагы япты, ләкин хәтерли алмады, ул ирektә чакта тәмәке тарта идеме, юкмы? Юк бугай. Әллә тарта идеме икән? Һичбер төрле ачык хәтерләмәде. Шулай да өйрәнмәгән кул белән бер папирос алды, каушап, калтырап яндырды да авызына капты. Ләкин тәмләп суырып, борынынnan чыгара белмәде, тәтенгә чәчәде дә,

кызара төшеп, сүнмәгән тәмәкесен өстәлгә, кара сукно өстенә куйды; яңа башлавын күреп, тиз генә кире бармагына алып изде дә папирос төпчеген кесәсенә тыкты, шунда, алдында торган көл савытын күргәч, төргәләнеп беткән төпчекне кире шунда алып салды. Бөтен бу хәлләр берничә секунд барды. Герасимов, күзе белән йотылып, яшь тоткынның болай каушавын гадәттән тыш бер интерес эчендә күзәтеп барды. Күз алмыйча, үзен югалта язып күзәтте. Баязид, кесәсеннән чыгарып, төпчекне кире көл савытына салуга, карт төлке урыныннан кузгалды. Үзенең портфеленнән берничә кәгазь чыгарды да, бик гади нәрсә кебек, берсен тоткынга биреп: – Сез моны кайчан язган идегез? – диде. Күзенә текәлеп карады.

Баязид Сафаровның күзләре уйнаган, томаланган кебек булды. Аның алдында зәңгәр кара белән басылган прокламация ята. Моның сүзләре генә түгел, хәрефләре дә таныш. Анда ачык татарча белән Баязид күчереп, җилем белән баскан сүзләр ярылып яталар. Егетнең күзе әлҗе-мелҗе килде. Юллар, хәрефләр, сүзләр бергә бутала башладылар.

Сафаров прокламацияне ачык таныды. Шик юк, моны ул күчерде, ул басты. Беркөн шулай Җиһангир белән урамнан китеп барганда, Гәрәй очрады да әйтте:

– Туганнар, сезгә бер эш бар, – диде.

Болар, эш тапшыруга шатланып, аны бакча почмагында көттеләр, Гәрәй Солтан каядыр барып килде, эскәмиядә бергә тәмәке тартып утырган булып, боларның кесәләренә бер кәгазь тыкты:

– Ачык булсын! Әйбәтләп күчерегез. Йөздән ким ярамый. Начар чыкса, ике тапкыр басарбыз, – диде.

Болар шуның өстендә, ишек бикләп, тәрәзәгә бишмәт корып, ике төн эшләделәр. Йөз ун нөсхәнең җидесе яраксыз чыкты, калган йөз дә өче гаҗәп ачык, матур басылдылар.

Жандарм Герасимовның: «Моны сез күчердегезме?» – дип, тоткын Баязидка сузган кәгазе менә шул йөз ун данә басылган прокламациянең берсе иде.

Герасимов яшьләр белән эш иткәндә психология моментына аерым кадалучан жандарм. Ул тоткынның башта калтырануын күреп торды, аннан тынычлануын сизенде, ләкин бу тынычлану жандарм өчен файда түгел, җавапны көтмичә үк тагын бер кәгазь сузды.

– Сез менә шунардан күчердегезме? – дип, тагы Сафаровның күзләренә йотылды.

Шик юк, Җиһангир белән Баязидка бакчада китереп кесәгә тыккан кәгазь менә шул иде. Булат кулы белән ашыгыч-ашыгыч язылган. Хәрефләре, сүзләре бары да Булатныкы икәне ачык күренеп тора. Болар бер түгел, күп

тапкыр аның язган прокламацияләрен шулай басып тараттылар. Бу – күпнең берсе генә.

Ике тапкыр каушап, калтырап, Баязид инде бөтенләй тынычланып китте.

– Рөхсәтме? – дип үзе сорап, тәмәке тартты. Тәме юк, тартасы килми. Шулай да тарта. Бер эш булсын өчен, шул жандармның, туктаусыз күзгә-күз карап, эчеңдәге сереңне суыруыннан котылыр өчен кирәк.

Полковник яңадан сорады, егет икесе турында да кире җавап бирде:

– Белмим, бу прокламацияне мин басмадым. Мин күчермәдем. Минем эшем түгел... Бу кәгазь кем кулы белән язылгандыр, танымыйм. Мин Булатның кульязуын танымыйм, – диде. Үзалдына аптырап, гаҗәпсенде, бу чаклы нәрсәне жандармнар кайдан белеп бетерәләр? Кайдан алалар? Ул охранканы, андагы эчке агентураны, тышкы күзәтче-филерларны ишеткән иде. Ләкин алар эшнең бу дәрәҗәдә эчләренә кереп белерләр дип хәтеренә китерми иде. Булат язган, аны Гәрәй безгә бирде. Без яздык. Йөз өчне тараттык... Ә соң Булатның карандаш белән язган оригиналын кая куйдык соң без? Кире кайтармадык. Ничектер шунда югалды бугай. Шик юк: ничек булса да болардан шул Булат кульязмасын алганнар... Әмма аны Булат язганын каян беләләр? Бу прокламацияне күчерүче мин икәнен ничек беләләр?

Тоткынның бу аптырауларына җавап сыман итеп, жандарм өченче бер кәгазь чыгарды. Бусы инде әле менә зинданнан яшерен юл буенча Җиһангиргә язган хаты иде. Исең китәр, биш юллык шул кечкенә хат та, кайдандыр узып, боларга эләккән. Монда кемдә хыянәт бар: Гәрәй Солтан сатлыкмы? Җиһангир, Давыт провокатормы? Әллә боларның эченә, йөрәгенә кереп, дус булып йөргән берәр иптәш охранкада агентмы?, Бер секундта бу шикле уйлар тоткынның башыннан кичте. Ләкин аңа җавап чыга алмады, жандарм сүзне соңгысыннан башлады:

– Менә бу соңгы хат сезнекеме? Баязидка танарга урын юк иде:

– Минеке! – диде.

– Алайса, менә ике язуны чагыштырыгыз, бу хат белән прокламация икесе бөтенләй бер түгелме? Мин татарча белмим, ләкин гыйльми экспертиза боларның икесе бер кул белән, сезнең кул белән язылган дип тапты... Инде менә моны карагыз! Менә Булатның сеңелесе белән әнисенә язган хаты!.. Менә сезгә Гәрәй Солтан аркылы биргән прокламация оригиналы... Икесе бер кул түгелме?.. Экспертиза шулай тапты... Сез, мондый ачык әйберләргә каршы әйтеп, үзегезгә ышанычны бетерәсез. Әмма мин сезне әрәм итәсем килми. Сез зур кеше баласы... Сезне бу Булатлар, Гәрәйләр юлдан яздыралар. Сез миңа дөресен сөйләгез, мин сезнең язмышны җиңеләйтергә

тырышачакмын... Башлыкларыгызның ялганнарына ышанмагыз, алар сезгә һәрбер жандармны бер усал ерткыч итеп күрсәтәләр. Әмма безгә дөреслек кирәк, сезнең арада ниләр эшләнгәне турында безгә материал күп ага. Шулай да тулы мәгълүмат аласым килә минем! Сез миңа менә ачык, туры әйтегез!.. – диде дә урыныннан кузгалды, бер ачулы дошман, бер якын ата төсенә кереп, идән буенча йөри-йөри, тоткынны мең төрле сорау туфаны астына күмде. Егетнең бу сораулардан башы кабарды, акылы томаланды.

Башта, кечкенә әйбер итеп, ул көнне театрда, мөселманнарның Думага сайлау хәзерлеге турында ясалган җыелышларында җәнҗал куптарган исерек Абдулны телгә алды:

– Кем ул, аны яшьләр юри керткәнме, әллә чыннан исерекме? – ди.

Баязид рәхәтләнеп көлде, исерек булса кирәк, аны кем юри кертеп маташсын? Жандарм, моңа тукталмый, Гәүһәргә күчте, бозык, мыскыл көлү белән:

– Менә бит, үзләре социалисткалар, үзләре ир-хатын уртак булсын, диләр. Әмма менә Булат өчен ул Нина белән Гәүһәр ничек әрләшәләр? – дип, мәсхәрәгә алды.

Баязид карый моңа гаҗәпләнеп куйды. Ул шулар арасында эш-йомыш үтәп кайнаса да, ике кыз арасында нинди бәрелеш булганын ишетмәгән иде. Белмим, ишетмәдем, дип кенә үтәргә теләп карады. Ләкин жандарм карт яңадан мәсхәрәләп көлде:

– Алаймы? Ә менә безгә барын китереп сөйләделәр. Тентү вакытында Гәүһәрнең кулыннан Булатка язган ачу хаты алынды ич. Ул гына түгел, әле Нинаның Коля белән торуын Ширинскаядан ишеткәч, бу, Гәүһәрнең театрдан Булатка язган хаты да бик кызыклы. Менә күрәсез ич, безгә аларның бары да билгеле. Сез миңа ялган сөйләргә уйламагыз. Мин сезне бер сүздә үк тотармын...

Тоткын охранканың яшерен агентлары була икән дип белә иде. Ләкин бу дәрәҗәдә тырнак астындагы керләргә, ике кызның көнләшеп талашуларына чаклы җентекләп баруларын уйлый алмый иде. Шулай да жандармның сорауларына аз җавап белән үтәргә тырышты. Кадыйр байны ташлап чыккан унике приказчик вакыйгасы гәзитләрдә үк бар иде. Аны яшермәде, тәмләп, майлап сөйләп бирде, хәзер аңа каршы бойкот бара, ул үзе астыртын, «сораганнарын бирәм, керсеннәр кире», дип, Фәхригә илче йөрткәненәчә әйтеп ташлады. Монда Баязид өчен авыр бер момент: нәрсә турында сөйләргә ярамый, нәрсә турында ярый икәнен тиз генә өзеп аера алмавы булды, шуңа күрә ул тик һәммәгә билгеле әйберләрне генә сөйләп, азмы-күпме яшереннәрен тотып кала барды.

Карт жандарм йөреп арыды булса кирәк, яңадан креслога утырды:

– Җә, бик арыдым инде. Сезне дә ялыктырдым. Тагы бер-ике генә сүз: аннан җибәрәм, – дип, батырып тоткынның күзенә карады, бик гади сорады: – Нигә әле бу кызыл татар яшьләре үзләренең гәзитләрен һаман чыгара алмыйлар?.. Булатлар белән Госманнар манифестның икенче көнендә үк керешкәннәр иде... Партияләреннән мең сум акча да вәгъдә иткәннәр ич... Әллә бу вәгъдә сүздә генә калганмы? Теге Урманов, Мансуровларга да бит ике җүләр яшь татар бае күпмедер акча тыкмакчы, ди. Шулай да гәзитләре күренми, әллә үзара тыныша алмыйлармы? Булат бит ул көнне дә эшчеләр түгәрәгендә күкрәк киереп кычкырган: жандарм безнең телне кисмәкче була, юк, кулыннан килмәс, бер җирдә тыйсалар, без ун җирдә бәреп чыгарбыз, дип мактанып кычкырган... Шулай түгелме?

Тоткын ни дияргә белмәде, ул бик озын колактан гына Булатлар үзләренә гәзит чыгармакчылар икән дип ишетеп калган иде. Ләкин жандармга ул хакта ачык җавап бирергә кыенсынды.

– Белмим, ишетмәдем, – дип кичерде. Жандарм, күзләрен алмый, моның каршына килде:

– Ярый. Әмма шәкерт бунты турында нәрсә әйтәсез? Аларны кем котырта? Анда да шул Булатлар, Госман Азаматовлар идән астыннан ут йөртәме?.. Сез эчендә кайныйсыз, туры әйтегез! – диде.

Баязид бик артык яшеренмәде, шәкерт хәрәкәтен сөйләп бирде, ләкин бөтен кузгалышны тик муллага, иске схоластикага каршы сугыш итеп күрсәтергә тырышты, сәяси кызыл көрәш фикерләре турында бернәрсә дә әйтмәде.

Моңарчы сабыр килгән жандарм сикереп торды, ачу белән кычкырды:

– Ник ялганлыйсыз?! Менә миндә яшерен шәкерт гәзитләре, менә тәрҗемәләре! – дип, портфеленнән бер кочак кәгазь чыгарды. – Менә бу нәрсә? «Алласын, патшасын, мулласын – барын бер җепкә бәйләп атарга» чакырып шигырь басу – бу кызыл фикер түгелмени?.. Мәдрәсәи исламия эчендә бүген-иртәгә калкырга торган бунттан сезнең хәбәр юкмыни? Сезнең иптәшегез Җиһангир бунтның башында тора ич! Ярый, ярый, аны да ташлыйк! Менә сез үзегез катнашкан шәкерт оешмасы «Фидаиләр» нәрсә? Бу да шул «Аллага, муллага, патшага берьюлы сугышка чыга» торган кызыл шәкертләр түгелмени?.. Мин сезне яшь итеп, үз итеп карадым... сез яшереп маташасыз... Кызыллар кая бара?.. Алар Алланы, динне, Инҗил, Коръәнне таптыйлар. Дәүләтне, гаиләне, милекне җимерәләр. Ир-хатынны уртак итәләр. «Алласын, мулласын, патшасын бер баганага бәйләп асмак булалар». Шуның өчен партия төзиләр... Шуның өчен яшерен типография ачалар, халык эченә коткы тараталар, халыкны буржуа дип, пролетар дип аералар... Шуның өчен яшерен корал җыялар, коралллы күтәрелешкә чакыралар – болар

дөньяны кан дәрьясына әйләндермәкчеләр... Болар бары да азган-тузган жидлар эше, әмма сезгә ни калган? Мин мөселманны яратам. Алар яхшы халык, бердәм халык. Алар моңарчы: «Әүвәл – Алла, икенче – патша!» дип ышандылар. Инде менә шул Булатлар кебек азган-тузган кызыл малайлар шайкасы яхшы күңелле, патшаны сөюче, динле, дәүләтле мөселман халкын юлдан яздырырга азапланалар... Сез бала-чага шуларның кызыл сүзләренә ышанасыз! Шәкерт бунты дип, «Фидаиләр» дип дөнья бозасыз... Сезгә ни калган?

Бу ачулы жандарм ташкыны тоткын Баязидка ныклык бирде. Аның эш-көрәш юлы карт полковник сүзләре аркылы тагы да тулырак ачылып киткәндәй булды. Ул үзен ачык, кискен рәвештә дошман кулына әсир төшкән сугышчы, каһарман солдат кебек тойды; шул аңа яңа көч, яңа ышаныч бирде, ул бик усал тавыш белән жандармның өстенә: «Нигә мине болай газаплыйсыз? Вак сүзгә алданырга мин малаймы? Әйе, мин: «Алласын, мулласын, патшасын – барын бер баганага бәйләп атарга кирәк!» дигән фикердәмен... Җитәр. Мин менә шул. Газапламагыз, теләсәгез, атыгыз, мин әзер!» – дип кычкырырга дәртләнеп, канатланып куйды. Ләкин тыелды, шул дүрт-биш сәгать сузылган сорау газаплары эчендә егет берничә еллык үсте. Инде үзен чыннан да Аллага, муллага, патшага, капиталга каршы сугышчы армиянең ныклы, бик ныклы тимер солдаты итеп тойды... Әгәр жандарм тагы йомшак күңелле ана кебек сөйләнә башласа, «Җитәр, мине алдый алмассың!» – дип кычкырырга исәпләп куйды.

Ләкин үзенең утыз еллык хезмәтендә мондый күп хәлне кичергән карт жандарм Герасимов тоткынның психологиясендәге бу кискен үзгәреш моментын шунда ук сизде дә кыңгырау чылтыратты, аннан каравыл керде, Баязидны кире алып чыктылар. Бер янтык бүлмәгә кертеп, кулын, аягын, бармакларын, әллә ничә яктан йөзен, буен фоторәсемгә алдылар да яңадан шул сигезенче бүлмәгә китереп яптылар. Тимер ишек өстеннән тагын зур йозак шалтырап бикләнде.

## XVIII
## СТЕНА АРКЫЛЫ

Тар, биек, озын таш камера. Шуның эчендә ялгыз Баязид бертуктаусыз ишектән түргә таба, нидер уйланып, ашыгыч, кызу адымнар белән йөреп тора. Җәнлекләр йортында зур бер аюның кечкенә, тар тимер читлек эчендә көн-төн туктамый әйләнеп йөреп торуын күреп, кечкенә чагында Баязид үзе бик гаҗәпләнгән иде. Хәзер моны яхшы аңлады. Үзен шулай тойды. Биек, тар бүлмәнең көнбатыш ягында югарыда, кеше башыннан биегрәк җирдә, фонарьдай асылган кебек кечкенә генә тәрәзә. Ул буйлы-аркылы тимер

рәшәткә белән капланган. Шулай да аннан дөньяның тышкы, якты, ирекле күк йөзенең бер чите күренә. Ак болытлар кар кебек, мамык кебек калын-калын укмашып, төньягына таба агалар. Нигә, кая агалар? Аларны кем куа? Ахрысы, җил бардыр, шул куадыр, шуңа күрә ашыгып-ашыгып ага торганнардыр.

Әле һаман да карт полковник жандарм Герасимовның дүрт-биш сәгать буенча туктаусыз сораулар белән газаплау дулкыныннан тынычланып җитә алмаган Баязид, тимер рәшәткәле тәрәзәгә карап, менә шулай уйлана да тагы йөрергә тотына. Аның күз алдында: уртага өстәл куелган зур кабинет, стенада Николай патша, аның бер ягында хатыны, икенче ягында кызлары. Болар астында, тирән креслога чумып, карт жандарм полковник Герасимов утыра. Аның аягында ревматизм. Ул ыңгырашып куя. Йөзендә арыганлык, күзләрендә бер тынычлык, бер ут уйный. Ул хәзер генә йомшак күңелле ата үзенең азгын улын кызганып үгетләгән кебек сөйли, тагы шунда ук куркыныч ерткычка әйләнә, бугазыңнан алырга торган палач яки алдындагы корбанын чәйнәргә торган усал лачынга әверелә.

Ярый. Баязид каушап-куркып керсә дә, башын күтәреп, күкрәген киереп чыкты аның яныннан. Юк, алай зыянлы әйбер ычкындырмады, революционер тоткын исемен сатарлык сүз чыгармады бугай... Нәрсә ди бит, Алласын, мулласын, патшасын барын бер баганага бәйләп атарга телиләр алар, сез шул шайкага койрык булып йөрисез, ди. Койрыкмы, түгелме – анда күрелер, әле хәзергә беренче авыр адымнарым яхшы атланды бугай... Минем өчен эшнең шул ягында мәгънә...

Тукта!.. Ни бар? Менә коридорда тимер тавышы. Бик күп аякларның ашыгыч атлап керүләре ишетелә. Тоткын ни барын ачык уйлап җитә алмый, тимер тавышлары белән буталып, күп аяклар тапыр-топыр киләләр дә монның сигезенче камерасының зур йозакларын, тимер ишекләрен шалтыр-шолтыр ачып җибәрәләр. Тар таш камера эче зур итекле, соры шинельле солдатлар белән тула. Болар бер сүз әйтмиләр, җавап та сорамыйлар, иң элек тоткынның үзенә ташланалар. Аның чалбар, казаки кесәләрен актаралар, бот араларын, оят җирләрен бөтенләй оятсыз рәвештә кат-кат капшыйлар, аягындагы ботинкасын салдырып, бармак араларын җентеклиләр, ботинканы шарт-шорт итеп таш идәнгә бәрәләр, олтаннарын, үкчәләрен каерырга азапланалар. Берсе колак тишекләрен актара, борын эчләрен күтәртеп, авызын, уртын, теш араларын каерып-каерып карый да: «Юк, бернәрсә юк!» – дип, идән уртасына басып, багана кебек туктый. Башкалары Баязидның яткан тимер караватын, мендәрен, нечкә салам матрасын актаралар, юеш, черек почмак янына, ташка кертеп ясалган шүрлектәге икмәкне кискәлиләр; юк, бернәрсә дә юк; бары шуны табалар: зинданның авыр, озын төннәрендә,

ялгызы эшсезлектән ничек вакытны үтерергә белми аптыраган минутларда, Баязид ашарга бирелә торган чи икмәкләрдән шахмат фигуралары ясаган, ялгызы уйнар өчен кесә кулъяулыгын күмер белән сызгалап шакмаклаган иде. Башка әйбер чыкмый, менә шуңа бик зур җинаять итеп ябышалар.

– Бу ни эш? Хәзинә икмәген болай итәргә ярыймы? – дип, берсе тоткынның өстенә акырып килә.

Болай сүзсез-нисез кереп басуларына да, базарда хайван саткан кебек оят җирләрне, танау, колак тишекләрен казуларына да Баязидның җаны хурланган, әрнегән иде. Соры шинель акырып өстенә ташлана башлагач, Баязидның каны кызды, күз алды томаланып китте: ул үзен тәхкыйрь иткән[1] бу тентүчеләргә каршы сугыш белән ташлана язып калды, ләкин зур көчлек белән тыелды.

Болар, бик зур эш эшләгән кебек:

– Икмәк белән болай шаяру не полагается... Җәза шул: син иртәгә бер тәүлек икмәксез калырсың! – дип, чыгып киттеләр.

Тоткынның моңа исе китмәде: «Икмәк бирмиләр икән, бирмәсеннәр. Кеше бер көн ашамаудан үлми! Ләкин ничек аңларга? Ниндидер тупас хайваннар аңсыздан басып керәләр дә тәхкыйрьләп чыгып китәләр, мин нәрсә – базарга сатарга чыгарылган сыермыни, мине алай капшарга?!.»

Егет кан, нерва кызуы астында тагын тар, биек, озын, ярым караңгы таш камера буйлап ялгызы ашыгыч-ашыгыч йөрергә керешә. Чү!.. Күрше бүлмәдән чиертәләр. Тоткын тимер ишеккә таба барып колагын сала да, кире шул чиертү тавышы ишетелгән стенага килеп, тыңлый башлый. Ахры, бүлгәннәрдер: берничә генә чиертә дә киселә... Тагын бер-ике чиертә, тагы киселә.... Тагы бик ашыгыч чиертергә тотыналар.

Баязид аннан: «Бик зур вакыйгалар...» – дигәнен аңлап кала. Шуның белән тагы киселә, тагы берничә сүзне кыенлык белән аерып ала: «Петербург Эшче Депутатлары Советыннан килгән Разия...»

Ләкин ул арада ачкычның йозак эчендә челдерәп борылганы ишетелә, тоткын стенадан сикереп качканчы зур тимер ишек шалтырап ачыла, анда үзенең зур фигурасы белән бусагада надзиратель Иванов тора. Кан баскан күзе белән батырып карый:

– Сафаров, төзәнергә! – ди.

Баязид ишек төбендә тынчып, сасып утырган пычрак парашаны җирәнә-җирәнә ике кулы белән күтәреп ала да коридорга чыга. Тар, озын, ярым караңгы коридорның төньяк башында бәдрәф бар. Баязид кайнаган нерва, кызган баш белән ашыгып барды да, ялгышып, парашаны су кранына

---

[1] *Тәхкыйрь иткән* – мыскыл иткән.

якын тидереп куйды. Тоткыннан бер минут күзен алмый каравыллап килгән надзирательнең ачудан йөзе бүртенеп китә:

– Ах, син – татарчонок гололобый! Мин сиңа ничә әйттем: анда куярга ярамый дип. Син чукракмы? Син мондагы тәртипне җимерергә барасыңмы? – дип, тоткынның өстенә акырды.

Баязидның каны башын, миен каплады, үзенә хуҗалыгын югалтып җибәрде:

– Ник акырасың? Җүнләп әйтсәң, булмыймы?.. Мин сиңа хайванмы?.. – дип каршы омтылды.

Ике арада тавыш-талаш күтәрелде; эшнең нәрсәдә икәнен сизенү белән, коридорның ябык камераларында эчкә бикләнгән башка күп сәяси тоткыннар, ишек дөбердәтеп, кычкырып, протест итәргә керештеләр. Зур гауга башланды. Надзиратель ачу белән акырынды:

– Мин үз эшемне беләм! Молчать, сволочьлар! Бунт чыгарырга итәсезме?.. Мин начальникка жалоба белән барам!..

Шул тавыш эчендә күрше тугызынчы камерадагы яһүд егете, сәяси тоткын, үзенең милли акценты белән яман кычкырып, ишекне дөбердәтә башлады:

– Тоткыннар белән талашырга беләсең! Мине һаман бәдрәфкә чыгармыйсың! Ач, тиз, минем эшем килеп терәлде! – дип, каты бәйләнде.

Надзиратель бу яһүд тоткынга җан дошманы иде. Аңардан ничек үч алырга җай белми йөри иде. Сылтау чыкканына дәртләнеп үк китте. Баязидны бөтенләй онытып, моңа ташланды:

– Ах, син – жидовская морда[1]! Син бер үзең бунт чыгарасыңмы монда! – дип, ата-анасы, бабасы, Тәүраты [22*], дине, пәйгамбәре белән сүгәргә тотынды.

Башка камералардан тагын яман ишек дөбердәтергә керештеләр. Бөтен коридор Ивановка каршы җәнҗал, шау-шу, гауга белән тула, ләкин ул башкаларны бер якка ташлый да үзенең бөтен ачуын, дошманлыгын яһүдкә төбәп сүгенә. Шунда ук зиндан башлыгына хәбәр ителә, аның ярдәмчесе яшь офицер Петров килә. Надзиратель Иванов Баязидны да, башкаларны да бер якта калдыра:

– Ваше высокоблагородие... менә бер тоткын тәртип боза, бунт чыгара... – дип, озын, буталчык ялган әләк бирә.

Яһүд тоткыны Ицковичны биш көнгә карцерга илтеп ябалар, шуның белән надзирательнең ачуы кайта, ул үзе, ахырдан шаярып килеп, кечкенә тәрәзәне ача да карлыккан тавыш белән, бераз елмаеп, Баязидка әйтә:

---

[1] *Жидовская морда* – башка халыклар яһүдләрне җидлар дип атыйлар.

– Ну, Сафаров! Бәхетең! Сине теге жид коткарды! – ди.

Баязид моның сүзен җүнләп аңламады, тик тизрәк ишектән китүен теләде Чөнки күрше камерадан чиерткән тоткын иптәш гадәттән тыш зур вакыйгалар турында хәбәр бирә башлаган иде.

Надзиратель Иванов сүзен әйтте дә ишекнең кечкенә капкачын шалтыратып япты. Баязид аяк тавышыннан аның бәдрәф башына таба атлап югалганын сизенде, стенага ике тапкыр чиертте. Бу: «Мин тыңлыйм!» – дигән сүз иде. Ләкин нидер комачаулады бугай: тегеннән ничектер башламый тордылар. Шул арада Баязид бу стена аркылы сөйләшер өчен ясалган әлифба тәртибе кәгазен яшереп алып карарга тотынды.

Зиндан ишегенә каушабрак аяк атлаган Баязид электән үк инде камералар арасында стена чиертеп аңлашу, сөйләшү барлыгын ишеткән иде. Ләкин моның тәртибен, рәвешен белми иде. Ябылган кичтә үк аңа ике як күршесе дә чиертә башладылар.

Баязид җавап бирә алмады, үзенең бу наданлыгына әрнеде, хурланды; бәлки, бик күп кирәкле әйберләрдән шул белмәвем аркасында мәхрүм калам булыр, дип көенде. Әмма кайдан, кемнән өйрәнәсең? Аны ялгызын бер камерага яптылар. Ашарга, эчәргә шунда, ишектәге кечкенә капкачны . ачып кына бирәләр. Көнгә ярты сәгать зинданның таш коймалар белән әйләндерелгән тар йортына йөрергә чыгаралар чыгаруын. Анда да каравыл белән чыгасың, каравыл күзе астында йөрисең, каравыл белән керәсең. Бер кешегә очрап, беркемгә бер сүз дә әйтә дә алмыйсың. Бу хәлдә ул әлифба тәртибен кайдан, ничек белергә мөмкин? Атнадан артык бер заманны Баязид шулай ялгызлык газабы эчендә үткәрде. Бу зинданда барысы өч зур корпус бар. Шуларның берсендә уголовныйлар тулы. Бу яңа, кызыл кирпеч корпусның һәр ике катлавында тик сәясиләр генә. Сәяси тоткыннарга зинданның кухнясеннән аш-чәй ташу эшенә уголовныйлар җигеләләр. Бу коридорга Бессарабиядән килеп эләккән бер кечкенә карак молдаван хезмәт итә. Яшь, чибәр егет. Ләкин бер сүз дә русча белми. Әллә юри белмәмешкә салына. Баязид аңа берничә тапкыр, надзиратель карап тормаган чактарак, ишекнең кечкенә капкачы аркылы аш-чәй биргән чакта, русча сүз әйтеп караган иде. Карак молдаван җавап кайтармады, күгелҗем күзен нурландырып көлде дә сары чәчле кечкенә башын селекте: белмим, аңламыйм, ди булса кирәк. Ләкин бу телсезлек киртә була алмады, тоткын белән карак тиз дуслаштылар. Көлеп, елмаеп, бер-берсенә дуслык аңлата торган булдылар. Менә бервакыт Баязид, һәммәсе бер-беренә ошаган бу зиндан көннәрен ничек үткәрергә белмичә, эшсезлектән аптырап, бүлмәнең бер башыннан икенче башына йөргәндә, тимер ишекнең уртасындагы кечкенә бүрек зурлыгы капкачы ачылып китте, аннан иң элек кечкенә тимер

савыт белән кәбестәле шулпа һәм карабодай ярмасыннан пешерелгән әче ботка сузылды, шулар артыннан карак дустының яшь, чибәр йөзе күренде. Ул бүген башка көннәрдәгедән дә дусрак булып елмая. Йөзендә шатлык, күзендә көлү ялтырый. Шулай бөтен йөзе белән ишек капкачына тыгылды да телен сузды, аның астында дүрткә бөкләп салынган кечкенә ак кәгазь кисәге бар. Тоткын тиз генә алды да капкачны япты, стенага кертеп ясалган тимер өстәлгә кәбестә шулпасы белән карабодай боткасын куйды да, ишеккә арты белән борылып, йөзе белән аш өстенә капланды. Каушап, калтырап, кәгазьне ачарга әзерләнде. Ул моны Җиһангирдән хаттыр, Җиһангир хат-хәбәр язгандыр дип уйлады. Ләкин дүрткел кечкенә кәгазьне ачкач, аптырап калды. Хат юк, ләкин нидер бар... Бар! Бар! Ул моны гомерендә күргәне юк иде, күзе төшүгә йөрәге сизенде: шик юк, бу шул. Шул әлифба. Шул! Шул!

Аның кулы калтырады, йөрәге суга башлады. Бер торып, бер утырып, кырык тапкыр карады. Аннан соң гына аңлап алды. Ул кәгазьдә менә шундый әлифба бирелгән иде:

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | а | б | в | г | д |
| 2 | е | ж | з | и | к |
| 3 | л | м | н | о | п |
| 4 | р | с | т | у | ф |
| 5 | х | ц | ч | ш | щ |
| 6 | э | ю | я | | |

Бу әлифбаны алган, аңлаган сәгать Баязид өчен үз гомеренең иң зур шатлыклы минутларыннан булды. Ул кәбестәле шулпаны, карабодай боткасын онытты – боларга кул да тидермәде. Шул өстәлгә капланган килеш өйрәнергә тотынды. Ул моңарчы ике яклап чиерткән иптәшләреннән сизә иде. Алар тик коры шакылдатмыйлар, берничә чиертүне аерып-аерып туктаталар. Аз гына туктаталар. Дөресрәге, туктатмыйлар, тынышлар ясыйлар, ул да түгел, ничектер шулай әз-әз генә сулыш алган кебек булыбрак чиертәләр.

Кеше ярдәме кирәкмәде, тоткынның зирәклеге үзе өйрәтте. Шунда ук үзалдына өстәлгә сугып, үзе белән русча сөйләшә башлады. Ярый. Бер сүз әйтәм: «Ты кто?». Менә «т» хәрефе дүртенче рәттә өченче хәреф икән. Ярый. Элек дүртен сугам. Бусы рәтне күрсәтә. Ярый, дүртенче рәттә өченче хәреф икән, – өчне сугам. Дүрт белән өч арасында әз генә, нәни генә тыныш була. Шулай чиертсәң, теге камерадагы иптәшең синең әйтәчәк сүзеңнең беренче хәрефе «т» икәнен сизеп ала. Инде «ы»га килә. Ул юк. Бу ни хәл? Ярый, ярый. Бу бит кыскартылган әлифба, ошаш ике авазга бер хәреф йөри икән, «ы» урынына «и» икән. Бу икенче рәттә, дүртенче хәреф. Элек ике чиерт. Бик

аз гына тыныш, аннан дүрт чиерт. Менә синең иптәшең «и» хәрефен аңлый: «ти» булып чыга. Барыбер. Ярый. «кто»да да шулай. «к» хәрефе икенче рәт, бишенче хәреф. Димәк, 2+5 чиертәсең, 4 + 3 = «т», «о» хәрефе өченче рәт, дүртенче хәреф – димәк, 3+4 чиертәсең. Шулай итеп чиертә торгач, 4 + 3, 2 + 4, 2 + 5, 4 + 3, 3 + 4 = «ты кто» булып, иптәшеңнең миенә, йөрәгенә барып керә.

Баязид бу авыр серне эзли-эзли тирләп бетте, арыды, ләкин үзе сизмәде. Беренче сүзне, чирек сәгатькә якын азапланып, өстәлгә чиертте – дөрес килеп басты. Егет, әйтерсең, зур каланы сугышып алды инде, шулай шатланып, канатланып, сикереп торды. Шунда ук күрше як стенага таба иелеп, чиертергә исәпләде. Ләкин ишекнең кечкенә капкачы ачылды, аннан елмаеп, карак молдаван күренде. Аңладыңмы дип, башын селкеп, ике кат сорады. Баязидның авызы колагынача ерылган, йөзе көлә, күзендә ут уйный иде. Чыдамады, теге баштан надзиратель Ивановның калын сүгенү тавышы килүгә карамастан, карак дустының кулын тартып алып, кат-кат кысты. Молдаван, бер кашык та кимемәгән ашын күреп, гаҗәп белән, шелтә белән карады:

– Ник ашамыйсың? – дип, ымлап сорады.

Баязид, баскан җирендә чыдаша алмый, сикереп биеде генә. Кул белән: «Ал, ал, минем тамак ашамый да тук!» – дигәнне шатланып аңлатты.

Шулай итеп, Баязид зиндан әлифбасын өйрәнде. Башта ул кайсы хәреф өчен ничә чиертергә икән дип, кәгазьгә карый иде. Тиз арада күңелдән белеп җитте. Бара торгач, бармаклар үзеннән-үзе, механик рәвештә кирәк санны чиертә торган булдылар. Аннан соң инде каршы якның чиертүләрен аңлау да җиңелләште. Күрше камерадагы иптәшнең өзек бер җөмләсен Баязид ике-өч хәреф чиерткәч үк алдан аңлап ала. Тегене бүлеп: аңладым, аңладым, дигән мәгънә белән ике тапкыр бу яктан чиертеп куя. Теге иптәш икенче җөмләгә күчә. Бара торгач, тоткыннар шул чаклы остаралар: икесе ике камерадан торып чиертешкәндә, гади сөйләшеп утырган кебек тиз аңлаша башлыйлар.

Бу чиертешү һөнәре Баязид өчен зур бер азатлык булып китте. Ул, әйтерсең, таш стеналарны, тимер ишекләрне, мылтыклы тыгыз каравылны бер кул селтәү белән җимереп, теләгән вакытта чыгып китә алырлык хәлгә килде. Үзе теләгән нәрсәне күршеләр белән чиертешеп сөйләшергә өйрәнү – аңа шул чаклы ирек биргәндәй булды. Ләкин моның арты яман иде, чиертешеп сөйләшкән өчен, бер күрсәләр, – шелтә бирәләр, икенче эләксәң, – карцерга, юеш, караңгы, пычрак идәнле, кандалалы бүлмәгә, берничә көнгә коры икмәк белән суга ябып бикилиләр. Шуңа күрә, күрше иптәш кат-кат әйтте:

– Сафаров, син бер дә сакланмыйсың, эләгерсең карцерга! – диде.

Надзиратель Ивановның теге яһүд тоткыны Ицкович вакыйгасы сәбәпле бүленгән чиертешүнең баш сүзе үк Баязид өчен бик тирән интереслы нәрсә иде, саклыкны бер якка куйды да колагын стенага ябыштырды. Тегеннән санап, акрын чиертәләр. Баязид сүзләрне беренче хәрефеннән үк аңлап йота бара: аңладым, дип, ике чиертә тора. Бүген шул чаклы гаҗәп тиз, гаҗәп тулы сөйләштеләр ки, Баязид бөтен бер доклад тыңлаган кебек тулы хәбәр алды. Ләкин ул бу хәбәр тула-зурая барган саен агара барды, калтырап ката барды – сүз киселгәндә, үзен-үзе белми аякка басты, үзалдына уйланып, үзалдына ялгыз сөйләнеп, камераның бер башыннан икенче башына йөри башлады.

## XIX
## ЧУКРАК ӘБИ

Тукта, ничек диде әле... Гәүһәрдә тентү булган, ди. Аңарда ике браунинг, дүрт адрес, өч паспорт яшерелгән булган икән, алар да киткән, ди. Гәрәй Солтан, татар полиграфистлары белән берләшеп, яшерен типография төзеп йөри иде, бу арада шуның белән беренче листовканы басып та чыгарганнар иде, ди. Ул яшерен типография дә җандармнар кулына эләккән, ди. Болар да чүп. Менә бит трагедия кайда: Гәүһәр туташ каяндыр, нинди юл беләндер: «Бу эшләрнең һәммәсе шул кызыл приказчикларның башлыкларыннан берсе саналган Шаһвәлиевтән генә булды, ул миңа гыйшык ачты, мин кире суктым, талаштык, ачудан, көнчелектән һәммәсен охранкага белдергән, шул этне бетерергә кирәк, кая, партия миңа тапшырсын, үзем бетерәм», – дип, җылап әрнеп, Булатка йөгерә. Булат шунда ук үзенең яшеренгән җиреннән өс-башын алмаштырып чыга да, Гәрәй Солтанны эзләп таба да бөтен вакыйгәне сөйләп бирә. Партия комитетына мәсьәлә куярга кирәк, Шаһвәлиевнең эшен тикшерер өчен комиссия төзергә, хөкем чыгартырга кирәк, ди. Кавказлы Гәрәй Солтан дәшми тыңлап тора-тора да, бер сүз әйтмичә, чыгып китә. Берәү белән дә киңәшмичә, итек кунычын зур үткен фин пычагын тыга да Шаһвәлиевнең квартирына бара. Ул өйдә юк. Кайчан кайтыры да мәгълүм түгел. Ләкин Гәрәй көтә. Бер сәгать, ике сәгать, өч сәгать үтә. Теге караңгы төшкәч кенә, мәче кебек сак атлап, куркынган, гаепле йөз белән кайтып керә. Хуҗа катын аңа ишек ачкач ук: «Әллә нинди бер адәм китми көтеп утыра», – дип өлгергән иде, шуннан йөрәгенә курку төшә, бүлмәсендә нindидер ачудан кара коен, ерткычланып утырган Гәрәй Солтановны күргәч, аның каушавы бөтенләй көчәя. Кавказлы, әллә нинди шөбһә астында җавап алган кебек, таштай авыр сүзләрен саный-саныйниләр турындадыр сорашырга керешә. Көтелмәгәндә кинәт мәсхәрә белән елмаеп:

– Син нәрсә, Гәүһәр белән шурый-мурый корасыңмыни? дип, хахылдап

көлеп җибәрә.

Шаһвәлиевнең йөрәге суга, иреннәре дерелди, күзләре томалана башлый. Ул нидер сизенә, эшнең кая барганын аңлап, бер ишеккә, бер тәрәзәгә каранып куя. Берничә минут сүзсез утырган Гәрәй өчен Шаһвәлиевнең менә шул качарга җай эзләгән бүредәй як-якка каранулары бөтен серне ачып ташлыйлар. Ул сизенү белән, икеләнү белән килгән иде, егетнең качарга эзләнүе – аның күңелендәге шикләрен бетерәләр. «Бу – провокатор», – дигән уй аның миенә кисеп керә. Бер секундта канын кайнатып җибәрә. Шаһвәлиев тыштан батыр, эчтән үлек тавыш белән:

– Менә гаҗәп! Минем кем белән шурый-мурый ясавым сиңа ник кирәкте? Әллә син әхлак, тәүфикъ күзәтүче муллалар роленә кердеңме? – дип, артка таба чигенә башлаганда, Гәрәй Солтан сикереп тора да, яман сүгенеп, Шаһвәлиевнең өстенә ыргытыла.

Шаһ мондый хәлгә әзерләнгән иде, кинәт бер якка талпынып, Гәрәйнең беренче селтәнүеннән котыла да тәрәзәгә ташлана. Пыяланы ватып, урамга сикерә, – шунда юк була.

Гәрәй Солтанов пычагын кире итек кунычына тыга да чыгып китә. Ләкин аңарда кискен ышану туа: «Гәүһәрнең шикләнүе, әлбәттә, дөрес. Серләр, әлбәттә, Шаһ аркылы бирелгәннәр. Шаһвәлиев – охранка агенты, провокатор».

Шул авыр хәбәр белән парткомга барса, анда зур вакыйга: бүген партия комитеты җыелырга тиешле бүлмәне бөтен йортны атлы жандармнар камап, әйләндереп алганнар. Урамнан кеше үткәрмиләр. Йорттан һичкемне чыгармыйлар; ялгыш барып кергәннәр шунда тотылып калалар. Гәрәй Солтан ерактан күрү белән эшне сизеп алды, тиз чабып барып, Гәүһәрне эзләп тапты, аны Фәхригә, Галимовка җибәрде; болар аркылы Булатка, аннан бүгенге партком җыелышына катнашырга уйланылган Разия белән Саммерга [23*] хәбәр итү чараларын күрергә йөгерде.

Бу арада шәһәрдә зур эш ташлаулар бара. Моңарчы хәрәкәтнең алдында барган металлистлар гына түгел, хәзер тимерьюлчылар, полиграфистлар, йөкчеләр, телефонистлар, приказчиклар, текстильчеләр дә – һәммәсе революциянең эш ташлаучылар армиясенә тезелделәр. Башта тик хуҗаларына каршы икътисадый теләкләр генә иде. Менә өченче көн инде бөтен хәрәкәт ачык, кискен рәвештә сәяси төс алды. Шәһәр туктаусыз митинглар, демонстрацияләр белән кайнап китте, карагруһлар тарафыннан үтерелгән эшче-большевик Филимоновны күмү уңае белән бөтен шәһәр аякка калыкты, бөтен урамнар кызыл байрак күтәреп мәрхүмне күмәргә барган исәпсез-хисапсыз халык дулкыны, демонстрацияләр ташкыны астында калды. Үзләренең квалификацияләре түбән, сәяси хәзерлекләре аз

булган һәм күбе авылдан өзелмәгән татар эшчеләре башта парткомны бераз борчуга салганнар иде: болар читтә кала күрмәсен, болар эш ташлау хәрәкәтендә штрейкбрехерлек [24*] ролен үтәмәсеннәр дигән курку бар, шуңа күрә түгәрәкләрдә дә, массовкаларда да, һәрнәрсәдән элек, татар эшчеләренә бик нык эш, көч бирү ягы беренче планга куелган иде. Булатлар кырыкка ярылалар. Митингтан түгәрәккә, түгәрәктән заводка, аннан массовкага чабалар.

Бу көннәрдә Гәрәй заводтан кайтмады. Әле менә алты ай гына элек курка-курка түгәрәккә килгән Галимов хәзер үзе татар эшчеләре арасында беренче актив булып җитеште. Исрафилов белән Вахитовлар – болар инде татар эшче массасы эчендә парткомның терәкләре иде. Шулай да борчылу бар иде. Бу соңгы хәрәкәтләр куркуның урынлы булып бетмәвен күрсәттеләр: татар эшчеләре киң масса кузгалышларында, бөтен сыйныфның алдында торган зур көрәшләрдә рус эшче иптәшләреннән һичбер турыда аерылмадылар. Яланга, урманга чыгып, яшерен массовкалар вакытында да, эш ташлауларда, митинг, демонстрацияләрдә полиция белән, гаскәр белән бәрелеш чакларында да рус эшче иптәшләр белән кулга-кул биреп, беренче сафта бардылар, бергә көрәштеләр, бергә сугыштылар. Ләкин киң масса хәрәкәтендә бергә көрәш алып барган татар эшчеләре үз араларында актив үстерүдә рус эшче иптәшләреннән бик нык артка калдылар. Булат бу мәсьәләне берничә тапкыр парткомга куйды. Сәбәбен эзләде. Ләкин тәкъдим ителгән эш методлары, үзләренең практик нәтиҗәләре буенча, канәгатьләндермәделәр. Большевик үзәк вәкилләреннән Разияның да, Саммерның да бергә туры килүеннән файдаланып, Булат парткомның бу җыелышына югарыгы мәсьәләне тагы куймакчы, әгәр үзәктән килгән иптәшләр мөмкин тапсалар, шул татар эшче массасының киң сыйнфый масса фронтында, рус иптәшләре белән дошманга каршы кулга-кул нык көрәшкәннәре хәлдә, үз эчләреннән актив үстерүдә канәгатьләнерлек дәрәҗәгә килә алмавын ачык формулаларга салып, алар аркылы партия Үзәк Комитетына доклад рәвешендә җибәрү ягын кузгатмакчы иде. Шуңа күрә парткомның бүгенге җыелышы Булат өчен дә, Гәрәй өчен дә аеруча үткен бер мәсьәлә булып көтелгән иде.

Бөтен тармаклары белән түгел, шулай да кемнәр катнашачагы чама белән аңлатылып, парткомның бу булачак җыелышы бер-берен белмәгән ике агент тарафыннан охранкага да белдерелгән иде. Соңгы көннәрдә үз кабинетын оператив штабка әйләндергән жандарм полковник Герасимов бу җыелышка аерым кыйммәт бирде. Чөнки Разия белән Саммерның большевик үзәгеннән кайчан, ничек, нинди эшләр өчен монда җибәрелүләре Петербургтан, департамент аркылы ашыгыч, яшерен шифрлы № 02148

телеграм буенча аңа хәбәр бирелгән, ликвидация хәзерлегендә бу беренче урынга куелган иде. Департамент, үзенең Герасимовка бирелгән яшерен, ашыгыч, шифрлы телеграмында Разия белән Саммерның өсләренә үзәк тарафыннан йөкләтелгән эшләрне санаганда, беренче итеп мондагы эш ташлауларга җитәкчелекне әйтә. Эш ташлау хәрәкәтен кораллы күтәрелешкә әйләндерү планы бирелгән. Моның өчен анда яшерен корал склады, корал – бомба, динамит фабрикасы бар. Шунда берничә эшче эшли. Арада берсе татар булырга тиеш. Элек тә түгел, соңга да калмаска, үз вакытында кешеләре белән эләктерегез, ди. Саммер менә шул яшерен склад эше белән китте, аны бер минут күздән яздырмый, эзәрләп торыгыз... ди.

Департаментның бу инструкциясе Герасимовка яңа әйбер булмады. Чөнки аңа Разия белән Саммерның монда кайчан, нинди ялган исем белән килеп, кайда төшүләре билгеле иде, ләкин шул яшерен фабрика-склад мәсьәләсе турында ун мең сорап язган яшерен, аноним хатның очына һаман чыга алмаган иде. Бүген партком җыелышын бөтен кешеләре: Разиялар, Булатлар, Саммерлар, Колялар (Николай Кадомцев) һәм башкалар белән берьюлы басып ала алса, яшереп фабрика-складның да берәр җебе кулга эләгер – әгәр эләкмәсә, ун мең белән теге аноним хат иясен сатып алырга туры килер дип уйлый иде.

Ике тәүлек яңгыр яуды. Һава гадәттән тыш юеш иде. Карт жандарм полковникның аягындагы ревматизм, туктамый сызлап, сыкрады. Тентүләргә ул үзе бик сирәк бара иде. Бу гадәтне дә җимерде, юеш һавада карт аякларының сызлауларын да онытты. Сөекле кара атны иярләтте, зур отряд алды, кирәкле урынга, гаскәри штабларга алдан хәбәр итеп куйды да үзенең составы, активы белән, большевизм үзәк вәкилләре белән тулы рәвештә җыелып җитәргә тиешле булган минутта партком бүлмәсен-йортын үзе командасында атлы жандармнар белән килеп басты. Йортны әйләндереп алдылар. Мондый вакыт бомба белән, корал белән каршы тору гадәтен белә иде, акрынлап, саклык белән, алдан филерларны җибәреп, корулы маузердан кулын алмый, өйнең эченә атылды. Хуҗалар котлары очып үлә яздылар. Алардан сорамыйча ук – партком җыелышы булачак бүлмәгә каты басып, кыю атлап, кораллы жандармнары белән килеп керде – керсә, ишек ачып, бусаганы атлау белән, баскан җирендә аптырап катып калды: бүлмәдә партком да юк, бер ир заты да юк. Разия да юк, Саммер да юк, Булат та юк, Николай Кадомцев та юк. Районнардан килергә тиешле дүрт эшче организатор да юк. Прокламацияләрне, листовкаларны, партия китапларын эшләп язып чыгаручы әдәби группаның кешеләре дә юк. Берсе дә, бернәрсә дә юк, бары – кулына тәсбих тоткан бер татар карчыгы бар. Ул әллә юри кыйлана, әллә чыннан шулай: һичбер нәрсә ишетми, дөнья шаулатып

кычкыргач, ишеткән кебек булды, ләкин бер сүз русча белми, низнай, дип, тик тора.

Герасимов бу көтелмәгән хурлыктан колакларынача кызарды, аннан ачу белән кара көйде, охранканы, начальнигын, барлык агентлары белән эченнән эт итеп сүкте. Ләкин бу дәрәҗәдә комга утырып калуына һаман ышана алмый иде. Бүлмәнең һәммә әйберен актарып, тентү ясатты. Булатның шул татар эшчеләре арасында масса көрәше белән актив үстерү турындагы сүзләре сызгаланган бармак бите чаклы кечкенә кәгазьдән башка бер әйбер дә чыкмады. Башка берәр якка яшерен ишек юкмы дип, стеналарны үз кулы белән капшады, идәнне ачтырып, аның астындагы базны, балчыкны актартты. Түшәмгә кылыч белән төрткәләде. Монда һичнәрсә табылмагач, бөтен өйне, йортны, утын сарайларын, очырмаларны[1] җентекләп тикшерде. Һичкайда, һичнәрсә чыкмады. Арып-талып бетте. Аягындагы ревматизмы котырып сызлый башлады. Полковник һаман кайта-кайта:

– Болваннар, сволочьлар[2]! Акча әрәм. Һәммәсен эт итеп ярырга кирәк, сволочьларны! – дип, охранканы, аның агентларын сүкте.

Бу тәсбих тоткан татар карчыгына яңадан килеп бәйләнде. Бәлки бу шулай кыйланадыр дип, аның турында йорт хуҗасы руслардан сорашты. Ләкин алар да:

– Чукрак ул, бер сүз дә русча белми, – диделәр.

Бу бүлмә эшче Вахитов исеменә алынган иде. Карчыкны татар бистәсеннән Хәдичә җиңги аркылы эзләтеп, Гәрәй Солтан табып яллаган иде. Ул бу бүлмәдә кем җыела, ниләр эшләнә – һичнәрсә белми дә, ишетми дә иде. Иртә-кич бүлмәне карый, самовар куя, Вахитов белән Исрафиловка аш пешерә – шуннан башкадан хәбәре юк иде. Ләкин Герасимовның охранка агентлары турында сүгенүе бөтенләй хаксыз иде. Алар туры сизенгәннәр: парткомның киңәйтелгән зур җыелышы шунда чыннан да билгеләнгән иде. Анда, үзәк вәкилләреннән башка, әдәби группа кешеләре белән завод-район организаторлары да киләчәк иде. Ләкин бүген иртәдән алып, бу урамда, бу йорт тирәсендә филерларның туктаусыз искәнүләрен Галимов сизеп калды. Аны секретарьга хәбәр итте... Шуннан Разия бүгенге җыелышның урынын да, вакытын да алмаштырып өлгерде. Килергә тиешле иптәшләрнең һәммәсенә тиз-тиз хәбәр иттеләр. Охранка менә бу соңгы моментлар турында хәбәр алып өлгерә алмады. Күп тәҗрибәле карт жандармның планын җимергән нәрсә менә шуннан килеп чыкты.

Яңадан үзенең кабинет-штабына кайтып, бу җимерелүнең сәбәбен

---

[1] *Очырма* – чома.
[2] *Сволочьлар* – кабәхәтләр, әтрәк-әләмнәр.

тикшерергә тотынган минутта кинәт ашыгыч телефон шалтыраттылар. Ул башта ишетә алмый, ишеткәч, ачык аңлап җитә алмый йөдәп бетте, яңадан каты кабатладылар:

– Завод капка төбендә эштән чыккан эшчеләрне көчләп туктаталар. Ничә җирдә кызыл байрак. Ораторлар бу хәзерге эш ташлау хәрәкәтен кораллы күтәрелешкә әйләндерергә чакыралар. Атаманнары һәммәсе дә мондалар...

Күп көрәшне кичергән карт, каты бәгырьле полковникның тимерләнеп каткан миен ут алган шикелле булды. Күз алдына бөтен дөньяны ялкын каплагандай күренеп китте. Ләкин бу бер секунд иде. Шул утлы, ачулы секунд эчендә аның башында кискен уй, тулы план туды. Манифест көннәреннән алып хәзерге минуткача сузылып килгән куркыныч икеләнү тактикасына да ул, югарыдан боерык булганын көтмичә, тик үз йөрәгенең кушуы белән чик куярга тиеш тапты, шуның баш планын ачулы, каһәрле ут эчендә яшен тизлеге белән эшләп күз алдына китерде дә, алтмыш яшен бәйрәм итәргә хәзерләнгән карт кебек түгел, егерме сигез яшьлек фронтчы офицер чагындагы кебек җитез егетлек белән яңадан кара атка сикереп менде, көрәш-сугыш өчен түгел, изәр, бетерер, юк итәр, аяк астына салып, ат дагасыннан таптатыр өчен эшчеләр бистәсенә – ерактан куе төтен чыгарып, бөтен шәһәрне ниндидер актык сугышка чакырып акырган завод ягына таба зур отряд алып, дөнья җимереп чапты.

## XX
## СӘФӘР КАРТ

Текстильче Галимов квартирында үзенә почмак алып тора торган каравылчы Сәфәр карт бар. Ул ике ел элек, җиреннән аерылгач, калага килде дә, авылдаш эшчеләре аркасында завод каравылларга ялланып, урынлашып калды. Бик каты динле адәм. Патшага тел тидергәнгә, мөфтигә, муллага сүз озатканга каршы тамак бетереп талашырга ярата, Галимов бүлмәсендә сәяси түгәрәкләр үткәргәндә, Булатка һаман бәйләнә, аның сүгенүләрен яратмый, иттифакчыларны, чалмалы, кәләпүшле кадет партиясе дип бәйләнүләренә чын күңелдән рәнҗи иде.

– Җә, егетләр, бу ни эшегез сезнең? Алла да юк, мулла да юк. Патша да юк. Бай да юк. Дин дә юк. Оҗмах, тәмуг та юк. Мөфти дә юк. Урыска ярый, әмма мөселманның үз партиясе булырга да ярамый, бу ни эш бу, егетләр? Сез безнең штанны салдырып, шыр ялангач калдырасыз ич, егетләр! – дип шелтәли торган иде. Ләкин үзе җыелышларны, демонстрацияләрне карарга яратучан иде. Дулкын башланса, илгә ни булса, миңа шул дип, бүреген басып кия дә авылдаш эшчеләреннән калышмый чыга иде.

Капкадан кара болыт булып эшчеләр агыла башлады, заводның чакырулы акыруы буенча бистәнең иске, кечкенә өйләреннән, пычрак урамнарыннан, тар тыкрыкларыннан ашыгып-ашыгып завод капкасына таба йөгергән эшчеләр артыннан хатыннар да, кызлар, карчыклар да, һай-һу кычкырып, уенга сабып, бала-чагалар да атылдылар. Шул дулкын Сәфәр картны да үзенә суырып алды, ул капкага җитү белән Булатка очрады, әллә көлеп, дусланып, әллә начар теләкләнеп, аңа тартылды:

– Кара син аны! Әле шулай һаман сине эләктермәделәрмени? – дип кычкырды.

Булат аңа текәлеп карады, таный алмады: «Юри киенгән берәр шпик түгелме бу карт убыр?» – дип, гадәттәге ышанмаучылык чаткысы аның миеннән йөгерде, ләкин тану белән көлде:

– Ә, Сәфәр бабай, синме? Танымый торам. Менә шулай чыкканың яхшы. Урыс, татар, димә. Барың бер кулдан дошманга каршы сугыш! Шулай бит, Сәфәр бабай?

Булат сүзен бетерә алмады. Гәрәй Солтан боевикларыннан Исрафил килеп чыкты да:

– Ни юк белән вакыт әрәм итәсең, әйдә, Булат, күрмисеңме анда? Бетмәс монда Сәфәр картның әкиятләре! – дип кычкырып җибәрде.

Бу арада заводның йорт эче, корпус буйлары, якын-тирә урамнар, чатлар – һәммәсе әле күбе эш киемендә булган корымлы өс-башлы эшчеләр белән капланып беткән иде инде. Кемдер бу шаулап торган дулкынлы халык диңгезе өстеннән каты тавыш белән русча:

– Иптәшләр, эшчеләр!.. – дип акырып ярып салды. Ләкин сүзләре аңлана алмады, кайдан кем сөйләгәне дә ачык күренә алмады.

Болай ярамый, әлбәттә: ораторларга трибуналар кирәк иде. Коля белән Исрафилов шунда, завод капкасы буенда яткан мичкәләрне шаулатып тәгәрәтә башладылар. Аларга башкалар кушылды, күз ачып күз йомганчы нәкъ капканың авызына ике мичкәне янәшә куйдылар, өченче бер кечкенәсен алар өстенә утырттылар. Шундый ук ашыгыч трибуналар тагын ике урында ясалып өлгергән икән: сүзләре монда ачык аңлашылмый, әмма береннән Разияның каты күкрәк тавышы болай таба яңгырый, икенчесендә Саммср бугай, кулын болгап-болгап, гадәтенчә, бөтен гәүдәсе белән селкенеп сөйләгәне күренә. Завод капка буенарак җыелган эшчеләрнең бик күбе бүрекле, бишмәтле татарлар иде, өч мичкәдән трибуна ясалуга Николай Кадомцев як-ягына каранды да Исрафилга әйтте:

– Кая соң Булат?! Нәрсә көтә? Татарча сөйләргә кирәк монда! – диде.

Зариф ике иптәш ярдәме белән мичкәләр өстенә сикереп менде дә зур, бераз чандыр гәүдәсен туры катырып басты, бераз ачы тамак тавышы белән

халык өстен яңгыратып җибәрде:

– Иптәшләр, революция көрәшенең кискен минутлары килеп җитте. Үзенең октябрь 17 манифесты белән бераз чигенгән дошман хәзер тагын безнең өскә ташлана. Хәзер тагын актык көчен җыеп, жандарлары, полициясе, гаскәре, палачлары белән пролетариатны буа башлый Иптәшләр, бу кискен минутларда элекке кебек эш ташлау, демонстрация ясау юлы белән генә бару җитми, хәзер бердәнбер актык чара – коралланып, дошманга һөҗүм, бөтен Русиядә дошманга каршы кораллы күтәрелешкә чыгу, моның өчен һәммә эшчеләр коралланырга... әзерләнергә...

Булат сүзе шул җиргә җиткәндә, шәһәр ягыннан ниндидер бик күп атлыларның болай таба чабып килүләре күзгә төште. Болар – кораллы жандармнар иде. Күп эшчеләр полковник Герасимовның зур матур кара атының алдан, очкан кебек, бу якка чабуын таныдылар.

Ничә көннәр буенча йокламаудан Исрафиловның нервалары кайнап чыккан чаклары иде. Күзләрен ала алмый, шул атылып килгән кара атның маңлаендагы яра кашкасына текәлеп катты, кобурына тыгылып, ирексез, наганын чыгарды. Ул солдатта төз атучылардан, шуның өчен бүләкләнгән егетләрдән иде. Тукта, бу этне бетерим, дип уйлап, салкын курокка бармагын иплӛп китерә башлады, Герасимовның кокардалы, күк читле фуражкасы да, матур кара атның маңлаенда ялтыраган ап-ак яра кашкасы да – һәр икесе аның пулясын сорап торган, шуның өчен болай таба ашкынып чапкан кебек тоелдылар. Ул менә атам дигәндә, аның янындагы Сәфәр карт, коты очып:

– Җәмәгать! Харап булдык, килеп бастылар ич! – дип, җенләнгәндәй акырырга тотынды, шуның котыруына борылып караган секундта Исрафил атның яра кашкасын да, кокардалы күк читле фуражканы да күзеннән югалтты. Болар, атылып чабып килгән җирдән кинәт борылып, тыкрыктан әйләнделәр дә, икенче як белән урап, дулкынлы халык тулы мәйдан өстенә ярып килеп чыктылар. Полковник зур, калын тавыш белән бөтен бистәне ярып, акырып җибәрә:

– Таралыгыз!.. Таралыгыз!.. Таралыгыз!.. Бер секундтан ут ачарга боерык бирәм! – диде.

Жандармнар шул арада арттан килеп өлгергән казачий эскадрон атлары белән массаның эченә чабып керәләр дә, кычкырып, һай-һулап, таптатып, уңга-сулга камчы кизәнеп, яра башлыйлар. Бала-чага, хатын-кыз чыр-пыр килеп, җылап, акырып-бакырып качарга тотына. Мондый бәрелешләргә өйрәнеп җитмәгән кайбер эшчеләр дә почмакларга, койма артларына посалар, мәйданда зур талаш, кычкырыш-тапташ китә. Алдан ук гражданнар киемендә шул җыелыш эчендә кайнаган филерлар, шпиклар, яшерен жандармнар, буталчык арасыннан җырып, ясалма трибуналарга агылалар,

митингның җитәкчеләрен, ораторларны, алар тирәсендәге алдынгы элементларны тотып, кулларын артка каерып бәйләргә керешәләр. Ләкин халык таралмый, эшчеләр, бигрәк тә боевик отрядлар, тиз арада оешып өлгерәләр, шунда яткан күп мичкәләрне коймага таба тәгәрәтеп-тәгәрәтеп өяләр, капкаларны аударып, китереп сөйиләр дә жандармнарның бирә башлаган залпларыннан ышыкланырга чара эзлиләр, шуннан торып, каршы сугыш башлыйлар.

Бу каты бәрелеш эчендә баш югалткан Сәфәр карт, тилергән тавык кебек, әле ул якка, әле бу якка ташлана:

– Балалар, чүгез, бу ни эш?! Лә хәүлә вә лә куәте илла билләһи газим... Ходаем, үзең сакла мөэмин-мөселманны! – дип, ялангач куллары белән үзенең битен, күзен тирә-ягында очкан пулялардан сакларга – капланырга маташа. Ләкин аның гомер җебе өзелгән сәгать шул икән – инде менә мичкәләр артына кереп яшеренәм, Галимовларның аргы ягына ышыкланам дигәндә ул: «Эһ... эһ... эһ...» – дип өч тапкыр әйтте дә, кинәт аягүрә басып, ике кулын күтәрде һәм шул секундта, тамыры киселгән агач кебек, лап итеп җиргә егылды. Аның якыныңдарак Галимовның хатыны тора иде, картның болай кинәт ауганын күргәч, тирә-якта пулялар бызылдап уйнавына карамыйча, тиз-тиз Сәфәрнең изүен чиште: «Сулышы кысылды бугай», – дип, авызына, йөрәгенә кулын куйды. Менә гаҗәп! Сулышы да килми. Йөрәк сугуы да ишетелми. Һичбер җирендә кан-яра эзе дә юк. Бу ни хәл!.. Хатын бу егылган карт белән күбрәк азапланды бугай, Исрафил аңа кычкырды:

– Ташла шуны! Нәрсә капландың! Күрәсең ич, ничек кысалар!

Хатын ташламады:

– Менә тиле! Таптың сүз! Урамда калдырырга әллә этме ул! Адәм ич! – диде дә, аягыннан өстерәп, корпусларның аргы ягына чыгарды. Тагы ипләп карады. Йөрәк туктаган. Тән суынган. Җан әсәре юк. Ләкин сәбәбе нәрсәдә? Хагын, бик күп эзләгәч кенә, картның баш сөягендә, җилкә чокырыннан аз гына өстә, каралып каткан ике тамчы кан тапты, шул җирнең тиресен каера төшсә, сөякнең тишелеп чатнаганын күрде. Пуля, шуннан кереп, минең эчендә тукталган икән! Хатын шулай уйлады да, картның үлек гәүдәсен аркасына салып, квартирларына алып китте. Ул аларда бер почмак алып тора иде:

– Эт түгел ич, ничек урамда калдырасың!? – дип, кат-кат үзенең теге мәйданнан китүенең сәбәбен көчәйтергә тырышты.

Жандармнар, эскадроннар өстенә шәһәрдән тагын бер рота җәяүле отряд китерделәр. Герасимов командасындагы бу көч сәгать ярым эчендә фронтны җимерә, җиңә алды. Бер казачий яраланды, ике жандармның үлеген таптылар, бер полицейскийның башын таш белән ярдылар. Шул

корбаннарны полковник күпкә санамады: «Ватан өчен, дин-чиркәү өчен, патша өчен!» – дип юанды. Ләкин аның җанын әрнеткән нәрсә шул булды: әллә ничаклы шау-шу, тавыш куптарып, кан түгеп, дүрт эшчене үтереп, кырыклапны ябып та, төп максат булмый калды: Разин белән Саммер тагы ычкынганнар! Департамент әйтер инде: «Җебегән авыз, шундый моментны качырган, карт җүләр!» – дияр. Ләкин полковник ни эшләсен? Ул кулыннан килгәнчә сугыша ич инде!

Николай Кадомцев башкаларга ни булганын аерып белә алмады, аның үзен эләктерделәр дә, кырык эшче белән бергә, участкага китереп яптылар. Анда төн кундыргач, башкалардан аерып, ялгызын охранкага җавапка әйдәделәр. Аннан туры зинданга озаттылар. Аның, тоткыннардан Зоя Горбатова белән электән бәйләнешы бар иде. Ике көн бушка җәфаланды, тик өченче тәүлекнең ахырында гына зинданның хатыннар бүлегенә җеп суза алды. Аңардан ала алган иң кирәк нәрсәсе шул булды, кыз әйтә: «Сезнең коридорда аш-чәй ташый торган молдаван бар. Ул безнеке», – ди.

Тагы ике тәүлек тә үтмәде, аны, ялгыз камерадан чыгарып, почмактан икенче бер камерага – дүрт сәяси тоткын янына бишенче итеп күчерделәр. Керә-керүгә бу дүртнең берсе сорады:

– Синең Баязид дигән танышың юкмы? Коля сикереп ташланды:

– Нәрсә? Әллә ул мондамы?

– Шулмы, түгелме? Белер хәл юк. Сине ике көн буенча кат-кат сорады, менә үзең чиертерсең, әзрәк сабыр ит, фиргавен теге башка үтсен!

Бу шул иде. Кадомцев кыенлык белән булса да, озаклап чиертә-чиертә, «якшәмбе вакыйгасы»н сөйләп бирде. Булат турында ачык сүзне ул да әйтмәде. Иптәшләр арасында төрле сүз йөри: эләккән имеш, кыйналып имгәнгән имеш, якшәмбе вакыйгасында кулга алып, зинданга китергәндә, «кача башлады» дигән сылтау белән юлда атып үтергәннәр имеш, дип сөйлиләр. Ләкин дөресен генә берсе дә белмәде.

## XXI
## ТӨНГЕ САТАШУ

Якшәмбе вакыйгасының, Булат язмышының чынын белә алмыйча, үз эчендәге ялкынга янып, Баязид камераның бер башыннан икенче башына туктаусыз йөри бирде. Кич килде. Караңгы басты. Зиндан үзенең төнге тынлыгына чумды, күрше бүлмәдән тоткыннарның хырылдаганнары ишетелә башлады. Ләкин аның күзләренә йокы кермәде, ул, читлектәге бүре кебек, камераның түреннән ишегенә, ишегеннән түренә үзен туктата алмый һаман кызу-кызу йөрүендә булды. Сәгать тугызны сугып үткәч, ишектәге кечкенә тимер күз ачыла. Аннан надзирательнең тавышы:

– Сафаров, ни йөрисең? Ят! – дип боерык бирә.

Тоткын туктала алмый карыша:

– Йокым килми минем! – ди.

Надзиратель боерыгын кабатлый, тавышына ачулы усаллык чыгара:

– Нәрсә? Синең карцерда утырасың киләме?

Баязид кызып-кызып тагы берничә әйләнә, надзиратель каты сорый:

– Ишетәсеңме, юкмы минем сүзне?

Баязид, теләмәсә дә, машинаны туктата, ярым-ярты чишенә, сыек саламлы матраслы тимер караватка ава да кызган тәне өстенә иске киндер юрган каплый. Ләкин күзләр йомылмыйлар. Башында дөнья кайный. Әллә чын? Әллә саташу? Белер хәл юк.

Төн караңгы. Дөнья үлем, кабер тынлыгы эчендә. Кинәт каты җил кузгала. Бала чакларында Давыт Урманов белән уйнап, сугышып үскән зур бакчаларындагы карт агачлар ниндидер бер куркыныч белән выжылдап шауларга тотыналар. Тузан, өермә күтәрелә. Ботаклары белән тирә-якны каплап утырган зур карт агач бу җил белән сугыша, карулаша башлый, ләкин җиңә алмый: котырган каты өермә, җенләнеп, тузанланып килә дә карт агачны уратып ала, бер сугыла, ике сугыла, өченчесендә төбе-тамырлары белән күтәреп, ыргытып бәрә. Баязид бу каты өермә эчендә суырып ташланган карт агачның астында калмас өчен якындагы җимерек иске сарайга сыенырга өлгерә алмый, коточкыч тавыш белән күк күкрәп җибәрә, куркыныч яшен, аклы-зәңгәрле утлар белән уйнап, җир-күкне ялтырата, шуның артыннан ук коеп яңгыр яварга керешә. Баязид куркудан кая качарга, ничек котылырга белми. Яңгырлы болытлардан түгелгән утлар эчендә, агачлардан сарайга ташланган секундта, алдына өч хатын килеп чыга да җылап йөгерергә башлыйлар. Боларның икесе ялангач, берсе ертык иске күлмәктән генә. Зур ак чалмалы, чапанлы, озын таяклы карт мулла чәч толымнарыннан тоткан да, аяклары белән типкәли-типкәли, аларны каядыр өстери. Хатыннар кызганыч тавыш белән җылыйлар, ялваралар. Егет, аптырап, кире чигенә алмый. Бу җылау тавышларының берсе... юк, барысы да таныш, бөтенләй якын таныш булып чыгалар. Ул аларга ташлана, иплэп карагач, кычкырып җибәрә: бу кыйналган хатыннарның берсе – Баязидның анасы – Гайшә апай, ике яшьрәге – сеңелләре Саҗидә белән Сабира төсенә әйләнәләр, кыйнаучы адәм – таныш чалма-чапаны белән егетнең туган атасы – Җиһан ишан сурәтенә керә. Җылаудан, газаптан, куркудан бит-күзләре шешенеп беткән Сабира Баязидны таный да: «Абзыкай! Безне коткар! Үтерә бит бу!» – дип акырып, моңа таба йөгерә. Баязид: «Мине эштән чыгаруың җитмәгән... инде анам белән сеңелләремә тотынгансың икән син, палач!» – дип, ерткычланып кычкыра да чалманың өстенә ыргытыла... Ләкин шул

минутта зур бакча да, агачлар да, җимерек иске сарай да каядыр югалалар. Тоткын Баязид үзен ерак Себернең кара ташлы куе урманнары эчендә, әллә нинди юеш чокыр төбендә күрә. Башының ярты чәче кырылган, өстендә солдатныкы сыман тегелгән, ләкин ертылып беткән соры чикмән, аягында авыр богаулар. Ул, үзе кебек, башлары яртылый кырылган, иске соры шинель кигән богаулы адәмнәр белән авыр атлап бара. Һәммәсе дә сүзсезләр. Басынкы, авыр карашлы караңгы йөзлеләр. Аякларындагы тимер богауны чак өстерәп, шатыр-шатыр зур ташлар тирәсендә кыймылдашалар. Болардан өстәрәк яшел читле фуражка кигән, сөңге, мылтык таккан кешеләр күз алмый карап торалар. Ике яклап биек таулар тезелеп китәләр. Анда ерак тау башларында җил уйный, болытлар бер капланып туктала да, аннан тагын агып китәләр дә югалалар. Күк йөзе ачыла. Ләкин анда кояш та юк, ай, йолдызлар да күренми; көнме, төнме, иртәме, кичме – белер хәл юк... Баязид, аптырабрак, тау башларына, ерак күккә бер генә карый да, озын калын тимер ломны тыгып, зур тауның ташын каера башлый. Ташлар селкенеп-селкенеп куялар. Кемдер: «Сак маташ! Үзеңне басмасын», – ди. Аның бу сүзе әйтелеп бетми, таш кузгала – менә, менә, хәзер, хәзер тәгәрәп китәчәк тә Баязидны изеп юк итәчәк. Кемдер: «Үләсең, тиз кач!» – ди. Теге авыр йөзле, тимер богаулы адәмнәр, акрын гына әйләнеп, аңа карыйлар, ләкин телсезләрдерме, һичберсе һичбер дәшми – бер генә күтәрелеп карыйлар да эшләренә керешәләр. Таш ава, Баязидның өстенә таба ишерелеп килә. Менә, менә, хәзер таптап, изеп китәчәк. Егет куркуыннан бөтен көче белән читкә ташланмак була, ләкин урыныннан кузгала алмый, гүя аны нидер тота. Теге авыр тимер богаулы, караңгы йөзле кешеләрнең йөзләре тагын да караңгылана төшә, ләкин алар һаман бер сүз дә дәшмиләр. Баязид җан ачуы белән тагын омтыла, кузгала алмый тора. Теге кылычлы, мылтыклы адәмнәрдән берсе яман акырып җибәрде, ләкин аның авызыннан тавыш чыкмады, каяндыр шарт-шорт мылтык аткан тавышлар күтәрелде. Баязид, куркып, бер якка ташланмак булды, кычкырып җибәрде – шул секундта сискәнеп уянып китте.

Караса, үзенең тар, биек, озынча таш камерасында, тимер караватта ялгызы ята. Бүлмә ярым караңгы, тик кечкенә төнге лампа гына әз генә яктылык биреп тора. Тоткын башта аера алмый куркып аптыранды: «Бу ни хәл, төшме, өнме? Кайда мылтык аталар? Чү! Тагы аталар. Әнә кемдер кычкыра... Тагы аталар...»

Коридорда йөгереш, тапташ, талаш башлана. Кемнәрдер качалармы, берәүне буалармы? Күрше камерадан тоткыннар сискәнеп уяналар да, ни эшләргә белми аптыранып, тимер ишекләрне дөбердәтергә ябышалар. Батып барган корабның актык минуты киләме, әллә зур янгын астында бөтен зиндан үзенең тоткыннары белән бикләнеп һәлак буламы? Баязид аера алмады, коты

очып, ишеккә барып сукты, аның кечкенә капкачына йодрык белән бәргәли башлады. Ахры, нык булмагандыр: капкачтагы кечкенә күз коридор ягына таба әйләнеп төште. Баязид ашыгып каранды: анда да ярым караңгы, җүнләп бернәрсә күренми. Тукта, бу ни хәл? Безнең надзиратель күренми, теге, көндезләрдә ишек капкачы аркылы аш-чәй бирүче карак молдаван яшен кебек атылып үтте. Шуның белән монда тынды. Ләкин атулар бетмәде, тик алар каядыр ерагая кебек ишетелде; шулар эчендә инде кычкырган, куган тавышлар да колакка чалынгандай тоелды.

Менә бервакыт коридорга менә торган караңгы баскычның түбән башында аяк атлаулар күтәрелә башлый. Үзара ашыгыч, акрын сөйләшәләр дә кызу-кызу коридорга кереп тулалар. Ни дә булса, әлбәттә, зур вакыйга. Жандарм ротмистр Николаев белән зиндан башлыгы Петров, аның ярдәмчесе Иргазов, бик күп надзирательләр ияртеп, бер көтү булып коридорны басалар. Камераларның калын тимер ишекләрен ачалар. Тоткынны карыйлар. Кулларындагы кәгазь буенча барлыйлар да, бер сүз әйтми, һичнәрсә сорамый, яңадан тимер ишекне ябып, зур йозакны шалтыратып биклиләр.

Коридорда унсигез камера бар. Боларның дүртесе Баязидныкы кебек тар, кечкенәләр. Ялгыз утыручылар өчен. Башкалары зуррак. Аларга бишәр-алтышарны ябалар. Көньяк башта берсе – гади вакытта унике кешелек, әмма хәзерге кебек революция чорында моңа инде утызга якын тоткын тутыралар. Баязид ишектән китмәде, колагын салып, өзелми тыңлады: бу унсигез камераның һәммәсен тикшереп, барлап чыктылар да, бу көтелмәгән төнге кунаклар яңадан шул тар, караңгы баскыч белән түбәнгә таба төшеп югалдылар.

## XXII
## БИШ ЙОЛДЫЗ

Яңа надзиратель Безобразов беренче адымында ук каты куллык күрсәтте. Баязид әле уң, әле сул күршегә берничә чиертергә теләп карады, ләкин Безобразов шунда ук каяндыр сизенә дә килеп җитә:

– Тагы бер күрсәм, карцер! – дип, нечкә, усал тавыш белән зәһәрләп кычкыра.

Тоткыннарның һичберсе һичбер нәрсә турында сорый да алмады, белә дә алмады. Таңны, көнне шулай каршы алдылар. Бүген теге карак молдаван күренмәде, аның урынына бер солдат аш-чәй ташыды. Тоткын Баязид нидер сизә иде. Ләкин ачык рәвештә һичбер нәрсә аңлый алмый, бөтен тәүлек буенча шөбһә эчендә газап белән үткәрде. Шулай тагы төн килде, сәгать тугызда тагы һәммә тоткыннарны көчләп караватларына яткырдылар. Дөнья тынды, зинданны кабер тынлыгы каплады. Һичкайда эһ иткән тавыш та юк,

тик бары гадәттән тыш сизгер табигатьле яңа надзиратель Безобразов кына коридорның бер башыннан икенче башына туктаусыз йөри, бик еш әле бер, әле икенче камераның ишегендәге кечкенә күзне ачып, тоткынның караватына карый. Карый да тагы йөрергә керешә.

Кич үтте. Шәһәрдә кайдадыр сәгать суга. Баязид унберне, уникене саный. Һаман ята. Һаман зинданның авыр тынлыгын тыңлап, ачык күз белән ята. Камера караңгы, ләкин тышта аяз, анда матур зәңгәр күк үзенең йолдызлары белән яна. Камераның югары тәрәзәсе бу якты күкнең тик кечкенә бер өлешен генә күрсәтә ала. Шунда биш йолдыз, туктаусыз карап, бу бүлмәгә җемелдиләр, җемелдәп-җемелдәп бер сүнәргә якынаялар. Аннан тагы ялкынланып китәләр. Баязид озак карап ятты. Бу ни нәрсә? Биш йолдызның уртадагысына нindидер җеп сузылып төшә. Каяндыр, югарыдан сузылып төшә. Җепнең башында кечкенә, бик кечкенә генә төенчек бар. Бу селкенә. Йолдызны каплый яза. Тагы югары менә, тагы төшә. Әллә йолдыз белән шаяра. Әллә инде Баязидның күзенә шулай күренә. Менә туктап катты. Тагы бер күтәрелде, бер төште. Инде тоткынның шиге калмады, минут саен карап йөргән надзиратель Безобразовны да онытты: «Ни булса шул, карцер булса карцер, Себер булса Себер, палач булса палач, әмма мин бу чаклы куркак була алмыйм!» Тоткын, үзе яткан җиреннән идәнгә кулы белән этәреп, караватны тәрәзәгә таба китерергә тырышып бакты, юк, көч җитми! Кинәт торды да ике кулы белән ашыгыч караватны тәрәзә янына китерде, яшен тизлеге белән каракаватның читенә басты, тәрәзәгә үрмәләде, аннан, тимер рәшәткә аркылы кулын тыгып, югарыдан җеп белән асылган кечкенә кәгазь төенчекне тартып алды да авызына капты. Бу төшеп чак өлгерде, надзиратель ишекнең кечкенә күзен шалтыратып ачты да кычкырды:

– Приказны белмисеңме? Нигә төнлә торып йөрисең! – диде.

Тоткын үзен югалтмады, сул кулы белән чалбарына тотынды да ишек төбендәге парашага килде, анда бушана башлады. Шуның белән надзиратель тынычланды, тоткынның торуы – шул кечкенә табигый йомыш өчен икән дип, тагы коридор буенча йөрергә, тагы минут саен камераларның күзләрен ачып караштыра барырга кереште.

Баязид, каушап, калтырап, үз егетлегенә үзе шатланып, караватына ятты. Лампа бик зәгыйфь яна. Югары каттагы тоткыннар тарафыннан җепкә асылып төшерелгән кәгазьне бик нечкәләп караса да, таный алмады; бер кулына алып, надзиратель ачса – авызына, уртына тыгып, көн туганчы ут эчендә дулкынланып кичерде.

Менә якты кояш. Менә тар камераның рәшәткәле тәрәзәсеннән җелтер-җелтер кояш нуры стенада уйный башлый. Егет, секунд саен ишеккә карый-карый, кәгазьне укып чыга алды: анда югарыгы иптәшләр көтелмәгән зур

шатлык язалар.

Бу зинданнан качу планы күптән бар иде. Яртылай чарасы эшләнеп беткәч, ике тапкыр эш сизелде. Ләкин, аңа карап, тукталмадылар. Үзара серле сүз йөри иде. Әмма конкрет планны Баязид белә алмаган иде. Бүген төндә егерме сигез иптәш зинданнан качканнар, – бу зур шатлык, ләкин зур кайгы да бар: каравыл, сизеп калып, качучылар артыннан куа башлаган, шунда иң ахырдан чыккан ике иптәшне атып үтергәннәр. Болар – корбан. Зур авыр корбан. Ләкин ни эшлисең! Арада иң гаҗәбе шунда: теге, явыз, усал күренгән ерткыч Иванов надзиратель белән аш-чәй ташучы карак молдаван да бергә качканнар. Бу ике кеше, ел буенча, партия тарафыннан айга иллешәр сум алып торган булганнар. Бара торгач инде, үзләре кызып, кызарып, теләп, бергә сызганнар. Качучылар элек унсигез кеше булыр дип план эшләнгән икән, соңгы көндә заводлар алдында митинг-демонстрация вакытында кулга алынган иптәшләрдән ун кеше – алдынгы большевиклар – шул бер көн эчендә планга кертелгәннәр. Шулай итеп, бу яңа иптәшләр очканнар.

Баязид бөтен төнне гадәттән тыш тирән дулкын эчендә кичерде. Элекке унсигез кемнәр икән? Бу яңа алынган ун большевик эчендә аның таныш татарлары юкмы икән? Кичә чиертеп сөйләшкән иптәш завод алдындагы бәрелеш чагында Булатлар да эләккән имеш тә дип, юк имеш тә дигән шикелле әйтә. Болар эләксә, качучылар эчендә释бармы, юкмы? Ике корбан бар. Болар кемнәр?

Баязид бу авыр төеннәрне чишә алмый газапланып бетте. Чиертеп сөйләргә дә мөмкин түгел. Күршеләргә бу кайгы катнаш шатлык вакыйганы сөйләргә кирәк, аларда Булат турында хәбәр юкмы – аны да белергә кирәк. Бөтен гомер чаклы озын ике тәүлекне Баязид шул белемсезлек газабы эчендә кичерде. Өченче көнне, көндез сәгать унда, надзиратель Безобразов камераның ишеген ачты да кычкырды:

– Сафаров Баязид, тиз бул. Күрешергә! Невестаң килгән! – диде.

Егет аптырады.

– Нигә мыскыл итәсең! – дип, ачулы җавап кайтарды.

Дөресе дә шаярган икән. Күрешергә булмады, зинданның торкыннар өчен мунчасы бар иде – Баязидны шунда юынырга илттеләр. Баязид мунчаны бик сагынган иде: юынып, рәхәтләнде. Шунда, тагы шул ук Кавказлы Гәрәй Солтанның тышкы элемтәләре буенча, яшь бер уголовник юынган чакта эзләп тапты да, бот арасыннан алып, кечкенә, яшерен кәгазьне төртте. Бу – Җиһангирдән хат иде. Егетнең үз серләре ике генә, ул әйткән:

«Дөнья кайный. Бүген Мәдрәсәи исламиянең асты-өскә киләчәк. Әгәр сораганнарыбыз бирелмәсә, ике йөз шәкерт-каһарман бу черек козгын оясын җимереп чыгып китәчәкбез! Эшләр шәп, туганкай. Тик син генә юк!» –

дигән.

Шул ук кәгазьнең түбән ягына «дөрес хәбәр дип ышан» сүзләре астына Булатлар, Гәрәйләр турында кыска гына язып белдергән. Син, дигән, анда тышкы хәлләр турында берни белми газаплана булырсың, нервыларыңны бик ватмаска тырыш! Кызма, юк-барга көенеп, янып китмә, дип үгетләгән дә, ахырдан вакыйганы аңлаткан.

Эш болай булган икән. Завод алдында митинг-демонстрациядә сөйләп торган минутта жандармнар белән каты бәрелеш булып үтә. Булатны ике жандарм эләктереп алалар. Ләкин алар аны участкага алып китә алмыйлар – Галимов дигән татар эшчесе белән Вәли Хөснетдинов, Исрафиловлар килеп чыгалар да жандармнар өстенә ташланалар. Ике арада бәрелеш китә. Боларны әллә ничаклы эшчеләр камап алалар. Шул бәрелеш, талаш, кычкырыш арасында Галимов белән Исрафилов Булатны, качырып, күрше йортка кертәләр, анда Фәхри тегүчегә яшерәләр. Ләкин филерлар[1] моны сизеп калалар да, бөтен тирә-якны басып, эзәрлиләр. Булатны табып, тотып алалар. Шунда ук китереп ябалар. Бу төндә зинданнан егерме сигез тоткын качты. Боларны качыру эшен тыштан, иректән торып оештырган дүрт организаторның берсе Кавказлы Гәрәй Солтан иде. Ул үзе ике тапкыр эләгә язып, бер әрмән карчыгы ярдәме белән чак котылып кала алды. Ләкин аның эзенә төшкәнлекләре бик ачык иде. Аны эзләргә керешелгәне бик күп сәбәпләрдән сизелеп тора иде. Эз яздыру өчен аңа хәзергә, бераз вакытка, моннан китеп торырга куштылар. Ул, өс-баш алмаштырып, ялган исем белән Уралга китте. Аңа Екатеринбургка, Семеновка явка бирделәр. Ул анда Семеновның боевая дружинасында эшләргә әмер алды.

Баязид бу күп төрле хәбәрләр арасында мунчаны онытты. Шул ук уголовник белән аңлашты да аның аркылы иреккә хат чыгару чарасын күрде. Яңа надзиратель Безобразовның артык каты көннәре бик озакка бара алмады, ул минут саен каранып йөрүдән арыды: коридор башында артсыз урындыкка утырып, стенага сөялгән килеш, калгый-калгый йокларга гадәтләнеп китте. Әүвәлге кебек чиертеп сөйләшүләр яңадан башлангач, Баязид инде Булат белән һәр көн янәшә камералар аша хәбәрләшә торган булды, аның аркылы Гәрәйнең элемтәсенә кереп, Җиһангиргә зур озын хат язды:

«Сәламәтлегем начар. Бу арада тагы үпкәдән кан килә. Мине залогка чыгартып торуның чаралары әллә тукталдымы? Бу турыда ни эшлисез? Кадыйр байның улы, теге Йосыфҗан, алты йөз сум акча биреп тормакчы дигәннәр иде... Миңа ничек тә озакламый чыгарга кирәк, юкса эш начар. Нигә бер чара күрелми?!»

---

[1] *Филерлар* – шымчылар.

## XXIII
## ПОЛИЦИЯ НӘРСӘ ӨЧЕН?

– Чыкмасалар, полиция ни өчен? Тагы бик карышсалар, зинданы да ерак түгел!

Мәдрәсәдә баш күтәреп, идарәгә каршы көрәшеп йөргән унике шәкертне куарга кирәк табылды, әмма болар үзләренчә фәлсәфә белән каршы торырга исәплиләр: «Мәдрәсә хәзрәтнеке түгел, ул вәкыф йорт[1]. Ул – мәхәлләнеке. Мәхәлләнең вәкыф йортыннан милләт яшьләрен урамга сөрергә хәзрәтнең нинди хакы бар? Без кусалар да чыкмыйбыз», – диләр. Ике якның бу талашлы сүзе барып ишетелгәч, мәдрәсәне акча белән караучы Кадыйр бай әйткән имеш: «Чыкмасалар, полиция ни өчен? Тагы бик карышсалар, зинданы да ерак түгел», – дигән имеш.

Бу сүз Йосыфҗан аркылы Фәхригә, аннан Габдрахманга, алардан Тангатаров, Нигъмәт казыйларга барып иреште. Җиһангир моны ишетү белән бөтенләй җенләнеп китә язды. Шунда ук кычкырды:

– Алаймы? Полиция кертергә уйлыймы? Алайса, без мәдрәсәнең астын-өскә китерербез! – диде.

Бүген сәяси түгәрәкнең җыелышы иде. Петербург курсларыннан куылган Разия Ширинская туташ ике сәгать ярым буенча Бөек Франция революциясе турында сөйләде. Җиһангир моны ялкынланып тыңлады, бөтен нәтиҗәне шул полиция белән, зиндан белән куркыткан идарәгә каршы сугышка китереп терәде. Сәяси түгәрәктән аның белән бергәрәк чыккан зур иптәше Нәҗип Камалга бу хакта янып сөйләде.

– Эш алайга калса, без мәдрәсәнең астын-өскә китерәчәкбез, шулай бит? – дип җавап көтте.

Ләкин бу иптәше сабыр гына елмаю белән эш бетерде, үз эченнән: «Ул мәдрәсәне җимердең ни, җимермәдең ни? Барыбер түгелме?» – дип куйды. Ләкин, Җиһангирнең ут кебек янган көрәш дәртен күргәнгә, талаш чыгарасы килмәде, хәрәкәтнең башындарак барган шәкертләр белән алдан аңлашыр өчен мәдрәсәгә юнәлде.

Җиһангир өчен Баязид турында сөйләшү кирәк, теге алты йөзне Йосыфҗаннан алып, авыру иптәшне тоткыннан хөкемгәчә чыгарып тору хакында ашыктыру тиеш иде. Аңа юлда ертык тезле ярлы гимназист – сипкел Тангатаров очрады. Бу, ничектер, бик дулкынланган хәлдә иде, кулын бирер-бирмәс кычкырып әйтте:

– Сөрделәр бит, малай, хәзер урамда калдым, – диде.

Җиһангирнең моңа бер дә исе китми карады. Тангатаровның

---

[1] *Вәкыф йорт* – берәр кеше тарафыннан җәмәгать файдасына бирелгән йорт.

кызыллыгы гимназия идарәсенә мәгълүм иде... Иптәшләренә начар тәэсир ясый дип, аны куарга әзерләнүләре күптән сизелә иде. Бары тик директорга якын таныш әбисе Мәрьямбикә карчык күңеле өчен егетне түзәләр иде. Кичә мендәр астыннан прокламация тапканнар. Гимназиянең пансионында, сәяси түгәрәктә, доклад ясап торганда килеп басканнар. Бүген сөргәннәр. Тангатаров үзе салкын карый:

– Әйдә, сөрә бирсеннәр! Миңа нәрсә? Мин адвокат булып кеше алдарга теләмим. Гимназиядән кумасыннар дип, мин үз иманымны сата алмыйм. Дөнья кайный. Самодержавиегә каршы, буржуазиягә каршы сугыш бара. Мондый чакта диплом дип, укыйм дип бикләнеп яту үзе бер начар эгоизм ул, мин революциягә кереп китәм... – ди.

Иптәшләр озак шулай дәртләнеп сөйләшеп бардылар. Тиздән әдәбият кичәсе куймакчылар. Зур ясамакчылар. Ярты файдасын зиндандагы тоткыннарга бирмәкчеләр. Тангатаров бу эшнең рәсми ягын башкаруны үз өстенә күтәргән иде, ялкынланып сайрады. Приказчиклар җәмгыяте үзенең залын буш бирәчәк, шәкертләр, гимназистлар һәммәсе катнашырга әзер торалар. Приказчиклар арасында мандолина белән оркестр оештырырга йөриләр. Бер башкорт шәкерте чын «Ашказар» көйләрен чыгып җырламакчы, тик менә рөхсәт ягы гына бераз комачаулы күренә. Кичәгә каршы түгелләр. Тик менә аның табышын сәяси тоткыннарга бирергә күнмиләр. Булмаса, инде моны башка бер битлек астында үткәрергә кирәк...

Тангатаров почмакта аерылды. Бүген мәдрәсәдә зур җыелыш. Шәкерт белән идарә актык сугышка әзерләнәләр. Җиһангир бер иптәшеннән алып торган зур көмеш сәгатен күкрәк кесәсеннән чыгарып карады да, вакыт бик җитеп килә икән дип, бакчага таба ашыкты. Инде керәм дип капканы ачканда, ашыгычлык белән бер кешегә бәрелә язды. Күтәрелеп караса, Урманов икән. Давыт гаҗәпләнеп карады:

– Чү! Бу ниткән эшең синең? Мәдрәсәи Исламиянең асты өскә килергә тора, син шуның башында барасын. Ә үзең иң кискен чакта бакчада йөрисең! – дип шелтә ташлады.

Җиһангир бакчаның аргы ягына күз атты да сөйләшеп торырга вакыты да юк икәнен аңлаткан кызулык белән җавап бирде:

– Зинһар, минем юлыма кискә булып ятма! Мин хәзер мәдрәсәдән килдем... Менә ун минуттан тагын анда булам, – диде. Тагы өстәде: – Мине җибәр! Мин хәзер мәдрәсәгә барып җитәм, минем серне беләсең ич! Мин Һаҗәрне көтәм. Аның ире хәзер мәдрәсәгә хөкемгә китә. Шул арада Һаҗәр җә үзе чыгарга, җә хат белән асравын чыгарырга тиеш!...

Бу як урам буйлап боларга таба бер хатынның килгәне күренде. Җиһангир, бөтен дөньядан яшеренергә мәҗбүр адәм кебек сакланып, шул

хатын ягына күз атты да кире бакча эченә чигенде.

Җиһангир инде якынлап ук килгән хатынга йотылып күз салды да тагы шул куркыну катнаш яшерен, ялварулы тавыш белән колагына пышылдады:

– Бәйләнеп торма, зинһар! Һаҗәр белән минем араны беләсең!

Хатын бакчаның кабырга як капкасыннан керде. Җиһангир кечкенә капкадан борылды. Икесе дә уң як почмактагы куе агачлыкларга таба киттеләр.

## XXIV
## МӘДРӘСӘ ЯШЬЛӘРЕ

Көньякка буе белән салынган өч катлы, киң, озын таш бина. Зур өлгеле киң тәрәзәләрнең һәммәсе ерактан балкылдап торалар. Әйтерсең, патша туган көн – шулай бәйрәмдәге кебек куәтле яктыртылганнар. Зур таш бинаның эче үзалдына бер завод, фабрика яки тузган умарта оясы шикелле гөрләп тора. Капкага каршы алты киртләчле таш баскычта әллә ничаклы яшьләр, шәкертләр куышып менеп үтәләр. Ике катлаулы зур ишекне ачып җибәрәләр. Аннан башына сары читле фуражка, өстенә Казан татарынча казаки, аягына савырлы читек-кәвеш кигән ябык, ярлы швейцар ачык йөз белән каршы ала:

– Нихәл, агайлар, бик исән-сау гына йөрисезме? – дип, исәнлек сораша-сораша, җиңел кузгалмый торган тупсаларны шыгырдатып, ишекне яба.

Мәдрәсәнең югары катлавында сыйныф – дәрес бүлмәләре. Урта катта начар, арзан караватлар тыгызланып тутырылган ятакханәләр, иң түбәнге катның бер ягы кухня, утын склады, икенче ягы – буяусыз, ашъяулыксыз озын агач өстәлләр белән тулы киң аш-чәй бүлмәсе.

Мәдрәсәнең һәммә катлавы туктаусыз кайнап торган дулкынны искә төшерә иде. Һәммә бүлмәләрдә шау-шу бара. Ябык, саргылт йөзле, хәлсез карашлы, ач яңаклы, беразы казаки, бишмәттән, кайберләре фуражка яки кара күлмәк өстенә бәйләнгән каештан, бик күбе җитү чәчле, ләкин һәммәсе диярлек начар киенгән шәкерт җәмәгате бүген эш ташлау алдыннан завод эчендә кайнаган эшчеләргә яки бунтка әзерләнгән күп солдатлы казармага ошыйлар. Үзләре туктаусыз төркем-төркем булып сөйләшәләр, кычкырышалар, каяндыр искән җил белән кузгалып торган диңгез кебек, бүлмәдән коридорга, аннан түбәнгә, баскычка, тагы югарыга, тагы коридордан бүлмәләргә агып, гөрләп йөриләр. Болар өстендә, каты җил астында шаулап торган караңгы урман гөрләве кебек, тавыш күтәрелә. Нәҗип Камалны күргәч, ябык, саргылт йөзле, ярым русча начар киемле, җитү чәчле, ләкин һәммә сугышка әзермен дип караган ялкын карашлы шәкертләрнең бер төркеме, шул уртак дулкыннан аерылып, аңа таба каршы

килделәр. Ул бераз көлке тавыш белән кычкырды:

– Ну, иптәшләр! Ниләр бар? Нык сугышасызмы? – дип сорады.

Шәкерт яшьләр, башта бераз тартынып, кайберләре кыюсызланып торсалар да, тиз телләнделәр, берсен-берсе бүлә-бүлә, идарә белән сүгешләрне сөйләргә керештеләр. Хәзрәт беренче яман сүзләр белән сүгелеп ташланды. Читтән торып мәдрәсә эшләрендә бармак уйнаткан байларны буржуйлар, юан корсаклар дип каһәрләделәр. Берсе өзеп әйтте:

– Без кадим мәдрәсәне ташлап монда килдек, монда тагы изә башласалар, дөньясын җимереп чыгарга әзербез! – диде. Бу кискен сүзне әйтүче Сөләйман Сәйфуллин нәрсәдер кинәт хәтерләде дә: – Хәзер киләм, иптәшләр, – дип, икенче катта уң яктагы ятак бүлмәләренең берсенә керде.

Артык тыгызланып тутырылган ике катлы тимер караватлары белән бу бүлмәләр иске заман пароходларының дүртенче классларын хәтерләтәләр. Бүлмәнең почмаклары каралган, тәрәзә төпләре юеш, һавасы гадәттән тыш авыр. Монда тир исе, адәм исе, әчегән бәрәңге исе бары берләшеп, ниндидер бер начарлык аңкытып, борынны ярып бара. Ишекне ачуга сак кына уйналган музыка тавышы ишетелде. Шәкерт эчендә модада булган «Сада» көенә [25*] ошашлы бернәрсә уйныйлар. Караса, караватларның берендә, ертык юрган өстендә, керле тышлы кечкенә мендәргә таяна төшеп, ябык-саргылт йөзле, кипкән иренле, ләкин дәртле карашлы унбиш яшьләрдә булыр бер шәкерт күлмәкчән скрипкә уйнап утыра. Сөләйман аңа карап көлде:

– Нихәл, Камил? Сиңа ирек икән? Назыйр[1] бәйләнмиме? – диде.

Шәкерт күп җәфа кичергән яшь йөзе белән бераз тартына төшеп елмайды, кыюсызрак тавыш белән җавап бирде:

– Җә хәзер алардан кем сорый дисең? Хәлфәләрдән курка торган заман түгел ич хәзер! Аша барса, мәдрәсәдән куарлар... Барыбер мине монда...

Бу вакыт югары катта кемдер, нигәдер, кыңгырау шыңгырдата башлады. Сөләйман ишеккә борылды:

– ...Анда, җәмгыять, башлана бугай... Әйдә очтык, – диде.

Камил скрипкәсен ташлады да аяклары җиргә тияр-тимәстән чабып югары катка атылып йөгерде. Әле яңа гына шәкерт белән тулып кайнаган зур, озын коридор бөтенләй бушаган, агымның койрыгы өске катка менә торган киң тимер баскыч белән, бөясен җимергән язгы ташкын кебек, бер кызу ашкыну белән югары менеп бара иде. Болар да шулар артына кушылды. Шулар белән бергә өченче каттагы җыелышларга билгеләнгән зур зал шәкерт дулкыны белән шыгрым тулып өлгергән иде инде. Ничаклы тыгыз булса да, әле һаман бүлмәләрдән шәкерт агыла, һаман берсен-берсе кысып, шул тыгыз

---

[1] *Назыйр* – мөдир (биредә мәдрәсә мөдире күз алдында тотыла).

тулган залга тыгыла баралар. Монда инә ташларлык урын калмады, һава гаҗәп тиз тарайды, тын алырга авыр булырлык хәлгә килде. Ләкин гомер буенча начар һавалы юеш биналарда ачлы-туклы яшәгән шәкерт җәмагате моны сизмәде. Чөнки бу – гади иде. Һавасыз тыгыз зал эчендә, мәдрәсә яшьләренең үпкәләрендәге авырлыкка карамастан, йөзләре җанлана бара, башка чакта хәлсез үлек карашлы булган күзләрендә бу сәгать ялкын ялтырый иде.

Арттан кемдер кычкырды:

– Халык җыелып бетте. Мәҗлесне ачарга вакыт! – диде.

Залның көньягында стенага терәлеп куелган өстәл бар; аның өстендә – кәгазь, кара, каләм. Ике ягында, берсе артсыз, ике урындык куелган. Мәҗлесне ачарга вакыт, дип кычкыруга каршы озынча буйлы, үткен карасу йөзле, тар ирен өстендә әле яңа гына кара мыек сызылып килгән, кәләпүш астында чәчен җиткергән чибәр шәкерт күтәрелде. Бу – әле яңа гына шәһәр бакчасы төбендә үзенең сөйгәне матур Һаҗәрне көткән һәм шул турыда Урманов белән бәрелешкән Җиһангир иде. Ачык кискен тавыш белән:

– Иптәшләр, татар шәкертләре! Сез беләсез, бүген безнең биргән таләпләрнең вакыты чыкты! – дип кычкырып җибәрде. Тавышы башта бераз каушый, кул-аяк та аз гына калтырый иде. Ләкин тиз кыюлыгын алды, батыр, усал сөйләрлек көчен күтәреп җибәрде.

Кысык, тар гаилә тормышы өчендә, аннан ярлы үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә каторга кләймәсе суга. Шат, уенчак, алсу йөз белән мәдрәсәгә килгәннәр, берничә ел анда яшәсә, буе көянтә кебек алга ята, йөзе, күп еллар зинданда кояш, иркен һава күрми кичергән тоткыннар кебек, кәфендәй агарына, саргаеп кибә, күзеннән үлем карый, мөгамәләсендә кыюсызлык, дәртсезлек, өмитсезлек башлана. Бөтен торышлары белән гәүдәле кайгы, аяклы кабер төсенә керәләр.

Җиһангирнең балалык, яшьлек гомерләре башкачарак шартлар эчендә үтте. Ул үз гаиләсенең төпчеге иде. Бик ярлы булмадылар. Пенза ягыннан Чиләбе өязенә зур, кәсепле авылга күчеп, шунда урынлашып калган атасы Гыйбай мишәр төрек сугышында вафат булды. Ире үлгәч, Нәгыймә карчык башка зур балалары арасында төпчек Җиһангирне аеруча кадерләп, иркәләп үстерде. Юк-бар өчен кыйнап, сугып баруларының бик күбеннән Җиһангир сабыйның яңаклары, аркалары исән калдылар. Ул башта схоластика белән ми череткән кадим мәдрәсәдә Давытлар белән бергә укыды. Ләкин анда да артык изелмәде. Шәкертнең күбен изгән ярлылык, ачлык, ялангачлык, садака белән көн итүчелек Җиһангиргә төшмәде: аңа авылыннан азмы-күпме ризык килә торды. Җәйләрдә авылына кайтып, агаларына, апаларына таяна төшеп, уен беләнрәк кичерде. Кыш көне мәдрәсәләрдә бик алай укуга чумып китә

белмәде. Ул гарьчел, өстенлек сөючән бала иде. Ләкин зирәклеге аны хурлыктан коткара барды. Ул хәлфә сораганга шәп җавап бирерлек хәзерләнә дә аннан соң мәдрәсә буена шаярып йөрергә ярата иде. Зуррак булгач та, башка кайберләр кебек, озын төннәр буенча шәрхләр[1], хашияләр[2] актарып, «моталәга»[3] эченә чумудан тәм тапмады.

Аның табигате җиңел, егет, гамәли кайнаучан иде. Ул, кадимне ташлап, монда, яңа аталган Мәдрәсәи Исламиягә килгәч тә, дәрестән бигрәк, җәмгыятьләргә, идарә белән көрәшләргә ыргытылды. Шулар аркасында ул, башкаларның күбе кебек, иртә бөкрәюдән үзен коткарды; аның йөзен кәфен аклыгы, күзен хәлсез кабер карашы каплый алмады, ул бөтен шәкерт эчендә шат, егет, җиңел, сугышчан табигатьлеләрдән булып калды. Дулкын бармы, көрәш башланамы – Җиһангир беренче сафта булыр. Мәдрәсәнең эчке, тышкы идарәләрен, бай-баниларын, хәзрәтләрен сүгәләрме – аның авызыннан ут чәчри. Ул һәркайчан сул канатта, ул һәр урында ялкын белән көрәшкә ыргытылырга әчер тора. Шул характеры сәбәпле ул Баязид карый белән тиз килеште. Шул сәбәпле үк аңа үзеннән югары укучы, тиздән мөгаллим, мулла булып чыгарга йөрүче өлкән шәкертләр – надан дип, кызыл авыз малай дип карасалар, шул ук сәбәп белән мәдрәсәнең бөтен яшь-җилкенчәге, барлык көрәшче демократиясе – Җиһангир дигәндә үлеп торалар.

Бүген дә, нинди булса да берәр рәсми хак буенча түгел, тик шул хәлләргә таянып, Җиһангир шәкерт җыелышында беренче сүзне әйтергә үзенә кыюлык тапты, башкалар да моны табигый күрделәр. Ул беренче сүздән үк мәдрәсә демократиясенең ялкынлы күз карашлары астында үзенең фикерен әйтеп бирергә батырчылык итә алды:

– Иптәшләр, – диде, – сез беләсез: моннан бер атна элек гариза бирдек. Аңа йөз илле шәкерт кул куйды. Без әйттек: бер атна вакыт, дидек, әгәр шул вакыт эчендә сораганнарыбыз бирелмәсә, дәрес ташлаячакбыз, дидек. Бүген әйткән вакыт үтте, әмма мәдрәсә идарәсе кыймылдап та карамады. Соң без нәрсә сорадык, иптәшләр: без ислах сорадык. Урысча мөкәммәл укылсын, Европа фәннәре күбрәк кертелсен, бернәрсә белмәгән ике утынавыз мөгаллим мәдрәсәдән чыгарылсын, каты, мөстәбид[4] назир алмашынсын, һәр атнада ирекле җәмгыятьләр булсын, мәдрәсәнең эчке идарәсенә шәкертләрдән вәкилләр керсен, дидек. Менә шәкертнең сораганы шул иде. Моңа каршы нәрсә әйтәләр? Әнә күрәсезме, канцелярия бүлмәсендә

---

[1] *Шәрх* – берәр китапның авыр урыннарын ачыклап аңлату.
[2] *Хашия* – бер китапның эчтәлеген аңлатучы икенче бер китап.
[3] *Моталәга* – берәр мәсьәләне төрле яклап тикшереп уку.
[4] *Мөстәбид* – изүче, деспот.

мәдрәсәгә хуҗалык итүче юан корсак байлар белән безнең хәлфә-хәзрәтләр җыелганнар. Мин озын колактан ишеттем: анда безгә каршы хөкем бара икән, унике иптәшне кумакчылар. Әгәр инде алар чыкмаса, полиция китермәкчеләр. Менә, иптәшләр, эш кая таба бара. Безне моңарчы изделәр, тагы изәрләр. Безгә бер генә юл: без бердәм булыйк, барыбыз берләшеп, мәдрәсәне үзенең кибете кебек санаган байларга, хәлфә-хәзрәтләргә каршы актык каныбызгача көрәшкә хәзер булыйк... Яшәсен ислах! Яшәсен татар шәкертләре, яшәсен каһарман унике иптәш! Долой буржуй байлар, хәзрәтләр! – дип бетерде.

Ораторның сүзен озак каты кул чабу белән, «Яшәсен!» тавышлары белән каршы алдылар.

Ләкин бу әле тик башлангыч иде. Алкышлар тына төшкәч, шул ук Җиһангир, кара кәләпүш астындагы җитү чәчләрен ипли төшеп, шыгрым тулы залга карады, нидер әйтергә уйлады, ләкин мәҗлес шаулаша башлады, төрле яктан нидер сөйләргә теләп кычкырырга тотындылар. Җиһангир, һәммәсен ярып, акырып җибәрде:

– Туктагыз, иптәшләр! Бу нәрсә? Авыл җыенымы? Әллә тәртипле җәмгыятьме? Болай ярамый, рәис сайларга кирәк! – диде.

Төрле яктан, төрле почмаклардан бер-бер артлы тәкъдимнәр ява башлады, бер-беренә каршы атылган исемнәр, фамилияләр чәчелде. Җиһангирне кычкырдылар. Берсе: Сәйфуллин, диде, аңа каршы:

– Ярамый, ул кызу, – дип карулаштылар. Нәҗип Камалны телгә алдылар – аны идарә яклы дип, байлар, хәзрәт-хәлфәләр тәрилкәсен ялый дип, кире суктылар.

Тагын Җиһангир акырды:

– Иптәшләр, Нигъмәт казый булсын! Ул оста, ул каты. Ул идарәнең тәрилкәсен яламый! – диде.

Зал өстеннән шау-шу, кычкырыш күтәрелде. Ләкин һәммәсе диярлек:

– Нигъмәт казый булсын, Нигъмәт булсын! – диләр. Арада тагы бер-ике тавыш:

– Нәҗип Камал! – дип чыкса да, бу инде күп эчендә тиз батып югалды.

Шунда Җиһангир артыннан ук берәү аякка басты. Озын буйлы, таза гәүдәле, киң җилкәле, аз гына шадра зур битле, мыеклы; утыз яшьләрендә булыр. Әмма үзе изелмәгән, нык сәламәт сакланган. Менә шул – Нигъмәт казый иде.

Бу – элек иске, кадим мәдрәсәдә хәтме көтеб кыйлып[1], ничә еллар усал казый булып торган шәкерт. Шул заманнан аңа «казый» сүзе кушамат булып

---

[1] *Хәтме көтеб кыйлып* – укуны тәмамлап.

калган. Мәдрәсәнең югары сыйныф шәкертләре, башка һәркайдагы кебек, монда да хәлфә-хәзрәт, байлар яклы булалар. Ләкин Нигъмәт казый аерым юл алды, сыйныфташларыннан аерылып, шәкерт хәрәкәте эченә кушылды. Шуның өчен анардан: «Ат азгыны тайга иярә!» – дип көләләр. Ләкин ул моңа карамый, сыйныфташлары эчендә дошманлыкка каршы, урталар, түбәннәр арасында җитәкче, көрәшче, ышанычлы иптәш булып санала. Акрын кузгалып, өстәл янына килде дә сабыр, ләкин калын көчле тавыш белән мәҗлеснең өстенә тәкъдим ташлады;

– Рәис булды, инде секретарь кирәк, кемне күрсәтәбез?! дип сорап, мәҗлескә карады.

Тагы исемнәр, фамилияләр чәчелә, тагы җыелыш гөр килә. Күп арасында Җиһангир белән Нәҗип Камал, Сөләйман Сәйфуллин телгә алынган иде. Болар үзләре теләмәделәр. Якында гына озын чылгы мыеклы шәкерт Вәли башкорт утыра. Җыры белән, тавышы-моңы белән моны һәммәсе бик ярата иде. Ләкин ул җыелышта секретарьлыкны түгел, кирәк дәресләрен дә язып барырга сөйми иде. Сәйфуллин шаярыбрак аның исемен телгә алу белән, бөтен мәҗлес ябыша куйды лабаса. Башкорт шәкерт Вәли, көлеп:

– Иптәшләр, мин яратмыйм, – дип, – мин булдыра алмам, – дип, киреләнеп карады. Ләкин котыла алмады. Күчеп, ана урын бирделәр дә алдына, өстәлгә, кәгазь, каләм китереп куйдылар. Ул:

– Бу татардан котылыр көн булырмы икән? – дип шаярыбрак язарга тотынды.

## XXV
## НИГЪМӘТ КАЗЫЙ

Рәис, кыңгырау шалтыратып, залны тынычландыра да шәкерт-мәдрәсә дөньясында йөртелгән бик күп гарәпчә сүзләр катыштырып, аягүрә баскан килеш, калын күкрәк тавышы белән үзе сүз ача:

– Иптәшләр, замандашлар! Мин һәммәгездән картмын. Бәлки шуңа күрә булыр, бу көннәрнең, бу дулкыннарның тарихи әһәмиятен һичбер шәкерт минем чаклы зур, тирән шатлык белән каршы ала алмыйдыр, дип уйларга батырлык итәм... Мин заманында кадим мәдрәсәсенең атаклы моназыйрләреннән[1] булган кеше. Ул заманда татар шәкерте берсе-берсенең итен чәйнәү белән, моназарә[2] дип, эт урынына сүгеш белән гомер үткәрә иде. Ләкин заман дигән нәрсә һәммә әйбердән көчлерәк булып чыкты. Иске

---

[1] *Моназыйр* – бәхәсләшүче, сүз көрәштерүче.
[2] *Моназарә* – сүз көрәштерү, дискуссия.

хәзрәтләр ничаклы гына каршы торсалар да, мәдрәсәләрнең ишекләрен бикләп, тәрәзәләрен томалап, һичбер яңа тавышны кертмәскә тырышсалар да революция җиңде. Без, иптәшләр, менә бүгенге кебек мәдрәсә яшьләре тормышының тарихында мисалы булмаган бер вакытка килдек... Без, иптәшләр, кадерен белик: зур бәхет, гаҗәп зур алмашынулар болар. Бер мин генә түгел, арада байтаклар шулай иске мәдрәсәдә моназыйр, пишкадәм, дәгъвалы хәлфә булып киенгәннәр. Ләкин заман безне юды, пакьләде. Без ул элекке вәхшәтләрдән арындык... Менә бүгенге вакыйга, бүгенге көрәш дулкыны моның ачык шаһите: безнең унике иптәшебезне куарга уйлыйлар. Чыкмасалар, полиция-жандар чакырмакчылар, тагы карышсак, зиндан да ерак түгел, дип куркыталар. Әгәр дә кадим мәдрәсәдә чак булса, без моңа шатланыр гына идек. Алар куылганда, мыскыл итеп, мәсхәрә белән көлеп калыр идек. Ләкин хәзерге татар шәкерте – ул инсан[1], ул арслан, ул милләт каһарманы! Кайда хаклык, кайда инсаният[2] – ул моны аера... Бу вакыт түбән каттан шаулап-кычкырышып бер төркем кеше менгәне ишетелде. Оратор, полиция булмасын тагын дип шикләнеп, боларга күз салды да тагын кереште:

– Шулай, иптәшләр, без беләбез, аерабыз: кем ул куылачак иптәшләр? Аларның гаебе нәрсәдә? Алар нинди гөнаһлары өчен сөреләләр? Кадыйр бай белән Гали хәзрәт ни өчен аларны полиция белән чыгармакчы?!

Ораторның бу сүзләренә каршы «унике»не яклап:

– Алар безнең җитәкчеләр, алар безнең каһарманнар! – дип, төрле яктан кычкыру күтәрелде.

Нигъмәт казый калын тавыш белән бу кычкыруларны басып алып китте:

– Әйе, иптәшләр, алар безнең каһарманнар! Без алар өчен каты көрәшкә әзер торабыз. Чөнки аларның изелгән татар шәкертләрен яклап, залим, мөстәбид идарәгә каршы сугышудан башка бер гөнаһсы да юк. Шуна күрә бөтен шәкертләр аларны актык көче белән якларга көрәш белән чыгачак... Мин үзем кадим мәдрәсәдә дүрт-биш ел казый булдым. Гадел, ләкин рәхимсезсең, диләр иде. Минем тәклифем[3] буенча, остазына каршы каты тел әйткән өчен, менә дигән зирәк, үткен егетләр мәдрәсәдән куылдылар. Бу вәхшәтем исемә төшсә, хәзер дә миемә кан йөгерә, күземне кара кан баса. Ул иптәшләргә барып, аякларына егыласым, гафу үтенәсем килә. Ләкин ул үткән инде. Миннән түгел, бөтен татар өчен артта калган... Инде ул кайтмаячак...

---

[1] *Инсан* – кеше.
[2] *Инсаният* – кешелеклелек.
[3] *Тәклифем* – кушуым.

Хәзерге яңарган шәкерт, хәзерге мәдрәсә яшьләре – ул вәхшәтләрне меңнәрчә чакрым узып киттеләр инде! Без «иптәш» дибез! Шуны гамәлгә куябыз һәм куярга тиешбез. Адәмлегебез бездән шуны тели. Менә бу көнге вакыйга безнең бөек тойгыны аңлаганлыгыбызны күрсәтеп бара... Иптәшлек – бу бөек сүз. Без моны аңладык. Моның белән тәбрик итәм... Коры иптәшлек ячтүгел, фикердә, гали мәсләктә[1] иптәшлек – бу тагы да бөегрәк. Бу сүзне дә аңладык, моның белән безне тарих тәбрик итәр, инде киләм асыл максатка... Иптәшләр, без ислах сорадык. Мәдрәсәләргә яңа програм сорадык. Гыйлем сорадык. Җавап урынында безнең ислах хәрәкәтенең башында баручы иптәшләрне мәдрәсәдән куарга хәзерләнәләр. Полиция, жандар, гаскәр чакырмакчылар. Беләсезме, әнә тегендә, канцелярия бүлмәсендә, эреле-ваклы байлар белән эреле-ваклы хәлфә-хәзрәтләр җыелганнар. Алар анда безнең өстән хөкем ясыйлар... Мин ышанам, алардан без издермәбез!..

Тагы ораторны бүлделәр, тагы:

– Юк, издермәбез, актык кангача сугышабыз! – дип шаулап, залны каплnetwork.

Нигъмәт тагы калын трубадан чыккандай тавыш белән үзен тыңларга мәҗбүр итте:

– Инде, – диде, – алдыгызга мин көрәшнең тарихын ачып салыйм! Әлбәттә, беләсез, бу талашларның төп сәбәбе – татар шәкертләренең хәзерге мәдрәсәләрдән риза булмавындадыр. Без кадим мәдрәсәдән дә, менә бу җәдит дигән мәдрәсәдән дә риза түгел. Без якты көнгә чыгарга телибез. Каршы килгән кара куәтләр белән сугышабыз... Эшнең төп нигез сәбәбе менә шунда. Әмма монда әле аерым сәбәпләр дә булып үтте. Сез беләсез, Кәрим Гайфи дигән бер мөстәбид мөгаллим бар. Бу адәм Истанбулда, Солтан Хәмид[26*] истибдадында[2] тәрбияләнеп кайткан бер мәхлук, үзен галим диләр. Анысын белмим, әмма мөгамәләсе бик әшәке: бер шулай, безнең гайрәтле, фидакяр иптәшебез Җиһангир белән менә шул Истанбул җимеше арасында юктан гына сүз чыга, Кәрим Гайфинең урынсыз бәйләнүенә каршы Җиһангир тиешле җавап бирә: «Сез – мөгаллим, сезнең вазыйфа – укытмак. Әмма коридорда «Марсельеза» җырлауга каршы бәйләнеп йөрү сезнең эш түгел, бу – жандармлык. Моны назыйр карар», – ди. Талаш зурая. Кызу канлы Кәрим Гайфи: «Бу митинг йорты түгел, гыйлем йорты. Сәяси җырлар белән шәкертнең башын әйләндерүчеләргә монда урын юк, мин сезне мәдрәсәдән кудыртырмын», – дип акыра. Җиһангир да яман кыза, хәлфәне мыскыллап көлә: «Тапкан бер сүз: имеш, мәдрәсәдән кудырам, бик исем

---

[1] *Гали мәсләк* – югары идея, тоткан юл.
[2] *Истибдад* – деспотизм, тиранлык.

китте инде; син үзең бер тиен, мәдрәсәң ике тиен», – дип ычкындыра. Сүз зурая. Талаш, кычкырыш. Башкалар да кушылалар. Хәлфәгә сөйләргә бирмиләр, сызгыралар, көләләр: «Истанбул» дип, «Солтан Хәмид җимеше» дип мыскыллыйлар. Кәрим Гайфи, ачуына сыеша алмыйча, кызара, бүртә дә, мин мәсьәләне идарәгә куячакмын, кудыртачакмын дип, үзенең кимия[1] бүлмәсенә кереп китә. Бүлмәнең ачкычы ишекнең тышкы ягында эленгән көйгә кала. Берничә сәгатьтән соң чыгарга дип ишеккә килсә – тыш яктан бикләгәннәр. Дөбердәтә, кычкыра башлый. Кайсылары көлә. Кайсылар, ачарга теләсәләр дә, ачкычны тапмыйлар. Бер ачкычны да ярата алмыйлар. Ничә сәгатьләр гомер үтә, хәлфә түземсезләнеп кычкыра: «Түзәр хәлем калмады... монда дару исе харап, һава бетте», – ди. Шуннан инде, ишекнең тупсаларын җимереп, Кәрим Гайфине чыгаралар. Ул агарынган, хәле беткән. Ат белән өенә озаталар. Берничә көн мәдрәсәгә килә алмый. Вакыйганы эчке-тышкы идарәгә ялган төс биреп, язу җибәрә. «Мондый эшләр Баязид карый, Җиһангир яки Сәйфуллин кебек әдәпсезләрнең генә этлеге», – ди... «Җиһангир мәдрәсәдән куылсын!» – ди.

Тикшерү башлана. Сәйфуллин авырый. Баязид карый инде күптән үк квартирга чыккан. Мәдрәсәгә җүнләп килми, җитмәсә тагын хәзер зинданда утыра. Җиһангирдән сорыйлар. Ул талашканын яшерми. Әмма кимияханәне бикләп, ачкычын югалтучы мин түгел, ди. Эчке идарә бу эшне мәдрәсәгә акча белән ярдәм итүче байлар катнаша торган тышкы идарәгә күчерә. Шул көнне кич мәдрәсә эченә җилем белән басылган «Яшен», «Без», «Шәкерт флагы», «Штык» кебек гәзитләр тарала. Боларның һәммәсендә Кәрим Гайфидән көлеп, ачы мәкаләләр бар. Тикшерү тагы киңәя: кем баскан? кем язган? Нәтиҗә болай килеп чыга: фатирда торып шундый нәрсәләрне яшерен бастырган өчеп ике шәкерт эләгә. Ул мәкаләләрне язганнар дип дүртәү гаепләнә. Бу эшләрне тикшергән чакта, эчке идарәдә шәкертләр вәкиле сыйфаты белән катнашкан Сәйфуллин каты сүгенде дип, мәҗлесне ташлап чыкты дип, карарны ялган буяуда аңлатып, шәкерт, котыртты дип, җавапка тартыла. Һәрвакыт дәрес ташлап, сәясәт артыннан йөргән, мәдрәсәдә яшерен сәяси түгәрәкләргә Булатны чакырып китергән, вакытлы-вакытсыз. «Марсельеза» [27*] җырлаган өчен дүртәү табыла; бөтен бәлаләрнең башлыгы булган өчен Җиһангир беренче җинаятьче итеп карала, иптәшләрен бомба ясарга өйрәтәм дип маташкан өчен тагы берәү хөкемгә алына – шулай барлыгы унике шәкертне мәдрәсәдән сөрергә карар бирәләр...

Нигъмәт, вакыйганы шулай сөйләп бирде дә, җыелыш өстенә сорау ташлады:

---

[1] *Кимия* – химия.

– Менә, иптәшләр, безне шулай изәргә теләделәр... Ләкин татар шәкерте моңа каршы кул кушырып, тик кенә торып калдымы? Әлбәттә, калмады. Бу хәбәр безгә мәгълүм булгач та, без «Химая[1] комитеты» төзедек: алты хакыйкый әгъза[2], дүрт наиб[3] сайладык. Бу комитет төн буе өзлексез эшләде. Иртәгесен гали, игъдади, рөшди сыйныфларның [28*] һәрбереннән икешәр вәкил чакырып, нинди юл белән идарәгә каршы тору хакында киңәш ясадык. Карар болай чыкты: «Көрәштән туктамаска, ислах өчен сугышны көчәйтергә». Шул ук сәгатьләрдә йөз илле шәкерттән: «Ислах өчен көрәшүдән башка гөнаһысы булмаган иптәшләрне кудыртмау юлында актык көчемә, актык тамчы каныма чаклы көрәшәчәкмен!» – дип имзалар алынды. Моны җыйганда гаҗәп бер дулкын күтәрелде. Бик яшьләрне катнаштырмаган идек, алар: «Без монда ни эшләрбез! Без сездән калмыйбыз», – дип җылый, ялвара башладылар. Картраклар эчендә, кемнәр икәнен әйтмәсәк тә сезгә мәгълүм, биш-ун әфәнде бар. Алар, тиздән мәдрәсәне бетереп, диплом алырга, шунда мөгаллим булып калырга яки идарә аркылы яхшы урын, бай мәхәллә табарга план коралар. Мондый корсак коллары бер читтә калдылар. Әмма башкалар һәммәсе комитетның карарын зур алкыш белән каршы алдылар. Бик күпләр имзалары янына: «җаным фида», дип яздылар... Менә, иптәшләр, каһарман татар шәкертләре, безнең көрәшнең барышы шул рәвешле. Ләкин йокларга ярамый, әле көрәш бетмәгән. Әнә коридорның теге ягында – канцеляриядә эчке-тышкы идарәнең уртак җыелышы бара. Без озын колактан ишеттек, Кадыйр бай әйткән имеш: «Чыкмасалар, полиция ни өчен!» – дигән имеш. «Тагы бик карулаша башласалар, зиндан да ерак түгел!» – дигән имеш. Төтен утсыз булмый, иптәшләр, безнең алдыбызда зур куркыныч тора, сез һәммәгез дә каһарман булыгыз, каты көрәшкә әзер торыгыз! – дигән чакыру белән Нигъмәт сүзен бетерде.

Ораторның актык сүзләре гадәттән тыш көчле, озак алкышлар эчендә югалды. Кул чабулардан зал, коридор, бөтен мәдрәсә яңгырады. Мондый зур шау-шудан, – ахры, бернәрсә булмадымы дип куркынган булса кирәк, – мәдрәсәнең назиры ике идарә җыелган бүлмәдән чыгып карады. Күрү белән, аңа каршы сызгыру, кычкырып мыскыллау китте. Ул тиз генә бүлмәгә кереп югалды, монда тагы яман гөрләп кычкыра башладылар.

---

[1] *Химая* – яклау.
[2] *Хакыйкый әгъза* – рәсми тулы хокуклы әгъза.
[3] *Наиб* – ярдәмче.

# XXVI
# КОЯШ ЧЫКТЫ, НУР БАЛКЫДЫ

Шул шау-шу астында секретарь яңа исем кычкырды: – Сөләйман Сәйфуллин!

Иң арттан урта буйлы, кипкән, каралып саргайган ябык йөзле, җитү чәчле, иске тужуркалы ярлы шәкерт, күзләрендә ут уйнатып, сикереп, тәрәзә төбенә калыкты да ачы, кискен, кызганыч тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Иптәшләр, начар соң безнең хәлләр!..

Аның сүзләре тәртипсез, ләкин дәртле, ялкынлы актылар. Ләгънәт, каһәр белән яндылар. Бөтен җыелышны да шул шәкерт уты эчендә яндырдылар. Ул үзенең яшьлек рәхәте күрмәве белән башлый, җиде яшьтән алып тар, кысык, сасы, татар мәдрәсәләрендә изелеп, ми черетүен сөйли.

– Гыйлем алыйм, адәм булыйм, халыкка хезмәт итим дидем. Кыш укыр өчен җәйләрдә утын кистем, сал чыгардым, җон юдым, Мәкәрҗәдә [29*] половой булдым, Төркстан кышлакларыннан, татар дип, урыс полициясеннән сөрелдем. Их, иптәшләр, азмы изелдек, инде монда тагы изәләр – мәдрәсә тыгыз, сасы, юеш, мөгаллим надан. Ашарга юк, булса – бәрәңге суы белән чи арыш икмәге! Йөзләр саргая, үпкәләр чери, аркалар вакытсыз бөкрәя, күзләр вакытсыз кабергә карый. Их, иптәшләр, кая яшьлек? Кая гыйлем? Кая безгә якты тормыш? Киләчәктә ни бар – анда да мулла бул, үлек күм, «Ясин» чык[30*], «Тәбарәк»[31] укы да садака ал! Их, иптәшләр, дөньяда татар шәкерте кебек бәхетсез яшьлек бармы икән? Без кайчангача болай изеләбез? Әйтегез, иптәшләр, без кайчангача түзәчәкбез!?

Ялкынлы шәкерт үз тавышына үзе буылды, йөрәге кысылды, бугазына килеп тыгылган күз яшен тыярга көче бетте, актык сүзе эчендә тавышы киселде. Бу ялкын шәкертләр йөрәген яндырды: һәммә кеше, урыннарыннан торып, китап, кәләпүш ыргытып, «шулай!», «дөрес!» дип акырып-акырып, кул чабарга тотындылар.

Сөләйман Сәйфуллиннан соң берничә шәкерт аякка баса. Болар да мәдрәсәне, хәзрәтне, байны сүгәләр. Хәлфәләрен канечкечләр, залимнәр, мөстәбидләр дип, яман әче сүзләр белән сыйфатлыйлар да:

– Без изелдек, безне изделәр, инде уянырга вакыт. «Алма пеш, авызыма төш», дип яту ярамый. Татар шәкерте, күтәрел, ислах флагы белән көрәшкә чык, издермә үзеңне! – дип, сүзләрен бетерәләр.

Шул кызу ялкыннар арасында Нәҗип Камал сүзләре салкын боз булып төште.

Озын буйлы, кыска кырылган чәч өстеннән яңа җефәк кара кәләпүш кигән, озын, кара казаки астыннан ак яканы аз гына чыгарып куйган бу егет ягымлы тавыш белән башлады. Ипләп тыңлыйлар кебек иде. Ләкин озак бара

алмады, төрле яктан:

– Кирәкми, сөйләмәсен! Долой! Сатлык! – дип, протестлар яварга тотынды... Сүзе ишетелмәслек дәрәҗәдә гауга күтәрелде, тик рәис Нигъмәт казый, бик каты шылтыратып, мәҗлескә шелтә ясагач кына, оратор Нәҗип Камалга сөйләп бетерергә мөмкин булды:

– Иптәшләр, – диде, – сез мине ялгыш аңладыгыз! Мин татар шәкертенең хәле бик яхшы димим. Мин ислахка каршы тормыйм, програмнарда кимчелек юк дип әйтмим. Мин беләм: татар шәкерте кызганыч. Мәдрәсәләр бер эшкә дә ярамый. Ләкин мин әйтәм: яратмаган кеше үзе чыксын да китсен! Урысча укысын, урыс, Европа мәктәбенә барсын!.. Әмма, менә хәзерге кебек, идарә сүгеп маташуны мин көлке саныйм. Ул хәлфәләрне залим, мөстәбид[1], канечкеч дип хурлап азаплану – ялгыш дип карыйм. Дөрес, алар наданнар. Ләкин залим, канечкеч түгелләр. Чөнки алар кулында бертөрле дә көч юк, куәт юк. Алар канечкеч түгел, алар үзләре кызганычлар. Шуңар күрә аларга каршы: «Ислах флагы күтәр дә көрәшкә чык!» – дип кычкыруны мин балалык, аңсызлык саныйм. Минемчә, алар белән көрәшеп азаплану...

Юк, бусы инде бөтенләй каршы булып чыкты, тагы элеккедән яман тавыш, сызгыру, аяк-кул белән дөбердәү күтәрелде. Нәҗип Камал, бер дә исе китмәгән кеше кебек, кул селекте дә урынына кире утырды.

Аның артыннан тагы берничә оратор-шәкерт кызу кан, дәртле ялкын белән мәдрәсә сүктеләр, идарәне яманладылар, үз язмышларының авырлыгыннан зарландылар, татар шәкертләрен берләшеп көрәшергә чакырдылар.

Мәҗлес кайнаша, шәкертләр үзара сөйләшә, кычкырышалар. Каяндыр арттан берсе «Беренче сада»ны [32*] күтәреп җибәрде:

Кояш чыкты, нур балкыды,
Тәрәзәдән өйгә аркылды.
Ятма йоклап, уян, шәкерт,
Кузгалырга вакыт җитте...

Бөтен зал моңа кушылды, арада атаклы җырчы Сәхип дигән берәү шул көннәрдә генә, «Поляк маршы» көенә салып, «Чыгабыз» исеменнән яңа шигырь иҗат иткән иде. Ул шуның бер-ике сүзен әйтеп бетә алмады, бөтен җыелыш котырып-котырып шуңа кушылды:

Чыгабыз, кузгалыгыз, мәзлум рәфыйклар[1], атлагыз!
Чыгабыз, кузгалыгыз, мәзлум рәфыйклар, атлагыз!..

---

[1] *Мөстәбид* – изүче, деспот.
[1] *Мәзлум рәфыйклар* – кимсетелгән, изелгән иптәшләр.

Зал, коридор – бөтен мәдрәсә бу тавышлар эчендә яңгырап, үзен-үзе тыя алу көчен югалтты. Җыр белән бер уңайдан шәкерт дулкыны үзе язгы ташкынга әйләнә. Утырган залга сыеша алмыйча агылып, коридорга чыга, бүлмәләрне каплый, зур бер дулкын, гадәттән тыш каты акырып, дөнья җимерелгәндәй җәнҗаллы шау-шу белән җырлап, теге эчке-тышкы идарәнең уртак җыелышы барган канцелярия бүлмәсенә таба ташлана.

Монда ишекне эчтән бикләгәннәр иде. Сөләйман Сәйфуллин гайрәт белән тартып ыргытырга чамалады, ләкин ныклы икән – ачылмады. Шулай да шәкерт таралмады. Дулкынның үзәге менә шул ишек төбендә, үзалдына таптанып, баягыдан яман тавыш белән җырлап җибәрделәр:

Аһ, бу татар милләте бер якты көн күрмәсмени,
Күзләгән өмитләре һич вөҗүдкә килмәсмени[1]?
Бетте хаклык, калмады шатлык, хакыйкать яклагыз!
Чыгабыз, кузгалыгыз, мәзлум рәфыйклар, атлагыз!
Чыгабыз, кузгалыгыз, мәзлум рәфыйклар, атлагыз!..

## XXVII
## АЧ КАЛУДАН КУРКАСЫҢМЫНИ!

Мәдрәсәне күтәреп шаулаган тавышка бикле бүлмә эчендә – идарә җыелышында утыручылар каушап, агарынып киттеләр. Мәдрәсәнең башы мөдәррис Гали хәзрәт чәчрәп килеп чыкты. Аның иреннәре агарган, күзләрендә ут яна, бөтен торышы ачу катнаш курку күрсәтә иде. Ул, чыгып җитәр-җитмәс, шунда ишек төбендә бугаз киереп акырган берничә яшь шәкерткә карап кычкырды:

– Әйтегез, Алла хакы өчен әйтегез! Ни бар? Сезгә нәрсә кирәк?!

Арттан кемдер кискен сүз ташлады:

– Ни кирәк булсын? Безгә җавап кирәк! Җавапның вакыты чыкты!

Мөдәррис, әле берәүгә, әле икенчегә әйләнеп, кызу ялварды:

– Нигә бу чаклы шаулыйсыз? Нигә тавышланасыз? Политсә кертәсез, мәдрәсәне яптырасыз лабаса болай!

Арткы кискен тавыш тагы күтәрелде:

– Ябылсын! Кадалсын мәдрәсәң! Ач калудан куркасыңмы, ул ябылса? – дип сорады.

Гали хәзрәтнең йөзе кәфендәй яман агарынды, бу соңгы сүз аның йөрәгенә ук булып кадалды. Ул ни әйтергә, бу хаксызлыкны ни белән үтерергә бер секунд аптырап калды. Ул үзен егерме ел гомерен төрле мәдрәсәләрдә гыйлем алу юлына биргән кеше дип карый. Русиядә Казан,

[1] *Вөҗүдкә килү* – барлыкка, гамәлгә ашу.

Кышкар бетерде. Аннан татар сәүдә кәрваны белән Бохарага барып, җиде ел хөҗрәдә[1] ятты. Аңа канәгатьләнмичә, Мәккә, Мәдинәгә, аннан Истанбул, Мисырга барды.

Шуннан ул үзе иске, кадим мәдрәсәләргә дошман киселде, монда, Русиягә кайтып, Мисыр, Истанбулның яңа мәдрәсәләре кебек мәдрәсә торгызмак булып эшкә тотынды. Юктан башлады, либерал татар капиталистлары ярдәме белән менә шундый зур биналар салды, хәерчеләнеп, акча җыйды, Истанбул, Мисыр күргән яңа тип мөгаллимнәр китертте. Динне, гарәпчәне яңача укытты. Тәфсир[2], хәдис[3], гарәбият[4] өстенә риазыят[5], табигыят[6], татар теле, рус теле дәресләрен арттырды. Ләкин ничек кенә тырышса да, заманны куып җитә алмады. Ничек кенә яңа програм дисә дә, уянган татар шәкертләренең күңелен канәгатьләндерә алырлык бер мәдрәсә ясый белмәде. Ул киң күңелле булырга тырыша, шәкертнең сүзсез бозау булуын яратмый, аларда тәнкыйть көче уянуга карышмый – авыр сүзләрен дә күтәрә иде. Ләкин бүгенге сүз аңа үз гомеренең иң ачы зәһәре булып миенә керде. Аның барлык хезмәте өстенә кара сөрем япты. Ни ди, ни ди бит: «Ач калудан куркасыңмы?» – ди. Моны кем әйтә: еллар буенча янып-көеп тәрбия биргән шәкерте, үз шәкерте әйтә! Мөкяфәт[7] шулмыни? Шуны ишетер өчен төнен көнгә катып эшләдемени?

Хәзрәтнең башы әйләнә язды, шулай да ул бирешмәскә теләде, аптыраулы тавыш белән:

– Ни дисез? Кем?.. Кем әйтә миңа ул сүзне? Гали мөдәррис сүзен аңлый алмый, шәкертләрне ике төркемгә аерып, аның каршысына Җиһангир килеп басты. Ул һөҗүм итәргә, хәзер атылып, җимереп ташларга торган бер ерткыч төстә иде. Килеп тә җитте, кычкырын та җибәрде:

– Хуш!.. Теләсә кем әйтсен! Хәзер аны тикшерә торган чак түгел! Без сездән җавап көтәбез! Гаризада әйтелгән вакыт тулды. Сез менә шуңа ни әйтәсез? Безгә җавап кирәк! – диде.

Сүзен бетерер-бетермәс, янындагы ике иптәшенең кулбашына таянып, бераз югары күтәрелде дә, кайнашып торган шәкертләр дулкыны өстенә карап, тагы яман куәт белән җикеренде:

– Иптәшләр, ни торасыз? Канцелярия алдына садака сорарга

---

[1] *Хөҗрә* – мәдрәсәдәге кечкенә бүлмә.

[2] *Тәфсир* – Коръән сүзләренә аңлатма.

[3] *Хәдис* – Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре дип тәкъдим ителгән сүз-сөйләмнәр җыелмасы.

[4] *Гарәбият* – гарәп теле һәм әдәбияты дәресләре.

[5] *Риазыят* – математика.

[6] *Табигыят* – табигать (фән).

[7] *Мөкяфәт* – берәр эшне башкарган өчен бирелә торган бүләк, компенсация.

килдегезме? Кая телегез? Кая сүзегез?! Ник дәшмисез?!

Коридор тагы гөрли, тагы хәрәкәт башлана. Сөләйман Сәйфуллин, тагы күтәрелеп, шәкертнең изелүе, идарәнең истибдады[1] турында кызып, ялкынлап сүз башлый, унике иптәшне кудыртмау турында көрәшкә чакыра...

Гали мөдәррис үзен-үзе баскан иде инде. Агарынган йөз, сабырлы тавыш белән:

– Һичкем изми, һичкем кумый. Без тикшерергә җыелдык, гаебе булмаса, берәү дә чыгарылмас, ярым сәгатьтән һәммәсе мәгълүм булыр, Алла хакы өчен сабыр итегез... шауламагыз... Болай кыйлансагыз, политсә килер, мәдрәсәне ябар, – диде.

Шәкертләр арасында:

– Юк инде, бик күп көттек. Вәгъдәләр бушка чыга барды, – дигән кебек шау-шу башланса да, Нигъмәт казый, югары күтәрелеп:

– Иптәшләр, бераз сабыр итүдән зыян юк!.. – диде.

Коридор бераз гына тынычлангандай булды.

## XXVIII
## ҖИҺАНГИР БЕЛӘН СӨЛӘЙМАН СӘЙФУЛЛИН

Шул моменттан идарәләр файдаланып калырга уйладылар. Гаепләнгән шәкертләрне берәм-берәм чакырып сорарга теләделәр.

Иң беренче Җиһангир чакырылды. Ләкин ул ачык ишектән канцеляриядәгеләргә ишеттерерлек итеп кычкырды:

– Булмас. Мин анда кереп җавап бирүне үземә ваклык саныйм! – диде.

Аның артыннан чакырылган кызу, ялкынлы Сөләйман Сәйфуллин да кермәде. Нигъмәт казый, көлә биреп керсә дә, шатлык ясамады:

– Мин, – диде, – чакырткач, кермәүне килештермәдем, ләкин җавап бирмәячәкмен. Әгәр дә шәкерт алдына чыгын, ачык җыелышта тикшерсәгез, бәлки бер-ике сүзем булыр иде, – диде дә ишеккә борылды.

Бу юлның файда итмәве идарәгә ачык күренгәч, тиз, җиңел уйлаучан Гали мөдәррис бер хәйлә юлына керергә исәпләде:

– Менә хәл шулай. Без кулдан килгәнчә эшлибез... Мәдрәсә таралмасын. Унике шәкертне куып чыгаруга минем үземнең дә җаным әрни... Сез әйтегез, гафу үтенсеннәр, моннан соң идарәнең куйган тәртибе буенча яшәргә кулдан язу бирсеннәр – шул вакыт һичкем куылмас! – дип, йонны уңайга сыпырмак булды.

Нигъмәт казый бөтенләй ачу белән кабарынды, сезнең белән уртак телем юк минем, дип, чыгып китәргә атлады, шулай да үзен көчләп туктатты,

---

[1] *Истибдады* – башбаштаклыгы.

гаҗәпсенгән кискен тавыш белән әйтте:

– Нинди гафу ул тагы? Аларның гөнаһсы нәрсә? Ни өчен гафу үтенерләр алар? Революция һичбер вакыт иске тәртип көчләре алдында гафу үтенми! Шәкерт хәрәкәте – үзенә күрә бер революция ул, – диде дә, җавап көтми, кызулап коридорга чыкты. Анда тагы җыелып өлгергән шәкертләр Нигъмәтне сырып алдылар:

– Ни сорадылар? Ни әйттең?

Ул сөйләп бирде. Шәкерттә тагы гайрәт кайнап китте.

– Яшәсен татар шәкертләре! – дип акыра башладылар. Инде хәзер идарә бүлмәсенә кергән һәрбер шәкерткә: «Курыкма! Гафу үтенмә! Монда синең артыңда ике йөз иптәшең әзер тора!» – дип боерык биреп кала башладылар.

Бер сәгатькә якын тынлык булды.

Шуннан соң идарә бүлмәсе ачылды. Авыр, салмак атлап, назир килеп чыга да әйтә:

– Җиһангир белән Сөләйман Сәйфуллин идарәнең чакыруына илтифат итмәделәр. Алар тагы бер тапкыр җавапка чакырылалар. Әгәр бусында кермәсәләр, мәдрәсә идарәсе аларны үз шәкертләре сафыннан чыгарылган дип хисап итәчәк. Керәсезме, юкмы? – ди.

Җиһангир шунда, назирның янында ук иде. Кискен, мәсхәрә тавыш белән өзеп ташлады:

– Бар әйт: теләсә нинди хөкем чыгарсыннар. Мин анда кереп җавап бирүне үземә хурлык саныйм! – диде.

Ишек ачык иде. Аның һәммә сүзе идарәгә ишетелә торды.

Назир шунда таба кереп китүгә, Җиһангир тагы ачы сүзләр ата башлады:

– Иптәшләр!.. Актык минутлар җитә!.. Бездә җан бармы, юкмы? Бездә шул биш-ун надан хәлфә белән биш-ун юан корсак бай алдына тезләнмәслек намус бармы? Бездә үз теләгебез өчен көрәшерлек гайрәт бармы? Булса, ни эшләп торабыз!.. Сез ни көтәсез?

Оратор артык ашыга, күзләре канланып, үз тавышына буылып бара. Аның ташланган сүзләре ялкынланып чәчрәгән ут кебек дулкынны яндырып җибәрәләр. Тагы шаулашу эчендә:

Кояш чыкты, нур балкыды, тәрәзәдән өйгә аркылды.
Ятма йоклап, уян, шәкерт! Кузгалырга вакыт җитте... –

дип күтәреп, акырырга тотыналар. Бу соңгы җыр бөтен бүлмәләрне, коридорларны тавыш, шау-шу белән тутыра. Куркыныч, кискен хәрәкәт башлана. Тегендә, идарә җыелышында утыручыларның каушавы чиккә җитә. Үзенең җөббәсе белән җилләнеп, тагы түземсез кызу кан белән Гали хәзрәт

килеп чыга да шәкерт дулкынының үзәгенә, җыелыш залы алдына ташлана. Әйтерсең, менә хәзер һәлакәт килеп баскан инде, шундый курку катнаш газап белән сүз башлый: «Милләт мондый яңа мәдрәсәләргә мохтаҗ, без кулдан килгәнне эшлибез, мөмкин булган барлык ислахны кертергә әзер торабыз», – дип тезәргә тотына. Аның сүзен бүләләр – арадан кемдер;

– Бары да ялган, бары да күз буявы – бөтен гаеп идарәдә генә, – дип ычкындыра.

Гали хәзрәт тагы йөрәгенә чәнчелгәндәй кыза:

– Бу сүзне кем әйтә? Кем әйтә? Их, җаным, бик артык баласың. Артык сабыйларча карыйсың! Бир миңа берничә миллион акча! Мин Парижның беренче университеты кебек рәвешкә кертеп мәдрәсә төзермен! Ул кирәк. Бу кирәк. Без ачбыз. Моннан чыккач, эшкә ярамыйбыз, дисез. Урыслар фәлән кыйла, төгән кыйла, безнекеләрдә юк, дип сүгәсез! Мин үзем дә аны беләм, кулдан килгәне бары да эшләнә. Әмма юкны кайдан алыйк: кая зур биналар? Кая яхшы мөгаллимнәр? Кая яхшы дәреслек китаплар? Кая һәртөрле фәнни әсбаб алырга байлык? Кая акча? Татар дөньясында булмаганны бүген генә мин кайдан алыйм?! Болар күктән яумый! Сез торасыз да идарәне сүгәсез... Идарәне гаеплисез, безнең белән көрәшкә чакырасыз... Бу юл – хата юл. Сез – эшче түгел, без – фабрикант түгел. Көрәшү, эш-сабак ташлау юлы – монда туры килми. Монда хәлфә, шәкерт – һәммәсе кулга-кул биреп, ярдәмләшеп барырга кирәк... Сез чыгасыз да: хәлфәләр изә, идарә изә, әйдәгез көрәшкә, дип акырынасыз!

Гали мөдәррис сүзгә оста санала иде. Күп вакыт аны яраталар иде. Ләкин бу көннәрдә аны җүнләп тыңларга да теләмиләр. Башка вакытта идарәне яклап кычкырыша торган биш-ун шәкерт – җасус, карагруһ[1] бар. Бүген алар да, яшеннән качкан шайтан кебек, әллә кая яшеренгәннәр. Алардан берсе, Миһран, арттарак качып, хәзрәтнең сүзенә кул чабарга теләп карады:

– Дөрес! Бик дөрес! – дип кычкырды. Ләкин бу шәкерт массасының канын кыздырды, йөрәген җенләндерде генә: Миһранның ялгыз алкышлары, «дөрес», «дөрес» дип кычкырган тавышлары аңа каршы кузгалган талаш, кычкырыш эчендә батты. Шул гауга эчендә Нигъмәт казый, шәкертләрнең җилкәләренә, урындыкларга басып, тагы сүзгә атылды:

– Монда, – диде, – зур тарихи хата бар. Егерменче йөз тормышы өчен хәзерләнергә тиешле яшьләрне һәммә татар халкы менә шул дини мәдрәсәләргә китереп ябалар. Монда иске-яңа схоластика белән, иске-яңа чүп-чар белән, иске-яңа кирәксез нәрсәләр белән яшь буынны агулыйлар,

---

[1] *Җасус, карагруһ* – шымчы, революцион хәрәкәткә каршы оешма вәкиле.

бөтен яшь буынны мулла булып садака алудан, үлек күмүдән башкага яраксыз калдыралар... Русияне каплаган зур революция аркасында татар мәдрәсәсе, татар шәкерте дә хәрәкәткә килде, реформалар өчен көрәш башлады. Пролетариатның эш ташлавы кебек, мәдрәсә ташлап, уку ташлап, иллешәре-йөзәре чыгып китүләр башланды... Без чыгабыз, дибез. Һәм чыгачакбыз. Бу ташлап чыгулардан, бу көрәшләрдән безнең үзебезгә файдасы тиярме, юкмы – әмма бу чыгулар, бу көрәшләр бөтен татар алдында шул югарыгы, тарихи хатага каршы протест итү хезмәтен үтәячәкләр!.. Без бер бу идарәгә, бер Гали хәзрәткә генә каршы сугышмыйбыз, бәлки барлык шул тарих белән килгән каралыкларга, тарихи хаталарга каршы сугышабыз. Менә бу протест, бу сугыш – бездә дә менә шундый шәкерт ихтиляллары[1] рәвешендә дөньяга бәреп чыга... – диде.

Тиз, янучан, тиз кабынучан Сөләйман Сәйфуллин тагы урындыкка сикереп менде. Йөзе агарынган. Күзендә көрәш, протест уты ялкынлана. Җитү чәчләрен тузгытып җибәрә. Ачы, кискен тавыш белән кычкыра:

– Әйтегез, безниләр теләдек? Без нәрсә өчен көрәшәбез?! Безгә ничә тапкыр вәгъдә иттеләр?.. Ничә чапкыр алдадылар? Инде тагы алданабызмы? Тагы шул юан корсак байларга, надан хәлфәләргә ышанабызмы? Булмас, аларга ышаныч калмады... Барыбер берләшеп көрәшкә ташланудан башка чара калмады...

Ул сүзен бетерә алмый, җырчы Сәхип башлый, бүтәннәр кушылып, тагы дөнья селкетеп, «Марсельеза» җырларга тотындылар:

Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Ул тормыштан илгә файда юк;
Булса, байлар илә тик түрәләр
Аркабызда рәхәт күрәләр...

…Чыгабыз … кузгалабыз … мазлум рәфыйклар, атлагыз!

## XXIX
## АХМАК БУЛМАГЫЗ!

Җыр, гауга, тавыш, кычкырыш белән бөтен мәдрәсә селкенгән минутта идарәнең ишеге тагы ачыла да, көтелмәгән кеше – Кадыйр бай үзе килеп чыга. Өстендә кара постау тышлы, кама якалы, төлке тамак тун. Башында колакка төшереп киелә торган каракүл бүрек, аягында американ читек өстеннән кыска кунычлы кара пима. Аның йөзе аксыл-кызгылт, сакалына чал кергән, күзләре ачу-шелтә белән карыйлар. Сабыр атлап бусаганы кичте дә, кайнап торган шәкерт дулкынына карап, акрын тавыш белән әйтте:

---

[1] *Ихтилал* – баш күтәрү, бунт, революция.

– Бу ни тавыш! Бу ни башбаштаклык! Сезгә ни кирәк? – дип шелтәләп сорады.

Байның сүзе бөтен шау-шуны, әйтерсең, кайчы белән кисеп төшерде: һәммәсе баскан җирләрендә каткан килеш шым булдылар. Тик Җиһангир генә алгарак сузылды, шунда, стенага, агач рамкалар белән пыялалап асылган мәдрәсәнең уставы-програмы янына ук килде дә өзеп әйтә салды:

– Ни кирәк булсын?! Без үзебезнең кирәкләрне санап, бер атна элек гариза бирдек... Инде вакыты үтте... Безгә җавап кирәк, безгә ислах кирәк! – диде.

Кадыйр бай авыр борылды, таягын ипләбрәк тотты да кечкенә ахмак баланың җүнсезлегенә каршы ясаган шелтә тавышы белән кисеп әйтте:

– Ахмак булмагыз! Ислахны шулай сорыйлармыни? Укыткан хәлфәләрегез сезгә ни кирәген белмиләрмени? Йомырка тавыкны өйрәтәме? Ахмак булмагыз!.. Барыгыз, таралыгыз! Бу ни хәл бу! Остаз юк, итагать юк, бу нинди адәм хурлыгы?! Баставайт итәргә сез рабучимени...[1] Гали хәзрәт, мин инде кайтам, минем актык сүзем шул: ул уникe ахмакны бүген, менә хәзерге сәгатьтән калдырмый мәдрәсәдән куыгыз! Безгә андый дәһри[2] башлар кирәкми. Андый итагатьсезләргә безнең бер тиенебез дә әрәм!.. – дип шулай бер үгетләп, бер боерыклап, сүзен бетерер-бетермәс кузгалган Кадыйр бай ике адым да атлый алмады, Җиһангир, якындагы урындыкка сикереп менде дә, җитү чәчләрен туздырып, кулларын селкеп-селкеп, шунда, стенага рамка белән пыялалап асылган устав-програмга төртә-төртә, акырды:

– Иптәшләр, татар шәкертләре! Күрәсезме, ишетәсезме? Безнең сораганнар биреләме? – юк, бирелми. Безнең теләкләрне байның, хәзрәтнең читек табаны таптый. Вәгъдәләр юкка чыга. Һаман иске програм кала. Уникe иптәшебезне ни эшләтәләр? – байның кәефе өчен аларны урамга сөрәләр. Аларны безнең арадан куып чыгаралар!.. Аларның гөнаһы нәрсә? Алар нинди җинаять өчен мәдрәсәдән куылалар? Бездә җан бармы? Гайрәт бармы? Без моңа тыныч карап калабызмы?..

Бөтен бүлмәләрдән, коридордан, залдан бөтен дөньяны җимергән сыман бер каты шау-шу, гауга, талаш, кычкырыш күтәрелә, тагы әллә ничә яктан берьюлы:

Чыгабыз... кузгалыгыз... атлагыз... –

дип җыр кузгала. Шул тавыш, гауга эчендә Җиһангир урындыктан сикереп төшә, шунда, стенага, алтынлы рамка эченә пыялалап куелган уставны, иске програмны Сөләйман Сәйфуллин белән икәүләп ике ягыннан күтәрәләр дә,

---

[1] *Баставайт итәргә сез рабучимени* – эш ташларга сез эшчеләрмени.
[2] *Дәһри* – динсез.

яшен тизлеге белән тартып төшереп, күз ачып-күз йомганчы өченче каттан түбәнгә – баскыч төбендәге таш идәнгә атып җибәрәләр. Ул анда төшә дә, пыялалары челпәрәмә килеп ватыла, рамнары шартлап сыналар.

Шәкерт дулкыны тагы бер искиткеч дулау, ашкыну белән хәрәкәткә килә. Бер якта: «Бетсен, кадалсын, ват, җимер барын!» – дигән тавышлар кузгала, икенче яктан зур шатлык белән тагы «Чыгабыз»ны, «Сада»ларны җырларга тотыналар. Устав – иске програм үзенең пыяласы, рамнары белән таш идәндә челпәрәмә килеп он булды, шул минутта ук игъдадиның[1] ике сыйныфында урындыклар бәреп, тәрәзәләр ватылган тавыш, берничә бүлмәдә зур лампаларның очып төшүләре ишетелде. Идарә бүлмәсендәге байлар, хәзрәт-хәлфәләр котлары очып килеп чыктылар...

Бу ни хәл? Кыяматме? Мәхшәрме? Дөнья җимереләме? Әйтерсең, диңгез котырды; әйтерсең, котырынган дулкыннар эчендә көрәшеп барган корабның актык куркыныч һәлак минуты килеп җитте. Гали хәзрәт үзен шундый хәлдә тойды. Ләкин шәкертләрнең йөзләрендә, күзләрендә, бөтен кычкырыш, талаш, җыр тавышларында канлы сугышлар, корбаннар соңында, менә-менә хәзер генә зур шәһәрне кулга алган гаскәр ашкынуы кайный иде. Гүя бөтен бәхетсезлекләрнең актык минуты килде, гүя шул алтын рамкалы пыяла эченә куелган иске устав (низамнамә) – програмны атып бәреп көл итү белән аларны изгән, кан-яшь аглаткан тарихи каһәр җиңелде, гүя шуның белән үзләрен баскан, бәхетсез ясаган иске, кара тормыштан мәңгегә котылдылар да яңа, якты, азат, матур көннәргә килеп чыктылар. Шәкерт дулкыны менә шундый шатлыклы ялкын эчендә кайнады.

Ләкин бу минут озакка сузыла алмады. Низамнамә үзенең рамнары, пыялалары белән түбәнгә – таш идәнгә төшеп чалдыр-чолдыр ватылып та өлгерде, шул ук секундта ватылган пыялалар өстенә аксыл-сары шинельле, җиз төймәле, мылтыклы, кылычлы жандарм офицер ротмистр килеп тә басты. Ротмистр, бернәрсә аңламаган кеше кебек:

– Бу ни хәл? Бу нинди бунт!? – дип, як-ягына каранды.

Ул арада кылычлы, мылтыклы, кара-күк шинельле жандарларның, полициянең, солдатның саны артты. Болар, бунт эченә килеп кердек бугай дигәндәй, куллары белән мылтык сөңгеләренә тотына биреп, тимер баскычтан югары менә башладылар.

Әйтерсең, һәммәнең өстенә салкын су сиптеләр.

Шау-шу кинәт басыла. Дулкын һичбер булмаган дәрәҗәдә тына. Башта бераз аптырап катып калган, үзен югалткан Гали хәзрәт тиз айныды. Шпорларын шалтырата биреп, югары таба менеп барган ротмистрга каршы

---

[1] *Игъдади* – хәзерлек сыйныфы.

килде. Ватык русча белән елмая төшеп әйтте:

– Гаҗәпләнмәгез! Үзара бер аңлашылмау гына! – диде.

Кадыйр бай китеп өлгермәгән икән. Ни булганын тиз генә сизенә алмады, өнме, төшме дигәндәй, аптырап калды. Ротмистр аны күргәч, тагы артыграк гаҗәпләнеп, каршына килде перчаткасын сала-сала:

– Кадыйр Хәйретдинович, сез ничек монда? – дип сорады да шунда ук өстәде: – Гафу итегез! Югарыдан боерык буенча мәдрәсәдә тентү ясарга тиешле булдык! – диде.

Бәй, алай икән, миңа барыбер дигән мәгънә белән елмаеп, кул селекте дә түбәнгә төште. Мәдрәсәгә банилык итеп,[1] бүген тышкы идарәгә килгән бүтән байлар да аңа иярделәр.

Ротмистр боларны туктатырга, тотарга уйлады, ләкин Кадыйр байның арада булуы аңа комачаулык итте. Һәммәсе билгеле, таныш байлар булганга, борчылырга сәбәп тапмады. Гали хәзрәткә килеп, ордерын күрсәтте.

Бөтен мәдрәсәдә, һәммә шәкертләрдә тентү башланды.

## XXX
## ТЕНТҮ БАШЛАНА

Эчтә тентү башланган чакта өч катлы таш мәдрәсә тышкы яктан атлы казачий гаскәр белән камалып алынган иде инде. Почмакларда – атлы казачий, ишекләрнең һәрберендә мылтык белән ике солдат каравыл тора. Болар һичкемне кертмиләр дә, чыгармыйлар да. Бу куркыныч вакыйга ишетелү белән, мөселман агай-эне, куркып, кызыксынып, мәдрәсә тирәсенә агыла башлады; урамнар, чатлар, койма буйлары, күрше йортлар – һәммәсе шул курку катнаш кызыксынган татарлар белән капланды.

Ротмистр эчтә үз эшен кызу, тәртипле алып барды. Ул иң элек Гали хәзрәтне, назирны, барлык мөгаллимнәрне канцелярия бүлмәсенә кертеп яба да ишек төбенә кораллы солдат куя. Шәкертләрне ничек туры килсә шулай төрле бүлмәләргә тарата да, ишекләргә сакчылар бастырып, актарынырга тотына. Иң элек уку-дәрес бүлмәләрендә парталарны тикшерәләр. Аннан урыс цензоры кул сукмаган һәммә китапларны, дәфтәрләрне алалар. Зур-зур төргәкләр ясап, төенчекләргә бәйли баралар. Аннан шәкертләрнең үзләренә керешәләр – аларның кесәләрен, чалбар, күлмәк эчләрен, читекләрен капшап, һәртөрле кәгазьләрне, хәтер дәфтәрләрен җыялар. Болар тагын исемләнә, аерым бәйләнә дә җинаятьле төргәкләр сафына тезеләләр.

Аннан соң ашханәгә, утын бүлмәләренә, ятакханәгә төшеп, ташландык кара керләргәчә актаралар. Бу аскы катлауларга төшкәч, алдынгырак

---

[1] *Банилык итеп* – ярдәм итеп, иганәче буларак.

шәкертләр арасында бераз борчылу башлана. Сөләйман Сәйфуллинга зинданга керер алдыннан Баязид карый кечкенә төенчек биргән булган икән. Шунда теге ясарга уйланган шәкертләр «партия»се, «Фидаиләр»[33*]нең програмы белән бомба ясарга өйрәткән бер кәгазь бар имеш, диләр. Аннан да бигрәк, Булатның кечкенә бер хат кисәге – Разия Ширинскаяның түгәрәкләре уңае белән язылып та җибәрелми калган бер мәктүб шул арада булган имеш, диләр. Бу чын булып чыкты. Ләкин хат иясе Сәйфуллин агарынып, ни эшләргә белми катып торды да кинәт кәгазьне, авызына кабып, чәйни башлады. Йотарга теләде – шунда, эчтә череп, юк булыр дип өметләнде, ләкин хат бугаздан үтмәде; инде бөтенләй аптырап калган минутта, тентүче солдатның икенче якка караганын гына көтте дә тәрәзәнең форточкасына ташламак булды. Моны ефрейтор сизеп калды да, ерткыч этнең куянга ташлануы кебек, Сөләйманның өстенә ыргытылды, бик зур нәрсә тапкан кебек: «Бу кәгазь Сөләйман Сәйфуллин кулыннан тартып алынмыштыр. Тәрәзәдән ташларга уйлаган иде», – дип, русча, полиция протокол теле белән дәфтәргә теркәп куйды.

Мәдрәсә яшьләре арасында Разия туташның сәяси түгәрәкләренә йөрүче биш-алты шәкерт бар иде. Бу хатларның солдат кулына керүе аларны бик куркытты, Разия да арага керде бугай дип, үзара борчылдылар.

Өч йөзгә якын шәкертне, өч катлы зур мәдрәсәнең ятак, аш-чәй, дәрес бүлмәләренең һәммәсен тентеп бетереп, мөгаллимнәр бүлмәсе – канцеляриягә килгәндә, таң якынлашкан иде.

Ротмистр үзе янына околоточный жандарм, городовой, ике пүнәтәйне алды да, бу бүлмәгә кереп, яшел постау ябылган өстәлнең янына урындыкка утырды. Ул бик арыган, талган, бөтен торышында ачулы хәлсезлек күренә иде.

Киерелә төшеп утыра да, озак көттерергә мәҗбүр булуы өчен гафу үтенеп, берәмләп сорый, тикшерә башлый. Мөгаллимнәр йокысыз үткәрелгән борчулы төн буенча бик җәфаланганнар иде. Мәдрәсәнең ябылу куркынычы да һәрберенең күз алдында булды, үзләренең зинданга алыну, сөрелү кебек хәлләргә дучар ителүләре дә аларның хыялларыннан китмәде.

Беренче сорау мәдрәсәнең рәсми башлыгы, мәхәлләнең имамы Гали хәзрәттән булды. Аның русчасы такыр иде. Шулай да: «Мәдрәсәдә күпме шәкерт бар? Кайда басылган китаплардан укытасыз? Ничә мөгаллим? Аларга нинди акчадан, күпме түлисез? Гомумән, мәдрәсә кемнәрнең акчасы белән яши?» – дигән кебек сөальләргә, мәшәкать беләнрәк булса да, җавап биреп котыла алды. Акча ягын сораганда, үзеннән арттырып: «Тик менә милләтнең

үз ярдәме белән, байларның иганәсе[1] белән генә барабыз, хөкүмәт хәзинәсеннән безнең укыту-мәдрәсә эшләренә бер тиен бирелми», – дияргә уйлаган иде. «Бу сүзне хөкүмәткә каршы фикер бар дип аңлауларыннан курыкты да телен тешләде. Сүзең көмеш булса, тик торуың алтын, дигән сүз менә шундый урынга карап әйтелгәндер дип, эченнән тынды.

Аның артыннан башкаларны сорауга күчәләр.

Мөгаллимнәр арыган, куркынган. Русчалары бик зәгыйфь, бик күп урында үзенең ярты теле белән тылмачлык итү хезмәте Гали хәзрәтнең үзенә төште.

Иң соңыннан соралган кеше мөгаллим Кәрим Гайфи булды. Околоточный башка мөгаллимнәрнең кесәләреннән чыккан хатларны, кәгазь, дәфтәрләрне протоколга теркәп маташа иде. Жандарм ротмистр, арыган ачулы күзләрен Кәрим Гайфи әфәнденең янып торган кызыл фәсе белән озын Истанбул җөббәсенә терәп, сорый башлады:

– Кай җирлек? Кайда укыган?

Боларга җавап кайтарырлык көчне, ничектер, Алласы бирде инде. Ләкин: «Нинди фәннәр укытасыз? Кайда басылган китаплар буенча? Кем әсәрләрен кулланасыз?» – дигән кебек авыр сорауларга килгәч, Кәрим әфәнде бөтенләй хәлдән тая. Сорауны ачык аңлап җитми, ничек итеп җавап кайтарырга да рус сүзләренә телен әйләндерә алмый.

Аның турында усал тел шәкертләр гайбәт сөйләргә яраталар иде. Ул фатир марҗасына: «Самовар куй», – диясе урында авызына бармагын тыгып аңлата имеш, дип гайбәт сөйлиләр иде. Бу бәлки дөрес үк булып бетмәс. Чөнки Кәрим Гайфи яшьлек заманын Истанбул мәктәпләрендә укып үткәрсә дә, кайтканына елдан артык вакыт үтте. Самовар куярга әйтерлек русча сүзләрне генә, әлбәттә, өйрәнгән булыр. Ләкин гыйльми атамаларга, фән, китап исемнәре кебек авыр мәсьәләгә килгәч, аның теле көрмәкләнә, күз алды караңгыланып китә. Үчеккән кебек ротмистр да соравын кабатлый:

– Сез кайсы фәннәрдән дәрес бирәсез? Кайда басылган, кем тарафыннан язылган китаплардан укытасыз? – ди.

Мөгаллимнең тез буыннары йомшый, күзләре әлҗе-мөлҗе килә. Шулай да егылмый, үзен-үзе югалта язган хәлдә, әллә кайдан көчләнеп, каушап килеп чыккан тавыш белән әйтеп ташлый:

– Мы учим... һәндәсә[2]... Жандар аңламый, кабатлап сорый:

– Нәрсә дисез?

Кәрим Гайфи тагы кабатлый:

---

[1] *Иганәсе* – ярдәме.
[2] *Мы учим... һәндәсә* – Без геометрия өйрәнәбез.

– Мы учим... һәндәсә!..

Кәрим Гайфинең эчке-тышкы идарә әгъзалары, шәкертнең кайбер катлаулары арасында нык авторитеты бар. Аңа төпле гыйлем кешесе дип карыйлар. Үз күңелендә шуңа каршы кара кер саклап, янып йөргән икенче мөгаллим Сәлим Фәйзи, бу җавапны ишетү белән, түзми – тыела алмый, мәсхәрәле тавыш белән көлеп җибәрә. Бүтәннәр дә – кайсылары мыек астыннан елмаялар, кайсылары урыс кяфер алдында чатнатып җавап бирә алмаганлык өчен эчтән көенәләр.

Жандарм өмит өзде, бу фәсле җөббәдән җүнле җавап алып булмас дип кистерде дә Гали хәзрәтнең тылмачлык итүен үтенде. Шуның белән мөгаллимнәрне газаплау тәмам булды.

Мәдрәсәдән алынган нәрсәләр алты-җиде йөккә төялеп, жандармерия йортына озатылды.

## XXXI
## КӘРИМ ГАЙФИ

Шул ук вакытта Гали хәзрәтнең үзендә, мөгаллимнәрнең һәммәсенең квартирларында озак тентүләр бара. Алардан да язулар, кәгазьләр, бик күп Мисыр, Һинд, Истанбул басма сары кәгазьле калын китапларны йөк-йөк төяп алып китәләр дә жандармерия йортына китереп актаралар. Хөкүмәт мөселманнар арасында социализм эзли, революция эзли. Шулай ук пантюркизм [34*] эзли, панисламизм [35*] эзли. Шуңа күрә прокломация баскан яки сәяси түгәрәккә йөргән һәрбер шәкерт жандарларны ничаклы борчыса, Кәрим Гайфинең кызыл фәсе белән тар кара җөббәсе, русча китаптан файдалана алмаганга күрә Истанбул басма дәреслекләр буенча укыткан һәрбер мөгаллим, аның квартирында табылган һәртөрле Мисыр, Төркия басма китаплар – охранка алдында гаҗәп зур шөбһәле әйберләр, куркынычлы нәрсәләр булып күренәләр. Урыннарда, губерна жандармерия кәгазьләрендә генә түгел, Петербургта департамент докладларында да панисламизм, пантюркизм белән татар социал-демократиясен бергә бутап, бер аршин белән үлчәп, йөдәп чыгалар. Шул ук Булатны социал-демократ большевик та, шул ук Булатны тагы панисламизм, пантюркизм хәрәкәтләрен яклаучы да ясап буталалар. Мәдрәсәдә, хәзрәттә, мөгаллимнәрдә ясалган тентүләр һәммәсе әнә шул чуалчык хәрәкәтнең тамырын эзләү өчен иде.

Мәдрәсә яшьләренең бу тентүләргә бер дә исләре китмәде. Алар аңа бер шатлыклы бәрелеш кебек, дошман белән якыннан очрашу дигән сыман карадылар. «Мәдрәсә ябыламы? Ябыла бирсен! Кемгә, нәрсәгә кирәге бар!» – дигән сүзләр дә ара-тирә ычкынды. Тентүнең икенче көнендә үк тагы яшерен җилем басма гәзитләр, журналлар басыла башлады. Болар тагы яманрак тел

белән эчке-тышкы идарәгә, Гали хәзрәткә, Кәрим Гайфигә бәйләнергә тотындылар. Гомумән, бу тентүләрнең иң авыр ягы шул ике кешегә төште. Гали мөдәррис йокыдан, аштан калды. Озын төннәрне мәдрәсә ябылу, шәкерт таралу, зинданга алыну, сөрелү вакыйгалары белән саташып чыга торган булды. Күпме көч түкте: бер яктан хөкүмәт алдында күз буяу уе, дин, милләт дип, байларның күңелен аулау, алардан һәр ел, һәр көз, һәр кыш, һәр яз, һәр җәй, аерым күреп, аерым үгетләп, мәдрәсәгә акча-иганә җыйна. Алар көйсез кияүләр – бер генә җире ошамаса, бер нәрсәгә кәефләре китсә, хәзер киреләнәләр, бер тиенем харам булсын дип, тәртә җимереп качарга торалар. Әмма шәкерт моны күрми, белми. Ул Европаны сорый. Бер көндә татарны урыс-француз кебек укытмак була. Шуны эшләмәгән өчен безне сүгә, безгә, идарәгә каршы сугыш ача. Безне дошман күрә. Шул ике ут арасында барганда инде – тагы жандарм, тагы тентү... Бәлки ябылыр, бәлки мәдрәсә генә түгел, үзебез дә ябылырбыз, үзебез дә сөрелербез! Янып, әрнеп, мулла шулай хафаланды.

Ул Кәрим Гайфине эчтән яратмый, артык борын күтәрүчән дип карый иде. Ләкин бу көннәрнең уртак кайгысы аларны нык якынлаштырды. Чөнки бөтен мөгаллимнәр арасында, бәлки бөтен татар дөньясында мәдрәсә башына килеп төшкән бу куркыныч турында башка һичкем Кәрим Гайфи дәрәҗәсендә кайгырмаганын мулла ачык күрде, шул уртак хәсрәт аларның күңелләрен беркетте.

Мулла кайгыны чын уртаклашкан бу мөгаллимен хәзер яңа якты эчендә карады, элек мин аның кыйммәтен белеп бетә алмаганмын дип уйлады. Кечерәк буйлы, нечкә гәүдәле, кызгылт-сары йөзле, кызу канлы, ләкин якты карашлы бу Кәрим Гайфи хәзер аңа бердәнбер төпле игътикад[1], чын гыйлем кешесе булып ачылды.

Бу Кәрим Гайфи үзе яшьтән үк зирәклеге чәчрәп торган бала иде. Остазы Шәймәрдән мулланың димләве буенча, аны мәхәллә бае Кәмал хаҗиның ярдәме белән Истанбулга укырга җибәрделәр. Ул анда рәсми мәктәпкә керде. Әүвәлге елыннан ук үз сыйныфында, иптәшләре арасында беренче барды. Мәктәпне алтын медаль белән тәмам кылды. Әгәр Төркиядә калса, фән дөньясында яхшы урын тотарлык галим булып чыгуында шик ителми иде. Әгәр үзе теләсә, Төркия хөкүмәте исәбеннән Европага укырга җибәреләчәк, аннан бетереп кайткач, Төркиядә профессор булып калачак иде. Ул башта шундый өмитләр, хыяллар белән янды. Үзе исламчы, төрекче булганга, Төркиядә калып хезмәт итүне мәсләгенә каршы тапмый иде: татармы, гарәб яки фарсимы – аерым карамый, мөселман булгач, бары да

[1] *Игътикад* – чын күңелдән ышану, инану, идеал.

бер. Кайсына гына хезмәт кылсаң да, үз идеалыңа хезмәт була дип таба иде. Аңа һәммә мөселман бер милләттән, аларның теләсә кайсына хезмәт тә мөкаддәс булып күренә иде. Ләкин күп мәсьәләләрдә үзенә остаз, җитәкче итеп караган мәшһүр карт мөхәррир Әхмәд Мидхәд[36*] әфәнде аңа кискен киңәш бирде:

– Син, балам, Русиягә кайт. Русия мөселманнары синең хезмәтеңә тагы да артыграк мохтаҗлар. Кем артык сусаган булса, суны иң элек шуңа бирергә кирәк! – диде. Туган ил, туган кардәшләр дә күңелен тарттылар. Гали хәзрәт аңа Истанбулда чагында: «Яңа мәдрәсә, яңа фәннәр, яңача Мәдрәсәи Исламиягә айга җитмеш сум бәрабәренә риазыят[1], табигыять[2] дәресләреннән мөгаллим-мөдәррис итеп чакырды. Менә шуның белән ул җиңелдә, Русиягә кайта алды.

Ул французчадан шәп санала. Дәресләрне Төркиядән алып кайткан берничә французча китап буенча да арттырып зиннәтли иде. Мәсьәләсен, програмын ачык, кискен, тулы белә иде. Күпләрнең гаҗәпләнүенә каршы, сигез ел буенча яшәгән Истанбулда онытыла язган татар телен дә бик тиз арада тергезеп алды. Шулай башлап, ул беренче дәрестән үк шәкертләрне тәмам сихерләде. Мәдрәсәдә аннан башка да Төркиядән кайткан хәлфәләр бар иде. Ләкин аларның анда үз-үзеннән маташып, яки ун грошлык репетиторлардан алган аз-маз гыйлемнәре белән биреп маташкан ярлы сабакларыннан соң, Кәрим Гайфинең ачык, кискен, тулы якты дәресләре һәммә шәкерт өчен, тамактан үтмәслек начар сулар белән интеккән чакта, кинәт саф тау елгасына барып чыккандагы кебек әсәр итеп җибәрде. Бер атна эчендә ул шәкертләрнең иң сөекле остазы булып китте. Кайчандыр үзенең бик сул күренгән дини фикерләре, диннең һәммә нәрсәсен Европа мәдәнияте белән нигезләп сөйләгән дәресләре, дин белән мәдәниятне, гыйлемне берләштергән ялкынлы сүзләре аркасында, шәкерт өчен бик кадерле, бик югары күренгән Гали мөдәррис хәзер үзе дә бик гадигә әйләнеп кала язды. Кәрим Гайфидән соң ул ничектер искерә башлаган кебек күренде. Гайфи хәзер шәкерт алдында мөгаллимлектә идеал, һәр турыда җитәкче үрнәк булып әверелде.

Ләкин бу дәрәҗәдә тиз кабынган мәхәббәт ялкыннары шулай ук тиз сүнделәр дә. Бер ай үтәр-үтмәс Гайфинең исеме начар як белән телгә алына башлады. Аның турында ике агым туды. Мәдрәсә дулкыннарына каршы торып килгән биш-ун карагруһ – шул Нәҗип Камаллар, Миһраннар аны күккә күтәрсә, Баязидлар, Җиһангир, Нигъмәт казый, Сөләйман

---

[1] *Риазыят* – математика (төгәл фәннәр).
[2] *Табигыять* – табигать фәннәре.

Сәйфуллиннар аны аяк астына салып таптарга totындылар.

Кузгатылган һәрбер дулкын, күтәрелгән һәрбер көрәш мөгаллим Кәрим Гайфине шәкерт ялкыны белән капма-каршы куя торган булып китте. Ул бөтен көче белән мәдрәсә яшьләре эчендәге бу хәрәкәтне туктатырга, дулкынны басарга, ялкынны сүндерергә теләде. Яңа фәннәр, яңа програмнар турында шәкертнең үзенең сугышып йөрүен гаҗәп бер начарлык итеп каршы алды. Ул шәкерт җыелышында да, идарәдә дә ачык куйды:

– Шәкертнең вазыйфасы – укымак, укымак, укымактыр. Шәкерт укысын! Гыйлем алсын! Ә фикер, тәнкыйть аңардан шул алган гыйлемнең мәҗбүри нәтиҗәсе рәвешендә үзе килеп чыгар. Шәкерт укудан, гыйлемнән башканы белмәсен! – диде. Шуның өчен һәртөрле шәкерт җәмгыятьләрен яптырту ягын алга сөрде, шәкертләрнең яңа програм турында сөйләүләрен җинаять дип тапты: – Ничек ул? Шәкерт кем? Укыймы, укытамы? Шәкертләр үзләренә програм төзиме? Бу ни дигән сүз?

Революция җилләре аркасында шәкертләр эчке идарәгә вәкил керткәннәр иде. Гайфи моңа да каршы барды, кергән шәкертләрне дә идарәдән чыгарту ягын алга сөрде. Бу турыда шәкерт җыелышларында кызып сөйләде:

– Сезнең вазыйфагыз бер генә – укымак, укымак, тагы укымак, әмма идарә, програм эшләрен мөгаллимнәр карар, – дигән фикерне көчләде.

Шулар һәм аны харап иттеләр. Шәкертләр беренче мәҗлестә аптырап карадылар, икенчесендә аңа каршы бәйләнеп чыктылар, өченче җыелышта, сызгырып, кычкырып сүзен бүлдерделәр.

– Кирәкми! Сөйләмәсен! Бетмәс монда солтан Хәмид агентлары! – дип, зур талаш-җәнҗал куптардылар.

Мөгаллим Гайфи тиз җиңелмәде, үз юлында бара бирде: «Заман үтәр, бу ахмак дулкын басылыр, минем фикерләремне шәкерт аңлар, мин алар файдасы өчен кайгырам, алар мәдрәсәдә гыйлем алсын, мин коры бушбугаз, надан булып калмауларын телим, заман килер, мине шәкерт аңлар, минем фикерем өскә чыгар!» – дип ышанды. Көрәшне туктатмады. Ул үзенең бу фикерләрен революция белән нык бәйләде. Ул революциянең шау-шуын, дулкынын яратмый. Социализмны булмый торган хыял саный. Ләкин иске хөкүмәт мөселман халкын изә. Патша хөкүмәте Истанбулны алу, Төркияне бетерү – йоту планы белән яши. Шуңа күрә иске идарәнең җимерелүе кирәк. Революциянең бу ягы файдалы. Әмма безнең яшьләр аны ялгыш аңлый. Безгә мөселман берлеге кирәк, төрек халкының берлеге кирәк. Моның өчен без бай, ярлы, эшче, фабрикант, алпавыт, крәстиән һәм шәкерт белән мөгаллим кулга-кул тотынып эшләшергә кирәк. Әмма үзара көрәш-талаш – бу хата юл. Революцияне ялгыш аңлау юлы. Революция хөррият бирсен, азатлык бирсен,

шуның аркасында мөселман халкы, төрек халкы бер җан, бер тән булып гыйлемгә, мәдәнияткә барсыннар. Бу жандарларның бер ягы бар. Алар кызыл янгынны басалар. Кызыл утны сүндерәләр. Әмма икенче ягы начар: болар панисламизмга, пантюркизмга каршы баралар Шуны бетерергә телиләр. Шуңа каршы сугыш өчен тентүләр ясап, күпме газап, җәфа бирәләр. Шуңа күрә бу урыс жандарларны яратырга мөмкин түгел...

Мөгаллим Кәрим Гайфи бу араларда көннәрен-төннәрен шулай борчылып кичерде.

Тентүдән соң шәкерт арасында яшерен җилем басмада таралган гәзитләр – ул «Штык», «Шәкерт флагы», «Сөнге»ләр аның бу борчылуларын бергә мең тапкыр арттырдылар. Бу яшь буын кая бара? Шәкертнең акылы кая булды? Монда намус кая, вөҗдан, тәрбия кая? Ни диләр, ничек язалар бит? Аеруча «Шәкерт флагы» гәзитендәге бернәрсә аның җанын зур әрнетте.

Фәс, җөббә кигән бер адәм. Өс-башы, авыз-борыны, күз-кашы нәкъ Гайфинеке төсле ясалганнар. Шул кеше ашыга-ашыга өч катлы таш бинаның нигезен чукый. Бина бераз чалшайган. Тагы бераз чукыса, җимереләчәк. Рәсемнең астына: «Кәрим Гайфи әфәнденең мәдрәсәгә зур хезмәте!» дип язганнар.

«Чеметкеч»тә, шул ук өч катлы бинаның нигезен чуку сәбәпле, ул бөтенләй ауган. Тау астына таба җимерелеп, ишерелеп бара, янында ук Кәрим Гайфи кыяфәтле бер адәм кулына бик зур гармун тоткан, үзе уйный, үзе җырлый:

Ай Дунай, вай Дунай!
Шәкерт изү бик уңай!
Ай Дунай, вай Дунай!
Шәкерт изү бик уңай! –

дип такмаклый. Шул такмак уңаена кыска, бераз кәкре аяклары белән теттереп бии... Берничә мөгаллим читтән карап: «Яшә, Гайфи!» – дип, кул чабып торалар.

Мондый нәрсәләр һәрбер идән асты шәкерт гәзитендә чыга бара. Һәммәсен, күрми калмасын дигән сыман, почта белән аның квартирына җибәрәләр. Гайфи күрә, хафалана, төннәрен йокысыз кичерә. Менә бу тентүдән соң чыкканнары тагы яман котырыналар. Элегрәк номерларда шәкертнең үз эчендәге вак-төяк талашларга, гайбәтләргә, партия интригаларына күп урын бирәләр иде. Тентүдән соң алар бетте, сүз берләшкән кебек, һәммәсе Гайфинең жандарм алдында каушап, калтырап торуы турындагы рәсем белән беренче битне башлыйлар да беренче мәкаләләренә: «Мы учим... һәндәсә!» – дип исем бирәләр. Шуннан көләргә, мәсхәрәгә тотыналар.

«Кара күз» дигән яшерен идән асты көлке журналы соңгы номерына ашыгыч кушымта бирә, аны: «Мы учим... һәндәсә» – дип атый да бөтен бер табак буенча шуны изә. Ахырга килеп, ярым гарәбчә, ярым Истанбулча сүзләр белән бутап, Гайфигә киңәш бирә:

«Сез җәнабе гали, бурая риҗгатеңез белән чук хата эш япмышсыңыз! Монда сезнең кеби әһле истибдадә зәмин юктыр. Сез, әфәнде хәзрәтләре, Госманлы мәмләкәте галиясенә барып, урада солтан Габделхәмидең[37*] зыйльлендә асаяшь бәр кәмал таләбәе мөкаддәс истибдадыңыз тәхтендә тәрбияя чалышмалыйсыз... Әфәндем, ихтираматеме кабулыңызны риҗа идәрем...»[1].

Гайфинең башында бер яктан полиция, жандарм газабы, мәдрәсә ябылу куркусы булса, икенче яктан мәдрәсә идән астының җәфасы аның башын әйләндерделәр. Шулай да ул үзенең иманын, игътикадын[2] бозмады.

«Юк! Юк! Болар һәммәсе вакытлы хәлләр! Дулкын туктар. Елгалар үзләренең ярларына керерләр. Шуннан соң минем фикерем тагы өстен чыгар, шуннан соң шәкерт акылга утырыр – бу эш өчен тик заман кирәк, көрәшергә, тәрбияләргә кирәк!» – дип уйлады.

Көннәрен, төннәрен шул юлда көрәш эшләренә бирергә булды. «Ләкин мәдрәсә ябылмый калса, бу азгын, бозык унике шәкертне куарга кирәк. Чөнки һәрбер начар авыру кебек, начар фикерләр дә йогышлы була; яман чиргә каршы иң яхшы чара – черек әгъзаны кисеп ташлау», – дип уен беркетте. Шуның өчен үз эченнән сугышка әзерләнә башлады.

## XXXII
## НИ БУЛГАН?

Шәкерт кузгалышы элек телләрдә бик нык чәйнәлгән иде. Кадыйр бай белән бәрелешләр, үзенә бер сугыш кебек, калада әкият итеп сөйләнә башлаган иде. Ләкин жандарм ротмистрның җиде төн уртасында атлы гаскәре белән, полициясе белән килеп, мәдрәсәне камап алуы, ишекләргә каравыл солдат куеп, озын төн буенча тентү ясавы – ул шәкерт революциясе турындагы гайбәтләрне күләгә эчендә калдырды.

Сәгате, минуты белән бу шомлы хәбәр шәһәргә таралды, йөз еллар буенча полициядән, патшаның зинданыннан, палачыннан коты очып яшәгән

---

[1] *Тәрҗемәсе:* «Сез җәнабе гали, монда кайтып, зур хата эшләгәнсез! Монда сезнең кебек деспотизм әһленә җирлек юктыр. Сез, әфәнде хәзрәтләре, бөек Госманлы мәмләкәтенә барып, анда солтан Габделхәмид канаты астында үзегезнең камил белемле шәкертләрегез белән мөкатдәс деспотизмыгыз тәхетендә тыныч кына тәрбия эшләре алып барыгыз. Әфәндем, ихтирамымны кабул итүегезне үтенәм...»

[2] *Игътикад* – ышану. инану.

киң татар массасы бу тирәгә агылды. Башта сакланып, ерактан, читтән карадылар. Акрын-акрын кыюланып, зур таш бинаның почмакларына, капкасына чаклы килеп җиттеләр. Берничә сәгать үтмәде, вакытның соң булуына да карамастан, бу урамнар, койма, капка буйлары, күрше йортлар балалар белән, баласын күтәргән кызыл яулыклы хатыннар, авызын ачып, хәйран булып каткан кырма бүрекле егетләр белән, хәерлегә булмас, ата-баба заманыннан бирле күрелгән хәл түгел бу, дип хафаланып караган картлар белән капланды.

Сүзнең, гәп-әңгәмәнең исәбе күренми, агылып киләләр дә, хәйран калып, сорашалар:

– Ни бар?

– Ни булган?

Шуннан китә берсеннән-берсе куркынычрак хәбәрләр!

...Имеш, мәдрәсәдә шәкертләр белән хәлфәләр арасында сугыш булган имеш... Кадыйр байны кыйнап, корсагын ярганнар имеш, бер хәлфәне имгәткәннәр имеш... Ул хәзер больницада имеш, доктор караган да, хәле начар, үләр дип әйткән имеш... Менә шул сугышны басар өчен гаскәр килгән имеш, мәдрәсә ябылачак имеш. Гали хәзрәт богауланган имеш, аңа каты җәза булачак имеш, мөгаллимнәр бары да хөкемгә биреләчәк, шәкертләр һәммәсе сөреләчәк имеш, имеш... имеш...

Шул имешләр эчендә тагы яңа хәбәр туа. Имеш, Вафа хәзрәт бу Гали мулла мәдрәсәсенең бик шәбәеп китүенә эче яна булган имеш. Миһран дигән бер шәкертне чакырып сыйлап, шуның аркылы бу мәдрәсәнең поварын яллаган имеш тә аска, утын бүлмәсенә, бомба белән мылтык куйдырган имеш, үзе, полициягә барып «Алар бомба ясыйлар... Алар патшага каршы баралар... Алар төрек хәлифәсе өчен акча җыялар», – дип әләкләгән имеш, шуннан соң менә гаскәр белән килеп басканнар имеш, диләр.

Тирә-як урамнарны сырып алган халык диңгезе, менә шулай күп төрле имеш-мимеш дулкыннары эчендә гөрләп, кайнап, ни булыр, дип сабырсызланып көткән минутта, кинәт мәдрәсәнең зур ишекләре ачылып китә. Эчтән агылып-агылып полицияләр, солдатлар, пүнәтәйләр, жандармнар чыга башлыйлар. Ул арада гаскәргә дә кузгалырга боерык була. Йөк-йөк төялгән тентү әйберләре хәрәкәтләнә, шулар белән бергә, чиләктән түгелгән бәрәңге кебек, арган-талган ябык, саргылт шәкертләр төркем-төркем урамга ыргылалар. Алар артыннан йокысыз, куркыныч эчендә үткәргән төндә йөзләре бозылып, газапланып беткән мөгаллимнәр күренәләр. Иң гаҗәбе – Гали хәзрәт намаз туны, таягы, бүреге белән, агарынып, ләкин богаусыз-нисез килеп чыккач, тамаша көткән урам җәмәгатенең дәрте сүнеп үк китә. Күпләр үз эчләрендә канәгатьсезлек сизәләр. «Хәерсезне юкка көттем... Юк

өчен төн йокымны калдырдым...» – дип, үкенебрәк таралалар.

Бу вакыт кояш чыгып килә, көн аяз, якты, матур булыр кебек күренә.

## XXXIII
## МИҺРАН СҮЗЕ

Җиһангир уянганда караңгы төшеп киләдер иде инде.

Ул сәгатьләр буенча урыныннан тормый ятты. Тән арган, кул-аяк кузгалырга теләми, ләкин ми ачык, якты, күңел шат.

Мәдрәсә ябылырмы, юкмы? – аның өчен ике ягы бер. Ләкин кичә мәдрәсә яшьләре үзләренең бөтен тарихларында иң матур, иң дулкынлы минутларын кичерделәр. Ул шуның башында барды.

Чыгарылганмы, юкмы? – анысы башка нәрсә. Барыбер актык сәгать суккан, бөтен нәрсә әзерләнеп беткән, йөз илле шәкерт, иртәдән үк төенләп куйган әйберләрен атларга йөкләтеп, өч катлы таш йортны ташларга гына калган иде инде. Эшнең үзәге чыгу-чыкмауның фактында түгел. Мәдрәсә яшьләре үзләренең үлмәгәнлекләрен күрсәттеләр, үз теләкләре юлында көрәшә алырлык куәтләре бөтенләй бетерелмәгәнлеген дөньяга таныттылар.

Эшнең ахыры кая барып терәлер – мәсьәлә анда түгел. Кичәге дулкыннар әле дә күз алдында котырып уйныйлар. Әле дә йөрәккә килеп кагылалар, җанга, бөтен тәнгә дәрт, шатлык бирәләр.

Җиһангир шулай тәмле, дулкынлы уйлар эчендә ләззәтләнеп яткан чакта, кинәт кичә мәдрәсә тентүләре арасында кемнеңдер Һаҗәрне телгә алуын хәтерләде. Тукта, ул кем иде? Миһран бугай. Тукта, ул җасус кайдан, ничек белер? Тукта, ул ни диде әле? «Бишәү җитмәгән, инде алтынчыга кеше хатынын алдый башлагансың икән!» – диде бугай.

Егет ятагыннан сикереп торганын сизми дә калды.

Кемдер ул йоклаганда бакча як тәрәзәне ачып куйган. Бүлмәдә һава күп, саф. Ләкин бераз юеш. Бераз дымга тартым. Җиһангир күлмәкчән тәнгә пальтосын япты да ачык тәрәзәгә таба килде... Юк, һава тагы бозылган икән! Иртә белән тентүдән таралганда нинди матур, якты көн булмакчы иде. Хәзер тышта җил уйный. Күк ачулы. Чытык йөзле. Куе кара болытлар, бөтенләй түбәнәеп, менә шул минутта бөтен шәһәрне яңгырга коендырырга әзер булгандай үтеп торалар. Бакчадагы ялангач агачлар көзге ачы җилгә каршы, урманда адаштырылган җен баласы кебек, ыжылдап җылыйлар, шаулашалар. Ахшам караңгылыгы эчендә җилнең, агачларның үзара кемнәндер зарланып утырганга ошаш шаулаулары астында, Җиһангир үткән төннең вакыйгаларын берәм-берәм күз алдыннан кичерде. Мәдрәсәдәге дулкыннар, талашлар, хәзрәт белән, Кадыйр бай белән бәрелешләр, полиция, гаскәр, тентү аның зиһененнән үттеләр.

Ләкин ул боларга озак туктала алмады.

Менә бер атна инде ул Һаҗәрне күргәне юк. Өч тапкыр үзе әйтеп чакырган җиргә күрешергә килә алмады. Кичә шәһәр бакчасының куе агачлы почмагында, бөтенләй ышанып көткән минутта, асрауның китергән язуы егетне тагы шөбһә катнаш хәсрәткә төшерде. Ул әйтә:

«Ирем нәрсәдер сизенә бугай. Шикләнгән кеше кебек кыйлана. Тирә-ягымны карчыклар белән тутырды. Аяк атлап чыгар хәлем юк. Ни генә кыйлыйм соң, җан кисәгем?» – ди.

Шулай, сизә башлады, ди. Ничек, кайдан, кем аркылы сизәр? Менә җиде ай инде, нинди куркыныч минутлар килеп кичмәде! Менә, менә эләгәләр, харап булалар дигән чаклар күп үтте, – һәммәсендә бер чарасы табылган, язмыш ярдәм биргән иде. Бу араларда очрашканнары да юк лабаса! Кайдан белер, ничек сизенер!?

Шунда тагы теге Миһранның сүзе! Бу эт авыз, шпион нәрсә ди? «Бише җитмәгән, алтынчыга кеше хатыны алдарга, харап итәргә тотынгансың икән!» – ди. Менә эт авыз! Нинди биш? Нинди алтынчы? Нинди алдау? Мин аны сөям. Без сөешәбез! – бу алдау буламы?

Тукта, мәдрәсәдә тентү арасында тагы кем дә булса шундый сүз әйттеме? Кем дә булса Һаҗәр исемен телгә алдымы? Әллә барын да минем шикләнүчән, вәсвәсәләнүчән хыялым гына уйлап чыгарамы? Юк, вәсвәсә түгел, дөрестә дә шулай. Кичә Миһран тентү бетәр алдыннан, мәчет бүлмәсендә, ярым мәсхәрәле, ярым куркытулы тавыш белән әйтте. Эт бит, көнче бит! Ул мәдрәсә яшьләре хәрәкәте эчендә Җиһангир алгы сафта беренче булып, арысландай сугышып баруына эче янгандыр этнең! Шәкерт арасында минем авторитетны бетерер өчен шундый гайбәтне җибәрергә азапланган булыр. Тукта, танытырмын мин ул эт авызга үзенең кем икәнен!

Ул ялгыз да түгел, янында берничә иптәше дә бар иде. Кайсыдыр, көлә төшеп, эчке агу белән тагы чәнечте шунда: «Безнең Җиһангир егет кеше ул, – ди, – ул, ди, бөтен дөньяга гыйшык чәчә. Иртә-кич, көндез-төнлә аның аерым-аерым күрешүләре була. Атнаның һәрбер көнендә безнең Җиһангирнең биш кызга хат язып өлгерергә вакыты җитә. Аларның һәрберсенә: җаным, бәгърем, сиңа гашыйкмын, тик сине генә сөям... дөньяда тик синең өчен генә яшим... син булмасаң якты дөнья кара кабергә әйләнә, дин яза. Һәрбер сөйгәненнән шундый ялкынлы мәхәббәт хатлары ала, егет кеше безнең Җиһангир!» – дип көләргә азапланды.

Моңарчы Җиһангир тирәсендә койрык болгатып, дуслашкан булып йөргән Фәйзи бар. Ул да шунда килеп тыгылган булды тагы: «Егет булсаң, Җиһангир бул. Яшьлек ялкынында Җиһангир кебек ян: менә ул, янам, көям дип, көненә биш кызга хат язарга гына түгел, бишесе белән күрешергә дә

өлгерә, – егет булсаң, шулай бул, Җиһангир күк барына да өлгер,» – дигән булып, мыскылларга көчәнде. Ләкин мәсхәрә урынына үзенең авызыннан селәгәй акты бугай. Шулаймы? Яшьлекме, ялкынлы яшьлек, диеләме? Мәхәббәт бакчасында, кызыл гөлләр эчендә күбәләктәй уйнаган ялкынлы яшьлегемне гайбәт сөреме белән агуларга уйлыйлармы?! Юк, көчләре җитмәс!

Тукта! Тагы кайсы эте матур кыз Бибиәсма гайбәтен телгә алды соң әле? «Имеш, – ди, – яз көне икән, ди. Идел өсләренең матур чагы икән, ди. Җиһангир, ди, пароходта Самардан Казанга килергә юлга чыккан икән, ди, шунда, ди, сөйгән кызы матур Әсманы очраткан икән дә, ди, актык сәгатен сатып, кыз артыннан Әстерханга киткән имеш», – ди.

Менә көчекләр! Менә эт авызлар! Сөю гаепме? Матур яз көнендә сөйгән кызың өчен, Казанга барасы урында, пароход белән кире Әстерханга китү зур начарлыкмы? Сөйгән кызыңны озату өчен бер сәгать сату – гаепме? Анда аларның ни эше бар? Яшь күңел кыз артыннан җәһәннәмгә дә китәр – аларның ни эше бар? Ялкынлы яшьлекне богауларга телиләрме?

Болар һәммәсе үткән эшләр ич инде! Хәзер берсе дә, берсе дә юк. Зифа да, Сафия дә, Гафия дә – берсе дә юк, хәзер бөтен дөньяда бер генә сөйгән хатыным – тик Һаҗәр генә. Тик ул гына!

Яшь йөрәк күп җилкенде, күбәләк күңел күп чәчәкләр тирәсендә очынды, ләкин Һаҗәр килде – шуның белән башкалар һәммәсе югалды. Кояш чыгамы? Кояш чыккач, йолдызлар сүнәләр, югалалармы? Күңел күгемдә Һаҗәр килеп чыккач, бары да югалды, онытылды, дөньяда тик ул гына калды. Менә бит хәл ничек. Ә дошман телләр чәйни бирәләр.

Берсе тагы шунда нәрсә диде: «Егет син, Җиһангир, бабаң Гыйбайдан калышмыйсың! Нәселеңә ошадың, синең бабаң, җитмеш яшьлек карт көенчә, уналты яшьлек кызны үзенә ябыштырып чыгарган кеше ич! Әйдә, ата-бабаң җоласын читкә ташлама!» – дип лыгырданды. Җитмәсә тагын анасы Фатыйха романын тәмләп, гайбәтләп чәйнәргә тотынды.

## XXXIV
## ФАТЫЙХА

Тентү чагында, уен-көлке арасында ташланган бу соңгы гайбәтләрне хәтерләгәч, Җиһангир үзалдына кызарып китте. Кайдан беләләр? Кайдан ишеткәннәр ул минем Гыйбай бабайның уналты яшьлек кызны үзенә ябыштырып чыгаруын?!

Таза, нык гәүдәле, уйнап торган көләч йөзле аксакал бабасы Гыйбай картны Җиһангир бик аз хәтерли. Ул үзе үлгәч, аның өч яшьлек улы белән егерме яшьләрендә чибәр яшь хатыны калды. Карт бу хатынны, шулай халык

телендә гайбәт булып чәйнәлгәнчә, чынлап та ата-аналарыннан качырып, үзенә ябыштырып чыгарганмы, әллә бу сүз усал телләрнең ялган гайбәте генәме? – Җиһангир аны нык белә алмады. Әмма ил авызында шулай чәйниләр. Усал телләр ул таза чибәр картның шулай уналты яшьлек кызны чыгарып алуына бәйләнешле эшләрне көлкеле итеп сөйли бирәләр. Кем белсен – чынмы, ялганмы? Бәлки, бары да уйдырма гынадыр? Әмма апасы Фатыйха романы турындагы гайбәт?! Бу да шулай усал телләрнең ялганлап чыгарган матур әкиятләре генәме?

Юк, болар инде Җиһангирнең балалык хәтерләренә мәңге җуелмаслык булып кисеп кергәннәр.

Җиһангирнең бер-берсен куып үскән ике апасы булды. Боларның кечесе Саҗидә яше тулар-тулмас кияүгә бирелде. Әмма зурысы бик күп еллар кызлыкта утырды.

Ул озын буйлы, бераз нечкәрәк гәүдәле, моңлы карашлы, биленнән төшеп торган җефәк чәчле, сабыр холыклы, аз сүзле, уйчан кыз иде. Аңа яучы йөрмәде түгел, уналты-унҗидегә керү белән сүз салулар өзелмәде. Чиләбе ягына, зур базарлы авылга килеп яши башлагач, тирә-якның яхшы хәлле, яхшы нәселнең егетләреннән илчеләр тол карчык Фәризәнең маен, каймагын, тавыгын күп ашадылар. Ләкин: «Уйлап карарбыз әле. Кызымның үзе белән дә киңәшим, мин алай үзем генә эшне өзә алмыйм, агай-эне бар. Күрше-күлән бар. Ни әйтерләр тагы...» – дигән сүзне ишетеп, буш кул белән кайтып киттеләр.

Яучы килә дә китә, Фатыйха һаман бармый, һаман «утыра» бирә.

Күп еллар «утырган», күп егетләрнең яучыларын кире кайтарган менә шул Фатыйха турында ил теле куркыныч, серле гайбәт сөйли башлый.

Имеш, диләр, Фатыйханың сөйгән егете бар имеш, шуны көтә имеш. Яучы килгән саен анасының күкрәгенә ятып җылый имеш, ялвара имеш. Әнкәсе Фәризә карчык, бала сөючән йомшак күңелле булганга, сөекле кызын алай көчләп бирә алмый имеш, шуңар күрә килгән бер илче май-коймак ашый да имеш: «Җавабыгызны көтәрбез!» – дип, кире китә имеш. Җавап булмый имеш, кыз тагы шулай утырып кала имеш, диләр.

Фатыйханың сөйгән егете әле каралмаган имеш, кыз аның каралып, солдаттан калганын көтә имеш. Ләкин кызның егете, бәхетсезлеккә каршы, һәр ел карала да «яшелгә» кала имеш, алдагы елга тагы караласы имеш, кыз тагы, шуны көтә-көтә озын төннәрдә күз яшь түгеп, гыйшык-мәхәббәт утында яна имеш, көя имеш, саргая имеш...

Бара торгач, бу гайбәтнең ачыграк калыпка салынганнары да чыга башлады.

Егет, урау юлны туры итеп, җәй көннәре яланга атка куна барганда,

һаман болар тыкрыгыннан үтә икән, диләр. Атта кунып яткан җиреннән таң алдында авылга кайтып, ындырда сызгыра икән, төн буена зарыгып көткән гашыйк кыз Фатыйха үзенең сердәше Гыйльминур җиңгәсен уята икән дә, болар комган алып икәү абзарга чыгалар икән, шунда егет белән кыз кавышалар икән, шунда вәгъдәләр, антлар бирешәләр икән, дип гайбәтлиләр.

Бервакыт, ди, кич, ахшам вакытында, Фатыйха кыз кайнаган самовар белән өйгә кереп килә булган икән, ди. Шунда сөйгән егетенең ат өстендә акрын гына җырлап үткәнен ишеткән дә, ди, кулындагы кайнаган самоварын төшереп җибәргән имеш, ди...

Фатыйханың бу романы озакка сузылды.

Бозганнар икән, егет аны сихерләткән икән, шуңа күрә кызганалар, серен сорашалар, дуслык кулы сузалар. Ләкин Фатыйха, алар белән бик дус булса да, үзенең йөрәк серен бирәүгә дә ачмый. Аналар борчылып карыйлар, үз кызлары шундый хәлгә төшмәсен дип, Ходайларына сыгыналар. Тагы кабартып, гайбәткә тотыналар.

Илнең бу озак гайбәте Җиһангирләр йорты өстендә бер авыр бәхетсезлек булып асылып тора. Торган саен авырая, зурая бара. Ана карчык, аптырап, өшкергән, сихер кайтара торган сулар эчерә, бөтиләр яздырып тага. Ләкин гыйшык сүнми, сихер кайтмый. Туган агалары кызның бу гайбәтле романына бер бәхетсезлек, бер хурлык итеп карыйлар. Фатыйхага ачулы шелтә белән усал сүз ташлыйлар: «Бөтен нәселгә кара яктың!.. Кая барсаң, сине чәйниләр, синең аркаңда безне мәсхәрә итәләр...» – диләр.

Ул вакыт Җиһангиргә тугыз яшьләр булыр. Ил гайбәтенең иң рәхимсезе аңа төшә. Урамга чыксаң, берәү белән талашыр, кычкырышыр хәл юк, хәзер китереп битеңә бәрәләр: «Җә, борыныңны бик күтәрмә! Үз апаңны бел!» – дип кисәләр.

Элек иптәш малайларының башларыннан очкан, кая барса да беренче йөргән сабый Җиһангиргә болар агулы ук булып йөрәккә утыралар. Ул ачуыннан, хурлыгыннан ярылса җир тишегенә керергә җитешә: «Нинди оят! Нинди мәсхәрә эш бит! Имеш, апаң егет сөйсен! Имеш, апаң гыйшык булсын! Дөнья йөзенә ничек күренерсең бу хурлыктан!..»

Ул, кешеләрдән ишетмешләй, апасының егетен сагалый башлый. Хәерсез икән: арыслан кебек ләбаса! Чибәр. Уенчак. Үткен. Менә дигән җырчы. Биюче. Сызылып чыккан кара мыек!

Юк, була бирсен: болар кечкенә батырны куркытмыйлар. Ул апасын мәсхәрәгә салган бу Закир егеттән үч алмый калмаячак. Ул гына җитми. Кыйнау гына аз. Аны үтерергә кирәк. Бала менә шул дәрт белән яна башлый.

Көз килә. Никрутлар йөриләр. Егет белән кыз тагын яман телгә төшәләр. Әллә кем күргән имеш: Фатыйха һәр көн кич, тәрәзә ачып, үзенең

сөйгән егетен янына кертә имеш; егетне бер тапкыр эләктерә язганнар имеш, ул, кесәсендәге барлык акчасын биреп, чак котылган имеш, диләр.

Кечкенә сабый Җиһангирнең түзәрлек чамасы калмый. Ул көндезен карап-әзерләп куя да, өйдәгеләр йоклап беткәч, курка-курка гына өйнең чормасына менә. Башка вакыт булса, коты очар, аяк атлый алмас иде, ләкин бүген куркуны җиңә. Ул озын, караңгы төннәрдә шунда өй башында егетне сагалап утыра. Менә килер, тәрәзә аркылы апасы Фатыйха янына керә башлар. Җиһангир янында көндездән мендереп куйган ташлар бар. Менә шуларны алачак та егетнең башына югарыдан түбәнгә таба җибәрәчәк, аның баш сөяген ярачак. Үлсә – үләр.

– Алай апайны хур итеп йөрмәсен!

Бала бик күп төннәр, шул дәрт белән янып, чормада саклап чыга.

## XXXV
## МИҢЛЕКӘЙ

Ләкин шул дәрт белән янып йөргән көннәрдә Җиһангир кинәт апасы ягына авыша да аны агаларының шелтәләреннән җылап, әрнеп яклый башлый.

«Кеше хәлен кеше белми... үз башына төшмәсә», – дип җырлыйлар бугай.

Сабый Җиһангирнең үз башы әйләнде.

Көтүче Сафый картның тугыз яшьлек кызы бар. Алтын сары чәчле, язгы күкне хәтерләтә торган зур, матур зәңгәр күзле бу сабый, чәчәктән чәчәккә кунып йөргән яз күбәләге кебек, уеннан башканы белми. Аны: «Миңлекәй», – диләр. Яратып иркәләп сөйлиләр.

Бер яз көне иде. Фәризә карчык авыл янында инеш елга буена кечкенә каз бәпкәләрен алып төште дә Җиһангирне шунда сакларга калдырды:

– Эт алмасын, төйлегән,[1] карга алмасын, яхшы кара, – диде.

Сафый картның да биш кенә бәпкәле бер казы бар икән. Аларның бәпкәләре зуррак, ләкин ямьсезрәк. Боларны Миңлекәй һәр көн үзе акрын гына каулап инеш буенча алып килә икән дә көн буена шунда саклый икән, кич булгач, эткәсе көтүдән кайтыр алдыннан, тагы кире өйгә таба акрын-акрын тал чыбык белән каулый икән.

Елга буенда каз бәпкәләре караганда очрашып, ике бала бергә уйнап киттеләр. Гаҗәп тиз дуслаштылар. Бу эшне элек үзенә бер җәфа кебек карый иде Җиһангир, хәзер үзе теләп, әнисеннән үзе сорап, каз бәпкәләрен елга буена алып китә торган булды. Анда тагы эт-коштан, карга-төйлегәннән

---

[1] *Төйлегән* – тилгән.

бәпкәләр саклап, су буенда үткәрүдән кызык, мәгънә таба торган булды. Ләкин бәпкәләр тиз үсәләр икән. Менә зураеп киттеләр. Сары алтын йоннары бераз аксыл яшькелт-карага әйләнде. Фәризә карчык әйтә куйды:

– Җә, балам, зурайдылар инде, карамасаң да ярый, – диде.

Җиһангир үзенең дусыннан аерылган бу беренче көндә нәрсәнедер юксынган, нидер җитмәгән кебек сизенде. Алай-болай уйлап тормады, Сафый карт өенә йөгерде.

Кыз яңгырап әйтте:

– Мин дә карамыйм, зурлар ич инде! – диде.

Су буена төшмәделәр, шунда бергә көн буе уйнадылар. Кич өйгә кайткач:

– Кая йөрисең бу чаклы?! Ашавыңны онытның лабаса! – дип, анасы да шелтәләде.

Ләкин малай аңа карамады, икенче, өченче, бишенче, унынчы көннәр дә һаман шул Сафый карт өе тирәсендә, Миңлекәй янында кайнашты, шунда уйнады. Уенда да, башкасында да аңардан аерыласы килмәде. Әнә зур кызлар көянтә күтәреп чишмәгә суга баралар. Миңлекәй аларга ияргән. Җиһангир эшен, уенын ыргытып бәрә дә бергә оча. Менә җиләк җитә, яланга, урманга, тауга җиләккә йөриләр. Һәр төре бар: җир җиләк, кура җиләк, бөрлегән, шомырт, аннан чикләвек – бары да әйбәт, бары да тәмле. Миңлекәй белән Җиһангир, бер-беренә тагылган ике матур колын кебек, зур кызлар, яшь киленнәр, карчыклар артыннан калмый, уйнап-көлеп бергә йөгерәләр.

Менә куркыныч. Авылда чәчәк авыруы тарала. Балаларны кырып сала. Сафый картлар очына барып җитә, анда авырмаган бала калмый. Ничәсе үлә, ничәсе яман, җыртлач кара шадра булып, шайтан кебек ямьсез булып кала. Берничәсенең күзе агып чыга, гомергә сукыр булып кала. Бер барганда, Миңлекәй йортта күренми. Өйгә барса, кертмиләр:

– Ярамый, үзеңә дә йогар, – диләр. Җиһангир ут йота, көненә әллә ничә тапкыр:

– Тормадымы, бетмәдеме, нигә алай озак?! – дип, килеп-китеп йөри.

Менә караңгы хәбәр. Миңлекәй терелә алмый, матур зәңгәр күзләре чәчәктән агып чыгалар, сөйкемле, яшь чибәр йөзе җыртлач-җыртлач кызарып телгәләнә-телгәләнә дә, шул төнне газап, ут эчендә җан бирә. Икенче көнне үк кичкә таба сабыйны илтеп караңгы кабергә күмәләр.

Җиһангир башын югалта, оятны сизми, җылап-җылап, Миңлекәйнең җеназасы артыннан йөгерә. «Ярамый, барма!» – диләр. Калмый, бара. Атасы Сафый карт та яман әрнеп, үксеп-үксеп җылый, бите-күзе шешенеп бетә.

Менә шул төндә Җиһангир үзенең апасы Фатыйха янына килә:

– Апай, мин синең яныңда ятыр идем! – ди.

Үзе дә җүнләп сизмәстән, Миңлекәй турында сөйли башлый, сүзе белән бергә күзеннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәри башлый. Сүз арасында апасының күкрәгенә кысылып кат-кат ант итә:

– Инде, апай, мин сине абыйлардан тидертмәм, Закир абыйны да үтермәм... Мин хәзер сине дә, аны да яратам, – ди.

Сердәш апасының бәхете ачылды: аның Закиры солдаттан котылды, шул елны туй ясап, Фатыйханы аңа кияүгә бирделәр. Әмма Миңлекәй үлгәч, апасының куенында җылап, үксеп үткәргән төн Җиһангирнең бөтен гомере буенча нур белән балкып торган бер якты минутлардан булып калды.

Егет аннан соң ялкынлы яшьлек дулкыннарында күп кайнады, күп мәхәббәтләр, көрәшләр кичерде, ләкин берсе дә ул төнне оныттыра алмады – теге Фәйзи шәкерт кебек эт авызлар менә шуны гайбәт итеп сөйлиләрме?..

Җиһангир кинәт урыныннан торды. Шөбһә юк, ул Һаҗәрне дә сөя. Сөелүенә дә ышана. Ләкин бу сөюнең биргәне бөтенләй башка!.. Монда агу белән ләззәт бергә кайный, монда шатлык белән көенеч бергә баралар. Бу хәзерге мәхәббәтләр, ул сабый чакның саф гыйшкы кебек, хыялый нур эчендә, чәчәкләр эчендә генә түгел... Ул беренче очрашты. Беренче күреште. Шул вакыт үзенең ирекен югалткан кебек булды. Сөю бар. Ләкин аның эчендә кемгәдер һәлакәт белән үлем дә бар. Әйтерсең, йөрәккә агулы хәнҗәр тыктылар. Хәзерге мәхәббәт менә шул хәнҗәр генә. Ләкин аны тартып алырга да теләми. Ул хәнҗәрне үзе эчкәрәк батыра, хәнҗәр йөрәкнең төбенә төшә, агуы белән газаплый. Ләкин газаплый бирсен! Бу – сөю газабы. Йөрәк үзе шуны тели, шуңа сусый...

Моңарчы алай ачык кара-каршы куеп караганы юк иде. Миңлекәй турындагы уйлар аңа хәзерге мәхәббәтнең агулы хәнҗәр булуын сөйләделәр.

Һаҗәр!

Миңлекәй!

Бу ике арада җир белән күк бар.

Егет Миңлекәйдән Һаҗәргә килде, алтын сары чәчле, зур матур зәңгәр күзле ул сабый кыз – язгы төннең якты йолдызы, хыялый бакча сандугачы; Һаҗәр дә матур, ләкин ул җир чәчәге, аһ, нинди матур, ләкин һаман да җир чәчәге!

## XXXVI
## ОЧРАШ

Кемдер ишек шакылдата. Караса, фатир хуҗасы хатын икән. Киенгән, ясанган, чәчен бөдрәләткән, кашын-күзен буяган, иреннәре кып-кызыл яналар. Чытлыкланып елмайды, карап кал, мин дә киенә беләм дигән кебек, назланып боргаланды да:

– Мин театрга барам. Чыксагыз, ишекне бикләп, ачкычны үзегез белән алыгыз! – диде.

Җиһангир аз гына да җылылык сизенмәде, ярый дип, аның артыннан ишеген япты. «Дуңгыз кәнтәй, үзен күрсәтергә, күңел аздырырга шулай юк йомышны бар итеп керә бу кыйланчык!» – дип тиргәнеп, бүлмәне берничә әйләнде. Тәрәзәгә туктады. Тышта соңгы көз. Караңгы төшеп килә. Утлар яна башлыйлар. Әнә бакча ашасыннан Һаҗәрләрнең тәрәзәләрендәге якты ничек балкылдап күренә. Егет, сөеклесенең соңгы хатларын алып, сагыну ялкыны астында берничә кат укыды да тиз-тиз өстәленә утырды, кулына каләм алды, кайнап, янып барган йөрәкнең дулкынына түзә алмый, ашыгыч язарга тотынды.

«Газизәм Һаҗәр!

Бөтен дөньяга ләгънәт укып, бөтен дөньяның өстенә төкереп, һәммәсен күңелдән чыгарып, барлык изелүләрне, бөтен ачы зәһәрле кайгыларны очырып, һичкемне бар дип белмичә, дөнья йөзендә миңа хаким, миңа баш тапмыйча, һичкемне үземә тиңләштермичә, бер генә минут һаваланган, бер генә минут җаныма тынычлык алган, бер генә минут язмышка кол булмаган һәм дөньяда мин генә, үзем генә дип барчасына кул селтәгән вакытым – яңа ут алган, яңа гына бакчада шыбырдап яңгыр ява башлаган кичке сәгать җиденче заманы иде.

Шул минутым, шул сәгатем кемгә тиеш? Моны кемгә бүләк итим? Ни нәрсә эшлим? Аһ, мин ни өчен сорыйм! Ни өчен күңелемә шик, шөбһә китерәм! Ни өчен вакыт сузам! Бер генә бит, бер генә һәм ул гына – бу минутым аңа булсын, ул хаким, ул куркучым: аның өчен булсын!

...Бөтен җир-күкләргә, барлык фирештәләргә алмаштырылмаячак Һаҗәрем өчен булсын!

Газиз иркәм, Һаҗәрем! Чыннан да, күңелемә башка һичбер вакыт булмаган бер дәрт, бер рәхәт, бер ашкыну килде. Үзем белмим, үзем сизмим, моның кайдан икәненә төшенмим.

Ләкин бөтенләй бушка гына, бөтенләй юкка гына булмагандыр. Барлык иптәшләрне, барлык яр-юлдашларны, барлык фирештәләрне, Аллаларны уйлап утыра идем. Аллага намаз укымаганга, пәйгамбәргә салават әйтмәгәнгә, дусларга хат язмаганга бик озак, бик күп вакытлар булган иде. Мин шушыларның һәммәсен тикшереп, йон шикелле тапаган идем, кайсын уйлап төкерә, кайсын җирәнеп ташлый, кайсын атып чәнчелдерә идем... Ах, дидем, ах, берсе дә кирәкми, ах, минем каләм кайда, кәгазь кайда, дидем, бөтенесенә төкерәм дә, сиңа, бөтен дөнья белән, күктәге ай-йолдызлар белән алмаштырылмаячак син иркәмә, син сөйгәнемә, син Һаҗәремә хат язарга

утырдым...»

Шул җиргә җиткәч, егетнең кулы үзеннән-үзе туктады. Каләм аның теләгеннән башка өстәлгә төште. Ул нидер сизенгәндәй булды... Чү!.. Тышкы ишек ачылды түгелме? Чү, кемдер сак атлап, ләкин бик таныш адымнар белән кереп килә түгелме?

Җиһангир шул сизенү астында, бәхетле ашкыну белән урыныннан кузгалырга өлгерә алмый, кинәт бүлмә ишеге ачыла, егет көтелмәгән хәлдән шашып, катып кала: бусагада яшь, чибәр хатын, ул да – Һаҗәр! Матур киемле, сөйгән карашлы, зифа буйлы Һаҗәр!

Егет дөньясын, үзен оныта:

– Җаным, Тәңрем синме! – дип, хатынның кочагына ташлана, биленнән, муеныннан куллары белән кысып ала да туктаусыз ялкынлы үбүләр утында югала. Үзе: – Иркәм, Һаҗәрем, бер атна – җиде көн түгел, җиде ел булды!... – дип, бәйләнешсез сүзләр сөйләнә.

Һаҗәр бу акылыннан шашкан егет сөяркәнең ялкыны эчендә берничә минут үзен-үзе белми, иреге бетә, бөтенләй югалып китә.

– Җаным, үләм, – дип, кинәт һушына килә. – Тукта, минем өс-башым бик изелмәсен!.. Мин бит туганым җиңгиләргә бүләк багу мәҗлесенә барырга чыккан җирдә бер секундка гына кердем... – дип, кискен рәвештә егетнең кочагыннан суырыла, аякка тора.

Егет тагы үбәргә тотынгач, хатын тагы үзен югалта, Җиһангирнең ялкынлы яшьлек уты аның үз йөрәгендәге ялкыннары белән тоташып, акылын, иркен бетерә. Берничә минутмы, бөтен бер гомерме шулай үтә. Хатын кинәт:

– Тукта, соңга калам, сизсәләр, харап булырбыз! – ди дә, сикереп торып, идәнгә баса. Янган ирен, тузылган чәч, тәпәрләнгән алсу платье белән көзге алдына ташлана. Үзен күреп, коты оча: – Харап бит, кеше төсем калмаган!.. Ул гайбәт капчыгы Казан хатыннары мәҗлесенә бу көенчә ничек барыйм?! – дип, ашыгыч-ашыгыч үзенең чәчләрен, күлмәк, пальтоларын төзәтергә тотына, ридикюлен ачып, кулъяулыгын, пудраларын чыгара да: – Син миңа бик карама! – дигәләп, Җиһангирне шаярта-шаярта икенче якка бора, үзе туктаусыз, кызарып янган иреннәрен, нур уйнаган йөзен, болай да каралып сызылган нечкә кыек кашларын төзәтә башлый.

Хатын озак кала алмады:

– Анда, чатта, ахирәтем көтә, ул минем сердәшем. Белдеңме? – дип, нурлы күзләре белән егеткә йотылып карады. – Җаным, озата чыкма! Шик төшерерсең! – дип, бүлмәдән юк булды.

Ләкин шул секунд ишек кире ачылды, Һаҗәр бусагага баскан килеш

егетнең кулын кысты, сүз ташлады:

– Җаным, иртәгә, ястүгә азан әйткән чакта, Мөнасиповларда бул!

Җиһангир артыннан шатланып, шашып кычкырды:

– Булам, җаным, булам. Җәһәннәмгә чакырсаң, анда да барам! – дип калды. Ләкин шик төшермәс өчен сөеклесен озата чыкмады. Бүгенге ялкынлы бәхетнең, иртәгә киләчәк өмитнең дулкыны эчендә, бераз һава алыйм дип, урамга атлады.

## XXXVII
## ҺАҖӘР

Һаҗәр җиде ел сөйде. Җиде ел буенча сөюен йөрәгенең тирән катлауларында яшереп саклады. Ул йомшак күңелле Сара карчыкның бердәнбер кызы иде. Ана үз гомерендә күп бәхетсезлекләр, кайгылар күрде, ире яшен утында кара көеп янып үлде, дөньяга китергән җиде баладан тик менә шул Һаҗәр калды. Аның өчен тормышның бөтен мәгънәсе – кызы Һаҗәрдә, Һаҗәрнең бәхетле булуында, рәхәт үсеп, яхшы иргә чыгып, бәхетле, шатлыклы гомер итүендә, анасының түккән күз яшьләрен онытмавында, картлык көн килгәч, терәк кул булуында иде.

Бала сөючән ананың бетмәс-төгәнмәс иркәсе, кадере эчендә Һаҗәр бай түгел, ләкин барынча бәхетле үсте. Үзе кебек күңелле, шаян кызлар, матур курчаклар, бакчалардагы зур кызыл чәчәкләр, тәмле җимешләр аның беренче яраткан әйберләре иде.

Ул иртә җитеште. Буй үсүе белән бергә, аның йөрәгендә бер егеткә сөю чәчәге дә үсте. Кыз үзенең сөйгәнен җиде ел буенча ерактан иркәләде. Ерактан аны чәчәкләр, гөлләр эчендә үзе белән бергә очраштырып, саташулы хыял эчендә сөйде. Ләкин дус кызлар да, сөючән ана да, башка һичкем дә җитү кызның йөрәгендә үзе белән озак еллар бергә үсеп җитешкән кызыл мәхәббәт чәчәген белмәделәр, күрмәделәр, сизмәделәр. Кыз берничә тапкыр ялгыз уйланды, гомерен шул энҗеле калфаклар эшләү өстендә үткәргән әнкәсе Сара карчыкка серен ачарга теләде, ләкин батырлыгы җитмәде. Анасы матур энҗеле калфакларны кала уртасында торган бай кызларына, бай бикәләргә илтергә киткән чакта, Һаҗәр ялгызы сүзгә әзерләнә, ничек итеп, ипләп, уңайлап сер ачуның юлларын эзли иде. Күп уйлады, ләкин үзендә моңа җитәрлек көч таба алмады.

Шул арада анасы калфак эшләп тапшыра торган Кадыйр байдан икенче хатынлыкка сорап яучы килә.

Имеш, байның әүвәлге хатыны, карт икәнме, авыру икәнме, нидер булган, – ул инде әҗәл көтеп ята имеш, тиздән үләр имеш, ул үлгәч тә, үлмәс борын да Һаҗәр зур байның кадерле яшь бикәсе булачак, зур сарайларда

җефәк-алтын эчендә йөзәчәк имеш...

Яучы җибәргән бай яшь түгел. Аның сакалына чал кергән имеш, ләкин карага буяп йөри имеш, дип тә сөйлиләр. Һаҗәргә яшьтәш диярлек улы Йосыфҗанны кыз үзе дә берничә тапкыр күрде. Ләкин, анасы Сара карчыкның зур шатлыгына каршы, байның карага буялган чал сакалы да, җиткән Йосыфҗаны да Һаҗәрне куркытмадылар. Ул, үзенә-үзе бик нык исәп биреп тә җитмичәрәк, туп-туры:

– Алса, барам, – диде.

Бай – акыллы шәрекъ карты иде. Матур, дәртле, ялкынлы Һаҗәрдән дөньяны кызганмады. Аны алтыннар, бриллиантлар белән бизәде, атласлар, җефәкләр эченә күмде... Һаҗәрнең көннән-көн күбәеп, төрләнеп барган теләкләре көне-сәгате белән үтәлә бара иде. Кадыйрны тулы яшьлек уты эчендә иркәләсен, аңардан башка һичбер, һичбер, һичбер ир затына күз дә, күңел дә төшермәсен! – менә тик шул бер генә нәрсә кирәк. Шул булса, Һаҗәр бөтен нәрсәгә, бөтен кешеләргә югарыдан карый ала торган кадерле бикә булачак.

Калфакчы Сара кызының болай кинәт күтәрелеп китүе күпләрнең көнчелеген уятты. Туй көнендә таралган начар-пычрак гайбәт куерып җәелә, телдән телгә йөри; Һаҗәрне әкияттәге кыз кебек хыялый эшләр урап ала башлады.

Кызның сөйгәне булган имеш, диләр. Ул сөйгәне – Кадыйрның чибәр, купшы яшь приказчигы Фәхри имеш. Кыз ундүрт яшьтә чакта ук шул чибәр, купшы егетне сөя башлаган имеш; анасы белән энҗеле калфак өчен кирәк әйберләр алырга барганда, кыз үзенең егетен һаман-һаман күреп кайта булган имеш, ләкин беркемгә дә серен ачмаган имеш. Тик менә бервакыт Кадыйр байга кияүгә чыгарга сүз биргәч, иртәгә зөфаф була, карт бай яшь Һаҗәр янына зөфафка керә дигән көндә, Һаҗәр үзенең җиде ел яшереп сөйгән егетен чакырып алган имеш тә: «Сине җиде ел сөйдем. Беренче кичем сиңа булсын!» дип, аны үз кочагында иркәләгән имеш.

«Мин сине сөйдем, әмма тәкъдирем башка булды», – дип, төн буена җылап чыккан имеш, диләр.

Бу яшерен серне Фәхри үзе дусты Габдрахманга гына ачкан, ул яшь сердәше Нәфисәгә, Нәфисә Зөһрә апага сөйләгән, Зөһрә апа үзенең сөяркәсе Гафурга әйткән имеш. Бу Гафур дигәннең яман тел, чәрелдек, аксак сеңлесе Мәгъфурә бар икән. Бөтен шәһәргә менә шул чәрелдек Мәгъфурәдән таралган имеш, диләр.

Бу кара гайбәт дошманнар аркылы Кадыйр байның да колагына барып ирешә. Ул ачуыннан кара көя, миен кан каплый, эшен, магазинын ташлый да: «Бер тиенем хәрам булсын! Хәзер куып чыгарам, ялангач хәлдә урамга

ташлатам!» – дип, кызып, җенләнеп, өенә кайта.

Ләкин яшь бикә Һаҗәрне күрү белән, сугарга күтәрелгән кулы кире төшә, шулай да, тиз җиңелмәскә тырыша:

– Әйт, җылан! Фәхри синең сөяркәң булдымы? – дип, бугазыннан буа башлый.

Хатын акырып җылап җибәрә:

– Ялган, бары да ялган: бары да көнче дошман сүзе генә! Сиңа килгәнче, һичбер ирнең һичбер бармагы да миңа кагылмады, – дип, иренең күкрәгенә ташлана, аңа кысылып, кочагына кереп, үбәргә тотына.

Ирнең каны уяна, ачуы югала, Һаҗәрнең иркәләре ялкынында күңеленең барлык вәсвәсәләре юкка чыгалар. Таза, куәтле тәннән тышкы авырулар тиз арада юк булган кебек, тулы тәнле, уйнаучан яшь канлы, алсу, чибәр йөзле, нур эчендә елмайган кара, якты күзле, иркәли белүче Һаҗәр тирәсендәге гайбәтләр дә үзеннән-үзе сүнәләр, байга килеп ирешми, каядыр юлда тукталып калалар.

Һаҗәр йөрәге үзенең эчке серләре белән тагы бикләнә. Бай унике приказчик белән бергә шуларның башлыгы Фәхрине дә куып чыгаргач, урам гайбәте тагы әзрәк кузгалырга әйткән иде, ләкин һәр көн кайнап, ташып торган революция дулкыннары эчендә андый вак гайбәт тиз югалып китте. Хатын тагы тынычланды.

## XXXVIII
## КАЙДА КҮРДЕМ ИКӘН?

Һаҗәргә киң Идел елгасын көймә белән аша чыгарга туры килде. Язгы матур көн иде. Батып барган кояшның нурлары Идел өстендә сары алтынланып уйныйлар. Кичке һава – эчеп туймаслык саф. Бөтен табигатьнең, кояшның, кичнең бу нурлары, бу саф һавасы эчендә, әйтерсең, сөю дәрте белән яшәреп, яңарып бара.

Яшь йөрәккә акрын-акрын гына йомшак канатлары белән кагылган бу рәхәт минутлар Һаҗәргә ниндидер хыялый бер төш хәлен бирделәр. Ул, үзенең хыялый уйларына батып, көймәнең тирбәтүе эчендә рәхәт, бик рәхәт, бик тыныч барды. Шул вакыт ниндидер бер куәтле күз карашының уң яктан үзенә кадалганын тойды. Янында ире Кадыйр бар иде. Эченнән куркынды: «Йа Ходай, бу кем булыр икән тагы?» – дип борчылды, иреннән бик курыкса да, үзен тыя алмады, ялгыш ридикюлен төшерде дә, шуны алып маташканда, керфек очлары белән генә сөзеп, шул караш тоелган якка күз кыеп алды.

Анда сызылып килгән кара мыеклы, карасу үткен йөзле бер чибәр егетне күрде.

Күрде дә хәтерләгән кебек булды: «Тукта, мин соң бу егетне кайда

күргән идем?»

Хатын бу егетне кайчан, кайда күргәнен һичбер вакыт хәтерли алмады. Әмма шул көннән соң урамнарда, почмакларда, бакчаларда, капка төпләрендә аны бик еш очрата, шул таныш куәтле күз карашының ерактан үзенә кадалып каршы алганын, арттан озак озатып калганын сизенә башлады.

Беркөн дусым-ахирәтләре, туганым-җиңгиләре, тудыклары – бары бергәләп татарча театр карарга барганнар иде. Шунда, уйнаучылар арасында, бер егет үзенең сөйгән кызына бик ялкынланып мәхәббәт сөйләде. Менә шул гашыйк егетне уйнаучы да ошаган кебек күренде, кем белсен, ошый гынамы, әллә үзе үк шулмы? Һаҗәр белә алмады, сорасам, шиккә төшәрләр, тагы гайбәт чәйнәргә тотынырлар дип, телен тешләде.

Менә гаҗәп! Һаҗәрләрнең төньягында кечкенә бакча кисәге бар. Шул бакчаның аргы ягында кечкенә агач өй бар. Монда бер яшь тол марҗа белән әби карчык тора бугай. Бер бүлмәләрен шулай буйдак егетләр, студент-мазарларга ике-өч тәңкәгә фатиргә бирәләр. Башта монда бер студент күренде. Аны кызыл булган, патшага каршы бара имеш дип тотып яптылар. Хәзер атылган имеш, дип сөйлиләр. Аннан соң бер зур буйлы таза шәкерт, – моны Нигъмәт Казый диләр бугай, – кергән иде. Хәзер ул да юк, япканнардырмы, асканнардырмы, белер хәл юк; менә хәзер анда теге, көймәдә очраган нечкә кара мыеклы, үткен, карасу күзле чибәр егет күренә. Үзе бай түгел бугай. Шулай да инде барынча бик пөхтә киенергә тырыша булса кирәк. Чәче җитү. Вакыт-вакыт озын көйгә сузып, «Мәдинәкәй»не җырлап җибәрә. Кычкырып түгел, сак җырлый, шулай да бакчаның агачлары арасыннан искән җил берничә тапкыр:

Мәдинәкәй, бөдрә тал,
Башын кис тә суга сал,
Бигрәк авыр безнең хәл! –

дигән кебек аерым сүзләрен Һаҗәргә китереп җиткерделәр. Сүзләрен күп тотып булмый, әмма көе, тавышы бик әйбәт, бик моңлы – ничектер йөрәккә төшә.

Бу җырлар, бу көйләр хатын белән егет арасында ниндидер бер нечкә җеп сузган кебек була башладылар. Һаҗәр боларны ишеткән саен: «Тукта, тавышы да таныш ич! Кайда гына күрдем соң мин бу егетне элек?» – дип, үзалдына уйга кала торган булды.

Шул уй аны еракка алып китте. Гомер шулай үтәрме? Байның элекке хатыны Суфия апа бар иде. Бичара, йөрәк авыруыннан үлде. Аның улы калды. Чибәр, акыллы егет. Ходаем, моңарчы күрми йөргән: бу Йосыфҗан атасы Кадыйрга аз гына да, инә очы чаклы да ошамый лабаса! Мәрхүм көндәш Суфия бичараны бик суфый булган, диләр. Шулай түздеме икән?

Әллә ул чакта Кадыйр башкача булдымы икән? Әллә Суфия апа да яшьлек канына чыдамый гөнаһ кыйлдымы икән? Йосыфҗан шул гөнаһтан, шул уйнаштан дөньяга килдеме икән?

Илаһым, хуҗам, кем гөнаһ кыйлмас, кем түзәр... Хатын булып яратыл. Тамырларыңда утлы кан кайнап ташсын! Син ир кочагында ят, ләкин хатынлыкны белмә, татыма! Ходаем, үзең чыдам бир! Харап, акыл томалана, йөрәгеңне ялкынлы дәрт дулкыны каплый, Ходай сакласын: менә төнлә яткан җиреңнән сикереп торырсың да яланбаш, яланаяк көе урамга йөгереп чыгарсың, анда беренче очраган ныклы ир егетнең кочагына ташланырсың! Илаһым, хуҗам, үзең чыдам бир! Үзең сабырлык бир! Ни булыр, гомер шулай үтәрме? Менә бит язлар килә, дөнья йөзе яшел хәтфәләргә, аллы-гөлле, кызыллы-зәңгәрле чәчәкләр, хуш исле матур гөлләр белән бизәнә – бөтен жир өсте яңа дәрт белән, яшәү дәрте, сөю-сөелү дәрте, иркәләнү дәрте белән ялкынланып кайный башлый – шул чакларда ничек түзәрсең! Ходаем, үзең сабырлык бир! Үзең чыдам бир. Гөнаһтан, хурлыктан үзең сакла!

Ястүгә азан ишетелде. Кадыйр бай әзерләп куелган җылы сулы комган белән тәһарәт алды да, соңга калам бугай, Гали хәзрәт белән Кәрим Гайфине, Гыйльман абзыйны да күрәсем бар иде дип, ашыга-ашыга, киң кама читле намаз тунын киеп, мәчеткә китте.

Һаҗәр ялгыз калды. Уйлар тагын миен каплады. Яшь канның ташуыннан, язгы кичләрнең мәхәббәтле дулкыннарыннан исергән башын кая куярга белмәгән бер хәлдә, иңенә соры мамык шәлен салды да бакча як тәрәзәгә килде.

Килсә, ай яктысында, агачка сөялгән килеш, теге егет басып тора. Ничектер, әллә кайчангы якыны кебек, вәгъдәле күрешүгә чыгуын көткән кебек тоелды. Сабыры югалды, үзен тота алмады, яшь дулкын аны каядыр кочаклап алып китте. Ул тәрәзәгә якын ук килде, егет белән күзгә-күз карашты да: «Хәзер чыгам. Урам чатында мине көт!» – дигән мәгънә белән баш селекте.

## XXXIX
## МИН КЕШЕ ХАТЫНЫ

Ике йорт аша аптека бар. Һаҗәр, кара-соры мамык шәлгә төренә төшеп, як-ягына бер-ике күз ташлады да, Һавалы, салмак атлап, шул аптекага керде.

Егетнең йөрәге суга. Башы каушый... Аяклары калтырыйлар. Ни эшләргә? Шулаймы икән? Ялгыш күрмәдеме, хатын чынлап та, башын чайкап, аны чакырдымы? Ләкин нигә уйлана? Ни булса – шул булыр! Калтыраган куллар белән аптеканың ишеген ачып җибәрде. Анда яшь, чибәр хатын нидер сатып ала. Егет тагы аптырый, тагы каушый. Җүнләп кирәге

булмаса да, карт провизордан[1] бөтенләй ят-чит тавыш белән үзенең актык акчасына хинин, аспирин сорый. Һаҗәргә күтәрелеп карый алмый, башлап бер сүз әйтерлек куәтен югалта. Үзе: «Чыгып китә бугай! Тагы бер сүз дәшми калам бугай!» – дип, коты очып, каушау утында яна башлый. Һичшиксез шулай калачак, теле әйләнмәячәк, бер сүз әйтә алмаячак иде; хатын үзе, акча түләргә дип, кассага таба һавалы, салмак атлаган килеш борылды да шунда үзен кая куярга белми буталган Җиһангир алдына кисәктән туктады. Бөтен ихтыярын, акылын югалтып барган тавыш белән:

– Сез нигә минем артымнан болай йөрисез? Мин кеше хатыны ич! – дип салды.

Җиһангиргә шул җитте. Инде дөнья анықы иде. Аңар беренче сүзне әйтү, бер тапкыр башлап җибәрү генә мөшкил. Бер башланса, ул алып китәчәк, җиңеп чыгачак, әлбәттә. Хатын сүзен әйтеп бетерә алмады, егет каты басып аның янына ук килде, үткен карашы белән күзләренә йотылды:

– Гафу итегез! Мин белмим... кеше хатыны түгелме?!. Мин йөрмим... сезнең мин... мин ихтыярсыз... – дип, нидер буталды да, кыюлык белән килеп, хатынның кайнап торган кызу, йомшак, тулы кулын тартып алып кысты. Кулыннан аның кулларын ычкындырмыйча, тагы нидер тезеп китте.

Хатын аңар йөзе белән әйләнде, күз карашы белән егеткә йотылды. Ни булса шул булыр дигәндәй, бер ихтыярсызлык эчендә акрын әйтте:

– Уң якта беренче капкадан кер дә мине шунда көт! Сак бул! – диде.

Егет акрын гына башын иде дә тиз-тиз атлап тышка чыкты. Хатын әйткән җир – бер ташландык йорт икән. Шунда үз ялкыны эчендә көтә башлады.

Һаҗәр тиз чыкты. Үзенең зифа буе, тулы гәүдәсе, калку күкрәге белән бераз уйнаклый төшеп килде дә, егеткә карап, кулларын алды, баягы сүзләр кабатланды:

– Мине куегыз! Мин харап булам... Мин бит кеше хатыны! – диде.

Ләкин актык сүз әйтелгәндә үзе егетнең кочагында иде инде. Күп сүз сөйләшә алмадылар, Һаҗәр кинәт айныды:

– Ах, кеше килеп чыгар! Эләгербез, икебез дә харап булырбыз!.. – дип, чыгып югалды.

Шул көнне Җиһангир аңа хат язарга утырды. Кырык тапкыр язып бозды. Мин синең өчен яшим дип, мең төрле хыялый күренешләр аркылы үзенең мәхәббәтен аңлатырга теләде. Сүз арасында бу бүлмәгә күчүе дә тик аның өчен генә икәнен ачты. Монда Нигъмәт казый дигән бер «аю» тора иде. Аңа яхшы бүлмә табып бирдем, аны күчердем... Мин инде үз бүлмәмдә

---

[1] *Провизор* – фармоцевт.

күрәсем, бөтен дөньядан аерылып, тик икәү генә бикләнеп, берничә минут гомер итәсем килә – сине көтәм. Урамда, ташландык йортта, бакчаларда түгел, үземнең ялгыз аулак бүлмәмдә көтәм! – дип язарга теләде. Ләкин ямьсез, мәгънәсез чыкты, бер очрармын, боларны сүз белән әйтермен, сүз белән аңлатырмын, әмма хатлар тик гыйшык белән туларга тиеш дип, яңадан язарга кереште.

Мәдрәсә дулкыннары көнендә, шәһәр бакчасына берничә минутка чыгармын дип, үзе әйттергән иде. Анда эчке-тышкы идарәнең җыелышы башлануга, шәкерт эчендә иң зур тарихи сугыш минуты килеп җиткәнгә дә карамастан, ул канатлы коштай очып бакчага килде. Ул чакта шелтә дә алды. Шелтәләре, әлбәттә, бер тиен иде. Ләкин авыры шунда булды: Һаҗәр үзе килә алмады, егет асрау аркылы бакчаның куе агачлы почмагында бары Һаҗәрнең: «Сизенәләр бугай, тирә-ягымны карчыклар белән әйләндерделәр...» дигән мәгънәдә кечкенә хатын гына алды.

Менә үткән төн ул эт авыз шпион Миһраннар да әллә ничаклы гайбәтләр белән башны катырдылар. Тентү арасында: «Бишәү җитмәгән, инде алтынчыга ир хатынын харап итмәкче буласың икән!» – дип өрделәр.

Болар барлыгы Җиһангирнең башын әйләндерде. Ул ничек, кайдан, кем аркылы барып, Һаҗәрнең хәлен белү теләге белән янды; аны бер күрү, аның белән кавышып, туйганчы бер сөйләшү өчен бөтен дөньясын бирергә әзер булды. Менә шундый өзелеп көткән, өмит өзәр чиккә җиткән сәгатьтә Һаҗәрнең килеп керүе егет өчен әйтеп булмый торган бер шатлык, бер бәйрәм булды. Хатын яшен кебек ялтырады, дәртле ялкын эчендә егетне яндырды да юк булды, ләкин бер чыккач, кире борылып: «Иртәгә, ястүгә азан әйткән чакта, Мөнасыйповларда бул!» – дигән сүзе – бу инде егет алдына матур, якты, ялкынлы яшьлекнең тагы да гаҗәп сәгатьләрен өмитләндерделәр.

## XL
## ДОШМАН КҮРӘ

Икенче көнне Җиһангир ахшамнан ук киенде. Нигъмәт казыйдан алып торган сәгатьне өстәлгә ачып куйды. Аның секундларын, минутларын санап үткәрергә тотынды. Ләкин вакыт гаҗәп әкрен кузгалды. Минуты – сәгать, сәгате – ай, ел булып үтте. Шундый газап белән инде барыр вакыт якынлый дип урамга чыкса, ниндидер бер кызмы, яшь хатынмы, шырпы яндырган да болар капкасының номерын карап азаплана. Ләкин калай югары, туташ ничаклы үрелсә дә, укый алмый, шырпы сүнә. Ридикюленнән шырпы кабы чыгара, тагы яндыра, тагы сүнә... Шулай азапланганда, ашыгып капкадан чыккан Җиһангирне күрү белән русча сорады:

– Бу ничәнче номер?! Җиһангир Гыйбаев бу йортта тормыймы?.. Белмисезме?.. – диде.

Егет башта шикләнеп карады, кичә мәдрәсә яшьләренең зур бәрелеше булды, бу аның башында барды, анда жандармерия, тентү ясап, әллә ничаклы нәрсәләр, язулар, хатлар алып китте. Җиһангирнең үз кесәсеннән дә байтак әйбер шунда эләкте. Бу марҗа кызы шпиондыр, мине бүген сагалап, төнлә тотып алырга әзерләнәләр булыр, дигән шиккә төште.

Ләкин кызның матур, яңгырак, музыкалы тавышы аңа таныш кебек булды, ул шөбһә эчендә дәште:

– Туктагыз, сез Илбаева туташ түгелме? Тавышыгыз ошый, – дип сорады.

Кыз шатлыгыннан сикереп җибәрде, күбрәген русча катнаштырып, иске мирза теле белән:

– Менә бәхет! Мин сезне эзлим ич! Сез Җиһангир Гыйбаев иптәш буласыз бит, – диде дә шунда ук үзе, матур сайрап, култыгыннан кысып алды: – Гаҗәп булды бу! Әйдәгез хәзер! Мин сезнең арттан килдем! – дип сөйләнә-сөйләнә, Гыйбаевны урам буйлап үзе белән алып китте.

Җиһангир башта бу ни хәл дип аптырый төште. Ул бу яшь, үткен туташны электән берничә тапкыр күргән иде. Бервакыт урамда Булат белән бергә култыклашып барган чакларын очратты. Булат, туктап, Җиһангир белән сөйләште, әмма кыз, нурлы күзләрен уйната биреп, тик торды, исәнләшмәде, кулын да бирмәде. Икенче бервакыт курсистка Разия туташ белән бергә сәяси түгәрәкләр була торган өйгә килеп керде, анысында түгәрәк шәкертләре белән бераз чытлыкланып, шаянланып сөйләште: «Сез, – дигән булды, – Разияны тыңлавын тыңлагыз... Француз революциясен сөйләтегез, әмма партияләр турында аңар егылмагыз!.. Менә мин үзем килеп, аның белән талашырга уйлыйм әле. Ул сезгә Маркcның «Капитал»ын да укытмый икән. Ансыз ничек аяк атлыйсың!.. Менә мин килеп, Разия белән талашырга уйлыйм», – дип, чыгып йөгерде.

Җиһангир шуннан соң Илбаева Гәүһәрне очратканы юк иде. Тик каядыр колагына чалынды: теге Фәхри күп сөйләде бугай, – үзе матур булса да, көнче нәрсә икән. Нина белән Булат өчен җәнҗал куптарды бит дип, нидер лыгырданганын ишетте. Менә кичә, тентү көтеп, мәдрәсә бүлмәләрендә бикләнеп яткан ялыктыргыч озын сәгатьләрдә, кемдер тагын бер гайбәт ташлады: «Ул матур кыз, – ди, – Зариф Булатовның сөйгәне булса да, астыртын теге Кадыйр бай малае Йосыфҗан белән дә чытлыклана имеш», – ди.

Бармы, юкмы, әллә бөтенләй ялганны сөйлиләрдер, – Җиһангир хәзер аларны уйлап тора алмады. Кыз, егетне култыклап, урам буенча барганда,

үзенең мәсьәләсен аңлатты:

– Менә, – диде, – эш шулай: Булат әләкте бит... Мин, аның невестасы дип, күрешергә теләдем, җибәрмәделәр. Прокурор отказ куйган. Иртәгә анасы Булат янына бара икән. Шуның аркылы кайбер нәрсәне Булатка тапшырасы бар. Сезнең миңа кирәк булуыгыз шуннан килеп чыкты! – диде.

Җиһангирнең ястүгә азан әйткәндә бик зур эше бар. Ул шуңа ашкына. Бу «сагыз»дан, бәлки, котылып булмасмы дигән өмит белән карулашып бакты:

– Сез, Гәүһәр туташ, – диде, – Булатның анасы кайда торганын үзегез беләсез. Нигә мине анда өстерисез?

Егетнең киреләү чамасын сизгәч, кыз аны ныграк тотты, ярым шаярып, чытлыкланып, русчалап сәбәбен әйтте:

– Миңа сезнең белән бару күңелле, – менә бер булдымы?.. Аннан соң ул караңгы пычрак урамнардан ялгыз барырга мин куркам, – ике булдымы? Инде боларны бер якка ташлап, чынын әйтсәм, өченче төп сәбәп бар: Булатның әнкәсе мине күрә алмый, мине үзенә дошман саный, өенә барсам, йомышымны сөйләтми куып чыгарыр дип куркам. Шуңа күрә мин сине алдым... Инде аңладыңмы?

Җиһангир, гаҗәпсенеп, туташка карады:

– Нидән ул алай? Карчык нигә Сезгә дошман? Әллә рәнҗеттегезме?

Гәүһәр тирән бер борчу белән җавап кайтарды:

– Юк. Бертөрле дә рәнҗеткәнем юк. Нииндидер бер бәхетсезлек инде шулай. Мин ераклап ишеттем: йөзендә, күзендә мөселман төсе юк, бөтен кыланышы коеп куйган марҗа гына дип әйтә икән, ди. Булатны аздырыр, аңа кияүгә чыгар дип коты очадыр, ди. Андый урыс кебек марҗаны ничек мин килен итеп өемә кертермен, аның бисмилласы булмас, догасы булмас, чип-чи марҗа ич, урыс кебек ич дип әйтәдер, ди.

Кыз Әсхәпҗамал карчыкның дошманлыгын үзенә бер бәхетсезлек итеп шулай сөйләде дә, почмактан борылгач, бик күп русчалар белән бутап, тагы өстәде:

– Минем менә шундый ике бәхетсезлегем бар. Әсхәпҗамал карчык тагы бер хәл. Менә Гәрәй дә миңа дошман бит!

– Ул нигә тагы?

– Һич аңламыйм. Башым җитми. Дөресен әйткәндә, ул бит тупас, каты кеше. Ну үзе революционер. Менә бит татар арасында казармага, солдат эченә беребез дә бара алмый идек. Ул, килеп төшүгә, казарма белән яшерен бәйләнеш ясады. Аның пулеметчы, артиллерист ике солдат дусты бар. Шулар белән полкка җеп суза. Без бит менә: түгәрәк, дибез, прокламация, митинг, дибез. Ә ул әллә кая, җир астында, бездән дә яшереп, рус эшчеләре белән

бергәләшеп, корал склады асрый. Бомба, маузер саклый, динамит саклый. Ул татардан партиядә беренче боевик. Менә шулар өчен мин аны үзен бик яратам. Ул миңа дошман карый. Телдән әйтми, әмма йөрәгем сизә: ул миңа ике тиенлек тә ышанмый. Мин моңа бик обижаться итәм[1]. Мин эшлим ич, мин дә утка-суга барырга әзермен. Нигә миңа ышанмаска? Нигә мине читкә кагарга? Минем ни гаебем бар?

Сүз кинәт киселде. Кыз, шәһәр читенә таба якынлап, бер ярлы, пычрак, баткак тыкрыкка туктады. Монда кечкенә, вак, тәбәнәк өйләр. Урамның уртасында йөрерлек түгел – баткак, әмма өй буйларында шул баткак эченнән тар сукмак бар. Сулы, пычрак урыннарга таш, кирпеч, такта салганнар. Ләкин караңгы кичтә боларны ачык күреп булмый, кыз үзе бата-чума алдан китте.

Җиһангир, аягын пычратмас өчен бик саклык белән атлап, җәфаланып бетте. Бөтен урамда сүнәр-сүнмәс утырган керосин фонарь бар. Шуңа җиткәч, сәгатен чыгарып карады: ястүгә вакыт бик якынлаша, азан килеп җитә инде. Ләкин Гәүһәрнең моны коткару ихтималы, әлбәттә, юк. Менә балчык урам. Исеме дә шулай икән: татарлар Балчык урам дип йөртәләр икән. Ләкин шунсы бераз ару – бик әйбәт сукмак салынган. Сулы пычракларга таш, кирпеч, такта ыргытылган. Менә почмакта кибет. Аны үткәч, ике йорт аша – кечкенә, иске агач өй. Туташ шуңа җитү белән кинәт туктады, Җиһангирнең кулыннан алды:

– Менә, – диде, – Әсхәпҗамал әби шунда тора. Хәзер сиңа эшнең сер ягын ачыйм. Менә сиңа кечкенә кәгазь. Анда шифр белән язылган. Карчык иртәгә төрмәгә, улы Булат янына күрешергә барачак икән. Син иплэп исәнләш, күрешеп, кул күтәреп дога кыл. Әби, диген, синнән үтенеч бар иде, диген. Гәүһәр туташтан димә, харап итәрсең. Үземнән, диген, улың Булатка бик кирәкле йомышым бар иде, шуны язган идем, диген. Әмма урыс жандар дин дошманы бит, уртага киртә була, минем язуны Булатка бирдерми, диген. Син, диген, күрешә барганда шул әманәтне тапшырсаң, гомергә дога кылыр идем, Әсхәпҗамал әби, диген! Аңладыңмы?

Кыз, елмаеп, үз өйрәтүенә үзе рәхәтләнеп көлде:

– Менә шулай сөйләп, карчыкның йөрәгенә кергәч, әйт: әби, диген, дошманның күзе дә, кулы да тимәсен. Бу кәгазьне, диген, авызыңа, уртыңа кабып бар. Күрешкәндә Булат белән үбеш, диген, үбешкән чакта Булатның авызына сал, диген. Ярыймы?

Җиһангирнең башында азан белән Һаҗәр генә иде. Шулай да болай ваклап, чәйнәп йоттырган нәрсә аның хәтеренә киселеп керде. Ул бер сүзен

---

[1] *Обижаться итәм* – үпкәлим.

дә кабатламастан: «Моны да аңламаска, мин сыермы?» – диде. Кыз, ридикюлен ачып, кечкенә кәгазьне егеткә бирде, кечкенә капканы ачты да, артыннан этәргәндәй төртеп, йорт эченә кертеп җибәрде. Үзе, бер яккарак китеп, битендәге калын пәрдәсен ачты, эшләпәсен төзәтте дә, Җиһангир чыкканын көтеп, арлы-бирле йөри башлады.

## XLI
## ИКЕ БАЛА

Җиһангир капкадан акрын гына керде дә йорт уртасына таба тар бер сукмак – нечкә такта буенча атлады. Йорт эченең түрендә кечкенә өй. Аның вак дүрт өлгеле ике тәрәзәсе бар. Анда сыек кына якты күренә. Егет, аягын пычратмас өчен иплэп атлый-атлый барды да, кечкенә өйнең тәрәзәсен шакылдатты. Анда нәрсәдер күренә, ниндидер күләгәләр бер аерылып, бер якын килеп селкенәләр. Ләкин тавышы ишетелмәде; ахры, чыгып ачучы булмады. Азрак көтте дә егет ишеккә килде. Бикләнме, түгелме – белер хәл юк. Акрын гына шыкылдатырга тотынды, һаман җавап юк. Ләкин эчтә җан иясе бар: анда йөриләрме, сикерәләрме, – ничектер кузгалалар, ара-тирә шаркылдап көлешәләр. Җиһангирнең сабыры бетте, ни булса шул булыр, диде дә, ишекне шалтыратып ачып, өйгә басып керде. Керсә, анда – берсе тугыз-ун, икенчесе унбер-унике яшьләрендә булыр ике кыз; үзләре нидер такмаклыйлар, үзләре шул такмак көенә биергә өйрәнәләр. Көтелмәгән кеше кереп баскач, башта аптырап, катып калдылар, аннан пырхылдап көлеп, мич алдына таба сикереп качтылар. Зуррагы үткен нәрсә икән: түргә, тегү машинасы өстенә куелган лампаның филтәсен күтәрде, бүлмәне яктыртты да кунакка каршы килде. Җиһангир, бу ябык аксыл битле, озынча нечкә гәүдәле кыз баланы күреп, хәйранга калды: бу – коеп куйган Булат иде. Төсе, күзләре шул. Елмаюы шул. Авызын ачып бер сүз әйтүгә тавышы да Булатка ошап чыкты. Тик баланың тавышы нечкәрәк, музыкалырак иде. Егет текәлеп карады:

– Сеңелем, миңа Булатның әнкәсе Әсхәпҗамал әби кирәк иде. Ул монда торамы? – дип сорады.

Кыз бу соңгы елларда полициядән, жандардан, шпионнан җәдәп беткән, куркып, коты очып, инде хәйләләнеп чыныккан иде. Җиһангирне шундый бернәрсә түгелме дип уйлады, юри белмәмешкә салынды:

– Булат дигәнегез кем? Зариф абыйны әйтәсезме? Ул төрмәдә ич! – диде.

Кунак аңа аңлатып биргәч кенә, якынрак килеп, битеннән, торышыннан дусмы-дошманмы икәнен сизәргә тырышты. «Юк, алай шиклегә ошамый. Бу – берәр иптәшедер Зариф абыйның!» – дип, эченнән искәрде дә такылдап

китте:

– Габдрахман абый өйләнә икән бит. Теге талчукчы, тискәре Сафа картның кызы Нәфисәгә өйләнә, ди. Безнең әнкәйне шунда, туй алдында бирнә-мазар тегәргә дип, үзләреннән кайтармыйлар... Таң иртә китә, ярты төндә кайта. Мин үзем дә куркып бетәм... Әле менә ярый, Хәдичә җиңги үзенең кызы Маһирәне миңа иптәшкә җибәрде. Икәү булгач, рәхәт, – диде дә, матур елмаеп: – Әле без сез килгәндә биергә өйрәнә идек!.. – диде. Шунда ук бөтенләй елмаюны онытып: – Әллә абыйдан хәбәр бармы? Бик каты кыйнамадылармы икән? Ни килсә безгә килә, әткәйне яндырып үтерделәр... инде Зариф абый да әләкте, – диде.

Кызның күзенә яшь килде, Җиһангир сүзне бетерде:

– Миңа синең әнкәңне ашыгыч күрергә кирәк. Бүген ничәдә кайтыр? Иртә белән ничәдә теге Габдрахманнарга китәр?

Кыз чатнатып әйтте:

– Бүген көтмәгез – ярты төнсез кайтмый. Иртәгә кояш белән бергә килегез! – диде.

Кечкенәрәк кыз бер сүз дәшми, һаман күзен алмый карап торды. Лампаны кулга алдылар да, икәүләшеп ишек ачып, сукмакны азрак яктыртып, озата калдылар.

Анда, капка төбендә, Гәүһәр туташ каршы алды. Баягыча култыклады да:

– Җә, ни бетердең? Карчык без әйткәнгә күнәме? – дип сорады.

Егет ни булганын сөйләп бирде. Бергә шәһәргә кайттылар. Туташ Булатның анасына бирергә тиешле кечкенә кәгазьне кире үзенә алды.

– Мин, – диде, – сезне иртәгә кояш белән бергә килеп уятырмын, тагы барырбыз... Сезгә тагы бер йомыш: бүгеннән калмый Разияны барып күрегез. Ул Йосыфҗанга әйтсен: ул сүзне җиңел ычкындырды, алты йөзне һаман бирми бугай. Ә анда, төрмәдә, Баязид кан косып ята. Бирәме, юкмы, бирерлек булса, тизләтсен. Давыт бит Баязидның кардәше, бу эш аның өстендә. Син хәзер Разияга кер – ул Давытка барып, менә шул эшне ашыктырсын! Шулай әйтте дә: – До свидания! Иртәгә иртә кузгал! дип, кул кысып, чатка борылды.

## XLII
## АЗАН ӘЙТКӘНДӘ

Егет көтелмәгән бу вакыйганы ут эчендә кичерде. Баязид, Разия мәсьәләләре ахырдан каралыр, диде дә мәчеткә йөгерде. Аның һәммә тәрәзәләрендә балкылдап утлар яна. Димәк, ястүгә әллә кайчан кергәннәр. Әнә мәчетнең фарыз бүлмәсендә берничә саф булып, ниндидер күләгәләр бер

яталар, бер торалар, тагы яталар, тагы торалар. Димәк, әллә кайчан азан әйтелгән. Әллә кайчан камәт төшерелгән[1]. Инде әнә ястү намазын укый да башлаганнар: «Их, соңга калдым... соңга калдым...» – дип, Мөнасыйповларга таба ут кебек очты.

Мөнасыйпов – зиярәт мәхәлләсенең мәктәбендә мөгаллим. Бу мәктәпне Кадыйр бай карый. Монда мөгаллимлек урыны аңа хатыны Фатыйханың үтенүе буенча, Һаҗәр сүзе белән бирелде; юкса алар элек һәр ел авылдан авылга күчеп, урын табар өчен, һәр ел көз Мәкәрҗәгә барып, көз көннәрендә гәзитләрдә игълан биреп, җөдәп бетәләр, дүрт-биш ай эшләп тапкан акчалары җәй көне эшсез, урынсыз чакта тамак туйдырырга да җитми иде. Бу зиярәт мәхәлләсендә нык утырып калдылар. Җәй-кыш шундалар. Мөгаллимгә торыр өчен чибәр генә квартир сыман нәрсәсе дә бар. Болар – еллар буенча әле анда, әле монда сөрелеп йөргән Фатыйхаларга бик зур бәхет булып, бик рәхәт, җылы оя булып төште. Бу җылы оя тик Һаҗәр аркылы гына насыйп булганга, Фатыйха үзен Һаҗәр алдында мәңге бурычлы дип исәпли, ни генә әйтсә, шуны үтәргә әзер иде. Җиһангир белән кавышу урыны итеп квартирларын бирү башта ничектер уңайсызрак тоелды. Мөнасыйпов үзе бераз эчтән хурланды, ләкин бара торгач мөгаллим үзе белмәмешкә салынды, күз йомды, хатыны Фатыйха өйрәнеп китте, гади эш итеп карый башлады.

Җиһангир, гадәт буенча, арткы капкадан акрын гына керде дә кечкенә тәрәзәгә чиертте. Өйдәге утның ишеккә таба кузгалганы күренде, эчтән егеткә таныш сак тавыш килде:

– Кем бар?

– Мин, акыллым, мин...

Ишек ачылды. Анда Һаҗәр иде. Хатын сагыну катнаш курку уты эчендә күренде. Бераз иркәле шелтә белән:

– Ни булды? Нигә син болай кичектең? Әллә кайчан азан әйттеләр ич! – диде дә Җиһангирнең күкрәгенә сыенды.

Егет, хатынның ялкынлы кулын кысып, иреннәреннән үпте.

– Әйтмә, җаным! Көтелмәгән бәла чыкты, сөйләрмен! – диде дә, биленнән алган килеш, эчкә таба үттеләр.

Бай түгел, ләкин барынча пөхтә җыештырылган кечкенә квартир.

Хатын тиз җанланды, бөтенләй хуҗа роленә кереп:

– Залда булса, тәрәзәдән утны күрәләр!.. – дип, тагы эчкә, ятак бүлмәсенә алып керде; керә-керүгә тәрәзәнең пәрдәсе өстенә чигүле намазлык корды, урамның һичнәрсәсе күренмәвен ваклап, нечкәләп карады да, бөтенләй үз булып, бите, иреннәре янып барган, бөтен тулы тәне

---

[1] *Камәт төшерү* – намаз алдыннан аягүрә укыла торган дога.

дулкынланып ялкынланган хәлдә егетнең тезенә килеп утырды, кочагына кереп югалды...

Ләкин ул гадәттән тыш тынычсыз иде. Беренче ялкыннардан айну белән, тагын барып ишек, тәрәзәне карады, тагы йөрәгенә урын таба алмый Җиһангирнең тезенә утырып, кочагына керде.

– Җә, – диде, – ник кичектең? Әйт! Мин бит монда үпкәләп беттем. Тагы биш минуттан китмәкче идем, – диде.

Җиһангир вакыйганы сөйләп бирде. Ләкин барын да дөрес көенчә әйтә алмады. Гәүһәрнең матур, чибәр, яшь кыз икәнен яшерде, тәмәке тартып йөри торган бернәрсә шунда, үзе бик усалга ошый, дип бетерде. Булатка бәйләнешле яшерен якны да, Гәрәй турындагы әңгәмәләрне дә калдырды, бары тик Булатның әнисе белән сеңлесен, пычрак тыкрыктан бата-бата баруын киңәйтеп хикәя кылды. Ләкин хатын моны җүнләп тыңламады да. Аның үз башында бүтән мәсьәләләре бар иде, шуларны бер кызып, бер өзеп сайрады.

Бу арада ире Кадыйр нәрсәдер шикләнә башлаган икән. Юк өчен кызып, дулап бара, ди. Унике приказчикның ташлап чыгуына бер дә исе китмәгән иде. Урыс, татар гәзитләрендә: «Бойкот, бойкот!» дип кычкыра башлагач, ачуы бик кабарып китте, губернаторга менәргә кирәк дип саташа башлады. Ашка утырса, чәйгә утырса һаман шул турыда тиргәнә торган булып китте, ди. Кичә мәдрәсәдән кайткач, яман сүгенде дә: – Күпме акча тотам. Мәдрәсә салып бирдем. Жалуния[1] бирәм. Башка байларны көчләп бирдерәм. Бу нинди кадерсез халык! Миңа рәхмәт урынында өстемә акырып киләләр, минем алдымда мәдрәсәнең әйберләрен вата башлыйлар... Башларын Себердә черетергә кирәк... Бары да шул Гали хәзрәттән булды, мин аңа әйттем: тезгенне каты тот, дидем, ул буш куйды, инде хәзер бары да бәйләүдән ычкынган эт кебек котыралар... Алай кыйлансалар, бер тиен бирмәм – дип, сәгатьләр буенча зур залда йөреп сүгенде, – ди. – Төнге сәгать уникедә үзенә Гали хәзрәтне, Кәрим Гайфине алдырып, иң элек аларны яман тиргәде, аннан бергәләп киңәштеләр. Байның туган абзасы Шәрәфи хаҗи бар. Дәүләт ягыннан кимрәк. Фикер ягыннан бөтенләй Кадыйрга каршы инде. Ул кадим фикерле муллаларны, иске схоластик мәдрәсәләрне, ишаннарны карый, зәкятен, садакасын шуларга гына бирә иде. Энесе Кадыйрга җәдит-кадим талашы сәбәбеннән сигез ай буенча килми йөри иде. Кичә, Гали хәзрәт белән Кәрим Гайфи утырган чакта, төнлә сәгать бердә кызып килеп керде дә, ашка, чәйгә утырмыйча, ишек төбендә аягүрә баскан килеш, яман шелтәләргә тотынды, ди. Менә, дип әйтеп әйтә, ди, мин сиңа әйтмәдемме? Җәдиткә мал

---

[1] *Жалуния (жалование)* – хезмәт хакы.

түкмә, харамга китә димәдемме? Бервакыт үз малың үзеңнең якаңнан алыр димәдемме? Менә нәрсә булды: ун ел укыткан шәкертләрегез, Гали, синең дә, Кадыйр, синең дә битеңә килеп, лачт итеп төкермәделәрме? Төкерделәр! Битегезгә төкерделәр... Бары да шул җәдит бәласе. Мин сезгә ун ел буе әйттем – тыңламадыгыз... Дөньялыкта хурлыгын күрдегез, инде алда, кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә алдында җавап бирүегезне дә уйлагыз! – дип әйтте дә исәнләшми-нитми, шалтыратып ишек ябып, җенле кеше кебек котырып чыгып китте, – ди...

Шуларга үч иткән кебек, тагы Йосыфҗанның Баязид карыйны хөкемгәчә чыгарту өчен алты йөз сум акча бирергә вәгъдә кылуы, әллә кайдан барып, Кадыйр байның колагына эләккән икән...

Һаҗәр, бер егетнең тезенә ятып, күзенә йотылып, бер сикереп утырып, бу вакыйгага да озак тукталды:

– Бүген, – ди, – шул алты йөз тәңкә өстендә ике тапкыр каты бәрелештеләр, ди. Кадыйр яман шелтәли, атаң мал тапты, дөнья куды, син аны җыен кызыл авызларга өләшә башладың, дип кычкыра, ди. Йосыфҗан моңарчы мәче кебек атасы алдында бик юаш йөри иде. Бүген ул да яман телләнә, ди. Мин, дип әйтеп әйтә ди, сиңа алты йөз тәңкәлек тә тормыйммы? Мин зинданда кан косып яткан иптәшемне коткарыр өчен бер тиен акча да тота алмыйммы? Хәзер андый заман түгел, минем өлешемне бир, мин бу йорттан китәм, мин бу коллыкка түзәр хәлем юк, дип әйтә, ди. Кадыйр, бу сүздән котырып китеп, аяк тибеп кычкырды, ди. Китмәгәең, чәнчел! Дүрт ягың кыйбла! Әмма мин исән чакта сиңа үз кулым белән бер тиен бирмәм, дип кисте, – ди.

Һаҗәрнең зиһене кинәт икенчегә күчте. Ул ашыгып торды да, кулларын егетнең кулбашына куеп, күз-күзгә карашып, матур елмайды:

– Әйт әле зинһар: шәкерт сүккәндә, ул синең исемеңне һаман телгә алды, каторгада башын черетермен мин аның, дип сүгенде, син ни эшләдең анда? – дип сорады.

Җиһангир, хатынны үз янына утыртып, бөтен гәүдәсен кысып алды да кичәге талаш, тентү җәнҗалларын сөйләргә кереште, мәдрәсә ихтилялының[1] кызык якларын, шәкерт белән идарә сугышларын тасвир итте. Устав куелган пыяла рамкаларны түбәнгә – таш идәнгә атып бәргән чакта полиция килеп басуын озак сөйләде, тентүнең көлкеләренә, солдаттан яшерү өчен, Сөләйман Сәйфуллинның бер куркыныч кәгазь кисәген чәйнәп-чәйнәп тә йота алмавына озак тукталды.

Шулай барганда, Һаҗәр кинәт нәрсәдәндер куркынып китә. Сикереп

---

[1] *Ихтилял* – баш күтәрү, бунт ясау.

тора да, пәрдә өстенә тәрәзәгә корылган намазлыкның бер читен ачып, урамга карый. Ишеккә барын, элгечне тарта.

– Юк, бернәрсә дә юк, шулай да күңелем бик курка минем, бер хәл булмаса ярар иде... Ирем утарга киткән иде; анда, Яманташ буенда, безнең җир-сулар, урманнар бар бит, шуларга тирә-якның татар крәстиәннәре басып керә башлаганнар имеш, ди. Ишеткәч тә, шунда чапкан иде. Чиркәсләр бар икән бит, шуларны мылтыклары белән каравылга ялламакчы бугай. Бер-бер хәл булып кайтып килеп төшмәсен, дим... Күңелем бик курка минем, нигә икән, жаным?!.

Егет, хатынның биленнән алып, тезенә утыртырга теләде. Һаҗәр тагы ялкынлана, тагы күзе томанлана, яңаклары кызарып утлана, иреннәре янып бара иде, инде хәлсезләнеп егылам дигәндә, кисәктән сикереп торды да ишеккә йөгерде.

Анда кемдер сак кына шакылдата. Фатыйха икән. Тавышы ничектер борчулы тоелды:

– Һаҗәрбикә, бер-бер хәл булмаса ярар иде. Күңелем бик курка... Байның ике приказчигы белән теге Миһран дигән шәкерт, безнең тәрәзәгә бик карап, ике тапкыр үттеләр... Бер-бер нәрсә сагаламыйлармы икән ул эт авызлар? – диде.

Егет үзен батыр йөрәк саный, юк-бардан курку күрсәтергә яратмый иде. Ләкин ике хатынның вәсвәсәсе аның күңеленә дә керде. Ул Миһран эт монда да килеп җитәрме? Кичә тентү вакытында әллә нинди гайбәтләр белән баш катырган иде! Ике приказчик – кемнәр булыр? Байның унике приказчигы эш ташлады. Бойкот күтәрелде. Әмма чыкмый калган карагруһ приказчиклар да бар иде. Болар – шул калдыклардан икесе булыр. Ләкин Җиһангир боларның кемнәр булуын белеп бетә алмады. Хатыннарның куркулы шөбһәләренә җиңелә башлады.

Аның үзенә бернәрсә дә түгел. Аңа дөнья – Һаҗәр. Ләкин сөекле Һаҗәр ил гайбәтеннән бик артык курка. Әгәр роман дөньяга фаш ителсә, Һаҗәр өчен үлем хурлыгы булачак, якты көнгә чыгарлык хәле калмаячак.

Тиз-тиз киенделәр.

Һаҗәрнең йөзе агарып үлде. Иреннәре катты. Күзләре куркыныч белән агарып туңдылар.

Болар чыкканда төн караңгы, җир-күк куе каралык эченә уралып югалган, ерак күкнең якты йолдызлары кечкенә бриллиант булып янып торалар, ләкин җиргә аларның яктысы килен ирешми иде. Фатыйха үзенә яхшы таныш юллар буенча, күрше урыс йорты ашасыннан, Һаҗәрне озата китте Җиһангир туры урамга чыкты. Бераз юл яздыру булсын дип, акрын, борчулы адымнар белән шәһәр бакчасына таба юнәлде.

Анда да тын. Агачлар куе караңгылык эчендә нидер тыңлаган кебек шым гына утыралар. Ләкин егет бу авыр тынлык эчендә тынычсыз яшьлек ялкыны утында яна башлады: «Ни булыр? Тагы бер газап килеп чыгармы? Ул Миһранга нәрсә кирәк? Үч алмакчымы? Сагалап торып, мине дә, Һаҗәрне дә хур итмәкчеме?»

Юк, Җиһангир үзе өчен курыкмый! Аз гына да курыкмый. Яшьлек бар. Яшь йөрәктә эш-көрәш дәрте белән, мәхәббәт белән кайнаган ялкын бар. Мәдрәсә яшьләре өчен көрәш тә, Һаҗәргә булган гыйшык та – икесе шул бер ялкыннан көч алалар. Юк, егет үзе өчен куркырга уйламый.

«Әмма Һаҗәргә ни булыр? Ничек аны коткарырга? Ничек аның йөрәгенә батырлык ялкыны салырга? Гайбәтче карчыклар сөйлиме? – төкерсен! Дөньяда сөюдән югары ни бар? Ялкынлы яшьлек өчен сөю гаепме? Без бармы? Без сөябезме? Сөйсәң, Миһраннан да, Кадыйрдан да курыкма! Дөнья бар, тормыш бар, без яратышабыз – безнең бәхетебез кайнап таша. Әмма Кадыйрлар безне аермакчы, яңадан кол итмәкче икән – ялкынлы яшьлек моңа җиңелмәс. Киртәләрне, тау-ташларны җимерер, диңгезләрне яндырып кичәр! Ләкин Һаҗәргә ничек боларны аңлатырга мөмкин? Боларны аңлармы? Дөньяда сөюгә каршы торып та, җиңелми калган һичбер төрле көч юклыкны Һаҗәр төшенеп җитәрме? Әллә шул никах аның да йөрәген сүндерерме? Йә булмаса, Кадыйрның алтыннары, атлас-җефәкләре Һаҗәрнең аяк-кулына богау булып багланырлар, аны шул иске коллыгында калдырырлармы? Иртәге көн ни китерер, ни китерер?»

Егет караңгы бакчаның озын, биек агачлары арасында озак йөрде, ләкин йөрәген газаплаган мәсьәләгә җавап таба алмады. Шул вакыт кинәт Гәүһәрне хәтерләде, аның тапшырган йомышы исенә төште, зинданда кан косып яткан дусты Баязидны коткару эше әле урыныннан аз гына да кузгалмый торганын уйлады да, кызу-кызу атлап, бакчадан чыкты – Гәүһәр әйткән йомышлар артыннан йөгерде.

## XLIII
## БАЙБӘТЧӘ

Озак бармый, шөбһәгә төшә: «Тукта, бу Гәүһәр ни дип мине Разиягә җибәрә? Ул пычагыма кирәкме? Баязид өчен алты йөз турында сөйләп бирергә минем үземнең телем юкмы? Ни дип мин Ширинскийлар йортына өстерәлим?» Шул шөбһә белән кире борылырга теләгәндә, яңадан алга китте: «Юк, ярамас, моның берәр мәгънәсе бардыр, ул Гәүһәр тагы тигәнәк кебек килеп ябышыр: нигә әйткәнчә эшләмәдең дип күзеңне ачырмас. Ерак түгел бугай. Менә Екатеринский урам. Менә икенче чат. Менә чаттан икенче капканың уң ягында кечерәк сары өй. Бу – Ширинскийларның йорты булырга

тиеш».

Егет, шырпы яндырып, номерын карады. Шулай туры килә. Ул бераз каушабрак барды да, урам як баскычтан күтәрелеп, ике якка ачылмалы, ак буяулы ишекнең ун ягындагы электр кыңгыравының төймәсен басты.

Кыңгырау челдерәп тә өлгермәгән булыр – эчтән каты басып аяк тавышы килде, ишек шалтырап ачылып китте. Аннан өстенә күгелҗем төсле кара костюм, башына киң читле кара эшләпә кигән, кара-туткыл йөзле, озын буйлы бер туташ, кайдадыр бик ашыккан кеше кебек, җилләнеп килеп чыкты. Беләгенә көмеш ридикюль аскан, үзе кулындагы озын замш перчаткасын каптыра-каптыра азаплана бара. Каршысындагы төнге көтелмәгән кунакны башта танымады, куркып, кире чигенә язды, танығач, хахылдап кычкырып көлеп җибәрде:

– Бәрелешә яздык ич! Маңгайларны җимерербез бит! Сез миңамы, Гыйбаев иптәш? Ник бик соң? – дип, бер-бер артлы әллә ничаклы сүзләр тезә-тезә, төймәсе каптырылмаган перчатка аркылы нечкә озын бармаклы кулын сузды.

Җиһангир аңа мәсьәләне аңлатып бирде:

– Мин үзем дә ул йомышны әйткән булыр идем, ни мәгънә бардыр, Гәүһәр туташ миңа сезнең аркылы әйттерергә кушты, шуңа күрә төнлә килеп мәшәкатьләдем, гафу итегез! – диде.

Кыз, ишекне американ бик белән бикләп, ачкычын көмеш ридикюленә салды да егет белән бергә урам буйлап шәһәргә таба барган килеш, иске мирза гадәтенчә, бик күп русча тыгып сөйләп бирде:

– Беләм мин, зәһәр нәрсә ул Гәүһәрегез! Мине ничек чәнчергә белми йөри. Урмановка дигән йомышны юри минем аркылы йөрткән була. Үзенә күрә бер интрига инде бу!.. Аның интригасына исем китми. Әмма бик кызганыч, мин хәзер аңа бара алмыйм. Минем анакай чирләп китте. Миңа доктор чакырырга кирәк. Сездән үтенеч: иренмәгез, бу йомышны үзегез үтәгез. Мин сезгә бик рәхмәт әйтермен. Шулай бит, үзегез барасыз бит? Менә рәхмәт сезгә!

Туташ кат-кат Җиһангирнең кулын кысты да үз юлы белән очты. Егет шәһәр читенә, Урмановның җәһәннәм базына таба кызулап атлады.

Бу ни хәл? Җимерек капка төбендә яхшы күк аргамак башын чайкап, аякларын сугып тора. Егет барып җитүгә, казлар уянып гайгылдаша башлыйлар, кучер боларның тавышына уяна да Җиһангирне күрә:

– Син, абзый кеше, шунда керәсең булыр? Төсең шундыйларга ошый... Минем байга әйтсәңче, карт бай тагы орыша башлар, кайтасы иде ләбаса, тагы минем башка төшәр... – дип сукранып үтенде.

Җиһангир кем, нәрсә барын аңламыйчарак, авыру карчыкны

сукрандыра-сукрандыра, җәһәннәм базына барып керсә, шул ярлы, җимерек бүлмәнең ватык караватында, зәгыйфь лампа яктысында Давыт утыра, аның янында аягүрә баскан килеш бер кунак нидер сөйләп тора...

Кунакның башында кыйммәтле каракүл бүрек. Өстендә бик килешле тегелгән демисезон драп пальто, аягында американ читек-кәвеш, кулында көмеш башлы яхшы таяк. Үзе нечкәрәк урта буйлы, кара-туткыл чандыр йөзле. Уң кулы белән күкрәк кесәсеннән салынган алтын сәгать чылбырларын туктаусыз шаярта. Бөтен торышы алай дөньяның каты михнәте, җәфасы белән ватылмый үскән, төз, кадерле яшьлекне сөйли. Җиһангир керүгә, үзенең акыллы кара күзләре белән бераз елмаеп, аңа карады, сүзен туктатып:

– Кара таракан булды ич бу бәндә! – дигән сыман итеп хуҗага – Урмановка борылды. Ул боларны таныштырды.

Чибәр киемле егет – Кадыйр бай баласы Йосыфҗан икән. Җиһангир аны ишетеп белә иде, ләкин таныш түгел иде, кул биреп күреште дә шунда, артсыз ватык урындыкка урынлашты. Урманов элекке кунагына:

– Жиһангир ышанычлы кеше... Аңардан яшерен әйбер юк. Әйдә, сөйлә! – диде.

Йосыфҗан сүзен кыскача очлады:

– Менә шуннан, – диде, – безнең талаш китте. Ул куам, ди. Атаң тапкан малны кызыл авызларга ашатасың, минем башымны Себердә черетергә әйтәсең, ди; мин әйтәм, минем өлешемне бир... кумасаң да чыгам, бу коллыкта түзеп тора алмыйм, мин әйтәм. Аяк тибеп, минем өстемә акыра... Кайчан үләрмен, тияреңне шунда алырсың, әмма мин үзем исән чакта сиңа бер тиен бирдермәм, ди. Шулай талаштык-талаштык та, мин ишекне шалтыратып ябып чыгып киттем. Шуннан бирле сөйләшкәнем юк. Сөйләшмим дә инде, – дип, Йосыфҗан үзенең планын ачты, атасының йортын ташламакчы да Истанбулга укырга китмәкче. – Бераз җыйган-урлаган нәрсәм бар. Шулар белән берничә ел укый алырмын, ди.

Урманов моңа гаҗәпсенде:

– Китүең бик яхшы. Ләкин нигә Истанбулга китәсең? Төрекләрнең үзләренә юк гыйлемне... син нәрсә алырсың... Әнә шул Кәрим Гайфи булып кайтырсың ич!

Йосыфҗан планыннан кайтырга теләми:

– Башка юл юк миңа! Урыс мәктәбенә керергә теләсәм, минем телем җитми. Европага китсәм дә шулай. Инде боларның урта мәктәп програмы буенча хәзерләнергә тотынсаң, күпме заман кирәк. Әмма Төркиядә мин туры университетка керә алам. Аны бетергәч, Европа мәктәпләренә китә алам. Менә план шушы... Тик син миңа ике төрле яшерен паспорт бирү чарасын

кара. Бер тәүлектә булдырырга тырыш! Калган эшкә кар ява башлар, тимерне кызуында сугарга кирәк, – диде.

Паспорт эше Урманов өчен әйтерлек мөшкил түгел иде. Ул иртәгә көндез сөйләшмәкче, кичке сәгать сигезләргә Русиядән читкә качар өчен Йосыфҗан исеменә паспорт табып бирмәкче булды.

Җиһангир эченнән бу байбәтчәгә бераз якынлык тойды: «Кара син аны! Моңа да җан кергән, революция ни эшләтә бит егетләрне!» дип уйланды. Телдән бу турыда бер сүз дә әйтмичә, сүзне туры Гәүһәр тапшырган мәсьәләгә борды.

Йосыфҗанның җавабы әзер булып чыкты, ул һаман шуны өзә алмавы өчен үзен шелтәләп гафу үтенде:

– Менә иртәгә үзем, Давыт, сиңа сәгать сигездә теге эш өчен керәм бит. Шунда аны да кертермен! – диде, чыгарга исәнләшә башлады.

Җиһангир аңа кул биргәндә генә әйтә калды:

– Анда сезнең кучер бая ук сукрана иде...

Йосыфҗан:

– Ул шундый карт инде, сукранырга ярата, үзе бик әйбәт ул, – дип, нечкә ирене белән елмайды, ашыгып чыгып сызды.

## XLIV
## ДУҢГЫЗДАН БЕР КЫЛ

Ул ишектән югалуга, Җиһангир ышанычсыз аптырау белән Урмановка карады.

– Дуңгыздан бер кыл гынамы бу? Әллә чыннан да кеше булырга уйлыймы бу байбәтчә?

Урманов ашамаган иде. Карчык мич алдыннан кайнар чәйнек, ике стакан, тәрилкә, пычак, май, шикәр китереп куйды. Давыт Урманов шунда китаплар арасында яткан савыттан чәй салып кайнатты, икесенә ике стаканга чәй ясады, икмәккә май якты да, ашый-ашый җавап бирде:

– Монда син әйткәннең икесе дә бардыр. Катлаулы мәсьәлә ул! – диде. Зур чәйнектән бер-бер артлы стаканнарны ясый торды, икмәкне майлап ашый торды, шул катлаулы мәсьәләнең тарихын Җиһангир алдында акрынлап ачып җәя барды: – Ул акыллы, суык канлы, нечкә аңлы, зирәк, тырыш, ләкин гаҗәп эгоист табигатьле бер егет. Ул байлык та ярата. Хатыннар өчен, матур кыз өчен җанын бирергә риза. Әмма боларның һәммәсеннән аңарда өстенлек сөю тойгысы көчле, ул мал түгәр, дошманны кочагына алыр, сөйгән кызын, дусын корбан итәр, тик бер нәрсә булсын: аның исеме югары асылсын! Аны һәммә кеше яратып, мактап телгә алсыннар. Кайда барса да, аны якты йөз белән күтәреп каршыласыннар! Ул

һәркайда яхшы күренергә, яхшылык итәргә тели, ләкин яхшылык-изгелекнең үзен яратып, әхлакый сәбәп буенча түгел, тик менә шул өстенлек дәрте өчен, кеше алдында яхшы күренер өчен... Күпме заманнар кан-җан дошманы булып йөргәннән соң, тагы безгә, миңа кушылуы да, Баязидны коткарыр өчеп акчалар бирүе дә – һәммәсе әнә шул бер чишмәдән агалар. Ул җылан дус, әмма кирәкле, файдалы дошман була беләǃ..

Сүз озынга китте. Җиһангир бик арыган, кичәдән бирле җүнләп тамак итмәгән иде: чәйнектә су, өстәлдә май, икмәк беткәнче тукталмады; шул ашау эчендә Урмановның Йосыфҗан турындагы хикәясен тыңлады.

Иске, кадим, сасы мәдрәсә. Дин дә укылмый. Көн-төн каты моназарә эчендә схоластика чәйниләр. Европада урта йөзләрдә башларны тутырган схоластиканың ислам калыбына салынган, Кышкар, Бохара мәдрәсәләрендә кайнап куерган мөселман схоластикасы. Менә шул схоластик моназарә казанына, башка күпләр арасына, аталары тарафыннан Йосыфҗан белән Давыт та китереп ябылалар, – ике бала шәрик[1] булып укый. Алар икесе дә зирәкләр, тырышлар. Гаҗәп тиз дусланып китәләр. Дөрес, ашаулары, йоклаулары бергә түгел: Йосыфҗан – бай баласы. Аның урыны хәлфә янында, дәресханәдә, ашавы да шунда. Әмма Давыт авылыннан килгән каты-коты арыш икмәге белән, садака белән киченә. Ләкин бу аерма аларның күңелләрен аермый... Алар гомерлек дус кебек булып баралар. Сабый чакның бу саф дуслыгын үсә төшкәч мантыйк, схоластиканың каты талашлы моназарәләре, туктаусыз ызгышлары кимереп, җимереп төшерәләр.

Бервакыт шулай дамелла дәресендә утыралар: дәреснең темасы схоластика фәлсәфәсенең иң югары моментлары. Көтелмәгәндә моназарә кызып, кискенләшеп китә. Бик күп мәсьәләләрнең берсеннән икенчесенә күчә торгач, важыб[2], мөмкин, мөмтәнигъ[3] тәкъсиматына[4] ташланалар, аннан Алланың барлыгы, дөньяның яратылуы турында мөтәкәллимин[5] белән хөкяманың[6] фәлсәфәләре тирәсендә сүз бураны котыра башлый. Давыт кычкырып әйтә сала:

– Юк, юк! Мин мөтәкәллимин фәлсәфәсенең «җәүһәре фәрд» (атом) теориясенә ышана алмыйм, минем күңелем хөкяма фәлсәфәсе ягында. Мин хөкяманың бу галәм «һәйүлә»[7] белән «сурәт»тән мөрәккәб[8] дигән

[1] *Шәрик* – иптәш, дус.
[2] *Важыб* – тиешле; ислам динендәге кеше эшләргә тиешле эшләр.
[3] *Мөмтәнигъ* – тыелган эшләр.
[4] *Тәкъсимат* – бүлек.
[5] *Мөтәкәллимин* – логика галимнәре.
[6] *Хөкяма* – философлар.
[7] *Һәйүлә* – материя, матдә (философик термин).
[8] *Мөрәккәб* – укмашкан.

фәлсәфәсенә игътикад итәм[1], – дип ычкындыра.

Бу сүз, уртага бомба ташлаган кебек, шау-шу кузгата. Талашның каһарманы булып, Йосыфҗан котырына, ул төкерекләрен чәчеп Давытка акыра:

– Бу галәм һәйүле-сурәттән мөрәккәб булса, үлгәч терелү дигән сүз юкка чыга, хәтерне, кыямәтне инкяр итүгә алып бара, син көфер сөйлисең, тәүбә ит, ахмак, – ди.

Давыт анардан катырак акыра:

– Тфү, байбәтчә, кая килеп тыгыласың, син аңлый торган мәсьәләмени бу! – дип мәсхәрәли. Талаш утка әйләнә.

Йосыфҗан хурлыгыннан, ачуыннан ярыла язып, чыдаша алмый сикереп тора да:

– Тфү, кяфер, бәдбәхет, гөнаһ шомлыгың кагылыр! – дип, төкереп чыгып китә.

Шул талаштан сон дүрт ай сөйләшмиләр, ике дус бер-беренә үлем дошманы булып киселәләр. Дөрес, азрак вакыт үткәч алар килештеләр, ләкин тагы моназарә, талаш, кычкырыш, хурлаш – тагы ара бозыла. Ахыр чик болар шуңа җитәләр: бер-беренә сүз дәшмиләр, болар ике явыз дошман, болар бер-беренә аяк чалырга, бер-берен изәргә ашкыналар.

Ахырдан, Давыт Урманов яңа фикергә ава. Дамелла белән талаша, шәкерт котырта, дип, аны кадим мәдрәсәдән кудалар.

Менә шул Мәдрәсәи исламиягә килеп укый башлагач, ул үзенең балалык дусты Йосыфҗанны сагына. Аңа озын хат яза: «Мин синең белән дошманлыкны теләмим. Ул бары схоластик моназарә бәласе генә иде. Яңадан килешик. Мин шуны көтәм», – ди.

Ләкин Йосыфҗан башкача карый. Ул, бик күп гарәпчә сүзләр белән тутырып, Давытка искечә хат яза. Анда әйтә:

«Безнең аңладыкымыза бинаән[2], бездән ризалашуны теләгәнсез икән, бу тарика[3] мөгамәләңез чын калебдән[4] булса, гүзәл мөгамәлә. Ләкин чын калебдән булмаганда минем шигем бар...» – ди.

Аннан ул гафу-рәнҗешнең психологик моментларын тикшерергә тотына. Аныңча мәсьәлә болай: «Күңел адәмнең һәммә эшендә юлбашчы, җитәкче, хаким бер нәрсә; әгәр рәнҗеш менә шул хаким күңелнең эченә кереп утырмаган булса, бәлки күңелнең өстендә генә калса, яки рәнҗеш тышкы бер сурәттә генә булса, шик юк, андый рәнҗеш үз-үзеннән бетәчәк,

---

[1] *Игътикад итәм* – чын күңелдән ышанам, инанам.
[2] *Аңладыкымыза бинаән* – аңлавыбызга нигезләнеп.
[3] *Тарика* – ысул, алым.
[4] *Калеб* – күңел.

сакларга теләсәң дә, тормаячак. Әмма рәнҗеш, гафу алай тышкы нәрсәләр түгел, болар – җан әйберләре. Болар турыдан-туры күңелнең эчендә, аның каравындалар. Без әхлаксызлыкның, кешелексезлекнең, аңсызлыкның иң кабахәт дәрәҗәсенә ирешкәнгә, ул рәнҗешләр күңелнең иң эченә, үзәгенә урнашканга, заманнар үтүе белән үз-үзеннән череп, шартлап төшмәсә, мин һичбер тышкы сәбәп белән, үз ирадәм[1] белән ул рәнҗешне бетерә алмам дип уйлыйм, ди... Шуңа күрә, бу хатны, бу килешергә теләү мөгамәләсен, бер хәлфәнең үзара сугышкан ике баланы ризалаштыруы кебек бер сабыйлык икәнен сиңа белдерәсем килә. Мондый ризалашу – һичбер вакыт ризалашу булмаган кебек, мондый рәнҗеш-күңел калышлар да чын рәнҗеш, чын күңел калыш түгелләр дип карыйм. Яки рәнҗүләр булса да, гафу-ризалык ихластан булмыйча, тик бер риялык, буйсынучанлык, балалык яки уйсыз җиңеллек дип саныйм... Безнең рәнҗешләр күңелнең иң үзәгенә кереп урнашканга, ризалашу дигән сүз, шул тапны, шул яраны аштан күбек, баштан кәләпүш, авыздан төкерек ташлаган кебек генә түгел, бәлки карбызның орлыгын, йомырканың сарысын, тышкы кабыкларын ватмыйча гына, алып ташларга мөмкин булмаганга, безнең яралар, рәнҗешләр, күңелдә кортлап, сасып, үз-үзенә бетмәсә, мин үз теләгем белән аны өзеп алып ташлый алмыйм, чөнки күңелем минем кул астымда түгел, мин үзем күңелнең кулы астындамын...»

Шул мәгънәдә яза-яза да әйтә:

«Калебтә булган җәрәхәт һичбер вакыт китәчәк дәгел. Фараз кылыйм ки, нисфы мәвет[2] булган сәкран[3] хәленә керсәм, зиһенемдә булачак... Әфәндем, арамызда шундый бер салкынлык булмыш ки, һич җылынмаячак, һич кызмаячак... Кятиб[4] шәрик җасусыңыз[5] Йосыфҗан ибне Кадыйр...»

Давытка каршы Йосыфҗан башта шулай җавап бирә. Ләкин ул заман вакыйгаларның яшен тизлеге белән аккан чаклары иде. Революция ялкыны шәкертләрне уята. Теге кадим мәдрәсәдә яңа дулкын баш күтәрә. Аннан шәкертләрнең күбесе кача, байтагы монда Мәдрәсәи исламиягә киләләр. Тегендә тик аңсыз, җүнсез карт-коры суфыйлар, аксак-туксаклар торып кала. Һәркайда өстенлек сөйгән Йосыфҗанның җанын хурлык каплый. Ул бу калдыклар арасында кала алмый. Дулкын белән бергә монда килеп чыга. Килгәч, Давыт белән исәнләшми, үзенә башка бер партия төзеп маташа. Ләкин бу барып чыкмый. Кызыл яшьләр эченә керергә юл эзли, ике тапкыр, юк йомышны бар итеп, Булатка барып кагыла. Ләкин анда Гәрәй Солтан

---

[1] *Ирадәм* – теләгем.
[2] *Нисфы мәвет* – ярым үлек.
[3] *Сәкран* – исерек.
[4] *Кятиб* – язучы; хатны язучы.
[5] *Шәрик җасусыңыз* – ээзрлекли торган иптәшегез.

белән очраша.

Кавказлы егет батырып карый да үз алдында ук Йосыфҗан турында:

– Бу нинди кош? Адашып йөриме әллә? – дип сорый.

Йосыфҗан бераз ялгызлыкка бата. Ләкин дөнья кайнаганда ялгыз бер якта калу аның һәркайда өстенлек сөйгән эгоист йөрәген канәгатьләндерми. Ул, Булаттан чыккач, ун көн уйлана да Давытның адресын таба. Баязид карыйның эләгүен ишетә. Аның зинданда кан косуын сөйлиләр. Хөкемгәчә коткарырга акча эзлиләр.

Менә шул моментта ул Давыт Урмановның җәһәннәм базын эзләп таба да бер кичне аңа килә:

– Иптәш, бары бетсен!.. Мин күп газапландым... Ул кадим схоластикадан калган дошманлыкны ташлыйк, мин килешергә килдем, бир кулыңны! – ди. Шунда ук Баязид мәсьәләсе. Шунда ук аңа уңайлы сылтау... Алты йөз ярдәм... Менә шулай кушыла да китә ул...

Давыт, чәй эчеп, май-икмәк ашап, шул вакыйгаларны төрле яклап сөйләде.

Җиһангир:

– Фу, башым томаланды бу Йосыфҗан белән!.. – дип, аякка торды, сәгатенә карады: – Их, унике була лабаса! Миңа иртәнге алтыда торырга кирәк. Ярый, мин китәм.

Ул Давытка кул биреп чыга барганда тагы өстәде:

– Син онытма. Иртәгә кич мәдрәсәдә зур җыелыш. Ул көнне дә Әхмәт Нурый килеп сине бик изде.

– Ничек мине изде?

– Сине түгел, социализмны изде. Бездә, ди, дин бар, милләт бар. Без Русия мөселманнары менә шул ике бөек нигездә үзебезгә сәяси партия төзибез, «Иттифак» төзибез... Шул ике бөек нигездә бөтен Русия мөселманнарын дини-милли байрак астында бер сәяси партия эчендә берләштерәбез, безнең мәдрәсә яшьләре бу олы тарихи көрәштә безнең белән кулга-кул тотышып барачакларына ышанабыз, ди...

Давыт кызып китә башлады, Җиһангиргә бәйләнеп китте:

– Ә син нәрсә авыз йомып тордың? Сызгырып, сүзен бүлдерәләр аның... Син әйтергә кирәк иде: сез менә «Иттифак» төзисез дә урыс кадетлар белән берләшәсез,[38*] бу да шул дин-милләт нигезендәме, дияргә кирәк иде! Авыз йомып калалармыни!

Җиһангир көлде:

– Кем йомсын?! Без җәнҗал куптардык. Аларның сүзен бүлеп, «Марсельеза» җырларга тотындык. Аның белән генә бетми шул: менә иртәгә тагы җыелыш. Тагы шул мәдрәсә яшьләре өчен көрәш!.. Тагы дин дип,

милләт дип сөрем очырырлар... Миһран белән Нәҗип Камал икәү шул иттифакчы Әхмәт Нурый әфәндегә барганнар: шәкерт сине көтә, дигәннәр. Килергә вәгъдә биргән. Кәрим Гайфи белән Гали хәзрәт тә килмәкчеләр, ди, бугай. Монда Нигъмәт казый әзерләнә. Син бармый калма, тегеләрне изеп ыргытмый ярамый. Анда дин мәсьәләсе бик яман кузгалырга тора... Тентү булып үткәннән бирле безнең үз карагруһларыбыз бик нык аякландылар... Бу турыда Нигъмәт казый да алар белән бара ич... Ни булса, сугыш зур булачак, тешләреңне кайрап бар!..

Шулай кат-кат Давытны иртәгә булачак талашлы җыелышка чакырып, Җиһангир өенә юнәлде.

## XLV
## ОРАТОРЛАР*

Баскычтан менеп барганда теге яшь шәкерт Камил очрады. Давыт абый, тукта, сиңа хат бар, үз кулыңа гына бирергә, диде дә атылып ятак бүлмәсенә кереп китте. Аннан йөгереп, күк конверт китереп тоттырды. Давыт менә-менә хатны укыды. Гаҗәпләнде, күзләренә ышанмый тагы укыды. Хат Җиһангирдән. Ул болай яза:

«Иптәш, дөньялар әйләнде. Бу мәҗлес – минем шәкерт – мәдрәсә эшендә актык сугышым булыр. Мин китәм. Беләмсең, китәм. Хаҗәрне алып китәм. Безнең серләр ачылган булса кирәк, Хаҗәргә көн бетте. Аның ире палачка, зобанига әйләнгән. Хаҗәр кичә хәбәр итте: минем көнем җәһәннәм. Мин тора алмыйм. Мине коткар. Дөньяда синнән башка кешем калмады, ди. Шулай без иртәнге таңда китәбез… Яңа тормышка, яңа көрәшкә!»

Урманов, бу тагын нинди балалык инде дип әрнеп, хатны кесәсенә тыкты да югарыга җыелыш залына ашыкты. Анда мәдрәсә яшьләре кайныйлар. Зал шыгырым тулы. Түрдә өстәл. Аның янында ике урындык. Рәис булып Нәҗип Камал утыра. Аның янында җитү чәчләрен кара кәләпүше астына тыга биргән гайрәтле егет – кара туткыл Җиһангир секретарьлык итә. Уң як стена буенда ниндидер бер урындыккамы, нәрсәгәдер оратор шәкерт Хәким Кадри баскан. Ул бераз алга бөкерәйгән озынча буйлы, иске сары казакилы, такыр башына иске саргылт кәләпүш кигән. Саргылт, ябык, кипкән йөзе хәсез, ярым үлек күк карашы аның татар мәдрәсәләрендә күп еллар гомер уздырганлыгын күрсәтеп тора. Ул ютәлли. Шулай да әче кычкырып сөйли, шәкерт, мәдрәсә эчендә кулланыла торган, бик күп шаблон гарәпчә сүзләр кыстыра:

* **XLV. Ораторлар** һәм **XLVI . Без ник беттек?** дип исемләнгән бүлекләр 1976 елда басылган 4 нче томга кермәгән, төшереп калдырылган. Бу бүлекләргә караган текстлар 1934 елда чыккан басмадан алып урнаштырылды.

– ...Һәрбер милләтнең, әфәнделәр, тәрәккый вә тәгалли кылып[1] рәффәһ вә сәгадәт үзәренә хәят сөрмәге[2] фәкать иттифак вә иттихад[3] аркасында гына була аладыр. Әфәнделәр, иттифак вә иттихад аркасында гадәтләре, аз булган кадәр милләти нәҗибәсе[4] көррәи арзның[5] там нисфына[6] хаким уларак, заманнарында дөньяга дәһшәт биргән Рум вә Фарис[7] дәүләтләрен зир-зәбәр кылып галәмнең яратылышына хуҗалык иткәннәр. Галәмнең нисфына хакаикы исламия нуры идәрәк[8], тәрәккый вә мәдәниятнең, гыйлемнең, сәнгати әдәбиятнең үз заманнары өчен иң гали[9] дәрәҗәләренә менмешләр... Шул иттифак вә иттихад аркасында дөньяда һич кемгә нам вә нишаны[10] мәгълүм булмаган кечкенә Япон милләте бөек Русия дәүләтен егып салды... Иттифак... Иттихад, әфәнделәр...

Хәким Кадри шулай озак сөйләде.

– Яшәсен иттифак! Яшәсен иттихад! – дип сүзен бетерде. Ул кызу, ялкынлы сөйләде. Аңа бик каты кул чаптылар. Аңардан соң Вәли Әхмәровка сүз бирелде. Бу да саргылт кәләпүшле, кипкән, ач йөзле, кабергә карап торган үлек күзле иде Ләкин ютәлләмәде. Бу да мәгълүм шаблон гарәпчә сүзләрне күп кушты:

– Әфәнделәр, – диде. – Һәрбер милләтнең тәрәккый вә тәгаллисе – хатыннарның тәрбия вә тәрәккыйләренә баглыдыр. Хатыннар – милләтнең нисфы, хатыннар – милләтнең аналары... Ана ничек тәрбия кылса, бала шулай була. Безнең милләтнең артта калуы – фәкать, фәкать хатыннарыбызны дүрт дивар эченә бикләп, хиҗап[11] астында йөртүебездәндер... Бетсен хиҗап! Яшәсен тәрбияле хатын, тәрбияле ана! – дип кычкырды. Мисырлы Касыйм Әмин бәкнең «Тәхрир әл-мәрьәт» [3?*] атлы китабын телгә алды да баскан җиреннән сикереп, юк булды.

Аның артыннан ябык саргылт йөзле. ютәлле Габдулла Хәлими калыкты. Ул кыска бетерде:

– Әфәнделәр! Һәрбер милләтнең тәрәккый вә тәгалли итмәге – балаларның гүзәл тәрбияләренә баглы. Чөнки бу көнге балалар – киләчәк

---

[1] *Тәрәккый вә тәгалли кылып* – алга китеп, үсеп һәм күтәрелеп.
[2] *Рәффәһ вә сәгадәт үзәренә хәят сөрмәге* – рәхәт һәм бәхетле тормыш итүе.
[3] *Иттифак вә иттихад* – килешү һәм бердәмлек, бер фикердә булу.
[4] *Милләти нәҗибәсе* – милләтенә хас булган таланты, акылы.
[5] *Көррәи арзның* – җир шарының
[6] *Там нисфына* – төгәл яртысына.
[7] *Рум вә Фарис* – Византия һәм Фарсы.
[8] *Хакаикы исламия нуры идәрәк* – чын, гадел ислам нуры иңдереп.
[9] *Гали* – бөек.
[10] *Нам вә нишаны* – даны һәм шөһрәте.
[11] *Хиҗап* – пәрдә, йөз өрткеч.

көндә милләтнең аталары, юлбашчылары, көтүчеләре булачак. Көтүче кая кауласа, көтү шунда бара. Бәс, әфәнделәр, һәрбер милләтнең тәрәккъый табуы – фәкать, фәкать балаларның гүзәл тәрбиясе аркасында гына мөмкин. Нитәкки, мәшһүр төрек мөхәрире Әхмәд Мидхәт әфәнде үзенең әсәрләрендә бу хакта… дип берничә әсәрдән берничә сүз китерде дә тукталды.

Аның артыннан зур, калын гәүдәле, кызыл йөзле Кәримов кузгала. Зур мыегын бөтереп, мәҗлескә карый да сүз башлый:

– Юк, әфәнделәр, сез күзгә күренгән вак тармаклар белән маташасыз… Алай ярамый… Эшнең төбенә карарга кирәк. Төбе, тамыры кайда?.. Хөрриятта. Менә, иптәшләр, эш шунда. Хөррият булмады, шуңа күрә без беттек. Хөррият булыр – без яшәрбез. Шуңа күрә мин әйтәм: – Яшәсен хөррият! дим. Яшәсен татар шәкертләренең хөррият юлында көрәшләре, дим!..

Кәримовка озак кул чапкач, тагын ябык, кипкән, хәлсез карашлы өч шәкерт бер-бер артлы сүз алалар. бик күп гарәпчә катнаштырып сөйләргә тотыналар.

Берсе:

– Һәр милләтнең тәрәккъыйсе фәкать хатыннар аркасында гына, – дип; икенчесе:

– Һәр милләтнең тәрәккъыйсе фәкать балаларның гүзәл тәрбиясе саясендә генә, – дип; өченчесе:

– Милләтләрнең тәрәккъыйсе фәкать иттифак, иттихад аркасында гына, – дип исбат итәләр.

Болар артыннан үзенең ялкынлы сүзләре белән танылган Сөләйман Сәйфуллин урталыкка чыга. Аның өстендә иске тужурка, аягында ертык ботинка, үзе ябык, чандыр, йөзе саргаеп кипкән. Ләкин күзләре гайрәт белән карыйлар. Сүзләре ут булып чәчеләләр:

– Иптәшләр, сез беләсез, безнең милләтнең тезгене руханилар кулында. Һәрбер татар, мулланың авызыннан ни чыгар, дип, көтеп тора. Ни чыкса шуны чын дип, дөрес дип кабул итә. Без артта калдыкмы? Без беттекме? Безне кем бетерде? – дип тикшерәбезме? Мин әйтәм: без беттек. Безне муллалар бетерде. Без гасырлар буенча йокладыкмы? – Безне муллалар, ишаннар йоклатты. Чөнки йоклаган кара халыкның гошерен[1], фитырын[2], зәкятен[3], сәдакасын, фидиясен[4] талау җиңел була. Безнең муллалар – милләт

---

[1] *Гошер* – уңышның уннан бер күләмендәге дини налог.
[2] *Фитыр* – авыз ачу сәдакасы.
[3] *Зәкят* – еллык керемнең кырыктан бере күләмендә салынган налог.
[4] *Фидия* – үлгән кешенең гөнаһын йолып алу өчен бирелгән мал, йолым

микроблары. Алар безне йөз еллар буенча ашап, әүвәлге шәүкәтебезне[1] бетерделәр. Безне аяктан ектылар. Алар зарарлы кортлар. Без милләт өчен көрәшергә теләсәк – мәдәният юлына аркылы кискә булып яткан ишаннарны, мөтәгассыйб[2] муллаларны, милләтнең бара торган юлыннан алып ташларга, боларга каршы көрәшергә тиешлебез… Шунсыз милләт тәрәкъкый тапмас… Бетсен милләт микробы булган ишаннар! Бары да кадалсын, чәнчелсеннәр!

Сүлпәнрәк бара торган мәҗлес бу оратор сүзе белән җанланып китте. Төрле яктан кул чабып, аяк дөбердәтеп җыелышны дулаттылар. Рәис Нәҗип Камал бик көч белән яңадан тәртипне торгыза.

Берничә кыюсыз, оялган шәкерт бер-бер артлы төрле җирдән аякка калкалар. Ләкин Сөләйман Сәйфуллиннан соң сөйләргә батырлыклары җитми. Акрын. оялчан каушаулы тавыш белән:

– Әфәнделәр, мин үз фикеремне әйтермен дигән идем… Алдагы сөйләгән әфәнделәр минем фикерне әйттеләр. Минем сөйләргә сүзем калмады. Зинһар гафу кылыгыз, дип, кире утыралар.

Авыр сүзләр белән күмелеп барган халык бу өч шәкерт артыннан картлар кебек акрын гына кузгалып, ярым елмаеп, уртага таба атлаган Хәйрине күргәч, ирексез көлеп җибәрде. Бу – шәкерт арасында «икмәк беткән көй»не чыгару белән танылган бер шаян нәрсә. Ул вакыт теге унике шәкерт кууга каршы кузгалган дулкын жандарларның кереп тентүе белән ташка бәрелгәндәй чарпаланып юкка чыкты бит. Шәкерт тә, идарә дә бераз чигенделәр. Идарә ягы аптырап, баскан җиреннән көтеп туктады. «Кумыйм» дип тә әйтмәде.куып та чыгармады. Нидер көтеп тора әле дә. Әмма шәкерт рамкалы пыяла белән иске устав-программаны ватып, тентүләр кичергәч, үз каршындагы дошманның бер якка таба посканын сизенде. Җүнләп дәрес укымыйлар, назыйрга[3] буйсынмыйлар. Әдәби кичәләр куялар. Җыелып «Сада», «Марсельеза» җырлыйлар. Ничектер әле бер сугыштан чыккан, икенчесенә әзерләнеп җитмәгән, ял иткән гаскәр кебек арлы-бирле кайнашалар. Менә шул җырлы, «Марсельеза»лы кайнаш эчендә бик күп шәкерт ач калды. Алар электә дә ач иде, ләкин хәзерге азатлык эчендә дә ачлыкны артык үткен сизделәр. Менә шул азат ачлык кайнашында Сәлим Хәйри дигән шаян шәкерт «Икмәк беткән көй»не чыгара. Ләкин бу көйдә көлке дә, шаянлык та юк. Монда озын авыр көйгә салып кайгылы сүзне:

– Ярлы хәле авыр икән – каткан икмәк кимертә… дип җырлана. Ләкин революция дулкынында кайнаган дөнья һәм ялкынлы. гайрәтле яшьлек бу

---

[1] *Шәүкәтебезне* – куәтебезне, бөеклегебезне.
[2] *Мөтәгассыйб* – фанатик.
[3] *Назыйр* – мөдир.

көйнең күңелсезлеген ничектер йота да, аны шаян якка тарта, көлке белән күмә, кайгыны көлке белән каплый.

Оялчан өч оратор шәкерт соңында сүзгә чыгучы кеше менә шул, кайгыны көлке эченә күмеп көй чыгарган Сәлим Хәйри иде. Ни әйтә дип аңа кызыкланып карадылар. Аның озын, тузган бишмәте, өскә чыгып торган керле якасы, карасу шадра йөзе, ябык битендә әллә кая күтәрелеп торган зур барыны белән колакка таба җәелгән калын иренле зур авызы, ничектер үзләре үк көлке чакыралар. Ул акрын башлый:

– Балалар, ди, мин карт кеше инде… Мине борчымаганда да ярар иде… Бер кирәк әйбер бар, шул әйберне калмасын дип курыкканга гына чыктым… Минем сүзем урысча турында, иптәшләр. Менә безнең Төркиядә профессор булырга ярарлык Кәрим Гайфи бар. Әмма урысча бәлмәү аркасында, ул көн тентү чагында:

– Мы учим… һәндәсә…

дип сөйләп жандарның котын очырган… Дөрес, бер урысның коты очканнан дөнья җимерелмәс, әмма мин үзем аның самовар куй диясе урында марҗа алдында авызына бармак тыгып торганын үз күзем белән күрдем… Бу хурлык түгелме?..

Оратор шаян, көлке йөз ясап, авызына бармак тыгып катты. Бу бик көленеч чыкты. Мәҗлес шаркылдап көлеп җибәрде. Рәис Нәҗип Камалның ачуы кабарды. Ул шунда ук Хәйринең сүзен бүлмәкче: «Фикерең тугры. урысча кирәк. Әмма Кәрим Гайфине мыскыл итүең урынсыз… Син мең ел урысча укысаң да аның дәрәҗәсенә менә алмассың. Ул алай көлкегә мисал булырлык кеше түгел» – дип әйтмәкче булды. Ләкин үзен көчләп тыйды, чөнки башка урыннардагы кебек әле дә сүзен үткәрә алмавы ачык иде.

Хәйри көлкегә салып сүзен сузды:

– Шуңа күрә. мин әйтәм: борынгы «Иман шарты» китабында кырык фарыз дип язганнар. Мин әйтәм, моны төзәтергә кирәк. Хәзер фарызлар кырык бер булды. Кырык беренче фараз – урыс теле. урыс теле. урыс теле! Менә минем әйтми калдырырсыз дип курыкккан сүзем шул иде. Бу калса – Кәрим Гайфи куркынычы килә, - дип бетерде.

Тагын шулай милләтнең тәрәкъкый сәбәпләрен озак эзләделәр. Без ник беттек дип күп тикшерделәр, берсе – хиҗап дип, икенчесе – иттифак дип, өченчесе – мулла, ишан дип, дүртенчесе – муллалар өстеннән террорга чакырып, бишенчесе – урысча дип, алтынчысы – балалар тәрбиясе дип, җиденчесе – матбугат, әдәбият дип, … унынчысы – мәдрәсәләр ислахы дип кабат-кабат сөйләп, изеп, туйдырып, ялыктырып бетергәч ун минутка мәҗлесне яптылар. Гаҗәбе шул булды: Назыйрның әйтүенә карамастан Сөләйман Сәйфуллин белән Хәйри тирәсенә оешкан ун кешелек бер төркем

беренче тапкыр коридор буенча ачыктан-ачык тәмәке тартып йөрделәр.

Шәкерт арасында тартучылар күп иде, башкаларның кыюлыгы җитмәде, боларга да Миһран килеп бәйләнә башлаган иде. Талашның сугышка әйләнүе мөмкин иде. Ләкин Нәҗим Камал туктаусыз кыңгырау шалтыратып, җыелыш бүлмәсенә чакырырга тотынды. Халык шунда агылды.

## XLVI
## БЕЗ НИК БЕТТЕК

Без ник беттек?

Мәҗлес яңадан ачылгач, беренче сүз бирелгән Нигъмәт казый мәсьәләне менә шул рәвешкә салып җибәрде.

Зур калын гәүдәсе белән рәиснең янына ук баскан килеш куәтле тавыш белән җыелышның фикерен менә шул үткен моментка китереп бәйләде.

– Безнең милләт ни өчен артта калган?! Зур, авыр, тирән мәсьәлә.

– Без ник беттек? – авыр, куркыныч, шуның белән бергә еллар буенча газапланып күп төннәрне йокысыз кичертә торган куркыныч мәсьәлә. Иптәшләр, әфәнделәр! Без беттекме? Әйе, беттек. Безне кем бетерде? Без, үзебезне үзебез бетердек! Бер сүз белән әйткәндә гайнән[1] мәдәният, гайнән тәрәкъкый булган гали ислам динен ялгыш аңлау аркасында беттек. Безнең бабаларыбыз тарихта бөек, шәүкәтле[2], якты сәхифәләр…

Шул җирдә арттан, кайдандыр, кемдер яман сызгырып җибәрде. Халык аптыранып як-ягына карады. Ләкин Нигъмәт сүзен туктатмады:

– Минем сүземә сызгыралар. Ләкин бөтен дөнья каршы чыкса да мин үз фикеремдә калам. Мин әйтәм, Ислам, Коръән үзенең якты юлы белән бөтен дөнья мөселманнарын бер заманнар сәясәттә, сугышта, мәдәнияттә, гыйлемдә дөньяның иң алдынгы милләтләреннән ясады. Иң югары мәдәни, гыйльми дәрәҗәгә күтәрде… Ләкин безнең сукыр голәмаларыбыз шул гали исламны ялган әкият белән, хорафат белән тутырдылар. Исламны боздылар. Аңа фанатизм, схоластика, хорафат керттеләр. Менә бу бозылган ислам безне бетерде. Шуңа күрә әйтәм, без үзебезне бетердек дим. Чөнки саф дин урынына без хорафатка, схоластикага чумдык… Шул сәбәпле гыйлемгә, мәдәнияткә каршы киттек… Әмма чын, саф ислам дине бервакытта да гыйлемгә, мәдәнияткә каршы түгел, киресенчә, үзе тәрәккъыйга, мәдәнияткә хадим… сез беләсез, әфәнделәр…

Оратор үз фикерен куәтләр өчен Коръәнгә кереп китә, аннан аятьләр укый, хәдисләрне актарып чыгара, борынгы гарәп мәдәнияте тарихына кереп

---

[1] *Гайнән* – үзенчә (шул көнчә).
[2] *Шәүкәтле* – куәтле, көчле.

бата. Аннан мөселман дөньясында җитешкән зур галимнәрне: Фараби,[40*] Ибне Сина,[41*] Ибне Рөшд[42*] кебек философларны саный. Гарәпләрнең фәнгә, гыйлемгә күрсәткән хезмәтләрен кат-кат тезә, тасвирлый да сөземтәгә килә.

– Менә болар, ди, чын исламның җимешләре иде… Әмма соңгы бер ничә йөз ел эчендә исламны бозып схоластика белән, хорафат белән тутырдылар. Акыл сүнде, иҗтиһад капусы бикләнде. Дәрвишлек, ишанлык каплады. Ислам дине намаз белән уразадан, зәкят белән гошердән. хәез-нифаздан[1], фидиядән гыйбарәт булып калды. Моны безнең надан мөтәгассыйб голәмаларыбыз шул хәлгә куйды… Менә шулар чын динне дә бетерде, мөселман халкын христиан Европада кол итеп калдырды. Әгәр без яңадан котылырга теләсәк, безгә бер генә чара: без исламны үзенең әүвәлге чын хәленә, сафлыгына кайтарырга кирәк. Шуның буенча барырга кирәк… Ислам белән Европа мәдәнияте безгә ике канат булыр… Шул чакта без тәрәккъый табарбыз, яңадан күтәрелербез… Инде хәзер киләбез…

Нигъмәтне тагы кистеләр. Каяндыр бер почмактан көлке Сәлим Хәйри баш күтәрде шаяртып сүз башлады:

– Тукта бик кызма, бер генә соравым бар, чын ислам буенча барганда байның әйберен урлаган өчен ике кулны да кисәргә кирәкме, әллә берсен генәме? Үзе теләгән егет белән йоклаган өчен хатыннарны биленнән чокырга күмеп таш белән атып үтерү кирәкме, әллә башкачамы? – диде.

Мәҗлес шаркылдап көлде. Оратор яңадан кызды, тирләп-пешеп тагын тарихка, Коръәнгә чумды. Тагы, безнең терелүебез өчен ике канат кирәк, берсе – чын ислам,  икенчесе – Европа мәдәнияте. Менә шуңа күрә без кара фикерле ишаннар-муллаларга, иске мәдрәсәләргә каршы сугышабыз…, – дип китереп очлады. Миһраннар, Нәҗип Камаллар ораторга озак каты кул чаптылар. Җыелышның бер катлавы – боларга кушылды. Инде нәрсә, мәсьәлә өзелде ич, тагы нигә сөйләп азапланырга диган сыман төс бирергә теләделәр.

Шундый караш оешып барганда секретарь Җиһангирнең:

– Давыт Урманов! – дип кычкырганы  бер гаҗәбрәк эш була язып калды. Рәис Нәҗип Камал җыелышка күз тегеп, нәрсәдер, кемнедер эзләгәндәй булды. Ишек буеннан озын җиләнле, кыскартып кырган мыеклы, усал карашлы, таза, нык шәкерт Миһран Гайфуллин баш калкыта да акырып җибәрә:

– Нәрсәгә сүз тагы? Һаман бер балык башы! Нигъмәт казый мәсьәләне чишеп бирде. Артык кирәге юк! Без Давыт Урмановны кырык тапкыр

[1] *Хәез-нифаз* – күрем, бала тудырганнан соң аналыктан килә торган кан.

ишеткән инде. Сөйләмәсен, бетмәс монда чабаталы дәһриләр[1]! – ди.

Давыт үзе нидер әйтмәкче булган иде, аны кисеп, Сөләйман Сәйфуллин атылды:

– Ничек сөйләмәсен! Нигә кешенең телен кисәргә? Хөррият шулай буламы? Син Нәҗип Камал белән бергәләп теге иттифакчы Әхмәт Нурый әфәндене барып чакырганда без бер сүз дә әйтмәдек ие! Әйдә сөйләсен, дәһриме, социалистмы, бары да сөйләсен. Безнең заман – хөррият заманы! Берәүнең дә телен кисә алмыйсың?! Шулай бит, иптәшләр!

Җыелышта «шулай», дип «түгел» дип шау-шу кузгалды. Давыт Уманов ишек төбеннән алгарак тартылды да, шул шау-шудан яманрак кычкырырга тотынды. Гауга акрынлап басылды, ораторны тыңлый башладылар:

– Мисырдан, Истанбулдан, таралган бер әкият бар. Моны башлап Җамалетдин Әфганиләр,[43*] Мөхәммәт Габдеһләр[44*] чыгарды. Әхмәд Мидхәтләр бу турыда исәпсез кәгазь әрәм иттеләр. Менә шул әкият Кара диңгез аркылы Русиягә дә кайтты… Казан, Уфа, Буби, Кырым, Кавказларга таралды. Әле менә хәзер генә Нигъмәт казыйның бик зурлап, минем, фикерем, дип сөйләгәне менә шул әкияттән башка нәрсә түгел… Диннәр бөтен көчләре белән фәлсәфәгә, гыйлемгә, мәдәнияткә каршы сугышып баралар-баралар да, җиңелгәч, килешү ягын эзлиләр. Бу борынгы Юнанстанда Аристотелистлар дәверендә булып кичте. Европада христианлык XV нче йөздән бирле шулай азаплана… Менә XIX нчы йөзнең урталарыннан алып мөселман дөньясында да динче голәманың бер катлавы хәзер шул килештерүчелек юлына керделәр. Болар хәзер исламны Европа мәдәниятенә татбикъ кылып[2] маташалар. Гүя ислам, чын, саф ислам Европаның фәлсәфәсенә, техникасына, гыйлем, мәдәниятенә үзе алып барачак имеш. Үзенең билгеле шартлары, дәвере эчендә борынгы Юнанстанның дини һәм европа христианлыгы кичергән әнә шул тарихи мәҗбүри хәрәкәтен хәзер исламчылар үз башларыннан үткәрәләр. Димәк, Нигъмәт казый сөйләгән әкият Мисыр, Истанбулның XIX нчы йөз ахырында чыгарган әкияте генә түгел икән, бәлки тарихта башка диннәрнең, иске Греция диненең, христианлыкның билгеле бер дәверендә үз башыннан кичергән бер уртак чир икән. Шуңа күрә, монда мин мәсьәләнең бу ягына…

Ораторның «чир», «әкият» дигән сүзләренә Нигъмәтнең ачуы кабарып утыра иде. Күп кабатлангач, түзмәде, калын ерткыч тавыш белән акырды:

– «Чир» түгел, «әкият»тә түгел. Ул зур хакыйкать! Ул – бөек гыйльми, тарихи хакыйкать! Моны аңламау җә наданлык, җә ахмаклык! Җә сукыр

---

[1] *Дәһри* – атеист, динсез.
[2] *Татбикъ кылып* – яраклаштырып.

дәһрилектән башка нәрсә түгел. Мондый сүзне тик кызыл авыз, чабаталы дәһриләрдән генә ишетергә мөмкин. Безнең Давыт та шуларга бозау булган, – дип утырган җиреннән ташлады. Аңа берничә урыннан бик яңгыратып кул чаптылар. Тагы:

– «Сөйләсен!», «Кирәкми!», «Дини мәдрәсә шәкертләре эченә килеп динсезлек сату урынлы эш түгел!» – дип шау-шу күтәрделәр. Боларга каршы Сәйфуллиннар, Хәйриләр, Сахип, Җиһангирләр: «Тагы нигә жандар буласыз?», «Нигә кешенең телен кисәсез?» – дип тавыш кузгаттылар. Рәис зур көчлек белән мәҗлесне тынычландырды. Тәртипне урынлаштыра алды. Урманов сүзен алып китте.

– Монда, диде, Нигъмәт казый диндә, исламда адвокатлык итәргә азаплана. Иске әкиятне, тарихи зарарлы җирләрне «хакыйкать»ләр дип йоттырырга азаплана. Ләкин, ләкин без андый «хакыйкатьләрнең чын тарих, чын гыйлем алдында ничә тиен тотканын бик яхшы беләбез. Шуңа күрә, ислам дине белән мәдәниятне, техниканы, фәлсәфәне берләштереп азаплану – дин белән мәдәниятне яраштыру кебек хәрәкәтләрне иске чир, иске әкият дип кыя әйтә[1] алабыз… әгәр кирәк булса, мин сезгә бөтен тарих буенча, диннәрнең гыйлемгә, техникага, прогресска каршы сугышып килүләре турында күп тарихи фактлар китерә алачакмын…

Урманов шулай дип мәсьәлә куйды да үз сүзенә куәт өчен тарихка керде: – Үзләре җиңгән дәверләрдә диннәр һәммәсе гыйлемне, техниканы, мәдәниятне җимерәләр, хәрәкәтне буалар. Әмма инде мәдәният җиңеп китсә, яңа мәдәни хәрәкәтне яклаган көчләр өстенлек алса, диннәр тактиканы алмаштыралар. Бөтенләй тапталып калмас өчен яңа көчләр. яңа мәдәни хәрәкәтләр белән килешү ягын эзлиләр. Юнанда Аристотелистлар заманы. Европада XIV-XV нче йөзләрнең бу ягыннан, ислам дөньясында XIX нчы йөздән башлап динчеләр менә шул тактиканы тоталар, – дип сөйләп, мисалларына тукталды. – Әфганиләр, Әхмәд Мидхәтләр, бездәге Бубыйлар[45*], Бигиләр[46*] менә Нигъмәт казыйлар – һәммәсе дә шул тактика астына яшеренеп, исламны бөтенләй җимерелеп тапталудан коткарырга азапланучылар гына. Болар диннең бик артык ачык ялган урыннарын ташлыйлар, анысы чын диндә юк, аны ахырдан фанатик голәма гына өстәгән, диләр. Бу тактика бер маневр, зарарлы, алдаткыч маневр. Безгә моны ачарга кирәк. Хәзер сезнең алда Нигъмәтнең әйткән – менә шул маневрның, яңа дини тактиканың шәкерт арасына килеп керүеннән башка нәрсә түгел. Ләкин бу иске, билгеле маневр. Аны юнан, христиан кичергән. Хәзер ислам азаплана. Шуңа күрә без аны иске әкият, иске чир дибез.

---

[1] *Кыя әйтү* – кыеп әйтү, кистереп әйтү.

Оратор, сүзен шул җирдә кичеп, Нигъмәтләр белән чәкәләшеп алды да тагы дәвам итте:

– Монда – диде, – миңа «дәһри», «бозау», «чабаталы социалист» диделәр. Мин «дәһри» дигәнен дә, «чабаталы» белән «социалистлык»ны да үземә алам. Ләкин «бозау» дигәнен кире ыргытам. Чөнки дингә каршы бу фикерләрем минем ияреп түгел, тормышның күп тәҗрибәләреннән соң миндә тудылар. Бер вакытлар мин дә, сезнең кебек җен-пәригә, убырга, албастыга ышанып йөрдем. Ул чакта мине кабер газабы белән куркыттылар. Күмеп киткәч, караңгы гүреңә Мөнкир-Нәнкир[47*] килер, җавап бирә белмәсәң утлы гөрзи белән орыр, дип котны очырдылар. Шул чакларда мин кыяматкә ышандым. Кылдан нечкә, кылычтан үткен сыйрат күпереннән атлап чыгу өчен дөньяда чакта корбан суярга кирәк дип, күперне шуңа атланып чыгарсың икән дип иман иттем. Алла диләр, аның пәйгамбәренә Җәбраил[48*] аркылы вәхи[1] кылә булган, дөньяның барлык хакыйкатьләре шул вәхи белән язылган. Коръәнгә кереп беткән, дип игътикад иттерделәр[2]. Ул вакыт ул игътикадларым буенча, Алла бу дөньяны җиде көндә яраткан иде. Дөньяның бар гомере җиде мең ел гына иде, җир үгез өстендә иде. Адәмнәр көн-төн гыйбадәт кылып, муллага, ишанга сәдака биреп, байга, хуҗага, буйсынып, кыямәтне көтәргә тиешләр иде. Бу ахырзаман бик якын иде. Шуңа күрә ул чакта көтә идек. Бәни Әсфәр дигән кавем[49*] чыгар, бөтен җир йөзен алыр, аңа каршы «Хәлифә» Лива әл-Хәмдене күтәрәчәк[3], бөтен мөселманга җиһад фарыз булачак[4], Дәҗҗал[50*] чыгып, барлык гөнаһлы кешеләрне үз артына ияртәчәк. Аңа каршы Мәһди[51*] күтәреләчәк, Гайсә күктән иңәчәк,[52*] Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ кауме[53*] җирнең кара туфрагын ашап бетереп барачак.«Даббател әзр» чыгачак,[54*] аның бер кулында Муса таягы,[55*] икенче кулында Сөләйман йөзеге[56*] булачак. «Син – кяфер», «Син – мөселман» дип һәркемнең маңлаена мөһир басып, йөриячәк – шул куркыныч хәлләр өстендә кыямәт[57*] булачак. Кыяматтә Исрафил сурын өрәчәк,[58*] һәм үлекләр каберләреннән, кәфеннәрен күтәреп, торачаклар; « вә нәфсаһ!»,[5] «вә нәфсаһ» дип «тәразу»[6]га, «сыйрат»[59*]ка барачаклар, аны үтә алмаган гөнаһлылар тәмуг утына төшәчәк, чыгып киткәннәр – изгеләр оҗмахка керәчәк. Анда аракы эчәчәк, тәмәке

---

[1] *Вәхи* – Аллаһ тарафыннан пәйгамбәргә ирештерелгән фикерләр. күрсәтмәләр; пәйгамбәр күңеленә иңдерелгән боерыклар.

[2] *Игътикад иттерделәр* – ышандырдылар.

[3] *«Хәлифә» Лива әл-Хәмдене күтәрәчәк* – пәйгамбәр плащын байрак итеп күтәрәчәк.

[4] *Җиһад фарыз булачак* – көрәшкә күтәрелергә тиешле булачак.

[5] *«Вә нәфсаһ»* – «аның җаны».

[6] *Тәразу* – үлчәү, бизмән. Биредә: кыямәт көнендә кешенең изге гамәлләреме әллә гөнаһларымы икәнен “үлчәү” күз алдында тотыла.

тартачак, бер үзенә җитмеш хур кызы хатын итеп биреләчәк – шуңа күрә, адәм дөньяда түзсен, гыйбадәт кылып, сәдака бирсен; байга, хуҗага, түрәгә, муллага, патшага, буйсынып торсын – менә безне баладан шулай ышандырдылар. Без дә сезнең кебек гомернең баскычында шуларга ышандык. Ислам дине боларның һәммәсенә иман итүне фарыз дип танытты. Боларга каршы бару – көфер саналды. Хәзер менә бу әкиятләрнең нигезләре җимерелә башлагач, инде яңа буржуазия ягындагы динчеләр әйтәләр:

– Боларның күбе дин түгел, боларның күбе хорафат, – диләр, – дингә гыйлем нигезендә исляхат кертергә[1], – дип, – исламны элекке сафлыгына кайтарырга кирәк, диләр.

Сез миңа «бозау» дисез, ләкин мин үзем дә нәкъ сезнең кебек бер заман менә шул яңа дингә ышанып карадым. Шулайдыр, сафлыгына кайтарганда гыйлемгә, мәдәнияткә хезмәтче буладыр, дип иман кылдырдылар. Ләкин пәрдә тиз ачылды – бу яңа динчелек бары тик иске хуҗаны яңа хуҗага алмаштыру гына булып чыкты. Элекке кадим дин феодализмга тамырланса, бу яңартып, сафлап маташу – яңарган буржуазиянең халыкны талавына динне уңайлаштыру икәне миңа тиз ачылды. Шуңа күрә дә мин «бозау» дигән гайбәтне Нигъмәт казыйның үзенә кире ташлыйм. Бу – бозыклык, сукыр маймыллык түгел. Бу – атадан калган иске хатаны да, яңа буржуаның ялганын да җимереп ташлап, алга таба көрәшеп бару гына. Яшь иптәшләр, шуңа күрә исламның искесен дә, яңартылганын да, шул зарарлы, агулы әкиятләр белән чүплеккә ташларга тиешләр. Без элек кешеләрне икегә: мөселман белән мөселман түгелгә аера идек. Ләкин берәүнең мөселман яки христиан булуы – минем аңа күңел карашымның нигезен үзгәртә алмый. Хәзер без адәмнәрне дини мөнәсәбәт белән мөселман, мөселман түгелгә аермыйбыз, бәлки эшләүче белән эшләтүчегә, бай белән ярлыга, ач белән тукка, мәшһүр сүз белән әйтсәк, буржуазия белән пролетариатка, талаучы белән таланучыга бүләбез. Менә, бүленешләрдә диннәр һәммәсе дә халык талаучы югары иҗтимагый катлаулар, руханилар ягында талау, сукырайту, агулау коралы булып калдылар. Диннәр һәммәсе үз заманнарындагы нинди дә булса берәр иҗтимагый катлауның, бер төрле иҗтимагый хәрәкәтнең җимеше булып, коралы булып мәйданга килделәр. Әмма безнең хәзерге дәвер, эшләүче белән эшләтүче арасында хөкем сөргән җәберле мөнәсәбәтнең тәэсире сәбәпле яңа бер идея: социализм идеясе тудырды. Маркслар, Энгельсләрне[60*] китереп чыгарды. Без бүген ул талау коралы, халыкны агулау коралы булган яһүд, христиан, ислам диннәренең һәммәсенә каршы сугышып, яңа идея өчен, социализм өчен көрәшкә мәдрәсә яшьләрен

[1] *Исляхат кертергә* – үзгәртергә, реформа ясарга.

чакырабыз һәм ышанабыз, ул иске зарарлы әкиятләр безнең яшь буынның башын агуларга…

Оратор тагы бүләргә мәҗбүр булды, тагы аяк дөбердәтеп, сызгырган шау-шу күтәрделәр. Миһраннар нык оешып, яңадан сүз бирмәү өчен җанҗалны куертырга омтылдылар. Бу якның җанлануы белән Нигъмәт казый тагы канатланды, өстәлгә сикереп менде дә, татар яшьләренең динне сүгеп, социализм өчен көрәшеп йөрүләре вакытлы бер модага иярү дип, бу хәрәкәт милләтнең тамырына балта чабу дип, кычкыра башлады. Сүз арасында «Тәрҗеман»[61*]ны уртага атты: «Яшәсен карт милләтче Исмәгыйль баба!»[62*] – дип акырып җибәрде.

Ни чаклы каты акырса да җиңә алмады. Миһраннарның, Нәҗип Камалларның җанҗалларына каршы Җиһангир, секретарьлеген ташлап, нидер кычкырмак булды. Тавышын беркем дә ишетмәде. Шунда ук ябык, хәлсез шәкерт-җырчы Сәхип тора иде. Аның колагына бер сүз әйтте дә, үз ягына, тәрәзә төбенә тартып мендерде. Җырчы Сәхип үзенең шәп яңгыравыклы көчле тавышы белән «Марсельеза»ны сузды. Шунда ук аңа яшь шәкерт Камил белән Хәйри кушылды. Уртадан Сөләйман Сәйфуллин начар, музыкасыз, ләкин бик көчле тавыш белән аларга иярде. Бу көй, бу җыр шәкертләргә бик таныш иде. Бигрәк тә төнтүдән соң ятканда да, торганда да, җыелганда да, таралганда да шуны җырлыйлар иде.

Нигъмәтләр, Миһран, Нәҗип Камалларның җанҗалы шул җыр-көй эчендә батты. Бөтен җыелыш ниндидер бер дәрт, бер ашкыну белән гадәттән тыш каты тавыш, көчле җилкенү белән «Марсельеза»ны күтәреп җибәрде:

> Ташлыйк, туганнар, иске тормышны.
> Ул тормыштан илгә файда юк;
> Булса, байлар илә тик түрәләр
> Аркабызда рәхәт күрәләр.

Бөтен җәмгыять башта бергә кушылып җырлады. Аннан аерым-аерым төркемләнеп, коридорга, бүлмәгә таралганда да туктаусыз:

> Ташлыйк, туганнар, иске тормышны…

авазы яңгырады.

## XLVII
## ӘХМӘТ НУРЫЙ ӘФӘНДЕ

Әхмәт Нурый әфәнде бу мәҗлескә чакырылган иде. Ләкин ул көн шәһәр театрында думага сайлауда рус партияләреннән кайсылары белән бару, үзебездән нинди кешеләрне сайлау турында ясалган җыелыш зур талаш белән ябылды. Монда да шундый хәл булуы мөмкин. Алдан болай үзара аңлашырга кирәк дип уйлады. Әмма алдан аңлашымый ясалган мәҗлесләр

үзара берләшүгә түгел, бәлки аерылышуга хезмәт итәләр дип ышанды. Аның Булатны бик күрәсе килгән иде. Аны зинданга яптылар. Кайчан чыгарырлар – билгеле түгел. Хәзер зинданнар бик тулы, диләр. Сәяси тоткыннарны ябарга урын җитми имеш, диләр. Якын арада партия-партия җыеп, ерак Себергә сөрәчәкләр имеш. Булат та шунда эләккән имеш, сөрелгән имеш, йә сөреләимеш, диләр. Аның иптәшләреннән Госман Азаматов белән Акчулпанов бар. Ләкин болар белән сөйләшергә ярар иде. Тагы менә Давыт Урманов дигәннәре бар. Күбрәк дингә, мулла-мунтагайга бәйләнеп, шуларны сүгеп маташа бугай, ләкин барыбер адәм бит яхшы сүзне, дөрес фикерне аңлар. Безгә бөтен гомерне болай үзара сугышып үткәрү ярамый. Аңлашмак безнең бурычыбыз! – Әхмәт Нурый менә шулай уйлады.

Ул көн театрда сайлау алды хәзерлеге белән сөйләнгән сүзләрен киңәйтергә теләде:

– Бездә, – диде, – нәрсә бар? Дин бар, милләт бар. Бу ике бөек куәт безне берләштерәләр. Бездә сыйныф сүзенә урын юк. Безнен буржуй дигәннәребез дә Американың эшчеләреннән югары түгел. Сыйныф сүзен ташламалы, дин-милләт нигезендә куәтле бер иттифак вөҗүдкә китермәле! – Менә ул шулай сөйләргә алдан хәзерләнде. Кызыл яшьләрнең һәр ике партиясенә – социал-демократларына да, социалист революционерларына да, партиясез кызылларга да шундый киң бер платформада берләшүне тәкъдим итмәкче булды.

– Мин үзем буржуй түгел, мин дә сезнең кебек үз кул көчем белән яши торган, дәрестән, мөхәррирлектән килгән жалованье[1] белән киченгән бер зыялы. Мин – эксплуататор[2] түгел. Без сезнең белән бу мәсьәләләрдә аңлашырга тиешле! – дип, сүзен куәтләргә теләде. Ләкин турыдан-туры үзе барып сүз ачарга базмады. Базмады түгел, ваксыну булыр дип карады. Йосыфҗан аңа якын таныш иде. Хатыны ягыннан Разия туташ белән дә якын иде. Иң элек шулар буенча кыл тартып карыйм диде. Шулай дип уйлап йөргәндә, моңа Йосыфҗан үзе килеп керде дә:

– Әхмәт Нурый әфәнде, сездән зур үтенеч! – дип, Истанбул мәктәпләре турында сорашты. Анда укулар ничек? Аларны бетергәч, Германиянең нинди мәктәбенә кереп була? Шул турыда аңардан материал алды. Әлбәттә, үзем качам димәде, бер шәкерт китмәкче, шул үтенгән иде, дип каплады.

Әхмәт Нурый әфәнде Йосыфҗанны мондагы кызыллар арасында үз кешесе дип белә иде. Серен ачты, үзара берләшү, аңлашу платформасын сөйләде:

---

[1] *Жалованье* – хезмәт хакы.
[2] *Эксплуататор* – изүче.

– Минем зур мәсьәләм бар. Сез ничек карыйсыз? – диде.

Сүз озынга китте. Күп нигъмәтле, бай хәзерләнгән өстәл янында, кайнаган самоварны бушата-бушата, озак тикшеренделәр. Ләкин Йосыфҗан яшермәде:

– Бик кире нәрсәләр, минем ышанычым аз... Көләрләр генә... Шулай да син Разия белән сөйләшеп кара. Ул сиңа ераграк балдыз да була ич. Кыл тартсын! Син әйтәсең, сезнең белән берләшергә, дисең. Алар үзара да ут белән су кебек ич!.. Каршы очрашканда алар хәзер талашып баралар. Талашсыз бер минут үтми. Ул көнне Булат бер митингта Давытларны, Мансуровларны эт итеп сүкте. «Сез, ди, тыштан гына кызыл, сүздә генә кызыл, ди. Сез бушбугазлар, сез социалист түгел, сез шул буржуазиянең сул яктагы бер канаты гына, сезне пролетариат эченнән куарга кирәк», – ди. Әйтәм бит, дөньяга карарлыкларын калдырмады... Ә син әле үзегез белән бер платформага чакырмакчы буласың!...

Ләкин Әхмәт Нурыйның дәрте сүнмәде, ул бу хакта Разия Ширинская аркылы кыл тартуны уйлап калды.

Йосыфҗан, кирәк материалны алгач, исәнләште дә чыгып атына утырды. Кичә кич Җиһангир алдында биргән вәгъдә буенча бүген кичкә, сигез сәгатьтә, Йосыфҗанга кирәкле юл әйберләрен – ялган паспортларны Давыт әзерләп куярга тиешле иде. Ул шунда барырга булып, чаттан борылды. Ләкин шунда ук аңа приказчик Фәхри очрады:

– Кайда барасың? Әйдә, тегендә бүген митинг ич! Талаш зур булыр, ник бармыйсың? – дип кычкырды.

Йосыфҗанга бүген-иртәгә үз язмышын өзәргә кирәк иде:

– Юк, минем эшем бар. Мин Давытка барам, – диде. Фәхри тагы кычкырды:

– Алайса бигрәк тә яхшы! Давытлар бая ук шунда киттеләр, – диде.

Йосыфҗанга башкача чара калмады. Кучерга атны борырга кушты. Фәхри аның янына утырды.

Тангатаров әллә кайчан ук шул әдәбият кичәсе ясау турында полицмейстердан рөхсәт ала алмый талашып йөри иде. Башта аңа: сәяси тоткыннар файдасына бирмәбез, дип бәйләнделәр. Ул аны шәкертләр файдасына дип алыштырды. Хәзер инде: програмны да, укыла, җырлана торган әйберләрнең, һәммәсен дә русчага тәрҗемә кылып китерегез дип киртә коралар икән. Уйнаклап барган күк аргамакның йөгертүе буенча, Фәхри менә шул әдәби кичә мәсьәләләрен сөйләп барды:

– Шәкертләр дә, гимназистлар да, приказчиклар да бик дәртләнеп йөриләр. Җырчы Сәхипнең бер хикәясе бар. Гаҗәп күңелле әйбер. Шуны укымакчы, башкортлар тормышыннан. Безнең Габдрахман да «Татар бае»

дигән искиткеч көлке нәрсә язган.

Йосыфҗан көлде:

– Әллә ул Нәфисәгә өйләнгәч шагыйрь булып киттеме?

Фәхри җавап бирә алмады. Кучер аның сүзен бүлде:

– Мәчетнең янына ук барыйммы? Әллә җитмичә туктыйбызмы?

– Тукта! Булды!

Аттан төшеп, караңгы тыкрык буенча бата-чума җәяү атладылар.

Менә караңгы күккә таба манарасын сузып утырган мәчет. Әнә аның янәшәсендә кечкенә, иске агач бина. Бусы мәдрәсә икән. Урам яклап койма. Тар ишек кебек кенә капка. Шуның баганасы янында бер күләгә кузгала. Фәхри: «Бу кем? Шпион түгелме?» – дип куркып, кире чигенә язды.

Тегеннән кемдер көлде:

– Котың очмасын, мин! – дигән тавыш килде.

Барсалар, реалист форма киемнән, фуражкадан Акчулпанов тора. Ул рөхсәтсез, качып-посып ясала торган мондый яшерен җыелышларга йөрергә яратмаса да, бүген ничектер килгән икән. Ләкин кайдан керергә белми аптырап тора икән. Капшана-капшана, өчәүләп алга атладылар. Мулла авырый. Мөгаллим кызыл икән. Бүген шуңардан файдаланып, аның мәктәбендә «Революция һәм җир мәсьәләсе» дигән темага баглап яшерен җыелыш ясалган икән.

Фәхриләр барып кергәндә мәктәп залы шыгрым тулы иде. Иң алгы сафта мәдрәсә яшьләре күренделәр. Җырчы Сәхипләр, Сөләйман Сәйфуллиннар ораторга карап катканнар. Алар артында моңарчы митингларга йөрми торган Вафа хәзрәт шәкертләре, байтак приказчиклар, бу тирәнең итекче, тегүче, бүрекче кебек вак һөнәрчеләре, тыгызланып, саф-саф утыралар. Фәхригә бөтенләй яңа, күтелмәгән кешеләр: иң артта, бер почмактарак утырган крәстиән Шакир солдат белән теге, театр җыелышына исереп кереп, зур җәнҗал куптарган Абдул булдылар. Ул урынсызлыктан эчәргә сабышкан Абдулның хәзер Йосыфҗан аркылы агач заводына эшкә алынганын белә иде. Ләкин яшьләргә катнашуын беренче тапкыр күрде. Шулар янында ук Габдрахман да күзгә чалынды. Ул аның янына үтәргә чамаласа да, зал бик тыгыз тулган иде, үтә алмады, шунда, тәрәзә яңагына сыенып, тыңлый башлады. Сөйләүче – әле күптән түгел генә Яманташ буйларында йөреп кайткан Хәбип Мансуров иде:

– Авыл ач... Алпавыт, урядник, земский начальник – бары берләшеп, мужикның җилкәсенә менеп атланганнар... Мужик ыңгыраша. Боларны атып бәрергә омтыла... Анда кеше кирәк, крәстиән балта-сәнәге белән күтәрелеп, алпавытка каршы бунт чыгарырга кирәк... Яшьләр менә шуңа хәзерләнсен... Тегеннән, арттан Шакир солдат кузгалып:

– Ул, агайлар, алай гына барып чыкмый. Минем дә сүзем бар, – дип, кул күтәргән иде, кинәт мәктәпнең ишеге ачыла да, ниндидер бер озын буйлы, кара эшләпәле, кызмы, яшь марҗа хатынмы атылып килеп керә.

Бу – Разия туташ Ширинская булып чыга. Аның күзләре маңлаена менгән. Йөзе куркып агарынган, тавышы ашыгып, каушап чыга:

– Иптәшләр, таралыгыз! Хәзер полиция килеп баса! – дип чинап, нәзек тавыш белән кычкырып җибәрә.

Һичкем һичнәрсә аңламый. Халык хәйран булып катып кала. Кыз кабатлап, чинап, каушап кычкыра:

– Аңлыйсызмы? Полиция баса, дим!..

Иң элек Качкын аңга килеп, хәлне сизеп ала да, кисәктән бер якка ташланып, урам як кечкенә тәрәзәне бәреп төшерә:

– Иптәшләр тиз таралырга! Таралырга! – дип акыра. Үзе шул секунд чыгып, каядыр югала...

Монда мәктәп эче янгын чыккан йорт яки батып барган кораб төсен ала. Залны каплаган җәмәгать, үзен-үзе белми, ватык тәрәзәдән, ишектән качарга ташлана. Кычкырышалар. Бәрелешәләр. Бер-берен этәрешәләр. Әйтерсең, дөньяның асты-өскә килә, шундый кызу кабаланып тапташып, бер минут вакыт үткәч, дүрт-биш йөз кешелек җәмәгать ишектән, тәрәзәдән качып чыгып бетәргә өлгерә. Полиция килгәндә инде мәктәпнең тупсасы каерылып ыргытылган ишеге, чәлпәрәмә килеп ватылган дүрт тәрәзәсе белән идәндә, мич буенда аунап яткан бер кәләпүш белән бер прокламация кисәгеннән башка һичбер нәрсә калмаган иде инде.

Ләкин жандарлар моның белән генә тынычлана алмадылар. Монда кеше калмавын күргәч тә, агентлар, филерлар, җен кебек очып, чатларга, тыкрыкларга таралдылар, җәмгыятьтән таралганнарны эзләргә йөгерделәр.

Шул мәхәлләнең мөәзине Госман белән якын иде. Ул Акчулпанны алды да шуңа кереп яшеренде. Давыт та, ике тыкрык үтә качып, җиңел котылды. Ничектер шулай туры килде: яңа мәчетне үтеп, Екатеринскийга борылганда, ул Разия белән очрашты. Туташ арыган, ватылган, ләкин үзе дулкынланып кайный, яна иде, күрүгә килеп тотынды:

– Сезме? Сезме? Тотылучы юкмы икән? – дип, аның кулларына асылынды.

Алар бергә кайттылар.

Разия туташ, шәһәр эченәрәк кереп, эләгү куркынычы беткәч, полиция килеп басарын ничек белүе турында сөйләп китте:

– Бүген, – ди, – анакайның мигрене кузгалды. Аптекка йөгердем... Аннан Петербурда үзем белән укыган ике иптәш курсистка килде. Шулар мине задерживать иттеләр... Ну, мин әйтәм, инде соң, бармыйм, бераз һава

алып керим дип чыксам, артымнан берәү ахылдап килә дә беләгемнән тота. Үзе котырган кебек карый. Тукта, мин әйтәм, кулларыңа воля бирмә, тотынма, дим. Аңа карамый, мине кулы белән этәрә. Син катнашасың, диләр, белә булырсың, безнең мөселман яшьләре каядыр җыелган икән... Шуларны басарга жандарлар китте... Бар әйт, таралсыннар, ди. Мин ни эшләргә белмәдем, ридикюлемне ачам да портмонетымны акчасы белән аңа ташлыйм: менә сиңа, рәхмәт, дим. Ни әйтерсең, акчамны алмый: кирәкми, алмыйм, әйдә минем изге бер эшем булсын, ди. Беләсеңме бу кем иде? Бу теге городовой Сафа карт иде. Менә бит татарның алтын йөрәге кайда! Ә без аны адәмгә санамыйбыз!.. Ну, мин извозчик алдым да чаптым, – дип, сүзне бетерде.

Давыт белән Разия бу вакыт туташларның йортларына килеп җиткәннәр иде инде. Кыз тагы:

– Минем күңелем курка... Берәр иптәш эләкмәдеме икән? – дип борчыла-борчыла, Урмановка кулын бирде дә ике якка ачылмалы ак ишекнең уң ягындагы кечкенә электрик кыңгырау төймәсен басты.

Өйдән аңа чыгарга өлгерә алмадылар. Екатеринский ягыннан йөгерә-атлый Фәхри килеп чыкты.

– Ишеттегезме?.. Базар чатында Качкынны эләктерделәр бит!.. Мин аның артындарак килә идем... Ул ике чатта хәйләләп качты... Өченчесендә каршы яктан килгән агент тотын алды, – диде.

Кыз, туктап, агарынды, эченнән: «Күңелем курыккан иде. Шулай булыр, эләктерерләр дигән идем... Кызганыч», – дип уйланды.

Болай җыелып, капка төбендә өчәүләп сөйләшеп тору куркынычсыз түгел иде. Кул бирештеләр дә өчесе өч якка аерылыштылар. Туташ аерылганда Давытка кат-кат әйтте:

– Хәбипнең кайда ябылганын син сорап бел. Мин аңа кирәк әйберен җибәртермен... Ул бөтенләй ялгыз ич, аның монда беркеме дә юк! – диде.

## XLVIII
## БУ ШПИКТЫР

Жандарм агентлары Качкынны бишенче полиция участкасына китергәндә сәгать төнге берне суккан иде инде. Төнге кизүгә калган ачулы йөзле карт околоточный аңа текәлеп карады, тиз таныды: «Ә, эләктеңме, бандит, күп йөрдең, җитәр!» – дип уйланды. Ләкин телдән әйтмәде, җентекләп, бәйләнерлек рәвештә җавап алды. Әйткәнен яза бардылар, шулай бер сәгатькә якын этләгәч, кесәсендәге һәммә әйберләрен алып, аны дүртенче номерга озаттылар.

Ике полицейский аны ярым караңгы, тузанлы, чүп-чарлы тимер баскыч белән түбәнгә алып төштеләр дә анда тагы шундый ук ярым караңгы,

тузанлы, чүп-чарлы коридорның сәясиләргә билгеләнгән дүртенче бүлмәсенә кертеп яптылар.

Бу – шәһәр участкаларында була торган гади бер камера иде. Почмаклары юешләнеп, череп каралган, бөтен стеналары тузанланып, үрмәкүч оялары белән капланып беткән. Кара асфальт идән юылмаган, себерелмәгән, анда чүп-чар, тузан, тәмәке төпчекләре, кәгазь кисәкләре тулып ята. Ишекнең бер ягында акшары кырылып, кирпечләре сырланып чыккан зур иске мич. Аңа озын саплы иске себерке сөялгән. Ишекнең икенче ягында тоткыннарның мәңгелек юлдашы – зур, сасы, пычрак, иске агач параша. Стенаның ике ягы буйлап сузылган озын, ялангач агач сәкеләр. Югарыда тимер рәшәткәле кечкенә тәрәзә.

Качкын Хәбипне китереп керткәндә бу ялангач агач сәкеләрнең өстендә, бүлмәнең ярым караңгы яктысы эчендә, сугыштан соң кырылып ташланган гаскәр кебек булып, буй-буй тезелешеп, бер-беренә кысыла төшеп яткан кешеләр тынычсыз йокыдалар, кайберләренең гырылдавы да ишетелә иде.

Зур, калып тимер ишекнең шартлатып ябылуына уяндылар булса кирәк, Качкын, болар нинди халык бу дип күз йөртергә өлгерә алмады, сәкенең түр як почмагыннан берәү кисәктән башын калкытты. Йокылы тавыш белән:

– Сез кем?.. Ә?.. Коллега! Тәмәкегез бармы? Зинһар, берне бирегез. Дүрт сәгать тартканым юк, алып калдылар, сволочьлар! Үләм инде! – дип мыгырданды.

Аның тавышына башкалар да берәм-берәм баш күтәрә башладылар. Әйтерсең, сүз берләшкәннәр: һәммәсе, йокылы күзләрен тырнап ача-ача, урыннарыннан кузгалып җитми:

– Коллега! Тәмәкегез бармы? Һич булмаса, бер генә суырырга бирә күрегез! – дип теләнергә башлыйлар.

Хәбип Мансуров көлә:

– Ай, булсачы! Тегендә алып калдылар ич, сволочьлар! – дип, хәлен аңлата.

Анардан эш чыкмагач, үзара кесәләрен актарынырга тотыналар. Тынычсыз йокы кача. Тиз арада һәммәсе уянып бетәләр. Яңа иптәш янына түгәрәкләнеп җыелалар да:

– Ну, коллега! Нинди эш белән эләктең?! – дип сорашырга, чәнечке, шаян сүзләр белән яңа «коллеганың» кылын тартып карарга керешәләр.

Мансуров үзенең соңгы ел ярымлык идән асты тормышында бу хәлләрне берничә тапкыр кичергән егет иде. Тиз үзләшеп, шаян иптәш булып китте. Болар һәммәсе студентлар булып чыктылар. Оренбург

землячествосының әгъзалары икән. Яшерен сәяси җыелыш вакытында тотканнар да һәммәсен шунда китереп япканнар. Араларында ике курсистка да бар. Алар күршедә хатыннар камерасына ябылганнар. Арада берсе татар кызы икән. Гриша атлы бер студент, зур, озын ялларын уйната-уйната, шаярта куйды:

– Үзе татар кызы, үзе менә дигән матур. Сиңа зиндан романы корырга була гына, егет! – диде.

Бу сүз сөючән сары яллы егет Качкынның якташы булып чыкты. Күптән түгел авылына да кайткан, бер базарда Хәбипнең атасы – пенсионер учитель Гомәр картны да күргән икән. Тиз үк матур татар кызын да онытып, шуңа ташланды:

– Атаң Гомәр карт бик кайгырып ята. Чәчләре агарган. Ашым аш түгел, чәем чәй түгел дип әйтә, ди. Ул – минем бердәнбер улым иде, менә икенче ел инде хат та юк, хәбәр дә юк. Сез, яшьләр, шулай бит: әз генә канатлансагыз, сезгә ата да юк, ана да юк, дип рәнҗи, ди. Менә дип әйтә, ди, урыс гәзитен кулыма тотсам, күз алларым караңгылана башлый, улым Хәбип турында бер-бер кара хәбәр юкмы дип калтырыйм, дип әйтә, ди. Инде әнкәсе шул кайгыдан авыруга сабышты, ел ярым түшәктән тормый, карчыкның йөзе саргаеп кипте, асылгандыр балам, атылгандыр балам, Качкын дигән кушаматы бар имеш дип ишеттем, инде менә ел ярым бер сүз, бер хәбәр, бер хат юк дип һаман җылый, дип әйтә, ди.

Бу якташ Гриша артык тәмәкече нәрсә икән. Иректән кергән кешедә була ул дип, Хәбипнең һәммә кесәләрен әйләндереп-әйләндереп актарды:

– Тәмәке вагы булса, кәгазь ничек тә табар идек, шырпысын фиргавеннәрдән алдалап алыр идек, – дип, кат-кат кесә төпләрен какты. Ләкин кипкән тузаннан башка бер әйбер дә чыкмады.

Алласын, патшасын, жандармын, полиция фиргавеннәрен ата-бабалары белән сүктеләр, ләгънәтләделәр дә, яңадан берәм-берәм шул студент форма шинельләренә төренеп, тузанлы, каты, ялангач агач сәкеләргә сузылдылар.

Ләкин йоклап өлгерә алмадылар: камераның авыр кузгалышлы тимер ишеге шалтырап ачыла да, фиргавен ниндидер бер бәндәне этәреп кертеп җибәрә. Тиз баш калкыталар.

Ябык, кечкенә, юаш бер адәм. Өсте-башы да начар. Үзе бик өшегәнгә ошый. Керү белән берәүгә дә җүнләп күтәрелеп карамады, исе киткән, аптыраган төс тә чыгармады. Нәрсәдер белергә, сер алырга теләгән кебек тә күренмәде. Ләкин һәммә кешенең күңеленә шик төште. Аяк атлавымы, күз карашымы, дәшми-тынмый бер почмакка барып, тезләрен кочаклап, бөрешеп утыруымы, – белмим, нәрсәдер, студентларда үзенә каршы шөбһә уятты. Аны күргәч үк үзара пыш-пыш: «Шпиктыр... шпиктыр...» – дип сүз китә.

Хәбипнең якташы Гриша түзми, яткан җиреннән тора да теге бәндәне сүз белән, юк-барны сорашу белән изәргә, шаяртырга тотына:

– Син кем?

– Чиновникмы?

– Чиновник особых поручениймы[1]?

Бәндә җавап кайтармый. Күтәрелеп тә карамый, һаман ярым караңгы почмакта тезләрен кочаклаган килеш бөтерешеп, ялгызы утыра бирә. Гриша туктамый, бәйләнә бирә. Студентлардан берсе чыдамады:

– Нигә юк белән маташасың? Кайдан белергә, әллә түгелдер! – дип, Гришаны тыярга теләде.

Бу йомшый төште, ләкин үзен туктата алмый:

– Сез кем? Нигә бер сүз дә дәшмисез? Мин сезне шпик дип уйладым... Безнең серне алырга дип юри кертелгән шпион дип шикләндем... Әгәр сез намуслы гражданин булсагыз, мин гафу үтенәм! – ди.

Бәндә һаман бер сүз дә дәшми. Ләкин мәсьәлә үзенең үткенлеген югалткан иде инде. Тоткыннар берәм-берәм тагы тузанлы ялангач агач сәкеләргә бөтәрләнеп яттылар.

## XLIX
## ПИКНИК

Качкын ике студент уртасына – буш калган урынга юка пальтосын түшәде дә ава куйды[2].

Аңа да каты иде. Ләкин Яманташтан киткәнле бирле аңа җүнләп баш куярга туры килмәде, ул ике тәүлек йокысыз үткәрде. Шуңа күрә урынның катылыгын сизәрлек чамасы юк иде: иплап ятып та җитмәде, үлек кебек йокыга чумды.

Ләкин бу халык аңа тынычланып озак йокы бирмәде. Бөтен төн буенча участканың тузанлы, борчалы, кандалалы каты сәке тактасында аунап, газапланып чыккан студентлар, төрле яктан баш күтәреп, сүгенергә, җырларга, ишек дөбердәтергә тотындылар. Шул шау-шуга Качкын да уянып торды. Тагы шул кичәге кайгы, һәммәсенең чәчләре тузган, ләкин тарарга хәтерләренә дә килми, мыеклары сынган, ләкин аны төзәтеп маташырга дәрт төшми. Күзләре канлы, йөзләре уңайсыз ятудан, йокысызлыктан, тәмәкесезлектән бөтенләй бозылып, газапланып беткән. Тору белән тагы кесә төпләрен актардылар. Ләкин бер әйбер дә чыкмады.

Булмагач, читлеген тешләп каерган ач җанварлар кебек, дөбердәтеп

---

[1] *Чиновник особых поручениймы* – махсус кушылган йомышларны үтәүче чиновникмы.

[2] *Ава куйды* – ятты.

ишек кагарга керештеләр. Коридорда кып-кызыл йөзле, таза, симез гәүдәле, усал карашлы полицейский килде, каты усал тавыш белән:

– Господа, акрын! Бу ни шау-шу бу?! Югары катта господин начальникның квартиры ич. Сез аңа йокларга бирмисез. Әле сәгать алты гына!.. Менә вакыты җитәр, йомышчы (вестовой) килер, ни кирәк, шуны алдырырсыз! – дип шелтәләде.

Шелтә үтмәде, студентлар тагы дөберди башладылар. Бу тавышлану астында алар үзләре дә бераз онытыла төштеләр. Кемдер сәяси җырларның берсен тартты. Һәммәсе кушылып, акырырга тотындылар.

Кызыл йөзле, усал карашлы полицейский, тагы килеп, ачу белән карады:

– Бу ни эш? Сез монда бунт чыгарасызмы?.. Үзегезне үзегез тоттырасыз ич! Акылыгыз кая? – диде.

Җырдан туктамадылар, ләкин сәяси җырлар ярамагач, тынгысыз Гриша калын каты тавыш белән:

– Налей, товарищ! [63*] ... – дип башлады.

Арада бик яхшы тавышлылар да бар икән, хорга кушылырга һәммәсе дә ярады. Тотындылар ачудан, ачлыктан, тәмәкесезлектән бөтен бугазларына акырырга!..

Бу җырның мәгънәсенә полицейский да бәйләнә алмады, тик ара-тирә килеп:

– Акрынрак! Акрынрак! Анда господин пристав квартиры! Йокларга бирмисез аңа, шайтан бунтарьлар! – дип шелтә ясый торды.

Сәгать унгача шулай үтте. Унберенчедә «тышка» – бәдрәфкә чыгардылар. Аннан кергәч, шаяра-шаяра, кара асфальт идәнгә су сибеп, озын саплы себерке белән себерергә тотындылар. Уголовниклардан икәве килеп, боларның ләгән-парашаларын алып китте.

Болытлар таралды булса кирәк: камераның тузанлы пыялалы, тимер рәшәткәле тәрәзәсеннән шакмакланып-шакмакланып, кояш нуры идәндә, сәкеләрдә уйный башлады. Тыштан яхшы саф һава кереп, күңелләрне күтәреп җибәрде. Инде тагы бер генә нәрсә булса дөнья тәгәлләнәчәк иде. Аны да күп көтәргә туры килмәде. Сәгать унберне сугу белән авыр ишек ике якка ачыла, аннан бераз шелтәле елмаю белән:

– Ах сез, бунтарьлар! Шайтан балалары! – дип, шаян сүзләр сөйләп, теге кызыл йөзле, усал карашлы полицейский күренә, аның белән ике йомышчы, кочакларын тутырып, кәгазь каплар, төргәкләр алып керәләр.

Бу – студентлар өчен иректә калган иптәшләре, дуслары, сөйгәннәре тарафыннан китерелгән ашамлыклар булып чыкты. Иң элек һәммәсе:

– Тәмәке бармы?

– Тәмәке бармы? – дип, төргәкләрне актарырга ташландылар.

Бар. Һәммәсе бар. Тәмәке дә бар. Күмәч, булки да бар. Сыр, май, пешкән йомырка, казылык, ветчина да бар. Әфлисун, шоколад та бар. Җаның ни тели – шул бар. Ул арада зур чәйнек белән кайнаган су китерделәр. Бу – аз гына суына төшкән. Шулай да бик эчәрлек әле. Талашып, тарткалашып, ике тимер касә дә таптылар. Җүнләп тамак туйдыру сирәк насыйп була торган Качкын Хәбипкә дә болар ярый калды: ул, үз булып, шунда ашау-эчүгә чумды. Майдан, йомыркадан башланды, казылыгы, ветчинасын йота-йота, шоколадларга, әфлисуннарга барып җитте. Үзе ашый, үзе шаяра:

– Өч ел элек пикникка чыкканда гына бер сыйланган идем, шәп төште бу, егетләр! – ди.

Эш шул дәрәҗәгә җитте: уңган, тынгысыз Гриша шул байлык аркасында полиция белән якынлашу чарасын күрде, зур кисек ветчина белән, әфлисун белән сыйлап, теге кызыл йөзле усал полицейский белән дуслашып өлгерде, аңардан байтак эчемлек тә китертте.

Пикник дияргә урманы, елгасы җитми. Шулай да хәзер бу бүлмә участканың тимер рәшәткәле, тузанлы, пычраклы, усал сакчылы камерасы төсен югалтты, ярлы студентларның җыелып яши торган уртак квартирына әйләнеп китте. Тәмәке кайгылары очты. Тамак туйгач, күңелләре тагы күтәрелде, инде тагы «Налей, товарищ...»ны суздылар. Аның артыннан башка җырлар кушылды, җырдан уенга, гимнастикага күчтеләр, аннан биюгә барып җиттеләр.

Ләкин бу хәлнең болай озак баруы мөмкин түгел, боларны башкача тыярга да чара юк кебек иде. Үткән төн эләккән җыелышлары шәһәрнең менә шул бишенче участкасына караган бер квартирда булган икән, шуңа күрә һәммәсен монда китереп япканнар икән. Хәзер аера башладылар. Кем кайсы участкага карый – аны шунда озаталар. Монда тик ялган паспорты бер җиргә теркәлмәгән Качкын Хәбип Мансуров кына торып калды. Кояш каядыр яшеренде бугай: идәндә шакмаклар уйнамый. Студентлар таралып бетү белән бүлмә яңадан үзенең каты каравыллы, тимер рәшәткәле пычрак, сасы камерага әйләнә. Хәбип асфальт идән буенча тимер ишектән каралып черегән почмакка таба туктаусыз йөри башлый... Гришаның кичәге сүзе исенә килеп төшә. Тукта, күрше камерада ике курсистка бар, берсе татар дигән иде. Безнең Разия түгелме икән, дип уйланды да, полицейскийның киткән вакытын чамалап торды. Ишекнең уртасында бүрек зурлыгында капкач бар. Ул ачылып ябылмалы. Мансуров аяк тавышы ерагайганны гына көтте дә капкачны коридор ягына этәрде. Авызын шуның ачыгына тыгып, күршегә, хатыннар камерасына таба тавыш бирде. Анда, ахры, ишек яныннан китә алмый торганнардыр. Тиз үк, шыңгырдап, ачык матур музыка авазы белән

җавап килде. Разия түгел. Ләкин бу тавышны да Качкын таный иде. Аптырый калды:

– Гәүһәр туташ! Мин ни ишетәм, сез түгелме?

Матур музыка яңадан шыңгырдады:

– Сез кем? Хәбипме әллә?

– Ул үзе!

Ерактан полициянең коридор буйлап болай таба килгәне ишетелде, һәр икәве эчкә тартылды. Аяк тавышы үткәч, Хәбип, яңадан тишеккә авызын сузып, күрше камерага таба тавыш бирде:

– Гәүһәр, сез ничек биредә?

– Ә сез ничек биредә?

Хәбип, берничә сүз белән, кичә мәктәптә яшерен җыелыш булганын, «Революция һәм җир мәсьәләсе» куелганын аңлатты да шаярып өстәде:

– Сезне, Гәүһәр туташ, монда эләгүегез белән тәбрик итәм. Әйбәт йокладыгызмы? Кабыргаларыгыз исәнме?

Гәүһәр, йөрәге өзелеп, чын әрнүле тавыш белән җавап кайтарды:

– Ай, әйтә күрмәгез, йокы кая? Монда тузан, пычрак. Мин башымны кая куярга урын тапмадым. Проституткаларны кертеп яптылар. Алар исерекләр... талаш, сүгеш туктамады.

Хабип һаман ярым көлкедән чыгарга теләмәде:

– Алайса, тагы тәбрик итәм... Ярлыларның хәлен аңларсыз, якыннан күрерсез...

Кыз бик борчулы тавыш белән җавап кайтарды:

– Ай, әйтә күрмәгез! Миңа ни булса – ул! Анакай ишетсә, үләр инде! – диде. Кызыл йөз полицейскийның коридор буйлап үткәнен көтте дә тагы өстәде: – Шундый досадный[1] хәл булды... һәммәсе шул җебегән авыз Нинадан булды.

– Ничек алай?

– Менә шулай: сез беләсез, кичә Булатны Себергә сөрделәр... Ул миңа анасы аркылы шифрлы хат бирде, кайда нәрсәләр барын аңлатты. Аңа юлга да әзерлисе бар иде. Мин ялгыз өлгерә алмыйм, әйдә, Нина, булыш, дидем, әйткәнемә дә үкенәм. Әллә кайчангы идән асты кешесе диләр, – җебегән авыз икән. Мин күрсәткән әйберләрне алган да Фәхриләргә кертеп куйган. Фәхри миңа китерде. Минем менә шул студентлар белән яшерен җыелышка барасым бик килә иде... Үзем дә җүләр булдым, кофточка эченә, күкрәккә яшердем дә, кичекмим дип, Гриша квартирына киттем... Шунда эләктек... Паспортлар, адреслар эләкте... Менә шунысы досадно да. Булат ишетсә,

---

[1] *Досадный* – үкенечле.

әйтер инде: гомердә бер эш тапшырдым, шуны да башкара алмадың, дияр.

Тегеннән тавыш килде, аяклар килде. Хәбип Мансуровны мылтыклы, кылычлы ике каравыл астында охранкага җавапка алып киттеләр.

## L
## ТАНЫШЫҢ КЕМ?

Качкынның беренче эләгүе түгел иде. Җаваптан курыкмады. Тик: «Җәфаламасыннар! Кыйнап имгәтмәсеннәр!» – дип борчылып барды. Чөнки соңгы вакытта экспроприация[1] эше белән эләккән ике эшче большевикны чәчләрен йолкып, тырнакларын эскәнҗә белән тартып, үкчәләрен телгәләп, яраларына тоз салып, каты газаплау турында зур җәнҗаллы хәбәрләр таралды. Шуңа каршы протест итеп, бөтен зиндан ике атна ач торды. Моннан башка да соңгы заманда зинданда, охранкада, жандармериядә усал, нечкә юллар белән каты газаплар ясалуын күп сөйли башладылар.

Шул куркынычлар астында, вывескасыз, тыштан капка каравылсыз, ике катлы иске таш өйгә килеп кергәч, Хәбипне иң элек бер кечкенә бүлмәгә куйдылар. Тәрәзәсе юк, утырырга урындык, ятарга дисәң, карават юк. Мансуров сүгенә-сүгенә шунда өч сәгать көтте. Аннан соң аны чакырып алдылар. Элек аны зур, якты кабинетка ротмистр үзе җавапка тарткан иде. Бу юлы коридор башында тыгыз, кечкенә бүлмәгә керттеләр. Анда ябык, кипкән чырайлы, түбән карашлы, салынкы кашлы, чал сакаллы бер жандар офицер утыра иде. Күтәрелеп кенә карады да алдына анкета төртте. Ләкин аның исеме, фамилиясе, дине, милләте, партиясе турында язып беткәнен дә көтмичә, гаҗәбрәк сорау китереп куйды:

– Сез нигә Яманташтан болай тиз кайттыгыз?! Партиягезнең әйткән вакытын тутырмадыгыз ич! – дип, басынкы кашлары астыннан бер тапкыр гына күз салды. Аннан үз алдына капланды.

Качкын җавапка ашыкмады, тартырга ярыймы, дип, кесәсеннән папиросын чыгарып яндырды. Куе төтененә карап, бер дә алай исе китмәгән төс белән акрын җавап кайтарды:

– Яманташ дип ни, мин бит анда бер танышыма кунакка барган идем...

Жандар, тагы башын күтәреп, ник ялганлыйсың, барын да беләм ич дигәндәй карады:

– Танышың кем? Бәдри учительме? Шакир солдатмы? Әллә Заһит мулламы? – дип сорады.

«Чукынсын! Барын да түкми-чәчми китереп салганнар икән!.. Шулай да миннән әйттерә алмас!» – дип, тик торды; үзе, сер саткан кеше кем булыр

---

[1] *Экспроприация* – көч белән тартып алу.

дип, күз алдына Яманташ вакыйгаларын берәм-берәм тезә башлады. Ләкин жандарга бөтенләй башкача җавап бирә торды.

Яманташ буйлары Качкынга электән таныш иде. Башка һәркайда булган кебек, монда да авылларда биш-ун кулактан башка халык ярлы, җир аз, урман юк, печәнлек, болын имана башына ярты сажиннан артмый. Ярлы-ябагай үзе җирен кулакка чәчәргә бирә, кыштан юк хакына урак урырга, печән чабарга алып, җәен үзе өчен җүнле бер әйбер дә эшли алмый кала. Авылда, тирә-як алпавытларда эш тапмаганнар калага, заводка, фабрикага, шахтага агылалар. Уч кебек имана җиренә, ике аты белән каторга кебек эт булып эшләвенә таянып, авылында бәйләнеп яткан урта хәлләләр үзара җир бүлешеп, «иске ревиз», «яңа ревиз»[64*] дип талашып гомер үткәрәләр. Тормыш төзәтү юлларын эзләмиләр, белмиләр. Аңлаткан кеше дә юк. Тик Мансуровлар белән бер школада болардан элегрәк бетереп кайткан Бәдри учитель бар, ул егет школада чагында бик кызылланып йөрде йөрүен. Ләкин Русиянең күп почмакларында алпавытка каршы крәстиән хәрәкәте кызып барган хәзерге заманда, Бәдриләр татар крәстиәне арасында бернәрсә эшлиләрме, юкмы – билгесез иде, шулай да тик ятмаганнардыр, хәзерләнгәннәрдер дип өмит итә иде.

Төнге сәгать уникедә Урмановның җәһәннәм базыннан вокзалга китеп, икенче көн поезд белән килеп төшкәч, Хәбип Мансуров туры шул элекке танышы Бәдри учительгә төште. Башта, ничектер, аптырабрак калды: учитель баеп бара бугай. Атасы үлгәч, аңардан мирасын алып, алты почмаклы өй, әйбәт келәт салдырган, ике аты, матур бакчасы, сыеры, сарык-кәҗәсе, йорт тулы тавыгы, каз-үрдәге бар. Аш, чәй хәзерлеге, савыт-сабасы бик яхшы. Әмма хатыны кача булса кирәк, ләкин Бәдри үзе Качкынны ачык, шат йөз, тик эчтән бераз куркыну белән каршы алды. Эшнең кая таба юнәләчәген сизгәч, бу курку тышка да чыкты. Бәдри туры әйтте:

– Мин синең алдыңда рия сатасым килми. Үзең күрәсең, хатын бар, бала-чага бар. Миңа бик сак булырга кирәк. Кулдан килгән ярдәмне аямам, әмма үзем читтә калам! – диде.

Һәм ярдәмен аямады.

Каладан кунакка килгән иптәше төсле итеп башта кунакка йөртте. Караңгы кичләрдә авылның аңлырак егетләре белән очраштыру юлларын карады.

Монда, халык арасында, бер-берсенә каршы имеш-мимешләр бер-бер артлы таралгалый тора иде. Җир чыга имеш, патша хәзрәтләре күрше боярның җирен, урманын, печәнлеген боларга өләшеп бирә имеш, дип сөйлиләр. Картлар үзләренчә моны юрыйлар: булыр, булыр, Аллаһе Тәгалә күңелләренә шәфкать, мәрхәмәт салса, бары да булыр; еракта торсак та,

безнен авыр көнкүрешебез патша хәзрәтенә билгеле имеш, ул безне кызгана имеш... тик менә шул боярлар гына юл бикләп торалар имеш, диләр. Шулар эченә буталып, яшь-җилкенчәкнең колагына кайдадыр шаулаган революция дулкынының да тавышлары туктаусыз керә торалар. Әллә кайда алпавыт белән крәстиән бәрелешә. Крәстиәннәр, балта, сәнәк белән коралланып барып, боярның җирен басып сөрә, урманын кисә, өсәктәге[1] ашлыгын талый, имениесен яндыра да, үзен, бала-чагасын шул янган утка ташлый, – менә шундый имешләр кайнап килеп җитешәләр.

Бәдри учитель күрсәтүе буенча танышкан крәстиән егетләренең күбе Хәбип турында үзара:

– Җир чыгарырга өйрәтә имеш.

– Алпавытны таларга алып бара имеш, – дип сөйли башладылар.

Арада Шакир Солдат дигән берәве бар иде. Ул бик тиз аңлады. Ул йортсыз-өйсез, бер табан җирсез ярлы крәстиән икән. Солдатта чагында бераз аң кергән. Шул аңы өчен анда дисциплинарный батальонга эләккән. Ул йөрәге белән ашкына. Ләкин кайдан, кем белән башлап китәргә җай таба алмый аптырый иде. Качкын белән танышканнан соң, Бәдри учительнең йортыннан китмәс булды. Үзе язу-сызу белми. Ләкин жир, крәстиән турында, тормыш турында ни сөйләсәң шуны аңлап, йотып бара. Таза гәүдәсе, калын беләге белән кизәнеп, хәзер алпавытка каршы сугышка атлыгып тора. Аның сорашудан туймавына, һәр әйткәнне аңы, мие белән генә түгел, йөрәге белән йотып алуына Хәбип хәйран калды. Ул берничә көн эчендә гаҗәп үсеп китте. Кемнәргә серне ачу, кемнәрне түгәрәккә чакыру кебек эшләрне бөтенләй үз кулына тартып алды. Беренче түгәрәкне үз сайлавы белән оештырды. Җыелышларның урынын, вакытын ул үзе билгели торган булды. Түгәрәкне барган саен киңәйтә торган булды. Беренче җыелышка дүрт, икенчегә ун, өченчегә унбиш, – түгәрәккә чакырыла торган кешеләрнең санын ул үзе шулай көннән -көн арттыра барды.

Тиз арада бу җыелышларны авыл эчендә өйләрдә, мунчаларда ясау кыенлана башлады. Урядник сизәр дигән куркыныч һәммәсенең күңеленә керде. Авылның буеннан кечкенә генә елга ага. Аның аръягы киң болын, урыны-урыны белән зур таллык. Егетләрнең берсе, кулына җөгән тотып, ат эзләп йөри дә шул куе таллыкларга кереп югала. Икенчесе кайтмый югалган бозавын карый, – ул да басма аркылы шунда барып чыга. Кайберләр биленә балтасын кыстыра да, чыбыркы сабы өчен тал кисәргә барган кеше булып, әллә ничек шунда, тал арасында юк була... Шулай көннең билгеле бер вакытында төрле юллар, төрле хәйләләр белән болынга, куе таллар эченә

---

[1] *Өсәк* – амбарда, келәттә иген, бөттекле ашлык салып саклый торган махсус урын.

җыелалар. Авылның чит, ярлы урамнарында көн итүче крәстиәннәр, тук торган төп йорттан аерылып чыгып, бернәрсәсез калган эшлекле, тырыш, ләкин җирсезлектән, ничаклы тырышса да, һаман тамагын туйдыра алмый интеккән, шулай да әле җиңелергә теләмәгән таза, куәтле, батыр егетләр Шакир артыннан шунда, нидер өмит итеп, еш йөрделәр. Качкынның сүзенә йотылалар. Җир дигән, революция аркасында алпавытның җирен алу дигән мәсьәләләргә һаман-һаман кире кайталар; их, тора белер идек без, дип хыялланып канатланалар. Хәбип Мансуров болар эчендә үзе дә ялкынланды... Тиз арада эшнең киңәеп баруына хәйран калды.

Ике тапкыр болынлыкта яхшы үтте. Өченчесендә, Солдатның әйтүе буенча, күрше авылдан да берничә егет кушылды, алар эшне зурайтмакчылар, үз авылларында да шундый яшерен түгәрәкләр ясамакчылар.

Берничә авыл шулай эшләр. Аңлы егетләр оешыр... Аннан соң барың берләш тә, көрәк, сәнәк, балта белән кораллан да күрше алпавытның җирен, урманын басып ал, йортын яндыр, үзен утка сал тавышы да чыкмасын, токымы, орлыгы калмасын!

Менә шундый хыяллар белән янып, өченче җыелышны үткәреп ятканда, авыл ягыннан берәүнең йөгереп килгәне күренде. Шакир Солдат үзе, талдан чыгып, елгага таба каршы барды. Килгән егет сулышын чак ала. Арып, ахылдап беткән:

– Учительгә, – ди, – урядник килгән, ди. Бәдри абзый әйтте, ди, тиз булсыннар, таралып бетсеннәр дип әйтеп әйтте, – ди.

Башка чара юк иде. Крәстиәннәр төрле якка сибелде. Тагы кайсы, балта күтәреп, чыбыркы сабына тал кисә башлады, кайсы, нуктасын тотып, ат эзләргә китте.

Качкын Ямanташ авылына бөтенләй кайтмады. Шуннан елга буйлап Йомран авылына сызды.

Азактан беленде: урядник килгән дә Бәдри учительгә:

– Син өеңдә студентлар асрыйсың икән. Алар яшерен җыелышлар ясый икән. Боярның ашлыгына ут төртергә әзерләнәләр икән! – дип бәйләнгән.

Учитель:

– Юк, ул студент түгел. Ул минем школа иптәшем. Миндә кунакта булды да кайтып китте, – дип җавап биргән.

Йомранда үткән ел гына указ алган яшь мулла бар. Исеме Заһит. Бу – шәкерт чагында бик кызыл иде. Бәдри аның турында: «Бик дәртле нәрсә! Тик кайдан барып кушылырга гына белми йөри», – дип сөйләгән иде.

Тал эчендәге яшерен җыелыш таралгач, үткенче-юлаучы шәкерт кыяфәте белән Качкын шул муллага барды, ләкин мәгънә тапмады.

Мулланың сүзләре икеле генә түгел, бөтенләй шөбһәле күренде. Беренче сүзендә үк:

– Бәдригә урядник китте, анда кызыллар ята имеш, әрәм була учитель! – дип башлады. Шул сүзне әйткәндә йөзенә, күзенә курку төсе чыкты.

Сәрүҗи мулладан өмит өзде, самовар куйганчы ук:

– Тышка йөреп килим! – дип йортка чыкты, абзарда комганын утыртып калдырды да, үзе ындырдан тыкрыкка төшеп, арткы урамнар белән тиз-тиз сызды. Эзгә төшәчәкләре ачык иде.

Шуннан туры яңадан калага кайтты.

Урядник җитез нәрсә булырга ошый. Тиз арада байтак әйбер иснәнеп сизенгән. Шакир Солдатны да, Бәдри учительне дә, Заһит мулланы да – барын бер җепкә бәйләп, монда калага хәбәр салган булырга тиеш.

Жандарм офицерының салынкы кашлары астыннан туры карап: «Танышың кем? Шакир Солдатмы? Бәдри учительме? Заһит мулламы?» – дип, Хәбип Мансуровтан соравы, әлбәттә, шул урядникның докладына нигезләнгән иде.

Качкын моны яхшы аңлады. Шулай да үз авызыннан бер дөрес сүз дә әйтмәскә карар бирде. Өч сәгатькә якын газаплаганның соңында офицер, салынкы кашын күтәрә биреп, кычкырды, тоткын алдына протокол кәгазен этәрде:

– Мә алайса, яз: «Мин бер сорауга да җавап бирергә теләмим», – диген. Шулай дип кул куй!

Мансуров моңа да бармады:

– Юк, мин алай язмыйм, мин сезгә ни белсәм, шуны әйтәм, шуны язам. Белмәгәнне ялганларга минем телем бармый! – диде. Тәмәкесен куе төтенләндереп утыра бирде.

Жандар ачулы төс белән алдындагы төймәне басты. Тегеннән килүче унтер-офицерга:

– Мансуровны алып чыгыгыз! – дип боерык бирде.

## LI
## ӘФЬЮНЧЫ КӘБИРГӘ КАРШЫ

Гаҗәбе шул булды: Качкынны гадәт буенча зинданга алып китмәделәр, кире баягы участканың сасы, пычрак камерасына китереп бикләделәр. Килеп кергәч, бераз аптырый калды: камерада башка һичкем юк, ике ябык, саргылт шәкерт бер почмакта боегып утыралар. Сәрүҗи шәкерт арасында байтак эшләгән кеше. Үз кеше. Ул керә-керүгә алар янына барды, иптәшчә дәште:

– Нихәл, туганнар? Сезне ни өчен яптылар? Болар Качкынның исемен ишеткәннәр иде. Ләкин үзен күреп танымыйлар иде. Ул икәнен белгәч, башта

кайдан башларга сүз тапмый калдылар, Хәбипнең сорауларына да тартынып, оялчанланып, кыска, кыюсыз җаваплар бирделәр. Ләкин асылда болар икесе дә үзләренчә үткен егетләр иде. Тиз ачылдылар. Үз кешеләре, үз татарлары итеп, Качкын белән бөтенләй үз булдылар. Нечкә, озын буйлы, нечкә иренле, кызу канлы шәкерт – Рәфыйк Әлхариси булып чыкты. Ул Гәрәй Солтанның авылдашы икән.

– Аның Кавказдан кайтып төшкәнен белгәч тә, бардым да әйттем: «Мине революция юлына керт», дип әйттем, – ди. – Ул миңа берничә китап бирде. Үзе күп сүзле түгел икән. Шулай да минем йөрәгемне тартып алды. Мин аңа көн дә килә торган булдым. Аның кушуы белән җилем басмада әйберләр бастырдым, – ди.

Качкын аның сүзен бүлде:

– Ә соң нигә сине монда китереп яптылар?

Шәкерт, кыюсызланып, әйтергә ярыймы, юкмы дип икеләнеп торды да кинәт ачып җибәрде:

– Без, – ди, – әфьюнчы Кәбир хәлфәне бетерергә әзерләндек... Шул сизелде бугай. Әле җүнләп үзем дә белмим, – диде.

Бу Рәфыйк Әлхариси шәһәрнең иң кара фанатик хәзрәте Вафа мулланың шәкерте иде. Башкалар дөнья җимереп дулкынланган чакта, бу мәдрәсә бөтенләй иске рәвештә тыныч калган иде. Бүтән мәдрәсәләр зияратка үлек күтәреп, садака өчен баруны хурлык дип ташлаганнан соң, бу мәдрәсә, Шәриф байның карчыгын күтәреп, «хәмел»гә[1] каберстанга барды. Аларны кайтканда башкалар «Хәмел бәете» җырлап, мыскыл итеп, чиләк төбе сугып каршыладылар. Ләкин мәдрәсә һаман да искечә, үзенең схоластикасы, моназарәсе эчендә сасып ята кебек иде. Менә шунда кинәт астыртын хәрәкәт башлана. Ике тапкыр яңа фәннәр, яңа програмнар, ислахлар сорап гариза бирәләр. Әфьюнчы Кәбир дигән хәлфә ишек-тәрәзәне бикләтә, каравыл куйдыра. Үзе йөрсә дә, каршы сөйләргә әзерләнеп барса да, һичбер шәкертне һичбер җәмгыятькә җибәрми, митингларга, демонстрацияләргә катнаштырмый. Белсә, идән уртасына яткызып, бөтенләй чишендереп, суктыра. Менә шулай барганда, бер көн хәлфә почтадан хат ала. Кыска, ачык язылган, фамилия белән түгел, № белән кырык кул куелган. Алар болай әйтәләр:

«Әфьюнчы Кәбиргә!

Җитәр,каныбызны күп эчтең, җитәр, күп гомеребезне схоластика белән харап иттең, миебезне чүп-чар белән тутырып күп череттең! Инде вакытың үтте. Җитәр! Милләт тамырына балта чабудан тукта. Син хәзер

---

[1] *Хәмел* – мәетне колаша белән күтәреп кабергә илтү.

безне укыта алмыйсың! Син хәзерге көндә умарта каравылыннан башкага ярамыйсың! Сиңа бер атна вакыт: шул мөддәт[1] эчендә мәдрәсәдән кит, без ислах сорыйбыз, без теләгебез юлында җаныбызны бирәбез. Син безнең барачак юлда кискә булып ятма: мәдрәсәдән кит! Кит! Яхшы сүзне тыңламасаң, бер атна эчендә мәдрәсәдән югалмасаң, без сине дөмектерәчәкбез! Кырык адәм берләштек. Шобага салачакбыз!»

Әфьюнчы Кәбир хәлфә, бу хатны укыгач, агарынып ката. Теле тотлыга, бераздан соң гына сүзен әйтә ала:

– Шулмыни? Минем кырык ел мәдрәсәдә ятуымның, егерме ел буенча бер тиен алмый ачлы-туклы шәкерт укытуымның мөкяфәте[2] шулмыни? – ди дә, йөзен каплан, Вафа хәзрәт алдында түзми җылап җибәрә.

Шунда ук мәдрәсәне караучы байларга хәбәр итәләр. Ашыгыч җыелышалар. Үзара талаш туа: «Ни эшләргә? Үлем белән куркыталар. Моны урыс полициягә әйтергәме, әллә серне кяферга чыгармый калдырыргамы?»

Ахыр, барып әйтәләр. Шул сәгатьтә үк жандармерия, электән үк кызылларга катнаша иде, бер очы шуңа тоташа булыр дип, Рәфыйк Әлхарисине кулга ала.

Аның эләгүе шул сәбәпле икән. Әмма аның белән бергә участкага ябылган икенче шәкерт Мәдрәсәи исламиядән җырчы Сәхип икән. Аның ябылуы сәяси түгел. Ул башта кыюсызланып торды да әйтә куйды:

– Мин җүләрлегем сәбәпле эләктем, – ди.

– Ничек җүләрлек сәбәпле?

– Менә шулай инде. Җәйләрдә мин Казакъстанда күп йөрим. Башкорт курайчылары эчендә кайныйм. Шуннан бер чир йокты. Мин җыр яратам. Әкият яратам... Җыр артыннан йөри торгач, бер гыйшык бәласенә эләктем. «Башкорт кызы Гөлбикә» дип атап, шуны яратып язган идем. Бер әкият, бер хикәя булсын дип язган идем. Укыгач, башкалар да яраттылар... Кулдан-кулга йөри башлады. Баязид карыйдан җилем басма өйрәнгән идем, бер көн тоттым да шуны, бикләнеп, баса башладым. Менә шул җүләрлегем белән килеп тә эләктем... «Башкорт кызы Гөлбикә» минем башыма җитте, – дип, үз эшенең бер мәгънәсе бармы, юкмы икәнен, әллә мондый эш чынлап та тик җүләрлек кенәме икәнен ачык аерып белә алмыйча, уңайсызланып кызарды. Ни әйтерләр дип, бер озын буйлы, нечкә иренле Рәфыйк Әлхарисигә, бер Качкынга карады.

Ләкин шәкерт мәсьәләне үз ягына тартты, көлә төшеп:

– Ярар, ни булса шул булыр: тарихка эләктем ичмаса, – дип шаяра.

---

[1] *Мөддәт* – вакыт, срок.

[2] *Мөкяфәте* – бүләге, компенсациясе.

Җырчы Сәхип тә шуңа якын бер мәгънә әйтергә тели:

– Мин дә кайгырмыйм, зинданга япсалар, урысча өйрәнермен, сәясәт белән, революция белән, партияләр белән танышырмын... Зиндан миңа дарелфөнүн[1] булыр! – дигән мәгънәдә бер сүз әйтмәк була. Ләкин читләр алдында кыюланып өйрәнмәгәнлек аның телен тота. Ул, тагы кызара төшеп, Качкыннан:

– Минем «Башкорт кызы Гөлбикә»мнең кулъязмасы да, яртылай җилем басмасы да жандарлар кулында китте, миңа кайтарырлармы икән? – дип сорый.

Җавап биреп өлгерми, яңадан Хәбип Мансуровны югарыга чакырып чыгаралар, аннан туры охранкага китереп, мең төрле сораулар белән дүрт сәгать газаплыйлар; тагы шул Ямanташ, Бәдри учитель, Заһит мулла, Шакир Солдатлар белән башын әйләндерәләр. Бу юлы бер сорау арта, аерым кискенләнеп чыгарыла:

– Шакир белән калага бергә кайттыгызмы? Әллә аерыммы? Шакир Солдат хәзер калага ни өчен килде? Ул нигә хәзер авылны ташлап, калага күчәргә йөри? Ул заводка кем аркылы урынлашмак була?

Мансуров иртәнге тактикасыннан чыкмый, аз, кыска әйтә, ялган сөйли, һаман шул кунакта булдым, башканы белмим, ди, жандар офицер аңа тагы протокол кәгазен ташлый:

– Алайса: «Мин җавап бирергә теләмим!» дип кул куегыз! – ди.

Качкын кул куймый:

– Ни белсәм, шуны әйттем! Артык берни белмим! – дип, катып, тәмәке тартып утыра бирә.

Аны, алып чыгып, зинданга озаталар. Ул охранка ишегеннән чыгып барганда, җырчы Сәхипне, үзенең бичара ярлы шәкерт киемендә, каушап-каушап, жандармерия өенең урам як ишегеннән алып кереп киттеләр.

Шул ук салынкы кашлы жандар офицер җырчы Сәхиптән дә җавап алды. Башта ук әйтте:

– Сез беренче эләгәсез. Гаебегез зур түгел. Мин сезне бүген чыгарта алам, тик бернәрсә әйтегез: сезгә җилем басманы кем бирде? – диде.

Шәкерт агарынды. Сорау вакытында төрле газаплар була имеш, дип ишеткәне бар иде. Ул язмам мине шул газапларга чаклы өстерәрме икән, дип уйлады. Ләкин башка бернәрсә дә ачмады, ватык-сынык рус теле белән:

– Кеше бирмәде, мин үзем ясадым, үткән ел асылган анархист Егордан ишетеп калган идем, – дип, кабат-кабат чәйнәде.

Жандар аптырады: «Моны ни эшләтергә? Бу көенчә берәүгә дә зыяны

---

[1] *Дарелфөнүн* – университет.

юк. Әгәр япсаң, зинданнан революционер булып чыгачак, япмасаң, бәлки, кирәкле бер серне ачмый чыгып китәчәк!.. Ни эшләтергә? Мондыйларны революция шаукымыннан ничек сакларга?»

Ләкин шулай да Сәхипне кайбер нәрсәләр әйттерми торып чыгармаска исәпләп куйды.

## LII
## ҖЫРЧЫ СӘХИП

Сәхип ярлы, ятим үсте.

Җиде яшькә җиткәч, аны әбисе карчык авылның мәчете янындагы кечкенә мәптеккә китерде дә, кулына ике йомырка тоттырып, ишектән төртеп кертеп җибәрде. Анда, кечкенә тыгыз бүлмәдә, сиксәнләп бала: әлепсеп-ә, бисен-бә, тиясен-ти, тисен-тә, дип шаулый, уртада, озын чыбык тотып, бер күзе кылый хәлфә утыра иде.

Ишектән Сәхип килеп керү белән мәптек шым булды, хәлфә аңа текәлеп карады:

– Сиңа ни кирәк?

Сәхип оялды, башы белән бер якка кырынаеп, җиң очын авызына капты да тик торды.

Хәлфә тагы:

– Кем углы? Укырга килдеңме? «Әлебби»еңбармы? диде.

Сәхип култык астыннан апасы биргән иске «Иман шарты»н[65*] чыгарды, ике йомырканы хәлфәгә китереп төртте.

«Кем баласы?» – дигәнгә каршы тагы, муенын кыйшайтып, җиңен чәйнәде, авыз ачарга курыкты, ялгыш әйтер дә, хәлфә үзенең озын чыбыгы белән шыелдатыр кебек тоела иде.

Хәлфә яңадан аңа күзләрен текәп, ачуланган тавыш белән:

– Ник дәшмисең? Әллә телсезме син?! – дигәч, Сәхип пес-пес җылый башлады.

Ул арада малайлардан берсе бик кабалан тавыш белән:

– Хәлфә абзый, мин аны беләм: ул Кәримә әбинең кызының улы. Аның ата-анасы юк, ул ятим... Алар түбән очта, күпер төбендә торалар... Мин беләм, аларның мөгезсез кәҗәләре бар иде, былтыр көз «Әшкүл» буенда бүре ашады.... Мин беләм, печән өстендә алачыклары янды... – дип такылдап китте.

Хәлфә Сәхипкә утырырга кушып:

– Бисмилланы беләсеңме? – диде..

Бала, муенын кыйшайтып, җиңен чәйнәгән килеш, ишстелер-ишетелмәс, авыз эченнән:

– Песмеррахан... – дип мыгырдады.

Хәлфә:

– Җиңеңне чәйнәмә, ачык әйт, кычкырып әйт! – дигәч, Сәхип тагы пыскылдап җылады.

Малайлар көләргә тотынды, хәлфә озын чыбыгы белән бер уңга, бер сулга ши-ши иттереп тартты, берничә яктан:

– У-у... у... беләккәем... у-у... Аллакаем!..

– У-у... у... муенкаем!.. – дип сызланып, бызылдап җылый башладылар. Үзләренә чыбык эләкмәгән малайлар бу җылаучыларны:

– Ә, алаймы? Үзәгеңә үттеме? Бая миннән көлгән идең... Икенче шаярмассыз! – дип үртиләр иде.

Хәлфә сабак бирде, Сәхип, уң кулы белән аяк табанын кашуда дәвам итеп, күзләрен мичнең ярыгыннан сузылып чыккан төтенгә юнәлдергән хәлдә: «Әлепсен-ә, бисен-бә... биасын-би...»не күңелдән кабатлый башлады.

Көн шулай үтте. Кич булды. Кылый күзле хәлфә урынына калган зур аксак шәкерт:

– Ятыгыз, ятыгыз! – диде.

Менә бервакыт сәндерәдән мендәрләр, бишмәтләр оча башлады. Ансыз да тыгыз, һавасыз мәктәптә тын алырга җай калмады: тузан күтәрелде, шау-шу кузгалды; кемнең аягына басканнар, кемнең мендәрен җыртканнар, аннан мәктәп эче йон белән тулды; кемнең юрганын пычракка ташлап таптаганнар, кемнең бишмәтен урлаганнар. Бер сәгатькә якын шау-шу, тузан-йон белән ду... килгәннән соң, мәктәп бераз тынды, ишекне ачкач, тузан бураны да басылып, һәркем урынлы-урынына сузылды. Арадан алты малайга урын калмаган. Алар, зур аксак шәкерткә барып:

– Без кая ятыйк? Урын юк... Апрайлар безне кысып чыгарды! – дип җыларга башладылар.

Шәкерт озын чыбыгын алды да яртылай йоклап беткән малайлар өстеннән:

– Әлиф ят! Әлиф ят! – дип, бер уңга, бер сулга шыелдата башлады.

Тагы кемнәрдер: «У-у... у... беләккәем... колаккаем!..» – дип сызланып, җыларга тотындылар.

Әлиф яткач, урын киңәйде, теге алты малай да арага сыйды.

Ут сүнү белән төрле яктан: «Әкият, әкият!» – ди башладылар. Бик күп ялындыргач, Садыйк таз дигән берәү:

– Борын-борын заманда бар ие ди бер патша, аның бар ие ди өч улы, таз ие ди кече улы... – дип сөйләргә тотынды.

Ул бик майлап, матурлап, килештереп сөйли иде. Сәхип теге кылый күзле хәлфәне дә, тыгызлыкны да, аксак шәкертне дә, уңлы-суллы чажылдап

торган озын чыбыкны да онытты, шул әкияттәге патшаның кече улы белән китеп, җиде диңгез кичте, җен патшасының җитмеш катлы бүлмә эчләренә кереп, анда сакланган матур кызларны күрде, алар белән яңадан чыгып, Каф тауларын үтте, адәм колагы ишетмәгән, күз күрмәгән кошларның канатында очып, патшага кайтырга чыкты... – шул арада үзенең йоклап киткәнен дә сизми калды.

Иртән тагы шул озын чыбыкның шыелдавына уянды. Башкалар торганнар, тәһарәт алып, мәчеткә дә киткәннәр, беразы уяна алмый ята икән, аксак шәкерт:

– Ни эшләп ятасыз, бинамазлар[1]! – дип кычкырды да буй-буй сыдыра башлады.

Сәхип ничек торганын белми дә калды. Мәптектә тагы кичәге тыгынлык, шау-шу һәм тапташ иде. Кемнең комганын алганнар, кемнең тәһарәткә дигән суын урлаганнар, кемнең башмагын киеп чыкканнар, кычкырышалар. Кызып китеп, Апрай Хәлкәйнең башына биреп ташлаган. Бусы, җылап, казыйга барды. Шунда ук тегене яткырып суктырдылар. Ләкин тавыш моңар карап басылмады. Монда Апрай аркасын ачып ята, тегендә тиргәш, кычкырыш дәвам итә, көче җитмәгәннәр җылашалар иде.

Сәхип ни эшләргә белми, каушап, аптырап торды да, шунда яткан агач табанлы, җүкә йөзле бер сыңар башмакны уң аягына эләктереп, башка малайлар артыннан дәңгезли-дәңгезли, якындагы елгага китте. Көн суык, башмак кар эченә батып-батып китә иде; ләкин бала аны сизмәде, елгага килеп, боз тишегеннән (бәкедән) ашык-пошык бит, күзен чылатты да тәһарәт алган төс белән мәптеккә[2] йөгерде.

Кайтып керсә, анда, аслы-өсле куелган өч мендәр өстендә, кулына озын чыбык тотып, чалма-чапаннан мулла абзый утыра.

Сәхип барып керүгә, мулла абзый аңа текәлеп карады да:

– Бу дамы? – диде.

Бала куркуыннан ни эшләргә белмәде, җылый да алмады, дер каушап, ишек янындаката калды.

Кемдер:

– Ул ятим бала... Кичә генә килде... Аның аягына кияргә юк, – дигәч, мулла абзый аны сукмады, янына чакырып алып сорашты да:

– Тырышып укы! Шаярма! – дип, бер тиен көмеш садака бирде.

Моның белән Сәхип йомшарып, бәхетләләнеп үк китте. Инде аңа дөнья башкарак иде, нидәндер күзләре яшьләнде; иртә намазыннан калган

---

[1] *Бинамаз* – намазсыз, намаз укымаучы.

[2] *Мәптек* – мәктәп.

малайларның, аркаларын ачып, идәндә тезелешеп ятулары, мулла абзый кулындагы озын чыбыкның шыелдавы аңа төштә кебек тоелалар иде.

Сәхипкә ишек төбеннән урын бирелде. Шул көннән алып ул мәптектә ятып укучы булып калды.

Авыл мәптәгендә биш кыш ятып, «Шәрхе-Габдулла»-га[66*] төшәрлек булгач, сабакка тырышлыгы, зирәклеге, үзен карарга һичкеме булмаганлыгы өчен, мулла абзасы аңар шәһәр мәдрәсәсенә китәргә фатиха бирде.

Анда ни белән яшәячәк, кем ашатачак, кем киендерәчәк? моны бер кем дә белми иде.

Озаткан вакыт мулла абзый аңа, үзенең дә шулай бер тиенсез чыгып китеп, зур мәдрәсәдә егерме ел укып кайтуын, данлыклы Шакир ахунда көтүче баласыннан шундый бөек дәрәҗәгә ашканын – аның да шулай һичбер караучысы булмаганын хикәя кылды; Алла ярдәм бирер, талибелгыйлемнәргә[1] шулай җир йөзенә таралырга пәйгамбәребез дога кылган дип сөйләп, аңа егерме тиен садака бирде:

– Сиңа бер арба гошер[2] куйдым. Игеннәр суккач, сатып, акчасын җибәрермен, бәхетеңнән җиде пот чыкса, ике тәңкә ярымнар чамасы булыр, – диде.

Соңгы көзнең яңгырлы бер көнендә, кичкә каршы, Сәхип авылыннан чыгып китте.

Бу вакыт аңа унөч яшь иде.

Бу – 1898 нче елда иде.

Шәһәр Сәхипнең котып алды. Ничә катлы, зур таш биналар аның өстенә җимерелер, шул шәп аргамаклар таптап изеп китәр, шул исәбе-хисабы юк, һәммәсе бер-беренә ошаш өйләр, урамнар арасында аның башы әйләнер, адашып үләр кебек иде. Элгәре Вафа хәзрәтнең мәчетен, аннан соң мәдрәсәсен эзләп, каңгырып беткәч, кемдер аңа:

– Менә шунда булыр! – дип күрсәткән капкадан керде.

Анда бер-берсенә якын салынган әллә ничә кызыл таш, ике агач бина, өем-өем киселмәгән бүрәнәләр ята, бер озын пычкы күренә иде. Кая барырга, кайсы ишеккә кагылырга тагын аптырады; ул арада якын мәчеттә мөәзиннең өйләгә азаны ишетелде, кайдадыр чиркәүме-ниме кактылар. Сәхип, курка-курка, аскы катка керә торган ишекләрдән беренә килде дә, баскыч белән түбән төшеп, ишекне ачты. Ул кая барып кергәнен белмәде: бер тирән базмы, мунчамы, башка бер нәрсәме? – һич белер хәл юк. Анда бик күп авыздан чыккан катыш гөрләү ишетелде; ләкин төтен һәм бу белән тулганга, кем,

---

[1] *Талибелгыйлем* – гыйлем эстәүче, укучы.
[2] *Гошер* – уңышның уннан бере күләмендә дини налог.

нәрсә барын күрергә имкян[1] юк иде. Ишек яңагына тотынып, бер-ике атлагач, күз өйрәнә төште: кергән җире ниндидер зур ук бер аскы өйгә ошашлы нәрсә икәне беленде. Анда ни нәрсәләр бар икәне дә аерыла башлады.

Ишектән керү белән, дивар[2] буйлап, кырыклап казан тезелеп киткән. Боларның аслары ягулы, өсләреннән бу чыгып тора, берничәсе ит куырганга ошаш чыжылдый – май, көек исе чыгара. Шул казаннарның янында һәммәсе, кулларын сызганып, зурлы-кечеле бик күп шәкертләр кайнаша: кем бәрәңге турый, кем токмач сала, кем ашының тозын карый, өресен түгә...

Сәхип үзенең ашханәгә килеп кергәнен аңлады. Инде күзләр дә өйрәнделәр: аңа ашханәнең зурлыгы, киңлеге, идәнендә яткан бәрәңге кабыкларына, баткагына, түгелгән суларына чаклы күренә башлады. Ике почмакта тактадан ясалган ике госелханә[3] бар. Аларда берничә егет нәүбәт көтә. Ике госелханәнең уртасында бик озын буй булып, чүгәләп, комганнар белән тәһарәт алып торган шәкертләр тезелгәннәр. Аларның артында тагын бик күпләре, муеннарына сөлге тагып, комган бушаганны көтәләр. Кемнәрдер: «Комганыңны кешегә бирмә, суы миңа да калсын», – ди; берсе, госелханә эчендә коенып ятучыларның ишеген кагып: «Әллә үлдеңме, тизрәк чык!» – дип кычкыра...

Ул арада булмый, казан янындагы тирләп-пешеп, кызарып беткән шәкертләрдән берсе ут чыккандай кабаланырга тотынды, әллә нинди ашыгыч тавыш белән:

– Куырдагым яна!.. Итем көя!.. Харап булдым, казаным шартлый, казаным шартлый!.. Су, су, су!.. – дип акырып җибәрде дә, янында су тапмагач, учагындагы кисәүләрне барын берьюлы тартып, идәнгә төшерде; алар гөрлиләр иде, аягы белән таптый башлады; кемдер су биргән икән – аны казанына салган уңайга, гөлт итеп, майдан ут күтәрелде, ләкин бу озак булмады, шунда ук сүнде.

Казан шартламады, ләкин ашханә май исе белән, төтен белән тулып, тамакны ачыта, җөткертә, күзне баягыдан яман кисеп ашый башлады. Кемнәрдер сүгенергә: «Адәм үтерәсез, кем ул?» – дип тиргәргә тотынды. Ишекне, тәрәзәне тутырып ачтылар, аннан салкын һава кереп тулды, берничә шәкерт күзләрен уа-уа чыгып киттеләр...

Шулардан берсе Сәхипне таптый язды, аның аягына басты, беләкләренә килеп тотынды да:

– Бу кем? – дип, кулыннан алган хәлдә, аны тышка өстерәде.

---

[1] *Имкян* – мөмкинлек.
[2] *Дивар* – стена.
[3] *Госелханә* – юыну бүлмәсе.

Бу, Сәхипнең бәхетенә каршы, аның якташларыннан бер шәкерт булып чыкты; кулында комганы бар иде, ашханәдән сукрана-сукрана, тышта тәһарәт алды да Сәхипне үзе белән бергә югары катка – үзе тора торган мәдрәсәгә алып керде. Ашханәдәге май исе белән ачы төтен мәдрәсәгә дә менгән иде. Мәдрәсәнең почмаклары юеш, тәрәзә төпләреннән су ага, кемдер коридорда, бик тузанлап, киез кага иде. Шәкертләр ябык, саргылт йөзлеләр иде, ләкин Сәхип боларның берсен дә күрмәде. Авыл мәптегенә караганда, монда һәммә эш хәйран шәп иде, һәммә эш үзенең олылыгы белән аны баса иде.

Мәдрәсәгә керү белән ул ишеккә якын мич буена тезләнеп утырды да шәкертләр өйләдән кайтканчы урыныннан кузгалмады; якташы үзләреннән калган ашны бирде; ул берсүзсез аны ашады да:

– Табак-савытыгызны төшеп юыйммы? – диде.

Якташ:

– Белсәң, ярар, – диде.

Яңарак «Шәрхе-Габдулла» башлап, әле тик экъсами сәбгага[67*] җиткән шәкертләр бар икән, икенче көн Сәхип, шуларга сабакка кушылып, мәдрәсә шәкерте булып китте.

## LIII
## КЫШКЫ ЧЕЛЛӘДӘ

Еллар үтте.

Кышкы челләнең күз ачкысыз ачы суык, куәтле буранлы көннәреннән берсе иде. Өйлә җитәр алдыннан гына Заһир хәлфә, чыгып, кичә вафат булган Насыйр байның җеназасын күтәреп зияратка барырга язылган утыз шәкертнең исемен игълан кылды. Арада Сәхип тә бар иде.

Ул күп ярлылык күрде. Мәдрәсәдә аның кебек ятимнәр байтак бар, ятим булмаганнарның да күбе өйләреннән алса ел буена биш-ун сум ала, тагы шул кадәр хосул[1] керә, алар шуның белән кыш чыгарга тиешле. Тамак – ашка, өст – киемгә туймый, шулай ачлы-туклы яшиләр.

Сәхипнең дөньяда һичкеме булмаганга, аңар бер тиен киләчәк җир юк, – булса, шул бәйрәм, хәтем, зиярат, аз-маз зәкят[2] хосуллары иде. Ул күп еллар шуның белән киченде. Бу тормыш аны, башка шәкертләр кебек үк суырган, тумыштан таза, киң күкрәкле һәм гайрәтле бала саргаеп кипкән егет хәленә әйләнергә якын иде. Үзе үсеп, дәрәҗә күтәрелә башлагач, аның урыны ишек төбеннән югарырак күчте. Җәй кәсеп итеп, бераз акча таба торган

---

[1] *Хосул* – керем, садака.
[2] *Зәкят* – керемнең кырыктан бере күләмендә салына торгаи налог.

булгач, бигрәк дәрәҗә зураю, мантыйкхан[1] булу сәбәпле керәчәк хосуллар да мулая башлаган иде.

«Гакаид»кә [68*] төшкәннән бирле ике бәхетле үлем булды. Һәр икесендә җеназа күтәрергә язылып барып, өчәр тәңкә алдылар. Насыйр бай мәхәлләнең иң зурларыннан; аңарда һәркем инде: өчтән дә ким булмас ди. Утыз язылган. Ләкин язылмаганнарның да һәммәсе бара. Шәкертләр генә түгел, аксак кизү дә: «Калмыйм!» – дип йөри. Башка вакыт бармаучылар була, көн суык чакта алардан кием алырга мөмкин иде, бүген кием табу мәсьәләсе бик үткенлеккә иреште. Авылның бер карчыгы Коръән чыккан өчен[69*] аңа бер ак киез итек җибәргән иде. Гөнаһшомлык, кичә әллә кайсылары аны ашханәгә киеп төшкәннәр дә, манма су ясап, пычракка ташлап менгәннәр. Ул кияргә яраклы түгел. Шәһәрдән читтә, бу мәдрәсәдән биш-алты чакрымлык җирдә булган зиратка шундый суык буранда чалыш ката, нәзек бишмәт, башка җылысы тимәгән чалма белән бару бу җиңел эш түгел, инде Ходай үзе ярдәм бирсен! Ләкин бармаска мөмкин түгел; бу әллә ничә елга бер туры килә торган бай җеназа – өч тәңкә уенмыни! Ачы буран шәкертләрнең үзәкләренә суга иде. Гөнаһшомлыкка каршы, күмү озак булды, хәзрәт Коръәнне акрын, озак укыды, күп шәкертләр, туңуларыннан сикереп торып, кайтырга йөгерә башлар хәлгә җиттеләр, ләкин түзделәр.

Сәхип җилгә каршы иде: аяклары, читеге, катасы, чолгавы бары бергә оешып туңды, арка үзәкләре катты, куллар тоймый иде; ләкин килгәч, күбенә түзгәч, тагы бер-ике минутка түзми хәл юк иде инде. Буранга яны беләнрәк борылды да, бармак очларына өрә-өрә, дерелдәвендә дәвам итте. Аңа күп өшергә туры килә, яшь вакытында кышкы көндә, яланаякка ката киеп, күрше кибеткә йөгереп чыгуда, мунчадан кайтуда ул еш-еш суык тидерә иде. Ләкин мәтрүшкәме, карлыган кагымы эчеп, тирләп, иртән сәламәт уяна иде.

Насыйр бай җеназасы карлыган кагы белән генә үтмәде, зираттан кайтып, чәй эчүгә бөгәрләнеп ятты һәм шул ятудан ул тик өч ай үткәч, иптәшләре табып биргән урынга – казакъка муллалыкка китү өчен генә торды.

Доктор китерделәр; ул мәдрәсәдә ятса, тагын начар булачагын, аны иркен җиргә куюу кирәген сөйләде, ләкин моңарга акча булмаганга, ул өч ай шул шау-шулы мәдрәсә почмагында ятарга мәҗбүр булды. Күпләр аның терелүенә дә шөбһә белән карый башлаганнар иде, ләкин казакъ сахрасы, иркен һава, куәтле кымыз аңа шул дәрәҗәдә килеште ки, күз кайтканда, ул танылмас мәртәбәдә тазарган, кызарып тулган иде.

[1] *Мантыйкхан* – мантыйк (философик логика) укучы.

Моназарәләр, озын төн моталәгаләр[1], мәдрәсәнең барлык торышы кыш буена аны яңадан суырды; ләкин ул һаман зыянсыз күренә иде. Каралыр вакыт керде; алар, җиде шәкерт, риязәт чигә[2] башладылар. Гөнаһшомлыкка, Сәхип өч ел каралды – һәр өч елның ике аен көненә ике бәрәңге, ике кипкән клиндер белән үткәрде. Казакъ кымызы аны яңадан төзәтте, шулай да Вафа хәзрәтне ташлап, Мәдрәсәи исламиягә килгән заман аның йөзе, күзе ниндидер эчке бер куәте, мае алынган төсле карый иде.

Шәкерттән теләсә кем генә докторга бармасын, ул уку ташларга, мәдрәсәдән чыгып, иркен һавада яшәргә куша. Ничектер бер сум акча арттыра алгач та, Сәхип тә докторга күренде. Аңа инде кискен рәвештә:

Сездә кан әсәре калмаган... Сездә тереклек бетә... диделәр.

Сәхип доктордан көлеп чыкты: аның ашарына юк, ул арыш икмәгенә акча тапмый, доктор аңа, бик гади эш төсле итен: «Һәр көн иртә-кич йомырка ашагыз, сөт, каймакны өзмәгез, кош ите, яшь тавык шурпасы файдалы булыр», – ди.

Сәхип, иптәшләренә моны сөйләп, күп вакытлар көлеп йөрде, ләкин алар бу көлүгә кушыла алмадылар. Татар шәкертләренең күбе ябык, саргылт, кансыз була. Әмма Сәхип шулар эчендә дә аерылып тора. Аның йөзендә ничектер тереклек төсе беткән кебек күренә; иреннәре, күзләре үзләренең селкенми, кузгалмый, ничектер катып калган, үле, кара саргылтлыклары белән гүр-кабер туфрагы кебек куркыталар. Егет үзе бу дәрәҗәгә җиткәнен сизенеп бетми бугай. Сизенсә дә, ни эшләсен: хәзер генә бөтен тормышын үзгәртеп, тиз генә сәламәтләнү чарасын күрергә аның кулыннан килми. Ул үзе, мәдрәсә ташлап, русча укымакчы, университетка студент булмакчы. Ләкин акча, ярдәм булмаганга, бу ашкыну тик аның күңелендә генә кала бара. Ул үз гомерендә, кыш укыр өчен җәй акча-кәсеп эзләп кайларда гына булмады: ул Сакмарда сал белән бүрәнә агызды, Мәкәрҗәдә, ярминкә вакытында,[70*] ашханәләрдә половойлык хезмәтен үтәде, Оренбург – Ташкент тимер юлын салганда ком өйде. Күп еллар Казакъстанга чыгып, җәй буе балалар укытты, шуннан кайткан утыз-кырык сум белән кыш укып чыкты. Инде менә хәзер тагы аның алдына шул кайгы килеп баса. Үзе инде молдәкәлек[3] кәсебеннән бик туйган иде. Ләкин башка эше-һөнәре булмаганга, яз җитү белән тагын Казакъстан сахрасына китүгә карар биреп куйды: анда ит ашар, кымыз эчәр, яхшы һавада яшәр – шулай итеп тазарыр. Алда русча укып китәр өчен азмы-күпме акча да табар.

---

[1] *Моталәга* – уку, өйрәнү.
[2] *Риязәт чигү* – ач тору.
[3] *Молдәкә* – казакъ балаларын укытучы.

Ул менә шул планнар белән йөргәндә, аны, яшерен язмалар басуда шикләнеп, кулга алдылар. Ләкин жандармерия аңарда үзенә кирәк әйберне табудан тиз өмит өзде. Охранкага ике тапкыр чакырып, җавапка тарттылар. Ул курыкмады, артык яшеренмәде дә:

– Мин, – диде, – уйламыйчарак эшләп җибәргәнмен. Бары да бик мактадылар: миңа укырга бир дә, укырга бир, дип, башымны катырдылар... Мин шуннан ул «Башкорт кызы»н басып, иптәшләргә бирергә уйладым... Башка түгел, коры бер җүләрлек, тилелек кенә инде... диде.

Салынкы кашлы жандар офицер үзенең эчке күңеле белән моның шулай икәнен сизенде дә артык бәйләнеп азапланмады. Егетне азат итәргә мөмкин дип карады.

## LIV
## ТАНГАТАРОВНЫ КУДЫЛАР

Ул чыгарылганда әдәби кичә мәсьәләсенең иң нык кызып барган чагы иде. Куылган гимназист Тангатаров бу эшнең ялкынлы организаторы[1] булып йөри. Аның үз исеменә, әлбәттә, рөхсәт бирмәгәннәр. Ул Фәхрине уйлап караган, аңа да булмагач, хәзер инде йә Габдрахманга, йә Разия исеменә алабыз дип очына. Туташ үзе дә бик дәртләнгән иде. Ләкин анакасы якын килмәде:

– Кызым дип тормам: туры үзем губернаторга менәрмен дә әйтермен. Николай Сергеевич, мин каршы, диярмен. Моңарчы үз гомеремдә ул минем сүземне кире кайтармады, монысын да кайтармас. Юк белән вакланып йөрмә! – дип кырт кисте.

Разия анасының каты, кире холкын да белә, губернатор аның сүзен тыңлавын да белә иде:

– Булмый, Тангатар, башканы карыйк! Мин болай сезгә булышырмын, – диде.

Рөхсәтне болай да яртылаш театраль булган Габдрахманга йөкләделәр. Ул җиң сызганып тотынды, әмма әдәби кичәнең башка һәммә ягын оештыруны Тангатаров үзенә алмакчы булды.

Ул гимназиядән куылганнан бирле бөтенләй урамда диярлек ялгыз калды. Чөнки моңарчы яклап килгән әбисе Мәрьямбикә аңа әйтте:

– Бар! Директордан гафу үтен! Алыр. Алмаса, мин үзем кирәк сүзне әйтермен. Кире кайтармас! – диде.

Ләкин егет якын бармады. Морза карчык, аяк тибеп, русча орышты:

– Барасыңмы? Гафу үтенәсеңме? – дип җилкенеп, өч тапкыр сорады.

---

[1] *Организаторы* – оештыручысы.

Тангатар өчесенә дә кисеп җавап бирде:

– Юк. Бармыйм. Гафу үтенмим! – диде.

Морза карчык кинәт кире борылды да китте. Үзенең асравына әйтте:

– Бу йолкышны куып чыгар. Яңадан минем йортыма аяк басмасын: ул минем сүземне тыңламады, – дип боерык бирде.

Тангатаров бөлгән морзалардан Гыйнаятьнең бердәнбер улы иде. Аның атасы үз гомерен земствода чиновник булып үткәрде. Бик эчә иде. Анасы больницаларда эшләде. Ләкин болар икесе бер төндә ис тиюдән һәлак булдылар. Яшь Тангатаров Әхтәм җиде яшьлек бала көенчә ятим калды. Башка кешесе юк иде. Мәрьямбикә карчык нәсел кардәш булган бу ятим баланы үз йортына алды да, ярым-йорты тәрбия биреп, гимназиягә кертте. Стипендия чыгартты. Башта малай яхшы барган иде. Гимназиядәге дәресләре дә бикәне канәгатьләндерә иде. Тик малайның битендәге куе сипкеле генә морза карчыкның эчен пошыра: «Безнең нәселдә юк, канда юк, бөтен морзаларда юк, кайдан килде бу мужик сипкеле! Бичарам, күгәрчен күкәе кебек чуар бит», – дип әрни иде. Шулай да яхшы бардылар. Тик менә революция кергәч, ул саташа башлады. Сабак дими, соңга калдым дими, бикәнең тыйганына да карамый, митингларга, демонстрацияләргә йөгерә. Яшерен әйберләр укый. Бер көн мендәр астыннан анархист Кропоткинның [70*] әсәрләре килеп чыкты. Бу нинди коточкыч тәрбиясезлек! Карчык аны чакырып шелтәләде. Әхтәм, башын аска иеп, шелтәне тыңлады да тагын үз юлына китте.

Егор атлы анархистны үзе барып эзләп тапты. Аны аттылар. Хәзер башканы эзләми. Татардан, рустан анархистлар оешмасы тудыру фикере дә юк. Ләкин шуларны укый, урыны чыкса, яшәсен Бакунин[71*], дип кычкырып куя. Ләкин аның бу анархизмы иптәшләреннән ничектер аермады. Ул, гимназиядән куылгач, әбисеннән дә сөрелгәч, ике урында җидешәр тәңкә хак белән репетиторлык тапты да үзбашына дөнья көтә башлады. Аның чәче тузган. Ул аны җүнләп тарамый. Сипкелле бите сабын күрми. Әле өзелеп төшмәгән гимназист форма чалбарының тезе тишелеп чыгып килә, җиңнәре төртеп торалар. Ләкин ул боларга карамый, ул, мин морзалыкны ташлыйм, мин халыклашам, дип хыяллана. Үзе һәркайда, туктаусыз татар морзаларының тарихи кара, пычрак, сатлык якларын сөйләп, өйрәнеп, шуңа материал җыеп йөри. Татарны да, башкортны да, казакъны да, Бохараны да Романовлар монархиясе[72*] кулы астына кертүдә, бер кергәч, басып, кол итүдә, бунт чыгарса, таптап изешүдә без морзаларның зур кара тарихи рольләре бар, дип әрнеп сүгенә. Аз гына эчеп алса, бу сүгенү, җылап, күз яшенә барып җитә. Ул крәстиән Шакир солдатны: «Мин синең алдыңда гаепле!» – дип, кочаклап үбә башлый. Менә миндә шул морзаның ләгънәтле

каннары бар, дип, үзен-үзе хурлый башлый. Әйтәләр: төнлә бервакыт кабактан исереп кайтып килә икән, шунда күпер өстендә теге начар сасы «алтын» түгүчеләр үтеп барганын күргән дә берсенең арбасына сикереп менгән, мичкәнең кучерына утырып, ат тотып барган кешене кочаклап үпкән, дип сөйлиләр.

Болай да ул бик яхшы, ихлас иптәш иде. Иң түбән, иң аз аңлы шәкертләр, приказчиклар арасында үз булып кайнады. Алар да моны бик яраттылар. Җырчы Сәхипнең «Башкорт кызы Гөлбикә»сен укып чыккач, Әхтәм Тангатаров аны кешеләр алдында:

– Син талант! Менә дигән талант! – дип, кызуланып кочаклап үпте.

Әдәби кичә турында эш күтәрелгәч, ул һаман әйтә йөрде:

– Их, Сәхип юк бит... Тизрәк чыкса иде. Безнең кичәдә беренче материал булыр иде... – дип көенде.

Сәхип чыккан икән дигәч, ашкынып аңа йөгерде:

– Син беренче укыйсың... Менә дигән кичә була! – дип шашты.

Җырчы бераз аптырап калды. Аның алай әдәби кичәләргә чыгып әсәр укырлык кыюлыгы юк иде. Бераз курыкты, бераз каушады:

– Начар чыкса, көлсәләр... хурлык бит... дөньяга ни йөзең белән күренәсең! – дип, котылырга чара эзләде.

Ләкин Тангатаровтан котылу мөмкин түгел иде:

– Курыкма! Сиңа өйрәнмәгәнгә генә шулай ул! Анда бер син түгел. Менә мин үз язганымны укыйм. Әнә Габдрахман «Татар бае» дигән көлке декламация сөйли. Күп анда. Әйдә, курыкма. Син беренче талант! – дип тарткалап, әдәби кичәнең материалларын карап үткәрү өчен ясалган җыелышка Сәхипне көчләп алып китте.

## LV
## ӘДӘБИ КИЧӘГӘ

Госман кызыллык өчен урыныннан чыгарылгач, аның урынына утырган Ногман учитель карамагындагы русча-татарча мәктәпнең залында җыелганнар икән. Болар яшеренеп-посып барып кергәндә, озынча дүрткел сыйныф бүлмәсенең кара парталары, стена буйлары төрлечә киенгән яшьләр, гимназистлар, приказчиклар, шәкертләр белән тулып, гөж килеп кайнап тора иде. Бер-берсен кочаклап, тыгыз җәмәгатьне ярып, биш-алты яшь гимназист, реалист идән буена йөриләр. Бүлмәнең яртысын каплаган кара парталарның бер читенә кысыла төшеп, ябык, саргылт йөзле, күбе җитү чәчле, кыска иске тужуркалы, һәммәсе бераз тартына төшеп, кыюсыз гына мәдрәсә яшьләре

утыралар. Аларның уң ягында үзенең шул алмашынмас озын кара платьесын[1] кигән Разия туташ урам тәрәзәгә сөялгән зур кара тактага нидер яза. Кыска калдырып киселгән кара чәчен селкә-селкә, ярым көлеп, алдындагы франт киемле, хуш исләнгән купшы приказчик Фәхри белән шундый ук аля франка киемле, реалист формада, аристократ кыяфәтле Акчулпановка нидер аңлатырга – исбат итәргә тырыша. Шуларга якын Габдрахман белән Җиһангир, Нәҗип Камал, Госман үзара нидер сөйләшеп торалар.

Урманов эчке бүлмәдән чыкты да туры менә шул төркем янына килде. Берәм-берәм исәнләшеп, Габдрахман белән сүз ялгап алды:

– Җә, эшләрең ничек? Матур көн итәсеңме?

Габдрахманның йөзе-күзе ачылып ук китте.

– Әйтмә, иптәш! Минем тормыш ал да гөл кебек. Бары да майланган кебек, хуҗа сүзендә торды: иллегә мендерде; фатирдан да бик уңдым...

– Яшь кәләшнең кәефе яхшымы? Нәфисә исәнме?

– Әйтмә генә: ал да гөл кебек, пар күгәрчен кебек гөрләшеп торабыз... Тик ул сиңа бик үпкәли. Элекке танышлар әллә кая булды? Давыт абый да безне ташлады, ди... Син нигә бер дә кереп чыкмыйсың?..

– Әйтә күрмә, туганкай. Үземә дә бик уңайсыз... Эш баштан ашкан, бер минут вакыт табар хәл юк... Ничек кенә булса да шул арада бер кереп чыгармын. Син Чехов урамында бит әле? Нәфисәгә сәлам әйт, гафу үтенә, диген...

Шулай сүз барганда, тагын ишек ачылды да, бусагада таза, калын, озын гәүдәсе, тыштан елмаючан каты, тулы йөзе белән Нигъмәт казый күренде. Өстендә камалы тун, башында яңа бүрек. Ул бусаганы аша атлау белән аның артында ук: «Ни генә күрәм инде монда», дигәндәй каушап, як-ягына аптырап каранып, курайчы Вәли килеп керде. Аның мондый чит, чобар җәмәгать эченә беренче катнашуы иде. Килеп керүгә башы шаулады, күз алды томаланып, каушый төште. Җәмәгать тә кинәт һәммәсе шул якка таба борылып карагандай булды. Аның ялтырап торган чем-кара куе чәче, бераз кысыла төшкән ялтыр кара күзләре, бераз кытайны хәтерләтә торган киң карасу йөзе, җәенкерәк борыны, ике якка чылгыйланып килгән кара мыегы күренү белән һәммә кешенең күзен тарттылар. Бөтен җәмәгать, чыннан сокланып, аңа карады. Разия, үзенең франт егетләрен онытып, Вәли башкортның йөзенә кадалып катты, эченнән: «Кара син, нинди матур да, оригинальный да!» – дип куйды.

Сыйныф бүлмәсендә сүз тавышы бетте. Бу хәл Вәли башкортны тагын уңайсызлатты, каушавын арттырды. Ул, бәлки, кире чыгып та сызган булыр

---

[1] *Платье* – күлмәк.

иде, ләкин, гөнаһшомлыкка каршы, бусагадан бер атлау белән, Нигъмәт казый аның култыгыннан алды да:

– Иптәшләр, менә сезгә Ашказар буеның беренче курайчыларыннан Вәли Батыршин иптәш! – дип, җәмәгать өстенә кычкырды.

Курайчы шәкерт өченче партаның бер читенә барып сыенды. Аның маңлаеннан эре бөртекле салкын тир чыкты.

Кирәк кеше килеп беткән иде. Тангатаров, уртагарак чыгып, мәҗлесне ачып җибәрде.

Ләкин эш беренче адымнан ук талаш белән башланды.

Габдрахманның «Татар бае» дигән көлкесе бар. Теле начар, ләкин кайбер сүзләре бик усал чәнчү булып чыкканнар.

Ул бер татар баеның корсагын төшендә тау чаклы булып шешенгәнен тасвир кыла. Шул вакыт байга приказчиклар киләләр дә: «Нихәл? Корсак шештемени?» – дип, чиртеп китәләр. Ул арада байның күз алдында ук аның яшь, чибәр хатыны бер матур егет белән үбешә башлый. Бай кычкыра, сугарга кизәнә. Ләкин кузгалырга корсак җибәрми. Ул һаман омтыла, газап чигә, корсак шешкәннән-шешә бара. Егет белән хатын үбешә-үбешә шунда бииләр. Бай яман ачу белән аларга ташланмак була, акырып җибәрә – шул минутта уянып китә.

Габдрахманның бу нәрсәсен яшьләр яратып, туктаусыз көлеп тыңладылар. Әдәби кичәдә шәп чыгар бу дип кычкырыштылар. Ләкин Нигъмәт казый каты протест белән күтәрелде.

– Булмас, мондый нәрсәне әдәби кичәгә кертә алмыйбыз без... Безнең дәүләтебез, хөкүмәтебез юк. Хәзинәбез юк. Милләтнең барлык мәдәни ихтыяҗлары тик байларның матди ярдәме белән генә үтәлеп бара: мәктәпме, мәдрәсәме, җәмгыяте хәйрияме[1], клубмы, гәзит-журналмы – һәммәсе-һәммәсе тик байларыбызның һиммәте[2] аркасында гына яшиләр. Моны күрмәү – сукырлык булачак. Әгәр күрә торып Габдрахман әсәрендәге кебек тәхкыйрьләргә[3] юл куйсак, бу зур тарихи ахмаклык булачак! – ди.

Нигъмәт сүзен бетерә алмый, аның соңгы айлардагы каты дошманы Җиһангир аякка калка. Бераз каушап башлый, ләкин тиз кыза, яман сүгенеп китә:

– Байларның һиммәте, юмартлыгы дисеңме? – ул дуңгыздан бер кыл гына! Башка түгел. Алар халыкның канын эчә. Баласы ач, үзе ялангач эшченең, крәстиәннең маңлай тире белән җыелган маллардан сарайлар

---

[1] *Җәмгыяте хәйрия* – ярдәм күрсәтү җәмгыяте.
[2] *Һиммәт* – тырышлык.
[3] *Тәхкыйрьләргә* – хурларга.

салалар да, адәм күзе буяр өчен, эшче тапкан миллионнардан бакыр бер тиеннәрне садака итәләр. Имеш, юмартлар. Мин әйтәм, садака алу хурлык. Байның ярдәме белән эшләү хурлык, дим. Аларның биргәннәре тик күз буявы – тик дуңгыздан бер кыл гына, дим...

Бу талаш байтакка барды. Ләкин Тангатаров белән Җиһангир җитәкчелеге астында барган яшьләр Нигъмәтне егып салдылар. Габдрахманның «Татар бае» әдәби кичәгә ярый табылды.

Аның артыннан Акчулпан үзенең русчадан тәрҗемә «Тоткын»[73*] дигән нәрсәсен укыды.

Монда егерме биш ел буенча Шлиссельбург крепостенда[74*] ябылып яткан, яшь егет чакта кереп, шунда чәчләре агарган карт тоткынның аһ-зары тасвир ителә. Ул да дөньядан сорый: «Кояш бардыр, табигать матурдыр, гөлләр, чәчәкләр эле дә шулай чибәрләрдер, сандугач эле дә шулай моңлы сайрыйдыр, ләкин әйтегез: адәм азат булдымы? Әллә һаман да авыр богаулар эчендә ыңгырашып яшиме?» – ди.

Монда бер куркыныч – цензор ягы булды. Әгәр үткәреп булса, әлбәттә, керсен, диештеләр.

Тангатаров моның артыннан Сәхипнең кулъязмасын тыңламакчы иде. Чөнки ул җырчының «Башкорт кызы Гөлбикә»сен бөтен кичәнең беренче әйбере булыр дип ышана. Шуңа күрә сабырсызлана иде. Ләкин Нигъмәт, тарткалашып:

– Вәли иптәшнең җырын, кураен тыңлыйк! – дип, шау-шу күтәрде.

Җырны, курайны сагынучылар күп иде. Тангатаров җиңелде. Башлап Вәли башкорт, Уралның моңлы күкрәк тавышы белән сыйныф бүлмәсен яңгыратып, «Ашказар», «Ирәмәл», «Тәфтиләү» көйләрен җырлады. Йөрәкләргә үтә төшеп, акылларны алып, Дим, Агыйдел буйларының кураен уйнады. Зал тынды. Тыңлаучылар каядыр югалдылар. Моңлы җыр артыннан башкорт җәйләвенә, Уралның биек тауларына, Агыйдел буйларына китеп онытылдылар.

Кинәт Госман уянды, үзен белер-белмәс:

– Тангатар, син «Ташчы»ны укымакчы идең түгелме? – дип сорады.

Ләкин егет Вәли башкорттан соң укырга чыга алмады:

– Юк. Менә бит Камил иптәш бар, – диде.

Яшь, ябык, ләкин чибәр йөзле шәкерт Камил күтәрелде. Кыска, кискен музыка белән яңа татар көйләрен яңгыратты. Моның да тавышы әйбәт, саф, музыкасы матур иде.

Шул җыр бетәр-бетмәс, Тангатаров үз янына җырчы Сәхипне чакырып алды. Нидер әйтте, димләде, партага урын ипләде дә янына утыртты, алдына кәгазьләрен юнәтеп салып куйды. Үзе җәмәгатькә карады:

– Иптәшләр, диде, – көтелмәгән бер әйбер бар: Сәхип хикәя язган. Мин берничә кат укыдым. Ул инде жандармнар кулына да эләгеп, тарихи-сәяси нәрсәгә әйләнде... – диде.

Төрле яктан:

– Укысын!.. Укысын!.. – дип шаулаша башладылар.

Агарынган гаепле йөз, аптыраулы караш белән Сәхип аякка басты. Калтыраган кул белән алдына, партага салынган кулъязма кәгазьләрен һич кирәкмәгәнгә актарынды да, бөтенләй ят, каушаулы тавыш белән гаепле елмаеп:

– Иптәшләр, – диде, – сезне башкорт җырлары артыннан Башкортстанның үзенә алып барсам, ничек булыр икән? Ялыксагыз, озын күренсә, туктатырсыз, мин теләмәгән идем, менә Әхтәм Тангатаров мине көчли, гаеп аңарда! – диде дә, алдындагы дәфтәрләргә бөгелеп, укый башлады.

## LVI
## БАШКОРТ КЫЗЫ ГӨЛБИКӘ

(Хикәя шул исемдә иде)

### 1

«Берәү сөйли, шәһәребездә, ди, татарча зур концерт бирмәкче булдылар, иске-яңа куәтләрнең күбе катнашырга вәгъдә кылды. Эшнең башында татарлашырга, үзенең сүзенчә әйтсәк, татар халкы эченә керергә тырышып йөри торган бер морза тора. Шул кемнәндер, «Ашказар», «Тәфтиләү» көйләрен безгә ялгыш җырлыйлар, имеш, боларның төп ияләре булган башкортларда бөтенләй башкача, имеш, дип ишеткән дә, нинди зур чыгым ясап булса да, шунда кеше җибәреп, «Ашказар»ларның дөресен алдырырга карар биргән.

Ул белгән җырчылар эчендә, күрәсең, иң шәбе мин булганмын. Бер көн өенә чакыртты да:

– Әфәнде, – ди, – вакытыгыз булса, ди, Ашказар буе башкортларына барып, милли көйләребезнең чынын өйрәнеп кайтыр идегез, – ди.

Үзем белән бергә башкорт шәкертләреннән берәр иптәш алуны муафыйк күрә, юллык егерме биш сум акча бирә.

«Ярый, – дим эчтән генә; әзер акча булгач, дим, кая да йөреп кайтырга мөмкин... Син әйткәнчә, ул көйләрнең чыны булса, отармын, ота алмасам, үземнең белгән озын көйләрем күп, шуларны боргалармын да менә сиңа милли «Ашказар»ның дөресе булып чыгар... Барыбер, дим, монда аларның асылларын белүче юк...»

Шулай итеп, мин Башкортстанга китәргә булдым.

Яныма, юаш дип, һәр такмагыма биер дип ышанган бер җырчы башкорт шәкерте алдым.

Һәйбәт язгы көннәрнең бере иде. Җыендык та вокзалга киттек. Юлдаш башкортым сөйләнә бара:

– Иптәш, – ди, – аксаны күп бетермәек... Һис булмаһа, яртыһы үзебезгә калһын, – ди.

– Ярый, – дим тыштан. Әмма эчтән икенчене уйлыйм.

Ләкин эш мин дигәнчә чыкмады. Мин акчаны үземнеке ясап, кирәк җиргә тотарга да, бетү-бетмәве турында иптәшемә исәп бирмәскә уйлаган идем. Начар заман бит, халыкның башында әллә нинди фикерләр йөри.

– Безнең, – ди, – эшләребез бертигез... Шулай булгач, хезмәткә каршы бирелгән малны да уртак бүләек, – ди.

Ни эшлисең, сүз көрәштереп үзеңне ваксытыр хәл юк, аның дигәненә каршы килмәдем.

Без вокзалга җиткәндә поезд кузгалырга якын иде; юлдашыма:

– Бар, син урын ала тор, мин билеткә йөгерим, – дидем.

Башкорт тилереп китте:

– Куй, куй! Ул ни эштәгәнең. Билет алмаек... Әйттем ги, аксаны янда калдыраек дип, – ди.

Мин дә күп вакыт арыш икмәгенә зар калган күп егетләрдән беремен. Биш-ун тәңкә кесәдә калса, минем дә эчне тишмәячәк.

– Ярый, – дим, – алмасак, алмыйк!

Поезд кузгалды. Сикереп мендек тә, кондукторны күреп, ярты хакны төртер өчен вагон ишеге төбендә җирләштек.

– Ваши билеты?.. – дип кычкырды берәү.

Кинәт әйләнсәм, ни күрим: ике кондуктор, бер күз карашы белән ашарга торгандай ачулы йөзле контроль безне ике яктан кысып алганнар. Иптәшем боларны күрүгә агарынды, теле бәйләнде; бер сүз дәшә алмый, ирексез артына таба чигенә бара, чигенә бара...

Теге куркыныч тавыш тагы кабатланды. Мин күземне өч зөбаниның әле берсенә, әле икенчесенә йөртсәм дә, һич берендә мәрхәмәт әсәре күренмәгәч, ялганларга тотынам:

– Без, – дим, – вокзалга килеп төшкәндә, поезд, дим, кузгалган иде. Билет алырга өлгерә алмадык, киләсе стансада, дим, алыр идек...

Контроль бик ачуланып безгә:

– Молчать! – дип кычкырды да янындагы ике кондукторга, безне саклап алып барып, киләсе стансада штраф түләтергә әмер бирде.

Без баскан җиребездә ката калдык.

Стансада безне сакчы белән жандармскийга кертеп, ике хакын

түләттеләр. Барачак җиребезгә чаклы билет алдырдылар.

– Менә мә! – дим. – Түләп, рәхәтләнеп барасы урында ике кабат тунадылар, өстәвенә яңадан билетләр дә алдырдылар.

Моңа минем эчем бик сызланды. Иптәшем акча күп чыгуга зарланыр дигән идем. Зарлану кайда!

– Әмма явыз нәмәләр икән! Котым осты... Ябып кыйнайлар икән инде дип торам, – ди. Үзе һаман бөтенләй котылуына ышанып җитә алмаган кебек, капкыннан ычкынган куяндай, як-ягына карана.

**2**

Икенде вакыты иде. Мөәзин манарадан азан әйтә.

Без, Мартый белән Таптыйдай җитәкләшеп, бер ягы зур урманлы, икенче ягы әллә каян-кая яшәреп яткан кебек болынлы елга буена утырган бер авылга барып кердек. Тугайда өер-өер җылкылар күренде. Берничә җирдә башкорт хатыннары бәйле колыннар янында бия савып йөриләр иде.

Иптәшем:

– Менә шул инде Таштамак дигәннәре, – диде.

Авыл кечкенә. Урамнар кәкре-бөкре. Йортлар тигезсез... Кайбер өйләрнең башы тимер белән ябыла башлап та, бер почмагы бетми калган. Инде ябылган җире дә череп килә. Кайбер биналарның түбә тимере яртылай буялган, калган ягы буяусызлыктан яңгыр белән күгәреп ята. Шулар белән янәшә үк бик күп өйләр түбә кыексыз, тәрәзәләре – карындык. Шул ук түбәсез өйләр янында яхшы аргамак муеныннан җеп белән ялгыз казыкка бәйләнгән. Аның артында яхшы көймә, зур яшел дуга тора. Минем аптыравыма каршы юлдашым:

– Ни булсын, башкортлар яңарак җир сатканнар, – диде.

Урамда көннең эссе, бөркү булуына карамыйча, бик яхшы камчат бүрекләр кигән башкортлар очрады.

Юлдашым һаман шул сүзне кабатлый бирде:

– Ни булсын, җир сатканнар!

Бик күп исерекләр дә күрдек. Бер башкорт малае пешкән бәрән ботының очыннан эләктергән дә артык симез бер этне шул ит белән шаярта. Аның өстендә кыйммәтле атлас камзул, ләкин ботлары ялангач, башы ачык... Шуңардан ерак түгел бик зур бер кисмәк янында, буй-буй ялтырап торган кыйммәтле бохара бикасабы[75*] киеп, бер хатын алачык янындагы зур казанда сары май кайната.

Иптәшем һаман:

– Җир сатканнар, – ди иде.

Көтү-көтү этләрне өрдереп, башкорт хатын-кызларының безне дәҗҗал күргәндәй бер ис китү белән, хәйранлык белән, әллә кая чаклы карап калган

күзләреннән котылып, авыл читендәге кечкенә бер өйгә барып туктадык.

Ике сажин ара ясап, урам буена ике казык кагылган.

Иптәшем:

– Менә бу капка булыр, – диде.

Читән, киртә дигәннең исеме дә юк. Капкадан керәбезмени, дип көлә-көлә, юри шул ике казык уртасыннан үттек. Бераз эчтә бер бина утыра: бу җирдәнме яки агач булып та, балчык белән сыланганмы – аерыр хәл юк.

Иптәшем:

– Менә бу өй инде, – диде.

Ул адәм буеннан бик аз гына биек, чолан-фәлән юк, ишеге туры киң сахрага карый. Ике ягында кечкенә ике тәрәзә сымак нәрсә бар. Кыйбла як, ахры, йомшара башлагандыр: берничә урында терәүле. Түбә, кыек башта ук ясалмаганмы яки, ясалса да, башкорт хатыны, май кайнатырга кирәк булган саен аны алып яга-яга бетергәнме, – анысын Алла белә – хәзер аның өстендә кеше биеклеге яшел алабуталар гөрләп утыралар.

Өй ялгыз; якын-тирәдә абзар, келәт кебек каралты юк. Һәр башкорт хатынына кирәк булган төтенле читән алачык та күренми. Тик өйнең кыйбла ягында, тәрәзә турында, бик яхшы тимер тарантас тора. Кертеп куярга урын булмаганга, тәгәрмәчләрне кояш какшатмасын дип, аның өстенә иске мунчала чыпта ябылган. Аның өстендә бер кыңгыраулы яхшы дуга, кыйммәтле чыбыркы ята...

Мин бераз аптырансам да, иптәшем үз йортында шикелле иде. Мал иясенә ошый, диләр. Ләкин башкортның эте һичбер вакыт үзе кебек ялкау булмый. Авылга кергәч үк шундый һөҗүм итә башладылар ки, мин, йа Ходай, өзгәләп ыргыталар, күрәсен, дип, котым очты. Бу йортның да күпме ит ашаганлыгы кабарып торган сыртыннан, җилкәләреннән ачык беленгән зур ала эте бар икән. Бәхеткә каршы, ул ераграк булды, күреп, һам-һам дип безгә сикергәнче ишектән кереп өлгердек.

Өйнең тәрәзәсе ачылмый – күтәрмәсе бозылган икән. Килеп кергән уңайга кап-кара төсле булды. Өйнең дүрттән бер өлешен зур мич алган. Аш пешергәннәрме, мичкә якканнармы – өйдә бик эссе, тын алу читен булыр дәрәҗәдә бөркү иде. Мич алды як такталар белән бүленгән. Бу якта, ишек төбендә, зур сандык, аның өстендә агартылмаганнан каралган, ләкин бик яңа өлкән самовар кырынаеп ята, аның янында яхшы чәйнек, чынаяк, берничә озын, һәйбәт пычак күренәләр. Түрдә өйнең дүрттән берен каплаган сәке ясалган. Анда берничә кара тышлы мендәр ауный, шулар янында кыйммәтле атластан, бөтен түше алтынга манылган тәңкәләр белән тулы хатыннар киеме тәпәрләнеп ята. Минем аптыравыма каршы, юлдашым һаман бер сүзне кабатлады:

– Җир сатканнар...

### 3

Хуҗалар өйдә икән. Безне бик ачык йөз белән:

– Ходай кунаклары... мөсафирлар... – дип, бик шат каршы алдылар.

Ач бүредән яман ачыккан идек – тамак туйдыра алудан өмит өзүемә каршы, әллә кайдан майлы күмәч тә, йомшак корт белән куе каймак та чыкты. Баягы сандык өстендә аунап яткан зур самовар да, тиз арада кайнап, гөж итеп безнең алдыбызга килеп утырды.

Сәкегә, юрганнар, мендәрләр өстенә тәмам җәелеп, аякларны бөкләп утырдык та башкортта гына табыла торган тәмле ашамлыкларны бөгә башладык.

Юлдашым үзенең башкортлыгы белән, җир сатып алган акчадан актык тиеннәре дә очканын сизенде булса кирәк, кунакчыл башкортның кәефен кырмаска, сүз башы урынында ниндидер бер әкият сөйләде дә үз кесәбездән кымызга җибәрде. Ул арада казаннан ит исе дә чыга башлады.

Тотындык итләп, кымызлап сыйларга һәм сыйланырга.

Хуҗабызның элекке хатыннарыннан Кәримә үлгән, Сафия белән Уразбикәне аерган, бу хатынына күптән түгел әйләнгән икән.

Үзе Җомагыл исемендә, карсак кына, ябык кына, сөйкемсез генә бер адәм. Кыяфәтендә башкортлык юк: ияккә таба очланып килгән тар йөз, су төсле күз, ул да эчкә баткан. Бите сары шадра, ияк очында бер-ике бөртек кенә сакалы селкенеп тора; өстендә камзул белән буй-буй ертылган керле күлмәк.

Әмма хатыны бөтенләй башка иде. Аның яшь, таза һәм төз гәүдәсе ничектер кан белән тулышып, биергә торгандай кузгалалар. Калку күкрәге, үзалдына көләргә, кочагына алырга торгандай дәртле күзләре тамырдагы канны ихтыярсыз кузгаталар. Ул миңа бик ошады. Шул дәрәҗәдә ки, ишектән керү белән күңелемне алып, мин аңа башка кайгыны бөтенләй оныттым.

Кымыз арасында сүздән сүз китеп, мич почмагына сөялгән хәлдә, бу хатын иреннән зарланып та өлгерде. Җир саткач, мең сум акча тигән икән. Шуңа, кулга кермәс борын, бурычка батып, ун тәңкәлек киемгә татар сатучысына илле сумлык вексель, утыз тәңкәлеккә – йөз, йөзлекә - өч йөз сумлык вексель биреп әрәм итүен, акча чыккач, калага барган җирендә авылның ун башкорты кайтмый атна буена эчеп ятуларын, акча алдыртуын, кулларына ике йөз дә кермәвен, аны да эчеп бетерүен, өй дә салдыра алмауларын, сөрдергән җирләрен дә чәчтерә алмый калуларын, инде шул меңнән тик бер арба белән шул атлас бишмәте генә калуын сөйләп чыкты.

Ләкин Җомагыл хатынының зарларына каршы:

– Эшең түгел, ырылдама! – дип кенә куйды.

Без, башкортның сатылган киң яланнарыннан, анда килмешәк хохоллар[1] салган зур сарайларыннан, савым бияләренең азаюыннан, борынгы куәтле кымызларның бетүләреннән килә-килә, сүзне милли көйләр мәсьәләсенә якынлаштыра башладык. Ләкин һаман да турыдан-туры: «Без көй отарга килгән идек», – дияргә мөмкин түгел иде. Болай кинәт кагылсак, башкорт агай табагачын алыр да: «Сез әллә ниткән нәмәләр икәнсез», – дип, куып чыгарыр. Юлдашым моңа бик нык ышана.

Шунлыктан мәсьәләгәерактанрак урап килергә мәҗбүр булдык. Башта үзебезне сәүдәгәр сымаграк, соңра шәкертрәк, хәлфәрәк ясап, без мәдрәсәдә чакта, атна кичләрдә җыелышып җырлаулар була иде, анда курайчы Вәли дигән шәп җырчы башкорт шәкерте бар иде дип, төп теләккә китереп терәдек.

– Җырчы дигәнең бездә инде ул, – диде хуҗабыз. – Бездә бер агай бар, шул, ди, өч тапкыр Питербурга барып, патша хәзрәтләренә җырлап кайтты. Әллә ничә медале бар. Азаккы баруында: «Монда кал, үзеңне акчага күмәрбез», – дигәннәр икән, тыңламаган, башкортымны, сахрамны, кымызымны сагынам дип, кайтып килгән.

– Соң ничек, Питербур шәп диме?

– Харап, ди, инде!.. Ул йортлары, ул өйләре, һарайлар, ди, мин һиңа әйтһәм, шундый бөек, ди, түбәһенә караһаң, башыңдагы бүрекләрең төшәр, ди.

– Патшаның үзен күргәнме?

– Күрмәгән кая!.. Күргән, әллә нисә рәт күргән... Патша хәзрәтенең туры үзенә алып баралар, ди... Патшаның һарае, ди, үзе бер кала саклы бар, ди. Идәннәре, ди, күзге кебек шома, ялтырап тора, ди, таеп егылып, башымны яра яздым, ди. Патша хәзрәтләренең хатынын да күргән... Адәм әйтеп бетерә алмастай уңган икән, ди... Мин, ди, китәргә булган көндә үземне һарайга чәйгә алдырттылар... Ул аш-һу, ди, ул канфитлар, ди, аша да үл – ун башкортны кушсаң да, ашап бетерә алмаслар, ди... Патшаның хатыны, ди, «җитеш, кунак!» дип, өлтерәп тора, ди...

– Ул Питербурга барган җырчы кайда?.. Аны монда китереп булмасмы?..

– Булыр иде дә, ул әле авылда юк... Мөфтинең бикәләре курай уйнарга чакыртып алганнар иде, әле шуннан кайтмаган, – ди.

– Авылыгызда башка җырчыгыз юкмыни?

– Ниткәнең? Булмаган кайда! Кирәк булһа, унны табарга мужны! – дип,

---

[1] *Хохоллар* – украиннар.

безгә карады.

Башкортыбыз, җиңеләеп, мәсьәләне очлап ук куйды, күршесендә генә тирә-якның атаклы җырчы, курайчыларыннан санала торган Хуҗабай бар икән. Ике минут үтмәде, ишеккә буе белән сыя алмыйча, бөгелә-сыгыла җырчыбыз килеп тә керде. Кулында курае да бар.

Исеме чын асабача[1] булган, кырык яшьләр чамалы бу адәм бөтен кыяфәте белән дә чын башкорт иде. Майланып, елтырап торган киң кара йөзе, кош йомыркасыдай зур кара уенчак күзе, бер дә пәке тиерелмәгән зур чылгыйлы кара мыегы, өстендәге киеменең сәләмә булуына карамыйча, башындагы чын камчат бүреге белән билендәге көмеш кәмәре – моның рус гаскәренең алгы сафында Парижга барып кайткан мәшһүр тарихи каһарманнарның калдыгы икәнен ачык күрсәтәләр иде.

Ул, килеп керүгә, безне үзе белән баладан ук бергә уйнап үскән адәмнәрдәй күреп, көлә, шаяра башлады. Ахры, тирә-яктагы мишәрләр белән кабилә талашы барадыр. Утырып, хәл сөйләштерүгә, шул мәсьәләне телгә алды:

– Менә, – ди, – бездә дә мишәрләр бар. Үзләренә дә әйтәм, һез кунак һыйлый белмәйһез дип, ди. Кунакка барһаң, дим, ситләрен мунсала белән байлап куйган зур бәлеш китереп утырталар... Аның эсендә пешмәгән тары ярмаһы белән тозлы суга башка берни булмай. Менә мин, ди, аларга әйтәм, һезне, дим, бер сакырып, башкортның һары майда эркелдәп пешкән бәлешен ашатаем әле... Телегезне йотып, аннан һуң башкортның кем икәнен таныրһыз, дим... Шулай итһәм, ярый бит, муллалар...

Мин сөйләргә сүз тапмадым. Иптәшем аның белән бик килешеп китте. Алар мишәрне, татарны яманлауда икесе бөтенләй бер авызлар иде.

Каймаклы чәй уңаена без аны, читләп-читләп, җырлар тирәсенә тарта башладык. Дөресме, ялганмы, – йөгенә керер хәлем юк, – әмма бу ирнең үзенең җырчылыгы хакында сөйләгәннәре бер авылдагы башкорт өчен аз түгел иде.

Оренбургта, бер җирдә туры килеп, аның җырына Әхмәт бай[76*] хәйран булган. Каргалы байларыннан кемнәрдер аны туйларына атап чакыртканнар... Троицкида кымыз мәҗлесләрендә ничаклы акчалар җыйган, Сембер фабрикантлары, алдырып, нинди зур хөрмәтләр күрсәткәннәр... Мөфтинең Өршәк буендагы утары үз кулында чакта, аның бикәләре, кызлары алдырып, күпме вакытлар курай уйнатканнар, ничә рус байлары тройка белән җибәреп алдырганнар. Белмәм, тагыниләр, тагы ниләр!

Күп сүздән соң, бер уңай табып, аның җырлавын үтенгән идем. Ахры,

---

[1] *Асаба* – җирле*; асабача* – җирлечә (милли).

җайсызрак кагылдым:

– Юк, – ди, – безнең кебек кешегә алай тиктән-тик җырлап утырып булмый ул, – ди.

Без бу сүзнең мәгънәсен аңлый алмадык, – ярый, хуҗабыз ярдәмгә җитеште:

– Тиктән-тик җырланмый инде... Тамак бераз йомшаргач әллә булыр да иде,-ди.

«Башта ук шуны әйтәләр аны, хәерсез», – дим эчтән генә.

– Мә, дим, – Җомагыл агай, безгә кәрзинкә пиво китер, – дим.

Җомагылның кабак астына яшерелгән су күзләре ялтырый башлады. Минем кесәдән акча чыкканны сабырсызлык белән көтеп, карчыгадай эләктерде дә йөгерә-йөгерә чыгып ук китте. Биш минут эчендә читәне белән бөтен кәрзинне өстерәп кайтты. Самовар, чәй, бушаган кымыз уҗаулары[1] алынып, алар урынына ачылган пиво бутылкалары белән стаканнар килде. Аякларны суза төшеп, төрлебез сәкенең төрле ягына кырынайдык та тотындык эчәргә, тотындык эчәргә! Стаканнар туктаусыз шыкылдыйлар, бутылкалар[2] кәрзиннән сәкегә менә, тиз арада бушап, мич астына тәгәри торалар.

Бераз эчкәч, җырчы Хуҗабайның тигезлек тойгысы уянды булса кирәк:

– Болай, – ди, – үзебез генә эчеп утыру килешмәй... Бичәләргә бал алдыргай идең, – ди.

– Күптән әйтәләр аны, – дим.

...Акча бирдем, каяндыр ике чирек әчегән бал да килеп чыкты. Пивога түккән акча әрәм китмәде, өй җанланды, җырчыбыз, үзе сизмичә үк, сахра угылларында гына була ала торган киң күкрәк авазы белән озын башкорт моңын сызып та җибәрде:

Сары да гынай җылан, ай, туз башлы,
Сызгырадыр камыш буенча...
Кара да гына кашлар, газиз башлар...
Йөри икән язмыш буенча.
Исем китә үземнең, ай, азуыма,
Һич чара юк Хакның язуына!..

Мәҗлес шулай дәвам итә. Халык кызганнан-кыза бара. Ләкин мин мөмкин кадәр исермәскә тырышам. Бераздан хуҗа хатын Гөлбикә каядыр барып килде. Азрак торгач, аның артыннан кап-кара йөзле, ямьсез генә, җылгыр гына кыяфәтле, керле күлмәкле бер кыз керде. Буйга җитү, дәртле,

---

[1] *Уҗау* – тустаган.
[2] *Бутылка* – шешә.

кыю күренә. Ләкин минем күңелемне бер дә тартмады. Бу – җырчы Хуҗабайның туган кызы икән. Гөлбикә аны, ахры, чакырып китергәндер. Кыз, ишек төбендә торып, нидер сорады, нидер эзләгәндәй булды. Шул вакыт хуҗа хатын кулындагы стаканына бал тутырды да кызга бирде:

– Мә әле, Уразбикә, татып кара: балы бик әйбәт күренә, – ди.

Уразбикә, мич почмагына сөялеп, бер тында стаканны каплады да ишеккә таба барды. Тагы нидер сорады, эзләнде дә, шулай әрле-бирле йөренгәли торгач, сиздермәстән, утырып ук калды. Хуҗабай җырлый, бутылкалар кәрзиннән сәкегә, аннан мич астына йөрүдә дәвам итәләр, халык кызганнан-кыза бара. Минем юлдашым белән Җомагыл инде бөтенләй исереп киләләр.

Ни сөйләгәннәре дә җүнләп аңлашылмый, үзләре һаман нидер лыгырдыйлар. Ләкин җырчы ныклы ир икән, тик кәефләнә генә бара. Кыз белән Гөлбикәнең дә балдан күзләре ялтырый башлый.

Бара торгач, Хуҗабайның җырына алар да катнаштылар.

Мин җырда, көй бабында җәяүле түгелмен. Русның театрында, концертларында, операларында булганым бар. Исерекменме яки чыны шулаймы, ни дә булса бар, аңарчы ишеткән һәммә нәрсә югалды, юк булды, Гөлбикә тавышы белән барлык җырчылар аяк астына төшеп тапталды; мин аның авызына карадым да каттым:

– Бу хатынга бирелгән моң белән музыка дөньяда тагы кемгә дә булса насыйбмы? – дип, хәйран булдым.

Гөлбикә мондый вакыт тәне, дәрте белән яраттыра торган хатын иде. Бер-ике көй сызу белән мин аңарда бөтенләй икенче адәм күрдем. Бу вакыт аның авазы ниндидер тирән бер трагедия белән аглый, йөзенә, күз карашына гаҗәеп бер матурлык балкый, ниндидер эчке яктылык белән яктыра иде.

**4**

Юлдашым белән хуҗа, бер якка авып, гырылдый башладылар. Без җыр белән эчүне дәвам иттердек. Кәрзинкә бушарга якын. Мин инде шуның белән фатиха бирү – яңадан алдырмау ниятендә идем. Гөнаһшомлыкка каршы, юлдашым уянды да, кызарган күзләре белән бер миңа, бер бушаган шешәләргә карап, исерек тавышы белән: «Без йоклаганда пивоны бетергәнсез», – дип, дау куптарды. Аның тавышына хуҗа да уянды.

Ул күзләрен җүнләп әчә[1] алмый, гәүдәсе авып-авып китә, шунда да сүзендә:

– Һе... тинтәкләр!.. бу нимә? Бу эсүмени?.. Әйдә тагы сыра... пива, – ди.

Бирмәскә мөмкин түгел инде; гөнаһшомлыкка, вагы да юк, бар, кадал,

[1] *Әчә* – ача.

дип, актык алтынны тоттырдым да җибәрдем. Җомагылым бөтенләй айнып ук китте:

– Мин, – ди, – кеше малына тия торган имәсмен... Миңа, ди, һинең бер тиенең дә кирәкмәй... Ун шишә сыра алам да, калганы үзеңә кайта, – ди.

Ул бая берничә минут эчендә кайтып җиткән иде. Әле исә, ничектер, бик озаклады. Ярты сәгатькә якын вакыт үтте. Җомагыл һаман юк. Бер сәгать тә үтте, һаман юк, көтәбез – юк, көтәбез – юк.

Ирендерә, иснәтә башлады. Җылгыр кара кыз: «Карап керим әле», – дип, әкрен генә шылды. «Кайткач, чакыртырсыз», – дип, җырчыбыз Хуҗабай да тайды.

Мин бераз хафалана башладым. Ләкин безнең белән берүзе калган Гөлбикә мине чыннан да гаҗәпләндерде. Ире чыгып югалды, шуның белән, гүя, аның өстеннән авыр йөк төште: ул аны авызга да алмый, кайда китте, тизрәк кайтса ярар иде, дими, калган балны ялгызы эчеп, ниндидер бер мөлаем, йомшак моң белән акрын гына көйләвендә дәвам итә. Без аның белән берничә мәртәбә бик мәгънәле карашып алдык. Ул миңа дәрт бирәчәк рәвештә елмайды. Егет йөрәге сизмәсенме, егетнең гакылы күңел дәртенә булышмасынмы? Мин бөтенләй чын төс белән иптәшемне:

– Үз бәләң, үзең җибәрдең, бар, хуҗаны эзләп кайт! – дип, чыгарып җибәрдем.

Беләм, ул исерек һичнәрсә булдыра алмаячак. Эш анда түгел – ул чыксын да, без Гөлбикә белән икәү генә аулакта калыйк.

Юлдашым абына-сөртенә чыгып китүгә, Гөлбикә белән сүз башлап, Җомагылның кайтмавыннан зарландым. Соңра сүзне Гөлбикәнең үзенә китереп, аның тавышын мактадым, мондый матур, музыкалы тавышны һичкайда ишеткәнем юк иде, дидем. Ул җылы сүз, мәгънәле елмаю белән җавап бирде.

Ниләр булып үткәндер, ачык хәтерләмим, тик шул ядымда[1]: юлдашым кайтып, исерек кулы белән ишек тоткасын таба алмый азапланган вакыт яшь, матур Гөлбикә, башын минем күкрәгемә куеп, күз яшьле тавыш белән нидер сөйли иде.

Исерекнең ишек янында капшануын ишетүгә сикереп торды. Күз яшен сөртте дә бөтенләй икенче хатын кыяфәте белән барып ишек ачты.

Юлдашым Җомагылны эзләмәгән-нитмәгән, кесәсендә егерме тиен акча бар икән, шуны бетергән, аның өстенә билендәге каешып салып эчкән дә кайтып килгән. Аягына баса алмый, авызы чабата кебек җәелгән.

– Мммин... мммин... тегене... ттаптым... ттаптым... таптым... ул...

---

[1] *Ядымда* – исемдә, хәтеремдә.

кайта... хәзер кайта... – дип мыгырдый. Нидер сизенергә итә бугай; ансыз да колакларына җиткән авызын тагы җәя төшеп, миннән көләргә, күз кысып, бармак янарга көчләнә... Ләкин изелүе чигенә җиткән иде инде. Җылы өйгә керү белән тагы йомшарып, шулай бераз мыгырдады да, идәндәге киезгә йөзтүбән капланып, хор... хор... йокыга китте.

«Күптән шулай кирәк иде сиңа, кадерле иптәш», – дидем эчтән генә.

**5**

Мондый авылларда манарада ястүгә азан әйтелеп бетү белән хәрәкәт туктый. Тиздән безнең өй дә тынды, ишек бикләнде, ут сүнде, юлдашым үлек кебек йоклый. Җан иясе – тик Гөлбикә дә мин генә калдык.

Минем гомерем бер-бер артлы тезелгән мәхрүмлекләр белән тулы. Мин – дөньяда кулындагы таягы белән аркасындагы капчыгыннан башка һичнәрсәсе булмаган юлчымын. Юлым караңгы, ярдәмчем юк. Күпләр балалык вакытын сагыналар. Ләкин мин сабый көннәремне уйласам, анда ачлык белән хурлыктан, түбәнсетелүдән башка һични күрмим.

Ана белмәдем, ана бәхетеннән мәхрүм яшәдем. Миңа күңелдән иркә бер сүз әйтүче булмады – гомерем шулай бер-бер артлы тезелгән мәхрүмлекләр, караңгы хурлыклар белән үтеп бара иде. Киләчәге дә үтәр, мин гүргә керер, – ихтимал, шул авыр моңым, караңгы ялгызлыгым белән үлемгә барыр идем; ләкин язмыш мондый рәхимсезлегеннән үзе оялды булырга тиеш. Нииндидер бер морза мине монда җибәрде, нииндидер бер көтелмәгән эш мине бу өйгә туры китерде, – мин дә бүген кич авыр, караңгы гомернең яңа ачылган нурлы, бәхетле минутлары каршында булдым.

Мин дә шул көтелмәгән эш аркасында бүгенге кичемне бер күргән, бер күрү белән сөйгән Гөлбикәмнең кочагында үткәрдем.

Рәхәт минутлар тиз кичәләр. Менә яңа гына ишекләр бикләнгән, яңа гына утлар сүндерелгән иде әле – ни арада төн үтеп тә киткән. Әнә тау артыннан таң сызылды, әнә якындагы әрәмәлекләрдә сандугач үзенең гыйшкын сайрый башлады. Сайра, былбыл, моңлан, былбыл! – музыкаңда сөю дәрте ишетәм. Син сөясеңдер, таң матурлыгы йөрәгеңдәге гыйшкыңны уятадыр, мин моны хис итәм, чөнки үзем дә сөям, чөнки үзем дә йөрәгемнең төбеннән яшьлек дәрте кузгалуын, шуның куәте белән дөнья йөзе матур елмаю белән мине каршылаганын хис итәм.

Сандугач, ахры, ерагайды: инде акрын ишетелә; таң нуры да күкнең көнчыгыш ягын алып бетеп килә. Әнә манарадан мөәзиннең иртә намазына азаны да ишетелә башлады. Ләкин Гөлбикә кузгалырга теләми әле. Аның эссе күз яше белән чыланган яңаклары минем йөземә тиеп торганын сизгәнем хәлдә бик ягымлы, ләкин эчке кайгылы тавышы белән дәвам иткән сүзен тыңлый идем:

– Ул, – ди, – һәр касан шулай йөри. Кулына ни керһә, шуны һатып эсә дә, минем киемнәремне һата башлый... Бирмәсәм, кыйнай. Һинең аксаңны алып китәсен күңелем сизгәйне... Бер төн булһа да жаным тыныч кунһын дип, юри әйтмәнем, – ди.

Төн буенча дәвам иткән бу зарларыннан мин Гөлбикәнең бөтен гомере белән танышып життем. Аның күп жылкылы бай башкортның кызы булуы, авылларындагы бер хәлфәне сөюе, ләкин аталары: ул татар дип, аңа бирмәүләре, көчләп, жылатып, Карман бай дигән берәүгә яшь хатынлыкка сатулары, андагы көндәшлек тормышы, иренең эчеп кайтып кыйнавы, ахырдан аның урыстан эчеп кайткан вакыт аты-арбасы белән тирән чокырга төшеп үлүе, аннан соң менә шул Җомагылга бирүләре, аның бар малын, йортын эчен бетерүе, сугышуы, аны бер дә яратмавы – һәммәсе күз яшьле кызганыч сурәтләр белән минем үз алдымнан кичтеләр.

Ул сыер саварга чыкты. Мин үз урыныма барып яттым. Бу вакыт кояш күтәрелеп килә иде инде.

**6**

Иртә сәгать уннар чамасында уяндык. Без торганда Гөлбикәнең самовары кайнаган, коймагы пешкән, комганына жылы су салынган, каяндыр исле сабын белән ап-ак сөлге дә табып чыгарылган иде.

Күтәрелү белән аңа карадым.

Аһ, яшь йөрәк!..

Аның йөзендә яңа бер нур уйный, күзләре үткән кичнең шатлыгы белән ялтырый иде. Ялкау гына, аның белән күңелле көлкеләр сөйләшә-сөйләшә юындык та чәйгә утырдык. Ул мөлаем көлә, жиңел шатлана, ләкин боларның астында ниндидер бер житди куәт хис кылына иде.

Аның чәе шундый шәп хәзерләнгән иде ки, минем юлдашым капкан саен:

– Мондый сыйларны дүрт ел мәдрәсәдә ятып кайткач, сагынып көткән әниләреңдә генә күрергә мөмкин, – дип кабатлый иде.

Чәй арасында Гөлбикә куе каймакны минем алдыма таба этәрә дә:

– Ашагыз, куәт кертә ул, – ди. Үзе акрын елмая. Чәйдән соң, казан асып, ит салды. Безне аш белән сыйламакчы. Ләкин бу насыйб түгел икән.

Гөлбикә самоварын, ашъяулыгын алып бетеп кенә тора иде, ава-түнә ире Җомагыл кайтып керде.

Өстенә карар хәл юк: йөзе пычрак, күлмәгенең бер жиңе бөтенләй өзелеп төшкән, күзләре канлы, бүреге белән казакие да юк. Мин сораштыра башлаган идем, жавап бирергә дә теләми, әйтерсең, берни булмаган, әйтерсең, ул безнең актык алтынны алып китмәгән.

Ахырдан беленде: ул кичә капканы чыгу белән кемнәргәдер очраган да,

бергә-бергә шунда акчаны тәгәлләгәннәр. Ул гына җитмәгәч, бүреге белән казакие да шунда йотылган.

Җомагыл үткән төн хакында нидер шикләнә бугай. Атап әйтмәсә дә, үз алдына сукрана башлады. «Акча бир», – дип, хатынына бәйләнде. Бусы: «Юк, булмаганны кайдан алып бирим», – ди.

Зур савыт белән әче әйрән сыеклатып эчте. Ахрысы, шул бераз хәл кертте булса кирәк: моңарчы сабыр гына торган Җомагылым кабахәтләп сүгенергә, хатынына аяк тибен кычкырырга тотынды. Без бераз уңайсызрак хәлдә калдык. Яклашсаң, шөбһәне арттырасың, тик торырга җан түзми. Ләкин ир мәсьәләне тиз өзде: мин ни булганын аңлап та бетә алмадым, Җомагыл, йөгереп барып, Гөлбикәнең биленә төшеп торган зур кара чәч толымнары очына тагылган яхшы чулпыларын өзеп алды. Шул секунд аны, этәргәләп кертеп, мич алды як аш бүлмәсенә ябып, өстеннән йозак салды, каядыр кабалангандай, ачкычын кесәсенә тыкты да, җил кебек очып, урамга таба йөгерде. Шуның белән вәссәлам – чулпылар да китте, Җомагыл да!

Без шаша калдык. Йа Ходай, хатыным янында егетләр кунган дип, авыл картларын чакырырга китте, күрәсең, дибез.

– Юк, – ди Гөлбикә, – аның, ди, картлар белән эше юк, минем сулпыларымны һатып эсәр дә мине кыйнарга тагы кайтыр, – ди. Үзе көлә: – Атын урлаткач капкасын бикләгән адәм шул булды инде, – ди.

**7**

Без китәргә җыендык. Гөлбикә шул өстеннән йозак белән бикләнгән бүлмәсенең ишеге ярыгыннан күз яшьле тавышы белән миңа ни өчендер рәхмәт укыды, бу авылга килсәң, безгә керми китмә, хәлдә барынча кунак итәрбез, диде.

– Баш өсте, баш өсте!.. Мин сине мәңгегә онытмам, – дидем.

Такта ярыгыннан исәнләшеп, кунак кылуы өчен күп изге теләкләр теләдек тә чыктык. Менә инде дөнья хәсрәтенең зурысы: кесәләрдә бер тиен акча юк. Ни белән кайтып җитәргә?

Җан биргәнгә җүн бирә, диләр. Минем башка бик шәп фикер төште. Монда без торган шәһәрнең бер мәхдүме кымызда ята. Үзе бераз таныш та егет. Юлдашымны көчләгәндәй кылып, шуңа җибәрдем:

– Бар, – дим, – Самардан кайтып килә идек, төндә акчабызны да, поезд билетебезне дә алдырдык. Безгә кайтырлык акча бир, тиздән җибәрербез диң, – дим.

Юлдашым, гел мине җигәсең, дип сукранды, бераз җилкәсен кашыды, шулай булса да, карышмады, мәхдүмгә китте. Менә, егетләр, дөньяда һичбер кайгырырга ярамый. Әбиләр: илдә чыпчык үлми, дигәннәр. Чыннан үлми: мәхдүм безгә дүртенче класс белән шәһәребезгә кайтып егылырлык акча

биргән.

Эшләр пеште, безне генә көткән поезд да бар икән, утырдык та бояр булып юнәлдек.

**8**

Сәфәрнең бөтен җавабы минем өстә, юлдашка җил дә, яңгыр да булмаячак. Ул көй отарга килүебезне бөтенләй онытты, ахры. Аны телгә дә алмый. Ләкин мин хафалана башладым. Вагонга кереп утыру белән мине яңа кайгы басты: «Ничек, – дим, – берәр нәрсә ота алганбызмы, юкмы?»

Нидер бар кебек, ләкин ачык түгел, томанлы, бик мәшәкать белән чыга. Җитмәсә тагы, үземнең борыннан белгән озын көйләрем дә теге башкортныкы белән буталып беткән. Башта нык борчылган идем, ләкин тиз юандым да. Ник юкка кайгырырга, дим, үзебезнең, дим, озын моңнарыбыз бар, шулардан оештыргалап, елга буе берәр көй төзәрбез дә – менә сиңа милли көйләребезнең асыллары булыр, дим.

Шәһәр вокзалында бер иптәш очрады, аңарда акча бар икән. Башкорт юлдашымның башы бик авырый иде. Кәеф төзәтергә дип, егерме дүрт тиен алды да, бакчалы бер пивнойга кердек. Ул эчә, мин җыр оту хәзинәмне актарам. Кая, синдә ни бар, дисәм, ул кул гына селкә – һичбер нәрсә хәтерләмим, миңа бары да төш кенә, ди. Үзе акрын гына көйли.

Бакча һәйбәт. Тирәдәге агач яфраклары акрын искән җил белән ни нәрсә хакындадыр җилфер-җилфер сөйләшәләр.

Шагыйрьләргә илһам, пәйгамбәрләргә вәхи килә, диләр. Табигать безнең кебек җырчыларны да моннан бөтенләй мәхрүм итмәгән, ахры.

Зур агач күләгәсендә яшел үлән өстендә ятып, үзалдыма ниндидер ят озын көйләрне моңлап, тукта... тукта... болайрак... менә... менә эзгә төшә дип газапланган вакытымда, Мөхәммәдкә вәхи белән килгән Җәбраилдәй,[77*] минем хыял күгем ачылып, анда гаҗәеп бер нур тулды; шул нур эчендә үзенең көләч йөзе, матур елмаюы белән минем «вәхи фәрештәм» Гөлбикә килеп басты.

Мин аны күрдем; күреп, табындым гына түгел, үткән кичәгә яңадан кайттым. Аның айлы кичәдә ерак күктән килгәнгә ошаш гаҗәеп моңын яңадан ишетәм – үземне белмәдем – аңа кушылып җырлап та җибәрдем, һәм шул минут минем шөбһәләрем дә очты – минем эзләгәнем шул икәнен хис кылдым.

Кайтып җырлагач, морзабыз шаша калды.

– Менә, – ди, – ничек икән ул чын «Ашказар»лар! Безнең монда, ди, бер дә алай җырламыйлар, хезмәтегезгә рәхмәт, – ди.

Концерт та бөтенләй икенче төс алды. Аңа катышучыларда дәрт артып, чын милли җан белән тырыша башладылар. Кемдер:

– Бу вакыйга татар көйләре тарихында зур урын тотарга тиеш, – дип йөри.

Икенче көн шәһәр урамнары безнең, афишалар белән тулды; анда бик эре иттереп шул сүзләр язылган иде:

«Башкортстанның үзенә кешеләр җибәреп, оста җырчыларыбыздан чын «Ашказар», асыл «Сакмар» көйләрен алдырдык...»

Билетлар җитмәде, халыкның күбе, урын булмаганнан, керә алмый мәхрүм калды.

Без дә, ахрысы, чын «Ашказар»ларны моңлаганбыздыр, халык дәрттән, ашкынудан кая басарып белми, чәчәкләрне җыеп бетәр хәл юк, тәбриктән – куллар, мактаудан колаклар талды.

Күп өлкән кешеләребез безне:

– Мили көйләребезне чын юлга салучыларыбыз, – дип сәламлиләр.

Кемнәрдер мал бүлгәндә безгә зуррак өлеш чыгарырга, тагы кайсыдыр кулларга күтәреп йөрергә димли башлаган иде.

Мин һәммәсенә кул гына селектем.

Шул мең төрле халык белән тулгап олы театрда, шул шау-шулар эчендә, минем хыялымда Гөлбикәнең фаҗигый матур йөзе, колагымда аның авыр моңлы музыкасы иде. һәммә тәбрикләргә каршы:

– Юк, сез мине сәламләмәгез, мине тәбрик итмәгез!.. Сезгә мин җырламыйм, сезгә башкорт кызы булып тууга башка гөнаһсы булмаган, фаҗигый язмышлы Гөлбикә моңлана... – диясем килә иде.

Ни дим, сине ни белән юатыйм, бәгърем Гөлбикә! Мин – бәхетсез бер җырчымын. Күңелем кайгылы – шуннандыр җырларым да моңлы. Ана – кем? – белмәдем. Бөтен гомеремә бер сүздән, дустанә бер караштан мәхрүм яшәдем. Шул авыр, моңлы, бетмәс караңгы кайгы белән тулы гомеремдә сиңа очравым һәм синең ихлас иркәң, җылы кочагың эчендә үткәргән сәгатьләрем минем боек күңелемне күтәрде, яралы йөрәгемә шифалы бер тамчы булды.

Башка ни дим, сине ни белән юатыйм, бәгърем Гөлбикәм!

Без икебез дә язмышның үги балалары! Безгә язмыш рәхимсез... Ерак күк безнең аһ-зарларга колак салмый... Безнең караңгы, күңелсез гомеребездә бергә үткәргән шул бер кичә мәңгелек нур, онытылмас юаныч булып калсын!»

Җырчы Сәхипнең хикәясе шулай бетте.

Хикәя тәмам булып, әдәбият кичәсендә укырга ярарлыкмы-түгелме мәсьәләсе уртага куелу белән, иң элек Җиһангир аякка басты:

– Әсәрдә, – ди, – аз сүз белән безем хатыннарның авыр язмышы ачык күргәзелгән. Мин, әлбәттә, укылсын ягындамын, – диде.

Аңа каршы Нигъмәт казый күтәрелде:

– Хикәя бик озын. Сәхнәдә укылса, халыкны ялыктырачак. Бу бер. Икенчедән: монда ниндидер башкорт хатыны Мөхәммәд галәйһиссәләмгә килмеш Җәбраил фәрештәгә ошатыла. Халыкта дингә җиңел карый башлау уята торган мондый мәгънәсезлекне үткәрү – безнең тарафтан җинаять булачак. Шулар белән бәрабәр, хикәядә бик мөһим нокталар бар: 1) көн-төн социализм диләр, эшче белән капиталны сугыштыралар. Яшьләр арасында бу йогышлы чир булып китте. Моның бер мәгънәсез тәкълид[1] һәм мода бәласе икәнен Сәхипнең хикәясе ачык күз алдына китерә. Монда башкорт сөйләнгән, ләкин җир сатуларын бер якка куйсак, башка һәммә сыйфатлары – бөтен милләткә гомуми хәлләрдәндер. Бер башкорт түгел, мишәре, татары, алатыры, типтәре, кәчиме, нугае – болар бары да шул Җомагыл, Хуҗабай, Гөлбикәләрнең үзедер. Үзенең халкы шул Җомагыл дәрәҗәсендә булган бер егетнең социализм дип, эшче дип, капитал дип лыгырдавы, иң әдәби тәгъбир кылганда[2], – әлифба белмәгән ач мужикка Ницше фәлсәфәсе[78*], юнан[3] трагедиясе хакында дәрес бирү белән бердер, яки аннан да кирерәк бер эштер... Урынымы, юкмы, – йөрәгем әрнегән бер мәсьәлә булганга, моны әйтми үтә алмыйм; 2) әсәрдәге икенче нокта: башкорт кардәшләребезнең ата-бабаларыннан килгән җирләреннән аерылулары, алар кулыннан алынган табигый хәзинәдән кайдандыр агылган хохолларның сарайлар салдыруы, башкортның ач калуы мәсьәләседер. Милләтебезнең башына килгән бу зур афәт – бер минут безнең хәтердән чыгарга тиеш түгел, шуның өчен мин бу әсәр укылсын, дим, ләкин бөтен көенә түгел – башкорт хатынын Җәбраилгә ошаткан, ниндидер әхлак бозгыч рәвештә булган тасвирлары ташлансын да җир сату маддәсе тагы бераз киңәйтелсен, ул вакыт хикәя – зур дәрес булыр, – диде.

Госман даим утырмады, керә-чыга йөрде, шунлыктан хикәяне бөтенләй ишетмәгән иде.

Нигъмәт казый сүзен бетерүгә, ул, бик аз гына калка төшеп:

– Хикәянең әдәбият кичәсенә яравы-ярамавы ягына керешмим. Тик Нигъмәт иптәшнең фикеренә каршы берәр генә сүзем бар, – дип башлап, җир, эшче, милләтләр, халыкның наданлыгы, эчүе хакында байтак сөйләп, шул рәвеш тәмам итте: – Монда социалистлар, һич булмаса, шулай уйларга тырышучы егетләр җыелган, болар арасыннан беренең бик аз гына да тартынмыйча: «башкорт кардәшләребез», «әллә нинди хохол килмешәкләр» дигән кебек сүзләрне әйтә алуы – мине чыннан гаҗәпләндерде. Тегендә, Орел

---

[1] *Тәкълид* – иярү.
[2] *Тәгъбир кылганда* – аңлатып биргәндә, ачыклаганда.
[3] *Юнан* – грек.

губернасында, Иван белән Василийның унбиш жанлы җәмәгатенә бер колач җире юк. Ә монда үз яланының иге-чиге кайда икәнен дә белмәгән бай башкорт, агач күләгәсендә кымыз эчеп, дүрт хатын асрап, хайванланып яши. Башкортмы, хохолмы – без моны белмибез... Гадәләт[1] моны танымый. Тигезлекнең, гадәләтнең сүзе бер: кем ач, кем эшли – җир шуныкы...

Күпләр Госманга кул чапты. Ул бетерүгә тагы берничә яктан сүз башланган иде, Разия туташның нидер әйтергә теләгәнен күргәч, башкалар һәммәсе туктады. Туташ урыныннан бик аз күтәрелде, күкрәге белән партага ята төште дә нидәндер җирәнгәнне белдерер тавыш белән:

– Сез әллә кая кереп киттегез!.. Җәбраилме, башкортмы, хохолмы – боларның беренә дә барасы юк. Сәхип иптәш ачуланмасын, иптәш булганга, мин уемны яшермим: аның хикәясе оста язылган, но[2] шундый урыннары бар, анда мин кызардым. Нинди эчүләр – нинди ямьсез утырышлар, тагы ниндидер исерек хатыннар гомерләрендә бер күргән ирнең кочагына атылалар... Боларны укыганда, мин кызардым. Мондый нәрсә укылса, мин катнаша алмам... – диде.

Моңа каршы Сәхип үзе күтәрелгән иде, баштан бирле һичбер тапкыр авызын ачмаган Вәли башкортның, нидер әйтмәк булып, урыныннан торганын күргәч, һәммәнең күзе аңа юнәлде, – Сәхип кире утырды.

Вәли башта бик каушады, тавышы җүнләп чыкмый, сүзләре бутала, аңлашылмый иде. Шулай да берничә җөмләдән соң табигыйләшеп китте:

– Сез, – ди, – монда юкка талашасыз. Сәхип әфәнде ялганламаган. Ул барын да үзе күргәнчә язган. Аның белән Ямanташка көй отарга баручы башкорт шәкерте – мин идем. Ул ялаганламаган, җир сатулары да, Җомагыл Гөлбикәсе дә – бары да бар. Ул дөрестен язган, – диде.

Тангатаров, урыныннан тора биреп, курайчы Вәлигә карады. Ипләп җавап бирде:

– Вәли иптәш, анысы шулайдыр шулаен... Ләкин мәсьәлә анда түгел. Без менә бу хикәя әдәби кичәдә укыр өчен ярармы икән, озынрак булмасмы икән, дибез. Сүз менә шул турыда гына! – диде.

Курайчы шәкерт тагы торды, ләкин күп сөйләмәде:

– Ә, алаймы? Алай булса, ярый! – дип, сүзеннән тукталды да катты. Ул, әйтерсең, урынына кире утыруны оныткан иде. Сүзен әйтеп бетереп, байтак вакыт үткәч кенә, исенә килеп, кире чүкте.

Яңадан Разия туташның сүзенә кайттылар. Аның протесты, үткенләнеп, уртага калыкты. Иң элек кулъязманың иясе аякка басты:

---

[1] *Гадәләт* – гаделлек.
[2] *Но* – әмма, ләкин

– Мин, – диде, – Разия туташның сүзенә каршы...

Ләкин Тангатаров, аның тавышыннан кире чигү чамасын сизенү белән, сикереп торды да, сүз бүлеп, кычкырды:

– Бу талант! Яшь талантларны күтәрергә, үстерергә кирәк! Сез монда матур чәчәк өстенә каплап яткан таш кебек...

Шулай талаш кызып барганда, эчке бүлмә ягыннан кечкенә бер кыз чыкты да Госманның колагына килеп нидер әйтте. Ахрысы, ашыгыч кирәкле әйбер турындадыр. Госман шунда ук урыныннан торды да теге як бүлмәгә кереп китте. Аның артыннан Акчулпанов та чыгып сызды. Разия туташ әллә кайчан ялыгып беткән иде. Тик ташлап китәргә килештермәгәнгә генә көчләнеп утыра иде. Ике иптәше кузгалгач, түзмәде: Госманга ана ягыннан әзрәк кардәш булган Гәүһәр туташ зинданнан котылып килмәдеме икән дип, сиздермәскә тырышып, акрын гына Акчулпаннар, Госманнар артыннан эчке бүлмәгә таба атлады.

## LVII
## ПРОВОКАТОРМЫ, БУТАЛЧЫК РЕВОЛЮЦИОНЕРМЫ?

Шаһвәли, кызып-кызып, Солдатны шатранҗ[1] уенына өйрәтеп маташа. Фигураларның исемнәрен әйтә, кем кая, ничек йөри аласын аңлатып азаплана. Шакир колак салырга теләми:

– Әй, куйчы! Юк белән башны катырасың! – ди дә калын итеп махри[2] төрергә тотына.

Шаһ яңадан бәйләнә:

– Мужик! Син тәмен белмисең аның! Менә күрдеңме: офицер хәзер синең атыңны ашады. Инде атсыз калдың, атсыз мужик ничек дөнья көтсен! – дип шаяртып, кыздыра.

Шакир, бүлмәне куе төтен белән тутырып, тәмәкесен тарта-тарта, фигураларга карап бераз уйлап тора да кинәт шантранҗ тактасы өстенә бармагын суза:

– Алаймы? Бу заманда эш башкача бит: менә синең әфисәреңне минем җәяүле солдатым бәреп ектымы? Уйнаган буласың тагын, адәм актыгы! Без – төрмә күргән кеше. Анда абзаңны ике ел өйрәттеләр! – дип хахылдап көлеп, офицер фигурасын алып ыргыткан минутта, ишек ачыла да, бусага өстенә бер адәм туктый. Зур гәүдәле, башында кама читле татар бүреге. Мыегын кыскартып кырган, кара сакалы битен каплап бара. Өстендә тук мужиклар, – юк, алай гына түгел, шәһәр белән нык катнашкан мәдәни кулаклар киенә

---

[1] *Шатранҗ* – шахмат.

[2] *Махри (махорка)* – тәмәке.

торган кама якалы, кара тышлы тун, аягында тезеннән югары менгән озын чобар пима[1].

Ул, күзләрен кыса төшеп, бүлмәгә, шатранҗ тактасы тирәсендә шаярышып утырган Шаһ белән Солдатка карады да:

– Фу, Вәли, син икәнсең, танымый торам!.. – дип, тиз атлап, өстәл буендагы зур тирән креслога чума биреп утырды. Дәшми-нитми, озаклап, акрынлап Шакирның янчыгыннан зур итеп махри төрде дә, төтен эчендә капланып, тартырга тотынды.

Ул гадәттә тартмый иде, ләкин Шаһ белән бу көтелмәгән очрашу аның башын кайнатып җибәрде. Ул ни эшләргә, нинди тактика тотарга икәнен тиз генә кисеп билгеләп өлгерә алмады; миен каплаган, нерваларын кайнаткан бу мәсьәләсен яшерү, шуны чишкәнче тышкы бер эшкә бирелгән күренү өчен иң уңай нәрсә – шул махри булды. Шуңа күрә, чәчмәскә тырышып, куе төтенне авызыннан кертеп, борыныннан чыгарып азапланды.

Ләкин Шаһ аның бу маневрын сизенде, – ачык түгел, шулай булса кирәк диебрәк сизенде. Аңа бер минут качырмый, хәзер һөҗүм башларга кирәген чамалап, шатранҗны да, Шакирны да бер якка ташлады, һичкемгә кул бирмичә, җүнләп исәнләшмичә креслога чумган иптәшенә барып, аның җилкәсенә тотынды: әллә нинди эчке рәнҗүле, трагедияле тавыш белән ялынып әйтте:

– Булат абый, бу ни хәл бу? Синең Гәрәй Солтаның һичбер гөнаһсызга мине үтерә башлады ич! Йөзенә ерткыч юлбарыс төсе чыккан, күзен кан баскан, җиңенә фин пычагын тыккан да, син – провокатор, дип өстемә ташланды ич! Мин бу хурлыкны күтәреп кала алмыйм. Мәсьәләне парткомга куям. Син миңа ярдәм итәрсең бит, мине аклатырсың ич, Булат абый? – дип, курку катнаш ялвару тулы күзләре белән Зарифның күзләренә кадалды.

Булат бу вакыйганы белә иде. Үзе кебек, Гәрәйнең дә кайбер чакларда гадәттән тыш шикләнүчән, ышанмаучан икәнен дә аңлый иде. Әле тыш яктан һичбер төрле тикшерү белән, һичбер төрле материал белән бу турыда ачык бер нәтиҗәгә килергә мөмкин була алганы юк иде. Шулай да егеткә алай җиңел генә бер чуалыш, бер яклау сүзен теленнән чыгара белмәде. Тагын куерак төтенләп, төтен болытлары арасыннан Шаһвәлинең аягындагы сары штиблетенә, алсу галстугына, ике якка мәче койрыгы кебек сузылган зур саргылт мыекларына карады.

– Мин ул эш белән һаман таныша алганым юк шул әле, – диебрәк, үзенең кара күзләрен кыса төшеп, Шаһның зур борынын, кечкенә соры ялтыр күзләрен озак сөзде. – Әйдә, бер партия уйнап алабызмы әллә, Госман да

---

[1] *Чобар пима* – чуар киез итек.

тегеннән тиз чыгар төсле күренми? – диде.

Куллары шахмат тактасы һәм төрле фигуралар өстендә йөргәндә, аның миендә утлы кадак булып бер уй әйләнүдән тукталмады. Йөрәге кискәләнде. Тукта, бу кем? Адашып йөргән бер революционермы? Әллә, Гәрәй Солтан шикләнгәнчә, күп катлаулы явыз провокатормы? Ул бит башта эсерлар тирәсендәрәк чобалган[1] иде, диләр. Хәзер безнең фронтның сугышчы солдаты булып кайнаша. Бу кем? Бу нигә Питерга барды? Кайдан акча ала? Кадыйр байларда приказчик булган бугай. Йосыфҗан белән аралары әле дә өзелеп җитмәгән шикелле.

Булат, шул уйлар эчендә чуалып, уенын оттырды: Шаһвәли аңа дүрт йөрүдә мат куйды да шаркылдап көлде. Зариф үзенең җиңелү хурлыгын да сизмәде, бу көлү дә аның колагына кермәде.

– Тукта инде, чынлап уйныйбыз! – диде дә бөтен фигураларын нервалы кулы белән тактадан себереп төшерде.

Яңа уенда да дүрт йөрештә тура белән ферзьне ашатты. Ләкин бу башта гына шулай булды. Зариф мәсьәләне гәзиткә редактор таба алмау турына күчерде:

– Менә, – диде, – без һәммәдән алда рөхсәт сорап кәгазь бирдек. Безнекен яткыралар, башкалар инде чыгара башлады, кара сөрем белән халыкны агуларга тотынды, ә менә безгә һаман кире сугалар. Госман исеменә соралган иде, аңа да бирмәделәр. Ничек уйлыйсың, Шаһ? Синең исемгә бирмәсләр идеме? – дип, Шаһвәлинең зур борынына, кечкенә, ялтыр соры күзләренә текәлде.

Бу маневрны Шаһ аңлап өлгермәде, уе шуңа китте: берьюлы берничә бик кадерле фигурасын оттырды, ләкин эш бу фигураларда түгел иде. Үзалдына уйланды, зур сары мыекларын ике якка таба борып җибәрде дә кинәт кисте:

– Юк, булмас, Булат абый! Жандарлар эт бит, бирмәсләр, миңа да бирмәсләр, – диде. Атны иң ахмак, иң куркыныч урынга китереп куйды.

Булат җәяүлене күчерде дә партнёрының мие капланудан файдаланып, икенче йөрештә үзенең турасы белән тегенең атын алып ташлады, ә корольгә шах игълан кылды. Шаһвәли калтырана биреп көлде, бөтенләй уен эченә чумып, яңадан фронтны бераз төзәтү чарасын күрде. Ул оста уенчы иде, Булатны яңадан кыса башлады. Бераз иркенәюгә күңеле күтәрелеп китте:

– Менә нәрсә, Зариф абый! Ятып калганчы атып кал, диләр түгелме? Редакторлыкка башка адәм тапмасаң, мин күнәм, әйдә, гәзит өчен сөрсәләр, мине сөрерләр. Япсалар, мине ябарлар: пролетариат өчен, социализм өчен

---

[1] *Чобалган* – чуалган.

мин үземне корбан итәргә әзермен! – диде дә, шаркылдап көлеп, каршы корольне дүрт яклап кысып бикләде.

Шаһвәлинең соңгы сүзе булмаса, Булат бер шик эчендә калачак иде, егетнең тавышындамы, сүз чыгышындамы, елмаюындамы – нәрсәсендәдер бер ясалмалык, бер фальш чыкты. Моңарчы Гәрәйне гаепләргә әзер торган Зариф, шул соңгы сүз әйтелгәч, кинәт Гәрәй ягына ауды: юк, аның шикләнүе дөрес, Гәүһәрнең шикләнүе дә дөрес: бу, шиксез, провокатор, дип кискен уйга тукталды. Шул эчке карары астында аның түбәнге ирене дерелдәп, бармаклары калтырап куйдылар. Кулы, ирексез, арткы кесәгә ишерелгән револьверга таба сузылды. Кызган бармагы белән кобурының төймәсен ычкындыра, салкын шома корычны кулына ипләп ала – ни эшләргә? Шул җирдә атып бетерергәме? Юк, ярамый. Бу җүләрлек, башсызлык булачак. Әгәр шуннан чыгып качса, бу эт бөтен организацияне җимерәчәк ич! Ни эшләргә? Шул кызу кискен ут эчендә инде револьверны кесәдән суырып чыгарам дигән моментта, тегеннән ишек ачыла да, Госман килеп керә. Зариф Булатов:

– Уф!.. – дип, җиңеләеп китеп, урыныннан сикереп тора.

Аның җилкәсеннән, әйтерсең, тау төште. Шулай бер котылу сизенде. Әйтерсең, авыр, саташулы йокыда өстеннән албастыны алып ташладылар. Шулай иркенләп, киңәеп сулыш алып җибәрде. Шаһвәлигә туры карап әйтте:

– Син бар, кайт инде: барыбыз бергә эләгә башларбыз тагын! - диде.

Шаһвәли аптырады, шулай да, шик төшермәс өчен, киенергә тотынды. Ул киенеп азапланганда, Булат шунда альбом актарынып утырган Солдатка күз кысты: «Син дә киен. Бүген аңардан калма, аңардан аерылма!» – дигәнне аңлатты.

Шакир, бик мужикча, озак иснәп, киерелде дә:

– Их, сөякләр катып беткән. Төн җитте ич, миңа да кузгалырга кирәк, – диде. Шаһвәлигә карап: – Шаһ, туган, шул фатирга кайта-кайта җаным чыга, бүген синдә генә куныйм әле мин? – дип сорады.

Егеткә агулы ук чәнечкәндәй булды. Ул, койрыгына басылган җылан кебек, бер секундка зәһәрләнеп катты, шунда ук зур мыекларын ике якка борып, хахылдап көлде:

– Их, мужик! Башың эшләми синең: ялгыз егеттә ни булмас. Син миңа кара таракан булырга әйтәсең ич! – дип, шаярыбрак аркасына сукты, шулай да карышмады, җитәкләп, үзе белән Шакирны да алып чыгып китте.

Булат күзе белән аларны ишек ябылганчы озатты да яңа кергән иптәше Госманга борылды:

– Кара әле, Госман, бу борын нигә синең тирәдә бик күп ышкыла? – дип, чәнчебрәк сорады.

Авыр, сабыр Госман ыкы-мыкы итә, җавап биреп өлгерә алмый – тагы ишек ачыла. Аннан озын буйлы, озынча аксыл, бик интеллигент йөзле, зур кара күзле, яңа туган ай кебек сызылган кара кашлы, рәсми реалист киемле, үзен бик тәрбияле тотарга тырыша торган чибәр бер егет – Акчулпанов килеп керә. Ул Булатны байтактан күрмәгән, әле бу соңгы качып кайтуыннан бирле бөтенләй очрата алмый йөргән иде. Нечкә, озын бармаклы ак куллары белән Зарифның ике кулын кысты, чибәр нечкә йөзе белән дусча елмаеп әйтте:

– Менә бәхет! Көтмәгәндә сине очраттым! – диде. Татарча башлап, русча тәмамлады: – Бик урынлы очрашу булды бу! Менә бер атна инде егетләрне тотып киләм. Син аларга аңлатырсың! – диде дә: – Мин хәзер керәм, – дип, кире чыкты. Шунда ук, теге як залдан Җиһангирне алып керде.

Акчулпанов Хәйдәр татар телен аз, авыр белә, шулай да аның ике телне бутарга ярамый дигән теориясе бар: йә русча гына, йә татарча гына сөйләш, ди. Үзе татарлар белән, әлбәттә, татарча гына сөйләшергә тырыша. Ләкин аның «къ» хәрефе «к» булып чыга. Яшьтән морза арасында кайнап, һаман русча тәрбия алганга, ул рус телендә уйлый, шуңа күрә татарча сөйләшергә әйткәндә дә аның җөмлә төзелеше русчага әйләнеп китә. Моңа карамастан, ул тырышын татарча башлый, әмма бик тиз, мәсьәлә аз гына кызу белән, бөтенләй русча керешә. Әле дә, Җиһангирне алып керүгә, бик тырышып татарча сүз башлады:

– Мин әйтәм, алай ярамас дип әйтәм. Алар ташламадылар... Менә син үзең аңлатып бир аларга! – диде. Булат аның фикеренә кушылмагач, аз гына талаш кузгалу белән, үзе дә сизмәстән бөтенләй рус теленә төште: – Кара син! Менә үзең укып кара. Монда башка бер әйбер юк. Тик солдат кебек сугышка өйрәнү генә бар. Без кем? Билгеле бер идея белән эш алып баручы партияме? Әллә коралы армия генәме?..

Булат, күз карашы белән елмаеп, ләкин катырак кисеп куйды:

– Тукта, Хәйдәр! Нигә бу икене кара-каршы куясың? Без – партия! Безнең партия – армия. Марксизм белән сугарылган армия! Капитализмны җимереп, социализмга барыр өчен көрәшүче армия! Бу көрәш сүз белән – агитация, пропаганда белән генә чикләнә алмый. Дошман кулында корал булган кебек, без дә коралланырга, бөтен пролетариатны коралландырырга кирәк. Корал табарга кирәк. Корал ясарга кирәк. Корал тотарга өйрәнергә кирәк. Бу безнең самодержавиегә каршы сугышта партиянең тоткан юлы... Син нәрсә, Өченче съезд карарын[79*] кая ташлыйсың? Әллә... меньшевиклар кебек...

Хәйдәр кызды:

– Ташламыйм. Съезд карары бер нәрсә. Әмма аерым мәкаләне прокламация итеп тарату икенче нәрсә. Син үзең бутама...

Сүз ачы, кискен полемика төсенә кереп китә. Бүлмә тавыш белән каплана.

Җиһангир болар арасында яңа кеше иде. Мондый халыкка катнашып гадәтләнмәгән шәкерт булганга, бераз тартына да иде. Башта ни эшләргә белмәде, кире чыгып китсә дә килештермәде. Шулай үзен кая куярга аптырабрак торганда, талаштан кызарган Хәйдәр аңа таба борылды, татарча әкренләп әйтте:

– Җиһангир иптәш, син теге, Гәрәй калдырган кәгазьне бир әле миңа! – диде.

Шәкерт бераз калтырап-каушап куйды. Шулай да сер бирмәде, алай бик ватылмыйча, күкрәк кесәсеннән ике кәгазь чыгарып төртте:

– Менә бусы татарчасы... Менә бусы без тәрҗемә иткәне... Аны безгә Гәрәй Солтан иптәш калдырган иде. Ул үзе безнең белән ике төн утырды, безгә русча сүзләрне чәйнәп салды, без татарчага әйләндердек. Ә менә Сәхип тә катнашты; икәү яздык, икәү басмакчы да идек. Гәрәй аны безгә ике йөзне басарга кушкан иде. Үзен сөрделәр, без инде басаргамы, юкмы дип киңәшсәк, Хәйдәр иптәш кире какты... Без ни эшләргә дә белми калдык... – дип, озын сүзен бетерде. Ул мәдрәсәдә, үзе кебек шәкертләр, хәлфәләр арасында өч сәгать сөйләүне бернигә санамый иде. Әмма бу ятрак кешеләр алдында шул югарыгы сүзне җырып чыкканчы маңлаеннан тир калыкты. Шулай да ярыйсы очлады бугай: үзе шулай уйлады.

Булат тәрҗемәне кычкырып укый башлады:

– «Үткән төндә җитмеш кешелек бер төркем халык Рига шәһәрендәге мәркәз зинданга[1] һөҗүм иттеләр. Телефон чыбыкларын кистеләр. Җеп[2] баскычлар белән зинданның йортына төштеләр. Анда кызу бәрелеш китте. Зиндан сакчыларыннан икәве үтерелде. Өчәве яраланды. Шулай басып кереп, манифестантлар зинданга ябылган ике сәяси тоткынны азатлыкка чыгардылар. Боларга хәрби судта хөкем булачак иде, боларны үлем җәзасы көтә иде. Манифестантлар качып өлгерделәр, аларны куганда, бары икесе эләкте; бер агент үтерелде, берничә полицейский яраланды... Шулай итеп, эшләр алга таба баралар. Язып бетерә алмаслык авырлыкларга, кыенлыкларга карамастан, кораллану эше һаман үсә бара...»[80*].

Укып, шул җиргә җиткәч, тәрҗемә турында Булатның берничә шиге уянды:

– Кая, русчасын бир әле, – дип алды да чагыштыра да барды. Ахырдан: – Ярый, ярарлык, тик менә шуларын төзәтергә, – дип, берничә урынын

---

[1] *Мәркәз зиндан* – үзәк төрмә.
[2] *Җеп* – биредә: юан бау, аркан мәгънәсендә.

күрсәтте. – Мөмкин булса, бүген үк басыгыз. Мин болар әллә кайчан чыгып таралгандыр дигән идем...

Җиһангир өчен беренче сүз авыр иде, ул хәзер үзен янәшә диярлек куеп әйтте:

– Менә монда тагы берсе бар. Башын тәрҗемә иттек. Бу җиренә хәл җитми. Ярдәм кирәк! – диде.

Булат тиз-тиз күз йөгертте дә Хәйдәргә карады:

– Акчулпан, син булыш. Русча мәгънәсен анлатып бирсәң, алар татарча сүзләрне үзләре табалар...

Соңгы берничә минут эчендә үзалдына нерваланып, кайнап торган реалистның күзе ялкынланды, кәгазьне кире ташлады, кызып русча җавап кайтарды:

– Булмас! Мин моңа каршы. Үзем каршы әйберне тәрҗемә кылдырып чыгару эшенә катнаша алмыйм! – дип кисте.

Зариф Булат бу җәнҗалдан туйган, ватылган иде. Арыган иде. Егетнең мондый кирелек белән кәгазьне кире ыргытып бәрүе – аның каның кайнатып җибәрде. Усал күзе белән Акчулпанга карады:

– Ул нинди сүз тагы: «булмас!» Беләмсең, бу әйбер типография юлы белән чыга алмады, аның русчасын да гектографта тараттылар. Татарчасын мин сөргенгә киткәнче үк җилем басмада таратырга партком тарафыннан кушылган иде. Менә кәгазь. Хәзер ал да, бүген эшләп бир!

Хәйдәр яңадан кызды, кызарды. Яңадан киреләнде:

– Булмас! Минем фикеремә каршы әйберне миннән эшләтә алмассың.

Булат бераз ачулы, бераз көлү-мәсхәрә катнаш тавыш белән аны кисте:

– Мин кушмыйм аны таратырга, организация куша. Беләмсең, организация куша! Син буйсынырга тиешсең. Партия дисциплинасы сине моңа мәҗбүр итә.

– Ничек мәҗбүр итә? Андый сукыр дисциплина буламы? Мин машинамы, автоматмы?

– Син машина түгел. Автомат түгел. Син – партия әгъзасы. Организациянең карарын үтәргә син мәҗбүрсең. Булмаса, синең кирәгең бер тиен. Дисциплинасыз әгъза – әгъза түгел. Андыйларга социал-демократия сафында урын булырга мөмкин түгел. Сине иртәгә чыгарып ыргытырлар! Бел аны!

Талашның бу дәрәҗәдә кискенләшүен басар өчен Госман катнашты. Кәгазьне кулына алды да русчасын укып чыкты. Хәйдәр яңадан бер кат зәһәр белән тыңлады.

Түбәндәге урыннарга аеруча каршы бәйләнде:

«... Проповедники должны давать отрядам[81*] каждому краткие и

простейшие рецепты бомб, элементарнейший рассказ о всем типе работ, а затем предоставлять всю деятельность им самим. Отряды должны тотчас-же начать военное обучение на немедленных операциях, тотчас-же. Одни сейчас же предпримут убийство шпика, взрыв полицейского участка, другие – нападение на банк для конфискации средств для восстаний, третьи – маневр или снятие планов и т. д. Но обязательно сейчас же начинать учиться на деле: не бойтесь этих пробных нападений. Они могут, конечно, выродиться в крайность, но это беда завтрашнего дня, а сегодня беда в нашей косности, в нашем доктринерстве, ученой неподвижности, старческой боязни инициативы. Пусть каждый отряд сам учится хотя бы на избиении городовых: десятки жертв окупятся с лихвой тем, что: дадут сотни опытных борцов, которые завтра поведут за собой сотни тысяч...»[1]

Госман укып бетәр-бетмәс, Булат аңа ялгады:

– Бу икенең беренчесе «Пролетарий»ның[82*] № 18 ндә (1905) чыкты. Анда Ленинның кулы куелмыйча басылган булган. Гәрәй шуннан алып, партком белән аңлашты – тәрҗемәгә карар ителде. Икенчесе 1905 нче елның октябрь ахырында язылган булырга тиеш. Ленин аны матбугатка бирмәгән. Бәлки Центральный Комитетка хат итеп җибәргән. Шуннан аны боевиклар, һәркайда үзләренә җитәкче инструкция кебек күчереп, кулъязмада йөртәләр. Гәрәй рус иптәшләрендә күргәч, татарчасы кирәк дип, ябыша калды. Партком карар итте. Бу әллә кайчан масса эчендә, татар боевик отрядлары кулында булырга тиеш иде. Син, Хәйдәр, үз белдегең белән организация карарына саботаж ясыйсың. Без хәзер бөтен Русиядә кораллы күтәрелешкә әзерлек алып барганда, син аяк чаласың! – дип бетерде.

Хәйдәрнең каны байтак басылган иде. Ул үз турында парткомга мәсьәлә куйдырырга теләмәде, кипкән тамак тавышы белән акырып җавап кайтарды:

---

[1] «... Өндәүчеләр отрядларның һәрберсенә бомба эшләү өчен кыска һәм иң гади рецептлар бирергә, эшләрнең бөтен типлары турында бик гади итеп сөйләргә, ә аннары бөтен эшне аларның үзләренә тапшырырга тиешләр. Отрядлар *шунда ук* кичектергесез операцияләрдә, шунда ук сугыш эшенә өйрәнә башларга тиешләр. Берәүләре – хәзер үк шымчыны үтерүне, полиция участогын шартлатуны оештырырлар, икенчеләре – восстаниегә акча конфискацияләү өчен банкка һөҗүм оештырырлар, өченчеләре – маневр яки планнар төшерүне оештырырлар һ. б. Ләкин әлбәттә хәзер үк эштә өйрәнә башларга кирәк: бу сынау һөҗүмнәреннән курыкмагыз. Аларның бик кыен хәлгә җиткерелүләре мөмкин, әлбәттә, ләкин бу иртәге көндә булачак бәла, ә бүгенге бәла безнең хәрәкәтсезлегебездә, безнең доктринерлыгыбызда, галимнәрчә акрын кыймылдауда, инициативадан картларча куркуда, һәрбер отряд үзе һич булмаса городовойларны кыйнап өйрәнсен: уннарча корбаннар, иртәгә йөзләрчә мең кешене үз артларыннан ияртеп барачак йөзләрчә тәҗрибәле көрәшчеләр биреп, бик зур файда китерерләр...» (В.И. Ленин. Әсәрләр, 9 том. – Казан, 1957 ел, 343 бит).

– Син, Булат, җәнҗал куптарма инде; беләсең – мин дисциплина кешесе. Бүген төнлә үк Җиһангир белән утырып эшләрбез, – диде.

Тагын нидер өстәмәк булып авызын ачкан иде, ишек ачылды, җилләнеп, һаваны хушбуйга тутырып, озын буйлы, кара-туткыл чибәр йөзле, кыскартып киселгән куе җефәк кара чәчле курсистка Разия туташ килеп керде. Килеп тә керде, дөньяда тик ул гына бар кебек, монда тик аның турында уйлап, аны гына көткәннәр сыман шатлыклы йөз белән, шатлыклы тавыш белән көлеп, Булатка ташланды, русча тезеп китте:

– Менә көтелмәгән бәхет! Зарифчик, сине күрәм ич! – дип, канатланды.

Ләкин, арыганмы, гадәте шулайга әйләнгәнме, башка сәбәбе бармы – Булат алай бәхеттән, шатлыктан кабарынмады, бераз елмаеп, кул бирде, элеккечә артык каты кысмады да. Җитмәсә тагы, Зарифның күзендә хәзер бер яңа караш бар. Ул эченнән мәсхәрә итеп карыймы, әзрәк көләме – нидер бар. Бу күз карашы Разиягә бер дә, бер дә ошамады: ул үз итми, ничектер читкә каккан кебек тоела. Әмма кайчандыр алай түгел иде ләбаса! Гимназияне бетерер-бетермәс чакларында, әле башкаларга ияреп, мода сыман гына сәяси җыелышларга катнашкалап, «Марзельеза» өйрәнеп йөргән заманнарда ул Булатны очраткан иде. Сөюгә, гыйшыкка барып җитә алмады, ләкин ул чакларда аеруча чибәр, матур, тулы канлы яшь Зариф бу кызның йөрәгендә ниндидер бер яратуга ошаш дулкын уятты, үзе дә бу ут кыз янында ялкынланып, янып китә язды. Яшь-җилкенчәк җыелып, Идел аръягына пикникка чыкканда, бер заман шулай Разия үзенең йөрәгенә ирек бирергә теләде – көн буенча, ничек теләсә шулай Булат белән шаярды, аңа әйбер бәреп качты, артыннан йөгереп кудырды, учлап-учлап чәчәк сипте. Булатның яшьлек каны котырып ташкан еллары иде – йөрәге кайнап котырды, шаяруга каршы шаярып, бер тапкыр бармак янады: «Кызый, бел аны! Ут тирәсендә уйныйсың!» – диде.

Разия аның саен акылын югалтып, егетне шашыртты. Шул шаянлык минутларының берендә кыз күп чәчәкләрне учлап алды да балчыклы тамырлары белән бергә Зарифның битенә сибеп качты. Үзе белмичәрәк, ялгыш бугай, агачның куерак җиренә барып керде, яшеренергә теләде, булдыра алмады. Булат аны сикереп, шаярып тотты да үзалдына дулкынланып торган гәүдәсен кочаклады, көлеп-шаркылдап, рәнҗеп протест итүенә карамастан, көчләп, кызның янып барган тулы кызыл иреннәреннән озак суырып үпте.

Чынмы, юриме, – Зариф аера алмады, – әмма кыз аңа гаҗәп ачу белән үпкәләп китте, ул көн аңа якын килмәде, кайтканда да башкалар белән тын гына, сабыр гына сөйләшеп барды. Ике көн шулай рәнҗегән төс саклады да өченче көн аның белән тагын очрашты. Теленнән һаман шелтәләде: «Мин

сезгә бик рәнҗим. Ачуым гомеремдә бетмәс сезгә!» – дип тиргәде, ләкин йөзендә, күзендә дусча елмаю нуры уйный иде. Бүлмәсенә кайткач, ялгызы озак уйланды, Булатны хыялы белән күз алдына китерде: «Ни эшлисең, нахаллык итте инде итүен, әмма ираннәре нинди тәмле каһәрнең», – дип елмайды.

Ул үз күңелендә Булатны байтак йөртте, сәяси эшләрдә дә ирексез аның юлына тартыла иде. Ләкин Гәүһәрнең кинәт кайтып төшеп, ачыктан-ачык Булат белән багланып китүе Разиянең хыялларын җимерде. Ул Гәрәйнең күз карашы усал дип зарлана торган булды, ничектер, сизелмәстән, Давытлар ягына таба акты, инде күп үтмәде: «Минем Булатлар белән килешеп җитмәгән принципиаль моментларым бар», – дин сөйләргә ярата башлады.

Ләкин бу соңгы арада ничектер Булат телгә күп керә. Завод алдындагы якшәмбе бәрелешендә Булат эләккән икән, кача башлагач, артыннан атып үтергәннәр икән, дип чыгаралар. Аннан зинданга эләгүен сөйлиләр. Ерак Себергә сөрелүе дә аның исеме тирәсендә күп сүз тудыра, инде иң ахыргы көннәрдә, Енисейгә җитәр алдыннан егерме сигез сөргенне урман эчендә боевик отряд һөҗүм итеп коткарган икән, берсе Булат булган икән, дип куерталар. Бөгелмәдә эләгә язып та, Шакир солдат егетлеге аркасында котылуы үзенә бер әкият булып халык эчендә тарала. Айлы төндә ярдан ярга сыя алмый аккан Кама бозлары өстеннән чыгып качулары турындагы сүзләр – тагы ныграк кабарып, яшьләр эченә керәләр. Разиянең күңелендә әллә кайда яшерен көйрәп яткан чаткы кабынып китә, бу әкиятләр дулкыны белән аның күңелендә Булатны күрәсе килү дәрте кузгала.

Ул аның качып кайтканын белә иде, ләкин бүген Госманда очрату өмите бертөрле дә аңарда юк иде. Җырчы Сәхипнең «Башкорт кызы Гөлбикә»сен тикшереп утырган яшьләр җыелышыннан акрын гына таеп, бу бүлмәгә килгәндә, ул Булатны хәтеренә дә китермәде; Госманга кардәш тиешле Гәүһәр туташ якын арада зинданнан чыкты, бәлки шул килгәндер дип кузгалган, Гәүһәрне күрү дәрте белән бу бүлмәгә ташланган иде. Ишек ачылып, бай мужик кыяфәтендә киенгән, сакалын җиткереп, мыегын кыскарткан адәмне күрүгә, ул бер секунд кына аптырап калды, ләкин шунда ук таныды. Тану белән канатланып ташланды, ул чактагы, пикниктагы кебек шаян якынлык сәгатьләре кайтыр дигәндәй бер өмит белән канатланды. Ләкин үзе көткәнчә каршылау тапмады: ул кергәнче башланган талашның очын өзә алмыйча, сузып маташа. Мин кем? Аңа йомышка килгән гимназист кыз түгел ич! Ул бервакыт үзе дә ычкындырды ич: «Их, Разия, чибәр син, күңелле син, вакыт булса иде, бөтен кич буенча синдә үткәрер идем», – дип ычкындырды ич! Әле нәрсә кылана? Акчулпан белән Госманны гомерендә

беренче күрәме әллә?!. Кул кысуы әйбәт, учлары җылы. Күзендә дә дуслык елмаюы бар. Әмма шулай да, исәнләшеп янына утыргач, тагы злекке талашны алып китә.

Туташ эченнән хурланды. Бу кергәч тә, бөтен дөньяны ташлап, тик аңа гына карап, аның турында гына сүз сөйләшеп-сорашып алып китмәүгә хурланды. Тәне, куллары кызды. Бите, иреннәре бер агарды, бер кызарып янды. Кинәт торып чыгып китим дигәндә, ирексез үзен-үзе белештереп җитмәстән, русча:

– Илаһым, бар икән бетмәгән талашыгыз! Мин аны сагынып кердем. Ул минем белән бер минут сөйләшергә дә җай таба белми... дип кисте дә, бөтен гәүдәсе белән дулкынланып, шаркылдап көлеп җибәргәнен сизми дә калды. Шул сүзенә үзе җанланып, батырланып, бәйләнде: – Җә, бетмәс, бетмәс синең җәнҗалың!.. – дип шаяртып, аны почмактагы көзгегә табарак көчләшеп тартты, нурлы, ялкынлы зур чибәр күзләре белән аның күзләренә елмаеп, дусча тавыш белән: – Зарифчигем! Үзеңә генә бер сүз: миндә дүшәмбе көн җыелыш була. Киләсең бит? – диде.

Булат, авыррак елмаеп, кулын кысты. Ярым дус, ярым ят тавыш белән:

– Их! Вакыт таба алсам, синең үзең белән ялгыз утырырга барыр идем, әмма, беләсең, ул җыелышларыңны синең мин яратмыйм! – дип, йомшаклап көлеп, сүзен бетерде.

Разия шелтә белән тагы көйсезләнде:

– Менә кеше. Үзе белми, үзе киреләнә. Андый җыелышлар түгел, бөтенләй башка! Киләсең, әлбәттә, киләсең! Килмәсәң, мәңгелек үпкә сиңа! – диде дә боерык биргән рәвеш белән чыгып югалды.

Булат, ул ишеккә җиткәндә артыннан җитеп, биленнән алды, ярым кочаклаган килеш, мәҗбүри сабыр тавыш белән:

– Кара әле, Разия, алайса Госман абзый аркылы яңадан белдерерсең. Әз генә мөмкинлек булса, кереп чыгарга тырышырмын! – дип юатып, шатландырып җибәрде.

Тәмәке төтене бүлмәдә күгелҗем төсле куе болытка әйләнде. Кеше арткаdebannan-арта барды. Яшерен басма эше белән кергән Акчулпанов белән Җиһангир артыннан Урмановның башы күренә. Аннан шаулап, талашып, Нигъмәт казый килеп керә.

Булат эченнән кискенләшә. Акчулпан белән Госман турында Гәрәй Солтанның сүзләрен хәтерли. Болай ярамый. Бүгенме, иртәгәме – төпләп актык тапкыр сөйләшергә кирәк. Эшчеләр бистәсендә татар түгәрәкләренә җитәкчелек итәргә вакытлары җитми, митингларда, демонстрацияләрдә татарча сөйләргә аларны таба алмый аптырыйлар. Кирәк урында, масса эчендә алар юк. Әмма монда кырык корама, йөз ялгауны җыеп, чобар юрган

тегәләр. Бу нинди җыелыш бу? Ширин кызы морза Разия да шунда. Анархист Тангатар да, народник Урманов та, монархист Нигъмәт казый да шунда. Инде кем калган? Хәзер бит Кадыйр бай белән Гали хәзрәтне чакырасы да: – «Җәмәгать! Сыйныф юк, көрәш юк. Партия юк. Барча мөэмин-мөселман, бай-ярлы, алпавыт-крәстиән, эшче-фабрикант – һәммәсе бер тән, бер җан булып берләште!» – дип, дөньяга игълан кыласы гына калган ич! Акчулпанны әйтмисең дә, бу Госман ни эшли? Партия йөзен югалта ич бу адәм! Байбәтчә Йосыфҗан өчен яшерен паспортлар табышып бирергә Госманның вакыты табыла. Әмма батрак Шакир солдат килсә, ул, эшем күп, ди, аның йомышын үти алмый. Бу эшләрнең тамыры кайда? Юк, Гәрәй Солтан хаклы иде. Ул ачык куйды: «Бу ике – безнең кеше түгел. Болар – меньшевиклар. Болар партиянең аягына мунчала булып уралалар, пролетариатның көрәшенә комачаулыйлар. Боларны организациядән сөрергә кирәк!» – Менә ул ничек тәкъдим итте. Ул парткомга да шулай кертте. Болар үзләрен ап-ачык: «Менә без – меньшевиклар», – дип тә чыкмыйлар. Кискен куелса, дисциплинага да буйсыналар. Шундый күп сәбәпләр аркасында аларны куып чыгару-чыгармау эше өзелмәде. Ләкин өзәргә туры киләчәк. Бу буталчыкны яргалап, кирәк элементларны аерып алырга, кирәкмәгән читләрне кисеп ташларга булыр.

Тыш яктан иптәшләр белән исәнләшеп, үзенең качу тарихын сөйләп утырган минутларда, Зариф Булатовның миенең кайсыдыр бер эчке катлауларында менә шул югарыгы уйлар кайнады. Ул бүген үк Госман белән кискен куеп сөйләшергә тиешле тапты, тик менә бу чобар[1], буталчык бәндәләр – бу Нигъмәтләр, Урмановлар чыгып китсен дип, операциягә әзерләнде.

Ләкин моңа җай туры килмәде: кинәт кайдадыр бик якында, кемнәрдер яман каты кычкырын җибәрәләр. Кыйныйлармы, качканнарны куып тоталармы? Акырып-бакырып йөгерәләр. Мылтык аткан, әйбер ватылган тавышлар килә. Госман агарынып китте:

– Иптәшләр, яһүд погромнары башланды булыр. Күптән хәзерлек бара иде, – диде дә урам як тәрәзәгә капланды.

Бу бүлмәдәгеләр дә, залга әдәби кичә әзерлегенә җыелганнар да, бергә буталып, ашыгыч-ашыгыч киенергә тотындылар. Шул шау-шу астында куркып, жылап, ике кыз килеп керде: берсе – Габдулла абзый кызы Маһирә, берсе – Булат сеңлесе Фәүзия икән. Үзләренең йөзләрендә, күзләрендә үлем куркусы; шуңа карамастан, Фәүзия, абыйсының култык астына сыена-сыена, урамдагы вакыйганы сөйләргә ашкына:

---

[1] *Чобар* – чуар.

– Кадыйр байлар чатыннан гына борылган идек, дүрт алты казак килеп чыкты. Үзләре чабалар. Үзләре аталар. Әллә нинди бер төркем кеше кача. Шуларны куалар. Без ни эшләргә белмәдек: коймага сөялдек тә каттык... Әй курыктык инде, үләбез дип торабыз...

Кызлар Булат артыннан килгәннәр икән. Фәүзия, беренче куркудан айныгач, күз яше ара көлеп, татылдап китте:

– Әнкәй, – ди, – сөргәннәр дигәч, авырып егылган иде. Үләм, күрәсең, ди иде. Яңадан кайтып төште дигәч, тагын аякка басты, әйдә, абый, тиз. Ул инде бәлешләрен мичтән алды...

Бу төтенле, буталчык халыклы бүлмәдән тизрәк таярга әйбәт сылтау булып төште. Булат сеңлесенең такылдавын бүлдерде дә шунда сүзсезлектән, эшсезлектән кыенсынып, газапланып утырган Җиһангиргә борылды:

– Син безнең әнкәй торган квартирга барганың бар бугай. Мондый погромлы төндә ике баланы җибәрү куркыныч. Шуларны озатып кайта күрсәнә. Аларны керткәч, мине таш мәчет чатындарак көт. Бергә бару ярамас, мин тиз тотармын! – диде.

Ике кыз белән Җиһангир китүгә, кама читле бүреген басты, яхшы тунның кызыл төймәләрен каптырды да арткы ишек белән йортка чыкты, аннан тыкрык аркылы кечкенә, караңгы урамга төште дә һичнәрсәдән шикләнмәгән бер кеше кыяфәте белән Балчык урамына таба атлады. Баягы тавышлар-атулар погром түгел, конвойдан качкан тоткыннарны куу иде. Хәзер ул тукталды. Тирә-як тыныч, төн.

Кар ява. Шәһәрнең өйләре, бакчалары ап-ак. Бөтен урамнар, калып итеп, йомшак ак мамык түшәгән кебек агарып, төнге ай астында ялтырап яталар. Аяк асты йомшак, рәхәт. Бөтен дөньяны ниндидер ак, саф күңеллелек чолгап алгандай тоела. Ниндидер бер кар бәйрәме эченә кереп киткән кебек сизәсең үзеңне.

Күгелҗем төтен болыты белән капланган бүлмәдән килеп чыгуга, Булатны шундый матур дөнья, шундый ак кар бәйрәме урап алды. Ул бер ел Урал башкортларында учитель булып торган иде. Уразгол атлы дәртле карт аучы аны чаңгыга өйрәтте. Зур таулар, карлы киң урманнар буенча үзе белән алып, җәнлеккә, куян, төлкегә, бүрегә сунарчылык өчен йөрүнең тәмен татытты.

Төнге ак ай нуры астында ялтыраган бу ак кар диңгезе Булатны шул урманнарга, шул карлы тауларга, Уразгол карт белән бүре куып йөргән көннәргә алып китте – шулар эченә буталып, аның гомеренең үткән кисәкләре берәм-берәм кайнап кичтеләр.

## LVIII
## АНА ЙӨРӘГЕ

Әсхәпҗамал карчык рәнҗи булыр. Сагынгандыр да, шелтәлидер дә, орышадыр да, изге теләкләр теләп җылыйдыр да. Ана күңеле шулай күп катлаулы бер нәрсә инде.

Шулай, көзнең караңгы авыр төннәренең берендә, кылычлы-мылтыклы кешеләр килделәр. Килделәр дә бөтен өйне тентеп, аның улын алып киттеләр. Бу – беренче хәсрәт, беренче белемсез куркыныч сәгать иде. Ананың йөрәге ярыла язды. Өч көн, өч төн үзен туктата алмый каты аглады. Ашаганы аш булмады, эчкәне су булмады. Күзенә йокы кермәде. Мәрхүм ире Гыйрфанга рәнҗеде, үзен, үзенең йомшаклыгын каргады:

– Шул инде, шул. Үземнән, бары үземнән генә килде. Алланың рәхмәтендә булсын, атасы мәрхүмнән генә булды. Мин әйттем: урыска бирмә, сурәтле китап каратма, дидем. Телемне алмады. Әйткәнемә колак салмады. Бала бит, бер баткач бата бирде. Башта адрес язарлык булсын, диделәр. Аның белән туктамады, тел белсен, кяфер урыс алдында аптырап, каушап, кызарып торырлык булмасын, диделәр. Күңелем сизенде, җаным курыкты, бу эшнең ахыры хәерле булмас дип йөрәгем типте. Әмма вакытында тыя алмадым. Атаның ирек куюына җиңелдем, баламның: «Әнкәй, мине кара калдырма», – дип җылавына җиңелдем. Ә адрескә тукталмады, урыс теле белән дә чикләнмәде, школасына да кереп китте, аны бетергәч, университетка әзерләнәм дип ашкынды. Бердәнберем иде, тыярга көчем җитмәде, теләсәм, тыйсам да, тыелмаган булыр иде, атасы мәрхүм кебек үзсүзле, кире холыклы булып үсте шул. Үсүенә шатландым. Акылына, яхшы сүзенә шатландым. Атасы мәрхүмне Кадыйр байларның конторыннан – урындагы хезмәтеннән кудылар. Дөньяга җигелдем. Казан эчендә беренче калфакчы булдым. Каланың иң матур энҗе калфакларын мин эшләдем. Шулай эшләп, өч җанны асрадым. Алланың рәхмәтендә булсын, атасы мәрхүм яшеннән янып үләреннән бер тәүлек элек әйтте – васыять кебек, үләрен алдан сизгән кебек әйтте: «Анасы, – диде, – инде минем җаным тыныч хәзер. Тәкъдир җитеп, бер-бер хәл булса, балалар ач калмас, калфакчы кулың аларга ризык табар», – диде. Кулым ризык тапты. Улым артыннан кечкенә чибәр Фәүзия кызым үсте – өсләренә карап яратып туя алмадым, туйганчы күрә алмадым. Инде менә бу хәсрәт каплады – бары да үземнән, үземнең йомшаклыгымнан. Алланың рәхмәтендә булсын, атасы мәрхүмнең тезгенне каты тота белмәвеннән булды... – дип, үзалдына сөйләнеп, кергән һәрбер кешегә шулай сөйләп җылады.

Бу җылауда каргыш бар, рәнҗеш тә бар, иге-чиге булмаган ярату да, сагыну да бар иде. Булат кайбер чаклар анасына үзенең тоткан юлын аңлатып

карарга теләде. Сыйныфлар көрәше турында, революция турында, социализм турында сөйләде. Ләкин Әсхәпҗамал әбинең карт миенә болар керә алмады.

Ул улын яратты. Тентүләр килгән саен, сөрелгән, ябылган, кыйналган саен, ач-ялангач калган, яшерен идән асты тормышында ябыгып, кибеп газапланган саен ныграк яратты. Социалист булганлык өчен түгел, үз баласы булганлык өчен, авыр газаплы тормыш кичергәнлек өчен яратты. Улының газабы арткан саен аның мәхәббәте артты. Бу мәхәббәт тау елгасы кебек көмештәй саф яки яз чәчәге кебек матур, күңелле булмады. Бу мәхәббәт каһәр белән, каргыш белән, рәнҗеш белән бергә катнашып кайнады. Шуңа күрә һичбер бетми торган көчкә, сүнми торган утка әйләнде.

Ара-тирә Зарифның кайтып кергән көннәре була. Карчык күңеле бу көннәрне бәйрәм итеп тоя. Елның көннәрен менә шул бәйрәмнәр белән исәпли торган булды.

Әмма Булатның кечкенә сеңлесе – аның үзенә гаҗәп ошаган, чибәр, үткен, уңган, ләкин бераз ябык, чандыр яшүсмер Фәүзия абзасының бу язмышына каршы бөтенләй башка төрле тойгы белән янды. Аны куркыныч эчендә сөйлиләр – яшь кызга бу ошый. Аны дошманга каршы туктаусыз сугыш фронтларында бара дип сөйлиләр, аның жандарларны алдап качуларын әкият кебек телдә йөртәләр – кызның яшь, кайнар хыялына болар ниндидер иске хикәяләрдәге батырны сурәтләп китерәләр. Ул җыламый, анасының рәнҗүле каргышларына каршы төшә:

– Юкны сөйләмә, әнкәй. Башы исән булсын диген, – дип туктата.

Карчыкның мие шул якка борыла:

– Илаһым, Тәңрем! Гомерен озын ит! Ризыгын киң кыл! Башы сау булсын! Газиз җанын сакла, илаһым, Тәңрем! Яшьлек – җүләрлек, диләр. Бу җүләрлекләр үтәр, минем Зарифым акылга утырыр, башкалар кебек юлга төшәр, башкалар кебек анасы, сеңлесе белән бергә, җәмәгатьле, бала-чагалы булып, тыныч, рәхәт гомер итәр, илаһым, Тәңрем, гомерен озын кыл, газиз җанын сакла! – дип, дога кыла башлый.

## LIX
## ШАКИР СОЛДАТ

Булат шәһәрнең урамнарын тыныч кичте. Арттан күләгә килгәне сизелмәде, шикләнерлек бернәрсә дә күренмәде. Балчык урамына борылырга дип кызурак атлаган минутта, кечкенә капка ачылды, аннан ниндидер сүзсез бер адәм чыкты да бу бара торган тар сукмакның нәкъ үзенә басып юлны кисте. Акрын тавыш белән:

– Тукта! – диде.

Бер секундка: «бәреп егыйм да качыйм» дигән уй яшен тизлеге белән

аның миен каплады. Ләкин шунда ук таныды:

– Фу! Чорт[1]! Син икәнсең, Галимов! Шпик дип торам!..

Галимов ике сүздә мәсьәләне аңлатты: калада бүген бик күп җирдә тентүләр бара, кичәдән бирле шул Балчык урамын, бигрәк тә Әсхәпҗамал карчык квартиры тирәсен ниндидер шикле адәмнәр әйләнеп йөриләр. Бу мәгълүм булгач, иптәшләр Галимовны җибәргәннәр: «Булат бүген анасына бармасын!» – дип әйтергә кушканнар.

Зариф, иптәшләрнең бу турыдагы сүзләрен тыңлагач, баскан җирендә бер минут уйланып катып торды: бу шикләнүгә буйсыныргамы? Әллә, вәгъдә буенча, берничә сәгатькә генә анасы белән сеңлесенә кереп чыгаргамы? Тел белән җавап бирмәде:

– Әйдә, алайса, Ризванга киттек! Минем анда эшем бар! – диде дә, кинәт борылып, Вахитов квартирына таба атлады.

Урам капкадан кергәч сул якта – түбән, тәбәнәк иске агач өй. Эчке як тәрәзәдә зәгыйфь кенә якты күренә. Галимов озын кунычлы итеге белән кар җырып барды да акрын гына шул тәрәзәгә ике тапкыр чиертте. Эчтәге ут каядыр күчте, анда дөм-караңгы булып калды. Болар, кар каплаган сукмак белән әйләнеп, яңадан ишеккә барганда, аннан чәчләрен тузгып, йокылы күзен тырнап Вахитов килеп чыкты. Өстендә тужурка, сакал-мыегы кырылган, кулында лампа. Ул карлыккан тавыш белән:

– Фу, таныр да хәл юк. Булат, синме? Әйдә! – диде дә төнге мөсафирларны, ишек-бусагаларга лампа яктысын төшерергә тырыша биреп, эчкә алып керде.

Аның хатыны авылга киткән икән. Өендә тәртип юк. Мич алдында утыннары, йомычкалары таралып ята. Шунда ук бозлы чиләк, эреп, тирә-ягын юешләп утыра. Бүлмәнең бер ягында, караватта мендәр, иске чикмән. Булат боларга игътибар итмәде, ишектән керә-керүгә Ризванның мендәре-чикмәне янында аунаган китап белән берничә кәгазь кисәгенә ташланды:

– Нәрсә укыйсың бу арада?

Ризванның бер дә елмаймыйча, һәркайчан текәлеп караучан күзләрендә аз гына шатлык күренде:

– Әйтмә, Зариф абый! Бу арада миңа агып кына килә! Коляга рәхмәт, ул минем авызымны чишмәгә тыкты, – дип, бу күк язулы яшерен басма кәгазь белән партиянең үзәк органын кайдан, ничек алып баруын сөйләде.

Булат хәтерләп көлде:

– Менә шул язуның татарчасын чыгартырга әллә кайчан Гәрәйгә тапшырылган иде. Аны сөргәч, безнең әйберләрне басучы шәкертләр, ни

---

[1] *Чорт* – (черт) – шайтан.

эшләргә белми аптырап, Акчулпановка киңәшкәннәр икән, ул кире кайтарган – шулай итеп, әлегечә татарчасын чыгармый токтан. Менә эт!

Галимов яман сүз белән сүгенде, ата-бабасы белән сагынды:

– Син дә, Булат, йомшакланасың; Гәрәйнеке рас: андыйлар аякка мунчала булып кына уралалар алар, – диде.

Вахитов белән Галимов икесе дә революция дулкыны астында уянып, Булатның сәяси түгәрәкләрен кичкән егетләр иде. Болар ничектер аңа олылабрак та карыйлар, бөтенләй үз иптәшләре кебек тә тоталар. Сүзләрендә дә «абый» дип тә куялар, үзара сөйләшкән кебек, исеме яисә фамилиясе белән дә йөртәләр. Вахитов үзенең китап байлыкларын күрсәтү өчен, чоланга яшерелгәннәрен дә кертеп, Булат алдына ташлады, Галимов, тиз генә Әсхәпҗамал карчыкка барып, Зарифның бүген кайта алмавының сәбәбен әйтеп килде. Шул арада өстен-башын, ап-ак кар каплаган бүрегеннән, кыска туныннан карны селкә-селкә сөйләде:

– Карчыкның җүне калмаган, малай. Мине күргәч, җылады да җибәрде: тагы эләктеме, ди. Юк, мин әйтәм, эләкмәде, әби, тик саклык өчен бүген аңа кайтырга без кушмадык, дигән булам. Соң, кайчан мин аны күрәм инде? дип җылый бирә. Иртәгә, дидем. Шулай бит?..

Ризван хатын-кыз эшенә җайлы гына икән. Шул арада самоварын да гөрләтеп кайнатты, кечкенә ачык агач шүрлектән чынаягын, икмәген, чәй-шикәрен дә алып буяусыз агач өстәлгә тезде. Мичтән кызган ит кисәге чыгарды.

Әсхәпҗамал әбинең җылавыннан сүзне әле күптән түгел завод алдында булып үткән якшәмбе бәрелешендә үтерелгән Сәфәр картка күчергән Галимов кинәт Булатка карады да күзе белән кадалып сорады:

– Кара әле, Зариф абый! Теге Шакирың нинди нәрсә синең? Эзләп җөдәтте бит: кирәк иде, ди. Үзе кызык, мин әйтәм, син монда ни эшләп йөрисең? дим. Ни эшлим? Акыл җыям. Корал эзлим, ди. Мин ачык әйтергә курыктым. Кем белә аны? Әллә бер шпик эт булыр, дим.

Булат актарган китап-гәзитләреннән башын күтәрде. Көлә төште:

– Их! Син аны үзеңә якынрак тарт. Бик җүнле мужик ул. Ут-су кичкән нәрсә. Төрмә күргән. Япон сугышында булган. Үзенең авыл читендә тавык кетәге кебек бер балчык өе бар да кәҗә тәкәсе кебек кечкенә аты бар. Шул ат белән бер төндә мине җитмеш чакрым чаптырды. Ул булмаса, эләктергәннәр иде. Тик шул, эләктем дигәндә, тегеләрнең авызыннан тартып алды, – диде.

Үзенә дигән бер чокырны салгач, чәйне эчә-эчә, Шакир солдат ярдәме белән ничек Кама-Идел аша кичкәнен сөйләде.

Себердән качып кайтканда, актык стансаларга якынлашкач, поездда да Булатны ниндидер шикләнү баса. Ул тирә-ягын күләгәләр, филерлар,

шпиклар белән чолганган кебек, бер тозак эчендә кебек сизә. Чыдаша алмый. Таштамакка җиткәч, сикереп төшә дә, ике кечкенә авыл аша үтеп, караңгы кичтә Шакир солдатка килеп керә. Бу әйтә: «Миндә ярамый. Мине монда күз өстендә каш кебек күзәтәләр», – ди дә, кечкенә атын җигеп, җиде төн уртасында алып китә. Казанга озатырга кирәк. Ләкин уртада Идел бар. Үзенең бөтен исәбе буенча, Идел токкан булырга тиеш дип ышанган иде Шакир. Әмма исәбе ялгыш чыкты. Таң алдында ярга килеп туктасалар, Идел тотмаган, ярдан-ярга тулышып, тапташып, көзге боз ага. Солдат, башына тау төшкән кебек, каты сулап куя, кышны, Иделне, бозны анасы-атасы белән сүгә дә Булатка карый: «Әйт дөрестен. Менә шул бозлар өстеннән чыгып китәргә синең йөрәгең җитәрме?» – ди. Булат туңган бит, каткан авыз белән шаркылдап көлеп җибәрә: «Әйдә! Миннән эш калмас, үлсәк, үлем хак!» – ди. Эшнең куркынычы шунда: бу җирләрдә озак калсаң да, кире стансага кайтсаң да, жандарлар тозагының бер җәтмәсенә эләгүең бик якын хәл. Эләктерсәләр инде, Енисейгә генә озатмаслар, Якутстанның ерак, караңгы почмакларына ташларлар. Моны Шакир да, Зариф та бик яхшы аңлыйлар. Ләкин бу турыда сүз әрәм итешеп тормадылар. Булат, туңган аякларын җылыту өчен, каткан балчык өстендә, түбәндә, яр астында үзалдына бии-бии калды. Шакир ярты чакрымдагы авылга атын илтеп, аннан аркан, озын колга белән өч егет алып килде. Зур буйлы, таза, шаян егетләр икән. Ләкин эштә сынаша башлагач, бары да бертөсле булып чыкмады.

Башына колаклы бүрек, аягына пима, өстенә кара тун кигән, муенына шарф ураган Әхмәр, яр буена килеп, Идел бозларының тыгызланып, берсе өстенә берсе менеп, котырып акканын күрүгә киреләнә.

– Булмас, Шакир абзыкай. Гаеп итмә: минем катыным, өч балам бар. Җан газиз бит! – ди дә, арканын, колгасын җилкәсенә салып, авылга таба тая.

Икенче егет дәшми-тынмый Идел бозларына карап тора-тора да, авыз эченнән иман укып, ярдан берничә сажин Иделгә керә. Шул арада тау-тау булып, боз боларга таба ишерелә. Егет, агарынып, туктый, артына таба чигенә башлый.

– Юк, Шакир кайнага! Йөрәк чыдамас, менә хәзер калтырап егылырга торам! – ди,

Шакир сугышта, солдатта, төрмәдә, алган барлык начар сүгенү сүзләре белән боларны кабахәтләп куа:

– Чәнчелеп китегез, анагызны куян үпкән нәрсәләр! Калган өченче егеткә карап кычкыра:

– Син ни торасың? Тезең калтырар. Бар, син дә кайтып кит, мәми авыз! – ди.

Ләкин нык икән:

– Әйдә, күп лыгырдама. Үзеңне бел. Чалбарың пычранмасын! – ди дә бозларның иң куркыныч кайнашкан җирләреннән таягын шаяртып сикерә-сикерә, алдан юл ярып, кыюланып китә...

Булат күптән түгел башыннан кичкән бу вакыйганы сөйләде дә Галимовның баягы соравына ялгады:

– Менә шул егет ул синең Шакир дигәнең! Безгә бик кирәк кеше. Крәстиән белән багланышка беренче элемент, – диде. Тагы өстәде: – Әнә сиңа әйткән бит: «Акыл җыям, корал эзлим» дип. Аның саташканы шул инде. Миңа да юл буенча мең кабат тукыды: «Без, ди, кара халык – кара сарык инде. Без, ди, яктылыкны каладан көтәбез. Кая, нәрсәгез бар? Безнең эш мужикча булыр: үзем кебек ярлы-ябагайны җыйнармын да... Дүрт чакрымда Әликсәй бояры бар. Шуны басарбыз... Безгә нәрсә? Балта, сәнәк. Күсәк. Калдык-постык мылтык, күгәргән сөңге кисәкләре дә ярый. Боярның җиренә исәп юк. Урманы менә безнең басу киртәсе яныннан алып ун чакрым буенча ишерелеп ята. Бер чыбыркы сабына агач алсаң – алты ай баструк[1]. Менә син сөйләш аның белән. Мин егетләрне чарладым. Барабыз да басабыз. Каршы тора башласа, сарайларына кызыл әтәч җибәрәбез, үзен, катынын, бөтен бала-чагасын янган утка чәнчелдерәбез... Этнең токымы калмасын! Әмма, малай, аның да арты сизә: ул хәзер, калага барып, мылтыклы, хәнҗәрле егерме чиркәс яллаган, ди, шулардан үзен саклата имеш, ди. Ну, безне чиркәс куркыта алмас, без яу булып барып бассак, кая керергә җир тапмаслар. Ну, син әйт: каладан ни ярдәм? Безгә кем юл күрсәтер? Мылтык бармы?» – дип минем колагымны кимерде. Безгә бу турыда уйларга кирәк. Минем бүген, Ризван, сиңа килүем – менә шул турыда сөйләшер өчен, бер эш күрер өчен! Син ни әйтерсең? – дип, Зариф иптәшләренең күзләренә кадалды.

Идел хикәясенең мондый рәвешкә кереп бетүе Вахитовның канын кайнатып җибәрде. Ул, кыза биреп, сикереп торды:

– Безгә нәрсә? Без – кечкенә кеше. Парткомга әйт: җибәрсеннәр. Мин әйтәм!.. Их, малай, корал ягы начар, ул чакта бөтен магазин таланды, әллә кая булып бетте ич, безгә бары тик алтмыш револьвер эләкте... Ичмаса, Гәрәй Солтан да юк, Исрафил да юк бит!

Ясалган чынаяклар суынды, кискән ит тә онытылды, – өчәүләп шул мәсьәлә эченә кереп югалдылар.

## LX
## ВАХИТОВНЫҢ ҖАВАБЫ

Ризван, башлап, курка-куркарак Булатның беренче түгәрәгенә

---

[1] *Баструк* – төрмә, зиндан.

килгәндә, юаш, сәяси аңсыз бер эшче егет иде. Беренче катнашкан демонстрация чагында, полиция белән бәрелеш китә. Урамга түшәлгән ташларны каерып жандарлар өстенә бәрә башлыйлар. Вахитов яшьлек кызуы белән ачудан кабара, башкалар артыннан ияреп, каера-каера зур ташлар ала да бер-бер артлы ике жандарның башына кундыра. Шул беренче сугыш – ике сәгатьлек бер вакыт эчендә – унсигез яшьлек яшь, ялкынлы егетне канатландырып җибәрде. Вәли Хөснетдинев атлы бер эшче большевик бар иде. Шул моны коралга өйрәтә. Шул аңа Кавказлы Гәрәй Солтаннарның боевик отрядларына керергә димли. Шунда кереп, беренче тапкыр маузер алган минут – аның гомеренең беренче бәйрәме булды. Ул үзендә бөтен дөньяга каршы сугышырлык көч бар кебек тоя башлады. Шулай тиз үсеп, чыныгып, каты сугыш дулкыннарында Ризван Вахитовтан батыр энтузиаст ясап чыгардылар. Революция хәрәкәтләренең сыйнфый сугышлар уты белән йөрәкләре ялкынланып, көрәш мәйданына ташланган меңнәр, йөз меңнәрчә эшче яшьләр сафында безнең Ризван да беренчеләрдән булып китте. Аны иптәшләре яратты гына түгел, вак-төяк татар полицейскийлар аңардан шүрли башладылар, юк-бар өчен аңа бәйләнмәскә – күрмәмешкә салынырга тырыша торган булдылар. Эш шул чиккә барды: кайбер вакыт хатыннар, карчыклар полициянең хаксызлыклары өстеннән Вахитовка килеп зарлана башладылар. Ризван эченнән мактана төшеп көлсә дә, тыштан сер бирми: «Ярый, карармын, ул этләрне өйрәтәсе бар әле», – дип җибәрә иде. Ләкин бер трагедия бар – ул эчә. Бик нык эчә. Үзен тыя алмый эчә. Эш калдырмый, көрәш юлыннан язмый. Әмма һаман эчә. Баштарак аңа якын иптәшләре шелтә ясадылар. Ул үтмәгәч, Разия, аны чакырып, ике сәгать буе сөйләште:

– Ташла! Син татар пролетариатының алдынгы җитәкчеләреннән булып үсәчәк кеше. Бу сине һәлак итә. Ташла! – диде.

Егет дәшми-нитми сүзсез тыңлап торды да:

– Ярый, карап карармын әле, – дип, икеле җавап кайтарды. Ләкин үзе шул көннән аракыга якын бармады, бер тамчы капмас булды.

Шул арада якын стансада[1] экспроприация[2] ясала. Шикләнеп, боевикларны кулга ала башлыйлар. Тыштан куркып, эчтән ничек бетерергә белми йөргән ике полицейский аның өстеннән ялган әләк бирәләр. Шул сәгате белән пристав үзе өч полицейский белән килә дә Вахитовны богаулап ала, участкага китерә дә:

– Әйт, тагы кемнәр бар иде? Оештыручы кем иде? – дип, егетне кыйнарга тотына.

---

[1] *Станса* – станция.

[2] *Экспроприация* – көч кулланып талау.

Вахитов:

– Минем катнашканым юк, мин бернәрсә белмим, – ди.

Кызган пристав, ачуыннан каралып, Ризванны таш идәнгә ега да итекле аягы белән күкрәген таптый, җенләнеп, котырып кычкырып, аның өстендә биергә керешә. Тоткынның кабыргалары сына, авызыннан, борыныннан шарлап кан китә. Шунда да, ярым һушыннан язган килеш, тешен кысып, усал кычкыра:

– Үтер! Үтер! Анда да син эткә бер сүз әйтмәм! – дип ыңгыраша.

Калын, таза пристав тагын яман котыра, шул басурманнан сүз әйттерә алмауның хурлыгы аның миен каплый, йөрәген кайната; ул тагы шашып, җенләнеп, тоткынның битендә, күкрәгендә итек белән биергә ташлана. Ләкин сүз ала алмый, үзе арып, хәлсезләнеп:

– Тфү, басурман! – ди дә, ярты үлек хәлдә яткан егеткә төкереп, эчәргә чыгып китә.

Ризванны һушыннан язган килеш аягыннан өстерәп, эчке камерага кертәләр дә таш идәнгә, кан эчендә ташлап, өстеннән биклиләр.

Күпмедер вакыт үткәч, шул ук участкага караңгы төндә ике исерек сукбайны китереп ябалар. Болар күп ябылган, күп кыйналган, күпне кичергән адәмнәр иде. Караңгыда арттан төрткәләп кертү белән берсе аяк астындагы гәүдәгә абынып егыла язды:

– Фу, чорт! Әллә үлек! Әллә исерек! Монда берәү ята ич! – дип сүгенеп, шырпы яндырды.

Карыйлар: таш идәндә кан эчендә кыйналган-изелгән яшь егет ята. Сулышы бармы? – бар. Йөрәге сугамы? – суга. Алайса, малаең бетмәгән әле. Исләре китмәде. Махри төреп, тәмәке тарттылар да ишек шакылдатып ашарга сорадылар. Каравыл стражник сүгенде. Әмма үзе китмәде. Ике якның иң сайланган сүзләр белән сүгешүенең нәтиҗәсе шул булды: каравыл стражник каядыр барып, боларга аракы, суган, кыяр, арыш икмәге китерде. Савытны сугып ачуга, иң элек аның үзенә бирделәр. Ул күпме эчелгәнне чамалый-чамалый голт-голт йотты да, суган белән икмәк кисәген каба-каба, кечкенә тәрәзә ишеген япты. Сукбайлар үзләре белән бергә идәндәге егетне дә онытмадылар. Болар дөньяда һәммә авыруга каршы тик бер генә дару бар, ул да – аракы дип ышанучылардан иделәр. Ризванның авызын көчләп ачтылар, тешләрен каердылар да бугазына көчләп аракы салдылар, һушсыз егет йотып алды; җитмәсә, тәмләп иреннәрен ялап куйды. Моны күргәч, сукбайлар рәхәтләнеп көлеп үк җибәрделәр:

– Ничего! Аракы кереп өлгерсә, адәм үлми ул! – дигәләп, үз авызларыннан өзә-өзә Вахитовның бугазына барлыгы стаканга якын аракы койдылар. Төн буе шуның белән азапланып чыктылар.

Таңга таба Ризван, ыңгыраша биреп, торып утырды да як-ягына каранды. Башта аптырады. Тегеләр, бер-бер артлы шырпы яндырып, хәлне сөйләделәр.

Шул көннең иртәсендә аны зинданның больницасына күчерделәр. Сукбайларның эше кечкенә икән. Аларны ике көннән бөтенләй чыгарып җибәрделәр. Ләкин Вахитовны терелтү вакыйгасын алар онытa алмадылар: уңга да, сулга да, сораганга да, сорамаганга да шуны сөйләп йөрделәр: «Егетне без коткардык, эт авыз пристав бөтенләй бетергән иде үзен», – дип, борчак атудан туктамадылар.

Вахитовныц хаксызга кыйналып имгәнүе халык арасында бик күп сүз, шау-шу, әңгәмә тудырды, гәзитләрдә, эшче митингларда протест белән һаман тавыш күтәрә торган булдылар. Шул араларда гына шәһәр зинданында ике тоткынның үз кан тамырларын үзләре кисеп, кан күле эчендә үлүләре трагедиясе дә бик зур уңайсыз вакыйгага әйләнгән чак иде. Теге стансадагы талауларга беркетергә бертөрле дә материал таптыра алмаганга, прокурор, ахыр барып, Вахитовны чыгарырга мәҗбүр булды. Ризван, өч ай больницада ятып, сынган кабыргаларын, кул-аяк сөякләрен төзәтә дә яңадан элеккечә эшкә, көрәшкә тотына. Ләкин кара күләгә тагы калмый – участкадагы сукбайларның терелтүе белән башланган гадәт тагы ташлана алмый – тагы ялганып китә. Әмма көн-төн кайнаган көрәш вакыйгалары аны алай бик артык күзгә бәрелеп тору рәвешенә керергә юл бирмиләр хәзер. Бу кыйналу – егетнең күкрәк сөякләрен, кабыргаларын сындырса да, ул яшь егетне тимергә әйләндерә, һәрвакыт кешеләрнең зәгыйфь ягына бармак төртә торган Гәрәй Солтан аны, шаярыбрак: «Уң кулым», – дип йөртә. Ул эш ташлау комитетында Булатлар, Колялар белән янәшә барды. Алар ни әйтер дип, авыз ачып көтмәде – бу эшкә үз көче, үз карашы, үз фикере белән катнашты. Аңарда яшьлек канының котырып ташкан чагы иде. Бераз мактана биреп, «Вахитовтан башка кайсыгыз моны булдыра ала соң!» дигән кебек бераз борынны күтәрә төшеп, кайда куркыныч, аның йөрәге шунда ташланырга ашкына торган булды, шул кызу көрәшләр эчендә аның эчү гадәте бөтенләй ташланды, онытылды.

Кораллы күтәрелеш, диләр. Эшче сафлар шуңа хәзерлек турында яналар. Һәр авырлыкны, һәр җиңелүне шул кораллы күтәрелеш чаралары белән яндырып бетерергә өмит баглыйлар. Һәрбер тапталган саен, дошманның һәрбер җиңүе саен, жандарның, гаскәрләрнең, палачның һәрбер ерткычлыгы саен, зур масса хәрәкәтләрендә җиңелеп, өмитсезләнә башлау куркынычы килгән саен – алдагы якты юл булып, маяк булып шул кораллы күтәрелеш килеп баса. Эш ташлауларның зур җиңелүләр белән беткәнен ишеткәндә дә, Петербургта эшче депутатлары Советы[83*] президиумын кулга

алганнар, дигән хәбәр таралганда да, фронтның башка күп тармакларында күңелгә авыр вакыйгалар булганда да, һаман-һаман, алдагы зур бер моментка карап, көч-гайрәт арттырдылар, шул кораллы күтәрелеш көннәрендә дошманны бөтенләй җиңәр өчен актык хәзерлеккә күңел, куәт беркеттеләр. Ул көннәрнең башка алдынгы пролетарлары кебек, Вахитов та менә шул хәзерлек утында яна, шул көннәрдә дошманны яңадан кузгала алмаслык итеп бетерү, юк итү өмите эчендә ялкынланып көрәш фронтында бара иде.

Булат аңа Идел аркылы чыгу хикәясен Шакир солдатның соравы белән тәмамлап: «Җә, син ни әйтәсең?» – дип, күзгә кадалгач, һәр куркыныч фронтка беренче ташлануны үзенә мактаулы бурыч итеп алган энтузиаст Ризванның йөрәге кайнап китте. Ул үз эченнән карарга килде: «Шулаймы? Анда мужик акылга, җитәкчегә мохтаҗмы? Үзем шунда китсәм ни эшләр?» – дип уйланып кызды:

– Менә, – диде, – минем җавабым шул! Парткомга әйт. Җибәрсеннәр. Китәм. Менә Галимовны да алам. Тагы берничә егет барыр. Дөньясын җимерербез. Их, Исрафил дә булса! Әрәм иттеләр бит арысланны! – дип, утлы күзләре белән Булатка кадалды.

Бу караш астында Зариф үзе яшәргәндәй, аның үз йөрәгенә эшче сафындагы көрәш дәрте шул Ризван күзләре аркылы агылып кергәндәй булды. Әгәр митинг булса, әгәр хәзер трибунага чыкса, үз гомеренең иң яхшы сүзләрен иң оста рәвештә әйтә белер кебек сизенде.

Ләкин дәшмәде, шул ялкын эчендә уянган утлар белән чолганып уйланды – үзенә нидер йотты. Шул минут урам яктан ике күләгә үтеп китә. Берсе, тукталып, кире борыла да тагып алга атлый. Галимов чыдамады:

– Кем булыр? Мин бая сүз бүләсем килмәде, ике тапкыр менә шулай үтәләр инде, диде.

Зариф, эшне аңлаган кебек, кинәт торды да Вахитовка кул бирде:

– Менә нәрсә, Ризван, мин бүген сиңа менә шул эш турында сөйләшү өчен кергән идем. Парткомга куярмын. Син һәр минут әзер тор! – диде дә, тиз-тиз киенеп, йортка чыкты, Галимовның күрсәтүе буенча, урамга түгел, арткы койма белән барып, чиркәү бакчасы аша сызды. Егетләр кире өйгә керделәр.

## LXI
## ЧӘКЧӘК КИЛГӘН

Тегендә, Госман-Ногман мәктәбендә, яһүд погромына ошаш шау-шу, атыш ишетелү белән киенергә тотынган кешеләр тиз-тиз таралдылар. Әдәби кичәне башкару өчен: Разия туташ, җырчы Сәхип, Фәхри, Акчулпан, Тангатаров – барлыгы биш кешелек комиссия сайладылар да эшне шуларга

тапшырдылар. Фәхри рәислек итәргә билгеләнде. Җыю-чакыру аңа йөкләнде. Боларны бетергәч, Акчулпанов Разиягә килде:

– Ялгыз куркырсыз. Әйдәгез озатып куйыйм! – диде.

Туташ кинәт кашын җыерды, эченнән бераз чирканып: «Фи, балалык!» – дип әйтеп куя язды. Шулай да тыштан тыелды, тик шаян сүз белән чәнчеп:

– Ул нинди озату тагын? Әллә сез андый буржуазный предрассудокларны[1] һаман ташлап җитә алмыйсызмыни? – дип, дусча елмайды: – Рәхмәт, Хәйдәр. Минем Урмановта ашыгыч эшем бар. Аны көтеп, азрак калам! – диде.

Акчулпанов эченнән әрнеп хурланды:

«Бу нинди кыйлану инде бу? Имеш, буржуазный предрассудок! Әллә кеше, социалист булдым дигәч тә, грубый мужикка әйләнергә тиешме?» – дип зәһәрләнеп уйланды.

Реалист формадагы шинелен, кокардалы фуражкасын киде дә, шаулап чыгып барган яшьләр компаниясенә кушылып, гимназист Таңгатарның култыгыннан алды. Ләкин болар эчендә дә күңеленә юаныч таба алмады.

Ул үзен революционер дип, социал-демократ дип саный. Самодержавиегә генә түгел, буржуазиягә, капитализмга каршы социализм өчен көрәшкә чыккан революционер дип карый. Әле революция болай киңәеп башланмаган, 9 нчы гыйнвар вакыйгалары[84*] булмаган, Япон сугышы[85*] да ачылмаган иде әле. Петербурдан кайткан бер рус, таныш студент, димләве буенча, Хәйдәр Акчулпанов Марксны укый башлады. Реальный училищеның алтынчы сыйныфында чакта ук үзе кебек реалистлардан бер яшерен сәяси түгәрәк төзеде. Моның өчен ничә тапкыр шелтә алды. Директор үз кабинетына чакырып, ишек бикләп, аерым алын үгетләде:

– Синең фамилияң – иске, шәрәфле дворян-морза фамилиясе. Тарихи фамилия. Синең бабаларың Романовлар тәхете[86*] алдында зур хезмәтләр күрсәткән, патшаның илтифатын казанган тарихи кешеләр. Мондый бозык эшләр белән чуалу сиңа килешми, син үзеңне һәлак итмә! – дип, озак-озак шелтә катнаш үгет бирде.

Хәйдәр Акчулпанов тыш яктан аңлаган, буйсынган төс күрсәтте. Ләкин кире чигенмәде, Марксны укудан туктамады, тик бу үгетләрдән соң тирән яшеренде генә, үзе, Госман аркылы бәйләнеш ясагач, приказчиклар, гимназистлар, шәкертләр арасында төзелгән түгәрәкләрдә дә ул иң нык эшләүче, белем ягыннан нык хәзерлекле кешеләрнең берсе булып китте. Ул хәзер дә иптәшләре арасында икътисадый мәсьәләләрдә төпле белүче булып

---

[1] *Буржуазный предрассудоклар* – буржуаз хорафатлар.

карала. Аны яратып тыңлыйлар. Ләкин нигәдер, менә шул йолкыш Тангатарлар чаклы да, ул бу гөж килеп кайнашкан яшьләр эчендә үз кешесе булып китә алмый. Әнә хәзер дә кара: Госманның баскычыннан төшеп җитмиләр, шул Тангатар әллә кайдан танышып өлгергән фәкыйрь, оялчан, начар киемле, ябык, кыюсыз шәкертләрне кочаклап ала да, бергә туып үскән кебек, мыж килеп серләшеп, әңгәмәләшеп бара. Әйтерсең, ул аларның гомерлек юлдашлары инде!... Үзенең бите сипкел, фуражкасы ямьшәйгән, терсәкләре җиңнәрен төртеп чыгарга бара. Шулай да ул моны күрми, компания эчендә суга җибәрелгән балык кебек рәхәтләнеп йөзә. Хәйдәр болардан аерылмый бергә барды. Ләкин дәшмәде, сүзгә катнаша алмады, кайдан тотынырга сүз дә табалмады. Сүзсез барган саен уйлары да караңгыланды, авырланды: «Бу нindидер бер бәхетсезлек бит. Болар белән генә түгел, теге Гәрәй Солтан белән дә килешеп бетеп булмый. Ул да мине дошман саный, ике сүзнең берендә: «Алай кыйланса, арадан куарга кирәк!» дип кычкыра икән. Ул көн Госман абзый шулайрак ычкындырды. Бу нигә болай? Мин эшләмимме? Мин, алар белән сафта торып, революция өчен сугышка бармыйммы?»

Госман залында, башкалар чыгып беткәндә, теге икәү калганнар иде. Разия:

– Безнең юллар бер якка таба ич! Әйдә киттекме? – дип, Урмановның беләгенә килеп асылды. Якын, җылы, дус бик аз гына иркәле тавыш белән: – Уф, бик ардым... Нигә шул чаклы сузалар, билләһи! Туеп бетәсең! – дип өстәде. Госман квартирыннан чыгып, урам яктан баскычтан төшә-төшә: – Ходаем, бер дә генә тота белмисез инде! – дип, аз гына, сак кына чытлыклана төшеп, егетнең култыгына ипләбрәк керде.

Караңгы урам буйлап сөйләшә-сөйләшә киттеләр.

Туташ нидер әйтергә тели дә, ничек башлап китәргә аптыраган кебегрәк сизелә иде. Моңарчы булмаган бер якынлык белән Урмановка ныграк сыенды да акрын, эчке тавыш белән, көтелмәгәндә, көтелмәгән бер әйбер турында – үзен соңгы ай буенча газаплаган бер мәсьәләсен, яшерен серен ача салды:

– Давыт, – диде, – сез теге фабрикант Абыйзовны беләсезме?

Урманов, гаҗәпләнеп, туташка карады:

– Беләм. Ул нигә кирәк булды сезгә?

Кыз үзенең дулкынланып барган зур тулы гәүдәсе белән егеткә тагын ныграк сырылды:

– Шуның сөяркә марҗасы бар икән, акча түләп, читтә асрата торган ике баласы бар икән, диләр. Дөресме икән?

Давыт, сүзнең кая таба барганын сизмичә, каты кисте, үзе дә белмичә,

«син» белән башлап китте:

– Менә гаҗәп! Ул гайбәт сиңа ни өчен кирәкте? – дип, кызның күзләренә карады.

Бу вакыт алар Разияләрнең кечкенә, чибәр өйләренә килеп җиткәннәр иде инде. Урам яклап ике якка ачылмалы ак ишек төбенә, баскычка баскан килеш, туташ күтелмәгәндә егетнең кулын алып кысты да «син»гә күчте.

– Ул эш минем үземә дә гаҗәбрәк тоелды. Беләмсең, менә шул фабрикант, дустым Гәүһәрнең анасы аркылы, миңа предложение ясаган, татарча әйтсәң, миңа яучы җибәрткән! Беләсеңме, нәрсә ди икән: сүземне кайтармаслык булса, анасына визит белән барырмын, хатыным булса, теләсә укуын да туктатмам, теләсә үзенә аерым сарай салып бирермен, дөньясын җәннәт итәрмен, дигән. Йә, Давыт, көлке ич инде бу.

Урманов сызгырып җибәрде. Көләргә дә, сүгенергә дә сүз җиткерә алмады. Ул фабрикант Абыйзовны күргәне юк, ләкин татар гәзитләре аркылы аларның Семберме, Пензамы ягындагы фабрикалары турында кайбер нәрсә укыганы бар иде. Абыйзовны каты, усал бай, ләкин яңа фикерле, европеец буржуа имеш, диләр. Йосыфҗан аны бер ягы белән мактап, шунда ук тагы яшерен, яшь, матур сөяркә марҗасын бутап, уйнаштан туган ике баласы турында мыскыллап сөйләштергәли иде.

Бу турыда сүз нык сузылды. Урманов сөйли-сөйли дә бер нәрсәгә кайта:

– Кара син аны! Үзенең яшерен хатыны-сөяркәсе, ике баласы өстенә, Разия, сине сатып алырга план корганмыни? Ничек кенә европалашмасын, эше бөтенләй татар байларынча килеп чыккан, – дип кабатлый иде. Шуның белән бергә аңарда бик аз, бик кечкенә шөбһә уянды. Туташ ни өчендер күбрәк мәсьәләнең рәсми ягын җентекли: ике бала кем исемендә икән, ул марҗасы ничек, хөкем белән мал дауламыймы икән, әллә, кирәген алып, кире чигенергә ризаландымы икән, дигән кебек моментлар тирәсендә буталды. Шул нәрсә Урмановның күңеленә шик кертте: «Әллә булмаса, кызның күзе фабрикантның алтыннарына, җефәкләренә, зур сарайларына кызамы икән? Әллә ике арада киртә – тик шул рәсми як кынамы икән?» – дип уйлап куйды.

Туташның сизгер йөрәге бу шикне тотып алды, егетнең күңелен тынычландыру өчен аңа тагын да якынрак сыланды. Давыт китәргә кузгалгач, каты тотты, җибәрәсе килмәде:

– Мин, – диде, – чыгып китәм дә югалам. Иртә китәм дә кич кайтам. Көн буе түгәрәкләрдә, җыелышларда кайнашам. Анакай кайткан саен борчылып каршы ала... Минем хәзерге социалист дусларымны әллә нинди разбойниклар дип уйлый бугай. Син, Давыт, бер кереп, аның белән танышыр идең, – дип, хәзер үк өенә чакырды.

Урманов күнә алмады.

– Юк, – диде, чакыруыңа рәхмәт. Бер керермен. Хәзер булмый. Мине анда көтәләр булыр! – дип, китәргә әйтеп куйды.

Кыз баскычтан кире атылып төште. Күзләре зурайды. Ашыгып, яңадан үзенә тартты:

– Ул нинди сүз? Кемнәр көтә? Әллә берәр хәл бармы?

Урманов көлде:

– Юк. Бернәрсә дә юк. Син уйлаганча түгел, бөтенләй башка әйбер! – дип сөйләп бирде.

Аның авылда сеңлесе бар. Менә шул быел кияүгә чыккан икән. Туй алдыннан берьюлы ике хат килә. Авылга чакыралар. Сеңлесе үзенең булачак туе турында язарга тартынса да, кайтырга чакыруында бик ихлас: «Давыт абый, бик сагындык. Бер кайтып китәр идең!» – ди. Анасы Фәгыйлә карчык та улының иркенә бер дә куймый. «Гомердә бер килә торган шатлык. Сеңлеңне мәхрүм итмә. Кайт. Сүземне тыңламасаң, мәңге бәхил булмам!» – ди. Революция көрәшенең мондый кызу кайнаган көннәрендә Давыт, әлбәттә, авылга туйга кайтып йөри алмый. Кичә генә тагы хат бар. Сеңел бик үпкәләп яза:

«Өзелеп көткән идек. Туган итмәдең. Кеше арасында йөзебез кызарды!» – ди.

Үзе шулай үпкәләсә дә, абзасына әллә ничаклы туй күчтәнәчләре – чәкчәкләр, казлар, казылыклар, кактөшләр, бәлешләр, ләвәшләр җибәргән. Буйдак егет, үзе бу чаклы ашамлыкларның очына чыгарга җай табылмаганга, иптәшләр белән җыелып ашарга карар бирә. Үзенең бүлмәсе кечкенә, савыт-сабасы юк, карап, хәзерләп ашатырга кеше дә юк. Шуңа күрә дә күрше өйдә торучы Габдулла абзыйның хатыны Хәдичә җиңгидән үтенә:

– Менә шундый-шундый әйберләр бар. Син, апа, һәммәсен алып кит тә үзең белгәнчә әзерлә. Без бер ун ач бүре җыелып сиңа кунакка килербез, – ди.

Давыт Урмановның: «Мине анда көтәләр булыр!» – дигәне менә шул сый мәҗлесе иде.

Егетнең, сүзе бетәр-бетмәс, Разия, баскычтан сикереп, Давытка ташланды, ярым русча, ярым иске морза теле белән, кызып, үпкәләргә тотынды. Үзен чит иткәнгә дә бәйләнде, башкалар барган җиргә мине чакырмыйлар дип тә тиргәде, боларның һәммәсеннән үзенә ышанмауны нәтиҗәләп чыгарды, ахыры шул булды, Давытның: «Юкка үпкәләмә. Ышанмау түгел. Андый компаниядә сиңа кызык булмас дип уйлаганга чакырмадым», – дип аклануына да карамады, туташ:

– Бу ни тагы? Башкаларга ярый. Миңа ник ярамый? Сиңа кызык булган җирдә миңа ник булмый? – дип әрләп, егетнең култыгына керде дә: – Әйдә

киттек! – диде.

## LXII
## БАШЫ-АХЫРЫ ШУЛ БУЛСЫН!

Туташ юл буенча бер үпкәләп, бер әрнеп, бер иркәләнеп, туктаусыз сөйләнеп барды. Давытка мәгълүм булмаган, Давыт өчен сәбәбе, сере башта ачылмаган эчке процесслар буенча килеп, көтелмәгәнрәк рәвештә Госманнарны, Хәбилләрне, Булатларны берәм-берәм телгә алды:

– Мин, – ди, – иптәшләрнең һәммәсен яратам, һәммәсенә үз күңелемдә аерым зур урын бирәм. Әнә тезе, терсәге чыгып йөргән сипкел гимназист Тангатар бармы, миңа ул да ошый. Бу бичара бит революция өчен гимназиясеннән куылды. Стипендиядән мәхрүм калды. Өстенә карар хәл юк, җиңнәре, чалбарлары җыртылып беткән, үзе һаман чаба. Кечкенә соры күзле, вак кына шадра йөзле Качкын да үзенең һаман-һаман жандарларны, урядникларны алдап качуы белән миңа зур бер каһарман булып күренә. Үзе ач, ялангач, шулай да һаман йөгерә… Мин аны тимердән яратылгандыр дип уйлыйм…* Аңардан азрак куркам да... Үзем яратам да... Атасының байлыгын, рәхәтен ташлап качкан Йосыфҗан да минем каршымда күтәрелде... Нигъмәт казый дигәнегез фикере белән безгә каршы булса да, ул да миңа бик ошый – ул, әйтерсең, җил-давылга бирешми, дулкыннарга җиңелми утырган таш кыя, – шулай нык тора, нык бара... Әмма Булатны әйтмисең дә инде аны: ул миңа татар пролетариат гаскәрен, башкалар белән берләштереп, дошманга каршы сугышка алып баручы генерал кебек күренә... Әмма син... син инде, Давыт, бөтенләй башка булып...

Туташ, сүз таба алмаган, әйтимме, юкмы дип аптыраган кебек, берничә секунд уйланып торды да кинәт карарга килде. Егеткә сыена төшеп, эчке, ягымлы, акрын, сөемле тавыш белән әйтеп куйды:

– Син инде минем өчен бер революционер гына түгел. Син, как человек... как личность[1] та син миңа бик, бик якынсың! – дип өзеп туктады. Берничә секундтан тагы башлады:

– Үзең беләсең безнең среданы[2]: каннан, воспитаниедән[3] шулай урынлашкан инде: нинди генә кругка[4] барып керсәң дә, күңелең берәүне эзли башлый. Бер ир иптәшне – пошлое выражение[5] белән әйткәндә – бер

---

* Бу ике җөмлә 1976 нчы елгы басмада төшереп калдырылган.

[1] *Как человек... как личность* – кеше буларак… шәхес буларак та.

[2] *Средань*ы – даирәне.

[3] *Воспитаниедән* – тәрбиядән.

[4] *Кругка* – җәмгыятькә, даирәгә.

[5] *Пошлое выражение* – тупас гыйбарә.

кавалерны тапмый йөрәк тынычланмый... Ул Акчулпан кебек иске тип галантный[1] ухажорлар минем хәзер ачуымны гына китерәләр. Аңлыйсың бит, Давыт, син минем нәрсә әйтергә теләгәнемне?

Урманов, уйланып, байтак баргач кына җавап бирә алды:

– Аңлыйм, иркәм, бик аңлыйм. Мин күптән инде бу хакта бер сүз кузгалыр дип көтә идем. Ләкин кузгалмавын тели идем. Инде бер башлангач, әйтми үтә алмыйм... Үзең дә сизә булгансың, Разия иркәм, минем эчемдә күп заманнардан бирле көрәш килә. Мин синең алдыңда җиңелмәс өчен, үземнең йөрәгемдә сиңа каршы булган тойгыны үтерер өчен күп көрәштем... Чөнки минем әнә шул Гәрәйләр кебек, Булатлар кебек, тик революция өчен генә яшисем килә иде. Сиңа булган тойгым минем бу дәртемә киртә була иде...

– Нигә алай дисең, ул ике нәрсә бергә сыймыйлармы?

– Менә сиңа бер мисал алыйм. Әнә шул Гәрәй Солтанны беләсең бит. Менә ничә ел инде ул идән астында яши. Торырга бүлмәсе юк. Исеме-фамилиясе юк. Ай саен яңа паспорт, яңа исем. Туры килсә ашый, булмаса – ач бүре кебек йөри. Ләкин шунда да ул бер тапкыр зарланмас, революция көрәшеннән бер минут туктамас. Иң авыр хезмәтне ул ала. Жандарм, полициягә каршы утка-суга керә. Берүзе башлап яшерен типография төзи. Монда берүзе, беренче башлап, яшь татар эшчеләреннән боевиклар хәзерли. Корал таба. Коралга өйрәтә. Революцияне сугыш дип алдына утырткан да, шул сугыш өчен, үз сыйныфын коралландыру өчен көнен белми, төнен белми янып йөри. Беләсеңме, шул бит Кавказдан кайтып төшкәч, миңа очрады.

– Ничек?

– Бервакыт пивнойга барып керсәм, Габдулла абзый белән утыра. Шакир солдат та шунда. Мине үз өстәлләренә чакырдылар. Бардым. Гәрәй башта ук миңа мәсхәрәләп бәйләнә башлады. Нихәл, ди, һаман сүз боткасы пешерәсеңме? Һаман шул мулла-мунтагай сүгеп гомер үтәме, ди. Мин әйтәм, аларны сүгәргә дә кеше кирәк ич, алар дин исеменнән халыкның башын томалыйлар, динче, милләтче байраклар белән халыкның миен агулыйлар ич, дим. Анысы алай, ди. Әмма, ди, ул муллаларны, иттифакчыларны сүгү белән генә самодержавие җимерелмәс ич! Николай кулында палач, гаскәр, туп, мылтык![87*] Син аңа кәгазь пулеметтан атып кына күп эш кыра алмассың, ди. Пивной тыгыз, иркенләп сөйләшергә җайсыз иде. Җиһангир бүлмәсенә җыйнаулашып бардык. Аның үзен, бар, Разия туташка түгәрәкнең кайчан икәнен әйт, дип, юк йомышны бар итеп чыгарып җибәрдек. Гәрәй үзе пәрдәне төшерде, ишекне бикләде дә сүгенергә тотынды: «Организацияләр

---

[1] *Галантный* – нәзакәтле.

хәерче, китап, гәзит басарга акча юк. Идән астына төшкән профессиональ революционерларны яшәтеп булмый. Корал аз. Әмма коралсыз нинди сугыш? Коралны табарга да, сакларга да, кирәк җирләргә озатырга да акча кирәк! Аны кайдан аласың? Николай кулында туп, мылтык булганда, коры демонстрация белән ерак барасыңмы? Эш ташлау белән генә аны җиңәсеңме? Дума, диләр. Ярый. Думага менә, кадет белән кушылып, Әхмәт Нурый әфәндене җибәрделәр.Ул, анда барып, шәп сөйләсен дә! Столыпин [88*] нәрсә әйтәчәк? Таврический дворец[89*] алдына ике туп китереп куйса, ул Әхмәт Нурыйларның меңләбе берьюлы котлары очып кача ич! Сез Качкын Хәбип белән буш бугазланып, бунтарьланып, адәм саташтырып йөрисез», – диде. Шулай ул озак тиргәнде дә бер кадакка китереп терәде: «Кораллы күтәрелешкә әзерләнергә кирәк!» – диде. Габдулла абзый белән Шакир солдат аңа чат ябешкәннәр. Хәзер коралланып, баррикадага чыгарга әзер торалар... Менә шуннан чыккач, Разия, мин уйладым: нигә без шулай була алмыйбыз? Нигә без йөрәкнең, минең көчен тик бер нәрсәгә генә бәйләп, тик шуның белән генә яши алмыйбыз? Аңлыйсыңмы? Менә шул уй минем телемне бәйләп килде. Мин үз йөрәгемнән революциягә башка һәммә нәрсәне чыгарып ташларга теләдем. Шуңа күрә сиңа булган тойгымны үтерергә тырыштым. Күрәсең, ул үлмәгән. Үләргә уйламый да...

Моңарчы сүзнең ахырын сабырсызлык белән көтеп килгән Разия кинәт җиңеләйде, канатланып китте:

– Үлмәсен! Белдеңме, үтермә! Ансыз тормышның тәме дә, яме дә калмас! Алар икесе революция белән бергә йөрәгеңдә кайнасыннар. Белдеңме?

Килеп җиттеләр.

Бу озын-озак сүз эчендә Разия үзен үзәк итеп сизенде. Җаны шуңа рәхәтләнде. Аяклары җиңел атлап китте, йөрәге дулкынланды. Шулай капканы керәбез дигәндә генә ул Давытка:

– Тукта! – диде.

Егет, аяк баскан җирендә катып, кызның караңгы төн астында ялтыраган күзләренә карады. Разия, акрын кузгалып, перчаткасын салды, сабыр кузгалып, уң кулы белән егетнең муеныннан уратып кочаклады. Бик аз гына да тартынмыйча, шикләнмичә, аны никахлы ире яки күптәнге сөяркәсе кебек итеп, үзенә тартып, үбим дигәндә, Урманов көчле куллары белән туташның үзен кочаклап үпте.

Берничә секундка дөньядан югалдылар.

Иң элек Разия уянды. Кинәт кире чигенеп, русча:

– Җитәр! Башы-ахыры шул булсын! – диде.

Разия ашыгыч, җиңел шат адымнар белән капкадан кереп, кайсы

ишеккә барырга икәнен сорамыйча ук, үз сизенүе белән йортның түрендә, каеннарның аргы ягында җирдән бик аз гына күтәрелеп торган тәрәзәнең яктысына таба китте. Урманов аны куып тотты да, култыклап, караңгы тар, җимерек баскычлардан җайлап, акрынлап, Абдулның квартирына – каядыр түбәнгә алып төште.

Керсәләр, туташ аптырап калды.

Анда бер төркем халык җыелган: монархист, иттифакчы Нигъмәт казый да, анархист Тангатаров та, үзен партиясез революционер дип йөргән Җиһангир дә, сәяси агымнарга һичбер төрле катнашы булмаган җырчы Сәхип тә, күбрәк вакыт Булатлар тирәсендә кайнаган купшы приказчик Фәхри дә бар. Шулар эчендә үзенең ничек качуын сөйләп, вак кара шадралы, кечкенә соры күзле, чандыр Качкын Хәбип утыра.

Туташ күзләренә ышанмады, русча:

– Йа Ходай! Мин кемне күрәм! – дип кычкырды да, иптәшләрдән, шулай ук әле беренче тапкыр очрашкан хуҗа хатын Хәдичә җиңги белән Габдулла абзыйдан аз гына да тартынмыйча, оялуны хәтеренә дә китермичә, атылып барып, Хәбипне кочаклап, йөзеннән, маңлаеннан, күзләреннән кат-кат үбәргә тотынды.

Кунаклар аптырап калды. Мансуров, туташны ярым кочаклап, шат, уенчан көлке тавыш белән:

– Разия! Разия иптәш! Сез мине буып үтерәсез, тын алырга бирегез! – диде.

Туташ, кочагыннан чыгарып, үбүеннән туктагач, берничә минут кулларыннан ычкындырмыйча, күзләренә йотылып карап торды:

– Тагы бер карыйм: сезме бу!? Ялгыш түгелме? Разия бераз айный төшкәч, Хәбип, кузгалып, үзенең урынын аңа бирде, өстендәге пальтосын, эшләпәсен салырга булышты. Болай яхшы, шат каршы алуы өчен яңадан бер кат кызның кулын кысты.

Хәбип белән Разия электән үк якын дуслар. Качкынның бунтарь характеры кызга ошый, ул Мансуровның теленнән дә бераз курка. Шуңа күрә дә ныграк дусланырга тели иде. Бүгенге очрашуда морза кызы үзенең дуслыгын тагын күрсәтә төште, Давытка бәйләнде:

– Сез мине чакырмыйча шундый зур бәхеттән мәхрүм итә яздыгыз! – дип шелтәләде. Башкаларга карап: – Менә бит мине ничек рәнҗетә: бүтән иптәшләр җыелган җиргә мине чакырмый, үзем көчләшеп килдем, – дип зарланып куя. Аннан соң Хәбиптән китеп, ялкынлы учак янында тирләп-пешеп, нидер пешереп азапланган Хәдичә җиңгигә килде, гафу үтенергә тотынды: – Хәбип – безнең батыр иптәшебез. Аны күргәч, мин дөньяны оныттым. Сезнең белән җүнләп исәнләшә дә алмадым, кичерә күрегез, –

диде.

Хәдичә апай мондый өйрәнелмәгән сүзләрдән, бигрәк тә ят туташтан бераз тартынды.

Ул элек авылда ярлылык белән җәфа чикте. Ачлык елда авылны ташлап, ире, бала-чагасы белән калага күчкәч тә тамагы ашка, өсте киемгә туймады. Габдулла абзый эшсез калган чакларда актык әйберләрен сатып газапландылар. Шундый авыр көн иткәнгә, Хәдичә апа мондый укымышлы егетләргә, мондый яхшы киемле бай, матур кызларга катнашып өйрәнмәгән иде. Бераз тартына төште. Шулай да мичтә кызган симез казны икенче якка әйләндерә биреп, үзенең шатлыгын әйтә алды:

– Сөйләмә инде, туташ. Бүген Хәбипне күргәч, күземә ышанмадым. Акылымнан яза яздым. Әйтәм ич, акылымнан яза яздым. Сез beләсезме икән: бездән ерак түгел Баязид карый дигән бер иптәш тора иде, мин шуны жандарларның тотып алып киткәннәрен күреп калдым. Харап бит, туташ, алар җырткыч кебек кылаалар бит, дип, Баязид турында сөйләп китте.

Хәбип, урыныннан торып, болар янына килде.

– Шулай инде, Хәдичә апай! Ябылуы да, сөрелүе дә булыр. Аңа бик ис китәргә ярамый. Азатлык өчен сугышу заманы бит, – диде.

Ләкин җиңги туктамады, үзенекен алып китте:

– Сез шулай дисез дә бит... Безгә, монда калганнарга, бик кыен бит... Элек андый ябуларны ишеткән саен: юкка фетнә чыгарып йөрмәсеннәр, бик яхшы булган, дип куя идем, хәзер инде аңлыйм әзрәк... Шулай да йөрәгем әрни шул... Төнлә бер нәрсә шытырдаса, жандарлар килеп басты, күрәсең, дип куркып уянам... Бер кешене япканнар дисәләр, үз балаңны алып киткән төсле була... Менә ярый инде, Йосыфҗанга да рәхмәт: бай баласы булса да, мәрхәмәтен салды: менә Габдулла абзагызны агач заводына урынга куйдырды. Рәхмәт инде, хәзер әле менә эчүен дә куеп тора... – дип, шатлык катнаш кайгыларын сайрады.

Сүз икенчегә күчте. Бер ачылып киткәч, Хәдичә җиңгинең йөрәгендә җыелган барлык нәрсәсе туктамый агыла бирде:

– Туташ, – ди, – гаеп итмәссең инде: ярлылыгыбыз зур, фатирыбыз да бик начар. Иптәшләр күз күргән кешеләр, бикә туташ, син гаепкә санама инде... Ни хәл итик... сез килерне белгән булсам, азрак юган булыр идем ичмаса... Өлгерә алмадым шул, кызым Маһирәне Булатның сеңлесе алып китте, аларның әнкәләре авырый икән... Аңа да кыен шул инде: бердәнбер улы әле тоткында, әле сөргендә, көн юк, төн юк, жандар килә дә баса, килә дә баса... Кайгысыннан кибеп саргайды инде бичара Әсхәпҗамал апай! Ни эшләсен соң, язмышы шулдыр...

Разия, сүзнең ахырын көтми, уртасыннан кисте:

– Ходаем, бу ни хәл бу?! Әле килгәндә юл буенча Урманов белән дә талашып килдем... Мине нигә алай аерып куялар? Башкаларга яраган миңа ник ярамасын? Бик матур, бары да бик матур. Әнә Кадыйр байларның йортлары бик шәп тә бит, менә бу иптәшләрнең берсе дә, ул чакырса, бармаслар иде әле... Сиңа, Хәдичә апай, шатланып киләләр, фатирың тар булса, күңелең киң синең! – диде.

Фатир чыннан да тар, фәкыйрь иде. Ул, ничектер кысылып, җир астына төшеп утырган, ике кечкенә тәрәзәнең тик югарыгы өлгеләре генә җирдән өскә күтәреләләр. Балчыклап сыланган таш идән. Бусагадан атлауга – уң якта зур мич, аның акшарлары кубып беткән. Ятагы, аш бүлмәсе – һәммәсе шунда, бары бергә. Тик мич алды гына чаршау белән бик аз гына бүленгән. Түрдәрәк агач өстәл. Аның ике ягында эскәмья сузыла.

Фатир шулай тар, тыгыз, ярым караңгы булса да, иптәшләр үзләрен иркен тоялар, иркен тоталар. Кайсы тәрәзә төбенә, кайсы мич башына, берничәсе эскәмьягә сыешканнар. Нигъмәт казый идән буйлап йөри. Өй эче туктаусыз гөрләп, кайнап тора.

Разия, беренче сүзләрен бетерүгә, җиңги белән дуслашып китте. Аның рөхсәт итмәвенә дә карамыйча, алъяпкыч бәйләде дә савыт-саба юарга, аш әзерләшергә кереште.

Аның куллары оста, җиңел йөриләр. Үзе канатланган кебек, аягы җиргә тими кузгалган кебек очына – ул, әйтерсең, сөйгән егетенә кияүгә чыккан да бүген башлап аның йортында, аның өй җәмәгате эчендә хезмәткә керешкән. Шундый бер шатлык белән ак беләкне сызганып, алъяпкычны җилләтеп, аш хәзерләшә.

Качкын Хәбип үзенең жандардан, полициядән качу тарихларын сөйләргә яратучан кеше иде. Үз тирәсенә җыелган яшьләргә тәмләп-тәмләп шул вакыйгаларны тасвирлады. Ул арада аш та өлгергән иде инде. Разия һәммә иптәшләрен шаяртып, көчләп, өстәл тирәсенә таба куды. Тыгызлап, кысрыклап, аз урынга күп кеше сыйдырды. Тәрилкәләр юк. Чәнечкеләр юк. Тик бөтен өстәлгә бер пычак бар да җитәрлек агач кашыклар бар. Өй эче майлы шулпада пешкән тәмле токмач исе белән, мичтә кызган симез каз исе белән тулды. Борыннарны кытыклый башлады. Хәбип, бу чаклы тәмле итләрне аракысыз ашау гөнаһ булмасмы икән, дип шаярткалап, җиңгидән гафу үтенде дә Габдулла абзыйга карады:

– Боларга кирәкми булыр... Син дә антыңны бозма! Минем тән бик ватылган чак, аш алдыннан берәр яртыны төшергәндә, әллә бәлки зыян булмас иде, ә? – диде.

Урманов аңа:

– Юк белән кеше мәшәкатьлисең, – дип, бәйләнә башлаган иде. Туташ

аны кырт кисте:

– Юк, сез бәйләнмәгез, әйдә ул эчсен, ул бик ватылган кеше... Аңа файда булыр... Габдулла абзый, табып буламы? – дип карады.

Хуҗа күп сөйләтмәде:

– Аның ни мәшәкате бар? Ике адымлык җир ул: минем күрше Петрушкада була торган иде элек, – диде дә, җилкәсенә чикмәнен салып, чыгып китте.

Башкалар аңламадылар, бер генә минутка Хәдичә җиңги дә аның артыннан чыгып керде. Моның сәбәбен Урманов кына аңлады: Хәдичә җиңги иренең элек эчәргә яратуыннан күп газап чиккән хатын. Аракыга күзе төшкәч, тагын башлап китмәсен дип куркынды. Ире артыннан чыгып:

– Син, карт, Алла хакы өчен дип әйтәм, үзең эчмәссең бит, тагы элекке кебек булып китүдән котым оча минем, – диде. Ире вәгъдә биргәч, шатлыгыннан канатланып керде: Ходаем, нинди бәхет: кешеләр эчәләр. Алдында аракы тора, аның Габдулласы кыстасалар да эчми. Йа Ходай, бу төш түгелме?

Петрушка якын икән, биш минут та вакыт үтмәде, элекке гадәтенчә, ярты кызылбашны чалбар кесәсенә тыгып, Габдулла абзый кайтып керде.

Аш утырды. Хәбип алдына әзрәк кәбестә, кыяр, суган, зур чынаяк чокыры куйдылар. Ул болар янына тагын җиңгидән бер бәрәңге белән ит кисәге сорап алып, азрак суытты да чынаяк чокырындагы саф аракыны су эчкән кебек кенә йотып җибәрде.

Башкалар, капланып, тәмле токмачка йотылдылар. Давыт, ашый-ашый, Габдулла абзыйга карады: ул бөтенләй котыла алганмы? Әллә һаман да әле үзен көчләп кенә тыямы? Юк, ул бик тыныч күренә, бер дә исе китмичә, алдындагы аракыга күз дә төшермичә, рәхәтләнеп ашый. Димәк, бөтенләй котыла алган! Шешә төбендә калганын икенче тапкыр үзенә сала башлагач, Разия туташ Хәбипкә бәйләнде:

– Сез, бигрәк харап икәнсез: үзегез генә бетерәсез, миңа да салыгыз, мин сезнең белән брудершафт эчмәкче идем! – диде.

Җиңги дә, Габдулла абзый да, башкалар да, бераз гаҗәпләнеп, Разиягә карадылар:

«Нәрсә, ул чынлап эчмәкчеме? Әллә шаярып кына сөйләшәме?»

Мансуров, дусча елмаеп, туташка карады:

– Эчәмсез? Әгәр күтәрә алсагыз, рәхим генә итегез! Сезнең белән эчү минем өчен бик хозур булыр, – диде.

Хәдичә җиңги кечкенә чынаяк чокыры китерде. Туташ, шешәне алып, үз чокырына бер рюмка чаклы салды да кулына алды. Башкалар аның эчүенә һаман ышанмыйлар иде әле. Хәбип белән чыңгылдатып чәкештерде дә

авызына каплады:

– Бик әче була диләр иде, юк сүз икән, – дигән була, үзенең күзләреннән яшьләр килә. Ул башта сүз ачканда брудершафт эчәм дигән иде, ни өчендер аңардан киреләде.

Аш күп хәзерләнгән, ит олы табак белән өелеп килгән иде. Егетләрнең ачыгуы да ярыйсы булса кирәк, килгән бер нәрсә югала барды. Хәбип, бераз эчеп тә алгач, харап ашады, ул үзе йотына, үзе:

– Безгә мондый сыйланулар корбан бәйрәмнәрендә генә насыйп була торган иде! – дип көлә.

Мәҗлес кызык барды. Аштан соң чәй килде. Чәйгә бавырсак, чәкчәк бар. Болар – Давытның кияүгә бирелгән сеңлесеннән бүләкләр. Алар өстенә Хәдичә апа үзе кәрәзле ак җүкә балы белән лимон табып куйды. Күп сүз, уен-көлке арасында вакытның ничек үткәне сизелмичәрәк, болар таңгача утырачаклар иде. Кайдадыр кинәт бер-бер артлы өч тапкыр мылтык атканы ишетелде. Шуның артыннан куганга, кычкырып качканга охшаш шау-шу килде. Кунаклар һәммәсе ашау-эчүне, уен-көлкене оныттылар. Дөньясын ташлап, рәхәткә чумган Хәбип Мансуров иң элек үзе сикереп торды:

– Иптәшләр, безгә таралырга вакыт! Килеп бассалар, берьюлы һәммәбез эләгербез, – диде.

Яшьрәкләр шунда ук киенделәр дә юк булдылар. Аларның ничек чыгып качканнарын күргән кеше дә булмады. Нигъмәт казый калын труба таныш белән:

– Сезнең гөнаһшомлык миңа да эләгер, кайтырга кирәк, – дип сукрана-сукрана киенде.

Качкын бүген Нигъмәт казыйларда кунарга булды.

Иң ахырдан, һич тә теләмчиә, Разия кузгалды. Бер дә китәсе килмәгәнен сөйләп, Хәдичә җиңгигә кат-кат рәхмәтләр әйтеп, хәерле йокылар теләде дә:

– Җә, киттекме, Давыт? – дип, Урмановның беләгенә асылды.

## LXIII
## КӨЗГЕ АЛДЫНДА

Алар Габдулла абзыйның квартирыннан чыкканда күк йөзе ачылган, йолдызлар үтә якты бер нур белән ялтырап яналар, якты ай да үзенең тонык нуры белән шәһәр өстенә карап тора иде.

Туташ, тирән сулыш алып, егетнең култыгына керде.

Тегендә, тар, кечкенә фатирда, иптәшләр арасында канатланып очкан кыз танылмас дәрәҗәдә үзгәрде, басылды, күңеле әллә кая китте. Бик озак сүзсез бардылар. Икесе ике нәрсә турында уйлыйлар, ләкин уйларының төбе

бергә кайта иде.

Кыз, кечкенә, җыйнак, чибәр өйләренең таш баскычына җитеп, ике якка ачылмалы ак ишеккә туктагач та бер сүз әйтмәде, кесәсеннән ачкычын алды да ишегенә таба килде. Давыт үзен-үзе аңлап бетергәнче, Разия Ширинская ишек эченә кереп югалды.

Вакыт бик соң иде инде.

Туташ аяк очы белән генә керергә, һичкемне уятмаска тырышты.

Ишектән кергәч тә уң якта анакайның (Кытай сугышында һәлак булган полковник Сәлим морза Ширинскийның хатыны Алмасбикәнең) бүлмәсе иде. Кыз, туктап, аңа колак салды. Анакай карчык, тигез сулыш алып, тыныч, рәхәт йоклый.

«Ходаем, дөньяда нинди бәхетле җаннарың бар!»

Туташ шулай уйлап, һичкемне уятмыйча, зал аркылы үз бүлмәсенә үтте.

Бүлмә матур. Йомшак урындыклар, көзгеләр, язу, туалет өстәлләре, алтын тышлы китаплар белән тулы кызыл агач шкафлар нечкә бер зәвык белән тезелгәннәр. Стенада атасы полковник Сәлим морза, өч медаль белән бизәлгән күкрәген киерә төшеп, зур кара күзләре белән кызына текәлеп карап тора. Уң як почмакта нечкә кружеволар белән бизәлеп ябылган чибәр караватым, аның турында кечкенә өстәл. Анда асрау, гадәтенчә, Разиянең ачыгып кайтасын уйлап, атлам май белән булки һәм куе каймаклы сөт тулы стакан куйган.

Бөтен бүлмәдә тынычлык, матурлык, зәвык һәм гаҗәп бер хуш ис аңкып тора.

Башка көннәрдә туташ кайтып керә дә ныгытып ашый, аннан тиз-тиз чишенеп, үзенең йомшак мендәрләренә чумып, тирән рәхәт йокыга китә торган иде.

Бүген юк.

Акрынлап чишенә башлый. Яртылый чишенгәч, уйга батып туктала. Йокы каядыр качкан. Башта ниндидер чишелмәгән уйлар тулып кайнашалар. Булатны озак уйлады. Элек бервакыт аның белән башы әйләнә башлаган иде ич. Ничектер тиз айныды. Инде Давыт! Юк, ул гына түгел, әллә кайдан көчләп фабрикант Абыйзов килеп баса. Бу да матур. Каты карашлы. Ләкин шунсы яман: каядыр артта яшерен ике бала белән күз яшьле яшь, чибәр марҗа күренә... Юк, кирәкми. Тик Давыт кына калсын!..

Тышкы тормышта гына түгел, аның үз эчендә дә нидер җимерелә, нидер туа...

Менә дөньяның, мәдәниятнең барлык байлыклары, сәнгать матурлыклары белән бизәлгән чибәр мәрмәр зАллар.

Алтын, җефәк, атлас эченә чумган матур ханымнар, погонлы, төз буйлы, тәрбияле кавалерлар...

Музыка уйный... Матур күзләр сөеп, нур чәчеп карыйлар. Тулы алсу иреннәр матур елмаялар... Матур чәчәкләр... Тәмле эчемлекләр... Баллар... театрлар... кичәләр... ложалар... алтын погоннар...

Юк, алай түгел!

Эшчеләр, солдатлар, крәстиәннәр... Ябык саргылт йөзле, бөкрәя төшкән шәкертләр... приказчиклар... Җиңнәре, тез башлары бәреп чыккан йолкыш Тангатаровлар, исереп, талаш чыгаручы Абдулкалар... Кирәксә, зинданнар... сөргеннәр, бәлки үлем баганалары, баштанаяк кызыл киемле, ерткыч кара йөзле палачлар...

Кыз бу ике дөньяның уртасында торып озак уйланды.

Аннан акрын гына аякка басты. Озын зифа гәүдәсе өстенә, нечкә ак күлмәкләрен каплап, зәңгәр төсле киң, чибәр җефәк халатын салды да салмак атлап залга чыкты. Түшәмгә асылган зур люстраны якса, бик артык кискен якты булачак. Күңеле аны теләмәде. Альбомнар белән тулып яткан кечкенә түгәрәк өстәлдәге аяклы лампаның төймәсен борып яндырды да, бүлмәнең салкын һавасыннан җефәк зәңгәр халатка төренә биреп, көзге алдына килеп басты. Бүлмә ярым караңгы; анда көзгедә чибәр йөзле, озын, зифа буйлы кыз карап, зәңгәр халат эченнән дулкынланып тора.

Ул кайчандыр үзенә-үзе гашыйк иде. Ялгызы бикләнеп, көзге алдында үз матурлыгы белән үзе сокланырга ярата иде. Үзен борынгы юнан һәйкәлләре белән чагыштырып, сәгатьләрчә ләззәтләнә иде. Әле дә шулаймы? Шома ак мәрмәр. Аңа бик аз гына алсу кан йөгертелгән. Кулбашлар түгәрәкләнеп, тулып киләләр. Күкрәкләр зәңгәр җефәк халат эченнән бәреп, калкып торалар, Йөз үтә матур түгел. Уртача. Әгәр тагы бик аз гына озынчарак булса иде, борын да бик аз гына биегрәк эшләнсә иде – шиксез, иске юнан һәйкәлләрен искә төшерер иде. Ләкин юк. Бу ике кимчелекне һәрвакыт нурланып торган зур кара күзләр белән сузылып төшкән озын кара керфекләр, нечкәреп сызылган кара кашлар белән тулы алсу иреннәр артыгы белән тутыралар. Кара җефәк чәчләр кайчандыр бөтен күкрәкне, кулбашларны, арканы каплап, билгәчә төшеп дулкынланалар иде. Революция килде, кыз аларны кыскартып кисте, ләкин бу кыскарту матурлыкны арттырды гына... Кыз, кайчандыр элек вакытлар, менә шулай ялгызы кыйлана иде.

Ана, бичара ана Алмасбикә, кызының бу матурлыкларын Разиянең үзеннән дә артык ярата иде. Разиянең акылы, үзен яхшы тота белүе зур өмитләр баглаттылар. Маллы, дәрәҗәле, тәрбияле һәм акыллы бер пар табып, карчыкны тынычландырачагына ышандыралар иде. Туташ тирәсендә

берничә морза офицер егет әйләнде. Болар карчыкның үткен күзеннән үтәләр. Ләкин ул һичберенә күңел утырта алмады. Кайберләренең озаграк әйләнүе ананы шөбһәгә төшергәләп үтте. «Шулаймы – бу минем акыллы, чибәр кызым бу егетне үзенә сайлармы? Бу аңа тиң түгел ич», дип уйлана. Ләкин бераз вакыт үтә. Офицер егет югала. Ана йөрәге тынычлык таба. Разия алар турында җиңелчә көлеп, мыскыллап сөйли башлагач, бикәнең тынычлыгы бөтенләй арта иде. Нигә ашыгырга? Кызының яше яңа егермегә җиткән.

Разия туташ анасының бу фикерләрен читләп сизә иде. Аның үз карашы да шуңа якын иде.

Ләкин менә революция килде дә яшь йөрәкләрне үз дулкыннары эченә суырып алды. Юк, хәзер берсе дә юк, берсе дә калмады. Көзге алдында сокланып каралган озын зифа буй хәзер инде кара платьега төрелгән. Күңелнең һәммә катлаулары революция ялкыннары белән кайныйлар. Буй зифамы, тән матурмы, иреннәр кызарып тулышалармы – була бирсеннәр, болар хәзер көзге алдында кыйланмаслар, бәлки кирәк булса, революция өчен зинданнарда черер, яки палач кулыннан кичәр дә караңгы төндә чокырга ташланыр... Кыз шулай уйланды да, кинәт залдагы утны сүндереп, яңадан үз бүлмәсенә килде.

Ләкин йоклый алмады.

«Юк, болай ярамый. Бу акылсызлык. Бу үткәнгә җиңелү! Боларга яңадан кайтырга ярамый. Боларны күмәргә кирәк, бетерергә кирәк! Ләкин ничек? Кемнән, кайдан куәт алыйм, кем белән бу турыда сөйләшим? Давытмы? Булатмы? Хәбипме?

Булат мондый трагедияләрне аңларга теләмәс: сыйнфый нигезен югалта башлаган интеллигент кызның трагедиясе дип көләр генә. Давыт тирән уйлы, киң карашлы, ләкин йомшаграк. Хәбип кызгануны белми, хәнҗәр белән йөрәгеңне тереләтә ярып, кисеп ташлар. Кайбер чакта шул яхшы да була: ничектер берьюлы җиңеләеп үк каласың. Әйтерсең, рәхимсез, ләкин оста доктор бер минутта чирле әгъзаны ярып җибәрә.

Аңа барыйммы? Башкасынамы? Ләкин аларга баруда, алар белән сөйләшүдә ни файда? Тышкы формалары теләсә ничек булсын, әмма төп әйтәчәкләре миңа алдан ук билгеле ич:

– Бик гади эш бу, диярләр. Бер сыйныф, үзенең тарихи ролен үтәп, аның урынына башкалар килер заман җитсә, аның үз эченнән үз кешеләре яңа мәйданга чыккан сыйныфка килеп кушылалар. Сез иске дворян-буржуазия сыйныфыннан революция сәбәпле пролетариат сафына чыгучы элементларның берсе буласыз. Сезнең трагедиянең сыйнфый нигезе менә шунда гына... диярләр. Булат тагы чәнчеп өстәр: ләкин нык булыгыз,

интеллигенциянең бер катлавы, кызарып, социализм дип йөри дә, ахырдан барып мещанлык сазына бата, шуңардан сакланыгыз, дияр.

Юк, ни әйтәчәкләре, сөйләшсәң-сөйләшмәсәң дә, бик мәгълүм. Миңа аларның берсенә дә барырга, киңәшеп йөрергә кирәк түгел...

...Минем юлым ачык, иманым көчле. Ул иске тормыштан мин киттем. Анакай уйлаган Разия туташ хәзер дөньяда юк. Аның урынына башка Разия туды: мин революционер! Мин, социализм байрагын күтәреп, капитализмга, бөген буржуазиягә каршы сугышка чыккан көрәшчеләрнең берсемен.

Хуш, бәхил бул, иске дөнья! Мин сиңа мәңге кайтмаячакмын! Минем алдымда яңа дөньялар, яңа идеаллар!»

Шул уйлар белән саташып, туташ таң алдында гына йоклап китте.

Кызының бик соң ятуын Алмасбикә төндә үк сизгән иде. Иртә белән гадәттәгедән озак йоклагач, түзмәде, берничә тапкыр Разияның бүлмәсенә кереп карады: йөзе тыныч кебек күренә, ләкин башы уттай яна иде.

Ана йөрәге нидер сизенде – ни була? Ниләр генә була бу балама дип, авыр хәсрәткә төште. Ләкин кызына ул турыда сүз ачмады.

Сәгать унбер иде инде. Туташның уянганын белгәч, асрау керде:

– Анакаегыз кәефсез, башы авырый, сезне үз бүлмәсенә чакыра! – диде.

Разия бөтен тәнен кызартканчы салкын су белән сөртеп уды да, киенеп, анакае янына чыкты.

Карчык бер төндә ун еллык картайган. Йөз саргаеп кипкән. Күз тирәләрен тирән җыерчыклар бөтенләй каплап киткәннәр. Бикә кызын салкын гына үпте дә, кара кофены болгый-болгый:

– Кызым, сиңа ни булды? Бик соң кайттың? Бик соң йокладың? – дип сорады.

Разия мондый бер сорауны көтә иде. Шуңа әзерләнеп чыккан иде. Ничаклы гына сөйләшсәң дә, аңлашып булачак түгел!.. Сүз озайтуда ни файда? Разия шулай уйлады:

– Һичнәрсә юк, анакай! Мин хәзер собраниегә китәм. Сиңа аптекадан кирәк нәрсә юкмы? Кайтышлый алырмын! – диде дә, ридикюлен алып, урыныннан торды.

Карчык бикә ачуыннан, кайгысыннан катты. Эре, тирән җыерчыклар аның бөтен йөзен каплап алдылар. Ләкин сүз белән, тавыш белән белгертмәде:

– Юк, рәхмәт. Кирәк булса, мин асраудан алдырырмын, – дип, кырт кисте.

Разия ашыгыч атлап чыгып китте.

Бикә акылыннан шаша язып калды: бу ни бәхетсезлек бу? Собраниегә, собраниегә, партия, реферат, кружок... нindидер эшчеләр... Гәрәйләр...

Абдулкалар... митинглар... демонстрацияләр... революция... социализм!.. Йа Ходай, бу ни эш? Бу – минем кызыммы? Мин Разиямне шулар өчен үстердем, шулар өчен тәрбияләдемме?!. Йа Ходай!..

## LXIV
## ГӘҮҺӘРНЕҢ МӘХӘББӘТЕ

Разия беренче чатта Гәүһәргә очрады.

Бу яңарак кына чыгарылган иде. Әле күрешмәгәннәр иде. Дусларча үбештеләр. Гәүһәр Разияның кулыннан алды. Русча әйтте:

– Мин сиңа килә идем... Зур серем бар. Дөньяда синнән башка һичкемгә әйтә алмыйм! – диде.

Икәүләп Гәүһәр Илбаеваларның өйләренә киттеләр.

Мөхәррәм Илбаев чиновник татарларның берсе. Ул гомерен Земствода хезмәт итеп үткәрде. Үз өе бар. Гәүһәр аның бердәнбер кызы булганга, заманнан каласы килмәде: кызын гимназиядә укытты, аннан Петербурга, югары курсларга җибәрде. Быел Петербурның югары мәктәпләрендә укуларның җае калмаганга, туташ та монда кайтты. Кайтты да тегендәге кызу белән социалист яшьләр арасына чумды. Баштан ук Булатларга кушылды. Синең йөзең ачык түгел дип, Разияга һаман бәйләнә иде.

Разия, үзенчә, революция белән контрреволюция арасына тирән сызык сыза. Үзен революция ягында, Хәбипләр, Давытлар белән бер якта калдыра. Әмма Гәүһәр кискен кеше иде. Беренче адымнан ук үзенчә ачык юл сызды. Аның анасы бик динле, иске фикерле, намазчыл карчык иде. Кызын картларча орышып карады:

– Аллага да ышанмыйсың бугай. Кыяматтә ни җавап бирерсең! – дип шелтәләде. Болай көн-төн ят егетләр арасында, җыелышларда кайнап йөрүен дә яратмый иде. Карты Мөхәррәмгә әйтеп карады: – Ата була бел. Кызыңны бераз йөгәнлә! – диде.

Ләкин Илбаев йомшак, киң табигатьле кеше иде. Каты бәйләнә алмады. Карчыгына шаян җавап бирде:

– Кайгырма, анасы, революция җиңсә, Гәүһәр безне коткарыр. Әгәр дөнья искечә калса, без аны коткарырга тырышырбыз... Менә шулай ике якны да чамалаган яхшы ул! – диде.

Кыз революциягә гыйшык белән дулкынга ташланды. Ләкин шул дулкын җанлы кешеләр, ирләр, егетләр арасында бара иде. Ничектер Булат белән артык дусландылар. Шулай да, уртага Нина исеме ялгыш буталган чакта, ул Булатка ачу белән янды. Бик күптән Гәүһәргә күз атып йөргән Йосыфҗан менә шул моменттан файдалана белде. Шул арада Гәүһәр белән Йосыфҗан яшерен-яшерен берничә очраштылар. Һичбер нәрсә дә булмады.

Ләкин Йосыфҗан, караңгы кичтә озатып барганда, аны көчләбрәк ике тапкыр үбеп алды. Атасы Кадыйр бай белән талашып аерылышкан көннәрдә Гәүһәргә киңәшкә килде. Менә шулай ниндидер яшереп җеп сузылды. Кыз моны вакытлы бер хата дип карый, әмма егет шул хатаны таш нигезгә әйләндерергә, Гәүһәр белән ике арада тирән роман тудырырга тели. Атасыннан качып киткәндә, кыз аңа берничә ярдәм күрсәтте. Егет боларны йә ялгыш аңлаган, йә юри шулай суза. Менә бүген тагын озын хат. Кичә атасы Кадыйр байга да, Гәүһәргә дә телеграм. Ул атасы Кадыйр байга яза: «Ач калырмын, юк хакка эшли торган көнлекче булырмын! Шунда да мал дип, байлык дип яңадан синең коллыгыңа кайтмам! – ди. Одессадан Истанбулга китәргә пароходка утыргач, әнә шундый телеграм бирә.

Гәүһәргә язган озын хатында бөтенләй башка нәрсәләр сөйли.

Ул баштанаяк, – ялганмы, дөресме, – гыйшык-мәхәббәт белән тулы. «Дөньям рәхәт, үзем азат, берничә елга җитәрлек хәлем бар. Һәммә нәрсәм бар, тик син генә юк, сине көтәм. Үзең киләсеңме, әллә кайтып алыйммы», – ди.

Кыз моңа каршы озын хат язган. Ул бик иптәшчә башлый. Якын итеп күрә. Ләкин араларында андый гыйшык-мәхәббәт кебек һичбер нәрсәнең була алмавын ачык әйтә. «Мин синең дустың булып калырмын, ләкин минем дуслыгымны башка төстә аңлама: минем бер дустым Разия булса, икенчесе син булырсың. Мин Разияне да, сине дә бер үк төсле мәхәббәт белән яратам, мине ялгыш аңлама», – ди.

Гәүһәр менә бу хатны язды да почтага бирергә батырлыгы җитмәде. Берәүгә киңәшергә теләде. Разияга баруы, аны, зур серем бар дип, үзенә алып килүе – менә шуны укыр өчен иде.

Иптәшләр арасында кайбер гайбәтләр бар. Йосыфҗан үзе дә, атасыннан качкангача, монда, шәһәрдә якын дусларына сер итеп кенә: «Гәүһәр белән безнең ара...» – дип сүзләр ычкындырган бугай. Кыз мондый чуалчык хәлгә төшүне бер дә теләми. Әгәр туп-туры үзе иптәшләрчә сүз ачса, ничектер уңайсыз кебек тоела. Ул Разиянең андый гайбәтләрне яратучан икәнен белә иде. «Йосыфҗанга биргән җавап хатымны үзенә укысам, ике сүзгә урын калмас. Ул миннән китү белән Давытка сөйләр, аннан башкаларга таралыр, шулай итеп. Йосыфҗан белән минем арада һичнәрсә юклыгы, булмаячагы ачылыр», – дип уйлады.

Разияга менә шул исәп белән укырга кирәк тапты.

Киң йортның уң ягында зур бакча. Өлкән ак каеннар, карт имәннәр, җүкәләр ялангачланып, җил белән шаулашып утыралар. Менә шул бакчаның эченнән үткәч, бер катлы, яшел түбәле өлкән агач өй. Бу өй – Мөхәррәм Илбаевныкы. Кызларны асрау каршы алып, ачып кертте. Анасы да, атасы да

өйдә юк икән. Залны үтеп, уң яктагы бүлмәгә керделәр. Бүлмә кечкенә, бер генә тәрәзәле. Разиянеке дәрәҗәсендә кыйммәтле мебельләр булмаса да, зәвык белән җыештырылган. Китаплар шкафында бу революция эчендә генә чыга алган әллә ничаклы кечкенә русча китаплар өелеп яталар. Диван өстендә хәзер генә почтадан килгән ике журнал. Нәкъ шул диван турында, стенада, зур ак сакаллы, тузыла төшкән озын ак чәчле, зур чал мыеклы, бөтенләй зур арыслан карашлы Маркс басып, тирән күзләре белән карап тора... Разия керә-керүгә моңа карап шаккатты. Иптәш кызының бераз ярлырак, шулай да бик пакь, ак җыештырылган караватыннан, китапларыннан, йомшак диваннан бигрәк, бу арыслан тесле аксакал Маркстан күзләрен ала алмады.

Кызлар диванга утырдылар. Гәүһәр эшләпәсен, пальтосын салып бер якка куйды да, матур ридикюленнән зур конверт чыгарып, хатны алды. Нечкә иреннәрдә аз гына елмаю уйнап, Разиягә карады, русча:

– Син, кадерлем, гаҗәпләнмә, миңа синең киңәшең кирәк. Син миннән зуррак та, акыллырак та, – диде.

Русча нечкә язу белән язылган озын хатны укып чыкты. Йосыфҗанга карата: «Син минем дуслыгымны ялгыш аңлама, минем ике дустым бар. Берсе – Разия, берсе – син. Мин сине дә, Разияны да бер үк төсле мәхәббәт белән яратам... Сиңа бәхет телим. Синең дустың, ялгыш аңлама, тик дустың булып каласым килә»... – дигән кебек урыннарына аерым тукталып укыды. Укып бетерде дә: «Ни әйтәсең?» – дигәндәй, дустының күзләренә карады.

Разия тиз җавап бирә алмады, хатны кулында әйләндерә-әйләндерә, акрын башлады:

– Алай икән, кадерлем, син мине гафу ит. Ул бер көндә мин сине Йосыфҗанга башкачарак карый бугай дип бер сөйләгән идем... – диде. Бераз уйланып, тагын өстәде: – Син нигә болай кискен язасың? Егетне үтерәсең ич. Ул байлыгын, атасын ташлады, бөтен дөньясын җимереп качты. Шундый чакта син китереп аның йөрәгенә хәнҗәр тыгасың. Ипләбрәк, йомшаграк язсаң ни була? – диде.

Гәүһәрнең күгелҗем күзләрендә нindидер яктылык уйнады, нечкә иреннәрендә елмаю чыкты. Тагы ныграк текәлеп карады:

– Кадерлем, – диде, – хәнҗәр тыкмый ярамый. Миңа бу турыда ачыклык кирәк. Башкача мөмкин түгел, – диде.

Ул бу сүзләр өстенә тагы: «Үзең беләсең, мин Булатны сөям, күңелем сизә, аны тагы эләктерерләр, тагы сөргенгә җибәрерләр, мин аның артыннан Себергә, каторгага бергә китәчәкмен... Минем бәхетем дә, газабым да шунда, минем язмышым аның белән мәңгегә бәгланган»... – дип, туп-туры әйтергә теләде. Ләкин әйтмәде. Ул табигате белән бик артык яшеренүчән кыз иде.

Арада Нина вакыйгалары да булганга, үз язмышының бу тирән серен дөньяда һичкемгә белдерәсе килмәде. Ләкин сүз үзеннән-үзе Булатлар тирәсенә таба борылды. Гәүһәрнең нечкә иреннәрендә алсу нур уйнады, күзләре яктырып, сөю ялкыны белән яна башлады. Йөзеннән матур сөю елмаюы китмәде, тавышында мәхәббәт музыкасы туктамый яңгырады. Ул тел белән: «Мин Булатны яратам!» – дип бер сүз әйтмәде, ләкин аның йөзендә, күзендә уйнаган якты нурдан, гаҗәп якты сөю белән елмаюларыннан, тавышындагы йомшак нечкә музыкасыннан моны үзе сизде.

Ул үзен Гәүһәрдән матуррак саный иде. Ләкин бүген, менә бу сәгатьләрдә, йөзендә-күзендә уйнаган сөю нуры Гәүһәрне дөньяның иң матур кызларыннан да матуррак ясап җибәрде. Разия үз гомерендә беренче тапкыр башка кызның матурлыгына сокланып, яратып, күзләрен ала алмый сөеп карады. Туя алмыйча сокланып карады.

Телдән ул да бер сүз әйтмәде.

– Кадерлем, син бәхетлесең! Мин синең бәхетеңә кызыгам! – диде дә, дустының маңгаеннан үбеп, аякка басты.

Икәү бергә чыктылар.

Капка төбендә үбешеп аерылдылар. Разияга бүген кич иптәшләр киләчәк. Үзара уртак җыелыш булачак. Аңа чаклы шәкертләр белән ясала торган яшерен сәяси түгәрәкне үткәрәсе бар. Кичке җыелыш өчен әзерләнәсе бар. Һәммәсеннән бигрәк, анакай бүген имениегә китә, көндез сәгать өчтә аны озатасы бар. Ул шуларны башкарырга очты.

Гәүһәр Фәхриләргә китте.

Моннан бер атна элек шәһәрнең заводларында зур эш ташлаулар булды. Шунда болай, тыш яктан, эшчеләр җиңү белән беткән кебек иде. Ләкин гамәлдә башкача барып чыкты. Эшчеләр эшкә тотынган көндә үк элекке управляющий чыгарылырга тиеш иде. Аны бары икенче цехка гына күчергәннәр. Эш ташлауга катнашкан өчен һичбер эшче урыныннан чыгарылмаска тиеш иде. Сигез татар эшчесен слесарьлыктан кара эшкә куйганнар. Болар риза булмый талаша башлагач, куып чыгарганнар. Хәзер тагы берьюлы утыз эшчене куалар. Эш ташлау комитетында әгъза булган Галимовны кичә администрация тәртибе белән егерме дүрт сәгать эчендә шәһәрдән сөрделәр. Бу хәлләр һәммәсе җыелып килеп, эшчеләрне бик дулкынландырды. Үткән эш ташлау нәтиҗәсе яхшы булганга, хәзер элек катнашмаганнар да акырып торалар. Менә шуларга карата кичә прокламация басылды, бүген шуны Гәрәй Солтанның иптәше Ивановка тапшырыр өчен заводка кертергә кирәк. Бүген көндезге ашка таралганчы эшчеләр эченә кертеп өлгерергә кирәк Гәүһәргә менә шул тапшырылды. Ул кыз кеше. Тыш яктан беркем дә шикләнерлек түгел. Ул инде монарчы да мондый

хезмәтләрне күп башкарды.

Ул килгәндә Фәхри өйдә иде. Бергә аның фатирына керделәр. Очырмадан бүген төн генә басып әзерләнгән «Татар эшчеләренә» дигән ике төргәк прокламацияне икмәк төсле итеп ашъяулыкка урадылар да култык асларына кыстырып, кире Гәүһәр фатирына килделәр.

Кыз, икенче бүлмәгә чыгып, киң соры платьесын киеп керде. Билен ныграк кысып бәйләде. Төргәкләрне чиштеләр дә, ипләп-ипләп, бу прокламацияләрне платьеның эч ягына – күкрәккә, култык асларына тутырдылар. Ике йөз экземпляр иркен сыйды. Яңадан төймәләрен каптырып, пальтосын кигәч, кызның элекке нечкә буе таза, тулы хатын төсенә керде.

Гәүһәр килгәндә завод капкасында каравыл иде. Аерым рөхсәте булмаган һичкем кертелми иде.

– Управляющий кызы Ольга Дмитриевна кирәк, мин аның танышы! – диде. Әлбәттә, ышанмадылар. Алайса, конторадан аның квартирына телефон белән сорасыннар, дип талашты. Каравыл якын килмәде. Ул ара управляющий үзе ат белән кайтып төште. Зур сакаллы таза кеше икән. Каравыл аңа әйтте:

– Сезнең кызыгызга килгән, кертимме? – диде.

Управляющий елмаеп Гәүһәргә карады, көлде:

– Монда юк-бар коткычылар керә. Шуңа күрә каравыл куйдык, әйдә утырыгыз миңа, – диде.

Ольга белән болар Петербурда бергә, бер курста укыганнар иде. Бик сагынышканнар икән, үбешеп күрештеләр. Сүзләре тиз килешеп китте. Ләкин Гәүһәр аптырады. Бу кыз – Петербурда кызыл иде. Хәзер кем икән? Атасы монда эшчеләрне кыса. Бу да шул юлда булырмы? Әллә һаман да кызылмы? Белеп, ышанып җитә алмады. Серен ачмады. Гүя сүз арасында гына кебек:

– Кадерлем, монда безнең асрауның әнкәсе бар. Кечкенә чакта мине кулында уйнаткан карчык, шул бик авырый диләр, миңа казарманы күрсәтә алмассыңмы? Мин сиңа яңадан керермен. Анда, капкагызда, каравыл ич! – диде.

Ольга аңламадымы, аңламамышка салындымы:

– Ярар, әйдә! – диде дә Гәүһәрне җилтерәтеп алып, татар эшчеләре тора торган зур, иске, ярым караңгы, авыр сасы өйгә алып керде. Үзе: – Мин сине көтәм, – дип, кире очты.

Гәүһәр Ивановны таба алмады, сөрелгән Галимовның хатыны бар икән. Янып торган күзле яшь, чибәр нәрсә. Шул бер күрүдә шикләнде, – Булатлар җибәргән булыр дип, үзенә кертте. Гәүһәр аның кечкенә бүлмәсендә, яңадан чишенеп, тиз-тиз бушанды, кемгә ничек тапшырырга икәнен ике сүздә әйтте

дә кире Ольгага йөгерде. Аның кыставына карамастан, кофе эчәргә кала алмады, тиз-тиз исәнләште дә, үзенә кунакка чакырып, калага сызды.

## LXV
## ШӘКЕРТ ДУЛКЫНЫ

Гәүһәр, калага кайткач, иң элек Нигъмәт казыйны күрде. Ул каядыр ашыга иде. Озак сөйли алмады:

– Эшем бик ашыгыч, шәкертләргә квартир җиткереп булмый! – диде.

Гәүһәр нидер сизенде:

– Мәдрәсәгә ни булган? Аларга нигә квартир?! – диде.

Нигъмәт:

– Анда бунт. Ике мәдрәсә берьюлы кайный, – диде дә йөгерде.

Гәүһәрнең шәкертләр арасында якынрак танышы Җиһангир иде. Ни барын белим дип шунда китте. Ләкин ул да пальтосының төймәләрен каптыра-каптыра йөгерә иде.

– Харап анда, – диде дә мәдрәсәгә таба очты.

Ул вакыт, полициянең гаскәр белән урап алып, тентү ясавы аркасында, Мәдрәсәи исламия эчендәге дулкын ничектер үзеннән-үзе басылган иде. Ләкин ут сүнмәгән, тик көл арасындагы чаткы кебек астыртын. көйрәп яткан икән.

Кадыйр бай ул көндә әйткән сүзеннән кайтмады: «Хәрәкәтнең алдында барган унике шәкертне кумасагыз – мәдрәсәгә бер тиен акча бирмим. Андый фетнәчеләр шәкертне боза», – диде. Кадыйр байдан башка тагы ваграк байлар бар иде. Алар инде акча бирмәскә сылтау гына эзлиләр иде. Гали хәзрәт бу авыр хәлне тиз сизде. Кәрим Гайфи дә бөтен көче белән Кадыйр бай фикерен яклады. Нәтиҗәдә тагы эчке-тышкы идарәнең уртак җыелышлары башланды. Шәкерт боларны сизеп алуга, ул көндәге кебек, «Химая .комитеты»н тагы аякка бастырдылар. Фатирларда, ятак бүлмәләрендә аерым-аерым төркемнәр, үзара җыелышлар ясадылар да, идарәгә сиздермәстән, бөтен мәдрәсәнең гомуми җәмгыяте була дип игълан кылып җибәрделәр. Җиһангир тагын урындыкка менеп кычкырды:

– Иптәшләр, безнең, биргән таләпләребез бар. Без мәдрәсәне ничек ислах итү[1] турында програм бирдек. Без шул сүзләребездә хәзер дә торабызмы, юкмы? Әллә булмаса, жандарлар кереп басуы безнең котны очырдымы? – диде.

Тагын зур шау-шу күтәрелде:

– Юк, без сүздән кайтмыйбыз, безнең сораганнарны бирсеннәр.

---

[1] *Ислах итү* – үзгәртеп кору, реформа ясау.

Булмаса, без мәдрәсә ташлыйбыз! Бөтен татар милләтенә бу мәдрәсәләрнең эшкә ярамавын шуның белән тарих алдында игълан итәбез! – дип акырыштылар.

Тавышка Гали хәзрәт килеп чыкты, аның йөзе агарынган, ләкин тавышы кискен иде:

– Бу ни тавыш? Сез нигә килдегез мәдрәсәгә? Укыргамы, әллә митинг ясаргамы?... Мин сезгә идарәнең рәсми карарын игълан итәм: моннан соң теләсә кем, теләсә ничек җыелыш, җәмгыять ясарга рөхсәт юк. Җыелыш ясарга теләгәндә, алдан идарәгә белдерү лазем. Ул рөхсәт бирсә генә җыелыш була ала, – диде.

Сөләйман Сәйфуллин сикереп менеп кычкырды:

– Шулаймы? Сез революцияне таптыйсызмы? Сез безнең аякка яңадан богау саласызмы? Сез безнең телне кисәсезме? – диде.

Аның артыннан тагы Җиһангир күтәрелде:

– Иптәшләр, – диде, – идарә дигән сүз – ике юан корсак бай белән өч надан хәлфәдән гыйбарәт икәнен беләсез, боларның карары безгә закон була аламы? Без шулар сүзенә карап җыелышларны туктатабызмы? Булмас, туктатмабыз, әйдәгез залга! Әйдәгез, ирекле җыелыш ясыйбыз да үз хәлләребезне тикшерәбез! Җитәр, моңарчы да күп изелдек! Татар шәкерте, син арслан бул! Син үзеңне издермә! Үз теләгең өчен сугышка әзерлән!.. Шулаймы, иптәшләр? – дип, каты кискен тавыш белән бөтен мәдрәсәне кыздырды.

Барлык шәкертләр, гадәттән тыш кайнау-дулкынлау белән дуслашып, кычкырышып, зур залга ташландылар. Гали хәзрәт хәйранлыкта катты, ни эшләргә аптырады. Ләкин үзен-үзе кулга алды. Ул дулкын белән бергә зур залга керде дә уртага басты. Кулы белән селкеп тавышны туктатты. Санаулы аз сүз әйтте:

– Бу, – диде, – мәдрәсә. Монда дини-милли тәрбия өчен яшьләрне җыябыз. Мәдрәсәнең үзенең уставы бар, програмы бар. Һәркем үзе теләп килә. Яратмаса, үзе теләп чыгып китә. Кем дә кем мәдрәсәнең уставына, програмына, идарәнең карарына риза түгел икән – ишекләр ачык, үз юлын үзе карасын! Програм үзгәрми, унике кеше куылачак! – диде.

Аның актык сүзләре зур шау-шу эчендә батты. Әллә ничә җирдән берьюлы «Сада»лар, «Марсельеза» җырлары дөнья җимерәчәктәй тавышлар белән мәдрәсәне, коридорны, ятак бүлмәләрен шаулатты. Бөтен мәдрәсә эче батып барган кораб төсен алды. Шәкертләр, үзләренең алдан әзерләнгән төеннәрен, мендәр-юрганнарын, китапларын күтәреп, югарыдан түбәнгә, бүлмәдән-бүлмәгә йөгерә башладылар. Шул арада, биш минут эчендә, «Химая комитеты» ашыгыч, аягүрә җыелыш ясап ала да мәдрәсәне ташлап

чыгарга дип карар бирә. Аның карары тиз арада бөтен шәкерткә игълан ителә: шәкертләр туктаусыз сүгеш, кычкырыш, талаш белән, «Сада»лар, «Марсельеза»лар шау-шуы эчендә мәдрәсәне ташлап чыгып китәләр.

Мәдрәсәи исламия хәбәре Вафа хәзрәтләрнекенә барып җитә. Анда теге вакыт кырык кеше кул куеп, әфьюнчы Кәбирне мәдрәсәдән куарга сораганнар, булмаса, үтерәбез дип куркытканнар иде. Бу куркыту уңае белән кулга алынган озын буй Рәфыйк Әлхариси кичә генә зинданнан чыгарылган иде. Аның йөрәге ялкынланып утка әйләнде. Атылып Вафа хәзрәт мәдрәсәсенә килде дә кул куйган кырык шәкертнең җыелышын ясады. Монда талаш китте. Берничәләре:

– Без белмәдек. Безне көчләделәр, – дип, җылап җибәрде. Кырыкның унҗидесе шул сәгатьтә үк җыенып, мәдрәсәне ташлады. Шулай итеп, зур дулкын кече дулкынны тартты, бер көндә ике мәдрәсә яшьләре – берсе җәдит, берсе кадим ике мәдрәсәнең һәр икесенә каршы талашлы протест белән урамга ташландылар.

Шәһәр шәкерт белән тулды. Татарның арзанлы номерларында урын калмады, бер бүлмәгә бишәре-алтышары керде. Берничә көнгә халык телендә башка мәсьәлә бетте. Революция аркасында чыга башлаган татар гәзитләре бу шәкертләрне: «Милләт каһарманнары!» – дип, алкыш белән, сәлам белән мактап, зурлап каршы алдылар, һәркайда бу шәкертләр файдасына бик кызу ярдәм җыя башладылар. Татарның киң бер катлавы төбе-тамыры белән кайнады, дулкынланды.

Булат үзе турыдан-туры катнаша алмады. Чөнки ул әле яңа гына Енисейдан качып кайткан иде. Монда бик тар түгәрәк иптәшләрдән башка һичкем аны белергә тиеш түгел иде. Ул Госманга, Фәхригә әйтте. Болар Җиһангирләр аркылы хәрәкәтне куерттылар. Укымышлы татар җәмгыятенең катнашы белән зур җәмгыять ясалды. Шәһәр театрына халык сыймады, күбе урамда калды. Җыелыш бик зур гаугалы булды. Моңарчы тел ача алмаудан гаҗиз булган әфьюнчы Кәбир хәлфә үзе килеп җәнҗал куптарды. Рәис аны куа башлагач, итче Гайнетдин белән тирече Фәсхетдин дөнья җимереп талаш чыгардылар. Миһраннар, тагы шундый мәдрәсәдән чыкмый калган кара уң канат шәкертләр бу җыелышта да идарәләрне яклап азапландылар. Ләкин болар тавышы меңләгән халык ялкыны эчендә бер-ике тамчы пычрак су кебек көеп юк булды. Җәмгыять һәр ике мәдрәсәдән чыккан шәкертләрнең таләпләрен хаклы тапты. Аларның сораган фәннәре, програмнары – татар милләте өчен ут белән су кебек кирәкле нәрсәләр, дип карар чыгарды. Бу карарлар белән бергә:

– Яшәсен ислах! Яшәсен каһарман татар шәкерте! Яшәсен милләтнең яшь көрәшче каһарманнары! – дип гөрләп тавыш күтәрелде.

Бу зур җыелышта шәкерт исеменнән сөйләүчеләр арасында Вафа хәзрәттән куылган Рәфыйк әл-Харисинең сүзе дә, үзе дә халыкка бик ошады. Ул, кичә генә зинданнан чыккан булганга, нык күкрәк киереп әйтте:

– Сез мине зинданга аттыгыз, сез мине яптыру белән мәдрәсә искечә калыр дип өметләндегез... Юк, тарих сезгә «Ясин» укый, сезгә – үлем, кара үлем, әмма яшьләргә – якты киләчәк! – диде.

Җиһангир бу полиция катнаштыру моментын тагы куертып җибәрде. Ул башта татар шәкертенең авыр язмышын сөйләде. Аның бу сүзләре шундый ялкынлы кызу булып чыктылар, күпләрнең күңелләре тулды, күзләренә яшь килде; егет, үз сүзенә үзе дә йомшарып, җылый язды. Ул шулай сөйләп килде дә бөтен җәмгыять өстенә акырды:

– Менә шулай изелгән, шул изелүдән котылыр өчен көрәшкән каһарман шәкертләргә каршы безнең идарә, безнең Кадыйр бай нәрсә әйтте? Ул безне полиция белән, жандар белән куркытты. Ул әйтте: «Без куарбыз, чыкмасалар, полиция ни өчен?.. Әгәр бик карулашсалар, зинданы да ерак түгел», дип әйтте. Менә ул юан корсаклар, ул Гали хәзрәтләр – милләт каһарманы татар яшьләренең көрәшләренә ничек карадылар! Менә без кемгә каршы сугышып чыктык! – дип, сүзен бетерде.

Озак вакыт сугышып зур крепостьны алган гаскәрнең йөрәк дулкыны ничек булса, бу җыелышта бу көннәрдә мәдрәсәне ташлап чыккан егетләрнең дә йөрәкләре шулай дулкыннар белән кайнады. Һәркайда аларны алкышлыйлар. Тәбрик итәләр, каһарман диләр. Кайда барса да, мактап, кул кысып каршы алалар. Үзләренең эчләрендә дәрт, өмит ташкыны кайный, йөзләре көлә, күзләрендә алда киләчәк тормышның матур якты нуры ялтырый. Мәдрәсә бар иде, анда шәкерт булып изелү – зур бәхетсезлек иде. Мәдрәсәне ташладылар, инде алга азат тормышка барачаклар, үзләре теләгән яңа, якты көннәргә барачаклар...

Күңелләр шулай дулкынланды, шулай шатланып, бәйрәм итте.

Ләкин бу бәйрәм һәммәсендә дә булмады. Мәдрәсәи исламияне ташлап чыккан җитмеш шәкертнең уникесе: «Без белмәдек. Безне котырттылар!» – дип, Гали хезрәткә барып тәүбә иттеләр. «Безне кире ал», – дип ялындылар. Хәзрәт боларны гафу итте: идарәнең һәммә эшләренә буйсыну шарты белән яңадан мәдрәсәгә кабул итте.

Дүрт яшь шәкертнең авылдан аталары килеп, эт урынына кыйнап, типкәләп, Гали хәзрәткә тезләндереп, гафу соратып, кабат мәдрәсәгә биреп киттеләр...

Мәдрәсәне ташлап чыкканнарның зур күпчелеге үз юлында каты барды. Болар аталарыннан бөтенләй өзелделәр. Аталарының: «Яңадан кер. Хәзрәтнең аягына егыл! Сүземне тыңламасаң, бала итмәм, бер тиен акча

җибәрмәм. Күземә күренмә!» – дип каргап, куркытып язылган хатлар алдылар. Ләкин җиңелмәделәр. Аталарына җавап та язмыйча, үз өмитләрендә яндылар. Җыелган ярдәмнәр күпкә бармады. Актык әйберләрен сатып ашадылар. Ике тиенгә бер кадак арыш икмәге алырга аптыраган, шул ике тиен булмау сәбәпле тәүлекләр буе ач торган чаклары күп булды. Ләкин алар һаман бәхетлеләр иде, һаман да җиңелмәделәр. Искене сүгеп, яңага ашкыну ялкынында кайнадылар.

Хәллерәкләрнең берничәсе чыгу белән – Истанбулга, Мисырга укырга китте. Ике егет Бәйрүттәге «Американ көллиясе» белән хәбәрләшә башлады. Башкаларның дәртләре, Русиядә калып, рус мәктәпләренә керүдә, бо-лай русча укуда иде.

Унике шәкерт, берләшеп, шәһәр читендә җиде тәңкәгә квартир алдылар, аның идәнен себерү, мичен ягу өчен күршедәге бер татар хатынын айга ике сумнан яллыдылар, шунда торып, барысы бергә айга утыз биш тәңкә түләп, бер студенттан русча укырга тотындылар.

Акчасы барлары башкалары да шулай төрлечә җирләште.

Беразы читкә китте, калганнары гәрчә русча уку дәрте белән янсалар да, кайсы университетка, кайсы институтка керүне, байтагы болай укып учительлеккә имтихан тотуны планга куйган булса да, акча булмаганга, әле якын арада берәр җирдән ярдәм-фәлән күренмәгәнгә, әле хәзергә шулай җыелып искене сүгү, «Марсельеза» җырлау белән көннәр, төннәр үткәрделәр. Ләкин йөзләренә кайгы күләгәсе төшмәде. Чөнки алар яшьләр иде, яшь күңелләре киләчәкнең якты нурлы өмите белән тулып яна иде.

## LXVI
## ИШАН КЫЗЫ САҖИДӘ*

Бу шәкерт дулкыны белән кайнап бушанганнан соң, Җиһангир иң элек Баязидны чыгарту кайгысы белән йөрде. Йосыфҗанга сүз юк, ул акчаны тапты, ләкин прокурор Баязидны чыгару турындагы фикерен үзгәртте. Күкрәгеннән кан килгәнгә, аны байтак вакыт шул зиндан больницасында тоттылар да яңадан унөченче коридорның дүртенче камерасына илтеп яптылар.

Җиһангир үзе Баязидның атасы Җиһан ишанга ике тапкыр озын хат язды, бәлки йомшар, бәлки килер, булмаса, зинданда туграк ашатырга акча-ярдәм җибәрер, дип уйлады. Ләкин ишан йомшармады. Җавап та бирмәде. Шулай да бу хатларның зур бер мәгънәле ягы килеп чыкты.

* 1976 нчы елгы басмада бу бүлекнең исеме «**Ир хакы – Тәңре хакы**» дип үзгәртелгән.

Ишан үзенең улын гаилә эчендә авызга алмый булган. Әлбәттә, аңардан килгән хатларны да хатынына да, кызларына да күрсәтмәгән. Ләкин ундүрт яшьлек кызы Сабирә садакадан килгән акчаларны урлаштыру өчен атасының кесәсенә тыгыла торган икән. Бервакыт, ишан үзе юкта бишмәт кесәсен актарганда, озын бер хат килеп чыга, анда: «Улың Баязид үлем хәлендә, кан эчендә!..» – дигән сүзләр кызның күзенә чалына. Ул, куркып, апасы Саҗидәгә кычкыра:

– Апай, тиз кил, бу ни хәл? Монда Баязид абый турында сүз бара, – ди.

Ике кыз бу хатны урлыйлар. Яшеренеп укыйлар. Ләкин ни эшләргә? Ничек итеп тоткын абзаларына ярдәм итәргә? Моңарчы үзара талашудан бушамаган ике кыз гаҗәп тиз дуслашып китәләр. Яшерен план коралар. Зурысы Саҗидә абыйсы зинданда яткан шәһәргә качып китәргә юл әзерлеге күрә башлый. Кечкенәсе инде бик зур саклык белән ишан атасының кесәләреннән акча урларга керешә. Бер атнада егерме сум урлап җыя. Саҗидә бер караңгы төндә, шул егерме сум белән юлга чыгып, көтелмәгәндә поезд белән караңгы кичтә Җиһангиргә килеп төшә.

Егет өчен бу гаҗәп вакыйга булды. Ул теге Габдрахманның хатыны Нәфисә аркылы Саҗидәгә бер талчукчы татар гаиләсендә бүлмә алып бирә, аны зинданга алып бара. Разиядән, Баязид белән күрешергә сорап, прокурорга гариза яздыра. Ләкин хикмәтле бер хәл килеп чыга. Каяндыр, кем аркылыдыр, бу гариза буенча Җиһан ишанга сүз ирешә, югалган-качкан кызының, монда килеп, абзасына күрешергә йөрү хәбәре барып җитә, ул зур улы, үзенең мөрите Әхмәдулланы шул көндә үк кызы Саҗидә артыннан җибәрә. Монда зур җәнҗал кузгала. Кыз кайтмый да, үзен кыйнарга да бирми. Әхмәдулла белән яман талаша.

– Менә Баязид абый кайчан котылса, мин шул чакта кайтырмын... Аның белән бергә кайтырмын, әгәр аңа кайтырга әткәй рөхсәт итмәсә, мин дә кайтмам! – ди.

Бу кыз бик тиз аңлаучан булып чыкты. Үзе белән алып килгән ике җефәк күлмәген, алтын алкасы белән беләзеген сатты да тоткын абзасына кирәк әйберләрен зинданга илтә башлады, арткан акчасына үзе русча укырга тотынды:

– Бераз хәзерләнәм дә мөгаллимә булам. Әгәр хөкем булып, абзыйны сөрсәләр, бергә китәм! – ди.

Бу кыз вакыйгасы шәһәрдә күп сүзгә сәбәп булды. Аның турында гайбәтләр тулып өлгерде.

Бу гайбәтләр Кадыйр бай хатыны Һаҗәргә дә барып ирешкән булса кирәк. Һич тә көтелмәгәндә Һаҗәрнең асравы килә дә, ишан кызы Саҗидәгә тапшырырга дип, алтын йөзек биреп китә. Җиһангир шашып кала. Чөнки,

күп вакыттан бирле Һаҗәрдән хат булмаганга, әйтеп бетергесез газап эчендә иде.

Ул вакыт Һаҗәр бик канатланып куйды. Ирен ташлап, Җиһангиргә чыгарга күңеленнән карар итте. Бергәләп башка шәһәргә китәргә булдылар. Ләкин шул арада Йосыфҗан качты. Кадыйр бай авырып китте. Докторлар аңа: «тынычлык кирәк», – диделәр.

Хатын шундый чакта ташлап китүне күңеленә сыйдырмады. Бу вакыт аның йөрәге бик күп төрле газаплар эчендә кайнады. Җиһангир белән элекке кебек аулак урында күрешергә чыгарга да, аңа хат язарга да йөрәге җитмәде. Тукта, бүген үтсен, иртәгә, берсекөнгә дип, тик борчыла барды. Шул газаплар, борчулар эчендә вакытның күпмс-азмы үтүе ана билгесез калды.

Кичә Гали хәзрәт остабикәсе мәҗлесендә бик яманлап шул ишан кызы Саҗидәне сөйләделәр.

Һаҗәр сүзгә катнашмады, үз эченнән ничек, ни белән ярдәм итим икән дип уйлады. Кулында акчасы юк иде, күп йөзекләрнең берсен – калын, килешсез, ләкин үлчәүгә авырын сайлады да Җиһангиргә җибәрә куйды.

Егет, бу җепкә тотынып, караңгы газаптан чыкмак булып сикерде. Китергән асрауны көчләп утыртты да хәл сорашты, биш-ун сүзлек кенә ялкынлы хат язды:

«Син мине ташладың... Аны беләм... Шулай да үзеңнән бер сүз, актык бер сүз ишетәсем килә. Ни сәбәп булды, ни нәрсә минем бәхетемне җимерде?! Ике генә сүз яз, җаным, Һаҗәрем!!» – диде.

Шәкерт дулкыннары кайтып беткән көннәрнең берендә, авыр сәгатьтә, асрау елт итеп керде дә, егетнең алдына хат ташлап, йөгереп чыгып качты.

Егет ашыгып хатны ачты. Кабаланып күз йөгертте. Бер кат, ике кат, өч кат укыды. Ләкин йөрәгенә ял булырлык җуаныч сүз тапмады.

«Алай димә, Җиһангиркәем, мине ташладың, димә. Ташламадым, ташламам. Шулай да миңа моннан соң хат язма. Очрашу эзләмә. Күңелем синдә, ләкин мин аның хатыны. Алла шуны теләгән. Ир хакы – Тәңре хакы, диләр».

Кулын куйгач, тагын өстәгән:

«Ышан, Җиһангиркәем! Йөрәгем синең белән тулы! Ышан, мин сине ихлас күңел белән сөйдем һәм сөям. Дөньяда синнән башка бернәрсәм дә калмаган иде. Мең Кадыйрны аяк астында изеп, синең кочагыңа атылудан башканы уйламыйдыр идем. Инде бары да үтте. Бары да ерак, бәхетле, матур төш кебек сагынып уйларга, сагынып җыларга калды... Йөрәгемдә һәркайчан син. Сине мәңге сөячәкмен. Ләкин ни эшлим? Мине кичер: тәкъдирем башка икән!» – дигән.

Җиһангир озак уйлады да утырып җавап хат язды:

«Һаҗәрем, дөньяда син бар идең, мин синең өчен яши идем. Син матур идең, синең тавышың – былбыл сайравы, синең кузгалуларың аккош йөреше иде. Синең йөзләрең хур кызларын хәтерләтә, синең кочагың җәннәтне оныттыра иде.

Инде боларның һәммәсе үтте. Без аерылыштык. Яңадан кавыша алмабыз, һәм теләмим дә. Мин сине аңлыйм дип уйлый идем, ләкин зур ялгышуда булганмын: соңгы сүзләрең белән минем рухым алдында яңа Һаҗәр ачылды. Сиңа булган тойгым да икенче төс алды. Табигать синең кебек җаннарны сирәк ярата. Инде мин яңа Һаҗәрне яңа сөю белән сөям. Элекке сөюем агу эчендә – ширбәт, җәннәт эчендә җәһәннәм иде. Анда якты кояш, кара төн, куркыныч яшен белән матур алсу таң бер-бер артлы алмашыналар иде.... Инде боларның бары да бетте. Инде язгы төн, тын, айлы кичләр килде: шул вакыт мин, урманлы биек таулар арасындагы күл буена барып, таш өстенә ялгызым утырам да, татлы хыялга батып, дөньядан кичәм. Яңа сөюем миңа, иркәм, Һаҗәрем, хәзер менә шулай булып тоела! Хуш!!! Бәгърем! – башка ни языйм, ни гена языйм?!»

Егет, хатны язып, конвертка салгач, кире ачып укыды. Бер сүз арттырып язды:

«Ләкин, Һаҗәрем, дөнья мондый тын, айлы кичә булып тормас. Тагы яшен чыгар, күк күкрәр. Шул вакыт мин тагын, коралланып, сине коткарырга барырмын!» – дип өстәде.

Ләкин яңадан укыгач, моны артык тапты. Хат үзенең элекке йомшак, эчке серле мәгънәсендә калсын – шулай яхшы дип, яңадан яңа кәгазьгә язды, бу сүзләрне анда кертмәде.

## LXVII
## БУРЖУАНЫҢ СУЛ КАБЫРГАСЫННАН

Егет хатны, конвертлап, күкрәк кесәсенә тыкты да урамга чыкты.

Күктән ай карап тора. Йолдызлар җем-җем уйныйлар. Җиһангир, болар нигә шаяралар, дип уйлады. Сәгать сигез булган икән, Разияга җыелып беткәннәрдер. Өч көн элек үк әйтеп куйган иде ич.

Барасымы икән, юкмы икән? Ул ни бер бетмәгән сүз боткасы инде. Разиялар файдасыз, хәзер Гәрәй кирәк. Ул кая икән соң? Шакир солдат дигәннәре бар. Нык, батыр егет. Хәзер балта, сәнәк күтәреп, алпавытны суярга хәзерләнгән кеше кебек, каты карый. Бу арада шулар кирәк. Петербурда бөтен эшче советны таратталар. Ә безнекеләр монда ни эшли? Бу арада нидер әзерләнә бугай. Заводларда тагы эш ташлау көтәләр. Кичә корал магазинын талап чыкканнар. Хәзер шуны эзлиләр. Эт кебек искәнеп эзлиләр. Бүген Кәримовлар типографиясенә[90*] кораллы ун кеше көпә-көндез көчләп

кергәннәр дә бер сәгать эчендә прокламация бастырып чыгып киткәннәр. Ярты сәгатьсез чыкмаска дип, бусагага бомба куеп калдырганнар. Менә болар ярый. Ә без ни эшлибез?

Җиһангир, үзалдына шундый өзек уйлар белән саташып бара-бара, Разияларга җиткәнен сизми дә калды... Ак ишек яңагындагы кечкенә төймәне басканда, арт яктан аяк тавышы якынайган кебек булды. Караса, озынча буйлы, чәч-мыек кырулы чибәр бер рус икән. Бу ни эш? Дәшми-тынмый моның өстенә таба килә. Бу нәрсә, әллә шпикмы? Моны тотып алырга киләме? Кепкасын баса төшкән. Пальто якасын торгызган. Үзе болай чибәр, сөйкемле йөзле кеше. Менә гаҗәп: туп-туры килә, дәшми, кул суза да, моның куркып, ни эшләргә белми аптыраганын сизгәч, хахылдап, кычкырып көлеп җибәрә. Караса, Булат икән. Җиһангир, ул көнне генә сакал-мыек җиткән авыл бае булып килгән Булатны бу хәлдә күрергә уйламаганга, таный алмый калды. Таныгач:

– Син икән! Шпик дип торам! – дип кычкырып җибәрде.

Булат аның кулын кысып көлде:

– Син шпикка әләккәнең юктыр, ахры. Ул алай якын килми. Арттан, почмактан сагалап, күләгә кебек йөри. Бервакыт берсе мине бик җөдәтте шулай, калмый да калмый бит. Извозчикка утырам. Ул да извозчик ала. Вокзалга төшәм, – ул да минем арттан. Заводка кереп чыгам. Ул да мине капка төбендә каршы ала. Екатеринский урамда91* үтә чыгыла торган бер йорт бар. Извозчикны капкага туктаттым да үзем кереп киттем. Ул да туктый да минем арттан йөгерә. Капка баганасы төбендә яшерендем дә торам. Ул кызу-кызу атлап йорт эченә кереп китә. Мин тиз генә чыгам да, извозчикка акчаны төртеп, үзем җәяү йөгерәм... Карасам, бу дуңгыз каршыга атылып килә... Менә ничек йөриләр алар...

Булат сүзен бетерә алмады, асрау чыгып ишекне ачты.

Булат белән Җиһангир өйгә керделәр.

Зариф, бусагада ук туктап, мәҗлес булып утырган җәмәгатькә карады, шелтә катнаш уен тавышы белән Разияга:

– Бу ни эшең синең? Син монда бер парламент җыйгансың ич! Тик монархистлар фракциясенең башлыгы Нигъмәт казый гына юк! – дип, туташка кул бирде.

Кыз үзе генә белә торган бер сәбәптән кызарды. Ләкин аны әйтмәде:

– Җә, син ишектән кермәс борын мине таларга тотынма. Мин бүген – хуҗа! – дип, ике кунакны ике як култыгына алып, мәҗлеснең уртасына китерде. Үзе бик күп төрле тәмле ашамлыклар белән тулы өстәлдән яңа кунакларга тәрилкәләр этәрде, кызу пәрәмәчне Алларына куйды, гөжләп кайнап утырган зур көмеш самовардан чәй ясап бирде дә, уңайсызланып,

мәҗлескә карады.

Хәбип Мансуров аның бу хәлен сизде, ярым көлеп:

– Җә, Разия туташ, син нәрсә Булатка палачка караган кебек куркып карыйсың. Ул ашамас, әйдә, башлаган сүзеңне туктатма! – диде.

Аның бер ягында – Госман, Давыт Урманов, икенче ягында – Акчулпанов, җырчы Сәхип, Сөләйман Сәйфуллин, аларга тоташ Фәхриләр утырганнар иде. Җиһангир тыштан яхшы киенеп йөрсә дә, тамак ягы начар, күп вакыт икмәк-су белән яши иде. Разияның өе үзенең зур көзгеләре, кыйммәтле йомшак урындыклары, мең төрле ут белән уйнап янган зур люстралары, кыйммәтле паласлары, киң яфраклы көньяк гөлләре белән ничаклы хәйран итсә, өстәлдәге майлар, баллар, вареньелар, кечкенә бәлешләр, алмалар, әфлисуннар, яңа гына табадан чыгып килгән пәрәмәчләр аның ашау дәртен кайнаттылар. Ул бераз тартынып, бераз кыюсызлык белән башласа да, тиз ачылды, сүзгә күп колак салмыйча, бәлешләрне, салкын каз итләрен туктаусыз йота башлады.

Мәҗлес, ахры, Булат килми диптер, үзенең төп мәсьәләсенә керешкән булган икән. Бүген бик садә, ләкин гаҗәп килешле киенгән Разия туктаусыз елмаеп, тагын Булатка бәйләнде:

– Зариф, син минем өстемә һаман шелтә белән карыйсың, – диде.

Булат алдындагы суык каз итен кискәләргә пычак сорап алды да шаяртып әйтте:

– Туташ, син үзең кунакка чакырдың, үзең ашарга да ирек бирмисең, һаман миңа бәйләнәсең! Әйдә сөйли бир, мин бик ач килдем, – диде.

Туташ үзенең кыенлыгын җиңә алмады, шулай да болар кергәнче үк башланган мәсьәләсен русча җәеп алып китте:

– Иптәшләр, – диде, – самодержавие җимерелеп бара. Әмма җимерелеп бетмәгән әле. Ул актык көчен җыя. Актык көчләре белән революцияне буып үтерергә сугышка ташлана.... Искедән калма сүз бар. Аер да власть бул, диләр. Революция көчләре чыннан да бик аерымнар. Безнең самодержавиегә каршы ташланырга тиешле көчләребезнең бик күбе үзара талашка, үзара көрәшкә китә. Мин әйтәм, революция көчләренең үзара көрәшләре дошман тегерменәнә су кою булып чыга, революциягә каршы җинаять булып төшә, дим. Безгә менә бу турыда уйларга вакыт булса кирәк... Беләсез, социал-демократларның үз араларында да болай үзара фракция-фракция булып сугышуга каршы фикер кузгалды. Югарыда да кузгалды, түбәндә, масса эчендә дә кузгалды. Әмма татар арасында социализм көчләре бигрәк аз, бу аз көчләр дә үзара сугышып вакыт әрәм итсәләр, бөтен фронт алпавыт, буржуа кулына ачык кала... Мин тышкы формасын яки платформасын билгеләмим. Әмма йөрәгем бик әрнегәнгә, анакайның имениегә китүеннән файдаланып,

сезне мәшәкатьләдем... – диде, бик җүләр мәсьәлә кузгатмадыммы икән, көлмиләрме икән дип, күз чите белән Булатка һәм башкаларга карады.

Моңарчы сүзгә катышмаган Зариф үзалдына: «Шулай!» – дип, каты итеп әйтте дә тәрилкәсенә икенче кисәк суык каз итен салды, пычак-чәнечке белән аны кискәли-кискәли, Разиядан сорады:

– Габдулла абзыйга әйтмәдеңме? Әллә әйтеп тә килмәдеме? – диде. Ул Гәүһәр Илбаева турында да, нигә юк дип, сүз кузгатырга уйлаган иде, ләкин юк-бар елмаюларга сәбәп буласын белгәнгә, аны телгә алмады..

Булатның соравы кызның авырткан ярасына кагылган кебек булды. Ул колак астына төшереп кистергән матур кара чәчләрен кинәт селкеп җибәрде дә рәнҗегән тавыш белән җавап бирде:

– Сөйләмә инде. Мин аңа үзем бардым. Берсендә кызларына әйтеп киттем. Калмасын, барсын, үпкәләрмен, дидем. Икенче тапкыр барганда Хәдичә җиңги очрады. Туташ, ди, син гаеп итмә инде, ди. Монда, ди, теге Яманташның Шакир солдат килгән икән, ике көн буе берәүне дә очрата алмый җөдәп чыккан. Шул урамда мине туры китерде дә бергә кайтты. Аның белән тагы бер кавказлы эшче килгән иде. Аларны күргәч, Габдулла абзаң сагыз кебек ябышып катты, миңа әйтә: син Разия туташка әйт инде, ачуланмасын, бара алмам, дип әйтте, ди...

Туташ бу вакыйганы дулкынланып, рәнҗеп сөйләде дә үзеннән өстәп куйды:

– Ул көн аларда нинди күңелле булган иде... Бүген миңа килмәгән үзе... Һич тә онытмам! – диде. Бернәрсә искә төшереп, тагы кушты: – Кавказлы эшче дигәне безнең Гәрәй түгелме икән, дип уйладым. Хәдичә апа аны бик гайрәтле, үткен нәрсә булса кирәк, шулай күренә, ди. Туташ сине чакырды дип Габдулла абзаңа әйткәч, шул кавказлы дигәне: «Әле сездә шулай һаман чәй янында киңәшләр ясап, вакыт әрәм итү бетмәгәнмени?» – дип, чәнчеп көлде, ди. Шуннан мин аңладым, ул безнең Гәрәйдер дип...

Разия Ширинская кузгаткан мәсьәләдән башта ук шулай бер якка тайпылып киткәннәр иде, моңар эче пошып утырган Тангатаров сүзне үз урынына тартып җибәрде:

– Иптәшләр, – ди, – Разия туташның кузгаткан мәсьәләсе – бик кирәкле зур мәсьәлә. Минемчә, бу програм мәсьәләсе түгел, тактика мәсьәләләре. Туташның сүзе дөрес: дошман көчле, безнең куәтләр аз. Шул аз куәтләрне дә төрле груһларга[1] бүлеп, үзара талашка вакыт әрәм итү – минемчә дә, дошман тегермәненә су кою булып төшәчәк. Нинди формада булыр, әмма революция көчләрен берләштерергә кирәк, – диде.

---

[1] *Груһларга* – төркемнәргә.

Ул кызып, ялкынланып сөйләде, революция өчен һәммә нәрсәне, кирәк булса – партия фанатиклыгын да корбан итәргә чакырды.

– Менә мин анархист, әмма башкалар белән бергә бер фронт булып эшли алам, – дип бетерде.

Акчулпанов та шуңа кушылды. Ул үзенең сүзенә куәт өчен пролетариат хәрәкәте тарихыннан мисаллар китерде.

– Маркс-Энгельснең турыдан-туры җитәкчелеге астында эшләгән Беренче Интернационал[92*] дәверендә анархист прудонистлар, лассальянистлар, тредъюнионистлар, марксистлар кебек төрле агым социалистларының бер оешма эчендә эшләүләре безгә гыйбрәт булырга тиеш, – диде. Сүзен бер сорау белән тәмам итте: – Ул чакта Маркс, Энгельс белән анархист Бакуниннар, Прудоннар[93*], Кропоткиннар бергә, бер фронт тотып бара алганны бүген нигә социал-демократ большевик Булат белән анархист Тангатаровлар, народник Хәбип Мансуровлар бер уртак дошманга каршы бер фронт булып эшли алмасыннар? Разия иптәшнең мәсьәләсен мин шулай дип аңладым. Шуңа күрә мин аңа гаҗәпләнмим, – диде.

Разия бераз җиңеләеп тын алды, ярый, бөтенләй үк көлкегә калмыйм бугай, дип, эченнән юанды. Госман да моңа каршы түгел. Ләкин коры аңлашу, берләшү дигән белән бетми. Нинди нигезләрдә берләшү? Аныңча, мәсьәләнең төбе менә шунда.

Моңарчы сүзгә катнашмыйча, әйдә капчык төпләрен каксыннар әле дип утыргандай, мыек астыннан елмаебрак караган Зариф Булатов кинәт, көлә төшеп, Хәбипкә борылды:

– Җә, бунтарь! Син нигә тик торасың? Сөйлә: Герценнән[94*] башла. Михайловский аркылы Черновка, Гершуниларга[95*] китереп терә. Сиңа башка нәрсә кирәк: Русиянең тарихи юлы бөтен дөньяныкыннан аерым дип нәтиҗә чыгар да народникларның койрыкларына барып тотын! Шулай ич! – диде. Шаркылдап көлеп куйды.

Мансуровның ачудан аскы ирене күгәреп, дерелдәп китте. Үзен тыя алмады:

– Шулай шул. Русиянең тарихи үсү юлы аерым дибез. Народникларның байрагын күтәрәбез, – дип башлап, чыннан да, Герценнәр – Чернышевский – Михайловскийлар аша барып, үзләренең хәзерге атаманнарына тукталды. Анык исәбе зур иде. Ул бүген ике сәгать сөйлим дип әзерләнгән иде. Ләкин Булатның көтелмәгәндә, алдан шаярып, мәҗлес каршында боларның програмын бер көлке төстә аңлатып уйнавы – аны аяк баскан тактасын алып ыргыткан кебек хәлгә куйды. Ул канатлана алмады, тыңлаучыларга бер тәм, бер мәгънә йоктыра алмавын сизенеп, һич көтелмәгәндә сүзен кисте. Ләкин кирелегеннән кайтырга уйламады: «Булат менә үзе сөйләр, иң шәбе аның үз

сүзләренә бәйләнү булачак», – дип, алдына каләм-кәгазь чыгарып салды, фикерен шуңа төенләп тотты.

– Буржуаның сул кабыргасы ди торган иде безнең Гәрәй Солтан иптәш.

Мансурдан соң сүз алган Булат шулай башлады. Разия кинәт кызарып китте, ул бу сүзне үз адресына әйтелә бугай дип аңлаган иде. Ләкин тиз тынычланды. Чөнки Зарифның алдагы сүзләре без народниклар дип күкрәк суга торган эсерларга, Урмановларга, Мансуровларга карата әйтелгәне тиз ачылды.

Булат, чәнчеп, ярым мыскыллабрак дәвам итте:

– Эсер дигән партия буржуазиянең сул кабыргасыннан яралган дип сүгәләр икән, моңа бик гаҗәпсенмәгез. Маркс терминологиясенә салып әйткәндә, бу сүзнең мәгънәсе: элекке народникларның яңа формациясе булган социалист-революционерлар партиясе дигән сүз – буржуазиянең сул фракциясе дигән сүз була. Ленин моны бер түгел, бик күп тапкыр, бик күп мәкаләләрендә ачып салды... – диде дә, берәм-берәм санап, анализга тотынды.

Ләкин Булатның төп исәбе Мансуровлар белән полемика гына, аларны каплау гына түгел иде. Монда авызларын ачып, сусаган кеше су эчкән кебек йотып утырган партиясез яшьләр, шәкертләр бар. Ул бигрәк менә шуларны күз алдында тотты. Мәсьәләләрнең принцип ягына күчен, озак сөйләде. Сүз башына Марксны куйды. Бөтен тарих – сыйныфлар көрәшенең тарихы дип нигезләде. Европада, Русиядә пролетариат хәрәкәтенең зур моментларына тукталды. Народникларга – эсерларга каршы каты көрәшнең хәзерге кискен мәгънәсен ачты. Яңадан кабатлап:

– Боларда социализмның бер мыскалы да юк. Болар тик буржуазиянең сул фракциясе генә. Гәрәйнең: «Болар буржуаның сул канатыннан яратылган бушбугаз бунтарьлар!» – дип сүгүенең нигезе менә шунда, – диде дә меньшевикларга күчте, аларга каршы сугыш алып китте.

Башта дерелдәп алган Разия киң сулап рәхәтләнде, ярый, миңа төшми бугай, дип шатланды. Җиһангир, җырчы Сәхип кебек мәдрәсә яшьләренә болай бер чәй мәҗлесендә иркенләп, мондый сүзләрне аңлау сирәк насыйп була иде. Алар лекция яки доклад алдында утырган кебек йотылдылар. Тик җырчы Сәхип туктаусыз Разия туташ өчен борчылу сизенде, Зариф аңа кайтып бәйләнмәсә генә ярар иде, аның «берләшү» турындагы тәкдимен харап итмәсә генә ярар иде дип, эченнән теләнде. Ләкин Булат нәкъ ул сизенгән, ул куркынган мәсьәлә белән сүзен бетерде. Ярым шаярган, ярым чәнечкән тавыш белән нәтиҗәләде:

– Менә, – диде, – безнең юл шул! Мин берләшергә әзермен. Тик бер шарт, «кечкенә» генә, бик «кечкенә» генә бер шарт бар: сез безнең

програмны, безнең уставны кабул итәсез, менә шул нигездә берләшү булачак. Башкача мөмкин түгел, башкача булганда без үзебезнең юл өчен, безнең програм, безнең тактикага каршы торганнар белән рәхимсез сугыш алып барачакбыз!.. – диде дә, аягүрә торып, муенындагы кашнесын төзәтә-төзәтә, өстәл тирәсендәгеләрне кузгатып-кысып, чыга башлады.

Аңа бер яктан Акчулпанов кычкырып бәйләнергә тотынды:

– Бу дөрес түгел. Хәзерге көндә массада да, Үзәк комитетта да берләшү лозунгысы бара. Күп организациядә ике фракция берләште хәзер! – дип, Зарифның юлына каршы тукталды.

Икенче яктан Хәбип Мансуров бәйләнде:

– Ник качасың? Әйдә, безнекен дә тыңла. Шүрлисеңме? – дип, каршы күтәрелде.

Булат тукталмады, шау-шуга карамады, барып чөйдән соры кепкасын алып киде, кара пальтосының эре төймәләрен каптыра-каптыра, иң элек Хәйдәргә:

– Син ике әйберне бутама. Ул берләшү белән Разия туташ кузгаткан «берләшү» икесе бөтенләй ике нәрсә ич. Боларны саташтыру сиңа оят. Уртак фронт мәсьәләсе дә башка нәрсә. Чикләрне нык, тирән сызарга кирәк. Син күп укыгансың, әмма үзең буталасың, – диде; Мансуровка әйләнде: – Синең телең кычыта булыр. Әмма минем бер минут кичегергә ярамый торган эшем бар. Дөнья җимерелсә дә, артык кала алмыйм. Талашырга кеше кирәк булса, әнә Госман абзый кала! – диде, бөтен мәҗлескә, кепкасын салып башын иде дә Разиянең култыгыннан алды: – Әйдә, син мине ишеккә чаклы озата күр, таламасыннар болар, – дип көлде.

Чыкканда, бусага өстендә дә, кул кысканда да, туташка кабатлады:

– Син бераз буталгансың, Разия. Озак сөйләшеп булмады, минем кичегергә мөмкин булмаган эшем бар, миңа ачулана күрмә. Сыйлавыңа рәхмәт. Каз ите гаҗәп тәмле булды! – диде дә урамның караңгылыгы эчендә югалды.

Туташ аптырап өйгә керде, аның өчен бөтен җыелышның мәгънәсе югалган кебек булды. Шулай да белдермәскә тырышып, шат йөз белән бүлмәдәге мәҗлескә кайтты.

## LXVIII
## БЕЗДӘ СЫЙНЫФ ЮК

Керсә, монда Госман белән Хәбип Мансуров бугазга-бугаз талашалар. Разия Булаттан алган рәнҗешләрен онытты. Үзе башлаган мәсьәлә тирәсендә бу чаклы тавыш кузгалуына шатланды, бер яктан талашка кушылырга әзерләнде.

Ләкин аңа вакыт бирмәделәр. Тагы ишектә кыңгырау ишетелде. Иптәшләр, полиция түгелме, барыбызны берьюлы эләктермәсеннәр, диештеләр. Разия бераз кызарды, юк, булмас, иптәшләрдән берәрседер дип, ишеккә таба йөгерде.

Ни күрсеннәр, зур, калын гәүдәсе белән селкенә-селкенә, ишектән үк калын тавышы белән нидер сөйләнеп, Нигъмәт казый килеп кермәсенме! Разия чәч төпләренәчә кып-кызыл булды. Иптәшләреннән гафу үтенгән сыман:

– Мин бер мәсьәләдә эштән чыгып егылдым. Инде тагы ни диярсез? Тагын шуңа ошаш әйбер бар, – диде. Нигъмәтне Булат урынына утыртып, аңа чәй ясады да үзенең бу икенче «трагедия»сен сөйләп бирде: – Әхмәт Нурыйны белә булырсыз. Ул миңа хатыны ягыннан әзрәк кардәш кеше, татарча әйтсәк, җизни кеше. Менә шул минем җаныма тиеп бетте: «Без «Иттифак» төзедек, без һәммә мөселманны берләштерәбез, яшьләр генә читтә калмасын, алар безгә каршы сугышмасын, урынсыз талашларны куеп, милли теләкләр юлында самодержавиегә каршы һәммәбез берләшергә кирәк! Син, балдыз, яшьләр эчендә кайныйсың, шул турыда бер аңлашуның чарасын күр», – дип үтенгән иде... Бер гөнаһны да өстемә алмыйм, мин илче генә... Илчегә үлем юк!.. Нигъмәт казый менә шулар ягыннан килә булыр, – диде.

Ул сүзен бетерә алмады, Урманов кычкырып көлеп җибәрде:

– Кара син ул Әхмәт Нурыйны! Шундый оятсыз икән: имеш, самодержавиегә каршы көрәш дип сүз сөйли. Ә үзе «Иттифак»ның үзәк комитетында әгъза. Аның организаторы. Беләсезме, анда ни бар? Аларның програмында ачык әйтелә: хокукы бераз чикләнгән патша булыр, ди. Димәк, алар монархистлар... Тагы алар програмында, алпавытның җирен алып, крәстиәнгә бирергә туры килсә, моның өчен алпавытка гадел бәһа белән җир хакы түләнер, диелгән... Димәк, алар крәстиәннән ике тире суярга тели торган монархистлар булалар... Ә сез, Разия туташ, шулар белән берләшергә дип безне чакырасыз... Бу ни эш бу?

Разия кулын-башын селкеп протест ясый башлый:

– Юк, ялганлама... Мин кузгатмадым, алар үзләре... Менә Нигъмәт казый, – дип кычкырып җибәрде.

Бу арада Нигъмәт бераз ашап алган иде, бөтенләй рәсми төс белән аякка басты. Озак, куәтле сөйләде, сүзенең үзәге шул иде:

– Бездә капитализм юк. Татарның буржуазиясе юк. Пролетариаты юк. Булса да, бик аз. Бездә сыйныф нигезендә аерылып, үзара сугышырга урын юк. Без милләт намына[1] арадагы аз-маз ихтилафларны[1] ташламалы!

---

[1] *Намына* – хакына.

Моңа каршы Җиһангир, кызу сөйләп, җимереп ыргытырга исәпләгән иде. Урманов сизеп алды да кыска тотар өчен тәкъдим кертте:

– Безнең караш ачык. Бу хакта ике сүз юк. Мин мәсьәләне нәүбәттән алып ташларга кирәк дим!

Һәммәсе шуңа кушылдылар.

Нигъмәт казый ашап туйды. Туташка, кул кысып, рәхмәт укыды да аз гына да рәнҗү төсе чыкмаган тавыш белән бераз көлә төшеп әйтте:

– Дөньяда сезнең кебек кире кешеләр аз булыр!.. Чәнчелегез; сыйнфый көрәшләрегез, социализмыгыз, буржуа-пролетарларыгыз белән бергә җәһәннәмгә китегез! – диде. Шулай көлә-көлә ишеккә җиткәч, кире борылды да бу талаш эчендә башын югалткан җырчы Сәхипкә килеп әйтте: – Син әзерлән. Арба төшү белән китәрбез... Минем атай бик чакырып яза. Үзеңне нык сыйлярлар: безнең карт көе килгәндә бик юмарт кеше: сиңа май, йомырка теләгәнчә булыр, коймак, бәлеш өзелмәс. Тутырган тавыкка рәхәтләнерсең. Симез бәрән суярлар. Майлы казылык ашатырлар. Син монда ачлыктан кипкәнсең. Әйдә, әзерлән, арба тәгәри башлауга китәрбез, без баруга бия бәйләрләр, кымыз да теләгәнчә булыр! – диде.

Мондагылар шаулап калды, – ул кул селкеп чыгып сызды.

Разия Нигъмәтне озатып кергән генә иде, тегеннән асрау килеп, аның колагына пыш-пыш әйтте:

– Анда, – диде, – әллә нинди бер катын бар. Ахылдап беткән. Кер дисәм, керми. Сине сорый.

– Болай соң кем килер икән? – дип, бераз шикләнә төшеп чыкса, анда иске сырган бишмәт кигән, башына тузган калын шәл япкан бер хатын тора. Башта танымады, таныгач, куркып-шатланып, аның җиңеннән тотты: – Әй, Хәдичә апа, син икәнсең! Әйдә кер. Габдулла абзый ник килмәде? Мин бик үпкәләдем. Ул көн сездә шундый күңелле булган иде, бүген үзе мине санга да алмаган! – диде.

Кызның бу сүз ташкынын Хәдичә апа кыенланып бүлде:

– Алай димә, туташ! Картым сине ул көн бик яратып калды. Алар кешесеннән мондыйлар чыгар икән, ди. Ул бүген сиңа бик килмәкче иде. Кавказлы Гәрәй дигән бар бит. Шул Урал ягыннан бүген кич кенә кайтып төшкән икән. Теге Шакир солдат белән Габдулла абзаңны алды да, кайдадыр бергә киттеләр. Ул тимер ыргак кебек кеше ул, бер эләктерсә, ычкындырырлык түгел... Тукта, Ходаем, минем башым таркау шул. Габдулла абзаң хәзер генә кайтты да мине сиңа җибәрде... Бар әйт, таралсыннар, бүген калада бик күп тентүләр, ябулар бара, ди. Петербур белән Мәскәүдә

---

[1] *Ихтилаф* – каршылык.

кызылларны суеп, асып бетергәннәр имеш, инде монда да шуңа керешәләр имеш, тиз таралсыннар, жандар килеп басар үзләрен, дип әйтергә кушты, – ди.

Сүзен әйтте дә Хәдичә апа, иске шәленә капланып, китә башлады. Разия туташ:

– Рәхмәт апа, Габдулла абзыйга да рәхмәт, сиңа да рәхмәт! – диде дә, хатынны кочаклап, иреннәреннән, яңакларыннан үпте.

Мондый чыгышларга гадәтләнмәгән фәкыйрь хатын аптырап калды, бер сүз әйтмичә, авызын, яңагын шәл чите белән сөртә-сөртә кайтып китте.

Разия атлыгып керде дә иң элек Давыт янына барып утырды, ничаклы яшерергә тырышса да, булдыра алмады, борчулы тавыш белән сөйли башлады:

– Яңа хәбәр булган булса кирәк. Бүген кич кенә Гәрәй Уралдан кайтып төшкән икән. Шуның аркылы белгәннәр. Габдулла абзый әйтеп җибәргән: Мәскәүдә, Петербурда зур проваллар[1] бара, монда да бүген әллә ничаклы урыннарда ябулар, тентүләр... дигән, тизрәк таралсыннар, эләгерләр, дип әйтергә кушып җибәргән.

Сүз уртасында Хәбип Мансуров та колак салган иде. Ул бик тиз исәпләп өлгерде: Петербурда Эшче депутатлар советын таратып, президиумын кулга алдылар. Мәскәүдә декабрь кораллы күтәрелешен кан эчендә бастылар[96*]... Инде Думаны да кудылар[97*]. Болар һәммәсе контрреволюциянең нык, кискен җиңеп баруын күрсәтә иде. Миеннән, хыялыннан кичкән бу ашыгыч кара уйлар аның күзендә ялтырады, куркыныч якынлашкан чакта җәнлек ни хәлдә булса, Качкын да шуңа ошаш бернәрсә сизенде. Сүзнең ахырын көтмәде, сикереп торды да Разияга:

– Син пианинога утыр. Сәхип җырласын! Без таралабыз! – диде.

Туташ, ясамадан йөзенә шаян шатлык нуры чыгарып, Сәхипкә әйләнде:

– Сез гаҗәп матур җырлыйсыз! Әйдәгез, мин «Ашказар»ны уйныйм, сез җырлагыз! – диде.

Залда матур «Ашказар» яңгырап калды. Госманнар, Качкыннар, Давытлар акрын-акрын чыгып югалдылар.

## LXIX
## БЕЗ ПАТШАНЫ АСАБЫЗМЫ?

Ләкин зурлар киткәч, болар үзләре генә озак кала алмадылар, эшнең төбен белгәнгә, туташ үзенең бу соңгы кунакларын артык көчләмәде:

– Инде менә минем кая торганны белдегез, миңа килгәләгез, – дип,

---

[1] *Провал* – уңышсызлыка очрау (дучар булу).

берәм-берәм күрешеп, кул кысып, һәммәсен озатты.

Иптәшләр таралгач, Разия, яңадан пианинога утырып, берничә озын башкорт моңын уйнады да ялгызы уйга чумды. Менә егетләр. Берәм-берәм аның күз алдыннан үтәләр. Боларны нинди язмыш көтә? Шулаймы икән? Петербурда, Мәскәүдә зур ябулар, асулармы икән? Чыннан да революция җиңеләме икән? Шул чаклы каннар, корбаннар һәммәсе әрәм китәрме икән? Юк, булмас! Булат бернәрсә сиздеме икән? Нидер сизеп, кайдандыр Мәскәү-Петербур хәбәрләрен белеп, шулай ашыгыч чыгып киттеме икән? Ул башка нәрсә әйтмәде: «Һич тә мөмкин түгел калырга! Минем эшем бар, кичегергә ярамый торган эшем бар!» – диде. Ул нинди эш? Гәрәй Солтан да кайтып төшкән, ди. Бүген кич кайтып төшә дә шунда ук Шакир солдат белән Габдулла абзыйны эләктереп ала? Ул ни эшли? Бу икене үзенә тартмакчы буламы? Алар белән ни җимерә? Гәрәйнең башында һаман-һаман бер нәрсә иде: ул, самодержавиегә каршы кораллы сугыш кирәк, шуңа әзерләнергә кирәк, ди иде. Бу Габдулла абзыйны, Мансуровлардан тартып алып, үзенең кораллы дружинасына кертмәкче, Шакир солдатны сугыш эшен өйрәтергә җикмәкче икән? Бөтен Русиядә эш ташлау булды. Булды да туктады. Петербурның Эшче депутатлар советы бар иде. Аны да яптылар, президиумын сөрделәр. Мәскәүдә кораллы сугыш булды. Ул да җиңелде. Шулай әллә бетәләрме икән? Шулай бетәбезме икән? Контрреволюция җиңәме икән?

Бу авыр куркыныч сораулар туташның башын катырдылар. Ул авыр уйларның әле бер ягына, әле икенче ягына ташланды, ләкин очына чыга алмады. Бүлмә буйлап йөри-йөри, өстәлгә килеп утырды да кулы белән яңагына таянды: «Китеп барды шул. Булат булса, ачык бернәрсә әйткән булыр иде. Җүнле егет! Төпле егет. Тик бик артык кискен бара. Ярамый. Дөньяда алай һәммә нәрсәне үткен пычак белән кисеп төшереп булмый ич. Үзе болай сөйләгәндә ягымлы, чибәр була. Арада иң якты сурәт булып күз алдымда ул калды. Тик күзләре генә ничектер бераз чәнчеп, бераз мыскыл итеп карыйлар. Һәммә кешегә шулаймы, әллә морза кызы дип миңа гына шулаймы? Аның чибәр сылу йөзендә бер кискенлек бар. Күзләре, әйтерсең, нур чәчәләр. Болай тәрбиясез дә түгел. Теләгәндә киенә дә белә. Ничек кызык: әле яңа гына авыл бае булып, сакал үстереп кайткан иде, бүген немец эшче мастеры кебек кырынган, кепка кигән. Бүген баштан ук каты бәйләнде. Шулай да бераз елмая төшеп, күкрәк тавышы белән сөйләгәндә йөрәгеңә керә, сүзендә акыл, тирән уй ялтырый!..»

Шулай хыялланганда кинәт аның Нинасы хәтерләнде. Туташның тәненә суык су белән койдылар. Шулай чирканып китте: «Фу, валлаһи! Шундый томшыкларның нәрсәсенә исерәләрдер?! Ирләрдә зәвык дигәнең

бөтенләй юк бугай шул!»

Туташ бу төнне дә тынычсыз кичерде... Йокы арасында, һаман аның саташулы хыялы эчендә революция белән контрреволюция көчләре бәрелештеләр. Ул диңгез дулкыннары эчендә бер яктан икенче якка ташланып җәфаланды.

Давыт Урманов, Разиядан чыккач, почмакта Мансуровлар, Җиһангирләр белән исәнләште дә шәһәр читенә, үзенең җәһәннәм базына таба юнәлде.

Анда капка төбендә эскәмия. Эскәмиядә кемдер утыра. Аннан сак тавыш:

– Урманов, синме? Тукта!

Давыт чак таныды:

– Габдулла абзый, синме?

Абдул җавап бирмичә үк Урмановның кулыннан алды да, акрын атлап, кире якка таба алып китте:

– Бүген, – диде, – тентүләр, ябулар бара... Яңа гына Уралдан Гәрәй кайтып төште. Ул әйтә, Мәскәүдә, Петербурда да жандарлар бик баш күтәрәләр, ди. Бүлмәңдә бик ашыгыч кирәк нәрсәң булмаса, син кереп торма. Хәзер төрмәгә эләгеп, хәл җыеп ята торган чак түгел... Йомышың булса, иртәгә Хәдичә апаң карар, кайда очрашырга икәнен генә әйт, – диде.

Шуның белән аерылдылар. Давыт тентүдән, полициядән, жандардан бигрәк бу эшче турында уйга чумды: «Нинди яхшы, акыллы сөйли. Ничек әмер бирә! Әле кайчан гына бу – исерек Абдул иде. Әле кайчан гына бу – хатынының актык әйберләрен сатып эчә, урамда, пычракта аунап, фуражкаларын югалтып кайта, әле кайчан гына бу, җыелышларга эчеп барып, талаш куптара иде! Әле кайчан гына бу – патшага каршы, байга каршы көрәшү турындагы иң гади сүзләрне дә башына сыйдыра алмый иде. Хәзер кем булган? Кем булган! Их, гаҗәп могҗизаларың бар синең, революция!»

Габдулла абзыйдан аерылгач, Давытның алдына мәсьәлә килеп басты: кая барырга? Төнне кайда үткәрергә? Иң әйбәте, әлбәттә, Разиядә булыр иде: ул йорт, ул фамилия полиция алдында да ышанычлы. Анда рәхәтләнеп йокларга йомшак ятак та табылыр иде. Разия үзе эченнән шатланыр иде. Ләкин мөмкин түгел. Әле тормыш иске мещанлык богаулары эчендә бара. Ничек кенә дисәң дә, булмый торган эш: кайткач ишетсә, Алмасбикә карчык акылыннан язар. Разия турында да дөнья пычрак гайбәт белән тулыр.

Тукта, Габдрахман һаман бәйләнә бит: килмисең, безне исәпкә санамыйсың, ди. Нәфисәгә өйләнеп, яңа квартирга күчкәннән бирле аңа барганым юк. Вакыт соң соңын. Шулай да ни зарар? Алар бала-чагалы кеше

түгел ич!

Егет шунда борылды.

Бәхеткә каршы, капкалары бикле түгел икән. Әнә йорт уртасында ике катлы агач өй. Шуның түбәнге катында дигән иде бугай. Тәрәзәләрендә ут яна. Димәк, йокламаганнар. Тышкы ишеккә бик аз гына шакылдату белән, эчтән берәү йомшак басып ишеккә килде дә бераз куркынган тавыш белән:

– Кем бар? – дип сорады.

– Мин, Урманов. Габдрахман өйдәме?

Эчтәге кеше аптырап калды, бер ачарга теләп, ишек тоткасына кулын салгач, куркынып кире чигенде. Ачкыч өйдә калган икән дип, каушап, калтырап, яңадан эчкә йөгерде. Хәлбуки, ачкыч ишектә иде. Хатынның болай каушавы – ире өйдә булмаудан, аның ахмакча көнләшүеннән иде. Туп-туры кертсә, ире дөнья куптарачак, кертми җибәрергә дә көче җитми – чөнки аның беренче мәхәббәте һәм әле дә изге бөти кебек кадерләп, йөрәк төбендә саклаган кешесе килгән. Ни эшләргә белми аптырап өйгә йөгерсә дә, анда да киңәшергә һичкем юк...

Ишек төбендә бу икеләнү газабы барган секундта, арттан берәү килде дә Давытны кинәт кочаклап алды:

– Менә рәхмәт! Менә рәхмәт дигәч, рәхмәт!.. Безне искә төшерми дип Нәфисә бик үпкәли иде, рәхмәт дигәч, рәхмәт сиңа!

Караса, купшы приказчик белән Габдрахман икән. Кул бирешеп исәнләшүгә Габдрахман ишекне бик каты дөбертәдә башлады. Тегеннән бөтенләй икенче төрле басып Нәфисә килде, каты, салкын тавыш белән сорады:

– Габдрахман, синме? – диде.

– Мин, Нәфисә, мин! Ач, тизрәк, сиңа берьюлы ике кунак. Беләмсең, кемне әләктердем: Давытны, беләмсең, Давытны! Аның белән тагы Фәхри иптәш тә бар.

Дүртәү беренче ашыгыч сүзләр, исәнләшүләр белән шаулашып өйгә керделәр.

Нәфисә шатлыгыннан ни эшләргә белмәде; йөзе бер агарды, бер кызарды, сулышы кысылды, сүзен әйтә алмас булды.

Урманов, ишек төбендә пальтосын сала-сала:

– Сез тазаргансыз! Чибәрләнә төшкәнсез, – дип гади мактау сүзләрен әйтеп, аның кулын кысты, килә алмый йөрүенә гафу үтенде. Хатын бераз тынычлана, җанлана башлады.

Квартир матур. Бар кадәренчә җыйнак, пөхтә. Зал урынына исәпләнә торган зур бүлмәдә яңа урындыклар, диваннар, кечерәк көзгеләр белән бер китап өстәле дә бар. Анда татарча китаплар, кайбер гәзитләр яталар. Шуның

янында ук граммофон. Аның турына югары тәрәзәгә читлек белән сандугач асылган. Урманов бу граммофон белән сандугачка карап елмайды:

– Әле сез ни арада бу чаклы байлык җыя алдыгыз?

Габдрахман үз каршындагы купшы приказчик Фәхригә төртте, үзе көлде:

– Алар менә Фәхринеке. Бу квартирга күчкәч, бүләк итеп китерде: гаиләнең бәхете шулардан башка булмый! ди.

Нәфисәнең күңеле өчен Давыт өстәлдәге, этажеркадагы китапларны актарып, берәм-берәм мактау сүзләре әйтеп үтте. Эчке мәхәббәт белән янган яшь хатынның күзендә шатлык нуры балкыды:

– Сез эчтән көләсездер инде... Без әле яңа корылып киләбез шул... Ул җитми, бу җитми... – диде дә кухня бүлмәсенә йөгерде. Тиз арада аннан самовар гөрләгән тавышка буталып, май исе, кызган ит, кызган камырмы, коймакмы исе килә башлады.

Егетләр диванга, урындыкларга урнаштылар.

Габдрахман шәһәр хәлләрен сөйләп китте. Анда сәяси хәбәр дә, гайбәт тә, авыр трагедияләр белән комедияләр – бары да бергә кайный икән. Иң элек, иң яңа кайгы дип, Егорның асылуын сөйләде. Ул аны якыннан белгән икән. Аннан зиндандагы тоткыннарны сер әйттерер өчен ничек газаплауларына күчте. Думага барып җитте. Анда большевик ораторларның хөкүмәткә кискен бәйләнүләренә тукталды. Аннан туры Кадыйр байга сикерде:

– Шартлый бит, малай. Шартлый дигәч, шартлый: кичә ишеттем: аның яшь бикәсе Һаҗәр белән Җиһангир турында яман бәет чыгарганнар. Безнең жырчы Сәхип әйтә: теге «Икмәк беткән көй»не чыгаручы Хәйри белән миңа әйткәннәр иде, Кадыйрның дошманы Салих бай дүрт аршин пустау, бер кадак чәй, өч сум акча бирәчәк, син һәркайда ятлап җырларлык шәп бәет чыгар дигәннәр иде дә, мин якын килмәдем, ди. Аннан соң, ди, теге эт авыз Миһраннан чыгартканнар, ди. Хәзер шуны сукыр хәерчегә ятлатып, өйдән-өйгә кереп укыттыралар, ди. Чүп өстенә чүмәлә: байның улы Йосыфҗан да, күп алтын эләктереп, Истанбулга укырга качкан, ди. Шул Одессадан атасына телеграм биргән имеш, ди. «Ачка үлсәм үләрмен, иллә-мәгәр яңадан сиңа кайтып ялынмам!» – дип әйткән, ди... Харап бит, малай, бер җимерелсә җимерелә бит... Әйтмә инде, бу җимерелүнең башы менә бу кызыл авызлардан китте. – Шулай дип, Габдрахман үзенең дусты Фәхригә тагы төртте.

Бу өстәлдә альбом карап утыра иде, үзенә сүз килеп җиткәнен сизенде:

– Ну, Давыт, – ди, – ул чакта укыттык бит Кадыйр байның арт сабакларын! – диде дә, ипләп утырып, мең дә беренче тапкыр үзенең шул зур

каһарманлык күрсәткән минутларын сөйләргә кереште: – Шулай, атна кич, – ди, – безнең бай, зур корсагын киереп, магазинга керә дә кул куяр өчен контор өстәленә салынган кәгазьләрне актара башлый. Үзе ачулымы-ниме, һичкемгә һичбер сүз әйтми: кибәк ашап күбенгән сыер кебек пуф-ф... пуф-ф итеп тора. Безнең доверенный бик ялагай нәрсә: намазга торган кебек олылап, байның каршына бара да бөгелә-сыгыла нидер сөйләргә тели. Ачулы Кадыйр аңа күтәрелеп тә карамый: «Бар әле, бар, соңыннан карарбыз», – дип, кул гына селкә. Көн кичегеп тә бара иде инде. Ул болай да магазинда озак тормый. Йә чыгып-нитеп китә башлар, дидем дә, мин аның алдына бардым: «Бай абзый, мин әйтәм, сезгә бер-ике авыз сүз бар иде», – мин әйтәм. Ул миңа күтәрелеп тә карарга теләми. «Бар, кит әле, кәефем юк, иртәгә килерсең», – дип, кул гына селкә. «Юк, мин әйтәм. Минем йомышым иртәгә кала торган түгел», – дим. Ул, ахрысы, минем тавышка гаҗәпләндеме дим, ачу белән башын күтәреп, минем өс-башыма карады: миндә өр-яңа тегелгән костюм, муенда ак яка, җефәк галстук, аякта сары ботинка, баш ялангач, чәч кирегә таралган. Бай элек һичбер вакыт мине мондый рәвештә күргәне юк иде. Күтәрелеп карагач, аптырап китте, шунда ук ачуыннан кара көеп: «Бу ни эш бу?! Бу нинди кыяфәт?! Бар, хәзер күземнән югал!» – дип, минем өстемә җикеренде. Мин багана кебек катып торам. Урынымнан кузгалмыйм: «Минем, дим, мин әйтәм, зур йомышым бар, дим, мин әйтәм. Мин сезгә, дим, хезмәткә ялланган чакта озын бишмәт, җәенке кәләпүш белән савырлы читектән[1] башка нәрсә кимәскә сүз бирмәдем», – дим. Ул тагын кыза, күзләре акая, менә хәзер бер сүз белән сине дөньядан юк итәренә ышангандай: «Ишетәмсең? Сиңа әйтәм: бар, күз алдымнан югал! Бу нинди ахмаклык тагы!» – ди. Шунда миннән ерак түгел, пустау әрҗәсен бушатып, Гыйльметдин тора иде. Ул да чыдамады, байның бик кызганын күргәч, сүзгә килеп кушылды: «Бай абзый, сез, ди, Фәхринең бер үзен генә гаепләмәгез... Ул үзеннән түгел, без аны сайлап, сезнең белән сөйләшергә кушып җибәрдек. Болай булса, безнең түзәргә хәлебез калмады. Кичә тугыздан ишекне бикләделәр. Өченче көн театрдан кайткан ике иптәшне таң атканчы ишек төбендә тоттылар. Алар туңып беттеләр. Кәримгә ниндидер счет тактасын ярган өчен ике сум штраф салганнар. Ашау юк, эш муеннан. Җалония – хәерче акчасы гына. Болай булса, без ничек торыйк? Без адәм түгелмени? Безнең дә дөньяга карыйсыбыз килмимени?» – ди. Бай тагы җенләнә: «Сиңа ни калган? Син тагы нәрсә лыгырдыйсың? Дөнья иркен. Ачтан үләсегез килсә, бар, дөмегегез... Кергәндә ялынып керәләр. Аз гына тамаклары туйгач, өскә ыргый башлыйлар... Эт симерсә, иясен талый, дигәннәр... Минем

---

[1] *Савырлы читек* – ат савырыннан ясалган күннән тегелгән сыйфатлы читек.

икмәгем белән артык симердегез... Җүнсезләр», – ди. Сүз зурая. Бөтен иптәшләр дә килеп тыгылалар. Мин инде, болай булгач, бөтенләй канатландым: «Мин, дим, бер Фәхри түгел. Мин, дим, һәммә иптәшләр исеменнән сөйлим. Без болай яши алмыйбыз, дим, без ике магазиндагы егерме биш приказчик җыелып киңәштек... Безгә, дим, эш хакы арттырылсын, төнге сәгать уникегәчә чыгып йөрергә рөхсәт ителсен, дим. Бәйрәм көннәрендә арткы ишектән кереп эшләтү бетерелсен, дим. Безгә, дим, атнага бөтен бер көн ял итәргә булсын, эш вакыты сигез сәгатьтән артмасын, безнең белән кеше кебек мөгамәлә кылынсын, дим. Без, дим, барыбер адәмнәр, безнең өскә һич сәбәпсез аяк тибеп акырмасыннар, дим. Безне, дим, хуҗа йортында хатын-кыз йомышына йөртмәсеннәр, дим. Без, дим, менә шул нәрсәләрне требовать итәбез», – дим. Бай мәсхәрә белән көлеп җибәрде: «Нәрсә? Нәрсә? Җә әйт әле: тагы ишетим», – ди. Мин әйтәм: «Требовать итәбез!» – дим... Кадыйр тагы яман мәсхәрә белән миңа карый да кычкырып көлә: «Беләсеңме, ди, син бичараны кем адәм итте? Маңка малай идең бит, анаң килеп, аягыма ятып җылагач, кызганып алдым... Минем кулымда адәм булдың, инде, урыс-улакка ияреп, минем алдымда «требовать итәм» дип кычкырырга оялмыйсың. Бар, китегез, кәефем юк, ахмакланып йөрмәгез, баставайт итәргә[1] сез урыс түгел», – ди. Иң артта байның яратканнарыннан карт приказчик Тимербай тора иде. Бай кыза башлагач, ул да түзмәде: «Сезгә, ди, кәефем юк, ахмак булмагыз, сез урыс түгел дияргә җиңел... Әмма безнең көнкүреш бер дә җиңел түгел шул. Менә мин унсигез ел хезмәт итәм. Сез калыная барасыз, сезнең йортларыгыз, магазиннарыгыз елдан-ел арта. Әмма без көннән-көн кибә барабыз, ди. Менә мин, ди, җиде тәңкәлек квартирдан чыга алмыйм, бердәнбер кызым бар. Хәл юк, хәзерләп, гимназиягә бирергә акча юк. Кызым, мәхрүм калгач, күз яше белән җылый. Ә син көненә меңнәрне түгәсең», – ди... Шулай талашып таралдык. Икенче көнне яңадан киңәш булды. Бүтәннәр күп җәмәгать, бала-чагалы иде. Үзем генә булсам, берни түгел, балалар бар бит, ачмы-тукмы без шуннан китә алмыйбыз, туганнар, диделәр. Без уникe кеше: «Безнең сораганнарны бирмәсәң, эшкә килмибез», – дидек. Ул яман сүгенде, без ташлап чыгып киттек. Безне профсоюзда кочаклап каршы алдылар, хәзер инде бойкот турында хәрәкәт бара...

Фәхринең сүзе кухня ягыннан гөжләп өстәлгә килеп самоварның утыруы белән киселде. Нәфисә шунда, таба янында кызарынып, әллә ничаклы тәмле әйберләр пешереп өлгергән иде.

Майлап, каймаклап, коймаклап, пәрәмәчләп озак чәй эчтеләр. Чәйдән

---

[1] *Баставайт итәргә* – бастовать – эш ташларга.

соң Фәхри, исәнләшеп, рәхмәт укып, өенә китте. Ул шунда янәшәдә генә тора икән. Ул арада Нәфисә теге яктан ширма чыгарып, Давытка кәнәфидә, мендәрләр, йомшак юрганнар эчендә югалырлык итеп, ятарга урын әзерләде. Сөю яктысы белән янган күзләрен ала алмыйча, бераз каушап, бераз калтырап Урмановтан сорады:

– Давыт абый, сез ничәгә чаклы йокларсыз? Иртән ашыгыч эшегез юктыр бит?

Габдрахман аны кисте:

– Ни юк-барны сорап йөрисең! Туйганчы йоклар. Бар, ят! – диде.

Нәфисәнең бирешәсе килмәде:

– Ходаем, җүнләп әйтсәң ни була? Сәгатьле хезмәте булып, безгә шелтәсе төшмәсен дип сорыйм! – дип, ире белән карулашты.

Кунак рәхмәт укыды:

– Уннарда торсак ярар, хәзер вакыт соң бит инде, сәгать ике була торгандыр, – диебрәк иркен йокларга чамалады.

Ир, тагы бер тапкыр калкынып, хатынын теге бүлмәгә чыгып ятарга кушса да, Нәфисә буйсынмады:

– Бәйләнмә юк белән: минем йокым килми, сез сөйләшкәнне тыңлап утырасым килә минем! – дип киреләнде...

Урманов Габдрахманны яратмый иде. Аның өчен аңарда сүз юк иде. Әгәр ул ялгызы гына булса, бер-ике минуттан исни башлап, йокыга яткан булыр иде. Нәфисәнең, җилкәсенә соры мамык шәл салып, озак тыңларга әзерләнгән сыман, тирән креслога чумганын күргәч, егетнең сүз төеннәре үзеннән-үзе чишелде. Ул гади вакытта матур сөйли белми, тасвир буяулары сыек чыга. Ләкин бүген аның йөрәген кызгану катнаш иске истәлек каплады. Ул, берничә тапкыр бу квартирга, бу граммофон белән сандугачка карап, үзенең Нәфисә белән соңгы очрашуын хәтерләде.

Караңгы төн иде бит. Зөһрә апа биек баскыч төбендә каршы алды. Егет аяк очы белән басып Нәфисә янына керде. Их, ни булачак, ни булачак иде?! Әгәр егет шул төндә үзенә-үзе хуҗалыгын югалткан булса, ни булачак иде?! Кызны кызганыр, намусын алдым, мин өйләнергә тиешлемен, дияр дә өйләнгән булыр иде. Өйләнеп, бер чәүкә оясы корган булыр, менә шундыйрак бер квартир, шундыйрак бер граммофон белән сандугачлы читлек бүләк итәрләр – шулай мещанлык сазы акрынлап суырган булыр иде... Йөрәктә революция өчен янган ялкыннар сүнәр, якты киләчәк өчен, азат тормыш өчен көрәш юлында корбан ителергә тиешле булган утлы ялкын шул мещанлык богауларында үзен харап иткән булыр иде!.. Урманов шулай уйланды, йөрәгенә чәнчелгән кебек, ни булачак, ни булачак иде бит, дип кычкырып җибәрә язды. Шул истәлекләр белән бергә ул Нәфисәне сөеп,

кызганып карады, бүген аның күңелен табарга теләде, бәлки актык очрашу булыр, бәлки мине бүген-иртәгә тагын кулга алырлар, бәлки мин зинданнарда, сөргеннәрдә черермен дип, хатынның күңелен табарга теләде. Сүзләр ничектер үзеннән-үзе актылар. Беренче тапкыр сәяси түгәрәккә барган, беренче тапкыр жандарларга эләккән, беренче тапкыр зинданга ябылган көннәрне ярым көлке ясап, ярым сагынып, озак хикәя кылды.

Нәфисә, аның сүзләре эченә кереп, дөньясын югалтамы – ул үзе дә аера алмады. Урманов сүзләре аны шулай каядыр алып киттеләр. Шул үзен югалтулар эчендә' хатынның күңелендә кискен бер карар туды:

«Иртәме, соңмы, теләпме, куылыпмы, – һәрхәлдә ул моннан китәчәк. Давытның сөяркәсеме, асравымы, хатынымы, иптәше яки этеме булыр, – һәрхәлдә ул аның янында булыр, аның белән бергә яшәр, дөньяның кайгысын, шатлыгын аның белән уртаклашыр, аның авыр, ялгыз, газаплы көннәрендә җиңеллек бирер өчен көрәшер!» Күңелендә кинәт туган бу карарның ничек барып чыгуы турында Нәфисә хәзер план төзи алмады. Ничек булырын да уйлап очына чыга белмәде, ләкин бу ачык, кискен ышаныч аның йөрәгенә корычланып кереп утырды.

Давытның жандарм, зиндан, полиция турындагы сүзләренең арасында Габдрахман чәнечкеле кебек сикереп торды да, кунакның күзенә карап, көлеп җибәрде:

– Ну, малай, бу дөнья дигәнең бер җимерелсә җимерелә бит: теге Кадыйр байга Баязидның атасы Җиһан ишаннан, карагруһ мулла Вафа хәзрәт аркылы, бер кыска гына хат килгән, ди. Ишан Кадыйр байга ләгънәт укый, ди, болай язган ди: «Сиңа хәзер Алланың каһәре төште. Мин ул чакта синең үзеңә әйттем: җәдит булма, җәдитләр юлына ярдәм итмә, җәдитләргә акча бирмә, дидем. Әгәр җәдитләргә ярдәм итсәң, үзең кяфер, малың хәрам, хатының талак булыр, дидем. Минем сүземне тотмадың. Шул динсез дәһри Гали хәзрәткә ярдәм иттең. Аның мәдрәсәсенә мал түктең... Инде син чәчкәнеңне урасың, бары да сиңа каршы баш күтәрде, синең үз балаң үзеңнең битеңә төкереп качты. Бу сиңа Алланың дөньяда биргән җәзасы. Әмма кыяміттә синең ул җәдитләр файдасына түккән алтыннарың утлы күмер булып йөзеңә басылырлар... Минем сүзем шул: җәдитлектән тәүбә ит, яңадан борынгы, кадим сәләфләр[1] – остазлар юлына кайт. Әгәр шулай итсәң, Аллаһы Тәгалә гафурерраәхим[2] бәлки синең гөнаһларыңны кичерер! Юкса, син үзең мәңге тәмугда!» – дип әйткән, ди. Харап бит, бер җимерелсә җимерелә бит... Монда хатыны турында бәет чыга. Сукыр хәерче аны өйдән-

[1] *Сәләфләр* – борынгы (үткән замандагы) кешеләр.
[2] *Гафурерраәхим* – гафу итүче.

өйгә кереп җырлап йөри. Тегендә улы кача. Җитмәсә, шәкертләр, приказчиклар котыра... Инде бу ишан тәмугда урын хәзерләп куя. Харап бит эш! Ә?! Давыт, син ничек карыйсың?

Давыт моңа җавап биреп өлгермәде. Нәфисә, үзенең күңелендә туган яңа карарыннан кискенләнеп, куәтләнеп, урыныннан торды. Аз гына да иреннән тартынмыйча Урмановка килде. Озак, каты аның кулын кысты да аңа хәерле йокы теләде:

– Җә, җитәр, Габдрахман! Давыт абыйның алдында әллә ничаклы эшләр бар. Аңа йокларга кирәк! – диде.

Ир моңарчы юаш, йомшак, буйсынучан күренгән Нәфисәнең характерындагы бу яңаруга гаҗәпсенеп карады, тагын ишан дип, патшага дога дип сүз куертырга, хатынының кискенлеген җиңәргә теләде, иң зур сораулар күтәрде.

– Ну, нихәл, Давыт иптәш, революция ни эшли? Җиңәме, җиңелдеме? Без патшаны асабызмы, әллә патша безнең барыбызны да фонарь баганаларына тезеп асамы? Синеңчә ничек? Бу арада карагруһлар бик көчәяләр бит. Контрреволюция җиңә кебек. Думаны да куалар, эш ташлауларны да басалар, социал-демократия фракциясен кулга алып, хөкемгә бирәләр[98*]... Без кая барабыз: үлемме, җиңүме?

Ләкин бер-берсе өстенә өелгән бу күп сораулар хатынның йөрәген җиңә алмады, ул үзенең күңелендә туган яңа ышанычы тагы ныграк тамырлана барган кебек сизенде. Шулай: «Мин аның белән бергә булырмын, мин яңадан аңа кавышырмын, гомерлеккә кавышырмын!» – дип утыртып куйды. Шул тирән ышаныч белән канатланып, тагы бер тапкыр егетнең кулын кысты, тагын чибәррәк елмаеп, аңа хәерле йокы теләде. Шул ышану белән үзе дә тирән тыныч йокыга китте. Иртә уянып, чәй әзерләгәндә, майлар, коймаклар, пәрәмәчләр белән сыйлап Урмановны озатканда да шул ышану аңа бәхетле тынычлык бирде.

## LXX
## ӨЧЕНЧЕ ТАПКЫР

Кич Разиянең мәҗлесен ташлап чыгып киткәч, Булат чиркәү бакчасында Разин белән очрашырга тиеш иде. Шунда җитмәстән, почмакта ике жандар тотып алды. Жандармериядән туры зинданга китерделәр. Моңарчы Булат өч эләкте. Өчесендә дә жандарм полковник Герасимов үзе аңардан җавап алды. Ләкин өчесендә өч төрле йөз күрсәтте. Беренче эләгүе чагында әле ул партиягә әгъза булып кабул ителмәгән, ләкин оештырган сәяси түгәрәкләрдә, маевка, массовкаларда катнаша башлаган ялкынлы, беркатлы яшь егет булып, ныгып барган вакыты иде. Зубатовның

методларын кайбер урында файдалы тапкан карт полковник бу яшь, ялкынлы татар егетен «үз баласы» кебек каршы алды. Үзен «ата» кебек – йомшак күңелле, гафучан «ата» кебек тотты:

– Сезнең, – диде, – эшегез бик кечкенә дә, ләкин бик зур да. Кай якка борсаң, шунда барачак. Әмма мин сезне кызганам. Сез яшь, зирәк егетсез. Мин сезне каторгага яисә салкын сөргенгә, җибәреп әрәм итәсем килми. Мин утыз ел татар халкы арасында эшлим, әмма Русиядә татарлар кебек ак патшага хөрмәт иткән башка бер халык бардыр дип белмим... Татар халкының бер генә бәласе бар: ул надан, караңгы. Сез бу юк-бар эштән кайтып, үз халкыгызны агарту юлында хезмәт итсәгез, үзегез өчен дә, безнең өчен дә, мөселман халкыгыз өчен дә бик күп файда итә алырсыз... – диде.

Карт полковникның бу сүзләренә Зариф эченнән көлеп карады. Көлүен яшерергә тырышты, ләкин булдыра алмый, иреннәренә елмаю чыкты. Герасимов ревматизмлы аягын иплəп куя да юри ватылган карт төсен ала. Сүзен һаман кызганучан «атаның» азгын балага яратып үгетләве төсеннән чыгармый:

– Сез әйтәсез булыр, бу хәйләкәр карт миңа йомшак сүз белән тозак кора дип, юк, алай түгел. Мин дә жандарм булып тумадым. Гимназиянең актык сыйныфында мин дә, директордан яшереп, Марксны, Энгельсне укыдым... Мин дә социализм белән янып йөрдем... Шул мине Зубатовның юлына төшерде... Әле бу көндә дә мин Август Бебель[99*] кебек, Каутский[100*] кебек чит мәмләкәт социалистларына, үземчә, хөрмәт белән карыйм. Дөрес, алар ялгышалар, ләкин алар ихлас идеалистлар. Алар чын күңелдән яналар. Әмма безнекеләр нәрсә? Безнең социалист башлыклар кемнәр? Алар бит азган-тузган, бозык жид[1] малайлары! Менә кем! Алар үзләре анда заграницада[2] рәхәтләнеп яталар. Монда кайтсалар – алтын эчендә йөзәләр. Әмма менә сезнең кебек ышанучан ялкынлы яшьләрне матур сүз белән алдап, ут эченә җибәрәләр... Менә бит без шуңа әрнибез... Шуңа күрә сезнең кебек яшьләрнең күзен ачарга телибез... Хөкем белән, зиндан белән, сөрген белән генә түгел, дөрес сүз белән аңлатырга телибез... Әгәр сез миңа сүз бирсәгез, берничә соравыбызга дөрес җавап кайтарсагыз, мин сезне бүген үк азат итәчәкмен... Сез университетка керергә дип аттестатка хәзерләнәсез бугай? Бик яхшы эш. Татарлардан укыган кешеләр аз... Сез зирәк егет, сездән зур кеше чыга... Халкыгызга зур хезмәт күрсәтә алырсыз... – дип, картларча озак изеп килә дә Булатка берничә рәсем күрсәтә: – Болар кемнәр, кайдалар хәзер? – дип сорый. Аңарда табылган яшерен китаплар ничек, кайдан, кем

---

[1] *Жид* – яһүд.
[2] *Заграницада* – чит илдә.

аркылы алынганын әйтергә куша...

Алай да барып чыкмагач, ата-анасына барып төшә:

– Мин материал җыйдым. Сезнең атагыз фәкыйрь эшче булса да, сезне башкалар кебек сигез яшьтән фабрикага бирмәгән. Укыткан. Атагыз үлгәч, анагыз сезне укытыр өчен көннәр буе күз нуры түгеп, бай хатыннарына күлмәк теккән... Шулай бит? – дип, күзенә карый.

Булат түзмәде, сүзен кисте:

– Мин ундүрт яшьтән үк үзем дә эшләп, әнкәйгә ярдәм итә башладым...

– Анысы алайдыр. Әмма сезнең атагыз да, ул үлгәч – анагыз да, сезне рус мәктәбенә кертеп, уку ягына салганнар... Әгәр бу юлдан кайтмасагыз, ата-анагызның түккән көчләре бары да әрәм була, сез кайдадыр каторгада, сөргендә черисез...

Ләкин егет карт жандарның үгетләренә, аның артыннан китергән сорауларына:

– Белмим, берни дә белмим, – дип кырт кисеп җавап бирә.

Шуна карамастан, ике ай утыргач, Булатны чыгаралар.

Икенче тапкыр эләгүе – Октябрь манифестыннан соң булды. Ул вакыт жандарларның үз гади юлларын югалткан чаклары иде. Бер яктан азатлык бирәләр. Теләгәнчә яз, теләгәнчә җыелыш яса, теләгән динеңне тот, теләгән китабыңны чыгар, теләгән партияңне төзе, диләр. Икенче яктан зинданнар, сөргеннәр үзләренең сәяси тоткыннарын күбәйтәләр. Менә бу арада жандарм полковник та, яңа режимга күчеп җитә алмыйча, икеләнү, нидер көтү хәлен кичерде. Зарифны үзенә чакырып җавап алганда да берничә тапкыр яман акырып кычкырып җибәрде. Бөтен йөзенә, тавышына, хәзер палачны чакырып астырырга әзерләнгән кебек, усал, ерткыч төс чыкты. Шунда ук тагын тугарылып, йомшарып та китте. Ул вакыт полковник берничә көнгә койрыксыз көймәне хәтерләтеп торды. Ләкин бу тиз үтте.

Менә бу өченче тапкыр эләгүендә Булат үз алдындагы иске таныш, карт Герасимовны чак таныды. Ул яшәргән. Аның аягындагы ревматизмнан зарлануы да юк. Аның йөзендә гаҗәп бер зур җиңү бәйрәменә ошаган шатлык көче ялтырый.

Жандармерия йортына таң алдында ук китергәннәр иде. Кечкенә бер бүлмәгә бикләп, алты сәгать интектерделәр. Сәгать уннар җиткәндә генә аны кылычлы, мылтыклы ике жандарм, зур зал аша үтеп, полковникның кабинетына керттеләр. Карт жандарм Герасимов, күн креслога утырган килеш, күзе белән ялтырап, бераз елмайды, кулын биреп исәнләште, аның өчен бер стакан чәй китертте, алдына көмеш портсигарын ачып, тартырга да тәкъдим итте. Бик дусча сүз ачты:

– Безгә, – диде, – һәммә нәрсә мәгълүм. Сез иске таныш булганга,

кайбер нәрсә турында сөйләшеп үтәсем килде. Дөрестен әйткәндә, сәясәт өчен түгел, тик күңел рәхәте өчен чакырттым. Мин сезне бик яратам! – диде дә, хихылдап, җиңеп чыккан генерал елмаюы белән көлде.

Булат бераз сискәнеп уйланды: «Бу ни хәл бу? Бу этләр чыннан да үзләренең җиңү бәйрәмнәрен итәләрме? Әллә кулларына эләккән тоткынның психологиясен җимерү өчен, тыштан гына шулай бәйрәм шатлыгы чыгарып азапланалармы?»

Жандарм белән тоткын арасында бер-берссн алдау, бер-берсен эләктерү исәбе белән ачык, яшерен көрәш башлана. Ләкин полковник кулындагы материалның гадәттән тыш күплеге Зарифны уйга калдырды, тирән борчуга салды: «Бу ни эш? Үткән төндәге ябулар, тентүләр аркасында шул чаклы документлар кулга төшерелгәннәрме? Эләккән иптәшләрнең берсен җәзалап-газаплап, бар нәрсәне әйттергәннәрме? Әллә партия оешмасының эчендә, комитетның үзәгендә провокатор утырамы?»

Жандарм полковник сүзне: «Безгә һәммә нәрсә мәгълүм!» – дип башлады да, мактанган түгел, шаярган тавыш белән әйтте:

– Без сезнең дүшәмбе көн кич Идел аркылы боз өстеннән ничек куркыныч хәлдә чыкканыгызны да шул сәгатьтә белдек. Шакир солдатның кемнәрне ярдәмгә чакыруы да безгә мәгълүм. Монда сез, сакал-мыек җиткереп, авылның мәдәни кулагы булып кайткач, Госман квартирына, әдәби кичә җыелышына килеп кергән чагыгызда ук сезне тотып алырга мөмкин иде. Мин үзем әйттем, хәзергә тимәгез, дидем... Сездән унсигез сәгать соң Кавказлы Гәрәй Солтан Уралдан кайтып төште. Мин аны да ике тәүлек буенча шәһәрдә теләгәнчә йөрергә ирекле куйдым... Күрәсез, без керү белән кешенең бугазына ябышмыйбыз, – дип, туры күзләренә йотылды.

Булат полковникның бу дәрәҗәдә югары тавыш белән шаяртуына эченнән хурланды, сүзен бүлми чыдамады, тыштан һич тә исе китмәгән төс белән көчләнеп иснәде:

– Алайса, нигә мине монда алты сәгать көттереп азапладыгыз? Бар нәрсә мәгълүм булса, миннән сорап торуның кирәге нигә? Мин ике тәүлек йоклаганым юк. Мине зинданга кайтарыгыз, йокым килә минем! – диде.

Ләкин Герасимов алай тиз генә зинданга кайтарырга уйламый иде. Тыштан ашыкты, гафу үтенде:

– Озак тотмам. Сездән миңа бернәрсә дә кирәкми. Мин тик сәясәтнең берничә югары моменты турында сөйләшеп кенә үтәсем килә. Белегез, сездән җавап алу түгел, аның кирәге юк, революция сәясәтенең кайбер югары нокталары турында сезнең белән әңгәмә ясыйсым гына килә... Менә бу Гәрәйне әйтәм: сүзе аз, укымышы аз. Үзе нәрсә дип инде юк хыял артыннан чаба? Каян тапкан бер сүз: коралллы күтәрелеш ди дә үлә бит. Сез моңа ничек

карыйсыз?

Булат үз алдында пәрдәнең бер чите ачыла башлаган кебек сизенде. Юри яман иснәп җавап бирде:

– Мин солдат түгел. Мылтык ата белмим, гомеремдә револьвер да тотканым юк. Ул турыда нәрсә әйтим? – диде.

Полковник чал сакалын селкеп, ясамадан хахылдап көлде:

– Ай, Зариф Гирфанович! Ярамады, бер дә ярамады, сез инде мин белгәнне яшереп маташмагыз, алай килешми. Партиянең өченче съезды булдымы? Анда кораллы күтәрелеш турында нинди карар бар? Бу турыда Ленин нәрсә язды? [101*]

Булат тагын иснәде:

– Ул съездда булмадым. Лениннең язган бер әйберен туктата торалар... Кыен бит мондый кечкенә җирләрдә... Кирәк әйберләреңне дә укый алмыйсың! – диде.

Тоткынның һаман иснәп, бер тиенлек тә әһәмият бирмәгән кебек күренүе полковникның ачуын китерде. Ул шунда ук портфелен ачты да кораллы күтәрелеш турындагы татарча прокламациянең берьюлы дүрт экземплярен чыгарды. Аның өстенә Булат кулы белән язылган оригиналны күрсәтте:

– Сез бала түгел! Менә моны үз кулыгыз икәнен яшереп маташмассыз! – диде.

Булатның үз кулы, үз язуы иде. Баягы шөбһәләре тагы артты. Кем булыр? Әлбәттә, үз эчебездән барлык серне охранкага ташучы провокатор бар. Ләкин бу борчылуны йөзенә чыгармаска тырышты.

– Минеке түгел. Татар язулары чит күзгә бары да бертөсле күренәләр! – диде.

Герасимов сүзне икенчегә күчерде:

– Ярый. Бәлки, шулайдыр. Ул кечкенә эш. Мин аны суз уңаенда гына әйтәм. Сезнең йокы да килә. Тагы бер генә сорау: Разин нинди эшкә дип сезгә алты йөз сум акча бирде? – диде дә күзенә текәлде.

Булат кулы дерелдәүне яшерер өчен алдындагы портсигардан тәмәке алды да, яндырып, тарта башлады. Полковникның күзенә карап ялганлады:

– Нинди Разин? Нинди алты йөз сум ул? Ишеткән-белгән нәрсәм түгел, – дип чатнатып әйтте.

Полковникның йөзенә, күзенә карт төлке төсе чыкты. Тоткынга йотылды, шелтә белән башлады:

– Ничек белмисез? Үзәк Комитет әгъзасы Разинны белмисезме? Коля квартирында аның белән бергә кунган кеше кем иде? Сезгә меңне вәгъдә итеп, хәзергә алты йөзне бирделәр түгелме? Их, Зариф Гирфанович! Юкка

ватыласыз: Разин да, Коля да минем кулдалар. Ягъни бүген төнлә зинданга алындылар. Шулар белән бергә батыр егет Гәрәй дә эләкте... Сез әйтерсез, Гәрәйне дә белмим диярсез, шулаймы? Бәлки, сез сөргеннән качып кайткач, Гәрәйне күрә алмагансыздыр? Ул да миндә. Мин аны кызганам: ул батыр егет. Ул арыслан йөрәк. Әмма алдана. Җид малайларына алдана! Беләсезме, нәрсә булды? Без отряд белән бомба-динамит мастерскоен барып бастык. Аягымда ревматизм булуга карамадым. Утыз кеше белән үзем бардым. Әйләндереп алгач, кычкырдык: чыгыгыз, булмаса, ут ачабыз, дидем. Әрәм егетләр, тәрәзәдән, ишек ярыгыннан безгә каршы ата башладылар: ике сәгать азаплангач, бирелделәр. Карасам: сигез эшче егет. Җидесе рус, берсе татар. Татары – шул синең шәкертең Гәрәй. Җиде русның берсе шул җирдә үзен атып үтерде. Һәммәсен богаулап алгач, мастерскойны үзем актардым – бу зур бер фабрика. Җитмеш данә бомба кабыгы чыкты. Пироксилин, нитроглицерин, динамит – һәммәсе шул чаклы күп, әгәр ялгыш ут төшә калса, бөтен кварталны күккә күтәрәчәк. Иң гаҗәбе – егерме маузер, ундүрт солдат мылтыгы. Кыскасы, фабрика да шунда, склад та шунда... Менә болар бит сезнең җимешләр! Сез ничек бу турыда белмисез? Басып кергәч, башкалары бирелде; Гәрәй маузеры белән миңа төзәп ике тапкыр атты, тимәде... Менә бит, без беләдер идек аның ике экспроприациягә катнашканын... Бүген менә үзе килеп эләкте... Бары да сезнең җимешләр, – дип, Герасимов үзенең ачулы, сынаучан күзләрен тоткынга кадады.

Булатның йөрәге ут булды. Чөнки аңа складны күчерү эше барганлыгы мәгълүм иде. Жандармның бер сүзенә дә ышанмады; бәлкем әле эләгүләре дә ялгандыр. Ләкин нидер бар, нидер җимерелә... Ул зинданга кайтырга ашыкты, инде элемтәләр бар, анда мәгълүм булыр дип янды. Ләкин полковник аны тиз ычкындырасы килмәде:

– Мин, – диде, – сезгә шул чаклы яңа хәбәрләр сөйләдем, бер генә нәрсә турында сез дә миңа туры сөйләгез!..

Ләкин кинәт соравын туктатып, өстәлендәге кечкенә төймәне басты: тегеннән таза ике жандарм керде. Герасимов кушуы буенча, алар шундагы зур шкафны ачтылар. Полковник сикереп торды:

– Менә, – диде, – минем ганимәтләрем[1] болар... Бары да түгел. Менә динамит, менә пироксилин, менә бомба кабы, менә бикфорд җебе. Гаҗәбе шунда: миңа Петербургтан департамент аркылы мәгълүм иде: ике ай элек большевиклар Париждан Русиягә бик күп менә шул бикфорд шнурын чыгарганнар, дип. Мин аны табудан өмит өзгән идем. Менә маузер – егермедән моны алдым: Гәрәй шуның белән ике тапкыр атты. Миңа алтмыш

---

[1] *Ганимәт* – сугышта җиңеп алынган әйберләр, трофей.

яшемә бәйрәм ясамакчылар; ярдәмчем Иванов әйтте: бәйрәменңдә без бу маузерны сиңа бүләк итәрбез, дип шаяртты... Тукта, бер сорау дигән идем – сез Енисейдән Чиләбе аркылымы, әллә Екатеринбург аркылымы Русиягә үттегез? – диде.

Егет Чиләбе аркылы димәкче иде, исенә төшеп, телен тешләде: чөнки анда яшерен типографияне урынлаштыру турында ике көн эшләшеп үткән иде...

Шул арада телефон шалтырады. Ахрысы, берәр заводта эш ташлаумы, казармада дулкынмы-ниме булса кирәк, Герасимов кинәт агарынды:

– Хәзер, хәзер! – диде дә бөтен сорауларын онытты, элекке әтәчләнгән батыр йөзендәге җиңү, бәйрәм төсләре дә югалды. Тиз-тиз шкафны яптырды, шул минутта Булатны зинданга озатты.

Карт төлкенең сүзләрендә ялган белән дөрес бергә буталган икән. Разин эләкмәгән. Аның кунган бүлмәсендә тентү ясаганнар. Үзен тота алмаганнар. Коля шәһәрдән качкан. Әмма Гәрәйләр турындагы зур вакыйга дөрес булып чыкты. Жандар карт: «Берсе үзен-үзе үтерде», – дигән иде. Ялган сөйләгән. Үзен үтермәгән, аны, тәрәзәдән атып, жандарлар үтергәннәр.

Гәрәй шул сигезнең берсе булып зинданга алынды. Аның Уралда ике экспроприациягә катнашкан Әхмәт Хәйруллин исемендә йөргән кеше икәнен монда ачтылар. Ул кулга алынган көндә үк богауланды, гадәттә иң каты җәзаларга эләккән тоткыннар гына ябыла торган яшерен камерага бикләнде.

## LXXI
## КУНАККА КАЙТТЫЛАР

Җырчы Сәхип белән Нигъмәт казый кунакка кайттылар.

Сафа карт капканы үзе ачты.

Йорт уртасында арба майлап торган зур ялчы эшен ташлады да, кунакларга каршы йөгереп килеп, атларны җитәкләп кертте. Кыңгырау тавышына өйдән бер кыз бала атылып чыкты да яңгыр белән юешләнеп беткән атларга, баштанаяк пычранган тарантаска, өсләре, йөзләре балчык белән чобарланып беткән кунакларга карап аптырап калды, таныгач, иң элек:

– Мулла абзыкай, мулла абзыкай! – дип, аларга каршы очты, абзыкасы янында ниндидер ят кеше утырганын күргәч: – Җиңги, сөенче, җиңги, сөенче, мулла абзыкай кайтты! Мулла абзыкай кайтты! – дип, кире өйгә йөгерде.

Нигъмәт казый белән җырчы Сәхип арбадан төшәргә дә өлгерә алмадылар, аларның тирәсен күршедән, урамнан җыелган әллә ничаклы бала-чагалар, яшүсмер егетләр чолгап алды.

Сафа карт, аягында читек-кәвеш, чалбарсыз, тезенә төшеп торган аксыл

күлмәктән, өстендә буйлы бикасап камзул, башында Бохара кәләпүше, кулында комган булган хәлдә, балаларны:

– Бер читкәрәк китегез, аттан тапталырсыз, – дип куа, ләкин ачуланмый, аның йөзе, күзләре бертуктаусыз көлә, зур, таза гәүдәсе мондый шатлык сәбәбеннән яшьләрчә җиңел кузгала иде.

Нигъмәт хатыннар ягына, Сәхип кунаклык ягына кереп, исәнләшеп, сәлам биреп чыктылар да юынырга тотындылар. Аларга җиз комганнарга салып җылы су хәзерләгәннәр, ялчы биш көре белән эшләнгән өр-яңа сөлге тотып тора, кайдандыр исле сабын да тапканнар иде...

Карт үзе икендегә тәһарәт ала, кычкырып догаларын укый, шулар арасында ук:

– Рәхмәт, бик рәхмәт инде, улым, вакытында кайтуыңа... Без генә түгел, сине бөтен ил көтә иде!.. – дип, Нигъмәткә рәхмәт әйтә.

Нигъмәт, юынып, сөртенеп беткәч, үзенең кунак иптәшенә карап:

– Менә шул инде безнең атайның дөньясы, – диде. Йортка күз йөртеп, гүя беренче күргәндәй: – Аба, әткәй, син бик баегансың икән ләбаса!.. Капканы тимер белән ябып, яшелгә буяткан. Өйләрнең икесен дә яңадан сипләтеп, тимер белән яптырган... Җитмәсә, тагы бер келәт арттырган. Мунчаны да яңарткан. Күз тимәсен, бакчаны дә рәшәткә белән әйләндергән... Харап икән синең эш...

Карт кәефләнде:

– Тәңренең биргәненә шөкер, балам... Үткән ел Михайладан унике сажин урман алган идем. Синең бәхетеңә каршы, бик яхшы чыкты, осталар да ару кешеләр туры килгәч, бер кузгатканда барын да эшләтим, дидем. Өстәвенә мәчеткә дә, мәктәпкә дә әллә ничаклы агач ботагы бирдем... Бакчаның рәшәткәсе дисәң... рәшәткә инде ул, син аның эченә керсәң, тәүбә эстәгъфирулла, оҗмах дип уйларсың. Килен син кайта дип көн-төн бакчада эшләде, аны җимеш агачлары белән тутырды, чәчәкләр үстерде.

Картның күңеле өчен бакчаны кереп карадылар. Ул чыннан да чибәр иде. Җимешләр өлгереп утыралар, байтак ялан чәчәкләре дә бар иде. Бер башлагач, карт бакча белән генә тукталмады, бөтен йортны, яңа ясалган ныклы эш арбаларын, келәтләрне, анда ашлык белән тулы өсәкләрне күрсәтте. Ындыр ераграк иде, бармадылар; карт, анда утырган өч зур кибәнгә бармагы белән күрсәтеп:

– Әнә саклыгым да бар, өч кибән еллатам. Ходаныкын белеп булмый, кайбер елда чәчәсең, чәчәсең дә, бөтен ялан кара кала, – диде.

Нигъмәтнең яшь энисенең кызы Мәргубә килеп:

– Әткәй, чәй өлгерде, керегез инде, – диде.

Нигъмәт сеңлесен аз гына, салкын гына сөеп, кесәсеннән конфет

чыгарып бирде. Бала шатлыгыннан канатланып очты.

Нигъмәт хатын-кыз ягына китте. Сафа карт Сәхипне:

– Әйдә, шәкерт, рәхим ит, – дип, туры урам як өйгә алып керде.

Йорты, келәтләре, ындыры кебек, хуҗаның өй эче дә бик тулы иде. Ишек буенда, уңда да, сулда да, әллә ничаклы туннар, толыплар, бишмәтләр эленгән. Бик яхшы агартылган мич буена ярты баш шикәр, кадаклы чәйләр, буй-буй сабыннар тезелгән. Мич белән ишек арасында зур җиз таз, эреле-ваклы берничә җиз комган тора. Сул як почмакта һәртөрле савыт-сабалар, тәрилкәләр, чинаяклар, таш табаклар, бал, май савытлары белән тулы шкаф. Шуңа терәлеп, түргә таба кызыллы-сарылы калайлар белән чобарланган ике зур сандык. Аның аръягында үзенә күрә чибәр генә өстәл, зур ук көзге; сул якның түр почмагында киҗеле чаршау корылган киң караватт; аның өстендә матурлап өелгән түшәк, ястык, әллә ничаклы мендәрләр; өйнең бөтен диварлары диярлек авыл кызының бик мәшәкать белән чибәрләп, нык итеп эшләгән киҗеле сөлгеләр белән асулы... Идәнгә киез, аның өстенә авыл эше келәмнәр җәелгән; аның өстенә кара юрганнар түшәп, кечкенә табынлык ясаганнар.

Болар кергәндә шул идәндәге табынлыкка чәй, ашамлыклар куелган, зур ак самовар гөжләп кайнап тора иде

Сәхип, гадәт буенча, сәлам бирде дә өстендәге иске юка пальтосын салды, карт аны: «Түргә уз, шәкерт, түргә!» – дип, өстәлгә китереп утыртты.

Ул арада Нигъмәт казый килеп керде дә кунакны чәйгә утырырга чакырды:

– Әткәй, мин сиңа үземнең якын иптәшем Сәхипне алып килдем. Бу – ятимлек, фәкыйрьлек белән тырышып укып, кеше булган бер егет; миңа ни булса ул, сез аны кунак итегез! – дип, кунак турында сүз башлады.

Карт рәхмәт укыды:

– Рәхим итсен, рәхим итсен, без талибелгыйлемнәр[1] фатихасы белән торабыз, – диде.

Болар чәйгә утыргач, манарада мөәзин күренде, ахшамга азан әйткәне ишетелде. Карт эчке акрын тавыш белән:

– Алла гафу итсен, ахшамга азан әйтә, шулай да сезне ташлап китәсем килми инде! – дип, майлы коймакны зур авызына тыгып җибәрде.

Ул арада ишектән бер бала кереп:

– Сафа бабай, әткәй сезне ашка чакырды, кунагын да, Нигъмәт абзыйны да калдырмасын дип әйтте, – диде.

Сәхип карышса да, ихтыярына куймадылар. Мәҗлестә кеше күп, урын

---

[1] *Талибелгыйлем* – укучы, шәкерт.

тыгыз, ит бик артык симез, бәлеш май эчендә йөзә иде.

Сәхип сөйләргә сүз тапмады, ләкин Нигъмәт казый йөзде. Икенче думаның куылуыннан, социалистларның ябылуыннан, Столыпинның диктатор булуыннан, хәзер эшләр кире китүеннән башлап, Садыйкның атына, Вәлинең җиренә, Шәймәрдәннең бозавына чаклы барып җитте. Мужиклары да, мулласы да авыз ачып тыңлыйлар иде. Сәхип Нигъмәт казыйның сәяси мәсьәләләрдәге сүзләренә гаҗәпсенеп карады: ул монда ничектер сулрак күренә, социалистларны яхшы яктан күрсәтә, Столыпинны рус бояры дип атый, өмитнең зуры эшчеләрдә икәнен аңлата иде.

Моннан чыккач, тагы ике җирдә аш бар икән. Сәхип иптәшенең колагына: «Бара алмыйм, карыным шартлый бу сыйлардан», – дип караса да, Нигъмәт:

– Юк, юк, ярамый, түз, әйдә барабыз, – диде, иркенә куймыйча, алып китте.

Боларда да кеше күп, урын тыгыз, ит симез, бәлеш майлы иде. Монда да Нигъмәт казый сәясәттән башлап тавык-чебешләргәчә барып җитте. Мужиклар аңа бөтенләй гашыйк булып, безне искә төшереп кайтуыңа мең рәхмәт дип, кайта-кайта сөйләделәр.

Итләрдән, бәлешләрдән котылып өйгә кайтканда сәгать төнге унике иде инде.

Ни күрсеннәр: өйдә тагы, җиңел аш дип, сөтләп, дөгеләп, тавык итеннән өйрә пешергәннәр; май, бал, майлы коймак, вак бәлеш, тагы ниләр белән чәй хәзерләгәннәр.

Ни чара, тагы утырдылар.

Сәхип бик аз гына шулпа белән сөтсез куе чәйдән башка нәрсә каба алмады; Нигъмәт күп ашамады, ләкин карт, юрганга аяк бөкләп, тавыкка да, майлы коймакка да кирәген бирде, үзе, авыз тутырып чәйнәгән хәлдә:

– Мәдрәсәдә ач ятып эчегез кыркылып беткән, шуңа күрә ашый алмыйсыз. Бездә күбрәк торсагыз, өйрәнерсез әле! – дип, туктамый сөйләнә иде.

## LXXII
## КАЙСЫ БИЯНЕ СУЯРБЫЗ?

Чәйдән соң, өчесе өч якка – мендәрләр өстенә аудылар.

Карт авыр, басынкы тавыш белән сүз башлады:

– Нигъмәт, синең белән сөйләшермен дигән идем, теге карт туры бия ябыграк, җирәнен суярбызмы икән? Аның аягы да имгәнгән! – дип, сорау белән улының күзенә карады.

Нигъмәт казый аңламады:

– Җәй көне ник бия суярга? Аның ите бозыла бит. Кышка да өлгерерсең әле! – диде.

Карт җиңелчә көлде:

– Бозылу кайда ул? Бер бия җитмәс тә әле: монда бөтен тирә-як синең кайтуыңны дүрт күз белән көтте...

– Син ни сөйлисең, мин аңламыйм...

– Нәрсә аңламаска, – ди, – син бит мөфти хәзрәткә кереп, имтихан тоткансың, мөдәррислек алгансың[1]... Укуыңны бетердең, мин монда син кайтканчы тамга җыеп куйдым... Указ котлау өчен бия суеп туй ясыйбыз... Башкортлар болай да: «Сафа карт, син бу елларда бик саранландың, күптән сыйлаганың юк», – дип йөриләр.

Нигъмәт агарынды, мендәргә кырын яткан җиреннән кинәт йөрәгенә чәнчелгән кебек сикереп торып утырды.

– Чү, атай, син нәрсә сөйлисең? Нинди указ, нинди тамга да нинди туй? – дип аптыранып, атасының өстенә карады.

Карт аптырамады:

– Нинди тамга була димени? Сине югары мәчеткә мулла итеп сайладылар. Бөтен мәхәллә, берсе дә калмыйча, тамга салды, – дип, урыныннан торды да дивар буендагы сандыкларның берсен бик каты шаңгырдатып ачып, олы табаклы кәгазь китерде. Анда: «Кулым куйдым», «Тамгам салдым», дип, йөзләрчә кешенең исеме язылган, чүкеч, урак, дага, ыргак сурәтләре төшерелгән иде.

Егет тагы үзгәрә, кискенләшә төште:

– Атай, бу ни кылганың синең? Миңа хәбәр итү юк, сорау юк, буласыңмы дию юк; имеш, тот та имам яса, тамга җый! Бу ни эш бу? Теләсәң, мең тамга җыйна, мин барыбер мулла булмыйм әле! – дип, аягына басты.

Сафа, күзләрен дүрт итеп, урыныннан торды:

– Бу нинди сүз тагы?! Йөрүең аз булдымы? Минем сакалым агарды, хатының менә сигез ел инде туктаусыз җылый... Кодалар белән үпкәләшеп беттек, килгән саен: «Бер улыңа баш була алмыйсың, артыңны белмәгәч, өйләндермәскә кирәк иде», – дип әрлиләр... Син әле һаман дөнья гизмәкче буласың; һәр эшнең бер чиге була; мине кая куясың, хатыныңның күз яше кемгә төшәр дип уйлыйсың?!

– Атай, уеныңмы, чыныңмы? Ишетәмсең, мин мулла булмыйм әле!

Атаның күзе үткенләнеп улына кадалды, тавышы кискенләнде:

– Тукта, син кайчан дөнья көтә башларга әйтәсең? Яшең утыздан

---

[1] *Мөдәррислек алу* – муллалык итү һәм дәрес бирү хокукы алу.

артты. Каргалы Садыйк хәзрәт мәдрәсәсендә хәтме көтеб кыйлдың[1], остазың: «Нигъмәтнең моталәгасе чыкты[2], хәзер аның өчен һичбер мөшкил мәсьәлә юк, ни алса шуны белә», – ди торган иде. Аның белән канәгатьләнмичә, җәдиткә – Мәдрәсәи исламиягә күчтең... Моны тәмам итәм дә мулла булам, дидең. Без көттек, мин синең өчен карт башым белән дөнья кудым...

– Көттең, бик рәхмәт, ләкин мин ике генә көнгә кайттым. Иртәдән соң китәм...

Атаның күзе дүрт булды.

– Ул ни дигән сүзең тагы? Кая китәсең? Ике зур мәдрәсәдә хәтме көтеб кыйлдың, моталәгаң чыкты, мөдәррислек алдың, болар аръягында тагы гыйлем бармы?

– Бар, әткәй, бар. Тагы бар... Мин урысча укып, учительлеккә имтихан бирәм...

Карт ачу катыш мәсхәрә белән көлде:

– Менә сүз: имеш, учитель була! Нәрсәгә исе киткән; учитель булып, айга утыз сум алырсың; кирәк икән, мин сиңа бүгеннән үзем айга алтмышны бирим...

Нигъмәт тиз җавап бирмәде:

– Эш акчада түгел, гыйлемдә, әткәй... Аннан соң хәзер урысчадан башка эш чыкмый!

Карт дәшмәде, авыр сулап:

– Уфф-ф! – дип куйды.

Сәгать икене сукты. Нигъмәт, Сәхипкә хәзерләнгән урынны күрсәтеп, хатыны янына йокларга чыкты.

Улы чыгып китүгә карт, әрнеп, рәнжеп, аптырап, тагы сүзгә кереште:

– Балам Сәхип, акыллы күренәсең, җаным әрнегәнгә сөйлим, гаеп итмә: ата-анаң булмаса да, йөрәгең сизәр. Менә бердәнбер улым Нигъмәт, аны егерме биш ел укытам. Үзем көн-төн дөнья куам, мал җыям. Намазга, дога укырга вакытым да җитми... Динемә кимчелек китереп бетәм... Инде тынам дип торганда, ул тагы китмәкче! Әйтегез, сез нинди халык: сезнең каштa ата-ана хакы юкмы? Сезнең хәлфәләр, сез укыган китаплар ата-анага каршы барырга, аларның сүзенә колак салмаска кушамы? Нигъмәт акылсыз бала түгел. Гыйлеме дә зур; бетен тирә-якта аны пәйгамбәр кебек йөртәләр... Борын, шәкерт вакытта, мәҗлесләрдә муллаларны тетеп сала иде, хәзер аны куйды, инде күбрәк дөнья көтәргә өйрәтеп сөйли... Бер кайтканда, халыктан

---

[1] *Хәтме көтеб кыйлдың* – укыдың, белем алдың.

[2] *Моталәгасе чыкты* – белемле булды, кирәкле мәсьәләләрне тиешенчә аңлап житеште.

гошер җыеп, алты почмаклы зур мәктәп салдырып китте. Икенче берсендә, башкортлардан җир вакыф кыйлдырып[1], мәчет, мәдрәсәне юлга салды, мөгаллим китереп, аңа жалуния бирдерде... Халык үзен бик ярата, ул ни кушса шуны эшли... Менә күрерсең, ул кайтканын ишеткәч, иртәгә өйлә намазына килгән халык мәчеткә сыймас. Ә башка вакыт карт-корыдан башка һичкем булмый. Бары да аңардан файдалы бер сүз ишетергә, аның вәгазен тыңларга дип киләләр... Менә шул бала, иленнән бизеп, әллә кая кача... Бу ни дигән сүз? Минем башым боларны сыйдыра алмый. Хатыны сигез ел буенча җылап көтә... Ходайга шөкер, дәүләтем бар... Бу дәүләтне җыю өчен мин ниләр күрмәдем. Кеше рәнҗеткән чагым да булды... Без үзебез асылда Пенза ягыннан. Ун яшьтә чагында агам мине Себер ягына алып китте. Шунда сатуга өйрәндем. Агай үлде. Бераз мал җыйгач, менә шул Орски өязенә килеп, җир алдым, сәүдә башладым. Шунда хатын алып, йорт кордым... Дөньяда мин эшләмәгән эш калмады. Барын маңлай тирем белән таптым. Инде ул шул дәүләтне ташлап китә... Борынгылар: «Мисырда патша булганыңнан Кәнганда гидай булу артык», диләр иде. Сезнең китапларда бу сүз юкмыни?.. Ул урынлашса, мин дөньяны аңа тапшырыр идем дә үзем гыйбадәтем белән үткәрер идем... Үлем-җитем бар бит, сакал агарды, Газраил дә ерак йөрмидер... Иртә торсаң, намазга барып, ишракны[2] тутырып кайтсаң, Коръәнеңне, догаларыңны укып ятсаң, аннан йорт-җиргә азрак күз салып, өйләгә барсаң, икенде-ахшамын, ястүен, догасы, нәфелләре белән ашыкмый иркенләп үтәсәң, рамазан шәрифләрдә мәчеткә игътикафка[3] керсәң, насыйб булып, хаҗга да барып кайтсаң, миңа артык бернәрсә дә кирәкмәс иде... Ә мин хәзер намазның фарызларын чак-чак укыйм. Кайбер вакыт, ашыгыч бер эшең хәтергә килә дә, сәҗдәгә яткан җиреннән йөгереп кайтасың... Ә ул шуларны аңламый... – дип, карт озак зарланды.

Сәхип ни дияргә дә белмәде, аңа бу сүзләр бик иске, аның иптәшләре бары да мондый фаҗигаләрне үткәргәннәр, кайберләре, җиңелеп, аталар сүзенә буйсынганнар да иде. Ләкин Нигъмәтнең җиңелмәячәге аңарга мәгълүм иде. Ул картны юатырга тырышты:

– Аңламый түгел, аңлый, бик аңлый... Ул озакка китмәс... Күп булса бер ел йөрер, диде.

Карттан котылып йортка чыкса, анда Нигъмәт казыйны күреп, аптырый калды. Бу бер генә минутка һава алырга чыккан икән.

– Менә, Сәхип, күрдең инде минем тормышны, – ди, – бер яктан әти:

---

[1] *Җир вакыф кыйлдырып* – җир алып, тартып алынмый торган милек рәвешендә рәсмиләштереп.

[2] *Ишракны* – нурны, яктылыкны.

[3] *Игътикафка* – озак итеп утырып гыйбадәт кылырга.

мулла бул, дөнья көт, ди. Икенче яктан хатыным, бу бәхетсез җан, үкереп җылый: сигез ел көтәм, яшьлегем үтә, син булмагач, дөньяның ни тәме бар, китмә, китмә, дип ялвара, – дип зарлана башлады.

Ләкин егетләр тиз аерылыштылар.

Сәхип иптәшенең хатыны белән булган фаҗигасен күптән белә иде. Үзе мәдрәсәдә чакта аңа кыз ярәшеп, эшне бетереп куйганнар. Бу, яшьлек белән, каршы бара алмаган. Сигез ел элек кәләше куенына кергән. Хатын ямьсез түгел. Ләкин артык надан, артык авылча. Башка хасияте дә юк. Ике арада бөтен мөнәсәбәт – тик хайвани якынлык.

Нигъмәт аерылу фикере белән кайткан иде. Теләсәң торырсың, ләкин сине бәйләмәс өчен теләгән вакытта китәргә хаклысың дип язу калдырмакчы иде. Моны әйткәч, һушыннан язды, яшьлегемне син дип үткәрдем, инде мине куарга уйлыйсың икән дип, акырып җылый, ди.

## LXXIII
## МУЛЛА БУЛЫРСЫҢ БИТ?

Иртәнге чәйгә хәзерләнгән сыйларның исәбе-хисабы юк иде. Көн тагы ашка йөрүләр белән үтте.

Төнге уникедә өйгә кайтып, ахыргы чәйгә утыргач, кичәге мәсьәлә тагы кузгалды. Ләкин бу юлы артык кызмады, тиз киселде.

Сүзне ата башлады:

– Улым, синең чыныңмы, уеныңмы? Кичәдән бирле мин акылдан шашам инде, – дип, авыр сулады.

Нигъмәт мөмкин кадәрле тыныч, ләкин яңадан сөйләргә урын калдырмаска теләп, җавап бирде:

– Әткәй, син минем ике сөйләмәүне беләсең бит, нигә юк өчен кан бозасың... Мин иртәгә өйләдән соң китәм, – диде.

Карт улының табигатен яхшы белә иде, сүз көрәштерүнең файдасызлыгын аңлады. Шулай да тагы бер талпынды:

– Мин җибәрмәсәм?

– Ничек тотасың? Бәйләп куя алмыйсың бит! Киленегезне аталарына илтәм дә кайткан юлымнан кире китәм!

– Ә безне ни эшләтәсең?

– Хәзергечә торырсыз шулай. Җәй иген җыйган вакытта бер-ике айга кайтырмын...

Карт җиңелде.

– Ярый, улым, ярый... Тәүфигыңда бул; бала түгелсең, юкка йөрмисеңдер инде... Ахырдан кайтып, мулла булырсың бит?

– Әлбәттә, булам, мулла да, мөгаллим дә, учитель дә булам. Шулай

итмәгәндә бу халыкны җиңеп тә, агартып та булмый...

Карт, бераз җиңеләеп, тын алды:

– Ярар, балам, ярар, хәерлегә булсын! Хатының бик җылый, аны жуатырга тырыш, акчаң бармы?

– Аны сорама инде. Булса бир, булмаса – азактан берәр нәрсә сатып җибәрерсең.

– Ник сатарга? Әлхәмделилла, кул буш түгел әле. Дәүләт синең үзеңнеке инде. Яшь анаңда бераз кәгазьләр бар, шуннан кирәгеңне алырсың.

Икенче көнне өйләдән чыгуга байның яхшы тарантасына шәп пар ат җигелгән, кыңгыраулар тагылган иде.

Нигъмәтнең фән ягы учительлектән әллә никадәрле югары булса да, русча тел аны бик артык газаплый иде. Шул «явыз дошманны» җиңү, һәрвакыт русча гына сөйләшү өчен дип, татар аз, танышлар бер дә юк шәһәргә – Самарга барырга уйлады.

Нигъмәт казыйның китү хәбәре байтак кешене, кыңгырау тавышы бөтен тирә-якның бала-чагасын җыйган иде.

Кемдер азан әйтә, хатыны, кеше алдында аз гына да тартынмыйча, акырып җылый, атасы: хатыңны еш яз, укуыңны тизрәк бетереп кайт, дип вәгазьли... Кайберәүләр белән күреште, барыгыз да исән булыгыз, диде. Сәламәтлән, нык аша, хат язармын дип, Сәхип белән үбеште дә арбага утырды.

Атлар кузгалды, балалар кычкыра башлады, җылавы бик авыр рәвешкә кергән хатынны җитәкләп алып керделәр.

Сәхип башта кунакка, бер тамак туйдырырга дип кенә килсә дә, Нигъмәт аны бу авылда мөгаллим булып калырга димләде. Бу ел русчага тотынырга сәламәтлегең дә, акчаң да юк, монда торсаң, икесе дә булыр, диде. Сафа карт:

– Кал, шәкерт, кал, үз улым кебек тәрбияләрмен; син булгач, миңа да җиңелрәк булыр, – диде.

Сәхип калды.

Бу көн 1907 нче елның 10 нчы июле иде.

## LXXV
## «УРАЛ» БАРМЫ?

Сәхип бу авылда елдан артык торды.

Егерме-егерме биш ел буена сузылган ачлык, мохтаҗлык, ахрысы, аның әллә кай җирләрен өзгән, киптергәндер: карт үзе дә, ил халкы да бик кадерләсәләр дә, артык тазара алмады, шулай да адәм төсе керде, кесә ягы да начар булмады. Ул монда артык ярлы килгән иде, баштанаяк киенде, калага

баручы бер кеше табып, байтак китап та алдырды, шулар өстенә йөз егерме сумлап акчасы да җыелды. Бу аңа алты-җиде ай укырга җитәрлек иде, тик картның бер дә җибәрәсе килмәде, Нигъмәтнең дә: мин кайтканчы китмәсәң иде дип, хат саен үтенүе дә аны монда тота иде.

Көтелмәгән бер бәхет аны коткарды.

Тирә-яктагы берничә мөгаллим өстеннән ниндидер бер карт мулла: «Алар кызыллар, алар падишага каршы халыкны котырталар», – дип әләкләгән имеш, дигән хәбәрләр йөри, шуларның иң алдагысы Сәхип дип күрсәтелә иде.

Көннәрдән беркөнне Сафа байга урядник килеп төшә дә, бакчага үзен генә алып кереп, картка нидер сөйли.

Чәй эчәргә керми, пот ярым бодай оны белән биш кадак сары май, ике такта чәй, берничә баш мунчала ала да кайтып китә.

Анардан соң бай Сәхипкә серне ача.

Урядникка югарыдан әмер килгән: Сәхип өстеннән күз-колак булырга, аның үткәнен, хәзер ниләр сөйләвен тикшерергә, аз гына бернәрсәсе сизелсә, тотып Орскига озатырга. Ләкин Сафа карт күз күргән кеше булганга, урядник моны алдан хәбәр итә, Сәхипне озатырга куша...

Карт чыннан да кайгырды, ләкин мондый куркыныч булгач, китмә дияргә дә батырлык итә алмады.

Бер көн эчендә Сәхипнең керләрен юдылар, әллә ничаклы юл азыгы хәзерләделәр, тимер юлга илтергә дип, пар атны солыга куйдылар. Карт үзеннән, килене, ике хатыны исеменнән садака бирде, ике арба арыш гошере дип, алты сумга дога кылдырды.

Таң алдыннан Сәхип юлга чыкты, биш көннән Казанга барып җитте.

Көзнең яңгырлы, бик пычрак көннәреннән берсе иде. Ләкин бу Сәхипкә аз гына да әсәр итмәде. Сәламәтлек ярыйсы, өс-баш бөтен, тамак тук, кесәдә йөз сумлап акча бар – Сәхип бит мондый бәхетне гомерендә дә күргәне юк иде. Җитмәсә тагы, үзе Казанда, татар революциясенең учагында, менә бүген үк иптәшләрен дә күрер!

Шундый күтәренке рух белән урамга чыгып, гәзит сатучы малайлардан «Урал»[102*] сорады. Болар аңламады. бер-берсеннән:

– Андый гәзит бармыни? – дип сораша башладылар. Алар урынына пиво, сабын игъланнары белән тулган «Бәянел-хак»[103*], «Йолдыз»[104*], «Вакыт»[105*] тәкъдим иттеләр. Егет: «Болар ни белсен соң!» – дип, татар китап кибетенә керде. Каракүл бүрек кигән бер егет сату итә икән.

– Сездә «Урал» бармы?

Сатучы егет елмайды:

– Сез әллә теге дөньядан кайттыгызмы? Хәзер ни эшләп андый

гәзитләр булсын!

Сәхип, бераз уңайсызланып, үзенең шәһәрдән, почтадан да ерак җирдә, Урал башкортлары эчендә булганын әйтте.

– Ул гәзитләр булмаса, аларнын нәшриятыннан китаплар бардыр, шуларны бирегез. – диде.

– Ул китапларны хәзер сораучы юк. Шуңа күрә алдырмыйбыз, тентүләр була икән дигәч, үзебездә бар кадәрлесен дә яндырдык!

Сәхип, аптырап, бернәрсә аңламыйча чыгып китте дә иптәшләрен эзләргә тотынды.

Иң элек Давыт Урмановның җәһәннәм базына барды. Ни күрсен: әллә нинди бер ярлы итекче, ул да исерек, бернәрсә дә аңламый да, аңлата да алмый... Шул ук йортта Габдулла абзый бар иде бит, аның квартирына төште – бер хатын җылап утыра: кайда икәнлекләрен белмим, алар хәзер порох заводында эшлиләр бугай, квартирлары да шул тирәдә булыр, ди.

Егет тагы аптырый төште: кемгә барырга, кайдан табарга?

Йөри торгач, ак юртак белән акрын гына атлатып барган бер кешегә очрады: «Йа Ходай, бу Йосыфҗан бит! Менә бәхет!»

Сәхип, аз гына да тартынмыйча:

– Йосыфҗан, тукта! – дип кычкырды.

Теге әллә танымады, әллә танымамышка салынды; туктап сөйләшәсе урында, атын сугып чаптырды.

Йөри торгач, Җиһангиргә очрады. Әллә ничаклы рус дәреслекләре тоткан, каядыр ашыгып бара иде. Бусы качмады, бик шатланып, үбешеп күреште. Ләкин монда да элекке дәртле, канатлы Җиһангир күренми иде, – арганмы, сүнгәнме, ничектер рухсыз! Почмакта туктап, бераз сөйләштеләр. Давыт монда, ләкин адресын белмим, ди. Үзенең адресын әйтте, килеп утыр, диде, Сәхипнекен сорамады, русча укыйм, аттестатка хәзерләнәм, университетка керәм, ди. Габдулла абзыйны бу да белми, күптән күргәне дә юк икән.

Бу ни хәл?

Эзләп, арып, һичбер урын таба алмыйча, бернәрсә аңламыйча, эштән чыгып, ватылып, номерына кайтып, ач көенчә караватка ауды. Үзе сизмәстән, үлек кебек йокыга китте.

Торса, караңгылы-яктылы вакыт. Икендеме, ахшаммы? Әллә төн үтеп, иртәнге намаз чагымы?

Чыкса, ни күрсен: тоташтан унике сәгать йоклаган, төн үтеп, икенче көн туган икән.

## LXXV
## ХӘДИЧӘ ҖИҢГИНЕҢ ЗАРЫ

Өмит Габдулла абзыйга багланды: ничек кенә булса да аны табарга кирәк. Ул белер, анардан бер нәрсә алып булыр.

Шул уй белән кичә җылап утырган хатын әйткән заводка китте. Бер төркем, эшчеләргә очрады. Алар бер сүз белән Габдулла абзыйның квартирын өйрәттеләр.

Ашыгып, тыны бетеп барып керсә, ни күрсен: кечкенә генә, җыйнак кына квартир, урам як тәрәзә төбендә Хәдичә җиңги нидер тегеп утыра. Аны күрүгә егет:

– Ай, җиңгәкәем, җиңгәкәем, синме? Габдулла абзый исәнме? Иптәшләрдән һичкемне таба алмыйча газап чиктем... – дип шатланып, сикеренеп күреште, кат-кат исәнлек сорашып, бик озак кулын җибәрмичә торды.

Хәдичәнең йөзе ачылып китте, ул да бик шатланды:

– Искә төшереп килүеңә, – ди, – бик рәхмәт. Габдулла абзаң көн саен зарланып утыра: элек ду күчереп, шаулашып эшләп йөргән егетләр әллә кая югалдылар, әйтерсең, карчыгадан куркып, кошлар качып бетте, иптәшләрнең берсен дә табар хәл юк дип, аһ итә... Сине күрсә, шатлыгыннан башы күккә тияр аның... – дип, озаклап сөйләп китте.

Хәдичә җиңги Сәхипкә иренең заводта эшләгәнен, кайтыр вакыты җиткәнен әйтте дә, аны күрми китмә берүк дип, урыныннан торды. Мич алдына килеп, казан астын төзәтте, самоварын куя-куя акрын, салмак, кызганулы тавыш белән Сәхипнең сөальләре буенча, иптәшләре хакында сөйли башлады:

– Шулай, төрлесе төрле якка таралып, бер-берсен ташлап беттеләр инде... Элек шундый шәп егетләр иде, шундый эшлиләр иде. Абзаң һәр кайткан саен мактап бетерә алмый иде. Ә хәзер ул көн саен күңелсез хәбәрләр генә алып кайта: кемне тотып япканнар, кемне асканнар (хатын күз яшен сөртте). Һәр көн менә шундый авырлыклар ишетәсең дә торасың. Монда калганнарының кайсы байлар ягын каера башлаган, кайсы эчүгә сабышкан, иң күбе элекке юлны бөтенләй ташлаганнар...

Сәхип элекке иптәшләренең исемен атап сорады. Җиңгинең боларның һәммәсе хакында азмы-күпме хәбәре бар икән:

– Теге Гәрәй Солтан дигәннәре ике елдан бирле зинданда утыра. Аны асарлар, диләр... Тик әллә нәрсә өчен генә кичектерәләр имеш, ди. Булатны озаттылар. Эше бик каты түгел, кайтаралар имеш, дип сөйлиләр дә, әле һаман ни булыры билгеле түгел. Гәрәй Солтан эше белән эләккән ике мөселман эшченең берсе зинданда вафат булды, Алланың рәхмәтендә булсын, бик

әйбәт кеше иде, безгә килә иде... Тагы кем бар? Давыт Урманов монда тора, байлар акчасына чыга торган гәзиттә эшли, бик эчә, ди. Аңа да суд буласымы, булганмы дип сөйлиләр... Теге Разия дигәннәрегезне әйтәсе дә юк инде. Ул очраганда исәнләшми дә, ди... Канатлы эшләпәләр, каракүл туннар, берлиант йөзекләр киеп, әфисәрләр белән биеп йөри, диләр... Үзем күргәнем юк, гөнаһысына керер хәлем юк... Кеше сүзен генә әйтәм...

Сәхип, аптырап, сөальләрен бирүдә дәвам итте:

– Кадыйр бай, аның Йосыфҗаны, Һаҗәрләре ни хәлдә икән? Теге вакыт алар бик телдә иде бит...

Җиңги монда да гаҗәп ачык җаваплар бирде:

– Алар ни эшләсеннәр: байныкы уңга да, сулга да бара инде. Кадыйр бай терелде, хәзер сакалларын буяп, яшәреп, яшь бикә Һаҗәр белән пар атта гүләйт итәләр... Һаҗәр теге вакыт Җиһангир дип тилмерсә дә, инде оныткан, ясанып, бизәнеп, бай ире алдында куштан кәнизәк кебек кыланып тора, ди. Тиздән баласы да булачак имеш. Уллары Йосыфҗан Истанбулга киткән иде, аннан агелчангамы[1], французгамы барам дип әйтә, диләр иде. Атаң хәл эчендә дип телеграм биргәч, кайтты да яңадан китмәде... Абзаң көлдерәдер иде: безнең Йосыфҗан шәп акыл тапкан, ди: ул, ди, ник яңадан китмәдең, дигәч: укып ни чыга? Миеңне чертеп, яңадан биш-ун ел укысаң, бер доктор, бер адвокат, бер мөхәррир буласың икән, иң күбе елга өч мең алырсың, мин моны бер бармак селкетүдә табам дип әйтә икән, ди... Башка ни булсын, аслына кайткан шул... Хәзер атасының барлык эшләрен диярлек ул йөртә. Бик үткен, бик каты сәүдәгәр дип сөйлиләр... Кичә генә безнең күрше кибетче кереп, җылап утырды: карт бай, ди, ачуы килгәндә кыйнап чыгаргаласа да, ялынып барсаң, түләвеңне азрак кичектерә иде... Йосыфҗан дигәне харап икән, ди, векселем буенча алтмыш тәңкә җитмәгән өчен, кибетеңне торги белән[2] саттырам, йортыңны яздырам дип, эт кадерен калдырмыйча тиргәп чыгарды, ди...

Башкалар хакында белмәде, әнә абзаң да кайтып килә, ул сөйләр, диде.

Габдулла абзый ишектән керер-кермәс, Сәхипне таныды, үбеп күреште, элекке иптәшләрне көндез фонарь белән эзләргә җитешәм, һичберен күрер хәлем юк, ди, Сәхипкә текәлеп карады да:

– Авыл килешкән, син тазаргансың, – диде.

Ләкин Габдулла абзый үзе дә тазарган, ныкланган иде. Аның яңаклары иң башта катнашкандагы кебек кибеп эчкә кермәгәннәр, тулып торалар, буй да турайган, куллар да калтырамыйлар, өс-башы да чибәр генә: яхшы постау

---

[1] *Агелчангамы* – Англиягәме.
[2] *Торги белән* – аукционга куеп.

чалбар, ныклы пальто, башта күн фуражка.

Аш та, чәй дә хәзерләнде. Өчәүләп өстәл тирәсенә утырдылар.

Сәхип авылдагы ел ярым тормышын, урядник вакыйгасын, монда килүен, шәһәр буенда гәзитләр, китаплар, иптәшләр эзләп тә һичнәрсә тапмавын, әле җиңги сөйләгән нәрсәләрне башына сыйдыра алмавын тасвир итте.

Габдулла абзый авыр сулады:

– Шулай, туган, шулай... – дип, югарыгы вакыйгаларны тагы ачырак, карарак рәвештә хикәя итеп бирде Иң төплеләренең берсе саналган Госманның хәзер земствода хезмәт итүен, үзен аклау өчен кайбер нәрсәләрне ачкан дип сөйләүләрен аңлатты: – Дашкин дигән бернәрсә бар иде, ул элек тә җүнләп эшләми, ара-тирә митингыга килеп, бик кызылланып кычкырынгалый иде. Шул егет, сәяси иминлек алып, институтка керү өчен чукынган, хәзер охранкага хезмәт итә, жалование[1] ала имеш, диләр. Тагымы?.. Тагы Фәхри кибет ачты, өч приказчик тота. Бик каты, бик кыса дип зарланалар. Үзенең хәзер корсагы түгәрәкләнеп бара бугай. Габдрахман артист булып китте. Комедияләрдә бик яхшы уйный... Алга бара, диләр...

Сәхипнең башы шеште, һичнәрсә аңламас булды Аптырап, кайтырга җыйналды:

– Алайса, кем генә калды соң инде?

Габдулла абзый авыр җавап бирде:

– Син, мин, Әмин белән Дәмин диләр... Шуның кебек тагын Давыт бар. Көн-төн сүгенә. Аяусыз эчә... Булаттан хат килгәли. Озын яза: кайгырмагыз, бу караңгы төн мәңге булмас дип өмитләндерә... Минем берничә иптәш эшчем бар. Бу хатларны бергә укып, бөти кебек, күз агы кебек саклыйбыз... Күптән түгел ул үзе дә кайткан бугай.

Сәхип исәнләшеп чыга башлагач, җиңги аны туктатты:

– Кара әле, Сәхип, синең башкорт арасында Гөлбикә дигән берәр танышың бар идеме? Безгә яшь кенә, матур гына бер хатын килеп, сине әллә ничә сорады. Килсә, мине күрми китмәсен, минем адресым Давытта булыр, ди. Ул үзе башкортныкы, бер исерекнең хатыны икән... Иреннән аерылгач, аны шунда, якындагы бер стансада татарча театрмы, нәрсәме куйганда, тавышың яхшы дип, җырларга кушканнар. Авыл хатыны булса да, үткен нәрсә икән: шул җырлаудан исемгә чыгып, үзен шәһәргә алдырганнар. Хәзер монда, театр уйный, ди... Син аны эзләп тап, исеме Гөлбикә.

Бу хәбәр Сәхипнең башына сукты, ул аптырады, ләкин тышка чыгармаска тырышты:

---

[1] *Жалование* – эш хакы.

«Ничек? Шул теге бервакытта көй отарга барганда, матур бер төн биргән башкорт хатыны Гөлбикә шулай дөньяга чыга алырмы? Гаҗәп бу эш!» – дип уйлады.

Давытның адресын алды, бүген кич үк, дөньяның хәлен аңлар өчен аңарга барам диде дә, рәхмәт укып, чыгып китте.

Абзый да, җиңги дә:

– Безне ташлама, вакыт булганда килә күр, – дип калдылар.

Сәхип туры Давытка китте. Аның тәне арыган, башы авырып, шешеп каткан, Давытта, бәлки, мәсьәлә ачылыр дип уйлый иде.

## LXXVI
## ГӨЛБИКӘ

Давытны эзләргә дип номерга кереп барса, баскычтан нәкъ моның каршысына Гөлбикәнең төшеп килгәнен күреп, Сәхип шаша калды, башта күзләренә ышанмады: «Бу нәрсә? Төшме, өнме?»

Ләкин бу төш түгел иде. Аның алдында елмаеп, кулларын тартып алырга теләмичә, дөньядан бераз югалып, кайчандыр гаҗәп матур бер төн биргән Гөлбикә тора иде... Тик ул бераз үзгәргән, бераз мәдәниләшкән; өстендә элекке башкорт җиләне урынында хәзер тәннәрен кысып, күкрәген белендереп торган чибәр генә пальто; башында кечкенә калфак өстеннән килешле кара шәл; йөзе, күзе, иреннәре шул – тик аңардан элекке басып, каплап торган караңгы тормыш тупаслыгы алынган да, күзләргә акыллы нур сирпелгән, йөз ачылган, элекке җылтыр каралыктан чыгып, сөйкемле каратутлыга әйләнгән; иреннәр элекке кебек ахмакча яки артык изелеп көлмиләр, матур гына елмаялар. Иң гаҗәбе – куллары да байтак төзәлгән, йомшарганнар, егетнең кулы эчендә үзләреннән-үзләре бераз дулкынланып, йөрәкне уяталар...

Сәхип нәрсә әйтергә, нидән башларга белмәде, турыдан ук:

– Миңа тагы дөнья ачылды, иркәм, вакытың бардыр бит, әйдә миңа барыйк! – диде.

Гөлбикә карышмады: извозчик алдылар да туры егетнең номерына киттеләр.

Сәхип акчаны бик артык кысып тота торган кешеләрдән, чөнки аңа үз гомеренә ярты кадак арыш икмәге алыр өчен бер тиен бакыр таба алмыйча ач утырырга, билендәге каешын кибетчегә салып, кәмәрсез йөрергә бик-бик күп туры килгәләде.

Ләкин бүген ул боларны онытты. Тизрәк самовар куярга кушты, малайны шикәрле булкилар, шоколадлар, алма, виноградлар алырга йөгертте; хакына карамыйча, яхшысын сайларга кушты.

Болар һәммәсе килгәч, бүлмәне бикләде, тәрәзә пәрдәләрен төшерде, электрикны яктыртты да:

– Инде менә хәзер без икәү генә!.. Теге төндәге кебек, минем иптәш Вәли башкорт та, синең ирең исерек Җомагыл да, башка кеше дә юк... Җә, сөйлә, иркәм, нинди могҗизалар сине ул җәһәннәмнән коткарып, бу якты дөньяга чыгарды? – диде.

Гөлбикә, бер ноктаны да калдырмыйча, тулы бөтен күренештә сөйләп бирде.

Җиңги сөйләгәнчә, ireннән аерылуы, моның җырга осталыгын ишетеп, стансада ясалган бер кичәгә чакырулары, шунда шөһрәт алып, моның шәһәргә барып ирешүе, аннан да җырларга алдырулары, җырдан уенга күчерүләре, хәзер инде труппага катнашуы – бар да дөрес икән.

Боларны сөйләгәч, Гөлбикә йомшак, дустанә бер үпкә белән Сәхипнең аның хакында, исемен ачык әйтеп, бер хикәя язуы, моны иптәшләргә күрсәтеп, театрда да укырга теләве хакында халыктан ишеткәнен сөйләде, исемне дөньяга фаш итә язгансың дип, үпкәләвен аңлатты...

Егет моны авыр алмады, кулларыннан алмаш-тилмәш үпте дә:

– Җаным, иркәм, син бит ул вакытта шундый бер караңгы ерак почмакта идең ки, минем язганым ул тирәгә барып ирешүен аз гына хәтергә китерергә юл юк иде... Шулай да икърар итәм, ул эш минем тарафтан бер хата булган, – дип, гафу үтенде.

Ханым:

– Хикәяң янында булса, укып чыгар идең, хикәянең исеме «Башкорт кызы Гөлбикә» бугай? – диде.

Егет бер минутта бөтен сумкаларын актарып, әллә кая эчкә яшерелгән хикәяне табып алды.

Озаклап, хатирәләргә китеп, укып чыктылар. Гөлбикә бик яратты, егетнең күзләренә карап:

– Ул вакытта шул чаклы сөйгәнсең сөюен дә, аннан соң әллә кемнәр белән йөреп, мине исеңнән үк чыгаргансыңдыр инде, диде.

Гадәтендә булмаса да, Сәхип кычкырып, чәнчелеп ант итте:

– Валлаһи, шул яшькә җитеп, синнән башка һичбер хатын йөрәгемә кергәне юк... Сине гаҗәп сагына идем... Ләкин яшерми әйтим, сине бу хәлдә күрермен, дөньяда мондый могҗиза булыр дип аз гына да башыма китерә алмый идем, – диде.

Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: Гөлбикә егетнең куенына кереп югалды, иркәгә, сөюгә сусап кипкән иреннәре, бер-беренә юлыгып, дөньяны оныттылар...

Иң элек Гөлбикә айныды. Аның чәчләре тузган, күлмәкләре бөгәрләнеп

беткән иде – көзгегә килеп рәтләнде дә:

– Кайтырга вакыт, мине озат! – диде.

Егет бик сак, бик ялынулы рәвештә монда кунарга үтенде. Ханым башта куркынды, ай, булмас, белерләр, дип каушады. Ләкин Сәхипнең берничә сүзеннән соң, кинәт карарга килеп, өстендәге пальтосын, башындагы шәлен яңадан салып ташлады.

Моннан күп еллар элек, әллә кайда, караңгы башкорт авылында үткәргән бәхетле төнне яңадан кайтардылар.

Бу ике төн һәр икесе өчен дә бөтен гомерләрендә бердәнбер, бөтен гомерләрендә тирән сөю хисе, иге-чиге булмаган бәхете, рәхәте белән бөтен гомерләрендә тиңдәшсез һәм ошашсыз кебек күренде.

Кайбер җаннар сөю дәрте белән тулып яратылалар. Ләкин авыр, караңгы язмыш бу дәртне, бу ялкынны каплый, йөрәктә кайнаган бу ашкынуны үзенең эзләгәненнән мәхрүм итә – гүя аны караңгы зинданда асрый.

Бер вакыт килеп, бу зиндан ачылса, берничә минутка асыл чәчәк матур кояш нурына юлыкса, – алар өчен бу кавышу сәгатьләре дөньяның һәммә бәхетләреннән югары булалар, җәннәт хыялларын бирәләр.

Сәхип белән Гөлбикә шундый җаннардан, аларның бу ике кичәсе дә шундый сәгатьләрдән иде.

Яшь хатын якын арада труппа белән моннан китәчәк икән. Тагы берничә көнгә бергә булып, күңелдән аглап, һәр икесе бөтен дөньяда ятимлек хис итеп, тизлектә тагы кавышуны теләшеп аерылыштылар.

## LXXVII
## БАНКИРНЫҢ КАРТАСЫ ШӘП ТҮГЕЛ

Гөлбикәгә сихерләнеп иптәшләрен оныткан җырчы Сәхип, берничә көннәр йөреп, өйдә очрата алмыйча аптырап беткәннән соң, кичке сәгать унбердә Давытның номеры ачык булган вакытны туры китерә алды.

Берничә кага – тавыш юк; тагы катырак суккач, кемдер иренүле, ярым ачулы аваз белән русча:

– Кем бар анда? Керегез! – диде.

Ишекне ачкач, егет аптырап калды: бүлмә тәмәке төтене белән тулган, һава искиткеч авыр, тончыктыргыч; тәрәзә буендагы өстәлдә берничә аракы шишәсе, боларның кайсы буш, кайсы ярты, кайсы бер дә башланмаган; әллә ничаклы икмәк сыныклары, тоз, горчица, балык башы, ярты аршин озынлыгы колбаса, бер тәрилкә кыяр, байтак суган, – тагы белмим ниләр, – гаҗәп бер тәртипсезлек белән өелгәннәр. Өстәл астында пиво бутылкалары белән тулы кәрзинкә... Бүлмәнең уртасында, зур ук икенче бер өстәл тирәсенә, унлап

кеше утырганнар. Һәммәсенең чәчләре тузган, йөзләре эштән чыгып борчулы, үзләре һәммәсе дә, авыр бер математик мәсьәлә чишеп утырган кебек, артык тирән уйдалар. Арада берсе аягүрә баскан, кулында бер колода карта, исерегрәк тавыш белән банкы тота.

Сәхип күзләренә ышанмады: «Йа Ходай, бу Урманов түгелме соң?» – дип шаша калды...

Давыт шул иде. Ләкин Сәхипкә ул бөтенләй башка – элеккенең хәрәбәсе кебек күренде: чәч тузып маңлайга төшкән, күптән таралмый чобалып[1] беткән; йөзе ябыгып караңгыланган, күзләрдә элекке ут, элекке гайрәт юк; чәчендә бераз чал күренә, җитмәсә, буе да бераз бөкрәйгән, яңаклары эчкә кергән, ирен, күз төпләре җыерчыкланган...

Тагы ипләбрәк караса, һәммәсе диярлек танышлар булып чыкты: Госман, Тангатар, Баязид карый, Фәхри, Габдрахман, Гриша, Вера, Җиһангир... Тик арада Сәлимов дигән озынрак буйлы, аксыл ябык йөзле, ачык күгелҗем күзле бер егет белән яшь сәүдәгәргә ошашлы өч адәм генә чит иде... Болар яхшы киенгәннәр, ләкин компаниянең бик үз кешесе күренәләр иде.

Сәхип, аптырап, ни эшләргә белмәде, шулай да кире чыгарга көче җитмәде, әллә нинди бер ят тавыш белән:

– Исәнмесез, иптәшләр... – дип тартынып, кыюсыз сорады.

Урманов, Сәхип тавышын ишеткәч, борылып карады да:

– Нихәл, Сәхип, сине нинди җил ташлады?.. Хәзер сөйләшәм синең белән... Әле монда базарның бик кызган чагы... Банкыны харап итәләр, – диде. Урманов йөз чытты, тагы өстәде: – Әйдә, ала бирсеннәр... Чукынсын банкысы!

Давытның алдындагы карта кире ягы белән ята иде. Кемдер, кызып:

– Ачып уйна! – диде.

Анда алтылык буби икән. Моны күргәч, компаниянең өмите артты: «Банкирның картасы шәп түгел!»

Давыт тагы бер карта алды, алтылык буби астына тыкты да, озаклап, мәшәкатьләнеп, бер читеннән генә карады.

Монда унлык пики иде. Давытның иреннәре дерелдәде. Компания аңа карап катты, өмит уянды.

Уналты – банкир өчен бер дә, бер дә ярый торган сан түгел инде!

Артык кискен минут килде. Һәр ике як сулыш та алмый, – әйтерсең, хәзер үлмәк-яшәмәк мәсьәләсе чишелә... Үлем тынлыгы; йөзләр, күзләр бер ноктага текәлеп каткан!

---

[1] *Чобалып* – чуалып.

Аламы, юкмы? Алса, ни чыга?

Банкир карарга килде дә кинәт бер картаны ачып ташлады. Ни күрсеннәр: бишлек!

Компаниянең башына яшен суккан кебек булды:

– Гаҗәп бу эш: ике әйләнүдә тик бер мәртәбә бирде! – диештеләр.

– Күңелем сизгән иде, бармаска әйткән идем... фәлән-төгән, – дип сөйләнә-сөйләнә, банкыга акча түли башладылар.

Давыт ике йөз алтмыш сум акча җыеп алды.

Уен дәвам итте, Давыт үз янәшәсендәге иптәшенә:

– Минем картага бөтен мәхәлләсенә бар! – дип, үзе аракы өстәле янына – Сәхипкә килде. Көлә төшеп: – Син эшнең бик кызу чагына килгән идең, гафу ит инде, – дип, бик кыска рәвештә хәлен сорашты. – Син миңа кунарга кил, бу халык берәр сәгатьтән таралыр, сөйләшеп кунарбыз, – диде.

Шул арада, яңгырга манчылып, кемнедер эзләгән төс белән, Зариф Булатов килеп керде. Аның килүе һәммәсе өчен дә көтелмәгән бер әйбер булганга, исерек картачылар компаниясе бер минут гаҗәпсенеп карадылар да, ава-түнә, Булатны сырып алдылар. Ул Җиһангиргә карата:

– Шакир Солдатны син беләсең бит, бүген... – дип башлаган иде, аңа сөйләргә җай бирмәделәр – барысы берьюлы эчәргә кыстарга тотындылар.

Шул вакыт йомышчы малай килеп:

– Урмановны телефонга чакыралар, – диде. Давыт, нәрсә монда эш бүлдерәләр дип сүгенә-сүгенә, телефонга барып килә. Авызы җырылып керә:

– Булат, – ди, – сиңа яңа хәбәр: Нина кайткан. Синең номердан шалтырата. Әйберләре белән синең бүлмәгә дә кереп урнашкан.

Урмановның бу сүзләренә Булат башта ышанмады. Чөнки алты ай буе һичбер хат-хәбәре булмаганга, бәлки Коля белән бергә Русиядән качкандыр дип уйлый иде. Давыт чынлап әйткәч, ашыгыч чыгып китте.

## LXXVIII
## ЕГЕРМЕ БУЛСА, АЛ!

Сәхип төгәл бер сәгать йөреп килсә, монда һаман уен бара иде әле.

Эчүдән дә, уйнаудан да кызык тапмаганга, ул икегә чаклы карап утырды да, мин йоклыйм инде дип, ширма эченә кереп ятты.

Башы талган, йөрәге суга, хыял бик артык кызу эшли иде. Башта Гөлбикә белән җенләнде, аның белән беренче төнне үткәргән башкорт авылына, аннан шәһәргә китте. Кайдандыр Разия килеп чыкты, аларда булган җыелышны яңадан ясадылар, ләкин тегесе кебек чыкмады, туташ та чит карый, ир иптәшләрнең дә теле сүз тапмый иде. Кайдадыр Гәрәй Солтан күренде, аны асарга алып баралар, дар агачына китереп, муенына җеп сала

башлагач, ул кайдадыр югала да, баштанаяк кызыл киенгән кара йөзле палач үзе аның урынына асыла, нидәндер гыр-гыр килә, күзләре коточкыч булганнар...

Юк, кайдадыр зур җыелыш икән, яшерен типографияне тапканнар имеш дип, кемдер урамга йөгерә... Халык кача, кемдер таптала, атлы казаклар куып-куып, камчы белән яра башлыйлар... Куркып уянып китсә, компания һаман бара иде әле, кемдер: «Миндә унтугыз, егерме булса, ал!» – дигәне өндәме, төштәме ишетелеп кала. Сәхип, әйләнеп, башын мендәр астына тыга да авыр, саташулы йокы белән йоклап китә...

Иртән сәгать унда уянса, тегендә шул ук тавыш:

– Миндә унтугыз, егерме булса, ал!

Торып чыкса, ни күзең белән карыйсың: бүлмәдә төтен болыт булып оешкан. Өстәлдәге бутылкалар ауган, суган, колбаса кабыклары подностагы суда йөзәләр, аяк асты ватылган рюмкалар, түгелгән пиволар, тәмәке төпчекләре, икмәк сыныклары, балык башлары, кыяр кабыклары белән эштән чыгып, пычранып, адәм карый алмаслык рәвешкә кергән... Ләкин компания һаман бара... Тик Вера гына күренми... Башкалар урыннарыннан кузгала, башларын күтәреп карый алмыйлар; күзләре үлгән, куллары калтырый, йөзләре җәһәннәмнән чыккан шайтанны хәтерләтәләр.

Госман түзмәде, шешә төпләрендә калган аракыны каплап эчте, көзге алдында ава-түнә чәчен ипләп маташты да, булдыра алмагач, умывальникка килеп, йөзен, башын юды... Бу, ахры, бераз айныткандыр:

– Кадалып китсен дөньясы, сәгать унбер икән... Бүген тагы соңга калдым... Хушыгыз! – дип, ашыгыч-ашыгыч чыгып китте.

Уенның мәгънәсе беткән, уйнарлык көч калмаган иде Шулай да, тагы бер генә колода, тагы бер генә колода дип тарта-тарта, сәгать икегәчә маташтылар да тарала башладылар... Үзләре хәлсезләр, гәүдәләрен тота алмыйлар; аяклары кушканны тыңламый, чалыш атлый, көзгегә карыйлар да:

– Бит чабата төсенә кергән икән! – дип, ава-түнә киенә башлыйлар.

Тангатаров, Җиһангир, Госманнар барысы да төрле дәрәҗәдәге аттестатниклар, һәммәсе:

– Чукынсын! Бүген тагы дәрес калды, кичә ятлаган латин бүген тагы онытылып бетте, – дип, әбисе-бабасы белән сүгенеп чыгып киттеләр.

Алар артыннан Габдрахман: бүген тагы репитициягә кичегәм, тагы ачуланырлар, дип; ак, ачык йөзле, күгелҗем күзле Сәлимов: Столыпинның декларациясен тәрҗемә итәсе бар иде, редакция материал дип җанга тияр, тәрҗемә кыл инде менә бу баш белән, дип, тагы шулай һәммәсе эш калудан, баш ярылудан зарланып, сүгенеп таралдылар. Давыт Урманов ул заманның баш министры Коковцев[106*] белән Шингарев[107*] арасында бюджет

мәсьәләсендәге талаш мөнәсәбәте белән мәкалә язарга тиешле иде. Сәлимов, көлеп:

– Мәкаләң әзерме, әйдә редакциягә! – диде.

Давыт кул селекте.

– Бармыйм. Редактор: ник килми, эш калдыра, дип бәйләнсә, тәүлек буена карта уйнады, эчте, килә алмый, диярсең... Тагы кызып, материал сорый башласа, минем өчен ике җөмләлек баш мәкалә яз: Каковцев белән Шингарев дигән ике алпавыт – буржуа эт халык сөяге өчен талашалар, ләкин пролетариат боларны аерачак, диң! Ярыймы? Ну, исән бул, мин яттым!

Иптәшләрен озатуга, ишек-тәрәзәне ачып, һаваны сафлады да, Сәхиптән гафу үтенеп, кич белән кил, иптәшләр булыр дип, чишенеп ятты.

Сәхип, башын югалткан дивана кебек, кая барырга белми, зур, озын коридор буенча акрын атлап чыгып китте.

## LXXIX
## НИНА КАЙТЫП ТӨШТЕ

Нинаның кайтып төшүе Булатны канатландырып җибәрде.

Алар күптәнге танышлар иде. Партия эшендә якын иптәшләр иде. Ләкин моңарчы бер-беренә ир-хатын дип карамадылар. Ул турыда һичбер вакыт сүз дә булмады. Теге вакытта кызның Чиләбегә китәр алдыннан калдырып та, Гәүһәргә эләккән хаты шиксез бер сөяркәнең түгел, тик бер иптәшнең икенче иптәшкә язган хаты гына иде. Ул вакыт Нина ярым ачык, ярым яшерен рәвештә Коля белән тора иде. Сөеклесен Гәрәйләр белән бер төндә кулга алып, Якутстанның иң караңгы почмакларына сөрделәр. Кыз, барлык пәрдәне ташлап, аның артыннан китте. Ике ел бергә тордылар.

Ләкин бу ике ел аларны якынайтмады, киресенчә, алар бер-берсенә эчтән еракландылар, эчтән суындылар.

Нина болай төскә матур түгел. Гәүһәр белән Разия хурлаганча, томшык борын, киң авыз, мәче ялаган каш булмаса да, аның йөзендә бераз шадра бар. Борыны бераз гына җәенкерәк. Уң кашының бер чите йөзен шадралаткан чәчәк авыруы чагында бераз чокырланып, сыекланып калган. Ләкин аның күзләре бөтен йөзенә нур сибәләр, һәммә нәрсәгә яратып, сөеп-иркәләп, яки дошманлык уты белән янып карыйлар. Шул караш, шул күз нуры аның торышына матур мәгънә чәчә; аның йөзендә булган кайбер кимчелекләрне югалтып, каплап җибәрә. Ул каты сөя. Шул көчле сөюе белән ирләрне үзенә баглый. Аның беренче мәхәббәте Коля булды. Ул үзенең сөеклесен әллә ничаклы чибәр курсисткалар тозагыннан яшерен сугыш белән үзенә тартып алды. Ул: «Мин бер генә сөючән, мин үз гомеремдә бер генә ирне сөя алачакмын», – дип карый иде. Дөньяда партия өчен торам, революция өчен

торам дип ышана. «Ләкин шул ышануны мәхәббәт белән нурландырмасам, минем канатларым хәлсезләнә. Минем өчен партия бар. Революция бар. Шулар белән бергә багланып кайнашкан Коля бар. Үзем бар. Болар бер-берсенә башка әйбер түгел. Һәммәсе бер процесс, һәммәсе бер көрәшнең төрле күренешләре генә», – дип матурлап уйлый. Шуңа күрә, сөеклесе сөргенгә җибәрелгәч, ул аз гына да икеләнмәде – үзенең язмышын аның белән бәйләде. Ләкин сөргендә көтелмәгән бер трагедия булды. Анда социал-демократлар колониясендә карт революционер бар иде. Шуның җилбәзәк чибәр кызы Коляның башын әйләндерде. Нина гайбәткә ышанмый торган хатын иде. Юк-бар сүзгә колак салмады, ләкин ике тапкыр үз күзе белән күргәч, Коляга әйтте: «Син нигә яшеренәсең? Туры әйт миңа!» – диде.

Егет туры әйтергә батырлык итмәде: «Йә, төкер, кечкенә мәсьәлә ул», – дип кенә кичерде. Әгәр шуның белән беткән булса, Нина, әлбәттә, моны вакытлы бер җилнең вакытлы бер дулкыны дияр дә оныттыр иде. Алай булмады, хатын үз күзе белән тагы бер тапкыр вакыйгага шаһит булды һәм шул көн кич сөеклесен чаңгы шуарга авылдан читкә алып чыкты да йөрәгендә җыелганны сөйләп бирде. Шул көннән аның мәхәббәте киселде. Ул көнне көне белән аннан китмәкче иде. Ләкин партия ярдәме белән дүрт большевик сөргеннән, Япония аркылы качып, Швейцариягә китәргә тиешләр иде. Боларның берсе Коля иде. Нина бу качыру эшендә план буенча нык катнашучыларның берсе иде. Ике тапкыр план җимерелде, әлгә яздылар. Өченчесендә генә кача алдылар. Кыз озатканда ачык әйтте: «Без гомергә аерылабыз!» – диде.

Менә бүген озак юлдан арып, ватылып кайткач, аның башына бүтән һичбер уй килмәде. Бары иске иптәш, иске партиядәш дип карап, туры Булатны эзләде. Тапкач, аның кечкенә бер номерда торганын белгәч, аз гына да икеләнеп тормады:

– Мин аның якыны. Ышансагыз, кертегез! – дип, ачкычны алды да үзенең әйберләре, чемоданнары белән Зарифның бүлмәсенә, үзе юкта, иптәшчә кереп урнашты.

Булат, Давытлардагы мәҗлесне ташлап, канатлангандай очынып бүлмәсенә кайтканда, Нина юынып, таранып, өс-башын аз гына төзәтеп өлгергән иде инде.

Ишек ачылып китте, алар бусагада бер-берсенә капланыша яздылар:

– Зариф, синме?

– Нина, синме? – диешеп, кочакланышканнарын үзләре сизми дә калдылар.

Кыз башта, иптәшчә якын елмаеп, Булатның кулларын каты кысмакчы булган иде, егет ничектер:

– Их, Ниночка, синме бу? – диде дә култыгыннан биленнән кочаклап алды.

Кыз, шаян көлеп:

– Ай, мине егасың, – дип кычкырды. Ләкин протест итмәде, үзе аңа таба ава язды, Булат аның чәченнән иптәшчә үбим дип үзенә тартканда, күз карашлары ничектер очраштылар, шунда иреннәре юлыгышып китте. Озак үбештеләр...

– Бу ни эш, Булат? – дип кычкырып көлеп, кыз идән уртасына сикерде. Ләкин аның элеккечә матур нур чәчеп торган якты күгелҗем күзләрендә ачулану да, шелтәләү дә юк, бары тик бу кинәт булып киткән вакыйгага мәгънә бирә алмаудан килгән бер гаҗәпсенү генә бар иде.

Беренче сүзләр, беренче исәнләшүләр иң якын иптәшләр турында булды. Бер нәрсәдән икенчегә сикереп, аннан тагы кире кайтып, үзләренең башыннан кичкәннәрне тәртипсез, ашыгыч сөйләп үттеләр. Кыз үзенең өч елга якын этап, сөрген хәлләренә, чит илгә качыру вакыйгаларына кагылып китте. Булат үзенең сөрген, качу, зиндан хәлләрен, мондагы трагедияләрне кыска, аз, ләкин таштай авыр сүзләрдә әйтеп ташлады:

– Ни әйтәсең? Партком әгъзаларыннан берәвен астылар, өчесе ерак, салкын Туруханга сөрелде, дүртесе монда хөкем көтеп зинданда утыралар. Бер йөз икенче белән каплаячаклар, йә крепость, йә дүртәр ел сөрген булачак. Мин үзем дә хөкемгәчә генә чыгарылдым, – диде. Идән уртасына баскан килеш кызның күзенә текәлде: – Ләкин алай гына түгел. Эчтән черү дә бик тирән китте. Безнең Госман Азаматовка син бик ышанып карый идең, һаман мактый идең бит, шулай бит?

Нинаның шадралы йөзенә, якты күзләренә нечкә катлау болыт каплагандай булды; ул, кашын җыерып, Булатның кулыннан алды, күзләренә куркып йотылды:

– Нәрсә? Әллә провокатормы?

– Юк, алай түгел, менә ничек: 1907 нче елның дүртенче июнендә, төнлә сәгать икедә, миңа килгән. Күзләре аптырап каткан. Йөзе таш. Теле әйләнми. Ну, Зариф, ди, балалык җитте. Безгә хәзер уйланырга кирәк, ди. Мин әйтәм, ни бар? «Ни булсын! пролетариат җиңелде. Кораллы сугыш барып чыкмады. Икенче Дума куылды. Андагы социал-демократлар фракциясеннән илле кеше ябылды. Хәзер революция бетте, менә шуңа карап тактиканы яңартырга кирәк», ди. Ничек? мин әйтәм. «Тәртәләрне борырга кирәк!.. Кызыл авызлык җитәр! Тәртәләрне борырга кирәк!» – ди.

Нина кыенлык белән ышанды:

– Шул Госманмы? Соң ул бит, атасыннан мирас калган өен сатып, акчасын революция файдасына тоткан кеше...

– Шулай иде шул. Ә менә хәзер инде 1907 нче ел өченче июньнең законы [108*] буенча, үзенең Думага сайлау-сайлану хокукларын кайтару өчен, шул элек саткан йортны яңадан сатып алырга йөри, бу турыда Йосыфҗан белән компания кора имеш, диләр...

– Ул нинди Йосыфҗан тагын?

– Син аны белмәссең. Ул монда татар эсерлары белән кайнашып йөргән бер байбәтчә. Үткен, усал, үзенчә акыллы нәрсә... Шул безнең Гәүһәрнең дә тәртәсен уңга таба бордырырга план кора бугай...

Нина башта ук берничә тапкыр бу кыз турында сүз кузгатырга уйлап караган иде, ләкин, көнләшүчелек күренер дип, телен тешләгән иде. Булат үзе аны авызга алгач, бер дә алай исе китмәгән рәвештә:

– Ул тагы анда нәрсә бутала? – дип сорап куюдан үзен тыя алмады.

Кечкенә бүлмәнең почмагын каплаган этажеркадагы китаплар эченнән Булат бер тар, озынча, алсу матур конверт чыгарды. Аның эчендәге хатын алды да кызга бирде.

– Менә укы, күрерсең! Ул турыда синең электән бераз шөбһәң дә бар иде ич, мин ачыклык телим, шигең калмасын! – диде.

Нина иң элек матур алсу кәгазьне әйләндереп карады. Анардан килгән хуш искә борын җыерды да русча нечкә, чибәр кул белән язылган хатны кычкырып укыды,

«Булаткаем, мин китәм. Партия эшеннән дә, революциядән дә, синнән дә китәм. Сүгеп, әрләп түгел, кызганып китәм. Беләм, сагынырмын, шулай да китәм. Сезнең арада кайнап, мин күп нәрсә алдым. Башкаларын югалтып беттем бугай. Ләкин бер нәрсә калды: мин сездән ачык-кискен куярга өйрәндем. Туп-туры әйтергә гадәтләндем. Актык хатымда күңелемнең иң тирән серләрен сиңа ап-ачык итеп, туп-туры әйтергә телим: революция җиңелде, бетте. Хәзер контрреволюция бәйрәм итә. Мин моңа дошман! Мин эчемнән әрним. Ләкин миндә бу авыр шартлар эчендә көрәшеп бара алырлык көч юк икән. Минем канатларым сынды. Минем йөрәктә сезнең кебек, Нина кебек, Гәрәй кебек, Коля кебек сугышып бара торган куәт юк. Шуңа күрә китәм, гыйлемгә китәм. Беләсең, мин, Октябрь эш ташлаулары чорында курсларыбыз ябылгач, Разия белән уку ташлап кайткан идем. Хәзер шул ташланган җирдән яңадан башларга телим. Беләсең, әткәй Мөхәррәм карт үлде. Безнең өйдән килгән табыш әнкәй карчыкка киченергә чак җитә. Мин, укуны ташлап урынга керәм дигәндә, Йосыфҗан егетлек күрсәтте: ел ярым укуың калган, әрәм булма, тәмамла дип, миңа Петербурга китәргә киңәш бирде, акча тәкъдим итте. Булат, мин сиңа актык тапкыр язам, мин сине заманында сөйдем, әле дә сагынам. Синнән, сездән өйрәнгән гадәтем буенча, актык тапкыр ачык-туры сүз әйтим: мин Йосыфҗанның алай Алла ризалыгы

өчен акча түгә торган пакь күңелле егет түгел икәнен яхшы беләм. Шулай да аның ярдәмен алырга булдым: «Укып бетергәч, өч ел эчендә сезгә кире кайтарырмын», – дидем. Ул әйтте: «Кайтармассың!» – диде. Мин: «Кайтарырмын», – дидем. Мин: «Айга иллене бир, дидем. Барысы ел ярымга тугыз йөз сум була», – дидем. Ул: «Айга йөз сум ал. Ел ярымга мең сигез йөз сум булыр!», – диде. Мин кире сукмадым. Мин үземә ышанам. Иллене алсам да, йөзне алсам да, мин аңа бурычлы калмам, укуымны бетергәч, өч ел эчендә түләп өлгерермен дип ышанам. Мине гаепләмә. Һәммә кеше синең кебек каһарман була алмый икән, Зарифчигым. Сине сагынырмын, уйлармын. Ләкин яңадан хат язмам инде...

*Гәүһәр».*

Нина, укып бетәр-бетмәс, хатны җиргә ташлады:

– Фу! Пычрак! Сатылган, беткән. Ул гына җитми, шул сатылуны тагы ниндидер матур сүзләр белән бизәргә азаплана... Җылан! Ирләр алдап дөнья көтә торган матур җылан! Мин аңа электән дә бер минут та ышанмадым... Иптәшләрнең ышанып карауларына гаҗәпләнә идем...

Булат, борчылып, соң җавап кайтарды:

– Ышанды дип... ни... кайбер әйбер саклады... Разияны ничә тапкыр өендә яшереп тотты. Андыйлар да ул чакта кирәк иде бит...

## LXXX
## МИНЕМ УЛЫМНЫ НИГӘ АСТЫЛАР?

Нечкә бармак белән кемдер ишек шакылдаткандай тоелып китте.

Ачсалар, Габдулла абзыйның яшүсмер кечкенә кызы Маһирә ниндидер бик карт бер карчыкны җитәкләп алып килгән, ишек төбендә аптырап каранып торалар. Нина, бераз гаҗәпсенеп, якын ук килде. Булат, нидер таныган, кемгәдер ошаткан кебек, нидер сизенеп, карчыкка күзләре белән карады; кинәт уянып:

– Маһирә, син икәнсең ич! Бу әби кем?.. Әйдә керегез, ни торасыз, – диде.

Карчык җыерчыклар белән капланып, кара саргылтланып кипкән йөзе, салынкы кашлар астына әллә кая төпкә, тирәнгә яшеренгән сүнек күзләре белән Булатка күтәрелеп карады да:

– Син Зариф дигәннәре буласыңмы? Минем улымны нигә астылар?! – дип җылап җибәрде. Шунда, һушыннан язып, бусагага сузылып төште.

Нина завод районында учительница булып торган чагында эшче хатыннар белән күп катнашкан, мондый хәлләрне күп кичергән кеше иде. Аз гына да аптырамады, Булатка:

– Ни каттың? Әйдә тот аягыннан! – дип, һушсыз карчыкның

муеннарына килеп ябышты.

Икәүләп бүлмәгә керттеләр, Булатның караватына яткырып, иң элек аягындагы пычрак галошларын салдырдылар. Хатын тиз-тиз изүләрен чиште, иске ертык бишмәтнең төймәләрен бөтенләй ычкындырды. Булат йөгереп чыгып су китерде, нашатырь спирты тапты. Йөзенә бөркеп, чигәләрен уып, борынына иснәткәч, карчык һушына килде. Як-ягына каранды да Булатка күзләрен терәде. Әллә кайдан, җәһәннәм газабы аркылы килгән, көенеч белән кипкән тавыш баягы сүзләрне кабатлады:

– Зариф дигәннәре син буласыңмы? Минем баламны нигә астылар? – диде. Күз яшенә буылып тагы өстәде: – Кабере кайда? Каберен әйт. Ичмаса, исемен яздырып, таш куйыйм баламның?! – Артык сүз әйтә алмады, үксеп-үксеп, бик озак җылады. Битләре, борын буйлары, бармаклары күз яшенә чыланып бетте.

Маһирә ишек төбенә баскан килеш катты. Нина ни эшләргә белми калды. Трагедияне тик Булат кына белә иде:

– Юк, әби! Җылама, улыңны асмадылар... Ул тик төрмәдә генә! Башка кешене кертмиләр. Мин сине шуның өчен заводтан чакырттым... Сине кертерләр, менә иртәгә үзем алып барырмын, кертерләр, җылама, әби! – дип җуатырга тырышты.

Карчык колакларына ышанмады, сүнек, тирән күзләре белән йотылып, ябык, кипкән тамырлы куллары белән Булатка ябышты:

– Шулаймы, балам? Әле асмаганнармы? Миңа күрсәтерләрме? – диде. Туктала алмады, җылады, тагы үксеп-үксеп җылады.

– Эше яман, диделәр. Патшага каршы барган, диделәр. Андыйларны асалар икән, диделәр. Менә бер ай инде, Зариф балам, күзем йомсам, алдыма үлем баганасы килә, шунда бер шәүлә асылган кебек күренә. Тамагыма аш каба алмыйм, су алсам, канга әйләнә, Илаһым, Ходаем, нинди генә гөнаһшомлыкларым булдымы икән? Кемне рәнҗеттемме икән? Кемгә каты тел әйттемме икән? Кемнең хакына тидемме икән? Илаһым, хуҗам, үзең ярлыка, үзең барча гөнаһларыбызны кичер!

Карчык кул күтәреп дога кылды. Белгән аятьләрен, догаларын укыды:

– Дөньяда тәүфыйк, бәхет бир, кыяматтә рәхмәтеңнән мәхрүм итмә! Амин, – диде дә урыныннан торды, яңадан киенеп, ишеккә таба атлый башлады: – Шулай баламны күрә алырмынмы икән? Бәбкәм, мин карчык кеше, мин җүнне табып бара алмам, Алланың рәхмәтенә иреш, Зариф балам, мине чакыртып җибәрүеңә рәхмәт. Алла Тәгалә бергә мең итеп кайтарсын, мин Хәдичә киленнәргә төштем. Ул миңа кардәш тия. Иртәгә син, балам Зариф, мине алып бар! Күңелем курка, бу төндә генә балама бер-бер хәл итмәсеннәр иде, Илаһым! – дип, кулына таягын алды.

Аны түбәнгә төшереп, почмакка чаклы озаттылар да кире керделәр.

Хатын, Булатның беләгенә тотынып, күзенә карады:

– Шулай бит, бу аның анасы бит? Шулай ук качырырга бер дә юл таба алмадылармыни?

Булат ишекне бикләде, авыр, тирән борчылып, Гәрәйләрне зинданнан качыру планнарының хәзер ни дәрәҗәдә торганын сөйләп чыкты. Трагедиянең ахыры шунда: Разиянарны, Гәрәйләрне – барлыгы алты большевикны шәһәр зинданыннан коткару эше, инде менә булып бетте дигәндә, арада провокация баш күтәреп, ике тапкыр тотылалар, яман кыйналып, ватылып, ерткыч режим белән богауга утыртылалар. Ул гына түгел, провокаторлык аркасында, бу качуны оештыру өчен тыштан эш алып барган ике эшче организатор эләгеп, каравылга һөҗүм кылдылар дигән сылтау астында, шул җирдә атып үтереләләр.

Бу авыр трагедияләрне сөйләп, югалып утырганнан соң Булат кинәт уянгандай булды:

– Тукта, син ачтырсың! Сүз белән тамак туймас! – дип, кайнаган самовар, май, икмәк, сыр алдырды да чәй китергән керле алъяпкычлы малайга: сорасалар, «өйдә юк» дияргә кушып, яңадан ишекне бикләде.

Үзләре тагы сүзгә керештеләр. Килгән самовар сүнде, ясалган чәй стаканнарда суынды, майга, икмәккә кул да тидерелмәде. Нина, тамагын-ачлыгын онытып, өзлексез сөйләргә, сөйләтергә тотынды. Сөйләнгән вакыйгалар эчендә үзен онытты. Ул ерак сөргендә чагында ук революциянең җиңелгәнен, контрреволюциянең котырган эт кебек бәйрәм итүен белә иде. Юлда кайтканда да күп нәрсәләр белән танышкан иде. Ләкин Булат сөйләгән конкрет моментлар аның йөрәгенә каты таш булып утырдылар.

Ул берничә минут телдән калган кеше кебек катып торды да һич көтелмәгән нәрсә турында сорап куйды:

– Алайса, хәзер парткомны ничек оештырабыз инде? – дип, сөальле караш белән Булатка кадалды. Тиз генә җавап ала алмагач, яңа сорау өстәде: – Үзәк Комитеттан инструкция, директива алырга кирәк. Аның белән багланышны ничек юлга куябыз? – диде.

Зариф газаплы тынлык белән бераз тик торды. Ачык, кискен, конкрет рәвештә җавап таба белмәде. Җавап урынында башка мәсьәләләргә чумды:

– Бер монда гына түгел, анда, эмиграциядә дә, Ленинча әйтсәк, шул ук развал[1], распад[2], идейно-политический разброд[3] хөкем сөрә. Мин көтелмәгән

---

[1] *Развал* – тәртипсезлек, буталчыклык.
[2] *Распад* – таркалу.
[3] *Идейно-политический разброд* – идея-сәяси яктан таркалыш.

бәхет аркасында «Пролетарий»ның 1909 нчы ел, декабрь 11ндә чыккан 50 нче номерын кулыма төшерә алдым. Ленинның мәкаләсе бар, ул хәзерге хәлне партия кризисы дип атый. Моның сәбәпләреннән берсе итеп революциягә кушылган вак буржуа элементларының неустойчивостьларыннан[1] дип аңлата. Андагы материалдан бер нәтиҗә чыга: социалист партияләр арасында тик безнең большевиклар организациясе генә үзен, үзенең органнарын, үзәкләрен саклап чигенә алды, эсерлар, меньшевиклар эчендәге җимерелүне һич әйтеп бетерәсе юк. Меньшевиклар ликвидаторлык юлына баттылар: «Революция бетте. Яңадан булмаячак, хәзер яшерен партия кирәкми, идән асты оешмалары бетсен!» – дип чыгалар. Безнең большевиклар эчендә бер канат ультиматист-отзовист[109*], берсе богостроитель [110*] булып саташучылар туды. Таза, исән, нык үзәк тик Ленин җитәкчелеге астындагы большевик агым булып калды. Бу агым һәр ике якка: уңга – ликвидаторларга, сулга – ультиматистларга-отзовистларга каршы каты фронт белән сугыш алып бара.

Булат бу турыда озак, сәгатьләрчә сөйләде. Нина партия үзәкләреннән, үзәк материалларыннан нык аерылган иде. Аңа боларның күбе – бөтенләй яңа әйберләр булып төштеләр.

Көн үтте. Каралып, кич килде. Ул үтте. Төн килде. Ул үтеп бара. Ләкин Булат белән Нина һаман сөйләшүдән туя алмадылар. Куркыныч караңгы урманны ярып чыгар өчен сукмак эзләгән юлчылар кебек, ашкынып-ашкынып, алга, якты маяклы юлга таба күңелләрен суздылар. Вакыт үткәнен, төн кичеп, таң килгәнен сизмәделәр.

Тик таң яктысы тәрәзә аркылы төшә башлагач кына йокыга яттылар. Ләкин йокылары тыныч булмады.

## LXXXI
## ИРТӘГӘ КОЯШ ЧЫГУЫНА ЫШАНАСЫҢМЫ?

Тәрәзәдән төшкән көндезге кояш яктысына уянып китсәләр, инде сәгать унбер тулып, уникенчегә киткән.

Булат чәй эчәргә өлгермәде, тиз-тиз юынып, тузган чәчен тарады, соры кепкасын, эре төймәле кара пальтосын киде дә Гәрәйнең анасы карчыкны зинданга алып бару өчен Габдулла абзыйларга йөгерде.

Анда барып керсә, өй эче тулы кеше. Карчык үксеп-үксеп җылый. Хәдичә җиңги белән Габдулла абзый бик кызып талашалар, Сәхип, Баязид, Тангатаров, Җиһангир шуңа кушылганнар. Шакир солдат туры Булатка ташланды:

---

[1] *Неустойчивостьларыннан-* тотрыксызлыкларыннан,үзгәреп торучанлыкларыннан

– Менә ул гыйлем кеше, ул әйтсен: ярыймы, юкмы? – диде.

Хәдичә җиңги чәрелдәп, кызып сөйләп бирде:

– Менә, – диде, – Зариф, син үзең исәплә: Гәрәйне ничә заман төрмәдә утырталар. Аяк-кул богаулы... Атасы карт йөри алмый, ач ята. Менә җылап анасы килде. Инде ни була? Патшадан сораса, ни була?

Зариф мондый яңа мәсьәләгә бик гаҗәпләнде:

– Кем сораса, нәрсә сораса? – дип, аптыранып, әле җиңгигә, әле Шакир солдатка карады. Чөнки бу крәстиән дә башын селки-селки Хәдичә җиңгинең сүзен җөпләп, дөресләп торган кебек күренде, ләкин Булат кисеп туры карагач, ул бераз чигенде, үзе башламады, аның өчен Габдулла абзый җавап бирде:

– Безнең, – диде, – талаш шунда: төрмәдә мулла бар икән бит! Ул анда тоткыннарга җомга укыта икән, гает укыта икән. Шул Кәримә әбине, белмим, каяндыр ишеткән дә безгә килгән. Башында чалма, өстендә чапан, аягында яшел савырлы читек белән күн кәвеш, бер кулында тәсбих, бер кулында таяк. Әйтерсең, гает намазына бара инде. Шулай килгән. Утырып, дога кылды да Кәримә әбигә әйтте: «Әүвәл Алла булса, икенче патша, диде. Әби, синең улың патшага каршылык кылган, диде, мәгәр түбәнлек белән гафу үтенсә, патшаның күңеле киң, бәлки гафу итәр. Мин сезгә шуны әйтергә килдем. Бер мөэмин-мөселманның җанын сакласам, савабы булыр дип өмит итәм», – ди. Шулай сайрады-сайрады да, мулла чыгып китте... Менә без хәзер талашабыз. Минем хатын әйтә: «Гәрәй үзен уйламаса, карт атасы белән карчык анасын уйласын, патшадан гафу сорасын, бәлки кичәр», – ди. Мин әйтәм: «Ярамый», – дим. Әнә Шакир әйтә: «Сораса ни була, сорый бирсен», – ди. Менә Җиһангир иптәш тә: «Ярамый!» – ди. Шуннан талашабыз. Син нәрсә әйтерсең, мондый эш ярыймы, юкмы? – дип, Зарифның күзенә сорау белән карады.

Булатның йөзенә, күзләренә кара төс чыгып китте. Аскы иренен тешләп, берәр минут сүзсез торды да туры Габдулла абзыйга йотылды:

– Ул козгын ни эшләп йөри монда? Беләсеңме, аны охранка җибәргән монда! Инде шуннан үзең аңла! Ярыймы, юкмы? – диде.

Шакир солдатның күзләре маңлаена менде:

– Шулаймы икән? Аннан җибәрделәрме икән? Алайса, кайттым, тәүбә иттем... Безнең караңгылык шул! – диде.

Бу талаш вакытында Кәримә әби, күзен сөртеп, өстенә иске бишмәтен, аягына кәвешләрен кигән, башына шәлен ябынып, кулына Гәрәй өчен алып килгән күчтәнәче белән таягын алган иде инде. Булат хуҗалар белән исәнләште дә әбине алып чыкты. Егетләр һәммәсе аңа иярделәр, зиндан капкасына чаклы бергә килделәр. Әнә шул корал-бомба фабригы – склады

табылып, җиде рус эшчесе белән бергә эләккәннән бирле Гәрәйнең зинданда богауланып утырганын бар да беләләр иде. Жандармнар килеп баскач, маузердан атып каршы алганнарын да ишеткәннәр, аннан башка Гәрәйнең Уралдагы бер экспроприациягә катнашуда гаепләнгәне дә аларга билгеле иде. Юл буенча бу эшләр турында Булатовтан сораша килделәр. Ләкин Зариф сүзгә юмартланмады, теләсә дә, ачылып китә алмады. Чөнки аның башын бу гафу соратырга димләү провокациясе каплап алган иде. Ул шуңардан куркынды: әгәр элекке Гәрәй булса, бирешмәс, гафу сорау белән үзен пычратмас. Ләкин еллар буенча ялгыз зинданда утыру аны бик ватмадымы, характерын сындырмадымы икән? Харап бит. Нервылар изелгән булса, җиңелеп куйса – харап бит!

Бүген күрешү көне икән. Язуларын күрсәткәч, карчыкны эчкә керттеләр.

Булатлар шунда капка төбендә аны көтәчәк булдылар.

Сүз ничектер көйләнми маташты. Әле кичәге эчү-карта күренешләреннән айнып җитмәгән җырчы Сәхип, аптырап, Булатка карады:

– Бу ни инде бу, Зариф абый? Монда төрмә. Анда эчү, карта. Ә соң социализм кайда? Революция кайда? – диде.

Моңарчы һичбер сүзгә катнашмыйча, эченнән көеп килгән Баязид карый башын күтәрде, бер Сәхипкә, бер Булатның борчулы күзенә карады. «Ни әйтер? Ни әйтер?» – дип көтте. Булат Сәхипне ярата, аны үз юлына таба тарту ягын күзәтә иде. Батырып, аның аптыраулы күзенә карады:

– Иртәгә кояшның чыгуына ышанасыңмы? – дип сорады.

Җырчы Сәхип балаларча беркатлылык белән җавап кайтарды:

– Ник ышанмый? Ышанам! – диде.

Баязид эченнән чәнчелгәндәй, газапlangандай булды: «Юк, менә мин ышанмыйм», – дияргә теләде, ләкин тыелды.

Булат эчке нык тавыш белән:

– Иртәгә кояш чыгуына ышансаң, революциягә дә ышан! – диде.

Сәхип тукталмады:

– Ә соң хәзер менә миңа ни эшләргә?

– Шәһәр читендә ике сумга бүлмә ал. Биш сумга студент ялла да укырга тотын.

Җырчы күңелендәге актык газабын әйтми калмады:

– Ә аннан соң?

– Аннан соң, көне-сәгате килгәндә, барыбыз да яңадан кузгалырбыз... Җепне өзмә. Кергәли йөр. Нигъмәтләр белән пычранма! Алар кара сөрем хәзер! – диде.

## LXXXII
## НИЧЕК АКРЫНЛАП БАТАСЫҢ

Җиһангир белән Тангатаров, Булат янында, зиндан капкасы төбендә, ана карчыкның Гәрәй белән күрешеп чыкканын көтә калдылар. Җырчы Сәхип сүзсез кул биреп алардан аерылды. Баязид та аның белән китте. Алар бергә кайттылар, юл буенча Сәхип исәпләп барды.

Аның җитмеш сум акчасы бар. Менә шуның белән ничек тә бөтен кыш буе русча укып чыгарга кирәк. Күкрәк авыруы да бар. Ашауны да бик кысарга ярамый. Бик арзан бүлмә алсаң, юеш-салкын булып, тагын жүтәлне кузгатмасын – ул, дивана кебек үзалдына шулай исәп-хисап йөртеп бара-бара, Баязидның үзеннән аерылып, почмакта Давыт Урманов һәм Качкын Хәбип Мансуровлар белән сөйләшә-сөйләшә, каядыр аерылып калганын сизмәде дә. Үзенчә, болайрак килеп чыга: ике сумга бүлмә, биш сумга студент, биш сум ашау-эчү, барлыгы – айга унике сум китә. Шулай кысып торганда, җитмеш сум белән бу кышны укып чыгар. Бәлки, язга учительлеккә имтихан да тотар. Менә Булатлар университетка кермәкчеләр. Алар аттестатка әзерләнәләр. Әмма Сәхип әле хәзергә алай зур куймый. Башта учительлеккә барып җитәр. Аннан, бәлки, учительский институтка керер. Анда христиан булмаганны алмыйлар икән болай. Әмма чукынса, яисә министрдан аерым рөхсәт ала алса, татар да керә ала икән. Аннан соң университетка да юл якыная. Болар киләчәк эше. Әмма хәзер бик артык җүтәлләмичә, бер кышны русча укып чыгарга кирәк.

Шулай уйланып, үзалдына сөйләнеп бара торгач, шәһәр читенә җиткән. Кечкенә баткак урам. Тәрәзәләрдә «Бүлмә бирелә» дигән ак кәгазьләр күренә. Икесенә кереп, яратмый чыкты. Өченчесендә бер тәрәзәле кечкенә бүлмә, бик коры, караваты, ике урындыгы, бер өстәле бар. Укучыга тагы ни кирәк? Хуҗасы бер марҗа карчык икән. «Иртә-кич самовар куям, үз янымда чәй эчәрсең, утын миннән, керосин үзеңнән булыр, кирәген алсаң, мичтә аш пешереп тә бирермен, хакы ике тәңкә булыр», – ди. Шулай сөйләшкәндә ишек ачылды да, йөрүдән, суыктан бит алмалары кызарып, әбинең кызы кайтты. Уналты-унҗиде яшьләр булыр. Чибәрме, түгелме? – ничек әйтәсең. Уналты-унҗиде яшьтә чагында ямьсез кыз булмый инде. Йөзендә алсу кан, күзендә яшьлек нуры уйный, иреннәре елмая, йөреш җиңел, чәч толымнары ике иңенә төшә – мондый яшьлек эчендә кызлар ничек ямьсез булсын! Сәхипнең кыюлыгы юк иде, сөзеп карады, ләкин әйтергә сүз тапмады. Кыз үзе китапларын бер бүлмәгә кертеп куйды да шунда боргаланды-сыргаланды:

– Әнкәй, бу абый бүлмә аламыни? – дип, русча сорап елмайды. Начар уй белән түгел, бернәрсә дә уйламыйча, тик яшьлек белән елмайды.

Сәхип һаман да телен әйләндереп бер күңелле сүз әйтә белмәде. Кыз

үзе, тагы елмаеп:

– Сез тимераяк шуа беләсезме? – диде.

Егетнең күңеленә:

– Сез өйрәтерсез! – дигән матур җавап килгән иде, йә килешер, йә юк дип, аны да әйтә алмады. Берсүзсез кесәсенә тыгылып, илле тиен акча чыгарды да карчыкка бирде, русчаны ватыбрак әйтте:

– Йә, әби, бүлмә минеке булыр инде! – дип, ишеккә борылды.

Кыз нечкә, яңгыравык тавыш белән:

– Әнкәй, алайса, мин язуымны алам, – диде дә, егет белән бергә чыгып, тәрәзәгә тыш яктан ябыштырылган кәгазьне ертып ыргытты. Тагын елмаеп: – Сез бүген үк күчәсезме? – дип сорады.

Бу инде бик җиңел сорау иде, егет ватык русчасы белән:

– Әйе, бүген үк, хәзер үк күчәм! – диде. Шулай ашыгып күчәр өчен үз номерына кайтса, анда, түбән баскыч төбендә, ниндидер бер яшь мулла көтеп утыра. Җырчыны күрүгә:

– Нихәл, Сәхип иптәш! – дип, кулын суза.

Егет башта танымады, кулын биргәндә танып, кычкырып җибәрде:

– Сөләйман, синме? Бу ни хәл бу?.. Һич таныр хәл юк! Син мулламыни хәзер? – диде.

Икәүләп номерга керделәр. Бу – Сәхипләрнең, Җиһангирләрнең мәдрәсә көрәшләрендә бер фронтта сугышып барган каһарман кызыл көрәшче шәкерт Сөләйман Сәйфуллин иде. Ул элек Сәхипкә караганда бик күп дәрәҗәдә алда, үткен егет иде. Җырчы иң элек шуңа тотынды.

– Син мулламыни? Ни эшләп алай? Ә? – диде.

Сөләйман Сәйфуллин:

– Хәзер сөйлим, кая бер тәмәке генә яндырыйм, урамда тартсаң, мулла кешегә килешми кебек, авылда да шунардан җөдәп бетәм, – дип сөйләнә-сөйләнә, кесәсеннән папирос алып кабызды да бер тамчы төтен дә чыгармыйча, йотлыгып тарта башлады.

Сәхип саранланырга сүз бирсә дә, бу юлга инде күптән күрмәгән иптәш өчен кызганмады, кайнар самовар китертте, дүртәр пәрәмәч кушты.

Элек алар бер мәдрәсәдә генә түгел, бер сыйныфта, бер төркемдә булдылар. Яшьлек дулкынында бергә йөзделәр. Шуңа күрә сүз бик килеште.

Ул чакта Сәйфуллинның төсе бөтенләй башка иде. Җитү чәч шома таралып артка җибәрелгән була. Өстендә тужурка, аягында, иске булса да, ботинка, бөтен торышында, кузгалышында ут чәчри, бер нәрсәне җимерергә баргандай омтыла. Йөзе үткен, күз карашы кискен, сөйләсә, авызыннан ялкын оча торган иде. Шәкерт революциясе көннәрендә ул Җиһангирдән кала беренче бара иде. Җитмәсә, социалист та иде. Хәзер ничектер күзләр

сүнек карый. Йөздә элекке үткенлек юк. Чәч кырылган. Сакал үсә башлаган. Мыек ирен өстендә кыскартылган. Өстендә җөббә, аягында читек-кәвеш! Шулай да рәттән берничә тәмәке тарткач, беренче уңайсызланулар үткәч, Сәхип бу кунак мулла эчендә элекке дусты, үткен кылыч Сөләйманны таный башлады.

Алар сүзгә чумдылар. Сөләйман үткенләнеп китә:

– Ничек болай булдың дисең, Сәхип? Шулай икән шул. Бер баткач, батасың да батасың икән ул. Үзең сизми дә каласың икән!

Ул арада арзанлы номерның начар, кечкенә, пычраграк самовары гөжләп килеп утырды. Сәхип пәрәмәчләрне кунак иптәшенең алдынарак этәреп, ашарга кыстады. Сөләйман тагы бер тәмәке тартты, ике пәрәмәчне ашап, бер стакан чәйне эчте дә тагы тәмәкегә тотынды.

– Туя алмыйм, валлаһи!.. Авылда мулла булгач рәхәтләнеп тартып булмый, дип сөйләнә-сөйләнә, түгәрәк боҗра төтеннәр чыгарып уйнап, тагы үзенең язмышына кайтты: – Син беләсең: мин бит мулла булуга каршы идем. Мин дә шулай сезнең кебек хыялланып йөрдем: имеш, русча укыйм, учитель булам, аннан аттестатка әзерләнәм, аннан, имеш, университетка. Ә үземнең бер тиен акча юк. Атай белән өзелгәнбез. Ул мине каргап хат яза: «Минем сүземне алмадың, остазларыңа каршы киттең. Инде син минем балам түгел. Ачыкмагаең, кадалып кит, муеның астыңа килсен», – дип сүгенә... Аның сүзенә карамыйсың, һаман калада русча уку хыялы белән йөрисең. Ачлыктан яңагың эчкә керә, актык әйберләреңне сатып ашыйсың. Бурычка батасың... Билеңдәге актык каеш зинарыңны[1] кибетче марҗага ике кадак арыш икмәге өчен закладка саласың. Ул ике кадак та бетә. Инде ни эшләргә? Тукта, дисең, болай торып булмас, берәр җирдә мөгаллим булырга кирәк, дисең: көненә өч-дүрт сәгать кенә укытырмын. Калган вакытымда студент яллап, үзем хәзерләнермен, дисең. Имеш, берьюлы ике көймәнең койрыгын тотмак буласың...

Сөләйман, сүзен бүлеп, тагы тәмәке яндырды, тагы төтен боҗралары ясый-ясый сүзгә кереште:

– Мөгаллим булу фикере менә шулай, вакытлы бер эш рәвешендә туа... Сиңа шәһәрдә кирәк. Ләкин ул табылмый. Шулай да планыңны үзгәртмәскә тырышасың. Ачсың, бүлмәңнән куалар, кара күлмәктән зинарсыз йөрисең. Интеккәнсең, инде башка чара калмый, ярый, дисең: бер кыш авылда укытсаң да зыян юк. Тик ятмам, үземнән хәзерләнермен, анда тормыш арзан. Алдагы кышка укырлык акча арттырырмын дип җуанасың да барасың берәр авылга!.. Халык караңгы, мәктәп җимерек. Парта юк. Кара такта юк. Мулла

---

[1] *Зинарыңны* - билбавыңны

беренче сүзендә үк синең житкән чәчеңә карый. «Инде, ди, мин үзем, ягъни мәсәлән, алай каршы түгел, әмма без, ди, халык җаенарак карыйк, юкса сүз үткәреп булмый, башта ук бик өрекмәсеннәр, акрынлап бары да керер», – ди. Ярый, дисең, эчеңнән сүгенә-сүгенә, кара озын чәчеңне кырдырасың. Кәләпүш киясең. Билеңдәге каешыңны кәрзиннең төбенә үк яшереп куясың... Син Алласын, динен онытып килгәнсең, монда исеңә төшерәләр. Һәр көн мәчеткә биш вакыт намазга йөри алмасаң да, җомгалардан калу бер дә килешми инде. Барасың... Менә шулай бата башлыйсың...

Һәммәсе диярлек үз башыннан да кичкән бу хәлләрне Сәхип күңелләнеп тыңлады. «Син сүз белән бернәрсә дә ашамыйсың», – дип, кунак дусы алдына калган ике пәрәмәчне этәрде. Сөләйман, пәрәмәчтән бигрәк тәмәкене тәмле суыра-суыра, үз язмышына әрнеп чумды.

– Башына кадалсын, җомгага барганнан аягың сынмас. Син көненә өч-дүрт сәгать уйлагансың. Ә анда рәхим ит, ун сәгатькә барып баса. Чараң юк, яллангансың – өстерә. Ташлап китәр идең, акчаң юк, җитмәсә, алдан бурычка алгансың. Китсәң дә бит, башка һөнәрең булмагач, барыбер шундый бер урынга барып ялланырга туры киләчәк. Түзәсең, иркәләнеп үскән баерак мужик малайлары белән каның бозыла. Шулай да кышны чыгасың... Инде яз. Язгы кояш белән имтиханнар башлыйсың... Аларны бетерәсең дә тизрәк качасың... Карасаң, кесәңдә башы-аягы барлыгы йөз сумлап акчаң бар. Бу нәрсә? Бу бит җәй буе ашап киенергә дә җитми. Үзең арып, ябыгып, хәлдән тайгансың. Бераз ял итәргә, тазарырга да кирәк иде. Өс-баш ясыйсың. Берәр тибәсең, – карасаң, кесә ягы сап-сай калган... Атаң белән килешер-килешмәс авылга кайтып егыласың... Ярты-йорты белгән гарәпчәң, төрекчәң яисә русчаң бар. Шуның белән берәр китап тәрҗемә кылып маташасың... Шигырьләр язып карыйсың... Үз башыңнан үткән авыр хәлләрнең берәрсен хикәя итеп әвәләп аласың. Бер дә гаҗәп чыгалар... Синең «Башкорт кызы Гөлбикә»ң бар икән бит, аны мактыйлар... Шулай җенләнәсең. Сәхип язганны мин ник язмаска, дисең. Менә сиңа бер атуда ике куян: акча да, шөһрәт тә! Икесе берьюлы ташып килә. Җәйнең матур төннәрендә авылда ялгызың хыялланасың. Менә, дисең, Казанга барырмын да бу әсәрләрне сатармын. Акча булыр. Шуның белән укырга тотынырмын! Ул арада тагы берәр тәрҗемәме-нәрсә өлгерер, тагы акча килер, дисең. Шундый хыяллар белән актык бер тиеннәреңне тотып Казанга киләсең. Әнә нинди әйбәт китап магазиннары! Әнә нинди яхшы бай наширләр! Каушап, өмит-катнаш курку белән нашир әфәндегә барып, әсәреңне бирәсең. Ләкин гаҗәбе шунда: ул илтифатсыз, бераз караңгы йөз белән синең язмаларыңны алып кала, сукранып кына: «Бер атнадан килерсез», – ди. Их, нигә болай озак?! Ничек атна буена түзәрсең, аннан да бигрәк, нәрсә ашарсың?! Хыял, өмит белән

аптыраш бергә кайный. Ничек басарлар? Күпме гонорар бирерләр икән?.. Инде ул акчаны бик саклап тотарга кирәк. Бер кыш укырга җитсен!.. Шулай атна үтә. Өмит белән ут эчендә нашир әфәнденең китап магазинына барасың!.. Әйтерсең, тәнеңә салкын су койдылар: нашир әфәнденең укырга вакыты булмаган: «Бик ашыкса, кире алып китсен!» – дигән. Тагы атна-ун көн нәширнең магазинын, конторын таптыйсын. Ансыз да тузып барган ботинка табаннарыңны әллә ничаклы шомартканнан соң, мә сиңа, рәхим ит: «Әсәрегезне зарарсыз таптык. Ләкин басарга алган нәрсәләребез бик күп булганга, сезнекен ала алмыйбыз!» – ди. Үзе сиңа күтәрелеп тә карамый. Әйтерсең, син аны таларга килгән дошман инде. Әгәр ачулы вакыты булса: «Яратмадык, алмыйбыз! Кирәкми!» – дип өзеп үк сала... Фу, җүнсезләр! Ничек мөмкин шундый нәрсәне яратмаска! Янып, тирләп, сукранып, кулъязмаңны аласың да икенче нәширгә илтеп бирәсең. Анда да шул ук хәл. Ә син инде, һавадагы торнага ышанып, кесәңдәге актык тиеннәреңне бетергәнсең, гонорар алгач түләргә исәпләп, бурычка да баткансың. Инде ни эшләргә? Башыңны ташка орасыңмы? Башкача чара юк, тагы гәзит редакциясенә кереп, җитмеш тиенгә өч басарга игълан бирәсең дә мөгаллимлеккә урын көтәсең. Шәһәрдәге мәктәпләр тулы. Син – тагын караңгы бер авылга! Ләкин һаман бирешергә чамаң юк. Бу ел әрәм булды, алдагысына, җәйдән үк эзләп, калада урын табармын, укытырмын да, укырмын да дип җуанасың! Һәм табасың. Ләкин ни файда? Айга утыз сум. Каторга хезмәте. Акчаң ашарга бетә. Җәй айларына түләмиләр. Яз кояшы белән имтихан ясап, балаларны таратасың да, үзең, кых-кых җүтәлләп, тагы авылга китәсең. Ярый әле, атаң бар. Хәлдән тайганда, аңа кайтып баш куясың... Еллар менә шулай үтә. Яшең утызга якынлый. Күз төпләреңдә җыерчыклар әйләнә. Йөрәгеңдә бу бетмәс-төкәнмәс өстерәлүдән арыганлык сизә башлыйсың. Ялгызлыктан да туйган кебек тоеласың. Синдә яңа бер тойгы уяна: даими бер оя, туры бер гомер юлдашы кирәксенәсең!.. Менә матур кыз да бар. Яңа фикерле. Әдәбият сөючән. Кечкенә калфак кия, атасы күрмәгәндә мандолина уйнап та җибәрә белә. Бераз гына укытсаң, шиксез яхшы мөгаллимә булачак. Гыйшык, мәхәббәт. Ул риза. Өйләнсәң, бер башың ике була. Ул арада өченчесе дә килеп чыга. Хатының, бала-чагаң белән болай авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә ел саен өстерәлеп йөрү бер дә килешми инде. Хатын сукрана башлый: «Син нәрсә, мине чегән марҗасы кебек дөнья буенча үз артыңнан йөртергә алдыңмыни? Буйдак кешегә ярый да ул! Алай булгач, өйләнмәскә кирәк иде», – ди. Кайнатайлар да читләп сүз күтәрәләр: «Бик әйбәт урыннарга сорыйлар. Кияү нигә мулла булмый икән?! Гомер буенча болай чегән кебек йөрергә ярамый ич!» – диләр икән. Юк, юк, булмас, дим. Ләкин җиңеләм! Башка ни чара? Әллә кайчан шүрлеккә ташланган, инде

тузан астында калып беткән «Мохтасар» белән «Фәраиз»ны, «һидая»ләрне[111*] яңадан тартып чыгарасың, бер мәртәбә күз йөртәсең дә Уфага китәсең, анда казыйларга садака биргәләп, мөфтинең фатихасын аласың: имеш, имтихан тотасың... Атаң белән кайнатаң ул арада сиңа әллә кайчан тозакны корып куйган – ришвәтләр бирә-бирә тамга җыйган була. Сине указлы, мәхәлләле ясыйлар... Менә, Сәхип иптәш, шулай акрынлап килеп батасың ул... Менә син үзең сизмисең, менә шулай искә төшергәндә генә...

Номерның ишегенә кактылар. Сәхип: «Керегез, кем бар?» – дип кычкырырга өлгермәде, яшүсмер, нечкә буйлы, ябык, озынча ике кыз бала килеп керде. Берсе Габдулла абзый кызы Маһирә иде, икенчесе ябык, озынча, ләкин бик сөйкемле йөзле, кыска күлмәкле, унике-унөч тирәсендә булыр, чибәр бала. Сәхип бу кыздан күзен ала алмады, ләкин әйтмичә таныды:

– Бу кыз кем? Булатка гаҗәп ошаган ич! – диде.

Маһирә елмайды:

– Нигә ошамасын, сеңлесе ич! – дип, – аның исеме Фәүзия, – дип әйтте дә ашыгыч-ашыгыч үз йомышын сөйләргә кереште: – Сәхип абый, – диде, – безне сиңа әнкәй җибәрде. Әнкәй әйтте, бик кирәкле хат яздырасым бар. Бүген кич безгә килә күрсен лә, диде. Барырсың бит, Сәхип абый?

Егет:

– Барырмын, бик барырмын. Менә яңа бүлмәгә әйберләремне генә күчерермен дә барырмын... Шулай дип әйт, ярыймы? – диде.

Кызлар:

– Ярый-ярый, – диешеп, чыга башладылар.

Сәхип туктатты:

– Юк, юк, җибәрмим. Сезгә барган саен мин сыйланам... Менә чәй эчегез, хәзер алма алдырам, – дип көчләде. Көчләшә-көчләшә әйтте: – Маһирә, син нигә әнкәңнең хатларын үзең язмыйсың? Беләсең ич!

Маһирә көлде:

– Ник белми ди, беләм. Тик әнкәй яратмый. Синеке кып-кыска чыга, ике сүз белән бетерәсең дә куясың, ди. Менә Сәхип абыең уратып-уратып, матурлап, сәламнәр яза белә, ди. Миннән яздырмый!..

Булат сеңлесе якты күзле, ябык, озынча кыз Фәүзия үзенең дусы Маһирәнең бөеренә төртте, әйдә китик, минем әнкәй нигә озак йөрисең, дип, ачулана башлар дигәндәй карады. Сәхип бик кыстаса да, кызлар якын килмәделәр.

– Барасың бит? – диешеп, пырхылдап көлешеп, чыгып качтылар.

Сәхип үзенең кунак иптәшен, яңа квартирга чакырып, озатты да, тиз-тиз җыенып, яңа бүлмәгә күчте. Берничә еллар буенча бөтен дөньясын ташлап, университетка керер өчен аттестатка хәзерләнеп яткан Җиһангир

күрсәтүе буенча биш сумга студент тапты да укырга чумды.

## LXXXIII
## ЯШӘРГӘ МӨМКИНМЕ!

«Башымны кая куярга белмичә, сиңа килгән идем. Каты йоклап ятасың, уятмадым. Кичәге эчүләр, карталар ваткандыр, әйдә йокласын, дидем. Өстәлеңдә Нәҗип Камалның озын хаты ачык тора иде. Икегез дә үз кешеләрем ич. Ачуланмассың, укыдым... Ул нигә алай җылый? Реакция аның ишеләрне дә буа башлаганмыни? Нәрсә ди, күрәмсең? «Иман юк, идеал юк. Якты киләчәккә өмит юк. Мин ни белән яшим? Бер мин түгел, революция яшенле, утлы якты көн иде. Ул үтте. Бу хәзерге реакциянең кара төне эчендә мин юлымнан яздым. Идеалымны югалттым. Йөрәгемдә өмит ялкыны сүнде... Бер миндә түгел, бөтен тирә-ягымда шул кичә милләтче булып янган зыялы – бүген корсак колы. Кичәге социалист – бүген буржуага тәрилкә тота. Кичә арыслан булып айга сикергән яшь, ялкынлы шәкерт – бүген мөгаллим, иртәгә мулла булып, мәхәлләнең кара җырларын җырлый башлый... Син менә бервакыт Шлиссельбургта егерме биш ел тоткын газабы эчендә богауланып ятканнан соң да үз иманын югалтмаган каһарман көрәшчеләрне сөйләгән идең. Бу хатны язганда тагы хәтерләдем: яшь, ялкынлы йөрәк көрәшкә ташлана. Дошман көчле. Аны ябалар. Сөрәләр. Гомернең күбе богаулар эчендә үтә. Чәч агара, бил бөкрәя. Ләкин ул һаман үзенең көрәшендә бара, мин үләрмен, ләкин безнең түккән каннар әрәм китмәс, безнең чиккән газаплар, түккән каннар дулкыны дошманның таш крепостьларын җимерерләр, дөньяга азатлык тудырырлар дип ышана. Ләкин без нигә шулай була алмадык, нигә болай тиз безнең канатлар сынды, нигә болай тиз йөрәк сүнде? Революция яңадан киләме? Әллә без шул реакция газаплары эчендә канаты сынган кошлар кебек өстерәләбезме?» Мин, Давыт, Нәҗипнең ул хатын укыгач, үзем шашындым. Ул гаҗәп бер сүзләр табып әйтә белгән. Аңлата белгән. Әйт, Давыт, син ышанасыңмы? Берәр нәрсәгә ышанасыңмы? Ышанмаган кешегә яшәргә мөмкинме? Бу газапларның чиге кайда?..»

Үзе кичәге аракылы, карталы, төтенле мәҗлестән соң үлек кебек ватылып йоклаган чакта, Урмановның бүлмәсенә Баязид карый кергән дә шул саташулы нәрсәне өстәлдә яткан кәгазьгә язып чыгып киткән. Ләкин Давыт моның өстендә күп уйлап тора алмады; көзгегә караса, йөз ватылган, чәч тузган. Авызда тәм юк. Баш үтереп авырта. Төзәтергә кирәк. Ичмаса, калган нәрсәсе юкмы? Юк. Бернәрсә дә юк. Малайны чакыртты да баш төзәтергә китерергә кушты. Үзе умывальниктагы салкын су белән битен, башын, муенын, күкрәкләрен юарга тотынды.

Коридор башында ике кеше күренде. Берсе – ябык, озын, зәһәрләнеп кипкән Баязид. Икенчесе Хәбип икән. Шулар белән бергә малай баш төзәтергә китереп җиткерде.

Давыт, малай артыннан бүлмәне бикләүгә, Мансуровка бәйләнде:

– Бу ни эш? Теләсәң кайда эчеп йөрисең? Синең конспирацияң кайда?

Хәбип сызгырып, кул селекте:

– Юкка кайгырма, әйдә, эчәргә әзерлә! Кабарга кыярың юкмы? – диде.

Урманов туктамады, өстәлгә аракыны, икмәк, суганны куя-куя, чынаяк чокырларына сала-сала, әйтте:

– Син мәңге тискәре адәм инде. Шулай да мин һаман да сиңа сак булырга киңәш итәм...

Качкын иптәшчә чәнчеп көлде:

– Әйдә, лыгырдама. Киңәшеңне кесәңә тык та эчәргә утыр! – диде.

Акрынлап, озаклап, ишек бикләп эчә башладылар. Алганы бетте. Аның артыннан тагын килде, тагын өстәлде.

Байтак кызган Качкын Хәбип, гадәтенчә, үзенең бунт, талау хыялларына кереп китте. Мансуров үзе эчә, үзе шулай хыяллана.

Ләкин Урманов ачыла алмады. Шулай дәртләнеп, Качкынның бунт хыялларына кушылмады. Аңарда күптән инде моңарчы тоткан юллары турында уйлану бара иде. Хәбипнең бу хыяллары аңа шул үткән юлның хата калдыклары кебек күренделәр. Ул үз эченнән: «Хәбип, безгә бу бунтарь народник юлы турында яңадан уйлап карарга вакыт түгелме? Байтак тәҗрибәләр булды ич!» – дияргә теләде. Ләкин тәне ватылган, башы томанлы иде. Талаш кузгатмады, шулай калдырды. Баязид, әйтерсең, бу мәҗлестә бөтенләй юк. Шулай югалып утыра. Качкын Хәбип бу арада Баязидта кунгалаган иде. Ярым кызганып, ярым кызык итеп аның турында сөйләргә тотынды:

– Давыт, – ди, – синең Баязидыңның бер гадәте бар икән: кичтән сәгатьләр буенча бүлмәнең бер башыннан икенче башына йөри-йөри дә икән, хәлдән тайгач, караватына ава икән. Иртә белән бик иртә уяна да киенми, караватына утыра. Менә шунда, әле яңа сызылып килгән таң караңгылыгы эчендә, ул ялгызы акрын гына нидер көйли, нәрсәдер җырлый башлый. Кайгы белән, көенеч белән, озын сузып, авыр моңланып җырлый башлый... Нәрсә әйтим, мин башта шаяртып карадым, нигә син болай, анасын югалткан бозау кебек, таң иртә ялгыз мөңрисең, дим. Дәшми. Һәр таң иртә шулай, авыр моң белән озын көйгә салып, ялгызы озак җырлый да җырлый. Башта эчем пошты. Аннан йөрәгемне өзеп ала торган булды. Берничә көннән үзем дә аңар иярә торган булдым... Шулай таңнан уянабыз, карават читенә утырабыз да, ике ятим кебек, озын-озын көйне кайгы-хәсрәт белән әкрен генә, әкрен

генә суза башлыйбыз... Бу ни бу, Давыт?

Урманов моның сәбәбен ачык белми. Әмма ул Баязидның йөрәген әрнеткән ниндидер бер тирән яра барын сизә иде. Читләп тарткалады, ләкин егет сер бирмәде, туп-туры сорарга теле бармады. Менә әле дә ул иптәшләрдән калмый эчә. Әмма аракы аның күңелен күтәрми. Давытның зинданнан чыкканына күпме үтте инде, шуннан бирле ул Баязидның элеккечә яңгыратып көлгәнен ишетмәде. Җүнләп, иркенләп сөйләшми дә. Элгәре, эчкәч, кәефләнә, котыра иде. Әмма хәзер ул да юк. Йөзе, әйтерсең, нервы утында көйгән. Күзләрендә нидер бар: бер кайгымы, бер нәрсәсен югалтумы, теләп тә таба алмаумы, тирән әрнүме, сызланумы – белмим, нидер бар, аның күз карашлары шундый бер газапны сөйлиләр. Авызының ике читендә дә зәһәрле сызык. Ул электән дә аз, ләкин кискен сүзле иде. Хәзер бер мәсьәлә турында кызып китсә, берничә сүз белән үзен дә, дөньясын да сүгеп ташлый. Хәбип бүген аңа үзенең бунтарьлык хыялларын тәмләп кабатлый башлагач, Баязид аны зәһәрле сүз белән кырт кисте:

– Әй, ташлачы юкны! Төкер бөтен дөньясына! Барыбер бернәрсә дә чыкмый. Чәнчелсен, чукынып, муены астына килсен! – дип, өмитсез рәвештә кул селекте дә, актык стакан тулы аракысын берьюлы эчеп, исәнләшми-нитми чыгып китте.

Монда эчә калдылар. Эчү, карта компанияләренең җаны Сәлимов, кереп, ашыгыч-ашыгыч эчәргә тотынды. Аннан элекке купшы кызыл приказчик, хәзер үзе кибетле, яшь сәүдәгәр Фәхри ишек какты. Аның муены тулы. Йөзе кызарып, симереп килә. Сәлимов аның корсагына шаярып төртте:

– Син, Фәхри, өч приказчик яллагансың имеш, каннарын эчәсең имеш, диләр. Дөрес булса кирәк, монда түгәрәкләнә башлаган синең. Туры кәсептән алай кеше корсак үстерә алмый ул! – дип, уен-көлке кузгата башлады.

Фәхри:

– Бардыр инде, малай, дөньясы шул бит, – дигәләбрәк торганда, икенче рюмка аракыга сузылган Сәлимов кесәсеннән егерме бергә карта чыгара башлаган иде, ишек кактылар. Сәлимов русча:

– Керегез! – ди. Тагып кагалар, Сәлимов ачулы, бераз сүгенүле тавыш белән: – Керегез диләр ич сезгә, ни торасыз анда! – дип кычкыра.

Ишек ачыла. Урта буйлы, ярым европача, ярым татарча киенгән, кечкенә калфак өстеннән кара шәл ябынган, йөзе кара пәрдә белән капланган бер хатын килеп керә. Сәлимов мыскыллы тавыш белән һаман русча:

– Сезгә кем кирәк? Сез ялгыш кергәнсездер монда, – ди.

Хатын сак, эчке акрын тавыш белән:

– Миңа Давыт Урманов иптәш кирәк иде, ул монда тора бугай бит? – диде.

Урманов кинәт йокыдан уянгандай булды. Үзе дә сизмәстән, чишелгән изүен каплый, чәчен, билендәге кәмәрен төзәтә дә, сикереп торып, ишеккә бара. Сүзсез-нисез хатынның култыгыннан алып, ишектән кире чыгара. Үзе бер секундта айнып җитә. Коридор буенча бара-бара:

– Бүлмә кичәдән бирле җыелмаган... Иптәшләр исерек... Сине кертергә дә кыенсынам, – дип, хатынга гозер итә башлый.

Бу хатын – Урмановның әллә кайчангы мәхәббәте Нәфисә иде. Ул кире алып чыгуның сәбәбе бардыр, йә анда хатыннар утырадыр, йә мин тыңларга ярамый торган яшерен сәяси сүзләр бардыр дип уйлаган, вакытсыз килүенә борчылган иде. Урманов әйткән сәбәп аның өчен кечкенә нәрсә булып чыкты. Шелтә белән кире борыла башлады:

– Шул гынамы? Бу нинди яңа сүз тагын? Әллә мин сиңа чит кешеме? Иптәшләргә утырырга яраган бүлмә миңа ник ярамый? – диде.

Давыт гаҗәпсенеп тыңлады. Бу – кем? Шул юаш, йомшак, оялчан, кыюсыз Нәфисәгә мондый куәт кайдан килгән?

– Алайса, әйдә! – ди дә хатынны төтен белән аракы, суган исе белән тулган бүлмәгә алып керә. Иптәшләр белән таныштыра.

Сәлимов бетен гомере буенча хатыннар сүгүче, хатыннарны вак, түбән мещан сазыннан чыга алмый дип хурлаучы кешеләрдән иде. Компанияләрдә алардан кызык тапмый иде. Нәфисә килеп керүгә: «Мәҗлеснең яме китте», – дип уйлады.

Шулай да шешәдәге аракыны ашыкмый-нитми стаканнарга салып бетерде. Кабарга икмәкләр, суганнар әзерләде дә, колагына якынрак килеп, Качкынга әйтте:

– Әйдә китәбез, монда хәзер сантиментализм башланыр, – диде.

Ашыкмый-нитми актык тамчыгача эчеп бетерәләр дә өчәүләп чыгып китәләр.

Нәфисә электән Хәбипне таный иде. Аңа үзенчә байтак җылы сүзләр әйтте, миннән качасыз дип елмаеп, шелтәләп калды.

Ләкин үзе аларның китүенә күңеленнән шатланды. Ул зинданнан чыкканнан бирле Урмановны күргәне, ире Габдрахманнан аерылганнан бирле туйганчы сөйләшкәне юк иде. Хәбипләр артыннан ишекне бикләде дә, үзе килеп, Урмановның алдына утырды:

– Их, белсәң, бик сагындым! – дип, йөзе белән егетнең күкрәгенә капланды.

## LXXXIV
## ҺИЧКЕМНЕ ГАЕПЛӘМӘГЕЗ!

Бүлмә эштән чыккан иде.

Нәфисә иң элек Урмановның зинданнарын сорашты, үзе сөйләде. Ире Габдрахманнан ничек аерылганын тасвир итте. Аннан соң үзенең энҗеләрен, алкаларын, беләзекләрен сата-сата укырга керешүенә озак тукталды. Ахры килеп, үткән ел яз учительницалыкка имтихан тотуын әйтте. Ләкин тышкы фактлар үзләре генә бармадылар, хатын һәммә турыда үзенең мәхәббәтен китереп тыкты. «Ул вакыт син бездә кундың – сөрген, зиндан турында сөйләдең. Мин шунда үземә сүз биргән идем, шунда күңелемә бер ышану туган иде – мең газап күрдем, ләкин барып ирештем», – дип шатланып, канатланып, сүзен бетерде. Бу беренче сүзләр бетүгә, як-ягына каранды:

– Их бүлмәң! – диде дә, коридорга чыгып, щетка алды. Бөтен чүп-чарны себереп чыгарды, малайны чакырып, өстәлдәге аракы, икмәк, суган калдыкларын алдырды, форточканы ачып, һаваны тазартты да Урмановның ширмасы эченә керде – анда караватъ. Ләкин һәммә нәрсә тәртипсез, урынсыз иде. Комодтан алып, мендәрләрнең тышларын алмаштырды, яңа җәймә эзләп тапты, одеалны какты, сөлгесенә чаклы икенчене чыгарып, барлык керлеләрне иске чемоданга тыкты да одеколон эзләргә тотынды. Ләкин тапмады. Үзенең ридикюлендә ислемае бар икән. Стакан суга тамызып, караватъ өстенә беректе дә, яңадан Давытның тезенә утырып, йөзен күкрәгенә каплады. Бу – аның яраткан утырышы иде. Шул хәлдә озак, тәмле сүзләргә керербез, үземнең сагынуларымны сөйләрмен дип уйлады. «Бүген кич синдә куначакмын», – дип, үзе әйтергә, үзе башларга исәпләп куйды... Ләкин тынычлык бирмәделәр. Малай килеп, Давыттан номер өчен акча дип бимазалады. Аны озатып, инде мәшәкатьләмәсләр дигәндә, тагын кемдер ашыгыч, каты басып килде дә каты, ашыгыч тавыш белән:

– Урманов! Тиз чык әле! – диде.

Давыт ишеккә ташланды. Анда Тангатаров иде. Ашыгыч пыш-пыш нидер әйтте дә:

– Әйдә, тиз! – дип, коридор буенча югалды.

Урманов гадәттән тыш кабаланып, каракүл якалы пальтосы белән фуражкасын киде, аңа агарып бәйләнгән Нәфисәгә:

– Син барма... Өйдә кал!.. – гына диде дә чыгып йөгерде.

Ул барып кергәндә номерның коридоры халык белән тулган иде инде. Ләкин полицейскийны көтәләр икән, әле алмаганнар иде. Урманов, тупланган халыкны җырып барып, бусаганы атлау белән күз алдындагы күренештән шаша калды: түшәмгә лампа тагар өчен ясалган тимер ыргакка бармак калынлыгы җеп эленгән. Шуның түбән башы, бик ипләп, уңайланып, муенчак ясалган. Ул нык сакланып муенга кигәч, басып торган урындык аяк белән читкә тибәреп җибәрелгән – шуның белән буылып, үлем килгән. Ахры, байтактан асылган булгандыр, Давытлар килгәндә кул-аягы каткан, тәне

суынган, йөзе күгәреп, каралып көйгән; күзләре әллә нинди куркыныч караш белән катып, ачылып, тышка атылганнар. Авыз, иреннәр эштән чыгып бозылган, тел, – бер чирек булыр, – каралып, салынып тора.

Бу трагедия хәбәре тиз таралды, ишеткәннәр агылып килделәр. Иптәшләр арасында Баязидның соңгы заманда гадәттән тыш өмитсезлеккә, пессимизмга чумуы билгеле иде. Шундый бер хәл булмасын дигән куркыну юк түгел иде. Урманов та, башкалар да бу фаҗигале үлемне күрүгә: «Аһ, мин мондый бер хәлне сизенгән идем», – дип эчләреннән уйладылар. Ләкин сүз белән берсе дә моны әйтмәде. Ул арада номер хуҗасы килеп, коты очкан тавыш белән:

– Бу ни эш бу, Ходаем?! Сез миңа китереп кеше үтергәнсез! Башым Себер китте ич! – дип акырып җибәрде.

Аның сүзе бетмәде, полицейский, аннан доктор килеп керде. Шунда ук рәсми протокол яздылар. Баязид белән бер бүлмәдә Тангатаров торган икән. Полицейский иң элек аңардан җавап алды. Ул болай диде:

– Баязид Сафаров соңгы көннәрдә бик тирән борчуда йөрде. Аз сөйләште. Дөньяны, тормышны, кешеләрне сүкте. Ниндидер бер авыр кара өмитсезлек аның йөрәген каплаган кебек иде. Бүген ул Давыт Урманов белән Хәбип Мансуровлар мәҗлесеннән кайтканда, мин чыгып китәргә дип киенгән идем. «Әйдә, йөреп керик», – дидем. Кул селекте. Чыгып китүгә, мин үз артымнан бүлмәнең эчтән бикләнгәнен ишеттем. Күңелемә шик килде. Урамда да тынычлана алмадым, бер сәгать чамасы үткәч, эшемне ташлап, кире кайттым. Шакылдатам – җавап юк. Тагы шакылдатам – һаман ачмыйлар. Тагы катырак шакылдатам – һаман да ачмыйлар. Әллә берәр җиргә киттеме икән дип, шырпы яндырып карыйм, ачкыч эчтән күренә; димәк, ул бүлмәдә. Мин инде чыннан курка башладым: «Баязид, нигә ачмыйсың?!» – дип кычкырам. Җавап бирми. Аптырап, хуҗаны, официантны чакырам, алар ачкыч яратырга маташалар, булдыра алмыйлар. Ахыр, без слесарь чакырттык та бикне ваттырып кердек. Керсәк, менә шул хәлдә Баязид Сафаровны асылып үлгән таптык...

Полицейский, тагы номер хуҗасыннан, официанттан, слесарьдан җаваплар алып, протоколга теркәде дә мәрхүмнең калдырган кечкенә кәгазьгә язган актык сүзләрен тәрҗемә итәргә кушты. Анда болай язылган иде:

«Минем үлүемдә һичкемне гаепләмәгез, иптәшләр. Туйдым, дөньядан, тормышның газабыннан, мәгънәсезлегеннән туйдым. Давыт, синнән аерым бер үтенечем: әнкәй белән сеңлем Сәҗидәне юатырга тырыш! Хуш!

Баязид».

Шуның белән полиция үзенең эшен бетереп китте. Баязидны ярыр өчен

больницага озаттылар.

Асылганының дүртенче көнендә барлык рәсми яклар үтәлеп, күмәргә мөмкинлек булды. Каланың муллалары бу фаҗиганы ишетү белән үзара сүз беркеткәннәр, дип сөйләделәр. Гүя әйткән булалар: «Шәригатьтә катле нәфес[1] хәрам. Катиле нәфес[2] әлгаязе биллаһи, мөртәд китәр, дигән китаплар. Бәс, Баязид карыйга җеназа укымак җаиз дәгел[3]!» – диешеп, дини бойкот ясаганнар.

Ләкин моның гамәли мәгънәсе булмады. Иптәшләрдән һичберсе мулла-мөәзин чакырып, тәһлил ясатып, җеназа укытып йөрү кебек эшләрне исәпләмәде. Бөтенләй дини гадәтләрдән башка күмделәр. Кеше аз иде. Иң якын дуслар больницадан каберстанга чаклы алмашмый күтәреп бардылар. Кабере өстендә тик Давыт Урманов белән Хәбип Мансуров берничә сүз әйттеләр. Тангатаров, күмеп, тарала башлагач:

– Баязидның үлүенә җиде тәүлек тулганда, дүшәмбе көн кич, минем бүлмәмдә мәрхүм иптәшне хәтергә алу мәҗлесе булачак. Һичкемне атап чакырмыйм. Баязидны якын күргән дуслары рәхим итсеннәр! – диде.

Яңгырлы, болытлы караңгы көн иде. Иптәшләр кабер өстеннән авыр, салмак атлап, сүзсез-нисез һәрберсе үзалдына борчулы уй белән өйләренә таралдылар.

## LXXXV
## РАЗИЯ ХАНЫМ КИЛГӘН

Давыт Урманов авыр, басынкы, борчулы уйлар белән номерына кайтып, яңагына таянып утырган гына иде, керле алъяпкычлы малай кереп:

– Давыт абый, анда сине бер хатын чакыра! – диде. Урманов башын күтәрмәде:

– Ул кем тагы? Үзе нигә керми?

– Нигә кермидер, белмим. Ул атта, кучеры да бар. Үзе бик шәп киенгән. Бай, матур нәрсә... Тиз чык! Бер генә минутка, ди!

Шулай такылдады да, малай үз эшенә йөгерде. Урманов, үзен чак күтәреп кузгалды, малайның ни әйткәнен онытып, катып торды. «Ә, алай бит!» – дип, тагы хәтерләде дә, салмак, басынкы адым белән коридорны, баскычны кичеп, урамга чыкты.

Яхшы пар кара ат. Кара-күгелҗем чикмән кигән калын кучер. Яңа, бай, чибәр дышлода[4], кыйммәтле мех якаларга төренә төшеп, яшь ханым утырган.

---

[1] *Катле нәфес* – үз-үзеңне үтерү.
[2] *Катиле нәфес* – үз-үзен үтерүче.
[3] *Җаиз дәгел* – дөрес түгел.
[4] *Дышло* – Бер тәртәле арба.

Давыт башта танымады, таныгач, кире чигенеп китәргә теләде. Ләкин килештермәде:

– Разия туташ, сезгә миннән ни кирәк?! – диде.

Туташ озын, зифа буе белән алга таба омтылды, киң читле эшләпәсенә беркетелгән вуальне бер якка таба ачып җибәрде дә, дусча елмаеп, Урмановка йомшак, нечкә, кызу кулын сузды; җибәрмичә озак тотты, елмаюын яшереп, күз яшьле тавыш белән русча әйтте:

– Давыт иптәш, мин Баязид трагедиясен ишеткәч килдем. Сезнең партия белән минем ара өзелгәнгә еллар үтте. Минем элекке эсер иптәшләрем мине һәртөрле гөнаһларда гаепләп беттеләр. Шуңа күрә мин мәрхүм, иптәшнең бүлмәсенә дә, каберенә дә бара алмадым, әмма мин аны бик ярата идем... Мин читтә кала алмыйм. Ишеттем, кыйммәтле таш куйдырырга уйлыйсыз икән... Кире какмагыз, минем Баязид иптәш алдында үз кулымнан килгәнчә актык бурычымны үтисем килә... Аннан соң сөргендә, зинданда яткан иптәшләрнең хәлләре бик авыр диләр. Сез үзегез тиеш күргәнчә, Гәрәйгә, Качкын Хәбипкә тапшырырсыз... – дип сөйләп, эченә кәгазь акча тулы бер пакет сузды. Давыт бу пакетны алырга каршы кул сузмагач, Разия, әрнү катнаш елмаеп, зур күзләрендә уйнаган нуры белән Урмановка йотылды:

– Беләм, Давыт иптәш, сез мине партиягә, революциягә хыянәтче саныйсыз... Сез мине фабрикант Абыйзовка ике баласы, яшерен марҗасы өстенә, байлык өчен үзен хатынлыкка сатты дип гаеплисез. Их, бер очрашып, барын да сөйләсәм иде, сез мине аңлар идегез... гаепләмәс идегез... – диде.

Давыт Урманов кулын алды, пакетны кире этәрде:

– Хәерчелек җәмгыяте бар ич, шуңа бирегез бу садаканы! Әмма Гәрәйләр, Качкыннар сезнең садакагызны алмаслар!.. Сиңа нәрсә хәзер: сатылгансың, беткәнсең, инде безгә нинди сүзең булырга мөмкин! – дип, кире борылып китте.

Керсә, бүлмәсендә Тангатаров утыра. Давыт аны күрүгә сүгенә башлады:

– Беләсеңме, Әхтәм туган, хәзер кем белән сөйләштем?

– Кем белән?

– Фабрикант Абыйзовның сөяркәсеме, хатынымы хәзер, беләсең, элек безнең партиядә кайнаган Разия Ширинская бар идеме? Шул килгән. Гаҗәп атлар. Менә дигән кучер. Кыйммәтле дышло. Шуның түрендә матур, бай мехларга чумып, графинялар кебек башын арткарак салып утырган... Җылан бит. Коры җылан гына түгел, үз теләгенә ирешер өчен агуларын яшереп, «фирештә» сурәтенә керә торган, сине шулай астыртын чага торган матур җылан! Ни ди бит, җылан: «Мин иптәшләрне оныта алмыйм. Кулдан

килгәнчә ярдәм итим, Баязидка кыйммәтле таш куясыз икән, шуңа да булыр; Гәрәйләр, Качкыннар бик мохтаҗлар икән, тиешенчә белеп, аларга тапшырыгыз», – ди. Миңа пакет белән акча суза...

Әхтәм Тангатар дусты Баязид трагедиясе белән бик артык газаплана иде, җүнләп аңламады, исәп биреп бетерә алмады, аптырап карады:

– Шуннан?

– Шуннан, минем кулымны җибәрми, кысып тоткан. Элекке кебек, үзенең матур күзләрендә ут уйната, иркәләнеп елмая: «Иптәшләр мине бик күп төрле буржуалык гөнаһларында гаепләделәр, минем фабрикант Абыйзовка кияүгә чыгуымны революциягә хыянәт дип карадылар», – ди; их, Давыт иптәш, бу хәлләр турында сезнең белән иркенләп сөйләшсәк, иптәшләр миңа сатлык дип карамаслар, мине аңларлар иде», – ди... Мин чыдамадым, хахылдап көлеп җибәрдем: «Шулай, туташ, Йосыфҗаннар, Акчулпановлар катнаша торган хәерчелек җәмгыяте бар, бу садаканы шунда җибәрсәгез яхшырак булмасмы? Сатылгансыз, беткәнсез. Инде синең безгә тагы нинди сүзең булырга мөмкин», – дидем дә борылып киттем.

Урманов сөйләп торганда, акрын гына ишек ачып Җиһангир килеп керде, ишекне бикләде дә, берсүзсез килеп буш урындыкка утырды. Үзенең күзе шашып каткан. Йөзе таш кебек. Иреннәре ап-ак. Әйтерсең, теле әйләнми, шулай газапланып башлады:

– Мин, – диде, – харап бер эш белән килдем. Зур яшерен эш: Баязид провокатор булган икән! – диде дә туктады.

Урманов, Тангатаров башта колакларына ышанмый катып калдылар. Күзләренә, йөзләренә коточкынлык төсе чыкты. Әйтерсең, аяз көндә яшен сукты: болар кара таш күмер булып каттылар. Иң элек Давыт уянды:

– Булмас! Ялган! – диде.

Тангатаров та шуны кабатлады:

– Булмас, ялган! Үз күзем белән күрсәм дә, ышанмыйм... Бөтен дөнья сатылыр, әмма Баязидның сатылуы мөмкин түгел! Булмас! – дип кызды, җилкенде дә һаман әле катып торган Җиһангирның алдына барып басты, аның ике җилкәсеннән тотып, күзләренә карады: – Сиңа кем әйтте? – дип сорады.

Җиһангир әллә нинди ят, үлек тавыш белән сөйләп бирде:

– Бу хәбәр зинданнан килде. Аны Гәрәй белән Зоя Горбатова иң элек Нинага шифр белән язганнар. «Шулай сизелә: татарлардан монда озак вакыт зинданда утырып чыккан бер эсер провокатор булган. Фамилиясе хәзергә билгеле түгел. Әмма эсер икәне, Урманов белән Качкын Хәбипкә якын кеше булганы ачык мәгълүм» – дигәннәр. Менә бүген иртә инде фамилиясен, кушаматын да хәбәр иткәннәр. Гәрәй белән янәшә камерада Зоя Горбатова

дигән бер большевик кыз зинданда утыра икән. Гәрәй шуңа белдергән. Ул Габдулла абзый аркылы яшерен шифр белән Булатка язган. Бүген мин йомыш белән Булатка кергән идем. Анда заводтан килгән дүрт татар эшчесе утыра иде. Ул анда яңадан эшкә тотына бугай. Миңа әйтте: «Җиңелгән гаскәрнең беренче адымнары гына кыен. Бераз хәл алгач, яңадан сугышка әзерләнә башлый ул, мин хәзер заводка китәм, үзем барырга вакытым юк, син бар да аларга сөйлә, – белми йөрмәсеннәр!» – дип әйтте. Мин туры сезгә килдем. Сизәм, бу өйнең нигезе черек! – диде дә, башын югалткан кеше кебек, сүзеннән тукталды. Артык авызын ачмады. Катып, югалып утырды-утырды да, һичкем белән исәнләшми-нитми чыгып китте.

Туры үз бүлмәсенә арып, кыйналып кайтты да сабакларына – математикага, латин – «Юлий Цезарь»ны ятларга тотынды[112*]. Ул мең бәла белән, гадәттән тыш зур ярлылык, мохтаҗлык астында университет өчен аттестатка әзерләнә. Рус теле белән иске латин теле аны җөдәтәләр. Ул болардан двойка алып, ике тапкыр имтиханда егылды, быел яз өченче имтиханга керә. Көзгә: «Университет. Мин – студент!» – дип, үзенә ант бирде.

Моңарчы да ул һәр көн типографиядә сигез сәгатьлек корректура хезмәтеннән калган бөтен вакытын шул дәресләренә бирә, тәүлегенә дүрт сәгатьтән артык йоклауны үзенә хәрам итеп куйган иде. Шулай да, иске гадәт буенча, Мансуровлар тирәсенә барып чыккалый, ара-тирә катнашкалый иде. Баязидның асылып үлүе аңа беренче сигнал булды. Инде менә бүген, Булатның чакыртып аңа әйткән сүзе соңында, Җиһангир үзе белән Мансуровлар арасында җепнең бөтенләй өзелгәнен эченнән сизенде һәм җиңеләеп, рәхәтләнеп киткәндәй булды; гүя нindидер авыр бер ялгыштан, саташулы бер кара сөремнән котылгандай булды. Әйтерсең, үзен шулардан бер читкә таба алып ыргытты. «Яңадан ул якка таба минем муеным әйләнмәс!» – дип эченнән беркетте.

Әмма аның Гәрәйләр-Булатлар аша алып китереп ташлаган кара хәбәре буенча тегендә, тар бүлмәдә, Тангатаров белән Урманов, яшен сугып көйдергән, кара күмергә әйләнгән агачлар кебек, үзалларына көеп, катып озак утырдылар – сүзсез, уйсыз, үлеп, катып, кара көеп утырдылар.

## LXXXVI
## ДАВЫТ УРМАНОВ

Алар иптәшләре Баязидның үлеме турында, үзен-үзе асуы турында сөйләргә телиләр. Ләкин уртага провокатор килеп баса. Баязид – провокатормы? Бу – мөмкин түгел. Бу – аларның башына сыя алмый. Моны аңлауга көч җитми. Урмановның теленә бер сүз килә. Ләкин ачудан мие

кабарып, әйтергә хәленнән килми.

«Моның сәбәбе шулмы икән? Шулай ук мондый хәлләрнең сәбәпләре аерым кешеләрдә генә түгел, безнең – эсерларның – бөтен сыйнфый фикере нигезендә үк мондый хәлләргә туфрак бармы икән? Анда, югарыда, эсер хәрәкәтенең үзәгендә, үзәк җитәкче миендә – Азеф! Евно Азеф![113*] Даһи провокатор! Провокатор җитәкче. Монда Баязидлар провокатор. Бу Баязидлар, бу Азефлар бер үк тамырның мәҗбүри җимешләреме? Ул гына да түгел бит! Менә Разиялар, Йосыфҗаннар, Фәхриләр дә безнең эсерлар партиясе эчендә кайнап эшләгән кешеләр. Болар, әллә бәлкем, турыдан-туры охранкага бармаслар. Ләкин нәтиҗәдә барыбер түгелме? Дашкинны кара. Эсерның менә дигәне иде. Провокатор булган. Аңа гына туймыйча, институтка керү хакы алу өчен чиркәүгә барып, поп каршында чукынган. Хәзер муенына тәре тагып йөри, диләр. Шулаймы, безнең кичәге кызыллык – сахтә[1] кызыллык, фальш[2] кызыллык кына булдымы? Ул кызыллык кирәк идеме? Белмим, башым әйләнә бугай. Мин хәзер Госманнар, Нигъмәт казыйлар белән үз арамда булган диварларның җимерелгәнен сизәм. Бу ни хәл? Монда нинди процесс бара? Бу черүләрнең нигезләре кайда? Аерым кешеләрдәме, әллә башкалардамы? Гәрәйләр, Вахитовлар нигә черемиләр. Алар өстендәге кызыллык нигә уңмый? Алар нигә бу реакциянең кара дулкыннарына каршы баралар да, без нигә шул пычрак дулкын эченә йотылабыз? Шакир солдатны бит без дөньяга тарттык. Ә хәзер ул да Вахитовлар ягына авып бара. Габдулла абзыйны мин үзем тудырдым, үзем аңга керттем дип уйлый идем – хәзер ул да бит Вахитовлар, Гәрәйләр койрыгына тагылып китеп бара. Син аның сүзенә генә кара: «Егетлекмени ул социал-демократ та була алмагач!» – ди бит ул. Алары тагы бер хәл. Менә Хәбиптән нәрсә калды? Эчә дә сүгенә, эчә дә сүгенә. Әйтерсең, бер хулиган! Шул хәлгә төште, шулай черде бит ул. Гәрәй Солтан элек аңа әйтә иде: «Син революционер түгел, син бушбугаз бунтарь!» – ди иде. Әмма хәзер инде Хәбип Мансурның барлык бунтарьлыгы да эчкәч сүгенү генә булып калды. Инде аңа бунтарь да димиләр. Бары тик, бушбугаз дип кенә йөртәләр. Сәрүҗи дигән исеме-кушаматы шантажист-хулиган дигән мәгънәдә йөри. Бу хәлләрнең, бу черүләрнең сәбәбе кайда?»

Давыт Урмановның мондый саташулары байтак элек кузгалган иде. Реакция башлангач та, ул бераз вакыт зинданда утырып чыкты. Шунда менә ул үзенә алдагы юлга маяклар кадау турында эзләнеп азапланды, аңарда бервакыт революциягә, социализмга гына түгел, бөтен кешелеккә дә иман

---

[1] *Сахтә* – ясалма, ялган.
[2] *Фальш* – ялган, ясалма.

бетте. Ул Толстойга капланды, немец философы Фридрих Ницше юлына сугылды. Аның «Заратустра»сын[114*] бөти кебек кадерләп, догалык кебек ятлап йөргән чаклары булды. Бу чорларда ул үзенең эсерлыгы белән кичә сүккән иттифакчыларын аера алмый җөдәде. Болар икесе бер кебек тоелды. Гәрәй Солтан аларны сүккәндә: «Сез эсерлар буржуаның сул кабыргасыннан яратылгансыз, сез буржуаның кече туганы!» – дип чәнчә торган иде. Шул сүзләр хәзер Давытның миендә тимерле кадак булып туктаусыз әйләнде. «Шулаймы? Без эсерлар «Иттифак»ның сул кабыргасы, аның кечкенә туганымы? Алайса, нигә теге вакытта без аларны сүктек? Гәзитебездә дә сүктек. Мәкәрҗәгә барып та сүктек. Хәер инде, туганнар да бит үзара талашмый булмый. Бу да шулай гына буламыни? Чыннан шулаймы? Без – чыннан алар белән бер тамырданмы? Алай булса, Фәхриләр, Разиялар, Йосыфҗаннар да ачыктан-ачык Нигъмәт казый белән, Кадыйр байлар белән кушылган морза меньшевик Госман Азаматлар, Хәйдәр Акчулпановлар да яхшы юлга барып чыккан булалар түгелме?»

Җиһангирнең озак саташудан соң, яңа айнып, хәйран булгандай утырып-утырып та, бер сүз дәшми, исәнләшми чыгып китүен Урманов үз эченнән хурлану белән кичерде. «Нәрсә, мин аның атасын суйганмы? Бер сүз әйтергә теле дә әйләнми ич! Башка вакытта саескан кебек туктый алмый такылдап торган Тангатаров Әхтәмнең дә бүген теле киселгән. Ул да ниндидер бер ирония белән чәпчеп чыгып китте».

Аларны озаткач, Давыт Урманов чишенеп ятса да, йоклый алмады. Кичәге эсерлыгы белән иртәгәге иттифакчылыгы арасында тар нечкә сукмак салу белән саташып бетте. Әллә өн, әллә төш – аерыр хәл юк, шул нечкә тар сукмак таза гына күпергә әйләнә кебек тоелды. Аръяк ярда Нигъмәт казыйлар, Кадыйр байлар, Йосыфҗаннар, Разиялар, Абыйзовлар күренәләр. Башлап Госман Азаматов атлады. Аңа Хәйдәр Акчулпаннар, Фәхриләр иярде. Исерек башы белән ава-түнә баскалап Качкын Хәбип Мансуров та шулар артына тагылды. «Туктагыз, мин дә сезнең белән бергә, – дип кычкырып Давыт тегеләр артыннан йөгерде. Егыла язды, күпернең бер тактасы шалтырап аска төште, шул тавышка уянып китсә, ишектә кемдер шакылдата икән.

Бөтенләй юлча киенеп, Бәдри учитель килеп керде. Тышта яңгыр ява булса кирәк, өс-башы чыланган, итекләре пычранган.

– Җә, Давыт, бу ни эш, соңга калабыз ич! – диде дә, эчке кесәләреннән чыгарып, тәмәке яндыра башлады.

Бәдри авылга чакыра. Давыт аңа башта вәгъдә бирмәгән иде. Иә барырмын, йә юк диебрәк торган иде. Хәзер Бәдрине күрүгә ул үзенең башында билгеле уйга тукталды: «Шулай алдымда зур эш. Нигъмәтләр,

Азаматлар кебек батырып эшләрлек көч кирәк. Барам. Хәл җыеп кайтам да алар белән бергә эшкә тотынам!» – дип киерелеп торды да ашыгыч-ашыгыч киенә башлады. Аның Нәфисәне күрәсе, һич булмаса, аңа хат язып калдырасы бар иде. Бу эшкәчә вакыт җитмәде, йә бик үк кирәк булмавын сизенде. Шулай ук Баязид үлеменең җиде көнлеге мәҗлесенә дә калырга теләмәде.

Шулай җыендылар да Бәдринең пар ат җиккән яхшы тарантасына утырып авылга киттеләр.

## LXXXVII
## ТЕЛӘСӘ, ВАКЫТ ТАБАР ИДЕ

Бу мәҗлес талаш, җәнҗал белән башлана.

Әхтәм Тангатаров исереп килгән, ишектән кергәндә аның тонган күзләре почмактарак сөйләшеп торган чибәр студентка кадала. Карлыккан тавыш белән акырып җибәрә:

– Аба!.. Эш шулаймыни? Монда Акчулпановлар да чакырылганмыни?!

Бу мәҗлес башта Баязидның үз бүлмәсендә булырга уйланган булса да, анда бик тар, кечкенә дигән сылтау белән, Фәхриләрнең, Сәлимовларның димләве буенча, Госман Азаматов квартирында ясалган иде. Баязидның җиде көнлеге уңае белән яшьләрне, элекке кызылларны җыеп, кайбер турыда, бәлки, аңлашып та үтәргә булыр дип өмитләнгәннәр иде. Беренче адымнан ук болай талаш күтәрелү котларны очырды. Тангатарның исерек баш белән бәйләнүе Акчулпановның намусына, дәрәҗәсенә тукынды. Ул Әхтәмнең сүзен: «Андыйларны моннан куарга кирәк!» – дип аңлады, үзенә зур хурлык санады. Сүзен, иптәшләрен ташлап, ишек төбенә атылды да студент форма фуражкасын, сары төймәле студент шинелен кия башлады.

Аңа Госман йөгереп килә:

– Юк, ярамый, ярамый, Хәйдәр дус!.. Ул исерек ич!.. Бик кыйланса, мин аның үзен чыгарачакмын! Әйдә, чишен! – дип, яңадан пальтоларын, фуражкаларын салдырырга тотына.

Ул арада Фәхри дә килеп җитеп, кысташа башлый.

– Андый хулиганнар бетмәс! – дип кычкыра, әтәчләнә. Кул бутап җикеренә.

Бу сүз Тангатаровның колагына чалынды, ул кызып, күзе канланып, бәйләнеп, Фәхригә ташлана:

– Кем хулиган?! Синме, минме? Син кем? Кичәге кызыл приказчик! Син кибет ачтың, өч приказчикның канын эчәсең!.. Кадыйр байның табанын ялыйсың да, шуның белән бик шәп джентльмен булып киттем дисеңме? Их, мөртәт!

Тавыш зурга китәчәк иде. Ишек ачылып, аннан бер төркем иптәшләр килеп керделәр. Сәлимов:

– Ну, егетләр, эчәбез бүген! Баязидның үлемен эчәбез! – дип кычкырды.

Кичә генә авылдан килеп төшкән Нигъмәт казыйны соңгы ике-өч елда иптәшләрнең берсе дә күргәне юк иде. Көтелмәгәндә аның белән очрашу – һәммә иптәшләрне башка сүзләр, башка мәсьәләләр ягына борып алып китте.

Ул бик тазарган. Симергән. Йөзе кызарып тулышкан. Бөтен кузгалышында, сүзендә, күз карашында, тавышында әллә ничаклы эш – көрәш гайрәте балкып тора. Ул, гадәтенчә, киң йөзен тутырып шаркылдап көлде, иптәшләрнең берәм-берәм кулларын кысты да, түр бер урынга утырып, туктаусыз сөйләргә кереште. Аны сораулар белән күмделәр. Ул калын, гайрәтле тавыш белән машина кебек гөрләтеп торды.

Атасыннан акча алган да икән, татар булмаган калага китеп, русча укырга тотынган икән. Ике ел эчендә учительлеккә имтихан тоткан. Тагы югары китәргә, университет өчен аттестатка хәзерләнергә башлагач, атасы үлә. Йортны карарга дип, моны авылга чакыралар. Бу кайта да эшкә тотына. Учитель дә була, кооператор да була. Умартачы да, сәүдәгәр дә, җир хуҗасы да була. Аз гына вакыт эчендә «Ярдәм» җәмгыяте, «Җәмәгать кибете», «Умартачылар җәмгыяте», «Укучыларга ярдәм җәмгыяте», «Җәмгыяте хәйрия», ирләр мәктәбе, кызлар мәктәбе ачып бетергән, кайберләрен ачарга хәзерлекләр күргән. Боларны сөйли дә үзе мәҗлес тутырып шаркылдап көлә:

– Мин шулай җәмгыять ачам да үзем рәис булам. Хәзер бөтен өязне җәдит мәктәпләр белән тутырып барам. Тик менә земство бик кара, хөкүмәттән бер тиен дә ярдәм ала алмыйбыз. Һәммә мәктәпләр тик халык җилкәсендә генә бара... Шулай да берничә елдан без инде өязне каплыйбыз, аннан соң губернага кул сузам... Шуларны юлга куеп җибәргәч, шәһәргә күчәм дә монда «Милләт» исемендә нәшрият ширкәте төзим... Бу эшкә хәзердән үк нигез салырга уйлыйм. Акча бар, дәрт бар, ник эшләмәскә?! Әле менә бу килүем – шул эш белән! – ди.

Аны көчләп диярлек туктаттылар. Чөнки өстәлгә куелган салфетлар, чәнечке-пычаклар, кәбестә-кыяр, горчица, серкә, тоз, телем-телем икмәк – һәммәсе тезелгән, зур миски белән пилмәннәр озын өстәлнең уртасына, ике башына килеп утырганнар иде инде.

Госман, кунакларны дәрәҗәсе белән утырта-утырта, сәгатьне карады. «Кеше күп, иң кирәклеләр юк!» – дип, эченнән әрнеп уйлады.

Ул Булатка үзе күреп әйткән иде: «Монда Баязидны искә төшерү бер сылтау гына, минем өчен дә ул соңгы исәптә генә. Әмма мин кайбер мәсьәләләр кузгалыр дип өмитләнәм», – дигән иде. Аш утыртыр минут

җиткәч, тагы телефонга барды. Аңа аннан Нина җавап бирде:

– Безгә монда эшчеләр килгән иде, бу арада ул заводтан җүнләп кайтмый бит, тагы шунда китте бугай. Ачык белмим, кайтса, әйтермен, барыр, – диде.

Госман аскы иренен тешләде. «Теләми, теләсә, ике сәгать вакыт табар иде», – дип әрнеде. Нигъмәтнең мактануларына ачуы килүдән бер читтә альбом актарып утырган исерек Тангатаровка барып, Давыт белән Хәбипне сораган иде. Әхтәм аңа башта сүгенде:

– Син нәрсә нифак сатасың[1] Акчулпанов бар. Фәхри бар. Инде менә авылда крәстиәнне тереләй суеп, байлык җыючы кулак, реакция каһарманы Нигъмәт казыең да килеп төште. Сиңа тагы кем кирәк? Иттифакчы Әхмәт Нурый белән байбәтчә Йосыфҗан гына калган ич! Аларны да чакырырга идең, бигрәк тулы мәҗлес булыр иде, – дип әрләде. Ахырдан иплән өстәде: – Давытның башы әйләнгән, ул авылга сызды. Бунтарь Хәбипнең, эчеп йөри торгач, эзенә төшкәннәр. Бу арада ул да күздән югалды, – диде, ләкин чәнечми үтә алмады, Азаматовның тулы битенә, яхшы галстугына карап чәнечте: – Госман, «а» дигән кеше «б»ны әйтергә тиеш. Син нигә яшь бикә Разия ханым белән фабрикант Абыйзовны да чакырмадың? Хәзерге компанияң ич синең! – диде.

Госман ачуланмады, кызмады, бу сүзләр – һәммәсе исереклектән дип юрады. Тангатарның култыгыннан алды, инде тәрилкә-кашык белән, чәнечке белән туктаусыз шалтырап ашый башлаган мәҗлескә китерде дә үз янына утыртты.

Аш янында тагы Нигъмәт казый сүзгә кереште. Тагы үзенең авылдагы эшләрен сөйләргә тотынды.

Бу мәҗлес Баязидны искә алу мәҗлесе иде. Моны башлап кузгатучы Тангатаров иде. Ләкин ул көн Булатның зинданнан Гәрәй аркылы алган кара хәбәрен Җиһангир китереп тапшырган минуттан бирле ул Баязид исемен үзе телгә алмас булды. Шуңа күрә Сәлимов: «Синдә бик тыгыз. Ашауның җүне булмас. Әйдә, Госманда ясыйк», – дигәч, бер сүз белән күнде, өстеннән тау төшкән кебек сизенде. Ул башта: «Әйдә ясасыннар, мин, бәлки, бармам да», – дип уйлаган иде. Ләкин эчеп исереп, һаман йокысыз үткәргән бу өч тәүлектә аның фикере икенче якка таба борылды. Баязидның провокаторлыгы турында аның үзендә икеләнү башланды,

«Кайдан белгәннәр?! Баязидның провокатор икәнен кайдан белгәннәр?! Гәрәй зинданда утыра-утыруын. Ләкин анда бит охранканың яшерен дәфтәрләрен укып булмый! Ул кайдан белгән? Ләкин аның сүзенә ышанмау

---

[1] *Нифак сатасың* – икейөзлеләнәсең.

да авыр. Ул сәяси тоткын Зоя белән багланышта икән. Шуның аркылы язып иреккә чыгарткан: «Мине асарлар. Бүгенме, иртәгәме, мәгълүм түгел. Үзем исән чакта сезгә белдерергә тиеш күрдем: теге вакытта «Фидаиләр» эше белән эләккәч, сүз биргән. Акча алган. Бу ачык билгеле булды», дигән. Ләкин нәрсәгә таянып, «ачык билгеле булды», дип әйтә Гәрәй Солтан?»

Тангатаров өч тәүлек шуның эчендә газапланды. Бу шөбһә өстенә Баязидның үзен-үзе асуы да килеп кушылып, аның төн йокыларын алды. «Гәрәй кайдан белгән?» соравы өстенә яңа сорау өстәлде: «Баязид ник үзен-үзе асты?»

Дөньядан туйган өченме? Әллә охранкага ялланып, революцияне саткан өченме? Иптәшләренә, үзенең үткән кызыл байрагына хыянәт иткән өченме? Ни өчен? Ни өчен асылдың, Баязид дус? Шулаймы? Син чыннан провокатормы? Син чыннан кызыл байракны таптадыңмы? Син иптәшләрне саттыңмы? Революциягә, социализмга хыянәт иттеңме? Шул түбәнлегеңне, шул пычраклыгыңны күтәрә алмыйча, үзеңне-үзең астыңмы?

Тангатаров, шул сөальләр эчендә газапланып, өч тәүлек эчте. Ләкин аракы аңа җавап таба алмады. Ул башын югалтты. Баязид гаеплеме, провокатормы, – әллә бәхетсез кара гайбәт кенәме? Ялган гайбәт кенәме? – белә алмады. Ләкин бу сүзне кешегә чыгармаска булды. Шулай да Госман чакырган мәҗлестә, Баязидны хәтерләп, үзе сүз – мактау-сагыну әйтмәскә күңел беркетте. Шуңа күрә юри күп эчеп, нык исереп килде.

Мәҗлестә кашык-тәрилкә шалтыравы белән бергә һәммә рюмкалар аракы белән тулганнар иде. Сәлимов, Тангатаровка күз кысып, «сүз башла» дигәнне аңлатты. Ләкин Әхтәм авыз ачмады. Госман да сүзгә ашыкмады. Сәлимовның эчәсе бик килә иде. Оратор булмаганга, туп-туры гына әйтте дә куйды:

– Намус белән яшәде. Намус белән үлде. Буржуалар чанасына утырмады. Әйдәгез, Баязид дус хәтеренә эчәбез! – дип, аякка басты да рюмкасын күтәрде. Һәммәсе чәкешеп, бер тамчы калдырмый эчеп җибәрделәр.

Бер башлангач, Госман да батырланды. Ул Баязидны күптән белгән икән:

– Зирәк кеше иде. Гомер буенча искегә, кара, кысынкы тормышка каршы протест белән, көрәш белән барды. Ләкин үз теләгенә ирешә алмады, авыр көрәштә канатлары сынды. Якты киләчәккә иманын, өмитен югалтты. Шул һәм аны трагедиягә алып барды, – дип, озак сөйләде.

Аш бетәр-бетмәс, моңарчы да сүзгә катнашмыйчарак утырган Акчулпанов тагы китәргә җыена башлады. Бу юлы инде аңа Нигъмәт казый белән Фәхри бәйләнделәр:

– Госманның рефераты бар ич, аны ничек ташлыйсың? – диделәр.

Акчулпанов аны бер кат тыңлаган иде, күп русча катнаштырып, морзаларча әйтте:

– Ул көн, Кадыйр байларда картлар белән уртак мәҗлес беткәч, без Йосыфҗанның бүлмәсенә аерылып, үзара ул рефератны тыңладык инде, мин аңа бөтенләй кушылам... Әнә Тангатаров та бар иде анда... Ул бәйләнеп тә утырды! – диде.

Ләкин һаман да җибәрмәделәр:

– Ярты сәгатькә түз, – диделәр.

Госманның «Милләт нигезләре» дигән рефераты, бәлки, шулай ярты сәгать эчендә беткән дә булыр иде яисә, озынга сузылып, суык, салкын рәсми фикер алмашуга әйләнер иде. Ләкин аш янында тагы байтак эчеп алган Тангатаров бу мәсьәләгә үткенлек кертеп җибәрде, шуның белән ул рефераттан бигрәк дошманнарның кара-каршы килеп бәрелешүләренә, талашуларына әйләнеп китте.

## LXXXVIII
## РЕФЕРАТ

Әле җүнләп утырып бетмәс, рефератчы сүз башламас борын, Әхтәм Тангатаров бер чәнечми кала алмады:

– Йә, – диде, – иптәшләр! Кичәге социалистның, интернационалистның бүген кара милләтчелеккә, мөртәтлеккә чакырып язган нәрсәсен тыңлап карыйк әле! Безнең Госман морзабыз тәртәне кая таба бора икән?! – диде.

Нигъмәт аңа каршы шелтә ташлады:

– Әхтәм, бу ни эшең синең? Кешенең ни әйтәчәген белмисең, алдан бәйләнергә тотынасың?

– Ничек белмим? Ул элгәре байбәтчә Йосыфҗан кабинетында бер тапкыр сайрады инде. Аннан санкция алгач кына сезгә килә! Дипломат ул безнең Госман морза Азаматов! – диде.

«Морза» сүзен яратмаса да, Госман аңа карамады, җавап та бирмәде, үзенең озын итеп русча язылган рефератын бераз кызып, ялкынланып укып чыкты.

Ул үткән тәҗрибәләрнең сабаклары дип башлый. 1905 – 07 нче ел хәрәкәтләренә анализ ясап, буржуа милләтчелеген, милләтнең нигезләрен, төрек-татар «милләтенең» бөтенлеген саклау чараларын саный.

– Төрек-татар милләте!.. Төрек-татарның тарихи әдәбияты!.. Төрек-татар музыкасы, төрек-татар кызы!.. – дип ялкынланып, бөтен гәүдәсе белән дулкынланып-дулкынланып ораторлыкка тотына.

Акчулпанов, канатланып, дәртләнеп тыңлады. Тангатаровның

җәнҗалы сәбәпле кара болыт белән капланган йөзендә якты көрәш ялкыннары уйный башлады. Реферат буенча берничә тапкыр утырган җиреннән:

– Дөрес, дөрес! – дип кычкырды.

Фәхри һәммә турыда аңа кушыла барды. Сәлимов мыек астыннан мыскыллы елмаю белән Мефистофельчә[115*] көлеп утырды.

Ләкин Нигъмәт казый харап иде. Ул бер сәгатьтә әллә ничаклы үсте. Телдән әйтмәде. Ләкин күңеленнән уйлады: «Бу Госман ул заманда, шәһәр театрында, мөселманнарның Думага сайлау хәзерлеге киңәшендә, әллә нинди кызыл, социализм зәһәрләрен сөйләп милләтне агулаган иде. Җырчы Сәхипнең «Башкорт кызы Гөлбикә»сен әдәби кичә өчен тикшергәндә шул ук морза социалист Госман Азаматов үзенең әче, тирән сүзләре белән Нигъмәтләрне хурлап чыккан иде... Тарих безнең файдага эшләде, безнең юл өскә чыга!» – дип кабарынды. Болай ачык сөйләүне хәзерге мәҗлескә килешми дип тапса да, тик торып кала алмады. Госманның рефераты бетәр-бетмәс, кызарган йөз, утланып, шатланып янган күз белән аякка басты, мәҗлесне төрткәләп Госман янына килде дә рефератчының кулын кат-кат кысты, кочаклап үпте, дулкынланган тавыш белән әйтте:

– Мин, – диде, – бүген бәхетлемен, иптәшләр! Төрек-татар милләтенең яшьләре, 1905 ел дулкыны вакытында кызыл мода белән, тәкълид[1] бәласе белән исереп үз милләтләрен ташлаган, милли мәнфәгатьләрне аяк астына салып таптаган чакларында без ялгыз идек. Ул вакытта «милләт», «милләтче» дигән сүзләр карайөзлек иде, хурлык санала иде. Инде хакыйкать өскә чыкты. Безнең кичәге кызыл дошманнарыбыз, кичә мода, тәкълид афәте белән башлары исергән яшьләребез бүген үз аналарының кочакларына яңадан кайталар. Бу – безгә зур җуаныч, зур терәк, өмит. Бөек төрек-татар милләте үзенең борынгы шәүкәтен[2] яңадан кайтарачак. Мирза Госман иптәш Азаматовның рефераты менә шуның беренче сандугачлары...

Тангатаров чыдамады:

– Кичәге социалист белән кара милләтче бүген үбешәләрмени? Госман, сине тәбрик итәм! – дип кычкырды. Аны туктатмак булдылар, «кешенең сүзен бүләсең, тәртипсезлек бу», дип карадылар, ләкин ул айнымады, исерек тавыш белән үзенең сүзләрен ата бирде: – Шулай икән, морза Усман! Синең турыда сөйләгәннәр иде, земствога урынга кергән чакта губернаторга сүз биргәнеңне, моннан соң сәяси хәрәкәткә катнашмам дип вәгъдә биргәнеңне сөйләгәннәр иде. «Булмас, юк гайбәт!» дип караган идем. 1905 нче ел

---

[1] *Тәкълид* – ияру.
[2] *Шәукәт* – дан, шөһрәт.

революциясе чагында үзең сатып, акчасын партия файдасына тоткан өеңне хәзер яңадан кайтарып алырга йөри, диделәр, Кадыйр, Йосыфҗан, Абыйзов, Разия, Фәхриләр аркылы бу алдагы думага сайлану планын йөртә, диделәр. Аңа да ышанмадым: «Булмас, юк гайбәт!» – дип карадым. Инде үз күзем белән күрдем, үз колагым белән ишеттем: син бөтен мәгънәсе белән революцияне, социализмны саткансың икән, син дә ренегатсың[1], мөртәтсең икән!.. Хәер, бер дә гаҗәпләнергә ярамый: син бит меньшевик идең, морза-меньшевик идең! Ләкин меньшевизм байрагы белән чыга алмаганга гына большевик Булатлар, Гәрәйләр тирәсендә әйләнеп маташтың. Синең кебек меньшевиклардан ни көтәсең! Ренегат, мөртәт! Башка ни әйтәсең!.. – дип, озак сүгенде.

Рефератның нәтиҗәсендә мәҗлес Госманнар ягына нык аугандай булганга, Акчулпанов хәзер нык канатланган иде. Тангатаровның бу сүзләренә каршы ясамадан хахылдап көлде. Мыскыл тавыш белән хурларга тотынды:

– Их! Тангатар! Син көзгегә кара: кем ренегат?! «Яшәсен анархизм!» дип акыручы син түгелме? Бүген нигә анархиядән социализмга күчәсең? Бу да мөртәтлек түгелме? – дип, күзләренә мыскыл нуры чыгарды.

Тангатаров тагы кызып күтәрелде:

– Түгел! Бер дә түгел! Мин ачык кычкырам: мин анархизмнан киттем. Әмма мин анархизмнан гына киттем, революциядән, социализмнан китмәдем. Мин буржуа чанасына утырмадым. Мин сезнең кебек кара милләтчелеккә бармадым. Сез революция кайнаган елларда, меньшевик йөзегезне яшереп, Булатлар, Гәрәйләр тирәсенә сыендыгыз, хәзер менә, реакция килгәч, байбәтчә Йосыфҗаннар, Нигъмәтләр, фабрикант Абыйзовлар белән шайка төзисез?.. Нигә бүген монда Булат юк? Нигә эшче Габдулла абзый белән Шакир солдатлар монда юк?! Чөнки Булат килми. Сезнең кебек ренегат мөртәтләр белән бергә булып үзен пычратмый! Аны завод тарта. Ә сезне Кадыйр байның зур сарайлары тарта. Син, Хәйдәр, юкка әтәчләнмә: Тангатар анархизмнан китте, ләкин буржуазиягә барыр өчен түгел! Мин эзләнәм, минем эзләнүем Госман рефераты күрсәткән юлга таба түгел, заводка, фабрикага таба илтеп чыгарыр, бәлки, шул ук Булатларга, Гәрәйләргә илтеп кушар... Әмма менә бу меньшевик Госман морза Азаматов кебек, мин...

Талаш зурга китте. Акчулпанов белән Нигъмәт казый эчә тордылар, эчкән саен тагы яманрак кызып, кызарып, исерек тавыш белән Тангатаровка таба ташландылар. Ул артык эчмәде, иң элек бу икене сүкте, аннан барып

---

[1] *Ренегат* – хыянәтче, сатлык кеше.

тагы Госманга бәйләнде, ләкин бу аек иде, сүзләр талаш төсеннән болай акрын чәнчешү төсенә әйләнделәр. Бөтенләй тынычланган Тангатаров өстәлгә килеп, суына төшкән стаканны кулына алды да, лимонлы чәйне эчә-эчә, бөтен зал өстеннән Госманга чәнчеп кычкырды:

– Хәзер элекке социалист Госман юк диген! Капитализмны җимерү өчен Булатлар, Гәрәйләр белән бергәләшеп, эшче-крәстиәннән социализм армиясе төзү юлында эшләгән Госман хәзер юк диген, Шулай бит?

Госман, һич тә кызмыйча, гаҗәп ачык сабыр җаваплар бирә торды:

– Әйе, шулай диген!

Тангатаров аның кызгылт күзенә карады:

– Ул Госман кайда хәзер?

– Кайда дисеңме?

– Шулай дим.

– Ул үлде!

– Аның идеяләре, сыйнфый идеаллары, кызыл байраклары кайда булды?

Госман ачы көлде. Җавап бирмәде.

Тангатаров аңа ярдәм итәргә теләде:

– Димәк, болар да үлделәр?!

– Үлделәр, Әхтәм туган, үлделәр!

– Революция дә, социализм да, сыйнфый көрәш тә үлдеме?

– Бары да үлде!

– Аларны кем үтерде? Аларны кем алды?

– Алар язгы таңның матур хыяллары, яшьлекнең ал чәчәкләре иде. Аларны тормышның хыялга, өмиткә иярми торган кара көчләре алды.

– Инде алар яңадан кайтмаска беттеләрме?

– Кайтмаска!

Әхтәм Тангатаров:

– Тфү, мөртәт! – диде дә лачт итеп Госманга таба төкерде, үзе ашыгыч атлап ишеккә барды, тиз-тиз киемнәрен киде дә һичкемгә бер сүз әйтми, исәнләшми чыгып китте.

## LXXXIX
## БЕЗГӘ ДӨРЕС СҮЗ ГЕНӘ КИРӘК

Төн якты. Тулы ай ерак күктән елмаеп үтеп бара. Йолдызлар бриллиант булып яналар. Тангатаров боларны күрмәде, артыннан туп белән аттырган кебек, баскычлардан сикереп төште дә пальто төймәләрен каптыра-каптыра Булатларга таба йөгерде. Тукта, кем бу? Берсе: «Булат! синме?» – дип кычкыргандай булды ич! Әйләнеп карады: таныш адәм юк. Тик почмакта

ниндидер бер кеше җирдән әллә нәрсә эзли. Аның кулында таяк, башында колаклы бүрек. Әхтәм тагы кызулап китте. «Әле сәгать унбер генә. Зарифның үзе кайтып җитмәгән булса, хатыны Нина Николаевнаны күрермен. Алар икесе бер очтан киселеп теккән кешеләр ич». Шулай уйланып барып, чаттан борылыйм дигәндә, артка карап куйса, теге колаклы бүрек тагы күзгә чалынды. Бу – кем? Жуликмы? Мондый караңгы тыкрыкларда пальто салдырып алучылар бар дип сөйлиләр. Шулар түгелме? Тангатаров аягын тизләтте – менә Булатлар торган номерларга килеп тә җитә. Чү, тукта! – теге колаклы бүрек күләгә калмаган ич! Әнә кинәт чаттан килеп чыкты да, Әхтәм акрынайгач, кире чигенде. Егеткә шик төште. «Бу жулик түгел. Моңа пальто кирәкми. Бу – шпик. Бу – филер», – диде дә Булатларга керми үтеп китте. Зур урамга чыкты, анда электрик бөтен дөньяны яктырта, урам тулы киенгән-ясанган кешеләр, матур кызлар, яшь ханымнар, офицерлар, яшь егетләр парлап-парлап йөриләр. Тангатаров: «Шул тыгызланып, кайнаган йөрүчеләр эчендә югалырмын, эз яздырырмын», – дип уйлап, ярты сәгать буталды да уң якка, кечкенә бер урамга борылып керде. Анда извозчик бар иде. Сатулашмый утырды да:

– Әйдә вокзалга! – диде.

Чаптырып киттеләр. Караса, арттанрак тагы бер извозчик бара, анда колаклы бүрек аз гына күренеп селкенә. Тангатаровның ачуы кабарды: «Чукынсын ла! Нәрсәгә мин болай азапланам соң!» – дип, извозчикны вокзалга җитми, кире борды да: – Чехов урамы, № 41 гә илт, – дип кычкырды. Бу аның аерым кечкенә бүлмә алып тора торган өе иде.

Колаклы бүрек күләгәсе калмады, ераклап сагалап килде. Әхтәм извозчикка юри озак түләде, вак тапмый азапланды. Исәбе: теге филер якынрак килсә, мәсхәрә итеп көлү, яисә исереккә салышкан булып, борынына берне кундыру иде. Ләкин ул килеп тә җитте, өйгә, Таңгатарга җентекләп карап, чаба-чаба үтеп тә китте.

Моңарчы аны эзәрләүләре сизелми иде. Бу беренче тәҗрибә булды. Шик юк, бу – филер. Ләкин кемне күзәтә? Тангатарның үзенме? Әллә Госман җыелышында кемнәр булды дип барын да эзәрлиләрме? Шулай булыр. Охранка бит ике кешенең җыелып сөйләшүеннән дә коты очты. Ләкин Тангатаровның йөрәге каушамады. «Әйдә, эзәрләмәгәйләре, кадалып китсеннәр!» – диде дә, бүлмәсенә кереп, йокыга ятты.

Әллә төш, әллә өн. Кыңгырау шалтыраталар. Күп аяк залга керә. Аннан менә бик якын шакылдаталар. Уянып китсә, алдында озын рус: кокарда куелган фуражкалы, кылычлы, мылтыклы, зур сары мыеклы пристав басып тора. Янында ике жандарм. Алар артындарак түбәнге катта торучы исерек итекче Федорович белән кибетче Садыйк карт күренә. Бу икене тентү

вакытында пүнәтәй ясап китергәннәр булса кирәк.

Әхтәм тәртипсез бүлмә, студент тормышы белән яши иде. Бүлмәсендә иске одеяллы карават белән керле тышлы мендәрдән, анатомия белән физиология турында ике зур калын дәреслектән башка нәрсә тапмадылар. Бик эзләгәч, мич башыннан бер төргәк китереп чыгардылар. Аннан Бакунин белән Риклоның,[116*] Кропоткинның берәр китабы табылды. Шиккә төшерерлек бер хат, бер язу, бер телеграм кебек һичнәрсә юк, гәзит-журнал да юк, тик яртылаш эчелгән аракы шешәсе белән катып беткән, күгәргән икмәк сыныгы бар. Кызыл борынлы карт жандарм бу шешәгә ике тапкыр күз атты. Үзе ябылгач, әрәм кала ич монда дип кызганып карады. Ләкин бу пристав яңа кеше әле, аның белән бары икенче тапкыр гына тентүгә килә. Характерын аңлап өлгерә алмаган. Шуңа күрә, «әрәм калмасын» дип, авыз ачарга кыюлана алмады.

Шундый юк-барны тентеп, кечкенә бер төргәк ясагач, протоколга кул куйдырды да, пристав аякка басты. Тангатаровка:

– Киенегез! – диде.

Таң атып килгәндә аны бишенче участкага китерделәр. Ул иртән сәгать унгача ятты. Аннан туры жандармериягә – охранкага алып бардылар.

Карт полковник Герасимов зур өмит белән көткән алтмыш яшьлек бәйрәме, утыз биш ел жандарлык хезмәте өчен юбилей ясалуын күрә алмады. Аның үзенә сигез ел буенча яшерен агент булып хезмәт иткән провокатор Карачков көпә-көндез, шәһәр бакчасында, Герасимовны пычак белән суйды. Үзе шул көнне кулга алынды, төнлә зинданда асылып үлде. Хәзер карт полковник жандар Герасимов урынында, татар яшьләренең эшләрен тикшереп, салынкы кашлы жандарм офицер Николаев утыра.

Кайчандыр үзенең «Башкорт кызы Гөлбикә» хикәясен җилем белән басып тараткан өчен җырчы Сәхиптән җавап алынган бүлмәгә Тангатарны керттеләр,

Тангатаров, революция дулкыны эчендә күп кайнаса да, сәяси партияләрнең конспирация мәктәбен үтмәгән, эләккәндә ничек тоту, ничек җавап бирү турында сабак алмаган кеше иде. Ул бу яктан бераз борчылды. «Охранка мине үзенең мәкерле, хәйләле тозакларына эләктереп куймасын тагы, ләгънәт, – дип эченнән әзерләнде. – Һичкемне ачмам. Шикле сорауга дөрес җавап бирмәм. Ну! Әйдә, салынкы каш! Синең белән бил алышып карыйк, кем кемне отар!» – диебрәк жандарның күрсәткән урынына утырды.

Николаев һич хәйләсез, мәкерсез күренү белән каптырырга уйлады. Шуңа күрә бертөрле дә катлаулы сорау биреп маташмады. Тоткынның алдына анкета ташлады. Шуны тутырырга кушты.

Тоткын тиз-тиз укып чыкты да язарга кереште.

*Фамилияң*? – Тангатаров.

*Исемең*? – Әхтәм.

*Атаң*? – Шәңгәрәй.

*Яшең*? – Егерме сигез.

*Кайсы милләттән*? – Татар.

*Динең*? – Ата-бабайлар ислам динендә булганнар. Үзем бер дингә дә ышанмыйм.

*Туган, яшәгән җирең*? – Казан.

*Кем акчасына укыдың*? – Стипендия алдым. Хәзер үзем, татар балаларын русча укытып акча табам.

*Аталарыңның икътисади хәлләре*? – Атам вак чиновник. Мин бала чакта үлгән.

*Кайларда укыдың*? – Гимназиянең җиденче сыйныфыннан куылдым. Аттестатка хәзерләнеп, университетның медицина факультетына кердем. Хәзер өченче курстамын.

*Чит мәмләкәттә булдыңмы*? – Юк.

*Моңарчы хөкемгә тартылдыңмы*? – Юк.

*Кайсы партиядә әгъза*? – Һичбер сәяси партиядә әгъза булганым юк.

Әхтәм Тангатаров. 1911– Казан.

Ротмистр Николаев бу анкетаны карады да, гаҗәпләнгән төс белән салынкы кашларын күтәреп, Әхтәмгә йотылды. Акрын, сабыр, бераз тонык тавыш белән әйтте:

– Ник болай яшергән булып маташасыз? Чынын гына әйтеп бирегез, үзегезгә җиңеллек булыр.

– Ничек яшерәм?

– «Һичбер партиядә әгъза булганым юк» дисез, әмма менә сездән тентү вакытында алынган китаплар эчендә анархистларның прокламациясе бар. Бер түгел, өчәү. Димәк, сез үзегез язгансыз, басып тараткансыз. Димәк, анархистлар организациясендә актив эшләгәнсез.

Тангатаров бераз уйланды, ул каһәр прокламация моннан дүрт-биш ел элек үк мичкә ягарга әзерләнгән җирдә онытылып калган да хәзергәчә шул хәерсез китаплар эчендә сакланып яткан икәнен аңлады. Бу турыда артык ялганларга юл тапмады:

– Мин, – диде, – анархистларның һичбер оешмасында әгъза булмадым. Минем бөтен анархистлыгым шул булды: мин анархизм турындагы китапларны яратып укый идем. Идел пароходында барганда, күтәреп китап сатучыдан Бакунинның ике китабын алган идем, ул прокламацияләр шулар эчендә миңа килгәннәр. Мин аларны тотмадым, карамадым да, Аларның миңа бер тиенгә кирәге дә юк, – диде.

Жандарм кинәт бөтенләй икенче мәсьәләгә сикерде:

– Төркия флотына акча җыю эшенә ничек карыйсыз? – дип сорап, тоткынның күзенә йотылды.

Әхтәм җавап бирә алмады, аның алдына панисламизм, пантюркизм турында бер-бер артлы дурт-биш сорау килеп басты. Болар өстенә тагы:

– Татарлар арасындагы сепаратизм фикеренә ничек карыйсыз? – дип сөаль ташлады.

Тангатаров үзе өчен бөтенләй чит булган бу зур мәсьәләләр турында ни дияргә белмичә көлде:

– Нәрсә әйтим: университет белән кабактан башка беркайда да булмыйм, болар турында берни әйтергә дә хәлемнән килми! – диде.

Ротмистр, аскы иренен тешли биреп, тоткынга күзе белән текәлде:

– Алай димәгез... Беләсез... Тик яшеренәсез! Мин ышанам, сезнең белән без аңлаша алырбыз әле. Сез хәзерге тормышны корал көче белән җимерүче оешмаларда актив әгъза булучылык белән гаепләнәсез. Сезнең баш өстегездә 102 нче статья тора. Хөкем булыр – йә крепость, йә ерак сөрген. Өстәвенә һәммә хокуктан мәхрүмлек... Ләкин мин эшне ул чиккә җибәрмәскә тырышачакмын. Безгә күп нәрсә кирәкми, безгә бары дөрес сүз кирәк. Берничә чуалчык мәсьәлә турында хак сүз әйтә белсәгез, мин сезнең өскә төшәргә торган кылычны үз кулым белән читкә тибәрермен, – дип, урыныннан торды.

Тангатарны алып чыга башладылар. Ләкин ишеккә җиткәч, жандар аны тагы туктатты, тагы кире баягы урындыкка утыртты. Бөтенләй дусча, бөтенләй ике арада гына кала торган тирән сер итеп, акрын тавыш белән сорады:

– Большевикларның динамит фабрикалары белән эләккән сигез эшченең берсе Кавказлы Гәрәй Солтан икәнен сез, әлбәттә, беләсез. Ул хәзер безнең кулда. Егет нәрсә икән. Һичберен яшермәде, сөйләп бирде. Әмма бер әйберне танып азаплана: теге демонстрациядә үтерелгән Исрафилдән соң атаман булып кем калды – Галимовмы, Вахитовмы? Менә шул кечкенә әйберне Гәрәй яшереп маташа. Сез чынын белә булырсыз?

Тангатаров үзен тыя алмый кычкырып көлеп җибәрде:

– Сез шундый әйберләр сорыйсыз миннән, әгәр кичә үлгән булсам, боларны ишетми үлгән булыр идем, большевикларның яшерен динамит фабрикалары турында гомеремдә беренче тапкыр сездән генә ишетәм. Кавказлы Гәрәй Солтанның андый эшкә катнаша алуы – миңа бик гаҗәп нәрсә. Шулай ук мәрхүм Исрафилнең боевик отряды миңа бөтенләй яңа әйбер. Галимов белән Вахитовны мин алай отрядларга җитәкчелек итә алырлар дип гомеремдә дә уйлаганым юк иде. Мине болай газапламагыз!

Зинһар, кире илтеп ябарга кушыгыз! – диде дә аякка басты.

Аны күрше бүлмәгә чыгарып, әллә ничә рәвештә рәсемен алдылар да зинданга китереп яптылар.

## XC
## ЛӘКИН БУ ДА КЕЧКЕНӘ ЭШ ӘЛЕ

Язгы кояш баеган булса кирәк ахрысы, җил кузгалгандыр: мамык таулары кебек ап-ак йомшак болытлар, катлауланып-катлауланып, шәһәр өстенә таба агыла башладылар. Тоткын тимер рәшәткәле кечкенә тәрәзә аркылы берничә минут бу ишерелеп барган куе катлаулы болытларга карап катты. Өстендәге иске кырылган студент форма шинеле белән башындагы рәсми формалы фуражкасын салып кадакка элде дә: «Их! Ничек гомер үткәрәләр икән бу таш капчыкта?» – дип уйлана-уйлана тар, биек таш камераның бер башыннан икенче башына йөрергә тотынды.

Кич шулай үтә. Төн килә. Зинданда гына була торган авыр, озын, ел буенча сузылгандай озын кара төн баса. Аның артыннан аксыл нурлары белән өмитләндереп, ак таң килә. Ялтыраган матур яз кояшының нурлары таш камераның тузанлы тәрәзәсендә, тимер рәшәткәләрдә уйныйлар. Тагы кич. Тагы кояш бата. Баеп барган кояшның актык нурлары белән болытлар алсу кызыл ут эчендә яна башлыйлар. Тау-тау булып нурланып, утлы-кызыллы, карасу томанлы булып яналар. Яналар, яналар да, акрынлап сүнеп, кара төтенгә әйләнәләр. Җир өстен болытлы төн каплый. Дөнья караңгылык эчендә югала.

Әхтәм Тангатаров зинданда беренче төнен, беренче көнен тимер рәшәткә аркылы шул күктәге болытлар тормышы белән кичерде.

Икенче көнне зиндан караңгылыгы баса башлаган гына иде, күрше камерадан кемдер бик акрын гына чиертә кебек тоелды. Надзиратель шунда коридорда, моның ишеге төбендә, тышкы яклап нидер маташа бугай: җүтәллләгәне ишетелә. Ярый, тынды. Ярый, аяк тавышы коридорның теге башына таба китә. Тангатаров тиз-тиз уң як стена буена таба бөгелде дә: «Син кем?» – дип чиертте. Ул байтак еллар Баязид белән бергә торган иде. Зиндан турындагы бик күп хикәяләр-вакыйгалар белән бергә бу чиертү һөнәре дә анардан өйрәнелгән иде. Бүген бик эшкә ярады менә.

«Ләкин белеп булмый. Кем чиертә? Баязид әйтә иде, өйрәнмәгәнрәк тоткыннарның серләрен алыр өчен күрше камерага охранка агентын утырталар да, стена аркылы шулай сөйләтеп, материал суыралар, ди торган иде. Саграк булырга кирәк, тозакка төшермәсеннәр. Юк, иң дөресе шул: үзең сөйләмә. Аңардан сөйләт. Бара торгач бернәрсә ачылыр. Гәрәй Солтан Кавказлы да күп заманнан бирле шул зинданда утыра бит. Богауда диләр

аны. Бәлки, аның турында берәр әйбер белеп булмасмы?»

Шундый өмитләр, шундый саклыклар белән Әхтәм аз гына мөмкинлек булган саен, надзирательнең аяк тавышы еракланган саен, уң стенага сыенып, чиертүне – күрше белән шулай сөйләшүне үзенә гадәт итте. Кем белсен инде, ышаныргамы, юкмы? – күрше тоткын иректәге, зиндандагы барлык вакыйгаларны инәсеннән җебенәчә күреп тора. Әйтүенә караганда Гәрәй белән бер эштә кулга алынган Зоя Горбатованы да, Коляны да, Нинаны да бик якыннан таный. Татар активыннан Вахитов белән эш ташлау комитетында бергә эшләдек, ди. Мин – эшче, ди. Икенче тапкыр утырам инде, беренче эләгүем теге завод алдында булган якшәмбе вакыйгасында иде, без анда Булатлар белән кырык кеше ябылган идек. Булатны Енисейгә сөрделәр, ул аннан качып кайтты, әмма мине, ди, бары тик Пермь губернасына, Шадрин өязенә генә озаттылар. Мин анда ике ел торып кайттым. Хәзерге эләгүем бер провокаторның әләге буенча булды, чыксам, үз кулым белән ул провокаторны буып үтерәчәкмен, ди.

Һәммә әйбер турында бу чаклы материалны кайдан алган? Үзе хакында нигә бу дәрәҗәдә ачык сөйли? Бу – кем? Революционер тоткынмы? Әллә чыннан да охранка агентымы, берәр провокатормы? Җепнең берәр очы чыкмасмы дип, тоткын таш камераның сул як стенасына чиертеп карады. Ахрысы, анда әле таш стена аркылы чиертеп сөйләшү һөнәренә өйрәнеп өлгермәгән берәр яңа кеше утырадыр: иртә, кич, көндез кат-кат шакылдатып карый, җавап юк. Бөтенләй җавап юк. Ичмаса, белмим мин дигән сыман тәртипсез, мәгънәсез чиертеп тә җавап бирми. Әйтерсең, үлгәннәр.

Менә гаҗәп: уң як та туктады. Бу ни хәл тагы? Надзирательнең аяк тавышы еракланган саен шакылдата – юк! Юк та юк. Анда да үлем тынлыгы. Кайда булыр? Башка камерага күчерделәрме икән? Әллә провокатор булып та, миннән нәтиҗә чыгара алмагач, файдасызга санап, аны моннан алдылармы икән? Бер тәүлек шундый кабер тынлыгы астында калды. Тагы шул түшәм тактасы янына асылган фонарь кебек кенә торган тузанлы кечкенә тәрәзәнең тимер рәшәткәләре аркылы күк белән, ай, йолдыз, болыт белән яши башлады. Чү! Шакылдата түгелме? Ике генә чиертте дә туктады. Чү, тагы! Инде ачык: ул көн зиндан башлыгы белән талашкан өчен бер тәүлек карцер биргәннәр иде. Шуны утырып чыктым, ди. Дошманыңа язмасын, сулы, пычрак таш идән. Карават юк, урындык юк, тәрәзә юк. Дөм караңгы. Бөтен стеналары юеш... Караңгы коега ябып, өстеңнән таш бастырган кебек хәлдә торасың. Ашарга да тәүлегенә бер кисәк икмәк белән салкын судан башка һичнәрсә бирмиләр. Күбрәк утырсаң, акылдан шашарсың, шундый бер пычрак, юеш җәһәннәм икән ул карцер, ди.

Кем белә инде... Әхтәмгә тагы шик төште. Карцерда булганмы? Әллә

иреккә чыгып, охранкага материал биреп килгәнме? Тангатаровның башы әйләнде, һичбер сүзенә ышана алмагач, уң як стенага чиертүләр дә баштагы тәмен, мәгънәсен югалтты хәзер.

Шулай аптырабрак торганда, кинәт сул як шакылдата башлый. Бик белеп, бик оста кул белән. Син кем-фәлән, дип тә сорамый, туры әйтә: «Әхтәм, синдер бит, мин – Гриша», – ди. Алай гына ышану мөмкин түгел икәнен белгәнгә, тик үзләре арасында гына булып, тик икесенә генә мәгълүм булган бер «серне» ача: беләсеңме, хәтерлисеңме? Бер матур татар кызында, яшьрәк чакта, җүләрләнеп, икәү бергә йоклап чыктык, ди. Тангатаров моны оныткан иде, бу ярым кызыклы, ярым хурлыклы «сер» дөньяда башка берәүгә дә әйтелмәгән иде. Моны хәтерләү бик дөрес юл булып төште, Әхтәмнең шиге калмады. Үзенең иң якын иптәшләреннән Гриша белән янәшә туры килү – аңа зинданның зинданлыгын югалтып җибәрде, шиге-шөбһәсе, әлбәттә, калмады, һәрбер мөмкин минуттан файдаланып, сөйләшә торган булды. Заманында Тангатаров анархизм теоретикларыннан Кропоткинны күп укый иде. Аның Франция зинданында утырган чагына карата язган бер истәлеген хәтерләде. Кропоткин әйтә: Франция зинданында утырган чагымда, ди, күрше камерада ялгыз ябылган бер эшче тоткынга, шулай надзирательдән яшерә-яшерә таш стена аркылы чиертеп, 1871 иче елның Париж коммунасы турында тулы лекция укып чыктым. Бу лекцияне бер атна эчендә бетердем, ди.

==Тангатаров бу дәрәҗәдә виртуозлыкка җитә алмый, шулай да тиз-тиз аңлата һәм аңлый башлады инде. Менә Гриша башкарак. Ул Кропоткин дәрәҗәсендә оста булса кирәк, гаҗәп ачык, тиз әйтә, синең чиертүеңә каршы, сүзнең, җөмләнең бер-ике хәрефен шакылдату белән: «Аңладым, аңладым», – дип кисә тора.

Бу арада зиндан эчендә тоткыннар тарафыннан бик зур коллектив протестлар бара. Шуңа күрә надзирательләр минут саен диярлек тимер ишекнең кечкенә тимер күзен ачып, сагалап кына йөриләр. Моңа карамастан, Гриша берничә гаҗәп вакыйганы сөйләп өлгерә алды.

Саратовта эләккән Зоя Горбатованы монда күчергәндә, этап-вагонда, казачий каравыл көчләп хур иткәннәр. Унтугыз кеше бер-бер артлы тәхкыйрь кылдылар[1] дип әйтә, ди. Сифилис йоктырганнар. Ул зиндан больницасында ятып, әле яңарак кына аны менә шул корпуска, аргы башка, хатыннар бүлегенә япканнар икән. Аның эше хәзер бөтен Русиягә, бәлки, бетен Европага җәелә торган җәнҗал булып бара, ди.

Гриша моны сөйләде дә: «Ләкин бу кечкенә эш әле!» – дип өстәп

---

[1] *Тәхкыйрь кылдылар* – мәсхәрә иттеләр.

куйды. Аның үзен харап итә язганнар. Ул көнне зиндан башлыгының урынбасары, камераларга йөреп, тоткыннарны карап чykканда, Гриша аягүрә каршы алмаган. Әйткәч тә тормаган: аягым авырта, басарга кыен, дип киреләнгән. Шуннан талаш китә. Әләк бирәләр. Егетне өч көнгә икмәк-суга, караңгы, юеш карцерга ябалар. Анда чыгарган җәнҗал өчен кырык камчы суктыралар. Бөтен ботларым, аркаларым чиләнеп яраланды. Хәзер утыра да алмыйм, ята да алмыйм, ди. Прокурорга шикаять биргән икән, ничә көн үткән, җавап юк. Хәзер инде менә дүртенче көн аштан-судан ваз кичкән. Ачлык игълан итә. Губернаторга, министрга яздым, егерме көн түзәм, егерме көн ач торам, әгәр шул вакыт эчендә миңа булган хаксызлыкны тикшертмәсәләр, мине суктыручыларны җәзага тартмасалар, чыдар хәлем юк, кан тамырларымны үзем кисәчәкмен дип белдердем, ди. Ул моны сөйләп чыга да өстәп куя: «Ләкин бу да кечкенә эш әле, – ди. – Эшнең зурысы хәзер палач Тарбашев белән бүген-иртәгә үлем көткән Гәрәй Солтановта, ди. Иң яманы шул: мулла белән анасы, аның камерасына кереп, һәр көн аны патшадан мәрхәмәт сорап кәгазь бирергә димлиләр», – дип өстәде.

## XCI
## БЕЗНЕҢ КӨННӘР ЯҢАДАН КИЛЕРЛӘР

Казан Алафузов фабрикасыннан чыгарылгач, байтак вакытлар эш тапмый йөргәннән соң Бакуга киткән чакта ул ике баласын, хатыны Мәрьямне дә үзе белән бергә алып барган иде. Яңадан башка исем, башка паспорт белән Казанга качып кайтканда аңа, әлбәттә, җәмәгатен, баласын Кавказда калдырырга туры килде. Мәрьям анда Тагиевлар фабрикасында урын тапканга, аларның ач үлмәслек җайлары да бар, бу як белән Гәрәй Солтан байтак тынычланган иде. Ләкин бүген анасы карчык, күрешергә килгәндә, тоткынның йөрәк төбендә тирән сызланып яткан бу ярага яңадан кагылды. Патшадан гафу, мәрхәмәт сора, дип димләгән өчен Гәрәй кичә мулланы үз камерасыннан куып чыгарган иде. Хәлсез куллары белән богаулы тоткын улының муенына асылып, бичара ана да шул актык чарага сарылды, күз яшенә буыла-буыла:

– Балам, – диде, – сине күз яше түгеп үстердем. Туйганчы күрә алмадым. Бар гомерең җә заводта, җә тоткында узды... Хәзрәтнең сүзенә колак сал. Патшаның мәрхәмәте зур диләр, сораган кулны кире кайтармый икән диләр. Әзер язган кәгазь бар икән, шуңа кул куйсаң ни була, балам. Синең өчен җылап, күз нурлары беткән анаңны кызган, мине кызган. Мине кызганмасаң, балаларыңны кызган. Багалмасы кебек улың Әхмәт бар. Яз чәчәге кебек чибәр кызың бар. Синең өчен утка, суга керергә әзер торган яшь, чибәр хатынын, Мәрьям бар. Кичә алардан хат килде, бичараларым:

«Сагындык, – дигәннәр. – Әткәйне дә сагындык, Казанны да сагындык», – дигәннәр. «Иделне дә сагындык», – дигәннәр. Менә алар кайтып төшәрләр. Мин аларны ни белән юатырмын? Аларның күз яшьләрен ни белән сөртермен. Алар: «Әткәй кая?» – дип сорарлар. Мин ни әйтермен, балам?.. – диде дә карчык, һушыннан язып, катып калды.

Гәрәй әйтергә, юатырга сүз тапмады. Ул болай да аз сөйләүчән кеше иде, бу минутта ни генә әйтсә дә, анасын юата алмавын бөтен йөрәге белән сизенде, карчыкны һушына китергәч, тоткын, аңа карый алмыйча, санап, акрын әйтте:

– Әнкәй, йөрәгемне өзмә минем, әнкәй! Миңа җиңел дисеңме?..

Шул сүз белән Гәрәйнең тавышы киселеп куйды. Бугазына нидер килеп тыгылгандай булды, ике күзе яшь белән тулды, моңарчы үлем бу дәрәҗәдә якын килгәне, бу чаклы кискен сизелгәне юк иде. Яшь, кайнар, ялкынлы гомере менә ниндидер бер чиккә килеп җиткәндәй, хәзер-хәзер өзелә кебек булып китте. Бер секунд уйланып катты, тагы телгә килде:

– Әнкәй, җыламыйк! Син кайт инде. Балаларны минем өчен үбәрсең. Мәрьямгә әйт, Әхмәткә сукмасын, аның башы авыртучан бит, – диде дә, тагы бугазына нидер төенләнеп килә башлаганын сизенеп, анасын кочаклап үпте.

Каравыл: «Вакыт бетте», – дип, аларны аерды: карчыкны ике яктан җитәкләп алып чыгып киттеләр. Тоткын үз камерасының тимер ишеге шартлап ябылганын, надзиратель аяк тавышы коридорның икенче башына җиткәнен көтте дә, авызына яшерелгән кечкенә кәгазьне ачып, тимер рәшәткәле тәрәзә яктысына таба сыенды.

Ана белән угылның күрешеп үбешкән чакларында, авыздан авызга бирелгән бу кечкенә яшерен кәгазьдә бик вак, шулай да бик ачык итеп, Булат кулы белән шул сүзләр тезелгәннәр:

«Гәрәй! Без синең иректәге иптәшләрең, күп сагынып, сиңа сәлам язабыз. Сине юлдан яздыру өчен корылган тозак хакында ишеттек. Әмма без синең каты торуыңа шик итмибез. Караңгы авыр төннең иң авыр сәгатьләре үтә инде. Җиңелгән армиянең беренче адымнары гына кыен икән. Пролетариат, хәл алып, яңадан канатланырга бара. Ышан, дус, бу караңгы төннәр мәңге булмас, ышан, озакламас, безнең көннәр яңадан килерләр! Революция сине коткарыр, нык бул! Ялгызмын димә, иректәге барлык иптәшләреңнең көчләре, күңелләре синең белән бергәләр».

Тоткын бер укыды. Күзләренә, миенә ышанмагандай булды. Яңадан укыды. Ирektәге иптәшләренә барып кушылган кебек, алар белән бер эш, бер фронт, бер көрәш эчендә яңадан кайнаша шикелле тоелды. Авыр богаулар да, тимер рәшәткәләр, тимер ишекләр дә, зур калын таш стеналар да каядыр җимерелеп югалалар сыман тоелды. Ул тагы укыды. Һәммә сүзләрен

күңелдән белеп бетте. Шулай да үзен тыя алмады, һаман, һаман укый бирде. Шул кечкенә кәгазь өстенә тезелгән сүзләрнең тирән, кадерле мәгънәләрен ничаклы укыса да, миенә, йөрәгенә йотып бетә алмагандай булды. Утырып та, камераның бер башыннан икенче башына йөреп тә туктаусыз укыды. Юк. Бу кәгазь түгел. Анда тезелгән сүзләр – сүз түгел. Болар Гәрәй өчен, иптәшләреннән, ирегеннән аерылган Гәрәй өчен, бүген-иртәгә үлем көткән тоткын Гәрәй өчен алдагы тарих юлына ике яклап тезелгән маяклар булдылар. Юк, алай түгел, болар – тышкы дөньяга, болытлы, яшенле, дулкынлы, диңгезле, янар таулы, көрәшле, сугышлы гаҗәп тормышка таба Гәрәйгә юл ачтылар. Шулай! Бүгенме, иртәгәме – аны асарлар! Ләкин Гәрәйне асу белән дошман үзен коткара алмый. Гәрәй үләр, әмма революция бетми. Революция җиңми туктала алмый. Революция бармы? Ул бар булса, Гәрәй дә бетми, иске тормышны җимереп ыргытачак революция дулкыннары эчендә аның да бер тамчы каны булачак. Шул дулкыннарда, шул җиңгән революция, шул иптәшләр эчендә Гәрәй дә булачак.

Үлем белән яшәүнең бергә тоташкан сызыгында Гәрәйне шундый уйлар капладылар. Иртәме, кичме, яхшылап аермады, арганчы камера буйлап йөрде-йөрде дә... уф-ф... дип авыр сулап, караватының читенә утырган килеш, авыраеп ташка әйләнгән башын ике кулы эченә алды, бераз иелә төшеп, авыр уйлар эчендә катты.

Күпмедер сәгатьләр үтә. Гәрәй Солтан кузгалмады. Ашарга керттеләр. Аңа якын бармады. Тагы нидер сорадылар, күтәрелеп җавап бирмәде, кич сәгать тугыз булгач, надзиратель:

– Ятырга вакыт! Лампаңның филтәсен төшер әзрәк! – дип, тимер ишекнең кечкенә күзеннән кычкырган иде. Тоткын аны да ишетмәде.

Шулай кара төн килде.

## XCII
## ИПТӘШЛӘР!..

Кайдадыр сәгать төнге берне суга. Зиндан тыштан тын, тыныч, авыр, басынкы караңгылык эчендә чолганып утыра.

Ләкин тоткыннар йоклый алмыйлар. Хатыннар бүлегендәге Зоя Горбатова чыдамады, кинәт сикереп торды да нервы утында янган нечкә, озын бармаклары белән тиз-тиз күрше камерага чиертә башлады:

– Нигә икән? Йөрәгем бик курка! Бүген надзирательләр дә әллә ничек башкарак кыйланалар...

– Ни булыр дисең?

– . . . . . . . . . . . . . . . . . .

– . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Зиндан тагы тынды. Ләкин тынычланмады.

Кайдадыр түбәнге катта авыр тимер ишекләрнең берсе ачылып ябылгандай булды да тагы тавыш киселде. Юк, киселмәде, берничә аяк төннең тын караңгылыгы эчендә тар таш баскыч белән югары таба менеп киләләр бугай. Шулай кебек тоела. Чү! Берсе нәрсәдер төшерде, ахрысы. Ул кинәт шалтырап куйды, басылган ачулы тавыш: «Иплəп бар, болван!» – дигәндәй булды. Аяклар һаман якынлыйлар. Инде күбәйделәр. Үзләре һаман менә киләләр. Әнә менеп җиттеләр бугай. Коридорның төнгә караган яшерен бүлегенә таба үтәләр. Арадан берәү гаҗәп бер эчке, басынкы тавыш белән: «Кайда?» – дип сорады.

Бөтен төннәрен нервы газаплары эчендә янып кичергән Зоя, уяныпмы, саташыпмы, тагын сикереп тора да яланаяк, тузган чәч белән үз камерасының тимер ишегенә ташлана. Ишектәге тимер күзне кечкенә кулы белән коридорга таба сугып җибәрә. Ләкин ул ачылмый. Тегеннән, күп аяк тавышлары белән тулган коридордан, надзиратель яман ерткыч тавыш белән:

– Сиңа... тагы кирәкме? – дип сүгеп акыра...

Шул кычкыруга бөтен зиндан шашып китә, тоткыннар яткан җирләреннән сикерешеп торалар да һәммәсе камераларының тимер тишекләренә ташланалар. Куллар белән сугып, аяк белән тибеп, читлектә котырынган усал ерткыч җәнлекләр кебек шакылдатырга, шаулашырга, кычкырышырга тотыналар. Бөтен зиндан шау-шу, талаш, кычкырыш белән, тимер ишекләрне ватып чыгарга омтылган сугу, тибү тавышлары белән каплана, ләкин туктаусыз кайнаган надзирательләр һичбер камераның ишегендәге кечкенә күзлекне ачарга ирек бирмиләр. Анда басылган ачулы тавышлар, ашыгыч аяк атлаулар эчендә бер сугышмы, көрәшме, әллә башка бер эшме бара. Шул ике якның – коридор белән камералар стенасында кайнаган саташулы шау-шуын ниндидер бер тавыш, әйтерсең, кисеп төшерде:

– Иптәшләр!..

Ләкин бу кискен тавыш шуның белән үзе өзелде, бугазын буалармы, әйтергә бирмиләрме, ул, ахры, тагы бер талпынды, тагы бер тапкыр:

– Иптәшләр!.. мине... – дигән кискен тавыш бөтен камераларда, бөтен коридорда, таш баскычларда яңгырады да тагын киселде...

Гәрәйне шулай алып чыктылар. Бөтен зиндан һичкемнең тыюына, куркытуына карамады, камералардан берьюлы күтәрелгән көчле җыр тавышы белән капланды:

Вы жертвою пали в борьбе роковой... [117*]

Карт зиндан шул җырның таш стеналарда яңгырашы астында үзенең корбанын озатты,

# XCIII
# АКТЫК БУРЫЧ

Ниндидер тар, караңгы таш баскычлардан төшә-төшә, тәбәнәк, ярым караңгы бер залга керттеләр. Анда фонарь асылган. Төрле җиргә сибелебрәк бер төркем кешеләр баскан җирләрендә каткан килеш каршы алдылар. Ак сакаллы, күп медальле, зур гәүдәле, гаскәри киемле прокурор, тоткынга карамаска тырышып, күзен икенче якка борды. Полковник Герасимов бер провокатор тарафыннан үтерелгәч, аның урынына калган жандарм ротмистр Николаев басынкы кашлары астыннан күзлек аркылы батырып бер генә карады да күзен җиргә төшерде. Тагы ике офицер бар. Карты йокымсырап тора. Зур авызын ачып, ике тапкыр яман иснәп куйды. Яшьрәге үзен кая куярга белмәгән кеше кебек аптырана. Ләкин өлкәннәр алдында салкын канлылык сакларга тырышып газаплана. Боларның һәммәсеннән читтә, ялгызрак рәвештә, букчага салган Коръәнен култык астына кыстырган, чалма-чапанлы, ак сакаллы мулла тора.

Бу залга барып керүгә Гәрәйнең күзләре – озын буйлы, ябык, чандыр гәүдәле, зур, кызыл куллы Тарбашевка кадалды.

Бу кем? Гәрәй уйланды: «Дөрес икән! Бу эт – палач икән!»

Зинданның бөтен сәяси тоткыннары арасында күптән инде бер авыр шик бар иде: мирас өчен ике сеңлесен үтереп, егерме елга каторгага хөкем ителгән тоткын Тарбашев палачлык «хезмәтен» үти икән, ул элгәре Томск зинданында булган икән, мондагы палач Тригубов, акылдан шашып, пыяла белән бугазын кисеп үзен-үзе үтергәч, аны китергәннәр икән, һәрбер сәяси хезмәтчене аскан өчен бер ел җәзасын киметәләр икән, аракыдан өзмиләр икән, дип сөйлиләр иде.

Жандар белән прокурордан бер якта ниндидер, җебе кургаш очлы камчысы белән шул Тарбашевны күрүгә, Гәрәй Солтанның миенә кадак булып бер уй кадалды: «Кайдан алып китәрләр? Хатыннар бүлеге яклап булса, каты кычкырырмын, Зоя ишетер», – дип, шул эшен башкаруның чарасын эзләргә тотынды.

Палач килеп, ашыгыч каты хәрәкәт белән аның кулларын каерганда да, артка каерып бәйләгәндә дә бу уй аның башыннан чыкмады. Көрәш фронтларында кала торган иптәшләр тарафыннан үзенә йөкләнгән актык бурыч кебек, шуны үтәмәсә бер дә ярамый кебек ышанып, борчыла башлады.

Бер күз төшерү белән үлемгә алып барыла торган тоткынның психологиясен билгеләп өлгерергә гадәтләнгән карт прокурор Солтановның башында ниндидер бер уй әйләнгәнен тиз сизенеп алды. Шуның белән бераз җиңеләйде. Юкса, төрле хәл була. Сәясинең дә һәммәсе бер түгел, кайберләре актык сулышларында да прокурорның җанына тоз сибәргә

маташалар. Соңгы ай эчендә булган ике вакыйга аны аеруча агулады.

Әле менә күптән түгел, элекке палач Тригубов үзен-үзе суймас борын, берьюлы алты кешене астылар. Дүртесе тыныч, рәхәт үтте. Әмма берсе палачны, җепне, үлем агачын күрүгә прокурорның аягына ташланды: «Мине асмагыз! Балам бар. Анам бар. Алар хакына калдырыгыз! Мин патшаның гомерлек колы булырга әзермен!» – дип шашып, стеналар яңгыратып җылап җибәрде. Палач Тригубов аны прокурор аягына егылган җирдән тартып торгызырга азапланган минутта бөтенләй һушыннан язды, җепне, багананы көтмичә, прокурорның итеген кочаклаган хәлдә йөрәге ярылып үлде. Бу – ничектер корылган тәртипне бозу булып чыкты. Шул алтының берсе – чал сакаллы, урта буйлы, каты карашлы, яман телле эшче Назаров иде. Менә шул аскы тәбәнәк залга килеп кергәннән алып актык сулышынача туктаусыз сүгенде. Алласын, патшасын, жандарын, прокурорның үзен иң авыр тәхкыйрьле[1] сүзләрен кычкырып-кычкырып сүгенде. Муенына җеп салгач, инде гырылдый башлаганда да: «Син, карт убыр, бу палачың белән мактанма! Безгә дә көн килер, синең үзеңне урам баганасына асарлар, карт убыр!» – дип кычкырып үлеп китте.

Каравыл солдатлар, яшь офицерлар алдында мондый тәхкыйрьле сүгенүләрне ишетү прокурор өчен бик авыр булып төште. Шуңа күрә ул бүген килмәскә, бәлки ярдәмчеләреннән Григорьевны җибәрергә дип исәпләп куйган иде. Бәхетсезлеккә каршы, аның авырып китүен хәбәр иттеләр. Башка чара калмады, ул үзе килде. Тагы шундый бер күңелсезлек чыкмаса ярый дигән бер борчу аның йөрәгендә бар иде. Ләкин Гәрәй Солтановның ниндидер бер уй көче астында икәнен күргәч, тынычланды.

Яшь офицер хөкемнең карар кәгазен укыганда да тоткынның йөзе коелган таш кебек катып торуы аның бу тынычлыгын тагы көчәйтте.

Ләкин бу озакка бармады, бу тәбәнәк, ярым караңгы залдан тагы күп коридорлар, тимер ишекләр аркылы барып, үлем агачы әзерләнгән таш коймалар уртасына туктагач, муллага әмер булды. Ул аптырабрак, букчалы Коръәнен бер култыгыннан икенчесенә күчерә-күчерә, тоткынга килде, каушаган, калтыраган тавыш белән:

– Аллаһе Тәгаләнең рәхмәтенә чик юк, дип әйтә китап. Тәүбә кыйл. Иман әйт. Үлем алдыннан гөнаһларыңның кичерелүен сора. Аллаһе Тәгалә гафуррәхим[2]! – диде.

Гәрәй Солтан аңа карамый йөз чытты, кулы белән читкә таба этәрде, гаҗәп ят бер рәвештә:

---

[1] *Тәхкыйрьле* – мыскыллы, хурлыклы.
[2] *Гафуррәхим*[2] – ярлыкаучы, кичерүче.

– Синең алдыңда тәүбә итәрлек гөнаһ эшләгәнем юк минем! – дип кисте.

Мулла ни эшләргә белмәде, прокурор гаҗәпсенеп карады, мулла ватык рус теле белән:

– Ул теләми! – диде дә тагы букчадагы Коръәнен икенче як култык астына күчерде. Үзе җем-җем иткән күзе, дерелдәгән сакалы белән әле жандарга, әле палачка карады.

Мулла белән тоткын арасында бу бәрелеш булып үткән вакыт эчендә үзенең бөтен хәзерлек эшләрен бетереп өлгергән палач тиз, ашыгыч хәрәкәт белән ташланды, – кәфен капчыкны тоткынның башыннан кинәт кидерде дә, күз ачып күз йомган арада муенына бугалаклап ясалган җепне салды. Яшь офицер карый алмый, икенче якка борылды, прокурор, үлем шартларының тиз үтәлүен күзәткән кебек, палачтан, кәфен-күлмәк эчендә тыпырдаган җанлы гәүдәдән, муенга салынган бугалактан күзләрен алмый кадалды. Палач җепнең икенче башын тартты да югары асылган Гәрәйнең аяк баскан урындыгын кинәт тибеп читкә очырды.

Асылган гәүдә ике багана арасында берничә әйләнеп селкенә дә гырылдый башлый. Үлем катнаш бер коточкыч тавыш белән гырылдый; бөтен мигә, йөрәккә, бөтен кан тамырларына бу гырылдаудан үлем куркынычы тарала. Бу гырылдау, бу ыңгыраш ике таш стена уртасын каплый. Прокурорның күз алды караңгыланып китә, ул палачка акыра:

– Болван! Туктат бу газапны! Булмаса, мин синең үзеңне янәшә астырам! – дип җикеренә.

Тарбашев, калын озын кулы белән кочаклап, асылган гәүдәгә ябышты. Аны үз авырлыгы белән түбәнгә тартырга тотынды. Кысылган бугаз тагы берничә ыңгырашты, тереклек актык тапкыр тагы бер гырылдап селкенеп карады да сүнде.

Шулай үлем килде.

## XCIV
## ЯЗНЫҢ МАТУР КӨННӘРЕННӘН БЕРСЕ ТУЫП КИЛӘ

Ерактан таң сызыла. Балкып кояш чыга. Язның аяз матур көннәреннән берсе туа. Гәрәйнең анасы Газизә карчык:

– Төшләрем дә бик әйбәт иде, Ходай кушып, берәр шатлык сүз ишетмәмме! – дип, әле яңа күтәрелгән кояш белән бергә кузгала да Булатларга таба акрынлап атлый. Озак шакылдата. Нигәдер ачмыйлар. «Иртә килгәнмендер, бәлки, әле йоклыйлар булыр», – дип, шунда ишек төбенә утырып, хәл ала. Бераздан тагы шакылдата:

– Миңа Зариф кирәк иде, миңа Ризван кирәк иде, һаман тормыйлар бит,

рәхмәт төшкерләре! – дип сөйләнә-сөйләнә шакылдата.

Күршедә бер яшь чибәр кыз бар икән. Куркына төшеп, шул чыга:

– Шакылдатма, әби, алар өйдә юклар! – ди.

– Кайдалар икән, балам, тиз кайтырлармы икән? – дип сорагач:

– Юк, әби, тиз кайтмаслар: кичә тентү килеп баскан иде, Ризван Вахитовның коридорда чагы булды, ул көчкә качып котылды, Нина Николаевнаны тотып алып киттеләр. Булат абый жандарларга бирелергә теләми бугай, кайтмый. Аны эзлиләр. Таба алмыйлар, – дип җавап кайтарды да ишеген япты.

Газизә әби тагы утырып бераз ял итә дә таягына таянып: «Минем Гәрәем турында алар, бәлки, берәр әйбер белгәннәрдер инде», дигән өмит белән Габдулла абзыйларга кире кайтып китә.

*Трилогиянең беренче романы тәмам.*

# ЯЗУЧЫДАН

*(Икенче басмага сүз ахыры урынында)*

Сайланма әсәрләрнең өченче-дүртенче китабы булып барган «Безнең көннәр» романы бу икенче басма өчен автор тарафыннан карап чыгылды һәм яңа редакция астына алынды. Ачыграк әйткәндә, әсәр егерме елдан соң тагы бер тапкыр, бөтенләй диярлек, яңадан эшләнде. Шулай итеп, мин үз гомеремдә ике әсәремне, беренче, икенче басмалары чыгып, күп еллар үткәннән соң икенче яки өченче басмалар өчен яңа редакциягә салам. Бу икенең берсе – «Татар хатыны нилэр күрми» хикәясе иде. Бу турыда Казан «Яңалиф» басмасының (1929) икенче томында язучының кечкенә искәрмәсе бар. Хәзер аңа кайтмыйм. «Безнең көннәр»гә килсәк, моның яңа редакциясе уңае белән яшь укучыларга берничә сүз әйтеп үтүне кирәк табам.

Бу роман 1914 нче елда язылып тәмам булды. Шул елның сентябрендә Казанда («Гасыр» нәшриятында) басыла башлады. Ләкин революция хәрәкәтенә бәйләнышлы һәрбер сүздән коты очкан патша цензоры, сиксән бите җыелып, ике табагы басылгач, әсәрне туктатты. Яшь укучыларга ул заманнан бер материал күрсәтү өчен, мин 1914 нче елда цензор тарафыннан туктатылган китапның басыла алган беренче табакларыннан дүрт битнең үз үлчәвендә фотокопиясен алдырдым. Моны Татгосиздатның рәисе Шаһвәли Башкиров[118*] иптәш карамагына тапшырам. Ул үзе кирәк тапкан рәвештә матбугатка чыгарыр яки тиешле әдәби оешмаларның берсенә тарихи документ итеп сакларга бирер. Әмма 1914 нче елда басылган табак үзе минем архивымда саклана. Моны Татарстан Совет язучылары Оештыру комитетының җаваплы секретаре Кави Нәҗми[119*] белән Башкиров иптәшләргә күрсәтеп таныкландырдым.

Шулай 1914 тә басыла башлап та тукталган әсәр бары тик революциядән соң гына дөньяга чыга алды (1919 – 1920, Казан, «Өмит» типографиясе). Бу беренче басма шул 1914 елгы кулъязма тексты буенча эшләнде. Кулъязманы икенче тапкыр типографиягә биргәндә мин аны яңадан төзәтеп чыгу түгел, хәтта бер тапкыр карап, күз йөртеп үтәргә дә вакыт таба алмадым. Ул заман пролетариат революциясе фронтларының гадәттән тыш кызу сугышлы, көрәшле еллары иде. Мин, әле Ленинградта учредилканы ташлап[120*], киң массаны советлаштыру юлында матбугат аша каләм сугышы алып бардым, әле ВЦИКта әгъза[121*] булып сайланып, анда эшләдем, аннан комиссариатлар төзешеп[122*], татар буржуазиясенең контрреволюцион милли оешмаларын җимерешү хәрәкәтендә нык катнаштым. Бу арада вакытлы барып, Уфада эшләү[123*], аннан чехословакка каршы сугышкан Кызыл Армия белән Уфадан чигенү кебек моментлар, шулай ук Кызыл Армия

штабларының ярдәме белән Колчак контрреволюциясенә каршы идән асты хезмәтендә айларча йөреп кайту кебек эшләр бер-бер артлы тоташып, кайнап бардылар. Бу эшләр һәм күңелле, һәм беренче дәрәҗәдә кирәкле булганга, мин боларга бөтенләй чумдым, каләмем турыдан-туры газета аркылы совет өчен көрәш фронтында эшләде, һичбер әдәби әйбер турында уйламадым. Уңае чыкканда әйтим: 1917-18-19 нчы елларда мин һичбер әдәби әсәр язмадым һәм язарга вакыт та тапмадым. Революциядән соң язган беренче әдәби әсәрем – «Яңа кешеләр» (1920) драмасы булды. Менә шул әйтелгән утлы көрәш фронты чагында (1919 ның башында) типографиягә бирелгән «Безнең көннәр» кульязмасын карап торырга вакыт булмавы табигый иде. 1914 нче елда ничек язылган булса, мин аны шул килеш кочагы белән илттем дә типографиягә тапшырдым. Еллар буе кулдан кулга йөргәндә, аның 90 бите югалган иде. Үземнән башка һичкем таный алмаслык караламамны (черновикны) типографиядә наборщиклар кабул итмәс булганга, мин 1919 елның көзендә, фронт эченнән кайткач, 1914 елның танылмас караламасы буенча шул туксан битне эш арасында, аяк өстеннән генә диярлек күчереп бирә алдым. Ләкин совет матбугат эшенең көндәлек үткен мәсьәләләре язучыны шул дәрәҗәдә үзләренә тартканнар иде ки, мин ул әдәби әсәрнең соңгы җаваплы корректурасын да үзем карап барырга өлгерә алмадым. Шулай итеп, 1919 – 20 нче елларда «Өмит» типографиясендә чыккан беренче басма «Безнең көннәр» бөтен көенчә 1914 нче елның кульязма тексты буенча барды (шунсын әз генә хәтерлим, «ихтилял»[1], «инкыйлаб»[2] сүзләрен корректорга әйтеп, «революция» сүзе белән алмаштырттым, бугай).

Шулай китап чыкты. Матбугатта мактап каршы алуларга карамастан, мин китап чыгу белән үземдә тирән канәгатьсезлек сизендем. Шул вакытта ук, әгәр гомерем булса, вакыт җиткерә алсам, бу әсәргә яңадан бер кайтырмын дип, үз күңелемдә кистереп куйдым.

Канәгатьсезлекнең сәбәбе нәрсәдә иде соң?

Башта әсәрнең әдәби техникасыннан, әдәби сәнгатьчә эшләнү ягыннан күңелем риза булмады. Композициясен дә үзем теләгән дәрәҗәгә җитмәгән дип таптым. Эчтәлеккә килгәндә, дошман контрреволюция фронтын, бигрәк тә жандармерия, охранканың яшерен механизмын ачарга тиешле урыннарны тагын бик нык көчәйтергә кирәк һәм мөмкин дип күрдем, шуңа күрә яңа редакциядә мин инде, революция соңында гына безнең кулга төшә алган элекке яшерен архивтан нык файдаланып, жандармнарны, охранка агентларын, аеруча зинданнарны, тоткыннарны, палачларны күңелем

---

[1] *Ихтилял* – баш күтәрү, бунт ясау.

[2] *Инкыйлаб* – алмашыну, революция

туйганчы киңәйтә, тирәнәйтә баруны үземә бурыч санадым. 1914 нче ел редакциясендә Гәрәй Солтан Кавказлы кебек эшче боевикларның көрәш детальләренә, бигрәк тә аның эләгү, асылу моментларына бирелгән элекке материал мине бер дә канәгатьләндермәде. Революция аркасында гына кулга эләгә алган бөтен архив «хәзинәсеннән» Гәрәй өчен яңа мәгънәне, яңа сүз, яңа буяу бирүне күз алдында тоттым. Беренче революциядә дә, татар эчендә, үзләренә күрә бер агым булып килгән пантюркистлар, панисламистлар бар. Беренче редакциядә болар бераз күрсәтеләләр, егерме елдан соң кайтып, тагын тотынгач, бу типларны күп сузмаганда да, кыскалык белән үзләренчә фикри характерларын кискенрәк калыпка тыгу кирәкле булып сизелде. Гали хәзрәтләр, Кәрим Гайфиләр шуңа керәләр. Әсәрдәге меньшевик Азаматовлар бездә киң җәелгән фигуралардан икәне мәгълүм. Беренче редакция боларны чагылдыра, боларның анда да реакция керү белән революцияне сатучы, социализмны аяк астына таптап, контрреволюцион татар милли буржуа фронтына, Кадыйр байларга, Йосыфҗаннарга кушылучы мөртәт элемент икәнлекләре күренә, ләкин бу элементлар беренче революция хәрәкәтендә үк үзләренең төп тамырлары белән шул буржуаның вакытлы кызарган агентлары булганлыгын ачык күрсәтә торган буяулар җитми иде. Менә бу момент – яңа редакциядә үзеннән-үзе үсеп килеп чыкты. Акчулпаннарның, Госманнарның кем икәнлекләрен, кайсы сыйныфка тамырлары тоташуын Гәрәй Солтан баштан ук сизә дә боларга каршы көрәш башлый. Боларның сыйнфый көрәшкә хыянәтләре яңа түгел, бәлки моның тамыры әллә кайчаннан үсеп килгәнен әдәби күренешләрдә бирү – яңа редакциянең төп нигезләреннән берсе булды.

Реакция чорындагы хәлләрне аңлый алмый аптырап, өмит өзәргә якынлашкан җырчы шәкерт Сәхипнең соравына каршы беренче редакциядә большевик Булатов әйтә:

– «Иртәгә кояш чыгуына ышанасыңмы? Моңа ышансаң, революция килүенә дә ышан», – ди. Төп нигезе дөрес мәгънәне бирсә дә, сүз калыбы бөтенләй үк уңышлы булып җитмәгән бу җавап Зарифның тоткан юлында нык баручан бер большевик икәнен күрсәтә. Аннан башка урыннар да Булатовны аерым мәхәббәт белән бирергә тырышканлыкны ачалар, шулай да мин канәгатьләнә алмадым, яңа редакциядә боларга кабатлап тукталдым. Миңа революциядән соңгы 15-16 ел эчендә иске охранканың архивын күп тикшерергә туры килде. Элек һәркемнән яшерен булган бу «хәзинә» эчендә мин татар эшче активистлар, татар большевикларның 1905 ел хәрәкәтенә ничек, ни рәвешле катнашуларының формаларын, детальләрен, әдәби-сәнгать эшендә зур урын тоткан детальләрен җанландыра торган күп документларга очрадым. Шулар нәтиҗәсендә яңа редакциядә Гәрәйләр, Зарифлар

тулыландылар, яңа эшче фигуралар кереп киттеләр. Элек булган моментлар яңадан төзелделәр. Әдәби әсәрләр күктән, Алладан килгән илһам белән языла дип караучылар мондый метод белән эшләүгә, әлбәттә, каршы сөйлиләр. Алар: «Һичбер сүзне яңадан төзәтергә ярамый», – диләр. Ләкин мин бу байгышлар белән исәпләшергә кирәк тапмадым.

Әсәр, югарыда әйтелгәнчә, егерме ел элек язылып тәмам булган. Егерме ел элек дигән сүз – авторның әдәби балачагы дигән сүз, һәм авторның һичбер төрле сәяси партия белән багланмаган чагы дигән сүз. Беренче революция һәм реакция елларындагы сыйнфый сугышларны, иҗтимагый көчләрне ачык, кискен рәвештә Ленинча-Сталинча аңларлык дәрәҗәгә күтәрелмәгән һәм үзенең иҗат процессында шул аң буенча (Ленинча-Сталинча) әдәби сәнгать эшен алып бару дәрәҗәсенә җитмәгән заманы дигән сүз. 1914 нче ел редакциясе буенча чыккан беренче басманы яңадан кайтып карагач, минем күңелне иң нык канәгатьсезләндергән үзәк, нигез момент менә шул булды.

Реакция керү белән эсер Разия, Фәхри, Йосыфҗан, социализмны, революцияне ачыктан-ачык таптап, «иманнарын» сатып, капитализм сафына күчәләр. Бу иске редакциядә дә бар. Анда да бераз күрсәтелә, ләкин иске редакциядә төп нигезләре ачылып җиткерелми. Эсер Давыт Урманов реакция вакытында әле толстойчылык[124*], әле философ ницшечылык якларына авып чайкала. Сәрүҗи Хәбип Мансуровларның бандитизмга ошашлы бер бунтарьлык хыялы белән көн-төн эчеп, исереп йөрүдән башы чыкмый. Баязит карый дигәннәре, охранкага ялланып, провокатор була да үзен-үзе асып үтерә. Ләкин тулаем алганда, иске редакциядә эсерларның шулай вак буржуа баткаклыгында туып, черегәннән-чери барып, гомумән, ачыктан-ачык буржуазиянең ышанычлы көчләренә әверелүләрен күрсәтү бик томанлы – димәк, әсәрдә Ленинча-Сталинча принципиаль сәяси югарылык юк. Яңадан кайтып карагач, мин эсерлар партиясенең революциягә, сыйнфый көрәшкә, социализмга хыянәтләрен күрсәтүнең элекке редакциядәге дәрәҗәсе белән бөтенләй канәгатьләнмәдем. Монда бөтен әдәби техника, әдәби сәнгать методлары буенча, әлбәттә, типлар, вакыйгалар аркылы ул моментны бөтен ачыклыгы, кискенлеге белән бирүне тиеш таптым. Революциянең алдынгы төп нигез җитәкче көче – тик эшче сыйныф кына һәм аның партиясе большевиклар гына дигән иҗтимагый мәгънә – автор өчен нигез фикер. Бу фикер – аерым сүзләрдә, аерым бәрелешләрдә генә түгел, бәлки әсәр буенча җәелгән катлаулы көрәш вакыйгалары, җанлы сурәтләр аша гәүдәләндерелергә тиеш. Яңа редакция менә шул методны күзәтеп барды. Реакция керү белән контрреволюция тарафыннан асылган эшче боевик Кавказлы Гәрәй Солтан, романда ачы тел белән чәнчеп, Сәрүҗиләрне,

Урмановларны: «Сез буржуаның сул кабыргасыннан яратылган элементлар!» – дип хурлый. Разиядагы талаш мәҗлесендә Зариф Булатов эсерларга һәм аларның бөтен партияләренә карата: «Сез революционер да түгел, сез социалист та түгел, сез – буржуазиянең сул фракциясе генә», – дип, сүгеп чыгып китә. Революциянең кызу көннәрендә вак буржуа партияләренең әле бик «кызарып», «социалистланып» йөргән чагында, аларның битләренә ыргытылган бу сүз – реакциянең берничә елы үтү белән гаҗәп бер дәрәҗәдә тарихи дөреслеген тормышның практик вакыйгалары нәтиҗәсендә күрсәтте. Бу тарихи дөрес фикер – иске редакциядә үзенең бөтен ачыклыгы-кискенлеге белән куелмаган. Гомумән 1914 нче ел тексты буенча чыккан беренче басма романда төп ялгышлык – 1905 нче ел революциясен аңлауда әсәрдә Ленинча-Сталинча сәяси установканың булмавындадыр. Шул сәбәпле мин кайбер иптәшләрнең: «Безнең көннәр» романын шул иске редакциясе буенча, төзәтми, кул тидерми генә яңадан басарга кирәк, дигән киңәшләрен кабул итә алмадым.

---

Мин үземнең әдәби иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алулары – тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына мөмкин булды дип табам. Аңа кадәрле басылып чыккан әсәрләремне тик эзләнү һәм хәзерлек баскычының җимешләре генә дип саныйм. Гомумән, бөтен үткән тарихи тормышның сыйнфый сугышларын, аеруча беренче революция һәм реакция елларындагы тирән катлаулы сыйнфый көрәш фронтларын аңлап анализларга мин бары Октябрь революциясеннән соң гына, тик бөек юлбашчыбыз Ленин һәм Сталинның бу мәсьәләгә каратылган хезмәтләре яктысында гына ирешә алдым.

Яңа басма, яңа редакция уңае белән яшь укучыларга бу турыда бөтен ачыклыгы белән әйтеп үтүне автор үзенең бурычы санады.

Галимҗан Ибраһимов.

Ялта, Пирогов санаториясе
6 декабрь, 1933.

## ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

**БЕЗНЕҢ КӨННӘР[1].** Әсәр ике вариантта язылып, беренче варианты 1919-1920 елларда[*], ә яңабаштан эшләнгән икенче варианты 1934 елда[**] басылып чыга.

Беренче вариант 1914 елда тәмамланган. Бу турыда Г.Ибраһимов үзе әсәрнең «Язучыдан» дип аталган сүз ахырында да әйтә: «Бу роман 1914 елда язылып тәмам булды», – ди. Шулай ук аның кайда язылып бетүе дә билгеле. Әдип аны, М.Гафурига язган бер хатында искә алып үтә: «Мин 1914 елда, «Аң»ны ташлагач, зур иҗади дәрт белән шунда (Сухуми шәһәренә. – *А.Ш.)*[***] барып, «Безнең көннәр»не язып алып кайткан идем»,[****] – ди.

Димәк, романның беренче варианты 1914 елда Сухумида тәмамланган. Ләкин авторның аны кайчан һәм кайда яза башлавы турында ачык мәгълүматлар юк. Шулай да Г.Ибраһимов язган кайбер хатларның һәм патша полициясе департаменты архивыннан табылган документларның эчтәлегенә нигезләнеп, бу әсәрнең языла башлау вакытын беркадәр чамаларга була.

Г.Ибраһимов хатларында «Безнең көннәр» романы беренче тапкыр 1914 елның 25 апрелендә телгә алына. Сухуми шәһәреннән мәдрәсәдәш дусты, педагог һәм язучы Хөсни Кәримгә[*****] җибәргән бер хатында ул: «Сиңа язмадым бугай, мин бит «Безнең көннәр» язам, – ди. – Бу «Хәят дулкыннары» атлы трилогиянең беренче җөзье була. Хәзерге чамаларда өч йөз биттән артмас кебек. Ахырга таба арта торган булса, ничек булыр».[******]

Әдипнең Х.Кәримгә моннан элегрәк язган тагын бер хаты бар. Анысының датасы: 1913 ел, 8 ноябрь. Бу хатында ул дусты белән күп мәсьәләләрне уртаклашса да, «Безнең көннәр»не яза башлавы турында бер сүз дә әйтми. Шуңа таянып, без 1913 елның ноябрь башында әле автор бу әсәрне язарга керешмәгән дип уйлый алабыз.

---

[1] Бу әсәргә искәрмә һәм аңлатмаларны язганда моңарчы нәшер ителгән Г.Ибраһимов "Әсәрләре"нең сигез томлык (1974-1986) басмасының 4 томына (Ибраһимов Г. "Әсәрләр", сигез томда, Т.4. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1976. Томны төзүче, искәрмә һәм аңлатмаларны язучы Шамов А.Ш., текстларны әзерләүчеләр Шамов А.Ш., Гайнанов Р.Р.) бирелгән искәрмә һәм аңлатмалар да файдаланылды.

[*] *Г. Ибраһимов.* Безнең көннәр. Роман. – Казан: «Сабах» ширкәте, 1919 ел. – 454 бит. (Әсәрнең басылуы титул битендә 1919 ел дип күрсәтелгән булса да. асылда ул 1920 елның урталарында гына дөньяга чыга. Шуңа булса кирәк, автор аны 1919-1920 елларда басылды дип яза.)

[**] *Г. Ибраһимов.* Безнең көннәр. Роман. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 469 бит.

[***] *А.Ш.* – Афзал Шамов (1901-1990) күренекле прозаик, публицист; Г.Ибраһимовның 8 томлык әсәрләренең 1976 елда дөнья күргән 4 нче томын төзүче автор.

[****] «Совет әдәбияты», 1957, 3 сан. – Б.55.

[*****] *Хөсни Кәрим (1887—1965)* – язучы һәм җәмәгать эшлеклесе. Г.Ибраһимов белән Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыганда ук танышлар, фикердәшләр. 1914 елның җәенә кадәр Х.Кәрим Әстерханда рус-татар мәктәбендә укытучы булып эшли.

[******] «Совет әдәбияты», 1957, 3 сан. – Б. 52.

Г.Ибраһимов Сухумига 1914 елның 13 февралендә китә. Бу турыда Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы шул ук елның 15 февралендә үзенең бик яшерен донесениесе белән полиция департаментына түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Аң» журналының элеккеге секретаре, асылда, аның фактик редакторы булган Галимҗан Ибраһимов 13 февральдә, һич көтмәгәндә, скорый поездга утырып, Казаннан чыгып китте. Моннан китүенең сәбәбе турында ул таныш-белешләренә болай сөйләгән: Казаннан китү турында мин күптән хыяллана идем, дигән. Чөнки иҗат эше белән җитди рәвештә шөгыльләнергә телим. Ә биредә моңа мөмкинлек юк. Монда мин бөтен вакытымны «Аң» журналына бирергә тиеш булам, дигән. Ибраһимов «Аң»ның редакторы һәм нашире Хәсәнов* белән бик җылы саубуллашкан. Хәсәнов аңа, журналда басылачак әдәби әсәрләре өчен, юлга дип, алдан акча биргән һәм киләчәктә аңа ай саен тәртипле рәвештә гонорар җибәреп торырга вәгъдә иткән, чөнки Ибраһимов журналның сотрудникы булып кала икән. Галимҗан Ибраһимовның үзе билгеләгән маршруты: Киев, – анда ул берничә көн торачак; – аннан Кара диңгез белән Кырым аркылы Сухумига китәчәк»**.

Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Г.Ибраһимовның бу сәяхәткә чыгып китүе турында Киев һәм Кутаиси губерналары жандарм идарәсе башлыкларына һәм шулай ук Одесса шәһәре жандарм идарәсе башлыгына да хәбәр итә һәм алардан әдипне күзәтүне үтенә.

Киевтә дә, Одессада да жандарм управлениесенең яшерен агентлары Г.Ибраһимовны поезддан төшкәндә «каршы алалар» һәм шәһәрдәге бөтен хәрәкәтен бик җентекләп күзәтеп, аның кайда урнашуын һәм кайларда булуын хуҗаларына җиткереп торалар, ә тегеләре исә, үз нәүбәтләрендә боларның барысын да бик яшерен рәвештә полиция департаментына хәбәр итәләр.

Кутаиси губерна жандарм идарәсе башлыгының 2 апрельдәге донесениесенә караганда, Г.Ибраһимов Одессадан, «Цесаревич Георгий» пароходына утырып, Сухумига иске стиль белән 17 мартта килеп җиткән һәм Михайловский Набережный урамындагы «Венеция» кунакханәсенә урнашкан. Мөсафирларны теркәү кенәгәсенә үзен журналист дип яздырган. Агентлар аның Сухумида күпме торачагы белән дә кызыксыналар: «Дүрт ай чамасы торырга исәпли, квартира бәяләрен сораша», – диелә аларның бер донесениесендә.

Озакламый, Г.Ибраһимов кунакханәне ташлап, 2 нче Подгорный урамындагы Сигаев йортына күчә, шунда аерым бүлмә биләп яши башлый.

---

* *Хәсәнов* – Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883-1934), язучы, тәрҗемәче, журналист.

** ЦГАОР, фонд ЮИ-00, опись 1914, саклау берәмлеге 74, эш 3. – Б. 20.

Ул бу квартирада иҗат эше белән шөгыльләнә алуыннан бик канәгать икәнен әйтеп, шул ук елның 26 маенда Х.Кәримгә түбәндәгеләрне яза: «Мин менә Кавказга килгәч, дөньяда чын истирахәтне[1] татыдым. Аерым бүлмә. Зур, һавалы, якты. Аерым ход[2]. Теләсәң, көн буе идәндә ятып штансыз ауна. Бай түгелмен, ләкин мәгълүм микъдар бар. Түшәккә карап аяк сузам, ватылмыйм, үземне һичбер турыда көчләмим. Байтак эшлим. Ләкин үзем истирахәт хис итәм. Тәнемнән бигрәк, җаным, нервыларым хәл җыя. Хәзер мин шундый халәттәмен ки, гүя күп еллар дәвам итеп, бөтен организмымны артык дәрәҗәдә бетергән бер авырудан акрын-акрын терелеп киләм кеби»[*].

Г.Ибраһимов «Безнең көннәр» романы өстендә бик бирелеп эшли, вакытын бушка әрәм итми, беркем белән аралашмый, йөрешми, яшерен агентлар сүзе белән әйткәндә, «һәр көнне бер үк төсле дәвам иткән йомык тормыш алып бара». Дөрес: агентлар аның аерым ходлы, зур, иркен, һавалы бүлмәсендә ни эшләвен, көннәрне ничек үткәрүен белмиләр, тик аның һәрвакыт өйдә утыруыннан чыгып кына: «Әдәби хезмәт белән шөгыльләнә булса кирәк», – дигән фикергә киләләр. Шулай да сирәк-мирәк өйдән чыкканда аның кайларда булуы, нишләве агентлар күзеннән читтә калмый. Кутаиси губерна жандарм управлениесе иске стиль белән 1914 елның 8 маенда полиция департаментына җибәргән бик яшерен донесениесеннән без Г.Ибраһимовның квартирасыннан тышкы тормышы турында мондый юлларны укыйбыз: «Ибраһимов һәр көнне 12 дән 1 гә кадәр почтада була, – дип яза ул. – Анда конвертына басма хәрефләр белән: «Казан, «Болгар» номеры, «Йолдыз» газетасы редакциясе һәм конторасы» дип басылган, ә килү адреслары: Сухум, до востребования, Е. В. Б. (его высокое благородие. – *А.Ш.).* Галимҗан Ибраһимовка дип язылган татарча хатлар, газеталар ала. Аларны шунда почтада ук укый яки диңгез буендагы бульварда караштыргалап чыга, аннары ресторанга ашарга бара. Кайвакыт кичкә таба пристаньда яки бульварда йөри, калган вакытларын квартирасында уздыра»[*].

Әдип үзенең бу яңа әсәрен 1914 елның маенда язып бетерергә чамалый. Бу турыда ул Х.Кәримгә шул ук хатында: «Май ахырларына матбагага бирергә булыр дигән нияттәмен. Шул вакытка тәмам кулымнан җибәрергә тырышам», – дип яза. Ләкин ул аны май ахырында түгел, ә июнь урталарында тәмамлаган булса кирәк. Чөнки ул Сухумидан иске стиль белән 16 июньдә кайтырга чыга. Пароход белән Одессага китә. Кире кайтканда да яшерен агентлар һәр шәһәрдә аның бөтен хәрәкәтен, кайда булуын, ниләр

---

[1] *Истирахәт* – ял итү, рәхәт кичерү.
[2] *Ход* – кереп-чыгып йөрү юлы; ишек.
[*] «Совет әдәбияты», 1962, № 3, – Б. 96.
[*] ЦГАОР, фонд ЮИ-00, опись 1914, саклау берәмлеге 74, эш 3. – Б. 20.

эшләвен күзәтеп торалар. Казанга кайткач, хәтта туган авылы Солтанморатка кайткач та, күзәтүдән туктамыйлар. Мәсәлән, Уфа губернасы жандарм управлениесе начальнигы 1914 елның 18 сентябрендә Казан губернасы жандарм идарәсе башлыгына җибәргән яшерен донесениесендә Г.Ибраһимовның Солтанморат авылына кайтканлыгы турында хәбәр итә. Шуннан соң озакламыйча ул аңа: «... Галимҗан Ибраһимов 2 октябрьда Казанга китте...» – дип яза. Шулай итеп, «Безнең көннәр» романы иҗат ителгән айларда яшерен агентлар әдипне бер генә көн дә күздән югалтмыйлар.

Автор бу зур әсәрен язып бетергәнче үк аны бастырып чыгару турында «Гасыр» хуҗасы Әхмәтгәрәй Хәсәни белән алдан сөйләшеп, килешеп куя. Бу турыда ул хатларының берендә: «Безнең көннәр»не мин Гәрәйләргә бирәм. Килештек», – ди.

«Гасыр» нәшрияты романны шул ук елның сентябрендә басарга керешә. «Ләкин революция хәрәкәтенә бәйләнешле һәрбер сүздән коты очкан патша цензоры, сиксән бите җыелып, ике табагы басылгач, әсәрне» басудан туктата. Шулай итеп, Бөек Октябрь революциясенә кадәр бу роман дөнья күрми.

Автор аны 1919 елның башында яңадан кулына ала һәм басып чыгару өчен «Сабах» ширкәтенә тапшыра. Кульязманың нәшриятка нинди хәлдә тапшырылуы, революциядән соңгы басма өчен үзгәртелүе яисә үзгәртелмәве турында романның икенче басмасы ахырына әдипнең үз кулы белән язып урнаштырылган сүз ахырында бу хакта бик тәфсилле аңлату бирелгәнлектән, бу урында без аларны кабатлап тормыйбыз, укучыларның игътибарын сүз ахырына юнәлтәбез.

«Безнең көннәр», ниһаять, 1919-1920 ел урталарында илебездә каты, канлы гражданнар сугышы барган чорда басылып чыга, һәм татар әдәбияты тарихында бу беренче революцион роман укучылар тарафыннан да, вакытлы матбугат тарафыннан да бик җылы каршы алына. Яшь совет матбугаты аның дөньяга чыгуын әдәбиятыбыз тарихында зур, шатлыклы вакыйга итеп саный.

Язучы һәм журналист Фатыйх Сәйфи-Казанлы* бу әсәргә аеруча зур бәя бирә. Ул аны әдәбиятыбыз уңышы итеп кенә түгел, ә революция барышында «татар пролетариаты һәм демократиясе өчен тагы бер зур галәбә[1]» итеп исәпли. Аның сәнгатьчә эшләнешенә бик зур бәя биреп: «Безнең көннәр» романы моңа кадәр татар матбугатында күренгән әдәби әсәрләр арасында, кирәк алынган мәүзугысы[2], кирәк тасвир иткән буявының көчлелеге, кирәк

---

* *Фатыйх Сәйфи-Казанлы* (1888-1937), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе.

[1] *Галәбә* – җиңү, казаныш.

[2] *Мәүзугъ* – тема.

тәҗәссем иткән[1] типларның реальный булуы, бөтенлеге ягыннан, шөбһәсез, чагыштырмаслык аерым урында торырга тиештер»[*], – дип яза. Ул аның тар милли чикләрдән чыгып, руслар да, немецлар да һәм французлар да аңларлык типлар һәм вакыйгалар белән тулы бер роман итеп саный һәм бу төр әсәрнең татар әдәбияты тарихында яңа күренеш икәнен әйтә.

Утызынчы еллар башында, китап басылып чыкканнан сон унике ел чамасы вакыт узгач, әдәбият белгече Г.Нигъмәти романның беренче варианты турында тирән эчтәлекле зур мәкалә бастыра, «Безнең көннәр» һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый көрәшенең чагылышы» дип аталган бу мәкаләсендә[**] ул әсәрнең идея эчтәлеген, образларын, андагы вакыйгаларны һәм художество сыйфатын төрле яклап анализлый һәм аңа югары бәя бирә.

Романның беренче варианты турында рус матбугатында да күп кенә уңай фикерләр әйтелә[***].

. 1920 елны бу романны, башка китаплар белән бергә, Татарстан республикасының оештыру съезды делегатларына бүләк итеп бирәләр.

Матбугатта уңай бәя алуга карамастан, романның эчтәлеге, әдәби эшләнеше әдипне канәгатьләндерми.

Барыннан да элек, ул әсәрнең идея эчтәлегеннән канәгать түгел. Бу хакта ул романның икенче басмасына язган сүз ахырында түбәндәгеләрне әйтә: «Безнең көннәр» романының беренче варианты моннан егерме ел элек язылып тәмам булган иде... Егерме ел элек дигән сүз – авторның әдәби балачагы дигән сүз... Беренче революция һәм реакция елларындагы сыйнфый сугышларны, иҗтимагый көчләрне ачык, кискен рәвештә, Ленинча-Сталинча аңларлык дәрәҗәгә күтәрелмәгән һәм үзенең иҗат процессында шул аң буенча (Ленинча-Сталинча) әдәби сәнгать эшен алып бару дәрәҗәсенә җитмәгән заманы дигән сүз». Моны ул 1914 елда язылган текстның төп, үзәк кимчелеге итеп саный. Калган кимчелекләр шуның нәтиҗәсендә килеп туганнар дип исәпли.

«Татар хатыны ниләр күрми» хикәясенең үзгәртелгән яңа басмасын матбугатка биргәннән соң, Г.Ибраһимов «Безнең көннәр»не яңабаштан язып чыгу әзерлекләрен күрә башлый. Әдипнең тормыш иптәше Г.Мөхәммәдова 1929 елның икенче яртысында Г.Ибраһимов йомышы белән Казанга кайта

---

[1] *Тәҗәссем иткән* – гәүдәләндерелгән.

[*] «Кызыл Шәрекъ» журналы, Казан, 1920, № 3-4. – Б. 142.

[**] *Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – Б. 92-118.

[***] *Фалев П.* («Наука и просвещение» журналы, Ташкент, 1922, №1), Гобәйдуллин Г. («Вестник татароведения». Казан, 1925, № 1 – 2), Павлович М. («Новый Восток» журналы, Мәскәү, 1926, № 12) һ.б.

һәм аңа, башка китаплар белән бергә, «Безнең көннәр»нең беренче басмасын алып килә. «Күрәсең, Галимҗан бу әсәре турында бик уйланган булса кирәк: беренче басманы өстән генә карап чыкты…

Бу китапның яңабаштан эшләнергә тиешлеген Галимҗан миңа болай аңлаткан иде:

– Марксизм-ленинизм тәгълиматы иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны башкача аңларга өйрәтте. Икенче яктан, татарлар арасында инкыйлаб хәрәкәтләре тарихы өстендә эшләвем күп нәрсәгә яңача бәя бирергә, яңа күз белән карарга мәҗбүр итә. Дөньядагы катлаулы, тирән кузгалышлар, каршылыклар, аяусыз көрәшләр үзлегеннән килеп чыкмыйлар. Беренче редакциядә мәсьәләнең бу ягы тиешенчә күрсәтелмәгән. Әсәрнең алгы планында Давыт Урмановлар түгел, Гәрәй Солтаннар, Зариф Булатовлар торырга тиеш, чөнки болар – иҗтимагый-тарихи вакыйгаларның, көрәшнең үзәгендә кайнаган кешеләр. Болар – большевиклар һәм шулай күрсәтелергә тиешләр дә», – ди Гөлсем ханым үзенең истәлекләрендә*. «Безнең көннәр» романын яңабаштан, икенче вариант итеп эшләп чыгуының сәбәбен Г.Ибраһимов үзе үк «Язучыдан (икенче басмага сүз ахыры урынында)» дигән баш астында бик ачык аңлатып бирә.

Әдип «Безнең көннәр»нең икенче вариантын, чама белән, 1930 елның башында Ялтада яза башлый.

Аның шул көннәрдәге хәле һәм «Безнең көннәр»нең яңа варианты өстендә ничек эшләве турында Г.Мөхәммәдова түбәндәгеләрне яза: «Көндезләрен, мин эштә вакытта... ул, «Безнең көннәр»нең акка күчерелмәгән караламаларын алып, бик җентекләп карап чыга, төзәтмәләр кертә, кайбер җирләрен үзгәртә, кыскарта, аерым бүлекләр яза. Шулай эшли ала иде инде ул»*.

Озакламыйча ул романның яңа варианты өстендә генә түгел, ә калган ике томы өстендә дә эшләргә керешә. Бу турыда ул 1932 елның 5 октябрендә туганнан туган агасы Мохтар Ибраһимовка җибәргән хатында болай яза: «Беләсең, күп еллар буенча «Безнең көннәр» трилогиясе минем алдымда тора. Аның берсе генә чыкты, инде хәзер нәүбәт калган ике томга җитте. Шулар өстендә акрынлап эшләп торам»**.

Г.Ибраһимовның, әле терелеп җитмәвенә, авыру хәлдә булуына карамастан, бик тырышып, бирелеп, «Безнең көннәр»нең ике томы өстендә эшләгәнлеге турында утызынчы еллар башындагы матбугатта да кайбер

---

* Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р.Акъегет – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 403.

* Шунда ук, Б. 404.

** «Совет әдәбияты», 1962, № 3. – Б. 105.

мәгълүматлар бар. Шундыйлардан, мәсәлән, Г.Нигъмәтинең 1932 елда басылган бер мәкаләсендәге түбәндәге юлларны искә алып китәргә мөмкин: «Г.Ибраһимов, коммунист язучы буларак, үзенең электәге әдәби эшчәнлегенә яңадан бәя бирә һәм шуның реаль адымнарыннан тагын бер эш итеп «Безнең көннәр»нең яңа редакциясен хәзерли... Шуның артыннан трилогиянең икенче өлеше дә (икенче томы да. – *А.Ш.)* хәзерләнеп өлгергән. Димәк, совет укучылары якын арада тарихи ике зур том әсәрнең мәйданга чыгуын күрәчәк»[***].

Ниһаять, 1933 елның башында романның беренче томы яңабаштан языльп бетә һәм шул елның язында автор аны басып чыгару өчен Татгосиздатка җибәрә.

Романның ахырында, автор кулы белән язылган: «Ялта, Пирогов санаториясе, 6 декабрь, 1933», – дигән сүзләр бар. Бу дата, күпләр уйлаганча, романның язылып бетү датасы түгел (роман берничә ай элегрәк язылып беткән), ә кулъязма типографиядә наборда чакта автор тарафыннан җибәрелгән суз ахырының тәмамлану датасы.

Шулай итеп, «Безнең көннәр» трилогиясенең беренче томы – яңабаштан язылганы – 1934 елны Казанда басылып чыга. Ә язылып беткән икенче томы белән язылып яткан өченче томы кулъязмаларының язмышы, кызганычка каршы, билгеле түгел. Югалганнармы алар, әллә берәр архив шүрлегендә яталармы – әлегә билгесез.

Романның икенче варианты басылып чыккач, нинди сәбәпләр аркасындадыр, аның турында матбугат битләрендә рецензияләр тиз генә күренми. Әмма соңыннан, беркадәр еллар узгач, әдәбият белгечләре бу әсәрне аерым алып та, шулай ук әдипнең әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге белән тулаем рәвештә бәйләп тә бик күп тикшерделәр, өйрәнделәр, аның идея эчтәлегенә һәм сәнгатьчә эшләнешенә югары бәя бирделәр. Г.Ибраһимовның әдәби-иҗтимагый һәм гыйльми эшчәнлеген аеруча җентекләп өйрәнгән академик М.Хәсәнов бу әдәби җәүһәр турында: «Безнең көннәр» татар әдәбиятында беренче тарихи революцион роман булды, – дип яза. – Ул Ш.Камалның «Таң атканда», К.Нәҗминең «Язгы җилләр» һ. б. татар совет романнарына җирлек әзерләде. Атаклы француз язучысы коммунист Луи Арагонның Г.Ибраһимовның конфискацияләнгән романы татар совет романнарына җирлек әзерләде, дип әйтүе бер дә юкка гына түгел иде»[*], – ди.

«Безнең көннәр» романы әдип исән чакта рус теленә тәрҗемә ителмичә кала. Русча ул бары 1962 елда гына басыла (тәрҗемәчесе Р.Фәизова).

---

[***] *Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – Б. 118.

[*] *Хәсәнов М.* «Галимҗан Ибраһимов». – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 292.

Бу томга урнаштырылган «Безнең көннәр» романының тексты 1936 елда Казанда Татгосиздат тарафыннан чыгарылган өченче басмадан алынды. Ул басманы автор үзе карап һәм беркадәр төзәтүләр кертеп чыгарган. Текст 1934, 1976 елларда чыккан басмалар белән чагыштырылды. 1976 елда чыккан басмада теге яки бу сәбәп белән төшерелеп калдырылган бүлекләр өстәлде.

1936 елгы басмада автор рөхсәтеннән башка төшерелгән һәм аны заманында бик борчуга салган берничә юл текст бар иде. Аны бу басмага кертергә кирәк табылды. Ул «Язучыдан» дип аталган сүз ахырында, 435 биттә: «Яшь укучыларга ул заманнан бер материал күрсәтү өчен...» дип башлана, «Кави Нәҗми белән Башкиров иптәшләргә күрсәтеп таныкландырдым» дип тәмамлана.

[1] *Бөек Франция революциясенең конвент көннәре...* – 1789-1794 еллардагы француз буржуаз-демократик революциясенең закон чыгаручы һәм аны тормышка ашыручы милли югары орган күздә тотыла.

[2] *... 48 нче елга сикереп, Париж баррикадаларына килде...* – Автор 1848-1849 елларда Франциядә булган буржуаз демократик революциягә һәм баш күтәргән халык тарафыннан Париж урамнарында алып барылган сугышларга – баррикадаларга ишарәли.

[3] *Коля* – Николай Кадомцев. Бу образның прототибы 1905-1907 елларда революция хәрәкәтендә актив катнашкан, Уралда сугышчан дружиналар оештырган Николай Кадомцев.

[4] *«Инде конституция булды!..»* – (5 иче искәрмәне карагыз).

[5] *... манифест чыкканнан бирле...* – Сүз 1905 елның 17 Октябренда Николай II тарафыннан чыгарылган манифест турында бара. 17 нче октябрь манифесты Бөтенроссия Октябрь сәяси стачкасы вакытында халыкның күзен томалау өчен чыгарыла. Анда халыкка сүз иреге, шәхес азатлыгы, җыелышлар ясау, җәмгыятьләр һәм союзлар төзү иреге, шәхес иминлеге бирү турында һ.б. вәгъдәләр бирелсә дә, аларның берсе дә тормышка ашмый. Патша хөкүмәте аны, илдә революцион хәрәкәтнең дәһшәтле рәвештә көннән-көн көчәя баруыннан куркып, самодержавиене саклап калу максаты белән чыгарырга мәҗбүр була һәм биргән вәгъдәләрнең барысын да соңыннан юкка чыгара.

Манифестта шулай ук закон чыгарырга хаклы булган Дәүләт думасы – «Россия парламенты» булдыру турында да әйтелә. Буржуаз һәм вак буржуаз партияләр – кадетлар, меньшевиклар, эсерлар – бу конституцион иллюзияне мактап, чын конституция бирелде дип, лаф оралар. Чынлыкта конституция бирелми. Дума да өзлексез куылып, таратылып тора. Большевиклар бу манифестның ялган булуын халык арасында фаш итәләр.

[6] *«Боже, царя храни...»* – патша заманында Россия дәүләтенең гимны.

[7] *Вихри враждебные воют над нами* – «Варшавянка» исемле революцион җырның беренче юлы. Җырның беренче текстын 1883 елда поляк революционер-шагыйре Вацлав Свенцицкий иҗат итеп, полякларның революцион газетасында бастырып чыгарган. 1897 елда атаклы революционер, коммунист М.Г.Кржижановский (1872-1959) Мәскәүдә, Бутырская застава төрмәсендә утырганда, полякча текстны русчага тәрҗемә итеп, яңабаштан эшләгән, эчтәлеген баеткан, революцион рухын көчәйткән. Бөек Октябрь революциясенә чаклы Россиядә революцион эшчеләр арасында бик таралган җырларның берсе.

[8] *«Мөселман иттифакы» партиясе* (“Иттифак әл-мөслимин”) – Россия мөселманнарының либераль-демократик партиясе. Ул мөселманнарның 1905 елның 15 августында булган 1 съезды карары белән төзелә. Партия, кадетлар тоткан сәясәткә кушылып, конституцион монархия идеясен яклый. Бу сәяси оешма төп бурыч итеп ислам динен пропагандалауны куя.

[9] *Ротшильдләр* – финанс магнатлары династиясе, банкирлар. XIX гасыр башларында Вена, Лондон, Париж һәм Европаның башка шәһәрләрендә банклар ачып, бик күп илләрнең финанс эшләрен үз кулларында тоткан капиталистлар.

[10] *Максималист* – 1904 елда эсерлар партиясе эчендә барлыкка килгән вак буржуаз группа члены.

[11] *Меньшевик* – РСДРПның 2 нче съездында азчылыкны тәшкил иткән сәяси франкция тарафдары. Сайлап куелган үзәк җитәкчелегенә берсүзсез буйсыну тәртибенә (централизмга) каршы торучылар. 1917 елдан мөстәкыйль партия. 1923 елда меньшивиклар партиясе эшчәнлеге тыела.

[12] *Алафузов, Крестовников заводлары* – Казанда XIX гасыр уртасында үсеп киткән сәүдә-сәнәгать оештыручы һәм инкыйлабка кадәр Россиянең иң эре сәүдәгәр-капиталистлары булып саналган Алафузов һәм Крестовниковларның завод-фабрикалары күздә тотыла.

*Алафузов И.И.* (1839-1891), I нче гильдия Казан сәүдәгәре, фабрикант. 1858 елда уртак пайда “Казан күн эшкәртү заводы ширкәте”н оештыра. 1865 елда “Казан җитен эрләү-туку фабрикасы”н нигезли. Башка шәһәрләрдә дә завод-фабрикалар ача. 1870 еллардан Алафузов Россиянең иң эре сәнәгатьчеләреннән санала. Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте акционерлык җәмгыяте 1894 елда оештырыла.

Ширкәткә Казанда җитен эрләү-туку фабрикасы, 2 йомшак күн эшләү заводы, җилем кайнату һәм газ заводлары, аяк киемнәре тегү, икмәк пешерү йорты һ.б. керә. Боларда 1913 елда 6500 кеше эшли. 1918 елда Совет хөкүмәте декреты нигезендә ширкәт милке дәүләт тарафыннан үзләштерелә. Соңрак ширкәтнең Казан предприятияләре җирлегендә “Казан җитен

комбинаты” оештрыла.

*Крестовниковлар.* Мәскәү һәм Казан сәүдәгәрләре, эшмәкәрләр. Сәүдәгәрләр династиясен нигезләүче булып I нче гильдия сәүдәгәр К.В. Крестовников (1755-1814) тора. 1772 елда Мәскәүгә күчеп китә. Шикәр, буяу заводлары һәм туку фабрикасы ача. 1851 елда аның балалары Мәскәү сәүдәгәрләре. Оныклары “Бертуган Крестовниковлар һәм К°” оештыралар һәм 1855 елда Казанда “Шәм-стеарин, сабын кайнату, глецирин җитештерү һәм химия заводы” ачалар. Сәнәгатьнең бу өлкәсе тулысынча алар кулында була һәм киң үсеш ала. Октябрь инкыйлабыннан соң Крестовниковлар заводы биналары комплексы дәүләт карамагына ташшырыла. Яңабаштан үзгәртеп корыла. Совет чорында “Мулланур Вахитов исемендәге химия комбинаты” дип атала. Хәзерге көндә “Нәфис Косметик” АҖ дип йөртелә.

[13] *Эсерлар* (социаль-революционерлар партиясе) – Россиядә народниклар төркемнәре һәм түгәрәкләре бергә оешудан туган (1902) вак буржуаз партия. Алар капиталистларның хосусый милкенә кагылмыйча, җирне крестьяннарга бүлеп бирүне тәкъдим итә. Г.Ибраһимов, хаклы рәвештә, аны элекке народникларның яңа формациясе, ягъни буржуазиянең сул фракциясе дип атый.

[14] *«Мәкамәте Хәрири»* – Иранда туган гарәп шагыйре һәм әдибе Әбү Мөхәммәд әл-Касыйм ибн Гали әл-Басрый әл-Хәриринең (1054 – 1122) шаян новеллалардан торган, гасырлар буе әдәби камиллек үрнәге саналган мәкамнәр циклы. Мәкам жанры урта гасыр гарәп әдәбиятында киң таралган була. Аның үзенчәлеге шигырь белән аралаштырылган рифмик проза кулланып язылуында. Хәрири үз заманында бу жанрның остасы булып танылa. Аның мәкамнәрендә сюжет зирәк акыллы төп герой Әбү Зәед әс-Сәрүҗинең маҗараларын сөйләүгә корылган. Ул һәр мәкамдә төрле кыен ситуацияләрдән оста чыга алучы, үткен телле, хәйләкәр дә, үзен тыңларга җыелган халыкны авызына каратып тота алырлык шаян хикәяләр, анекдотлар сөйләүче итеп сурәтләнә. Мәкамнәрдә төп герой хәйләкәр һәм мут кеше генә түгел, бер үк вакытта ул гыйлем иясе дә, шәригатьне дә әйбәт белә, үзе шагыйрь–импровизатор, ораторлык сәнгатенә дә ия, үз чыгышларында ул зирәк акыл һәм киң белемгә ия икәнен дә демонстрацияли. Хәриринең мәкамнәре беренче тапкыр Ливанның Бәйрут шәһәрендә басылып чыккан бу шигъри әсәр гасырлар дәвамында гарәп әдәбиятында сәнгатьчә камиллекнең югары ноктасы булып исәпләнгән. Татарлар арасында кульъязма хәлендә күчермәләре киң таралган.

[15] *Ишми ишан* – Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт (1849-1919), дин эшлеклесе, кадимчелек вәкиле. Вятка губернасы Түнтәр авылында (хәзер Татарстанның Балтач районына карый) мәдрәсә тоткан, мулла. Алдынгы

фикерле татар дин әһелләренә, яңа ысул белән эшләүче мәдрәсәләргә (“Буби” һ.б.) каршы эш алып бара. 1919 елда большевиклар тарафыннан атып үтерелә. Дини эчтәлекле китаплар авторы.

[16] *Кышкарчы Вәли мулла* – Вәли мулла – Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап, Оренбург шәһәрендәге кадим мәдрәсәдә дамелла булган кеше. Вәли мулла мәдрәсәсе дип аталган, кадимлеге, яңалыкка, прогресска каршылыгы белән дан тоткан бу мәдрәсәдә Г.Ибраһимов унбер яшеннән унсигез яшенә чаклы укыган һәм ахырда аннан куылган. Бу турыда әдип үзе: «яңа фикерле булуым һәм уку-укыту эшендәге көнчыгыш-схоластик нигезләргә каршы көрәшкән өчен куылдым»*, – дип яза.

*Кышкар мәдрәсәсе* – Татарстанның хәзерге Арча районы Кышкар авылы мәдрәсәсе XVIII гасыр урталыгыннан алып 1918 елга кадәр яшәп килә. Телләр, дини гыйлемнәр укыту белән бергә, мәдрәсәдә формаль логика-мантыйк укытуга зур игътибар бирелә. Мәдрәсәдә бәхәсләшү, моназараләр уздыру белән данлыклы була.

Кышкар мәдрәсәсендә Тукайның этисе Мөхәммәтгариф, бабасы – Зиннәтулла Әмиров, Уральскидан Мотыйгулла хәзрәт Төхвәтуллин, драматург Ф.Халидиләр укый. Биредә Россиянең күп кенә башка төрки халык вәкилләре дә белем ала.

[17] *Каргалы... мәдрәсәсе...* – Оренбург губернасының Каргалы авылында (Сәгыйть бистәсендә) XVIII гасырның урталарында ачылып, Октябрь революциясенә кадәр яшәп килгән кадим мәдрәсәләрнең берсе; суфизм идеяләрен тарату үзәге. Заманында бу мәдрәсәдә татар шагыйрьләреннән Һибәтулла Салихов (1794 – 1867) һәм Шәмсетдин Зәки (1825 – 1865) укыткан.

[18] *Хозыр Ильяс* – Ислам дине мифологиясендә изге җаннарның берсе, легендар пәйгамбәр. Имеш, ул “тереклек суы” эчеп мәңге яшәү хәләтенә ирешкән. Ул халык арасында күзгә күренмичә яши, бәла-казага очраган мөселманнарга ярдәм итә, көтмәгәндә берәр юлчы карт сыйфатында килеп чыгып изгелекләр эшли, аларны бәладән коткара, кыен мәсьәләләрне дөрес хәл итү юлын өйрәтә дә, үзе шундук күздән югала, имеш.

[19] *Кадер һәм Мәүлед бәйрәме – Кадер кич* – рамазан аеның 27нче төнендә билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме. Ислам өйрәтүләрендә Мөхәммәд пәйгамбәргә Коръән аятьләре шушы төндә иңдерелә башлаган дип аңлатыла. Кадер кичендә мөселманнарның дога укып теләгән теләкләре кабул ителер, тәүбә кылган бәндәнең барлык гөнаһларын Аллаһы Тәгалә ярлыкар, дигән Мөхәммәд с.г.в. Шуңа күрә мөселманнар, гадәттә, бу төнне йокламый

---

* Ибраһимов Г., «Казан утлары» журналы, 1967, 2 нче сан. – Б. 4.

үткәрәләр: мәчеттә намаз укып дога кылалар, Коръән укыйлар. Бу кичәдә изге гамәлләрнең сәвабы башка кичәләргә караганда күп тапкыр артык икән. Г.Тукай үзенең "Кадер кич" шигырендә болай ди:

Бу кадер кич елда бер кич – барча кичләр изгесе,

Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе.

*Мәүлед бәйрәме* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне бәйрәме. Ай елының өченче – рабигыль-әүвәл аеның 12 нче кичендә билгеләп үтелә. Мәүлед бәйрәмендә мөселманнар мәчетләрдә пәйгамбәргә багышлап хөтбәләр укыйлар, вәгазьләр сөйлиләр.

[20] *Даут пәйгамбәр* – Коръәндә телгә алынган пәйгамбәр һәм падишаһ. Риваятьләргә караганда, Аллаһның якын иткән идарәчесе, фикер иясе һәм тел остасы. Имеш, ул көчле һәм бик матур көйле тавышлы (татлы тавышлы) булган. Библиядәге Давидка нисбәтләнә.

[21] *Зубатов методы* – патша хөкүмәтенең XX гасыр башында эшчеләр хәрәкәтенә карата тоткан сәясәте; эшчеләрне самодержавиегә каршы алып барган революцион көрәштән читләтү өчен, алар арасында патша хөкүмәтен яклый торган легаль эшчеләр оешмалары булдыру, бу оешмаларны яшерен рәвештә полиция һәм жандарм күзәтүе астында тоту, эшчеләрнең политик аңнарын үстермәү, аларның таләпләрен бары экономик таләпләргә генә кайтарып калдырырга тырышу. Эшчеләр сыйныфының үскәннән-үсә барган революцион хәрәкәте нәтиҗәсендә патша хөкүмәте мондый легаль оешмаларны бетерергә мәҗбүр була.

[22] *Тәүрат ...* – яһүдләрнең төп дини китабы. Ул Коръәнгә кадәр индерелгән дип исәпләнелә һәм Муса пәйгамбәргә нисбәт ителә.

[23] *Саммер* – Саммер И.А. (1870 – 1921), 1904 – 1907 елларда Казанда эшчеләр хәрәкәтендә актив катнашкан, аның җитәкчеләреннән берсе булган, ленинчы большевик. Ул Казанга 1904 елның октябрендә, В.И.Ленин җитәкчелегендәге Үзәкнең заданиесе белән килә һәм Казан РСДРП комитетының җаваплы оештыручысы булып эшли. Партиянең 1905 елны Лондонда үткәрелгән III съездында Казан оешмасыннан делегат булып катнаша һәм шунда Үзәк Комитет членлыгына кандидат итеп сайлана. Казанга килгәнче дә һәм соңыннан да ул күп кенә җаваплы урыннарда эшли, төрмәләрдә утыра, сөргеннәрдә була... 1921 елны, И.А.Саммер вафат булганнан соң, «Правда» газетасы аның турында: «...Иван Адамовичны без Казандагы восстаниенең юлбашчысы, ялкынлы трибуны итеп һәм шул ук вакытта эшчеләр һәм укучы яшьләр тарафыннан берничә көнгә (19-21 октябрьдә) яулап алынган шәһәрдәге революцион властьның вәкиле итеп тә

күрәбез»*, – дип яза.

[24] *Штрейкбрехерлек* – капиталистик илләрдә забастовка вакытында, эш ташламыйча, хуҗаларга ялланып, эшчеләр мәнфәгатенә хыянәт итү.

[25] *«Сада» көе* – 1905-1907 еллардагы революция дәверендә мәдрәсә реформасын даулаган шәкертләр тарафыннан чыгарылган көй. Авторы билгесез.

[26] *Истанбулда, Солтан Хәмид истибдадында ...* – Габделхәмид (1842-1918), 1876-1909 елларда Төркия солтаны. 1878 елда Төркиянең дәүләт мәҗлесен (парламентын) тарата, конституцияне гамәлдән чыгара, илдә деспотизм урнаштыра. Залимлыгы, реакционлыгы бедән солтанны Ленин “Төркиянең Николай Второе” дип атый.

[27] *«Марсельеза»* – французларның революцион җыры, Франциянең дәүләт гимны. Текстын һәм музыкасын француз шагыйре һәм композиторы Руже де Лиль (1760 – 1836) язган. Россиядә, беркадәр үзгәртелеп, XIX гасырның 80-90 нчы елларында тарала башлый. “Марсельеза”ны татарчага С.Рәмиев тәрҗемә итә. Җырның беренче куплеты:

Ташлыйк, туганнар иске тормышны,
Ул тормыштан илгә файда юк.
Булса, байлар илә тик түрәләр
Аркабызда рәхәт күрәләр.

[28] *Гали, игъдади, рөшди сыйныфлар* – Октябрь инкыйлабына кадәр яшәп килгән җәдит мәдрәсәләрендәге сыйныфлар. *Гали* – югары белем алу сыйныфы; уку срогы – ике ел. *Игъдади* – югары белем алуга әзерлек сыйныфы; уку срогы – ике яисә өч ел. *Рөшди* – урта белем алу сыйныфы; уку срогы – дүрт ел.

[29] *Мәкәрҗә* – Мәкәрҗә ярминкәсе, Россиядәге иң зур ярминкәләрнең берсе. XVI гасыр урталарында Идел буендагы Макарьев монастыре янында барлыкка килгән, 1849 елда Нижний Новгород шәһәре янына күчерелгән. Нижний Новгород шәһәрендә һәр елның июль-август айларында уздырыла торган була. Анда бөтен Россия шәһәрләреннән һәм чит илләрдән сәүдәгәрләр, бигрәк тә татар сәүдәгәрләре яратып йөргән. Ярминкәдә сату-алудан тыш күңел ачу һәм тамашалар уздырылган. Ярминкә вакытында шәкертләр һәм ярлы халык байларга хезмәт күрсәтеп бераз акча эшләгән. Бу базар элегрәк Макарьевода булганлыктан, татарлар арасында искечә Мәкәрҗә исемен саклаган. Тарихтан билгеле булганча, бу ярминкә асылда шәһре Болгардан Казанга күчерелгән базарның дәвамы. Мәкәрҗә ярминкәсе 1929 елда бөтенләй ябыла.

---

* «Правда», № 139, 1921, 29 июнь.

[30] “*Ясин”* – Коръәннең 36 нчы сүрәсе. Бу сүрәне дин тотучылар кеше үлем түшәгендә ятканда, кешенең баш очында, мәет өстендә укыйлар һәм аны ясин чыгу дип атыйлар. Шулай ук кемне дә булса ерак юлга озатканда, аңа яхшылык, уңышлар теләп ясин сүрәсен укыйлар.

[31] *“Тәбарәк”* – Коръәндә Алланың мәрхәмәтлелеген, шәфкать иясе булуын мактаган 67 нче – “Мөлек” сүрәсенең халык телендәге исеме.

[32] *«Беренче сада»* – мәдрәсә реформасын таләп иткән шәкертләр тарафыннан чыгарылган җыр; шәкертләр «Марсельеза»сы. Беренче тапкыр Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә җилем басмада яшерен рәвештә чыккан «Әльислах» газетасында басыла, шуннан Россиядәге барлык татар мәдрәсәләренә тарала. 1907 елда аны Оренбургта «Шәкерт садалары» исемле китапка кертеп басалар. Ләкин Оренбург жандармериясе бу китапны басылу белән үк җыеп ала, хәтта Казанга җибәрелгән өлешен дә юлда конфискацияли. «Беренче сада» һәм «Икенче сада» полиция тарафыннан тыелган җырлар исемлегенә кертелсә дә, шәкертләр арасында кульязма хәлендә йөри.

[33] *«Фидаиләр»* – 1905-1907 еллардагы революция вакытында кайбер мәдрәсәләрдә шәкертләр тарафыннан оештырылган, эсерлар партиясе тәэсирендә булган вак буржуаз оешма.

[34] *Пантюркизм* – төрки телдә сөйләшүче халыкларны этник һәм мәдәни бердәмлеккә өндәгән иҗтимагый-сәяси хәрәкәт XIX йөз ахырында Төркиядә барлыкка килә. Төрки халыкларны бер милләт кешеләре дип санап, Төркия дәүләте кул астына тупларга омтылган милләтчеләр идеологиясе. Татар милли хәрәкәтендә партюркизм киң мәгънәдә кабул ителә: милли үзбилгеләнүгә ирешү, милли мәдәниятне, милли үзаңны үстерү, башка төрки халыклар белән якынаю һ.б.

[35] *Панисламизм* – мөселманнарның Алла каршында бертигез булуын, аларның бердәмлеге нигезендә бер дәүләткә берләштерү зарурилыгын алга сөргән дини-сәяси идеология. Ул мөселман халыкларын колониаль изүдән коткару чарасы буларак формалаша. Аның нигезендә ислам динендәге халыклар милләтләргә, сыйныфларга бүленмиләр, алар бер милләт кешеләре, алар арасында байлар да, ярлылар да юк, шулай булгач, аларның барысын да бер мөселман хәлифәте кул астына тупларга кирәк дигән караш ята. Шул рәвешле панисламчылар мөселман халыкларын Ислам байрагы астында тупланып мөстәкыйльлек өчен актив көрәш алып барырга чакыралар, социаль, икътисадый һәм мәдәни үсеш максатында империалистик дәүләтләргә бәйлелектән котылуның зарурлыгын алга сөрәләр.

Панисламизм идеясе XIX гасыр азагында төрек мәгърифәтчесе Нәмык Кәмал (1840-1888) хезмәтләрендә чагылыш таба. Иранда дини-сәяси эшлекле

Җамалетдин Әфгани, Мисырда Мөхәммәд Габдеһ панисламизм идеясен таратуга күп көч куялар. Колониаль богаулардан азатлыкны күз алдында тоткан бу хәрәкәт Россия мөселманнары, татарлар арасында да билгеле бер күләмдә чагылыш таба, әмма киң таралыш алмый. Патша хөкүмәте дә мөселманнарның (бигрәк тә татарларның) Төркия кул астында берләшеп бердәм ислам дәүләте төзүенә ышанып бетмиләр. Шулай да татарлар арасында сәяси эшчәнлекнең активлашуы, төрле сәяси партияләр, иҗтимагый-сәяси оешмалар барлыкка килү фактлары, панисламизм идеясе Россия дәүләте өчен куркыныч дип игълан ителә.

[36] *Әхмәд Мидхәд* (1844-1913) – төрек язучысы, публицист, тарихчы, мәгърифәтче, төрек әдәбиятында кыска хикәягә һәм романга нигез салучы. Романнар, хикәяләр, пьесалар һәм шулай ук тарих, дин, философия, география мәсьәләләренә багышланган китаплар авторы.

[37] *Солтан Габделхәмид* (1842-1918) – Бу турыда ... биттәге 26нчы искәрмәне кара.

[38] *«Иттифак» төзисез дә урыс кадетлар белән берләшәсез ...* – “Иттифак” (“Иттифак әл-мөслимин”, “Мөселман иттифакы”) – Россия мөселманнарының либераль-демократик юнәлешле сәяси партиясе. 1905 елда 15 августта булган Бөтенроссия мөселманнарының беренче съезды карары белән оештырыла. Кадетлар тоткан сәясәткә кушылып, конституцион монархия идеясын яклый.

“*Кадетлар*” (Конституцион – демократлар партиясе) 1905-1907 елгы инкыйлаб нигезендә барлыкка килә. Беренче съездлары 1905 елда Мәскәүдә була. Россиядә империалистик буржуазиянең төп партиясе.

“Мөселман иттифакы” лидерлары да партиянең программасын төзегәндә кадетлар программасын нигез итеп алалар. Шул рәвешле “Мөселман иттифакы”ның программасы руслар белән мөселманнар арасында мәдәният һәм диннәрнең тигез хокуклыгын тәэмин итү, конституцион хөкүмәт төзү һәм мәгариф өлкәсендә автономиягә ирешү кебек принциплпрны үз эченә ала. Бу рус буржуазиясенең таләпләренә якын торган принциплар төрки-татар партиясе буларак формалашкан “Мөселман иттифакы” әгъзаларын үзенә җәлеп иткән. Г.Ибрагимов биредә шуңа ишарәли.

[39] *Мисырлы Касыйм Әмин бәкнең “Тәхрир әл-мәрьәт” атлы китабы...* – Касыйм Әмин (1865-1908), язучы һәм публицист. Милләте белән көрд. Мисырда туа һәм шунда гомер кичерә. Гарәп телендә яза. Белеме буенча хокук белгече, төп шөгыле – юристпруденция. Аның 1899 елда дөнья күргән “Тәхрир әл-мәрьям” (“Хатын-кызны азат итү”) дип аталган беренче китабы басылып чыгу белән үк матбугатта кайнар бәхәсләр кузгата, шау-шулы полемикага сәбәпче була.

[40] *Фараби* – Әбү Насыр Мөхәммәд ибне Тархан Узлаг әл-Фараби әт-Төрки (870-950), мәшһүр философ, энциклопедист галим. Аристотель тәгълиматын дәвам иттерүче, көнчыгыш фәлсәфи фикеренең күренекле вәкиле.

[41] *Ибне Сина* – Әбү Гали Хөсәен ибне Габдуллаһ ибне Сина (980-1037), Урта Азиянең бөек энциклопедист галиме. Көнчыгышның, гомумән, ислам галәменең мәшһүр философы, табиб. Фәлсәфәсендә Аристотель традициясен дәвам иттерүче. Бөтен дөньяда шөһрәт казанган хезмәтләре фәннең төрле өлкәсенә карый: фәлсәфә һәм математика, асторония һәм физика, химия һәм биология, медицина һәм фармакология, филология һәм лингвистика. Шулай ук ул музыкант һәм шагыйрь дә була.

[42] *Ибне Рөшд* – Әбү Вәлид Мөхәммәд ибне Әхмәд ибне Рөшд (1126-1198), Испаниянең Кордова шәһәрендә туа. Гарәп-мөселман философы һәм табибы. Энциклопедик галим, хокук белгече, табиб, кояшны өйрәнүче күренекле астрономия галиме. Шәрекътә Аристотель тарафдарларының күренекле вәкиле.

Татар фәлсәфәсендә һәм дин гыйлемендә XX йөз башына кадәр Ибн Рөшднең фәлсәфи тәгълиматы киң таралган була.

[43] *Җамалетдтн Әфгани* – Әфгани Җамалетдин (1893-1897). Гарәп Көнчыгышында Исламны яңарту, төп асылына кире кайту хәрәкәтенә нигез салучы, күренекле әфган галиме һәм сәяси эшлеклесе. Әфганинең төп максатларыннан берсе – Якын һәм Урта көнчыгыш мөселман дәүләтләренә мөстәкыйльлек яулап алу була.

Мөселман илләрен колониаль изүдән коткару чарасы буларак, Корьән өйрәтүләре нигезендә берләшергә, Ислам байрагы астында тупланырга һәм мөстәкыйльлек өчен актив көрәш алып барырга чакырган хәрәкәтнең идеологы да Җ.Әфгани була. Ул панисламизмга нигез салучыларның берсе.

Ислам өлкәсендәге күренекле галимнәребез Ризаэтдин Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Зыя Камали һ.б.ның дөньяга карашлары формалашуга да Әфганиның йогынтысы зур була. Ул Көнчыгышның мөселман дәүләтләре һәм Россиянең мөселман халыклары арасында милли-азатлык хәрәкәте формалашуына да сизелерлек эз калдыра.

Әфганинең төп хезмәтләре татар теленә XX гасыр башында ук тәрҗемә ителгән. Аның эшчәнлеге турында шактый мәкаләләр татар матбугаты битләрендә дөнья күргән.

[44] *Мөхәммәд Габдеһ* – Габдеһ Мөхәммәд (1849-1905), Мисырда мөселман яңарышының күренекле галиме. Ул – панисламизмга нигез салучы Җамалетдин Әфганинең актив көрәштәше. Үзенең хезмәләрендә Исламга реформа ясарга, аны җәмгыятьтәге яңа мөнәсәбәтләргә яраштырырга омтыла, дини йолаларны гадиләштерергә тәкъдим итә. Ислам догматларын акылга

ятышлы һәм заман таләпләренә туры китереп аңлатырга тырыша, тәкъдир турында өйрәтүләрне кире кагып, табигать һәм җәмгыятьнең үсеш закончалыкларын таный, ул закончалыкларны “Аллаһ акылы”ның чагылышы итеп карый. Шәригатькә реформа ясауга да зур тырышлык куя. Мөселман халыклары конфедерациясе рәвешендә хәлифәтне торгызу идеясен күтәреп чыга.

[45] *Бубыйлар* – 1895-1911 елларда Иж-Бубый мәдрәсәсе җитәкчеләре – бертуган Габдулла, Гобәйдулла, Мөхлисә Нигъмәтуллиннар. Алар мәдрәсәдә белем бирүне үзгәртеп коралар, җәдитчә укытуны гамәлгә ашыралар. XX йөз башы татар дини ислахчылык фикерен формалаштыруга шактый зур өлеш кертәләр. 1911 елда мөдәррис һәм шәкертләр панисламизмны таратуда гаепләнә һәм Идел буе төрки халыкларның мәгърифәт учагы булган мәдрәсә ябыла.

*Габдулла Бубый* (Нигъмәтуллин, 1871-1922) – дин галиме, педагог. Дин гыйлеме буенча хезмәтләр авторы.

*Гобәйдулла Бубый* (Нигъмәтуллин, 1866-1936) – педагог, мөдәррис, табигать фәннәре мөгаллиме. 1898-1917 елларда күп тапкырлар нәшер ителгән география, физика, табигать белеме, этика, татар теле дәреслекләре авторы.

*Мөхлисә Бубый* (Нигъмәтуллина, 1869-1937) – дин әһеле һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог. Иж-Бубый авылында хатын-кызлар мәктәбе оештыра; анда Россиянең күп кенә төрки халык вәкилләре укый. Мәктәп асылда татар халкының беренче хатын-кызлар гимназиясенә әверелә.

[46] *Бигиләр* – Муса Ќаруллаһ Бигиев (1875-1949), күренекле дин галиме һәм актив җәмәгать эшлеклесе, дин һәм хокук белгече. Россия мөселманнарының милли азатлык хәрәкәтенең актив эшлеклеләренең берсе. “Мөселман иттифакы”н оештыручы либераль-буржуаз идеологларының берсе. М.Бигиевнең фәнни-иҗади хезмәтләренең күпчелеге дин мәсьәләләренә багышланган. Аларда ул шәригатьнең бүгенге дөньяда (үз заманы өчен Ђ.А.) тоткан урынын билгеләргә тырыша һәм Коръәнне, шәригать законнарын хәзер дә нәтиҗәле файдаланырга мөмкин дигән нәтиҗәгә килә. Иҗади эшчәнлегенең тәүге адымнарында ук ул, Габдрәшит Ибраһимов белән бергә “Ислам социализмы” концепциясен эшли һәм исламның социализмга каршы түгеллеген исбатларга тырыша. Аның кайбер хезмәтләре хокук, әдәб-әхлак мәсьәләләрен яктыртса, күп кенә хезмәтләре татарлар арасындагы иҗтимагый хәрәкәтләрне, халык тормышында бара торган вакыйгаларны, сәяси агымнарны барлауга багышланганнар. “Исламият әлифбасы” (1923) дигән хезмәтендә М.Бигиев татар иҗтимагый үсешенә күзәтү ясый һәм Ислам берлеге идеясен яклап чыга.

[47] *Мөнкир-Нәнкир* – Мөнкир белән Нәкир, кабердә мәеттән сорау алучы фәрештәләр. Ислам дине өйрәтүләре буенча, мәетне җирләп күмүчеләр кырык адым җир киткәч, мәет каберендә терелә имеш һәм аның янына ике фәрештә – Мөнкир белән Нәкир килеп сорау алачаклар, газаплаячаклар. Һлгән кешенең җавапларыннан чыгып бу ике фәрештә аның оҗмахлымы яисә тәмуглымы икәнен ачыклап гамәл дәфтәренә язып куячаклар, имеш.

[48] *Җәбраил* – Ислам тәгълиматларында Аллаһы Тәгаләгә якын фәрештәләрнең берсе. Кешеләргә яхшылык эшли торган фәрештә исеме. Җәбраил фәрештә пәйгамбәрләргә Алланың вәхиләрен – хәбәрләрен җиткерә. Адәм балалары Җәбраил фәрештәне үзләренә бик якын зат, яклаучы һәм саклаучы итеп кабул итә.

[49] *Бәни Ъсфәр дигән кавем* – дини мифологиядә ахырзаман алдыннан дөньяны басып алачак кавем, сары раса дип тә атыйлар.

[50] *Дәҗҗал* – борынгы гарәп һәм ислам мифологиясе персонажы. Коръәндә телгә алынмый. Ахырзаман белән бәйле кыйссаларда сөйләнелә. Аның эш-гамәлләре Иблис белән бәйләнгән – ул адәм балаларын юлдан яздыручы. Мөселман хәдисләрендә ул океан уртасындагы утрауда кыя-ташка кадакланган дип күрсәтелә. Йәэҗүҗ–Мәэҗүҗ Искәндәр патша корган диварны җимергәч Дәҗҗал үзенең тоткынлыгыннан котылачак һәм аның артыннан кяферләр, монафыйклар ияреәчәк. Дәҗҗал үз юлында мәчетләрне җимереп, мөселманнарны туган җирләреннән куачак. Ләкин аның хакимияте 40 көннән артмаячак, имеш. Аңа каршы Мәһди чыгып Дәҗҗалны үтерәчәк, имеш.

[51] *Мәһди* – дөрес юлдан алып баручы. Дини ривайәт буенча Мәһди чыгып азгын халыкларны туры юлга салачак имеш. Сөнни мөселманнар карашынча, ахырзаман алдыннан җир йөзенә килергә тиешле зат, мөселман коткаручысы, Мөхәммәд пәйгамбәрнең соңгы дәвамчысы. Шигыйлар ышануынча да Мәһди имам кайтып пәйгамбәрнең эшен дәвам итәчәк, Ислам дине әүвәлге хәленә кайтарылачак. Җирдә гаделлек һәм тигезлек урнашачак, кешеләр хак юлдан барачак, дип аңлатыла.

Шушы идеясе аркасында шигыйчылык ислам дине тарихының билгеле бер чорында халык массаларының социаль гаделлек турындагы өметләрен чагылдырган. Мәһди имам кайтыр дигән ышану җәмгыятьне социаль үзгәртеп кору идеясенә әверелгән.

[52] *Гайсә күктән иңәчәк* – Гайсә пәйгамбәр. Христиан динендә исә ул Иисус-Христос – Алла, Аның Улы һәм Изге Рух итеп сурәтләнә.

Коръән өйрәтмәләре буенча Гайсә пәйгамбәр җиргә Аллаһ Тәгалә тарафыннан хак динне – ислам динен тарату өчен җибәрелгән мөселман пәйгамбәре. Ул үз тирәсендәге халыкларны ислам динен кабул итәргә үгетли.

Дини риваятьләрдә кяферләр (яһүдләр) Гайсәне үтерергә телиләр. Ләкин Аллаһ Гайсәне саклап кала, аны күккә күтәрә. Гайсә пәйгамбәр, Мәһди кебек үк ахырзаман якынлашуын хәбәр итүче буларак, Аллаһ кодрәте белән яңадан җиргә иңәчәк дип ышаналар.

[53] *Йәэҗүҗ–Мәэҗүҗ* – Коръәннең 18 нче (Мәгарә) сүрәсендә телгә алынган ике явыз зат (халык), дини мифологиядә фантастик варвар кабиләләр. Алар кояш чыгышы ягында – “җир читендә” яшиләр һәм кешеләргә һәрвакыт яманлык эшләргә әзер торалар, имеш. Кешеләрнең үтенүе буенча, Искәндәр патша (Зөлкәрнәйн) Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗне чыгартмас өчен биек дивар кора. Дөнья бетәр алдыннан бу дивар җимерелеп, явыз затлар кешеләр янына юл тотачаклар, җирне яулап алып, елга-күлләрнең суын эчеп бетерәчәкләр, ләкин Аллаһы Тәгалә аларның үзләрен дә юк итәчәк имеш.

[54] *“Даббәтел΄әзр” чыгачак* – ахырзаман алдыннан дөньяга чыгачак мифик зат, бөтен җир йөзен ашап-кырып бетерәчәк имеш.

[55] *Муса таягы* – Муса пәйгамбәрнең төрле могҗизалар күрсәтү көченә ия булган тылсымлы таягы (җиргә ташлагач ул еланга әверелгән, дәрья өстенә шушы таяк белән суккач, су икегә аерылып юл ача алган һ.б.). Бу турыда Коръәндә дә искә алына.

[56] *Сөйләйман йөзеге* – дини мифология буенча Сөйләйман пәйгамбәрнең тылсымлы йөзеге булган. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме арасыннан иң бөек исеме язылганга бу йөзек иясе җен-пәриләрне, кош-кортларны, җил-суларны үз ихтыярына буйсындырырлык кодрәткә ия булган. Сөйләйман йөзеге ярдәмендә теләсә нинди теләккә дә ирешергә мөмкин, имеш.

[57] *Кыямәт* – дини-мифологик категория: дөнья беткән көн. Мөселманнар ышануынча ахырзаман җитеп, Исрафил сурын өргәч, шул тавыштан барлык үлгән кешеләр дә тереләчәкләр һәм Аллаһ каршына килеп фани дөньядагы гамәлләре өчен җавап биреп, аның хөкеменә тартылалар. Кыямәт көне – барлык мөселманнар өчен дә иң куркыныч сынау көне. Чөнки кешенең бу дөньядагы тормышы “вакытлыча гына”. Аның мәңгелек гомере үлгәч, Ахирәттә башланачак. Ул мәңгелек гомернең нинди булуы әнә шул кыямәт көнне ачыклана да инде. Ул көнне һәркемгә үзе кылганнары өчен Аллаһ хөкеме белән Җәннәт яки Җәһәннәм булачак, ягъни кеше оҗмахка яки тәмугка эләгәчәк.

[58] *Исрафил сурын өрәчәк...* – ахырзаман җиткәнне белдереп, Исрафил сурын (зур боргы) өреп бик куркыныч, каты аваз салачак, имеш. Шунда барлык мөэминнәр терелеп, гарасат мәйданына, Аллаһ хозурына җыйналачаклар.

[59] *Сыйрат* – мөселманнар ышануы буенча җәһәннәм уты өстеннән

оҗмахка үтә торган кылдан нечкә, кылычтан үткен күпер.

[60] *Маркслар, Энгельслар* ... Карл Маркс (1818-1883), Фридрих Энгельс (1820-1895) – немец философлары, җир йөзендә социаль тигезлек, гадел җәмгыять строе урнаштыру турындагы хыялый теория тарафдарлары. Фәнни коммунизм идеясен нигезләүчеләр. Җәмгыять үсешен өйрәнүдә диалектик-материализм методына нигезләнәләр. Фәлсәфи һәм икътисадый теориягә таянып революцион пролетариат хәрәкәтенең нигез программасын эшләүчеләр һәм бу хәрәкәтнең җитәкчеләре.

Капитализмнан социализм строена күчүнең төп шарты итеп, сәяси властьне пролитариат үз кулына алып, пролетариат диктатурасы оештырырга һәм җәмгыятьне революцион юл белән үзгәртеп корырга тиеш дип саныйлар.

[61] "*Тәрҗеман*" – 1883-1918 елларда Кырымда Бакчасарай шәһәрендә чыккан беренче милли газета. Ул Россия җирлегендә барлык төрки халыклар арасында да таралган. Нашире һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспринский (1851-1914). Газета 1905 елга кадәр гомумтөрки һәм рус телләрендә, аннан соң гомумтөрки телдә генә чыга.

Ул заманда татар язучылары (шул исәптән Г.Ибраһимов та) бу газетаны тоткан юлы һәм чуар теле өчен тәнкыйть итәләр.

[62] *... карт милләтче Исмәгыйль баба* – Исмәгыйль Гаспринский (1851-1914), фикер иясе, педагог, журналист. "Тәрҗемен" газетасының нашире, оештуручысы һәм мөхәррире. Җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. "Мөселман иттифакы" партиясе җитәкчеләренең берсе буларак, И.Гаспринский "Тәрҗеман" газетасы аша эшчеләрне сыйнфый көрәштән читләшергә, мөселманнарга сәясәттә кайсы юлны тотарга, кайсы телдә сөйләшергә кирәклеген пропагандалый. Г.Ибраһимов биредә шушы якка да ишарәли кебек.

[63] *Налей, товарищ!..* – Бөек Октябрь революциясенә чаклы яшьләр арасында киң таралган табын җырының беренче сүзләре.

[64] *... «иске ревиз», «яңа ревиз»...* «иске ревизия», «яңа ревизия». Ревизия – XVIII-XIX гасырларда Россиядә җан башыннан налог түләргә һәм рекрут хезмәтен үтәргә тиешле кешеләрне ачыклар өчен халык санын исәпкә алу. 1881, 1887 елларда җир-суга, ә 1893 елдан башлап чәчү җирләренә ревизия ясала, ягъни аларның күләме исәпкә алына. Бу очракта әдип шуларны күз алдында тота.

[65] *"Иман шарты"* ("Шариат әл-иман") – мәдрәсәләрдә укырга, язарга өйрәнә башлаган балаларга бирелә торган беренче дәреслек – китап. Аның эчтәлеге моннан гыйбарәт: башта гарәп әлифбасы бирелә, аннары хәрефләрнең исемнәре, иҗекләрне уку күнегүләре, саннарны белдерү өчен кулланыла торган хәрефләр, гарәп телендә Аллага ышануны белдерә торган

догалар китерелә. Казанда 1874 елдан басыла башлый.

[66] *«Шәрхе Габдулла»* – Гыйззәтеддин Зәнҗанигә (1257 елда үлгән) нисбәт ителгән “Әл-Мугыйзза” исемле гарәп сарыфына (морфологиясенә) фарсы телендә шәрх (аңлатмалар) биргән грамматика дәреслеге; Идел буе җирлегенә аны Урта Азиядә укыган татар шәкертләре алып кайткан. Казанда күп мәртәбә басылган һәм кадим мәдрәсәләрдә дәреслек буларак укылган китап.

[67] *Әкъсами сәбга* – җиденче бүлек; ягъни «Шәрхе Габдулла»ның җиденче бүлеге.

[68] *«Гакаид»* – ислам дине кануннары, исламның терәкләре турындагы гарәпчә дәреслек. Авторы – Нәҗметдин Насафи (1068 – 1142).

[69] *... Коръән чыккан өчен ... – Коръән чыгу* – дини йола буенча: кемнең дә булса авыруын дәвалау яки гөнаһларын ярлыкау, бетерү йөзеннән берәр руханиның Коръәнне тулысынча укып чыгуы.

[70] *Кропоткин* – Кропоткин П.А. (1842 – 1921), анархизм эшлеклеләренең һәм теоретикларының берсе; географ һәм сәяхәтче.

[71] *Бакунин* – Бакунин М.А. (1814-1876), рус революционеры, анархизм идеологларының берсе.

[72] *Романовлар монархиясе* – 1613 елдан башлап 1917 елга кадәр Россия дәүләте Романовлар династиясе монархиясе идарәсендә була. Бу династиядән беренче патша Михаил Федорович Романов (1596-1645) – Земский Собор тарафыннан сайланып куела. Россия империясе белән хакимлек иткән соңгы патша Николай Александрович Романов (Николай II).

[73] *«Тоткын»* – «Узник», А. С. Пушкин шигыре.

[74] *Шлиссельбург крепосте ...* – хәзерге Ленинград өлкәсенә керә торган Шлиссельбург шәһәренә каршы Балтыйк диңгезенә урнашкан Орехов утравындагы борынгы рус крепосте. Төньяк-көнбатыштагы чикләрне саклар өчен хәрби ныгытма буларак 1323 елда аңа Александр Невскийның оныгы князь Юрий Данилович нигез салган һәм ул Орехов крепосте дип аталган. 1612 елдан 1702 елга кадәр бу крепость шведлар кулында була. 1702 елда рус-швед сугышы вакытында Петр I крепостьне яңадан Россиягә кайтара. һәм Шлиссельбург (ачкыч-шәһәр) крепосте дип исем бирә.

1703 елда Кронштад төзелгәч, Шлиссельбург крепосте үзенең хәрби әһәмиятен югалта һәм сәяси тоткыннарны яба торган каты режимлы зинданга әйләндерелә. Биредә үз иманнарына турылыклы тоткыннардан М.А.Романова, декабристлардан бертуган Бестужевлар, А.И.Ульянов, каһарман көрәшче Батырша һ.б. ябылып тотыла. 1949 елдан соң гына Шлиссельбург крепосте архитектура һәйкәле буларак игълан ителә. 1985 елдан инде хәрәбә хәленә җиткән бу крепость мемориаль музей статусын ала.

[75] *Бохара бикасабы* – Урта Азиядә бик популяр булган ярым ефәк затлы тукымадан тегелгән халатсыман хатын-кыз киеме.

[76] *Әхмәт бай* – Әхмәт Хөсәенов (1838 – 1906), Оренбургтагы эре сәүдәгәр, миллионер, меценат, милләтнең мәгърифәтенә әһәмият биреп, мәчетләр, мәдрәсәләр төзүгә, укытучы-мөгаллимнәр әзерләүгә күп акча тота. Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсен салдырып, аның материаль ягын тәэмин иткән кеше.

[77] *Мөхәммәдкә вәхи белән килгән Җәбраил ...* – мөселман мифологиясе буенча Җәбраил Аллаһка иң якын торган дүрт фәрештәнең берсе. Аңа Аллаһтан пәйгамбәрләргә вәхи (хәбәр) китерү йөкләнгән. Аны “вәхи фәрештәсе” дип тә йөртәләр. Аллаһы Тәгалә кушуы буенча Җәбраил Мөхәммәд пәйгамбәргә изге Коръән текстларын җиткерү өчен күктән иңә. Коръән сүрәләрен өлешләп-өлешләп пәйгамбәрнең күңеленә сеңдерә. Мөхәммәд соңыннан аны үзенең өммәтенә җиткерә, игълан итә.

[78] *Ницше фәлсәфәсе* – Фридрих Ницше (1844 – 1900), немец философы, идеалист, фашизм идеологиясен башлап җибәрүчеләрнең берсе. Аның дөньяга карашы революцион рухка каршы юнәлтелгән һәм халыкка дошманлык хисе белән сугарылган.

[79] *...Өченче съезд карары...* – РСДРПның III съезды иске стиль белән 1905 елның 12 – 27 апрелендә, Лондонда, В.И.Ленин җитәкчелегендә үткәрелә, һәм анда кораллы восстание турында карар кабул ителә; патша самодержавиесенә каршы бөтенхалык кораллы восстаниесен әзерләү, оештыру һәм аны тормышка ашыру партиянең кичектерелмәс бурычы икәнен басым ясап әйтелә.

[80] *«Үткән төндә җитмеш кешелек бер төркем халык...»* дип башланган текст В.И.Ленинның “От обороны к нападению” («Оборонадан һөҗүмгә») исемле мәкаләсеннән тәрҗемә итеп алынган (Оригиналы: Ленин В.И. “Полное собрание сочинений”. Издание 5-ое: в 55 томах. – Т. XI. – М., 1958, - С. 268).

[81] *«...Проповедники должны давать отрядам...»* дип башланган текст В.И. Ленинның 1905 елның 29(16) октябрендә “В Боевой комитет при Санкт-Петербургском комитете” («Санкт-Петербург Комитеты янындагы Сугышчан Комитетка») язган хатыннан алынган (Оригиналы: Ленин В.И. “Полное собрание сочинений”. Издание 5-ое: в 55 томах. – Т. XI. – М., 1958. – С. 316-317).

[82] *«Пролетарий»* – Женевада В.И.Ленин редакторлыгында чыккан атналык, яшерен большевистик газета. 1905 елның 14(27) маеннан 12(25) ноябренә чаклы дәвам итә; барлыгы 26 номер чыга.

[83] *Петербургта эшче депутатлары Советы* – 1905 елның 13 октябрендә,

революцион хәрәкәтнең көчәйгән көннәрендә төзелә; башта депутатлар Советы эшчеләр сыйныфының стачка көрәшләренә җитәкчелек итү органы булып барлыкка килә һәм тора-бара яңа революцион властьның – пролетариат диктатурасының башлангыч органына әверелә. Соңыннан, 1905-1907 еллардагы революция хәрәкәте мылтыклар, туплар белән бастырылгач, патша хөкүмәте тарафыннан таратыла, җитәкчеләре кулга алына.

[84] *9 нчы гыйнвар вакыйгалары...* – 1905 елдагы «Канлы якшәмбе» вакыйгалары; ул көнне патша хөкүмәте патша сарае янына петиция (үтенеч) белән барган Петербург эшчеләре демонстрациясен аттыра.

[85] *Япон сугышы* – 1904-1905 еллардагы рус – япон сугышы; Ерак көнчыгышта хакимлек итү өчен барган империалистик сугыш.

[86] *Романовлар тәхете...* 72 нче искәрмәне карагыз.

[87] *Николай кулында палач, гаскәр, туп, мылтык* – Романов Николай Александрович (1868 – 1918), 1894 – 1917 елларда Россия дәүләте императоры (Николай II). 1917 елның 2 мартында Россия тәхетеннән баш тарта. Аның идарәсе вакытында илдә сәяси каршылыклар (1905-1907 еллардагы революцион хәрәкәт һәм 1917 елгы Февраль революциясе), кораллы бәрелешләр, террор, репрессияләр дәвам итә: Россия Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Россиянең соңгы императоры Николай II 1918 елның июлендә Екатеринбург шәһәрендә, гаиләсе белән бергә, большевиклар тарафыннан атып үтерелә.

[88] *Столыпин* –Столыпин П.А. (1862 – 1911), патша Россиясендә дәүләт эшлеклесе, 1906-1911 елларда эчке эшләр министры һәм шул ук вакытта Министрлар советы председателе. XX гасыр башында Россия тарихында, беренче чиратта, реформатор буларак танылa. Илнең икътисадын күтәрү юлында әһәмиятле реформалар үткәрә. Авылда аграр реформа үткәреп, кулак хуҗалыкларын ныгытучы, шул ук вакытта революция хәрәкәтен кан эчендә бастыручы да ул. Тарихта диктаторлыгы, кансызлыгы, эшчеләр сыйныфына, ярлы һәм урта хәлле крестьяннарга каршы алып барган терроры, репрессияләре белән мәгълүм.

[89] *Таврический дворец* – Петербургта 1906 – 1917 елларда Дәүләт думасы урнашкан бина.

[90] *...Кәримевләр типографиясе...* – Бөек Октябрь революциясенә чаклы Казанда татарча, гарәпчә, фарсыча китаплар басу белән шөгыльләнгән иң зур типографияләрнең берсе. Китап басу эшен 1885 елдан алып 1919 елга хәтле дәвам иттергән.

[91] *Екатеринский урамы...* – Казанда хәзерге Тукай урамының көнчыгыш башы.

[92] *Беренче Интернационал* – пролетариатның беренче халыкара

революцион оешмасы (халыкара Товариществосы). Эшчеләр хәрәкәте тарихында беренче булган бу оешманы 1864 елда Лондонда К.Маркс оештыра һәм аңа җитәкчелек итә.

[93] *Прудон – Пьер Жозеф Прудон* (1809 – 1865), француз вак буржуаз социалисты; марксизмның дошманы булган вак буржуаз социализм һәм анархизм хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе.

[94] *Герцен* – Герцен А.И. (1812-1870), рус язучысы, публицист, философ. Н.П.Огарев белән берлектә “Колокол” дигән беренче рус революцон газетасын оетыра. Газетаның нашире дә, төп язучысы да Герцен була. “Колокол” Парижда чыга башлап бөтен Европада һәм легаль булмаган юллар белән Россиядә дә тарала.

Герцен – Гегель, Белинский карашларын яклаучы революцион-демократ.

[95] *Михайловский аркылы Черновка – Гершуниларга... –*

*Н.К.Михайловский* (1842-1904) – либераль народниклар идеологы, социолог, публицист.

*В.М.Чернов* (1876-1952) – эсерлар партиясенең лидерларыннан һәм теоретикларыннан берсе, партия программасының авторы. Октябрь революциясеннән соң Совет властена каршы актив көрәшкән кеше.

*Г.А.Гершуни* (1870-1908) – эсерлар партиясен оештыручылардан һәм аның лидерларыннан берсе; шул партиянең ҮК члены.

[96] *Мәскәүдә декабрь кораллы күтәрелешен кан эчендә бастылар...* – 1905 елның 9-18 декабрендә Мәскәү эшчеләре патша гаскәрләренә каршы баррикадалар корып сугышалар. Бу сугышларда сигез меңгә якын эшче дружинник катнаша. Мондый кораллы күтәрелешләр шулай ук Красноярск, Новороссийск, Казан, Сормово, Кронштадт, Чита, Мотовилиха һәм башка шәһәрләрдә дә була. Барысы да патша гаскәрләре тарафыннан кан эчендә бастырыла.

[97] *Инде Думаны да кудылар...* – 1906-1907 елларда патша хөкүмәте I һәм II Думаны куа, тарата. Бу урында сүз, 1907 елның 20 февралендә чакырылып, 3 июнендә куылган II Дума турында бара.

[98] *Думаны да куалар... социал-демократия фракциясен кулга алып, хөкемгә бирәләр...* – патша хөкүмәте II Думаны тарата һәм андагы социал-демократлар фракциясен – барлыгы 65 кешене кулга алып судка бирә, Себергә сөрә.

[99] *Аугуст Бебель* (1840 – 1913) – Германия социал-демократлар партиясен һәм II Интернационалны оештыручыларның берсе В.И.Ленин Аугуст Бебельнең бөтендөнья эшчеләр хәрәкәтендәге зур хезмәтләрен, бигрәк тә иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенең беренче чорында, К.Маркс һәм Ф.Энгельс тәгълиматлары тәэсирендә эшләгән чактагы хезмәтләрен билгеләп үтә.

[100] *Каутский* – Карл Каутский (1854-1938), Германия социал-демократлар партиясе һәм II Интернационал җитәкчеләреннән берсе, марксизмга хыянәт иткән кеше, уң социалистларның идея остазы һәм аңа юл башлап җибәрүче.

[101] *Партиянең өченче съезды булдымы? Анда кораллы күтәрелеш турында нинди карар бар? Бу турыда Ленин нәрсә язды?* – Сүз В.И.Ленинның өченче съезддан соң язылган «Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы» исемле мәшһүр китабы турында бара. Бу әсәрендә ул съезд карарларын фәнни нигезләп, аңлатып бирә, аларның әһәмиятен ассызымлап күрсәтә, партиянең стратегик планын һәм тактик линиясен тагын да ачыклый төшә, меньшевиклар тактикасын үтергеч рәвештә тәнкыйтьли.

[102] *«Урал»* – татар телендә чыккан беренче большевистик газета Беренче саны 1907 елның 4 гыйнварында чыга. Барлыгы 31 сан чыккач, 1907 елның 27 апрелендә патша хөкүмәте тарафыннан туктатыла. Редакторы – Хөсәен Ямашев.

[103] *«Бәянел-хак»* – 1906-1914 елларда Казанда татар телендә чыккан, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Динне һәм милләтчеләрне яклый. Эчтәлегендә халыкның мәдәни томышы, милли традицияләре, театр, музыка һәм әдәбият яңалыклары яктыртыла.

[104] *«Йолдыз»* – иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1906 елның 15 гыйнварыннан -1918 елның 21 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Газетада Россия һәм мөселман илләре турында фәнни-популяр мәкаләләр, иҗтимагый-сәяси тормышны яктырткан аналитик мәкаләләр басыла. Мәгариф, укыту, тәрбия мәсьәләләре яктыртыла һ.б.

“Йолдыз” революциягә кадәрге татар басмалары арасында иң абруйлы, тотрыклы газеталарның берсе итеп санала. Россиянең татарлар яшәгән күп төбәкләрендә тарала.

[105] *«Вакыт»* – 1906-1918 елларда Оренбургта татар телендә чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Биредә Россия һәм чит ил хәбәрләре, дини һәм милли мәсьәләләр яктыртыла. “Вакыт” битләрендә әдәбият, тел, музыка, театр, мәгариф, мөселман хатын-кызларының гаиләдәге роле һ.б. багышланган мәкаләләргә урын бирелә. Үз заманында барлык татар матбугатына үрнәк булып тора. “Вакыт” Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә тарала.

[106] *Коковцев* – В.Н.Коковцев (1858-1926), патша хөкүмәтенең күренекле чиновнигы, 1906-1914 елларда финанс министры; 1911-1914 елларда шул ук вакыт Министрлар советы председателе дә; хөкүмәтнең финанс һәм бюджет мәсьәләләрен тикшергәндә Дәүләт думасының хокукларын чикләү өчен көрәш алып барган кеше. «Доходлы урын чиновнигы Коковцев Думада,

барыннан да бигрәк, доходсыз урын чиновникларыннан Шингарев һәм Аджемов белән бәхәсләште»[*]. Романда сүз шушы бәхәс турында бара.

[107] *Шингарев* – А. И. Шингарев (1869 – 1918), 11,111 һәм IV Дәүләт Думасы депутаты; кадетлар фракциясе җитәкчесе. Думадагы бюджет һәм азык-төлек комиссияләренең члены.

[108] *... 1907 нче ел өченче июньнең законы...* – патша хөкүмәте II Дәүләт думасын куганнан соң, сайлаулар турында яңа закон чыгара; эшче-крестьяннарның сайлау хокукларын тагын да кыса төшә, шул ук вакытта алпавытларның һәм сәүдә-сәнәгать буржуазиясенең хокукларын бик күп арттыра. Бу закон нигезендә эшчеләр һәм крестьяннарның Думадагы вәкилләре электәгегә караганда берничә мәртәбә кими.

[109] *Ультиматист-отзовист* – 1908 елны большевиклар партиясе сафында барлыкка килгән оппортунистик вак буржуаз агымны яклаучы кеше.

Отзовистлар Дәүләт Думасындагы социал-демократлар фракциясен кире чакырып алуны һәм профсоюзларда, башка шуның кебек легаль оешмаларда эшләмәүне таләп итәләр. Отзовистларның икенче бер төре булган ультиматистлар исә, башта Дәүләт Думасындагы социал-демократлар фракциясенә: революционерлар карагруһчы Думада эшләргә тиеш түгел, – дип, ультиматум бирергә, әгәр ул үтәлмәсә, фракцияне аннан кире чакырып алырга тәкъдим итәләр.

[110] *Богостроитель* – Россиядә 1905-1907 еллардагы революция җиңелгәннән соң, кайбер социал-демократлар арасында туган реакцион дини-фәлсәфи карашны яклаучы кеше. Алар, марксизм белән динне бергә кушып, яңа «социалистик» дин булдырырга маташалар.

[111] *«Мохтасар», «Фәраиз», «Һидая»* – кадим мәдрәсәләрдәге дәреслекләр. «Мохтасар» белән «Фәраиз» ислам диненең юридик законнарын өйрәтүгә, ә «Һидая» мирас бүлү кагыйдәләрен аңлатып бирүгә багышланган.

[112] *... «Латин – Юлий Цезарь»ны ятларга тотынды... –*

*Юлий Цезарь (безнең эрага кадәр 100-44)* – Рим империясенең атаклы дәүләт эшлеклесе, гаскәр башлыгы, язучы, оратор. Аның «Галлия сугышы турындагы язмалар» һәм «Гражданнар сугышы турындагы язмалар» исемле әсәрләре патша Россиясе заманында гимназияләрдә латин теле дәреслекләре буларак кулланылып йөртелгән.

[113] *Евно Азеф* (1869-1918) – провокатор, эсерлар партиясенең һәм аның «сугышчан оешмасы»ның җитәкчеләреннән берсе. Полиция департаментының яшерен сотруднигы.

[114] *«Заратустра»* – немец философы Фридрих Ницшеның (78 нче

---

[*] Ленин В. И. Әсәрләр / рус телендә, 4 нче басма. – Т. XIII. – Б. 400.

искәрмәне кара) «Заратустра шулай әйтте» исемле китабы. Бу әсәрендә ул «башкалардан югары булган» кеше образын дөньяда булмаганча идеаллаштырып, һәр яктан камил, батыр, кыю итеп тасвирлый. Аның уенча, шундый кешеләр капитализмны һәлакәттән коткарып калырга тиешләр. «Башкалардан югары булган» бу кешенең чын йөзе философның икенче әсәрләрендә тагын да ачыла төшә. Ул анда кыргый, явыз инстинктлар белән сугарылган, шуңа җаны-тәне белән бирелгән яңа варварга әверелә.

[115] *... Мефистофельчә көлеп...* – явыз көлеп.

*Мефистофель* – кайбер халыкларның фольклорында һәм әдәбиятында кешеләрне аздыручы, юлдан яздыручы, явыз рухларның берсе, иблис, шайтан, җен, пәри, Газазил. Әдәбиятта бигрәк тә В. Гетеның мәшһүр «Фауст» драматик поэмасы персонажы буларак билгеле.

[116] *Рикло (Реклю)* – Жан Жак Элизе Реклю (1830 – 1905), француз галиме; 1848 елгы революциядә һәм Париж Коммунасында катнашкан кеше. Аның социологик карашлары «Эволюция, революция һәм анархизм идеалы» исемле әсәрендә ачык чагылган.

[117] *Вы жертвою пали в борьбе роковой...* – «Матәм маршы»ның беренче юлы; 1905 елдан соң революцион эшчеләр арасында аеруча киң таралган матәм җыры. Текстның авторы В.Г.Архангельский. 1900 елда язылган.

[118] *Башкиров* – Шаһвәли Гали улы Башкиров (1894-1942), 1919 елдан КПСС члены; «Безнең көннәр» романының икенче басмасы чыкканда Татгосиздат (Татарстан китап нәшрияты) директоры була.

[119] *Кави Нәҗми* (1901-1957) – татар совет язучысы, Дәүләт премиясе лауреаты; 1919 елдан КПСС члены. «Безнең көннәр»нең икенче варианты типографиягә бирелгәндә Татарстан Совет язучылары Оештыру комитетының җаваплы секретаре була.

[120] *... учредилканы ташлап...* – Г. Ибраһимов 1917 елның ноябрендә Уфа губернасыннан Учредительное собраниегә депутат булып сайлана һәм 1918 елның 5(18) январенда, Петроградта, Учредительное собрание утырышын «сул канат составында»* ташлап чыга.

[121] *...ВЦИКта әгъза...* – Г. Ибраһимов 1918 елның январенда, Советларның Өченче съездында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына член булып сайлана.

[122] *... комиссариатлар төзешеп...* – Мөселман эшләре комиссариатлары төзешеп.

[123] *Бу арада вакытлы барып, Уфада эшләү...* – Әдип 1918 елның җәендә Татар-башкорт Совет Социалистик Республикасын оештыру эшләре белән

---

* Ибраһимов Г. Автобиография// «Казан утлары», 1967, 2 сан. – Б. 10.

Мәскәүдән Уфага һәм Казанга командировкага җибәрелә. Бу урында сүз шул турыда бара.

[124] *Толстойчылык* – Л.Н.Толстойның фәлсәфи тәгълиматы. Толстой хезмәт ияләрен изүгә, аларны эксплуатацияләүгә корылган самодержавиене, аның дәүләт төзелешен, иҗтимагый-икътисадый тәртипләрен, гадел булмаган патша судын, динне, хаким сыйныфларны, буржуазиянең черек моралей һәм башка шуның кебекләрне ачы, каты тәнкыйтьли, фаш итә. Шуның белән бергә ул, самодержавие дәүләтенә, аның полициясенә, крепостной режимына каршы көрәшәсе урында, «явызлыкка каршы явызлык эшләмәскә» өнди, политикадан, революциядән баш тартырга, үз-үзеңне камилләштерергә чакыра; иске динне яңа дин белән алыштырырга кирәк таба. Толстой эшчеләр хәрәкәтенең әһәмиятен, мәгънәсен, революцияне тудыручы сәбәпләрне һәм революциянең булмыйча калуы мөмкин түгеллеген аңлый алмый. «Толстойчылык» – революцион хәрәкәткә зур зарар китергән утопик һәм реакцион тәгълимат.